Габдулла
# ТУКАЙ



ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ

В двух томах

Том 2

Статьи, воспоминания, письма

Казань
Татарское книжное издательство
2006

Габдулла
# ТУКАЙ



САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

Ике томда

2 том

Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2006

УДК 821.512.145–3
ББК 84(2Рос=Тат)–4
Т72

Томны төзүчеләр:
*Эльмера Галимҗанова, Заһир Шәйхелисламов, Зөфәр Рәмиев*

Искәрмәләр белән аңлатмаларны әзерләүче һәм
җаваплы мөхәррир *Зөфәр Рәмиев*

**Тукай Г.**

Т72 Сайланма әсәрләр: 2 томда / Габдулла Тукай. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5–298–03927–8

2 т.: Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / Төз.: Э.Галимҗанова, З.Шәйхелисламов, З.Рәмиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 383 б.

ISBN 5–298–03929–4

ISBN 5–298–03929–4(2 т.)
ISBN 5–298–03927–8

© Татарстан китап нәшрияты, 2006



# 1906

## КЫЯМӘТ КӨНЕ

Бу нинди йөрәкләрне тетрәтә торган тавыш икән? Сур мөгезеннән[1]* чыккан аваз һәр җакларда яңгырап, төшсез чикләвек шикелле, кешесез вәйран калган таш пулатлар, биек сарайлар, һәрберсе бер сур булып, чын сур илә җаваплашалар. Яшеннәр — һәлакәт вә хәраблык камчылары — баягы тавыштан әллә ни төсле булып үзгәргән һаваларда ялт-йолт ялтырамакта...

Аһ, Ярабби, бу төсләре бозылган һавалар, бу, чынҗырдан ычкынган төсле, бер-берсенә һөҗүм иткән җилләр җир балаларына яратылмышларының актык минуты җиткәнен хәбәр бирәмени? Сурның ачулы вә каһәрле нәгъръсеннән асты өстенә килгән мөхит диңгезе үзенең ярларыннан ачу илә атылып чыкмыш. Дөньяны куркынычлы тавышлар илә шаулатып, ул тау-тау дулкыннарны гяһ вакытта үзенә тартырга, күтәрергә гадәтләнгән күкләр илә сугышырга бара микән? Инде эш үтте, булачаклар булды! Бер хикмәт өчен генә яшеренлеге бәгъзе кяферләрнең көференә сәбәп булган Тәңремез мәгънәви яшерен җирдән тәмам заһир була башлады... Менә күренде... Шик-шөбһәсез — үзе!.. Каһһар сыйфатындагы каһәре илә яратылмышларны асты өстенә китерә икән.

Адәмнәр, тетрәңез, тетрик! Менә хакимнәр хакиме вә судьяләр судьясенең мәхкәмәсе: монда камил гаделлек вә тигезлек бардыр. Бу җирдә растлык иясе, хәкыйкать сахибе сезнең явызлыкларыңызны эченә алмыш дәфтәреңезне үз кулы илә әшкярә итәр — күрсәтер. Бервакытны шәфкатьле анаңыздан да йомшак булган дин хәзер бер тимер күңел илә үзенең көфра-

---

* Саннар белән күрсәтелгән искәрмәләрне 344–378 битләрән кара. (*Ред. искәрмәсе.*)

*Нәгъръ* — каты, гайрәтле тавыш.

*Мөхит диңгезе* — океан.

*Гяһ вакытта* — кайвакытта.

*Бәгъзе кяферләрнең көференә* — Аллага ышанмаучы кайберәүләрнең Аллага ышанмавына.

*Заһир булу* — күренү.

*Каһһар* — каһәрләүче, тиран.

*Хакимнәр хакиме* — иң югары (верховный) хаким, хөкемдар мәгънәсендә.

*Мәхкәмә* — хөкем урыны.

*Сахиб* — ия.

не нигъмәт иткән балаларына каршы дошманлык күрсәтәдер. И үлекләрнең рухлары!? Күп заманнардан бирле яшеренеп йоклаган җиреңездән чыгып, һәммәңез бер урынга җыелыңыз; әүвәлге тәннәреңез илә гарәсат мәйданына[2] килеңез. Сезне Раббел галәмин хәзрәте чакырды! Бөтен үлекләр, берьюлы уянып, бу көнгә чаклы яткан караңгылыктан чыгарлар; төсләре бозылган, чәһрәләре очкан, өстләреннән кабер туфрагының ягылып калганнары коела-коела, бик куркып кына, рәтсез-тәртипсез бер сурәттә Аллаһы Тәгалә хозурына киләләр.

И җир, синдә, синең куеныңда ничә төрле кавемнәр бардыр? Мөхәммәди, дәһри, гыйсави, мусави — җөмләсе бер Алланың хозурында җыелалар вә җыелачаклардыр. Ни хәсрәтле хәлләр, ни ялкынлы аһ-ваһлар!

Ярабби, бу көн җәза мәйданына чыгарылган гөнаһлыларның исәбен-хисабын кем белер? Монда ялганчылар, гамәл сатып ашаучылар, шәкертләр хакын ашаучы муллалар, үзләре яхшы аңлап җитмәгән нәрсәне балаларга укытып, ислам балаларының гомерен ашаган хәлфәләр, милләтне ялкауландырып, фәкыйрьләндереп зәһәрләгән ишаннар — тәрәкъкыйгә дошманнар, барлык һиммәтләрен, һәммә гайрәтләрен трахтирларда, мәйханәләрдә генә күрсәткән байлар, халыкны һәртөрле чирмеш, керәшен сүзләренә Коръәннән артык иман китерткән карчыклар, өшкерүчетөкерүчеләр, — һичберенең үз башын коткарырга чарасы булмаганлыктан, бер-берсеннән ярдәм теләргә мәҗбүр булырлар. Әйнәл-мәфәр? Качсаңыз да кайда качарсыз? Кайда барсаңыз да, бер нәзары интикам (үч алу күз карашы) сезгә төшәр. Борынгы олугълыкларыңыз кая китте? Сезнең алданып торган дарел-горурыңыз бетте — хәзер һәр җирдә һәркем һәр яктан тигездер.

И явызлар! Монда килеңез. Ничә йөз, ничә мең еллардан бирле көтелгән җәза таңы атты. Динне хурладыгыз, мөселманлыктан көлдеңез! Галимнәрне танымадыңыз. Тугъры сөйләгәннәрне кыстыңыз, издеңез. Шәкертләрне иң түбән телән-

---

*Көфране нигъмәт иту* — яхшылыкның кадерен белмәү.
*Раббел галәмин* — Алланың эпитеты, Галәмнең хуҗасы дигән сүз.
*Чәһрә* — йөз нуры.
*Хозурына* — каршына.
*Мөхәммәди* — Мөхәммәт пәйгамбәр иярченнәре (мөселманнар).
*Дәһри* — дингә, Аллага ышанмаучы.
*Гыйсави* — Гайса пәйгамбәр иярченнәре (христианнар).
*Мусави* — Муса пәйгамбәр иярченнәре (яһүдләр).
*Гамәл сатып* — хезмәт, эш биреп (кешене эшләтеп).
*Һиммәт* — юмартлык, булышучанлык.
*Әйнәл-мәфәр?* — Кача торган урын кайда?
*Дарел-горур* — горурлык йорты (дөнья).

чедән дә яман күрдеңез... Алла гафилмени? Җавап бирeңез! Нигә җылаган булып торабыз?.. Бушка җыламаңыз! Монда сезне кызганучы юк... Сезнең мышкылдап, мышык-мышык җылавыңыз мондагыларны көлдерүдән башкага ярамыйдыр. Ходай сезне Газраил тырнагына тапшырмыш иде. Инде сездән җәһәннәмдә өлешен (хиссасын) сорыйдыр. Алланың сөйгән колларының, ягъни дөньяда вакытта кул берләме, тел берләме дине исламның, милләте мөхәммәдиянең алга баруына тырышучылар, мәдрәсәләр-мәктәпләр салып та, шәкертләрне үзләренә габид ясамакны теләмәгән байлар, йөзләрендә шатлык нурлары балыккан хәлдә, һәр әгъзаларын бертөрле куаныч илә тибрәтеп, оҗмахка хурлар кочмакка, тел йотарлык ләззәтле ширбәтләр эчмәккә баралар. Ник бармасыннар? Кечкенә сабыйлар шәфкатьле аталары янына барудан куркынырлармы? Илаһи! Бу ни хәл? Бу, корт-кырмыскалар кеби, дөньяны каплаган адәмнәр эчендә әмерләренә буйсынып, максудка җиткәннәрне бик аз таптым. Вакытында җиһанны баскан гасый халыклар кая киткәннәр? Локомотивлар, балуннар вә башка һөнәр вә сәнәгатьләр илә дөньяны хәйран иткән француз, нәмсәләр, хәйлә-мөдаһинлек илә җир йөзен кайнаткан вә үзләренең политикаларына хилафрак дәүләтне батырган, бертөрле монафикълык илә башына җиткән инглизләр бу җирдә ни өчен хәйлә илә котылмыйлар вә, һиндлеләрне кылычтан кичереп, ачлык илә зәһәрләгәннәре шикелле, мондагы зобаниларга ник бер чара тапмыйлар икән?

## БЕЗНЕҢ МИЛЛӘТ ҮЛГӘНМЕ, ӘЛЛӘ ЙОКЛАГАН ГЫНАМЫ?

Һәртөрле мөхәррирләр вә ярты мөхәррирләр милләтемез үлгән вә яки йоклаган дип язалар. Вакыйгъдә безнең милләт үлгән үкме, әллә йоклаган гынамы? Әгәр милләтне йоклаган, дисәк, дөнья көпчәгенең бу кадәр дөбердәп әйләнүенә вә баш-

---

*Гафил* — хәбәрсез.
*Милләте мөхәммәдия* — Мөхәммәт милләте, аның тарафдарлары, мөселманнар.
*Габид* — баш июче, табынучы.
*Гасый* — гөнаһлы.
*Балун (баллон)* — аэростат.
*Сәнәгать* — һөнәрчелек, промышленность.
*Нәмсәләр* — немецлар.
*Мөдаһинлек* — икейөзлелек, хәйләкәрлек.
*Монафикълык* — икейөзлелек.
*Зобани* — тәмуг хезмәтчесе.
*Вакыйгъдә* — чынында.

ка милләтләрнең әллә нинди каты вә йөрәк яргыч тавышлауларына уянырга кирәк иде.

Чөнки йокының, әлбәттә, бер чиге булырга кирәк. Бәр тәкъдир милләтемез үлгән булса, без, үлгән милләтнең башы очында бер кәгазь кисәге булган гәзитәләр шытырдатып, аны уята алырмызмы? Болай булгач, безнең гәзитәләр укымакымыз үлгән милләт, рәхмәтуллаһи галәйһи рухына ясин шәриф укуга гына охшап калмазмы? Әллә милләтнең йокысы Гозәер пәйгамбәр йокысы[1] кеби микән? Әллә Мәксәлмина, Мәслина, Дөбернуш, Шаднуш, Кәфәштатыюшлар[2] йокысы кеби микән? Соң ничек икән?

Минем уемча, болай булырга кирәк: борын заманда безнең милләт, үзенең иптәшләре вә аркадашлары булган башка милләтләр илә, фәкыйрь генә, тыныч кына, күңелсез генә яшәгән. Берничә гасырлар безнең милләт алар илә казандаш һәм чәйдәш булып, барчасы бергә ачлы-туклы гына булса да, тыныч кына, тату гына гомер иткәннәр. Шулай тыныч кына торганда, ни хикмәттәндер, башка милләтләр, һәрберсе бер Сөләйман мөлкен[3] алып, үзләренә җилләрне, парларны, утларны, һаваларны хезмәтче иткәннәр; һәртөрле җан-җанвар, кош-кортларны мөсәххәр иткәннәр, хәтта тәхеткә утырып, күкләрдә очып, су төпләрендә балыклар илә бергә йөри башлаганнар. Безнең милләт, мискин, шул вакытта йоклаганмы, ни эшләгәндер, мин анысын белмим, ләкин безнең милләт баягы иптәшләренең кисәктән генә болай ук югары китүләренә тәкать тота алмаган, дәрхаль һушы китеп егылган; «Сагълүк» китабынча[4] әйтсәм, мөгаммә галәйһи булган. Менә шул ятудан безнең милләт һаман да ятадыр.

Соң, инде аны ничек һушына китерик?

Бу тугърыда минем фикре касыйрым болай дип әйтә: без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, гәзитә мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихад вә иттифакъ сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын; шундин соң бу вәгазьләрне сөйлик: «И бичара милләт, син ул иптәшләреңнән курыкма. Аларның хәленә исең

---

*Бәр тәкъдир* — әгәр.
*Мөсәххәр иту* — баш идерү.
*Дәрхаль* — кинәт.
*Мөгаммә галәйһи* — өртелгән, пәрдәләнгән.
*Фикре касыйрым* — кыска фикерем.
*Иттихад вә иттифакъ* — берләшү, бергәләп эшләү.

китмәсен; әгәр алар эшләгәнне эшләсәң, алар күргәнне күрсәң, алар белгәнне белсәң, син дә алар дәрәҗәсенә менә аласың; Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һичкемгә хас түгелдер, һәм бу галәм — галәмел-әсбабтыр. Һәм дә ялган сөйләмәси мөхаль вә мәмнугъ булган мөхбире садыйк әфәндемез дә: «Кеше тырышса, табар», — боермышлардыр. Тырышкан вә тырмашкан вакытларында синең бабаларың булган Бәгъдад вә Әндәлес[5] әһалисе бик каты тәрәкъкый иттеләр. Аларны күргәндә, башка милләтләр, синең кеби, һушлары китеп егылалар иде...»

Менә бу сүзләр илә милләтне җуатып, милләтнең һушы китеп, гакылсыз ятканда, милләтне ашаган, кабыргаларын тишкән оятсыз ак башлы каргаларны, кәкре башлы, яшел яки сары гәүдәле Бохара козгыннарыны[6] куып җибәрик. Тагы да ул кортлар вә ул козгыннарның милләтне ни рәвештә ашаганнарын рәссамнар хезмәте илә милләтнең үзенә күрсәтик, милләтне аларга каршы ачуландырыйк, чәчләрен аягүрә торгызыйк; борынгы кыйлган эшләре өчен милләт аларны аяк астына салып изсен, һич дөньяга килмәгән кеби итсен; каргаларны, муеныннан кысып, борынгы ашаганнарын карылдатып чыгарсын; шулай бит! Андин соң Бохара чапаны эченә төрелгән хәйләкәр төлкеләрне чапан җиңеннән өстерәп, күзге каршысына китерик; көзгегә каршы авызларын каерып ачыйк та, милләткә көзгедән канлы авызларын күрсәтик; милләт күрсен, ашаганнарына инансын, икенче мәртәбә та кыямәт алданмасын.

Бәс, безнең милләт үлмәгән дә, йокламаган да, һушы гына киткән. Мәзкүр рәвешләр илә һушына китерсәк, дуст кем, дошман кем — милләт үзе аерыр.

## ГРАФ ЛЕВ ТОЛСТОЙ ҖӘНАБЛӘРЕ ЯЗАДЫР

Уфа губернасында Ильяс исемле бер башкорт бар иде. Ильяс атасыннан бик зур байлык берлән калмаган иде. Ильясны өйләндергәч, бер елдан соңра атасы вафат итте. Ильясның шул вакыттагы милке 7 баш бия, 2 сыер һәм ике дистә куйдан гыйбарәт иде. Ләкин Ильяс дөньясын оныткан хуҗалар җөм-

---

*Галәм — галәмел-әсбабтыр* — дөнья — сәбәпләр дөньясы.
*Мөхаль вә мәмнугъ* — мөмкин булмаган һәм тыелган.
*Мөхбире Садыйк* — пәйгамбәр.
*Әһали* — халыклар.
*Та кыямәт* — мәңгегә, кыямәткәчә.
*Мәзкүр рәвешләр* — шул юллар, чаралар.

ләсеннән түгел иде. Ул хатыны берлән иртүк тора иде, тәмам эшләп аргач, соң гына йокларга ята иде. Һәм шул тырышулар аркасында Ильясның байлыгы көннән-көн артмакта иде. Шул рәвешчә тырыша-тырмаша торгач, 35 ел эчендә бик зур байлык ясады. Инде Ильясның атлары 200, мөгезле хайваннары 150, куйлары 1200 дәрәҗәләренә иреште. Көтүчеләр бу атлар, сыерларны көткән шикелле, хезмәтче хатыннар да сөт савып, кымыз, каймак, сары май кеби тәмле нәрсәләр ясыйлар иде. Ильясның һәр нәрсәсе ирешкән вә һәр кирәге җитешкән иде. Күрше-тирәдәге кешеләр Ильясның мондый бәхетле гомеренә көнләшәләр дә иде. Бәгъзе халык: «Ильяс бик бәхетле кеше, анда һәр нәрсә дә күп, аңа үлмәк тә тиеш түгел», — дип сөйлиләр иде. Бара-бара Ильясны зур-зур кешеләр дә таный башлап, Ильяс һәртөрле байлар илә дә йөрешә башлады. Ильяска ерак-ерак җирләрдән кунаклар килә иде. Һәр кунакка Ильясның өендә ит, шурпа, кымыз мөкәммәл иде. Кунак килә, бер куй йә ике куй суялар, әгәр кунаклар күбрәк килсә, бия дә суеп җибәрәләр иде. Сүз балалар ягына килсә, Ильясның ике угылы, бер кызы бар иде. Ильяс ике угылын өйләндереп, кызын кияүгә бирде. Ильясның ярлы вакытында угыллары хезмәт итәләр һәм Ильяс илә бергә мал да карыйлар иде. Әмма Ильяс баегач, угыллары аза башлап, берсе бөтенләй эчәргә салынды. Анысын бер исерекләр сугышында үлтерделәр. Икенчесенең хатыны тәкәббер тугъры килеп, угылы да, хатын сүзенә ияреп, атасына каршылык итә башлады. Шул сәбәпле Ильяска ул угылын аерып, башка чыгарырга тугъры килде. Ильяс угылын башка чыгарды, үзенә аерым йорт алып бирде һәм мөгезлесеннән, мөгезсезеннән маллар да бирде.

Билгеле инде, бу эш Ильясның байлыгын арттырмады, бәлки яхшы ук киметте. Шул ук вакытларда Ильясның куйларына бертөрле авыру төште. Бу авырудан күп куйлар үлде. Бер яктан, шул ел ачлык ел булып китте. Печән үсмәде. Кыш көне ачлыктан атлар, сыерлар үлә башладылар. Тагы да Ильясның яхшырак чабынлык җирләрен кыргызлар тартып алды. Шул рәвешчә Ильясның байлыгы җылдан-җылга кими бара иде.

Бичара Ильяс һаман түбәннән-түбәнгә төшә барган шикелле, икенче яктан, картлык килгәнлектән, көче дә азая бара иде. Ильяс, 70 яшьләренә җиткәндә, шулкадәр начар хәлгә калды ки, хәтта туннарын, киез өйләрен, паласларын, иярләрен сатарга тотынып, иң ахырда актык атын да сатты. Ниһаять, Ильяс бөтенләй юкка әверелде, бу рәвештә шаулап торган мал-мөлкәт урынына тик «юк» дигән сүз калганын Ильяс күрми дә калды.

---

*Җөмләсеннән* — исәбеннән.

һәм Ильяска, үзе генә тормак мөмкин булмагач, кешегә хезмәткә керергә тугъры килде. Ильясның калган малы тик өстендә бер бишмәт (ма яҗүзе галәйһи итлакыль-бишмәт), башында мәгълүм кәләпүш илә теге бүрек, аягында үзеңез белгән читек илә мәшһүр кәвеш һәм хатыны Шәмсемаһи иде. Ул да карчык иде. Аерылып чыккан угылы да әллә кая ерак җиргә киткән, кияүгә биргән кызы үлгән иде. Карт берлән карчыкка һичбер яктан ярдәм әсәре күренми иде. Шулай да карт берлә карчыкны күршедәге Мөхәммәтшаһ кызганды. Мөхәммәтшаһ үзе бай да түгел, ярлы да түгел. Үзенекен ычкындырмый, кешенекен эләктерми, чибәр генә көн күрә иде. Мөхәммәтшаһ, Ильясның борынгы икмәк-тозын исенә төшереп, Ильяска: «Ильяс бабай! Сез карчыгың берлән миңа торырга килеңез, җәй көне, хәлеңездән килгәнчә, бакчаларымда хезмәт итәрсез, кыш көне мал ашатырсыз, Шәмсемаһи да сыерларымны, бияләремне савар, кымыз, каймак ясар. Мин сезнең икеңезне дә ач та итмәм, ялангач та итмәм», — диде. Ильяс ни эшләсен, Мөхәммәтшаһка рәхмәт укыды да, карчыгы берлән җитәкләшеп, шуларга торырга керде.

Баштарак бик авыр күренсә дә, бара-бара гадәтләнеп, карт белән карчык Мөхәммәтшаһларда тора һәм кадәри хәл хезмәт итә башладылар. Хуҗага бик уңгай иде. Чөнки бу карт берлән карчык йорт тоту тәртипләрен бик яхшы беләләр һәм бер дә иренмиләр, көчтән килгән хезмәтне дә кызганмыйлар иде. Тик шунысы бар иде: Мөхәммәтшаһ шундый югары дәрәҗәдәге кешеләрнең болай түбән эштә йөргәннәрен күрәсе килми иде. Күргән саен вөҗданы газаплана иде.

Берзаман боларга ерак җирдән кунаклар килде. Кунаклар арасында бер мулла да килгән иде. Мөхәммәтшаһ Ильяска бер куй суярга кушты. Ильяс суйды, яхшылап пешерде, шурпалап, кунакларга китерде. Кунаклар ит ашадылар, иттән соң чәй эчкәч, кымызга керештеләр. Кунаклар мамык мендәр өстендә генә утыралар, ашыйлар, кымыз эчәләр, кәефләнәләр. Шул арада ничектер кунаклар алдындин Ильяс үтеп китте. Мөхәммәтшаһ, моны күргәч, бер кунакка карап: «Син бу картны күрдеңме?»

Кунак: «Күрдем, ул картта ни гаҗәп бар?»

Мөхәммәтшаһ: «Анда гаҗәп шул: ул безнең авылның Ильяс исемле беренче бае иде. Бәлки, сез ишеткәнеңез дә бардыр?»

Кунак: «Ник ишетмим, ишеттем, мин аны күрмәсәм дә, аның шөһрәте бик еракларда йөри иде».

---

*Ма яҗүзе галәйһи итлакыль-бишмәт* — бишмәт дип атарга яраклы әйбер.

*Кадәри хәл* — хәл кадәренчә, хәлдән килгәнчә.

Мөхәммәтшаһ: «Менә инде алайса, бу шул Ильяс бай, хәзердә, бернәрсәсе дә калмагач, карчыгы берлә бергә хезмәтчелеккә керде; карчыгы да безнең сыерларны, бияләрне сава».

Кунак, гаҗәпләнеп, телен шапылдата да сөйли: «Шулай шул, бәхет көпчәк шикелле әйләнә, берәүне түбән төшерә, берәүне югары менгерә». Урталыкта бераз сөкүттән соңра кунак: «Ул карт берлән сөйләшеп, аның үткән тормышларын сорашырга мөмкинме?»

Мөхәммәтшаһ: «Ник мөмкин булмасын!» — дип, киез өй алдына карап: «Бабай! Кил әле монда, карчыгыңны да алып кил, кымыз эчәрсез!» — дип кычкырды.

Бабай да шунда ук икән, хәзер керде дә, кунаклар берлән исәнләшкәч, тезләнеп дога кыйлырга кереште; карчыгы да, чаршау артына яшеренеп, хуҗа хатыны берлән бергә утырды. Ильяска бер җамыяк кымыз бирделәр. Ильяс, кымызны алып азрак эчкәч, эчкә таба сулыш алып, җамыякны куйды. Шундин соң баягы кунак, бабайга карап: «Ничек, бабай, син безгә карап, әүвәлге тормышларыңны исеңә төшереп күңелсезләнәсеңме?»

Бабай, көлемсерәп: «Мин сезгә бу тугърыда сөйләп сүз аңлата алмам, син аны минем карчыгымнан сөйләт, хатынкызның күңелендәге сере телендә була, шуның өчен ул сезгә тизрәк һәм яхшырак сөйләр», — диде.

Бу сүзне ишеткәч, кунак, чаршауга карап: «Җә, әби, син борынгы бәхет һәм хәзерге хәсрәт хакында ни хөкем итәсең?» — дигәч, чаршау артындагы Шәмсемаһидән ошбу сүзләр ишетелде: «Менә мин ничек хөкем итәм; без карт илә бергә 50 ел гомер иттек, бәхет эзләдек, әмма таба алмадык. Безнең бернәрсәмез дә калмаганга хәзер икенче ел инде, һәм без хезмәтчелектә торамыз, хәзер без шундый бәхет таптык ки, мондин артыгы бер дә кирәкми».

Кунаклар бик гаҗәпләнделәр, хуҗа да гаҗәпләнде, хәтта хуҗа, аягүрә торып, мондый гаҗәп сүз сөйләгән карчыкны күрмәк өчен, чаршауны бөтенләй ачып җибәрде. Карчык исә кулын җибәргән дә көлемсерәп утыра, картына да карап көлә, бабай да көлемсери. Карчык тәкрар: «Мин уйнап әйтмим, чынлап әйтәм, без тәмам ярты гасыр бәхет эзләдек һәм бай вакытымызда таба алмадык. Хәзер безнең бернәрсәмез дә калмады, кешегә торырга киттек, инде без шундый бәхет таптык ки, мондин артыгы бер дә кирәкми». Кунак: «Сезнең бәхетеңез нидән соң хәзер?» Карчык: «Менә нидән: без борын бай идек, ул вакыт карт берлән безнең икемезгә бер дә тынычлык юк иде, ахирәт уйлау да, на-

---

*Сөкүт* — тынлык.

маз уку да бездә юк иде. Бездә көне-төне мәшәкать, хезмәт иде. Җә безгә кунаклар килә; кемне ни берлән сыйларга, кемгә нинди бүләк кирәк — шуны уйлыйбыз, үземезне мактатырга тырышамыз, кунаклар да китә, тагы хезмәтчеләрне тикшерәмез, ягъни алар тик тормыйлар микән, тәмле ашамыйлар микән, димез; ничек тә булса үземезнекен ычкындырмаска телимез — гөнаһлы буламыз. Яки тайларны, бозауларны бүре эләктермәсен һәм дә караклар җылкыны куып китмәсен дип хафаланамыз. Йокларга ятсаң, йокы керми, бәтиләрне сарыклар, куйлар таптамасын, димез. Бер яктан тагы карт берлән безнең татулыгымыз юк иде. Карт әйтә: «Болай итик», — ди; мин әйтәм: «Тегеләй итик»; кычкырышырга тотынамыз — янә бер гөнаһ. Шул рәвештә без мәшәкатьтән михнәткә төшеп гомер иттек, әмма һичбер бәхет таба алмадык. Әмма хәзер? Хәзер карт берлән бик дустанә генә сөйләшәмез, инде кычкырышырга бернәрсә дә юк, шулай ук кайгырырга да малымыз юк. Хәзер безнең бар уйлаганымыз — тик хуҗага хезмәт итү генә. Без эшлимез, эшләгәндә дәрт берлән, хуҗага зарар булмасын, файда булсын дип эшлимез. Эшләгәч киләмез, аш бар, кымыз бар; салкын булса, утын бар, тизәк бар — җылынамыз. Кайвакытта ахирәтне дә уйлап җибәрәмез, намаз укыймыз. Кыскасы гына, без илле ел бәхет эзләп тапмаган идек. Менә хәзер таптык», — дип, Шәмсемаһи сүзен тәмам итте.

Кунаклар көлештеләр.

Шундин соң Ильяс, башын күтәреп: «Көлмәңез, кардәшләр, бу уен түгел, бу инсан гомере. Без байлыгымызны югалтканымыз өчен ахмаклык берлән җылаган идек, хәзер Аллаһы Тәгалә хаклыкны ачты; һәм сезгә бу серне ачуымыз үземезне җуатыр өчен түгел, бәлки, сезнең файдаңыз өчен», — диде.

Мулла да: «Әһә, әһә, бу бик мәгънәле сүз, Ильяс бик дөрес әйтә, китапта да шулай әйткән», — диде.

Соңра кунаклар, көлүдән туктап, тирән уйга чумдылар.

(Мөнасиб җирләренә үземнән дә кушып тәрҗемә иттем.)

## СҮЗ БАШЫ

«Уклар» журналының мәсләке мөселман карендәшләремезне укларымыз илә атып вә санчеп, тизрәк гафләт йокысыннан уйгату вә сикертеп торгызу булганлыгыннан, ушбу сүзләрне башта әйтмәклек мөнасиб күренде.

---

*Мөнасиб* — уңайлы, кирәкле.
*Гафләт* — гамьсезлек.
*Мөнасиб* — яраклы, муафикъ.

И мөселман карендәшләр! Уйганаек, заман уйганмак заманыдыр. Гафләт йокысыннан башларымызны күтәреп торалым. Торып селкенеп, баш-күзләремезне юып, як-ягымызны карап, дөньяның барышыннан хәбәрдар булалым. Башка милләт халкының барышыннан гыйбрәт алып, безләр дә алга таба аякларымызны атлап, һәр сәгать алга йөрмәгә иҗтиһад идәлем. Заман тырышмак заманы — тырышалым. Заман укымак, белмәк заманы — укыялым, беләлем. Заман тәрәкъкый заманы — һайди, карендәшләр, тырышалым, тәрәкъкый иделем. Җәһаләт вә әсарәт заманы үтеп, 20 нче гасыр — гыйлем вә мөсавәт заманы кәлде. Әүвәлдәге җәһаләтемези ташлап, надан ишаннарның фатихасенә вә мөтәгассыйб хәзрәтләрнең череп беткән бәддогасына алданып куркып тормак заманы кәчмештер һәм дә ялганчы әбиләрнең сөйдергеч, биздергеч догаларына ышану заманасы калмыштыр.

Ялган ишанстволарга кол булып торудан чыгып, хөр Русиянең свободный гражданы булмак кирәк. Ишанизмның гипнотизмы куәсеннән котылып, мөмкин кадәр дөнья, ахирәт өчен файдалы мәгърифәт хасил кыйлмак кирәк. Хәзрәтләрнең гомер буенча бәлеш ашап, җәй буенча мәҗлесләрне мәйханә сурәтенә кертеп, кымыз эчеп, голдыр-голдыр кикерүләренә ярхәмекә Алла дип торуны куеп, һәркем үз-үзене инсан хисапламак кирәк. Табигате йөкләми торган начар кешеләргә көчләп кымыз эчкезеп, шуларның эчә алмаенча зарланып, < ... > косып утыруларына бик кәефләре килеп һәм, тәмам туйганнан соңра, бер зур аяк илә һәммә кешегә, рәттән калдырмыйча, «монысы мәхдүм аягы» дип эчкезеп, икенче мәртәбә тагын, «монысы хәзрәт аягы» диеп эчкезеп, шуларга бик кәефләнеп утырганчы, халыкның җыелган җире мәҗлестә, милләт исемене бер-ике кәлимә булса да, халыкны гыйлемгә, сәнгатькә өндәсәләр, нинди яхшы булыр иде. Хәлбуки мәҗлестә безнең хәзрәтләрнең сөйләшкән сүзләре шул: «Фәлән кеше фәлән мәҗлестә кымыз эчә алмаенча косты, фәлән фәләнчә кадәре кымыз эчте. Ай-һай, бик яхшы эчә икән, шулай эчсәң ирде», —

*Иҗтиһад идәлем* — тырышыйк.
*Һайди* — әйдә.
*Җәһаләт* — наданлык.
*Әсарәт* — коллык.
*Мөсавәт* — тигезлек.
*Мөтәгассыйб* — фанатик.
*Куәсе* — көче.
*Ярхәмекә Алла* — Аллаһы Тәгалә сине рәхимлегеннән ташламас.
< ... > — бу урында чыганак бозылган.
*Аяк* — савыт, тустаган.
*Мәхдүм* — мулла, мөәззин улы.

дип, кирәкмәгән сафсаталар илән гомерне бушка уздыруны һичнәрсә хисап кыйлмаенча сөйләп утыралар.

Гавамга сөйләгән вәгазьләре булса, шул рәвештә була: «Осуле җәдит берлә укыту хәрам. Кызларга язу үгрәтергә ярамый. Кызлар язу белсәләр, егетләргә хат язалар. Җәдитләр замананы бозып бетерделәр. Язу үгрәтәмез дигән булып, һәркем үзе язу таныгач, гыйлемдә ни мәхәббәт калсын», — диләр. Җәдит берлә укымаска тиеш. Зәкят ялгыз муллаларга тиеш. Банкада ничә мең акчалары ятса да, үзләре зәкят бирмәсә дә ярый. Әгәр берәүнең башы авыртса, сәдака вирмәк кирәк. Берәү вафат улса, бай улсын, фәкыйрь булсын — фидия вирмәк кирәк. Ул кешенең хатыны, балаларына ашарына булмаса да, только давай вәрәсәэл энбия улан тәбәррек хәзрәтләргә. Фи игътабәру йа әүля әл-әбсар!*

## ЯЛКАУЛЫК, ЯХУД ҖИҢЕЛ КӘСЕП

Бер мулла яки ишан дисәм дә ярый, Казанский площадьтагы бер кибеткә керде. Моның әйләнәсенә вәгазь тыңлыймыз дипме, әллә иттифакый шулай туры килдеме, егерме-егерме биш башлап Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан абзыйлар җыелдылар. Мулла да, бер сүзгә мөнәсәбәт берләнрәк: «Әйе, ягъни мәсәлән, ялкау кешегә Аллаһы Тәгалә мин хәйсе ля яхтәсибтән бирә, менә мин сезгә шул хакта бер сәхих ривайәт тә сөйлим, — дип, сүзгә кереште: — Әүвәл заманда бик ялкау бер кеше бар иде. Ул кеше, бер дә кәсеп итмичә, тик үзенең мич башында тараканнар берлән бергә ята иде. Ләкин ачлык бик үзәгенә үтә башлагач, бу ялкау, пич башыннан төшеп, сәҗдәгә китеп, Аллаһы Тәгаләдән ризык сорый башлады. Нагяһ шул вакытта ялкауның капкасыннан зур гына, симез генә бер сыер килеп керде. Ялкау да, менә миңа Аллаһы Тәгалә ризык бирде дип, урыныннан сикереп торды да, сыерны егып, аякларын бәйләп, суеп та ташлады. Ялкау, сыерны суеп, тәмам тиресен тунап бетерим дигәндә, капкадан сыер хуҗасы килеп керде дә: «Бу ни эш?!» — дип кычкырды. Ялкау, бер дә каушамыйча: «Бу ни эш булсын, мин

---

* Игътибар итегез, әй, олы акылияләре!
*Осуле җәдит* — укытуда яңа метод.
*Вәрәсәэл энбия* — пәйгамбәрләр варисы.
*Тәбәррек* — газиз, хөрмәтле (*монда: ирония*).
*Иттифакый* — очраклы.
*Мин хәйсе ля яхтәсибтән* — көтелмәгән урыннан.
*Сәхих ривайәт* — дөрес хәбәр.
*Нагяһ* — кинәт.

Аллаһы Тәгаләдән ризык сораган идем, менә Аллаһы Тәгалә миңа бирде, мин суйдым», — диде. Сыер хуҗасы, ачуланып: «Синә Аллаһы Тәгалә ничек кеше сыерын биргән икән, әйдә казыйга!» — дип, икесе кул тотышып, шул заманда казый вә пәйгамбәр булган Давыт галәйһиссәламгә килделәр. Сыер хуҗасы ни булганны Давыт пәйгамбәргә сөйләп бирде. Давыт галәйһиссәлам, аңлагач, сыер хуҗасына карап: «Син сыерыңны бу кешегә бир, югыйсә хәлең начар булыр», — диде.

Сыер хуҗасы, гайрәт берлән: «Начар булса булыр, минем кеше өчен алган сыерым юк», — диде. Шундин соң Давыт пәйгамбәр моракабәгә китте, бераздан илһам да килде. Давыт галәйһиссәлам бу ике хәсамга иртәгә фәлән-фәлән сахрага чыгарга боерды. Таң аткач, болар сахрага чыктылар (Давыт пәйгамбәр дә шунда). Карап торалар. Берзаман шундагы бер кабер ярылды да, бер кеше атылып чыкты. Мәгәр бу кеше — ялкауның атасы икән. Ул Давыт галәйһиссәлам янына килде дә, кулы берлә сыер хуҗасына ишарә итеп: «Менә бу кеше мине үтергән иде. Малымны алган иде, хәзер бу кешедән кыйсас алынсын һәм барча маллары бу ялкау угылыма бирелсен», — диде дә янәдән җир астына кереп гаиб булды».

Бу җирдә сүз дә тәмам булды. Бичара Әхмәтҗан абзыйлар, бу мөбарәк хикәятне тыңлап, бөтенләй йокыга киткәннәр, авызларыннан сулар, селәгәйләр аккан. Һәрберсенең эченә ялкаулык дәрте кергән. Күңелләреннән: «Ай-һай, шул хәзрәт сөйләгәнчә ялкау булсаң иде!» — дип кызыгып торалар. Инде мин үз тарафымнан болай дип әйтәм: — Син, бичара мулла! Хатыннар качуын тәрҗих иткән асылсыз, әсассыз ривайәтләр җыеп-җыеп җәһилане Кирамнан вә мөтәгассыйбане гыйзамнан гыйззәтлү* Ахмакҗан абзыйга яшь хатынлык иткәнче, аның «Лап-лаплап» гәзитәсендә милләтне җәһәннәмгә таба өстери торган мәкаләләр язарга дәртләнгәнче, буның кеби, еврейлар тарафыннан чыккан асылсыз хикәятләрдән авызыңны тотсаң, бик мулла кеше булыр идең. Син бу хикәяңдә халыкны нәрсәгә өйрәткәнеңне сизәмсең? Әүвәл, ялкау булуны фазыйләт күреп, тыңлаучыларны кыздырдың. Икенче, сыер урлап суярга өйрәттең. Тагы

* Хөрмәтле наданнардан һәм бөек фанатиклардан булган.

*Моракабәгә киту* — уйга чуму.

*Хәсам* — дәгъвачы.

*Кыйсас* — үч.

*Гаиб булу* — югалу.

*Тәрҗих иту* — яклау.

*Мулла кеше* — белекле кеше.

*Фазыйләт* — артыклык.

сез Ахмакҗан абзый берлән хатыннарның йөзенә ыштан киертмәкче буласыз. Үзеңезгә мәгълүм бит инде, хәзрәт, ыштан кия торган җирбит түгел икәне. Әллә сез Петр Первыйдан борынгы урыс хатынларына иярдегезме? Афәрин һиммәтеңезгә!

## ТУГЪРЫ ҖАВАП

Казанда «17 нче октябрь союзы»ның члены Ахмакҗан абзый, — и, яңлыш ычкынды ла, — Әхмәтҗан абзый «Габдел хак» исемле гәзитендә[1] «Фикер»дә качмау хакында яздыгымыза каршы ачуланып, ни әйткәнене үзе дә аңламаенча, бер җавап язган иде. Бунларга каршы рәфикымез «Таң йолдызы» ушбу сурәттә бик яхшы һәм тугъры җавап биргән. Без шуның берлә хәзергә кифаятьләнәмез.

Җавап будыр:

«Габдел батыйль»дә хатыннарга качарга шәригать буенча лязем идеке бик нәҗес, бик әдәпсез, бик әхлаксыз гыйбарәләр берлә, озын иттереп баш мәкалә ясап языладыр. Шул мәкаләдә үк Сабир хәзрәт дигән бер зат кыргызларны көл әнгам, ягъни хайваннар кеби, ди. Бохар күргән хайван берлә күрмәгәне арасында нинди аерма бар икән? Шундук портрет төшертергә дөрест түгеллекене исбат кыйла.

Сәйдәш бабай, мөселманга портрет төшертергә ярыймы, юкмы, диеп, голямага бер сөаль биреп, гәзитәсендә зур бер мәсьәлә ачкан иде. Моны укыган кешеләр, әгәр әүвәлдән Сәйдәш бабайның кем икәнен белмәсәләр, Сәйдәш бабамыз беренче тәкъва кеше, хәтта голямага да көн күрсәтми, дигәннәрдер.

Сәйдәш бабайның үз портретын бер тәкъва түгел адәм кичә безнең «Таң» идарәсенә китереп бирде.

«Габдел батыйль»нең сөаленә голямадан элек без җавап бирәмез: мөселманнарга портрет төшертергә ярый, чөнки Сәйдәш бабай үзе төшерткән. Әхмәтҗан абзый белмичә төшертмәс инде.

«Безнең җиңгинең кырык кат күлмәге, урамга чыкса...» дигән табышмакны, шаять, ишеткәнеңез бардыр.

---

*Һиммәт* — тырышлык.
*Рәфикъ* — иптәш.
*Кифаятьләнү* — чикләнү.
*Нәҗес* — әшәке, пычрак.
*Бохар күргән* — Бохара мәдрәсәләрендә торып кайткан.
*Голяма* — галимнәр, укымышлылар.
*Тәкъва* — диндар, шәригать кушканча гына эш итүче.

# АЛАЙ-БОЛАЙ

## I

Мин Әхмәтҗан абзыйны ир ясадым. Теге Сабир муллалар вә Садыйк муллаларны[1] остабикәләре дип хөкем иттем, һәм бу мәкаләм беткәнче шул юл берлән барам. Шулай иттем, болай иттем итүен дә, сүзне ничек башларга кирәк? Хәер, болай башласам да ярый бит:

«Тәрҗеман» бабай[2] — ул карт бабай, күп заманнар гомер иткәнлек берлән, ул бик озын-озын тәҗрибәләр дә иткән инде. Шуның өчен ул күптән түгел чыккан бер «Тәрҗеман»ында «Әлифба мәктәбендә тәфсирдән дәм орылмаз» мәалендә* үткен гакыллы вә бик мәгънәле бер җөмлә дә язган. Вакыйган, дөрес бит! «Фикер» мөхәррире, Әхмәтҗан бабай шикелле бай заманында булсын вә хәзердәге кеби шартлаган заманында булсын, әлифбадан үтә алмаган бер карт гамигә тәфсир вә хәдистән дәрес бирә башлады. Әхмәтҗан бабай әүвәлге бай заманында, һәр мулланың ире вә һәр хәзрәтнең рәззакы булып йөргән заманнарын искә төшереп, бәгыре янып торган вакытта, тагы ул мискинне тәфсир дәресләре берлән газаплыйлар. Мин дә читтән карап кына бабамны кызганам, хәтта егълап та җибәрәм. Икенче яктан, бер карт сасы тиреченең мәйданда: «Дин! Шәригать!» — дип кычкырып, кәмиттәге дурак шикелле йөргәнен күрсәм, эчем катканчы көләмен. Әле мин Әхмәтҗан бабай хәзер муллаларга ир булудан калды дип язган идем, әмма уйлабрак карасам, ашыгып әйткәнмен, чөнки Әхмәтҗан бабай, Әхмәт бай[3] берлән даулашып, 12 мең тәңкә акча ала дип ишеттем. Бу акча әллә ничә миллионлы Әхмәт байга төкерек кенә булса да, кулында сүгенүдән башка сумасы калмаган һәм, карыны ачкач, шәригать, иман сатарга тотынган Сәйдәшкә бик зур байлык!.. 23 нче номер «Фикер»дә бер хәзрәтнең ялкауга Аллаһы Тәгалә уйламаган җирдән бирә дип ялганлаганы язылган иде бугай[4]. Бу бик дөрест сүз икән. Менә бу акчаны Сәйдәш бабай теге «Бәянел батыйль»не[5] чыгару өчен урыс алпавытларыннан алган 12 меңгә ку-

---

* «Башлангыч мәктәптә тәфсир (Коръәннең аңлатмалы тәрҗемәсе) укытылмас» мәгънәсендә.

*Вакыйган* — чыннан да.

*Гами* — надан.

*Тәфсир* — Коръәннең аңлатмалы тәрҗемәсе.

*Хәдис* — пәйгамбәр сүзе.

*Рәззакъ* — туйдыручы.

*Дурак* — клоун мәгънәсендә.

шып җибәрсә, 24 мең дә була. Ну, по крайней мере, Сәйдәшкә байлык! Тагы Сәйдәшкә Садыйк мулла, Сабир мулла шикелле яшь хатыннар табылды. Типтерә бабай! Мин әле ул ике мулланы бабайга гашыйк булганнар, имеш тә, бабайны фәкыйрь хәлендә дә ташлап бетермиләр, имеш, дип ишеткән идем. Юк! Алай түгел икән, ул ак башлы Бохара чәүкәләре теге яңы 24 меңнең исенә җыелган булырга кирәк. Ни булса да булсын, мин Сәйдәш бабайга гәзитәсенә дәһри, динсез, хәтта мөртәт дигән сүзләрне язарга ашыкмаска мәслихәт бирәм.

Борын заманда Сәйдәш лавкаларында приказчиклар, хәтта байның үзе дә, кибетләренә бер алучы килсә, аңар күзләрен акайтып: «Алсаң — ал, алмасаң — вон!» — дип төрткәләп җибәрә торганнар иде.

Дин вә шәригать Сәйдәшнең магазины түгел ич ул! Ничек кешене тиз генә диннән төрткәләп чыгарырга кирәк?

Ахырга таба җәзасын тапты бит: Сәйдәшнең үзен дә кибетләреннән төрткәләп чыгардылар. Әле бу тәкфирләрендә дә, яхшы, без ачуланмыйбыз: башка бер усалрак кешегә очраса, Сәйдәш бабайның үзен дә: «И карт мәҗүси»! — дип, биленнән кысып алып, иман коймасы аркылы көфер абзарына төшерер иде. Сәйдәш бабайның вә бикәләренең мондый зур эшкә хаклары булгач, без фараз иткән Усалның ник хакы булмасын? Бохар муллалары, Бохар Сабирлары вә Садыйкларычарак җибәрсәм: ләм ля йәҗүз?

Эш «дәһри дә динсез» дип кычкырышырга калса, без Садыйк мулла әл-Иманколыйны сүтәбез дә, урынына Кязиб мулла әл-Имансызыйны[6] утыртабыз да куябыз; бу бигайниһи «Лаплап-лап»тагы Золмәтетдин әл-Ноксаный шикелле була да кала. Тик Алладан шуны сораңыз: эш ул якка бармасын. Усаллык хәзинәсе бик зур, ул — күпме алсаң да бетми. Син, иптәш Сәйдәш, остабикәләреңнән теләсәң нәрсә яздыр. Ләкин дәһри, динсез кеби ләфызларга кадәр җибәрмә. Югыйсә безгә дә мока-

---

*Дәһри* — динсез, дингә каршы.

*Мөртәт* — диннән чыккан.

*Тәкфир* — кешене «кяфер, динсез» дип атау.

*Мәҗүси* — күп Аллага табынучы, монда акчага, байлыкка табыну күздә тотыла.

*Ләм ля йәҗүз?* — Ник дөрес түгел?

*Садыйк* — дөресне сөйләүче.

*Кязиб* — ялганчы.

*Бигайниһи* — нәкъ.

*Золмәтетдин* — диннең явызлыгы.

*Әл-Ноксаный* — кимчелекле.

*Ләфыз* — сүз.

бәлә билмисал лязим булыр да, җилгә каршы төкергән булып күренерсез. Син, Сәйдәш абзый, «Фикер»дә мине хурлаганнар, дип йөрмә. Минем белүемчә, сине хурларга һичбер хаҗәт юк. Синең бөтен вөҗүдең, синең «Бәянел батыйль»ең, яхуд бөтен гәзитәңне баскан «саттыр сыралап сыра (сыра)» игъланнары арасында көчкә генә күренгән сүгенүләрең — һәммәсе батыйль. Һәммәсе ялган. Хатыннарга театрга барырга дөрест түгел дисең дә, ник «Аркадия» бакчасындагы фахишәләрнең игъланын басасың? Мәдәният бер локомотив шикелледер. Ул полный ходка барганда, син юл өстенә чыгып туктатмакчы буласың. Локомотив ул синең кеби кабан дуңгызларын түгел, төяләрне дә изеп, яньчеп китәдер.

Кирәк дип әйтсәң, ахыры булмый калмас*.

## II

Казан хәзрәтләре иске-иске заманнан калган бер арыш кибәне астында тыныч кына, зәхмәтсез генә, өеп хәзерләп куйган арышны ашап ята торган тычканнар иделәр.

Ләкин, гөнаһ шомлыгы, гәзитәләр чыккач та, боларның кибәне ишелә, сүтелә башлады. Бичаралар, үзләренең өстендә шытыр-шытыр иткән әллә нинди ят тавыш ишеткәч, тынnарын да чыгармыйча, колакларын салып тыңлап тордылар, теге тавыш һаман боларга якынлашкандин-якынлаша башлады.

Тычканнар куркыша башладылар, чырылдаша башладылар. Тавыш исә, бара торгач, бөтенләй үк килеп җитте — кибән ишелде. Аның астында әллә нинди ак башлы Бохараи шәриф тычканнары ятканлыгы күренде.

Кибән сүтүчеләрнең яннарында мачылары да бар иде. Бу мачылар мондый зарарлы мәхлукларны күргәч, чыдамадылар: җәядән аткан ук шикелле атылдылар. Тычканнарны бик искедән бирле кыйлган гөнаһлары өчен рәнҗетә, кычкырта башладылар.

Тычканнар да: «Нәкадәр кибәнгә иттең хыянәт, юк икән сездә инсаф һәм хәянәт», — дигән бер сурәттә чыр-чыр чырылдарга керештеләр. Алар ул кибәнне бөтенләй милекләнеп алганга

* Ахыры «Фикер»нең 27 нче санында басылган.

*Мокабәлә билмисал лязим булыр* — охшашы белән каршы торырга кирәк булыр.

*Вөҗүдең* — барлыгың.

*Батыйль* — дөрес булмаган нәрсә.

*Бохараи шәриф* — изге Бохара (монда: ирония).

*Инсаф һәм хәянәт* — тыйнаклык һәм оят.

*Милекләнеп алу* — үзенеке итү.

һәм күп заман шуның берлә генә туенганга, аны сүтүчеләрне имчәкләрен чыгарып каргарга тотындылар. Аларны кяфер, динсез, дәһри кеби сүзләр илә сыйладылар. Әмма сүтүчеләр бик гайрәтле кешеләр иде. Алар, тычканнар кешене динсез ясый алмаганын бик яхшы белгәнгә, ул сүзләргә бер дә илтифат итмиләр иде. Тик мачыларның боларны төрле-төрле тавышлар берлә кычкырткannарын тамаша итеп, мыек астыннан гына көлеп торалар иде. Тычканнар, мискиннәр, ары бәрелделәр, бире сугылдылар, бер дә качарга, сыгынырга урын таба алмагач, борын-борыннан ук Бохараның тычкан шәрифләренә каршы шәфкате берлән мәшһүр булган, бөтен дөнья вә ма фиһасын, хәтта үзен-үзе дә Бохараның ишәкләре вә көчекләренә тиң күрмәве берлән мәгъруф Әхмәтҗан абзыйның идәне астына тулдылар.

Инде шул идән астыннан чырылдап-пырылдап кына эш итәләр, Әхмәтҗан абзый да каткан, көйгән икмәк кисәкләре булса, боларга ыргыта. Болар шуны кемер-кемер кимерәләр.

Әхмәтҗан абзыйның өч хатынлы кеше булуы вә «Бәянел хак» кәгазеннән файда килсә, дүртенчесен алуы да мөхәкъкакъ булуы тычканнарга бик зур бәхет вә сәгадәт иде. Чөнки, билгеле, бала-чагалы кешенең өендә тычканнарга яланырга сынык-санаклар табыладыр.

## Көлмичә сөйләү кыйсеме

Садыйк мулла, Сабир мулла, Гариф мулла, бер мөәззин, бер карга имзалары илә «Бәянел хак»та бик күп тәртипсез бәндләр, майламаган көпчәк арасыннан чыккан шигырьләр дәреҗ ителде. Бу телсез муллалар бер нәрсә әйтмәкче булалар, ләкин, ах, наданлык, иреннәрен селкетәләр дә, бер нәрсә дә фәһемләнми. Боларның сүзләрен тәрҗемә иттерү өчен Чабаксардан бер чуаш китермәсәк булмас, ахры. Бер мөәззин имзасы илә язган бер чуаш айгырларны, бияләрне, сыерларны, үгезләрне, ата чебен, ана чебеннәрне мисал китергән, ягъни бу мөәззиннең хатыннарга гаид гыйльме айгырлардан, үгезләрдән, ата чебеннәр, ата дуңгызлардан бер дә узмаган икән. Мәсәлән, ата дуңгыз ана дуңгызны нәрсә дип таныса, бу мөәззин дә хатыннарны шулай гына таный икән. Әгәр мөселман хатыннары качмый йөрсә, бу мөәззин хәзер бер хатынга урамдук ябышачак

---

*Дөнья вә ма фиһасы* — дөнья һәм анда булган нәрсәләр.
*Мәгъруф* — танылган.
*Дәреҗ ителү* — басылып чыгу.
*Фәһемләнми* — аңлашылмый.
*Гаид* — бәйләнешле.

икән. Әнә марҗалар бер дә качмый йөриләр. Барып ябыш әле, мөәззин хәзрәт, яңагыңнан утлар күрсәтсен. Чалмаларың очып киткәнен күрми дә калырсың. Әллә һәр хатынны фахишә дип белдеңме? Әллә һәр хатынны фәхешханәдән алалар дип белдеңме?

Тагы «Бәянел батыйль»нең 38 нче номерында Сәйдәш бабай З. әл-Кәмали[7] хәзрәтләре, «Фикер» мөхәррире Камил әл-Мотыйгый әфәнде илә чәйнәшергә тотынган. Сәйдәш бабай: «Мин галим булмасам да, күреп торамын, ничә, ничә үзенең хилафына булган аятьләрне урлап калдырган», — дип алдаган булган.

Син, галим булмасаң да, ничек урлап калдырган аятьләрне беләсең икән — бу бик гаҗәп белү! Үзең галим түгел, үзең беләм, дисең; галим булмагач, галимнең зыйдде — җаһилдер. Без сине җаһил дип әйтәбез. Ачулансаң, терсәгеңне тешләрсең. Гәзитәгә бер аять язгансың, шуны да дөрест яза алмагансың. Синең шикелле ушбу түбәндәге бәетнең мөсаддәкы булган татарларга халыкны сәләфе салихин тарикына өндәргә оят дип беләбез.

Бәет будыр:

Бәгъзеләремез бик суфи,
Көн дә биш намаз укый.
Бурычка йөз мең алгач,
Аны кесәгә салгач...

И дустым Сәйдәш! Бу заманда мәсҗедкә бурычтан качып кергән Казан байлары бик күп.

Вәһабиләрне кем дип беләсең? Аны ни белеп сүккән буласың? Вәһабиләрнең кем икәнен беләсең килсә, «Әлгасрел җәдит» журналына мөрәҗәгать боерасыз. Ул вәһабиләр, сәйдәшиләргә караганда, тәкрар-тәкрар артык булып чыкмасын. «Тәрҗеман» гәзитәсе: «Мөхәррирләр, әдибләр талчуктан тел алсалар, талчук ни эшләсен?» — дип язадыр.

«Җаным Исмәгыйль! Нә япмалый, хәсамымыз Сәйдәш талчукчыдыр. Без дә уңа талчук лисаны илә мөдафәга идиюрез. Без мөһаҗим улмай, анҗак мөдәфигъ улдыгымыз җәһәттән хакыйкатьтән бәхтыярыз*. Менә син дә карап тор, без Сәй-

---

* Җаным Исмәгыйль! Ни эшлик, оппонентыбыз Сәйдәш — талчукчы. Без дә аңа талчук теле белән каршы торабыз. Без, һөҗүм итүче булмыйча, бары сакланучы гына булуыбыз белән чын-чыннан бәхетлебез.

*Хилафына* — зарарына (үзенә каршы).

*Галимнең зыйдде — җаһилдер* — «галим» дигән сүзнең киресе «надан» дигән сүз.

*Бәетнең мөсаддәкы булган* — бәеткә туры килә торган.

*Сәләфе салихин тарикына* — борынгы изгеләр юлына.

*Суфи* — изге мәгънәсендә.

дәшкә ни дип әйтәбез: «Бабай Сәйдәш, надан Сәйдәш, усал эт төсле тик чәйнәш; безем корган нигезләр бер дә селкенмәй дә чайкалмай».

Без ул Гариф муллалардан вә аларның рәззакълары Сәйдәшләрдән ничә-ничә гасырлар көтеп тә ислам өчен бер зәррә хезмәт күрмәдек. Шимди милләт өчен җан вирәчәк каһарманнарга да аяк чалмак эстәдекләрендә, каләмемез вә күкрәгемез илә каршы торамыз. Әгәр җәнаб Аллаһыдан филҗөмлә хәүфем булмаса, мин дә имам Садыйк әл-Иманкулый әйткән сүзне әйтә белер идем. Бәлки, тагы берәр дәрәҗә уздырыр идем.

Батсын сорыкортлар, батсын манигы тәрәккъый Сәйдәш вә табигъләре!

Яшәсен әрбабе каләм! Яшәсен гайрәтле милләт арысланнары!

Кара әле Сәйдәшне: безне һәр гәзитәсендә дингә дәгъват итә, бу нинди пәйгамбәр икән? Ахырзаманга каршы бөлгән байлар пәйгамбәрлек дәгъвасы кыйлыр дигән сүзләр бар иде. Ахры, чын сүз булды.

Сезнең актык җавабыңыз улса, безнең дә актык сүземез:

Әхмәтҗан абзый!

Уйнаш кыйлуы бик уңгай да, бала табуы бик читен, диләр; шуның шикелле, сез дә, әллә нинди Мөхәммәтгариф әл-Салихи вә Садыйк әл-Иманкулый дигән кешеләр берлән бергәләшеп, безнең бер дә сезгә зарары тимәгән Мөкаддәс вә газиз иманымызга ябыштыңыз. Дәһри, диденез, динсез, диденез, кяфер, диденез, тагы аннан зуррак сүз тапсаңыз, аны да әйтәчәк иденез, тик таба алмаганлыктан гына туктадыңыз. Менә шуның өчен без дә, «Бик усал» имзалы бер мәкалә басып, зәһәрне зәһәр җиңәр өмиде илә сезгә иман вә исламымыз ачуы илә атылдык. Шулкадәр атылдык ки, кыяматкәчә һичкемнең иманына тимәскә кат-кат тәүбә итәрсез. Инде сезгә бу мәкаләнең яшен шикелле тәэсир иткәнлеге беленде, чөнки үзен кыйный башлагач: «Әнигә әйтәм, этигә әйтәм!» — дип кычкыра торган урам баласы төсле, окружныйга бирәм, макружныйга бирәм, дип лыкылдарга керештеңез.

Эшне кем башлады? Бер яздыңыз, ике сүктеңез — һаман без сабыр иттек. Тукта әле, Әхмәтҗан абзый шикелле гами-

---

*Зәррә* — тузан хәтле.

*Филҗөмлә хәүфем* — әз генә куркуым.

*Манигы тәрәккъый* — алга китешкә тоткарлык итүче.

*Табигъ* — иярчен.

*Әрбабе каләм* — язучылар, каләм ияләре.

*Дәгъват иту* — чакыру, өндәү.

*Окружныйга* — окружной судка.

ләргә карт булса да гакыл керми, әле алар балигъ булмаган бит, сабыйлык берлән авызларыннан ни чыкканын тоймый торганнардыр, дидек. Без һаман сабыр итәмез, үз тарафымыздан бер нәрсә дә язмыймыз: тик «Бик усал» имзалы мәктүбне генә басып, «Таң йолдызы»ннан[8] бер мәнзум кыйсса күчердек. Җә, безнең сабырсызлыгымыз шулмы?

Без «Бәянел хак»та безгә каршы кяфер, динсез, дәһри, хәтта мөртәт дигән сүзләрне күргәч, «Бәянел хак»ның мөрады хиҗаб мәсьәләсе түгел икән, тик безне кимсетеп, халык күзенә динсез күрсәтү генә икән дип хакыйкатән аңладык. Шуның өчен дә хиҗаб мәсьәләсен бер якка куеп, һәртөрле Әхмәтҗан абзыйны мактаган мәктүбләрне баса башладык. «Тәрәккый» гәзитәсен[9] дә бер-ике сәтыр күчердек. Бинаән галәйһи, «Фикер» мөхәррире бу эшләрдә гаепсез булса кирәк. Әхмәтҗан абзый, Әхмәт байны җиңгәч, гайрәтләнеп бугай, һәркемне суд берлән генә куркыта. Казан баеның безне динсез күрсәтүе Уральск халкына каты әсәр итте. Алар Садыйк әл-Иманкулый фәтвасы буенча безнең матбаганы ватмакчы булдылар. Без, моны ишеткәч, эшне судка бирдек. Безне дә Әхмәтҗан абзый окружныйга бирә: әйдә судлаш, давай судлаш. Әйдә, Сәйдәш, әйдә, чәйнәш! Безнең шәһәр халкын болгатучы Садыйк мулла вә Гариф муллалар судка килсәләр кирәк. Без ничек кяфер булдык икән? Күрсәтерләр. Ай-ай, гыйрзыңыз кадерле икән! Нинди тәти кешеләрнең, матур муллаларның гыйрзы нәфсаниятләренә тигәннәр, берсенә князь Әхмәтҗан вә берсенә Садыйк хәзрәт, димәгәннәр, һай, инсафсызлар, алар безгә: «Никадәр шәргыгә итдең хыянәт: юк икән сәндә инсаф һәм диянәт», — дип язганда, ник: «Дөрест, тәкъсир, дөрест, шулай шул», — дип пичәт басмаганнар. Аларның «траттата, траттата, траттата», бер дә очсыз, шәйтан траттатасы шикелле тәмсез, ләззәтсез шигырьләрен ник мактамыйлар? Тагы шигыренең ахырында: «Тәүбә итеп, ачык гәзитенә яз», — дигән сүзенә карап, ник мәсләк бозмыйлар, ник мәзһәб ватмыйлар? Һай, әдәпсезләр, һай, сапсаталар! Бары да ахырзаман галәмәте, ахырзаман, ахырзаман. Җә, кем тәүбә итте: безме? Сәйдәшме?

---

*Мәнзум кыйсса* — көйле әсәр.
*Хиҗаб* — хатын-кызларның йөзләрен каплап йөрүе.
*Сәтыр* — язма юл.
*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.
*Әсәр итү* — тәэсир итү.
*Гыйрзы нәфсаният* — үзен сөю хисе, эгоистлык.
*Шәргыгә* — дингә, шәригатькә.
*Диянәт* — динлелек.
*Мәсләк, мәзһәб* — тоткан юл, юнәлеш.

## ПОГРОМ

Лично-почетный потомственный гражданин — кәвеш тегүче Шәрәфетдин абзыйның[1] өендә 5 июльдә бик зур голяма җәмгыяте булды. Беләсең инде: һәркем үз тиңе вә үз шәриге берлән азаплана бит. Моның өенә лично-почетный потомственный гражданин Хәйрулла Гаделшин[2] хәзрәтләре дә килде. «Исәнме-саумы?», «Исәнме-саумы?», «Сәламәтме-саумы?» сүзләре кат-кат тәкрарлангач, бик озын, бик нечкә бер дога да кыйлынды. Шундин соң Пиршин-Пирлиннәрне вә Бинаевләрнең ишеге өстеннән коелган штукатураларны, вә черегән толыпларны, вә 50 тәңкә акчаларны, вә Карамалыдан сөрелеп килгән формаларны хәзер дә бик яхшы белә торган бер мулла[3], шәһәремезнең мөәззине илә Фәссах карыйга[4] карап, күзләрен имансыз кешенең җан биргәнендәге шикелле акайтып:

— Чыгарыңыз шуларны, алар «Фикер» гәзитәсен яклыйлар! — дип кычкырды.

Бу тавышка югарыдагы ике гражданинның берсе булган Хәйрулла Гаделшин сикереп торды да, Фәссах карыйның кулыннан тотып: «Чык мәҗлестән, вон! Шпион!» — дип куа башлады. Фәссах карый, бичара, мәҗлестәге кешеләрдән бер дә мәрхәмәт әсәре күренмәгәч, Габдерәкыйп хәзрәткә[5] карап: «Хәзрәт! Ни әйтәсез, мин, сез чыгарсаңыз — чыгам, сез чыгармасаңыз — чыкмыйм, бу мәҗлестә сездән башка чын кеше юк», — диде.

Бу рәвешчә Фәссах карый кат-кат сораса да, Габдерәкыйп хәзрәт җавап бирмәде. Ягъни: «Чыкмасаң чыкма», — дип ишарәт итте. Шулай да Фәссах карыйга чыкмыйча тугъры килмәде. Теге почетный гражданин, үзе генә чыгара алмагач, кәвешче почетный гражданинны ярдәмгә чакырды. Соңгы гражданин өй хуҗасы булгач, чар-начар, Фәссах карый хурлыгыннан вә хәкарәтләүләренә егълый-егълый чыгып китте. Җә инде. Хәйрулла Гаделшин берлән Сәхип Пиршин, Гайниҗамал хәзрәткә[6] тыныч калды. Манигъ мөндәфәгъ булды.

Инде сөйләгән сүзләрен карыйк. Хәйрулла Гаделшин шундагы иптәшләренә карап: «Иптәшләр! Без болай итик. Киләсе чәһаршәнбегә мин кырык кеше хәзерлим, аларга үзем командир булам да, «Фикер» идарәханәсендәге машиналарны,

---

*Голяма җәмгыяте* — галимнәр җыелышы.
*Шәрик* — иптәш, бергә эшләүче.
*Чар-начар* — ирекле-ирексез.
*Хәкарәтләү* — хурлау, кимсетү.
*Манигъ мөндәфәгъ булды* — тоткарлык бетте.
*Идарәханә* — монда: редакция мәгънәсендә.

кассаларны — һәммәсен ватамыз. Камил әфәнденең[7] үзен һәм бала-чагасын кыйныймыз, изәмез», — диде. Гайниҗамал хәзрәт тә 20 кеше тапмакчы булды, инде чәһаршәнбе көн киләчәкләр дә «Фикер» идарәсен тар вә мар итәчәкләр. Гайниҗамал хәзрәт «Фикер»нең шагыйренә дә бармак селкеп куйды: «Эләктерсәңез, аны да кыйнагыз», — диде.

Әй, күзләреңне хәсәд, тәмгы, хирыс берлән кан баскан Гайниҗамал хәзрәт! Син бу кадәр эшләр эшләүне әллә Шәрәфи абзыйның бәлешен кимерү дип белдеңме? Әллә Пиршиннән әллә ничә мең тәңкә мал алып ашап, соңра сумына бер тиен дә түләми котылу дип белдеңмени? Әллә син аны Мәннафовтан[8] алып ашаган закускаларың диденме? Әллә син ялкаулар хикәяте сөйләү дип белдеңме? Бар әле, «Фикер» идарәсен ват әле! Аннан сине Карамалыдан сөргән шикелле генә сөрмәсләр. Тагы катырак эләктерерләр. Син, кулыңнан килсә, дөньяда бер гәзитә дә калдырмас идең. Юк, ул алай булмый шул. Әллә син бу мәхәлләгә имам булмакчы буласыңмы? Ул да булмас. Чөнки син — әллә ничә җирдән сөрелгән кеше; тамагыңны туйдыра алмагач, төрле-төрле сурәтләргә кереп, бөлгән, шартлаган кеше һәм, хөкүмәт тарафыннан замечен булып, төрмәдә черүдән тик рәззакъ байларың аркасында гына котылган кеше. Син «Фикер» мөхәрриренең иманына, исламына ябыштың. Ул гына җитмәде, тагы аның җанына вә бала-чагасына касд кыйлмакчы буласыңмыни? Казандагы Мөхәммәди хәзрәт угылы Гариф мулла да, «Тәрҗеман» мөхәррире берлән талаша-талаша, таулар биеклек кәгазьләр өйгәч кенә туктаган иде. Син дә шулай үзеңне яратмаганнарны кяферләндереп, фаҗирләндереп ташламакчы булдыңмы?

Инсаф кирәк, хәзрәт, инсаф кирәк! Җитәр инде, болай да гәзитәдә һич хыялга килмәгән мәкаләләр басылып, мөхәррирләр сезгә каршы тормакчы булдылар. Әүвәл сезнең шикелле сорыкортларны бетереп, дәфгы мәзаррат кыйлмакчы булдылар да, аннан соң гына гәзитәне милләт файдасына хаслап, җәлбе мәнфәгать кыйлмакчы булдылар. Бу эш «Тәрҗеман» мөхәррире башыннан да кичте. Ул да сезнең шикелле чалмалы җаһиллар берлән бик озак тартышты. Гакыйбәт чалмалылар мәгъ-

---

*Хәсәд, тәмгы, хирыс* — көнчелек, кеше малына кызыгу, комсызлык.
*Замечен* — күзәтү астына алынган аферист мәгънәсендә.
*Рәззакъ* — туйдыручы.
*Җанына касд кыйлмакчы* — кыйнарга, үтерергә ниятләнмәкче.
*Кяферләндерү, фаҗирләндерү* — кяфер, бозык кеше итеп күрсәтү.
*Дәфгы мәзаррат* — зарарларны юк итү.
*Җәлбе мәнфәгать кыйлу* — файдалыны тарту, китерү.
*Җаһиллар* — наданнар.
*Гакыйбәт* — соң чиктә.

лүб булдылар. Бәгъзесе инсафка килде. Бәгъзесе никадәр тырышып та пешерә алмагач, шул иске гыйнадлары, иске тәгассыблары илә каберләренә керделәр. Әле оныткканмын икән, хәзрәт, син, беркөн мәҗлестә, кымызны хәрам дип эчәм, дидең, җылкы итен хәрам дип ашыйм, дидең, — ялган, дисәң, шаһитлар да бар. Бөтен мәҗлес халкы ишетте.

Инде редакцияне дә шулай хәрам дип ватасыңмыни? Пиршин малын да шулай хәрам дип ашадыңмыни? Сез бит беренче суфилык, хәтта вәлилек дәгъвасы кыйлган кеше; алай булгач, ник хәрамны бик батырлык берлән эшлисең? Бу сөальләр җавапсыз калмасын.

## УРАЛЬСК ИМАМНАРЫНА АЧЫК ХАТ

Хәзрәтләр! Заманы хазирдә мөмкин кадәренчә фитнә чыгармаска һәр каюмызга важиб була торып, сез, хөрмәтле имамнарымыз, ничөн «Фикер» гәзитәсе идарәсенә тел озайтып йөрисез? Хәйрулла абзый багъчада гомер итә: «Ул бай кеше, безне ашка чакырып сәдака бирер», — дип тәмгы итәсезме әллә? Ничөн ушбу июльнең 5 нче көнендә Шәрәфи тегүче өенә яман касд берлән җыелышып, Шәрәфетдин Каниев[1] илән Хәйрулла Гаделшин чанасына утырып, аларның: «Кырык кеше булып «Фикер» идарәсенә барып, типографияне ватамыз, кырамыз», — дигән сүзләренә «ләббәйкә-ләббәйкә!» дип тордыңыз? Ул матбага, әлхәмделиллаһ, ислам кулында булганлыкы ичүн тәшәккерләр лязим иде; сез, әфәнделәр, киресенә барып, бунын кеби матбаганың мөселман кулында булып, һәртөрле гәзитә, журнал, китап, рисаләләр язылып торуына хәсәд итәсезме? Андай, хәсәдләр итеп фитнә чыгару тугърысында сөйләнгән сүзләр бәлеш табынында сөйләнсә дә, аңгар шәһәремездә гакыллырак адәмнәр разый булмазлар бит, рәнҗерләр.

Сез муллаларга белергә тиеш дәгелме: бу Хәйрулла «Фикер» идарәсенә кадимгә дошман кеше ич. Һәр каюңыз моны

---

*Мәгълүб булу* — җиңелү.
*Гыйнад* — кирелек, тискәрелек.
*Тәгассыб* — фанатизм, искелек.
*Вәлилек* — изгелек.
*Заманы хазир* — хәзерге заман.
*Важиб булу* — тиеш булу.
*Тәмгы иту* — ачкүзләнеп өметләнү.
*Яман касд* — яман ният.
*«Ләббәйкә!»* — «Ни боерасыз, без әзер!» мәгънәсендә.
*Тәшәккерләр лязим* — рәхмәтләр әйтергә кирәк.
*Хәсәд иту* — көнләшү, куралмау.

туксан мәртәбә ишеткән-белгән ич. Үткән ел да шәһәремезнең ахуны Духовный собраниенең 10 апрель җыелышына киткәндә, баягы Хәйрулла, әллә нидә бер булса да, мәсҗедкә барып, ахунд артыннан яман тел берлә таш атып калган иде. «Менә Мотыйгулла мулла Духовный собраниегә качып китте, менә күрерсез, динне сатып кайтыр», — дигәндә, ничөн сез, муллалар, мөәззиннәр, сөкүт итеп калдыңыз? Хәйруллага әйтә алмадыңызмы: «Ник качып китсен, ул бөтен мәсҗед җәмәгате берлән исәнләшеп, рөхсәтләрене алып китте», — дип. «Ул ник динне сатып кайтсын, безнең динемез сатыла торган дин түгел ич. Хосусән Собраниегә бөтен әһле ислам голямасы җыелганда, дин сатмак һичбер гакыллы кешенең хәтеренә китерергә ярый торган эш тә түгел», — дип ник әйтмәдеңез? Шундый кабахәт сүзләрне сөйләп йөргәндә, ничөн ул кадәр сөкүттә булдыңыз? Инде хәзердә: «Фикер» идарәсен кырдырам, ваттырам», — дип сөйләп утырганда, аңар итәк астыннан спичка сызып, пожар чыгарасыз.

Хәйрулланы бездән артыграк үзеңез беләсез бит. Карт абзасы мәшһүр Тау Гайни[2] үлгәч, мәрхүмнең малын үзләре генә алып, хатыны Мәфтуха Гыйззәтулла кызына бирдермәскә йөргәне ни булды? Шәригать сатылырга яраса иде, мәрхүмнең хатынына мал бирмәзләр иде, — чөнки Хәйрулла Духовный собраниене, Окружной палатаны, министрны калдырмады. Карт бабамызның малын хатынына бирдермәскә гаять иҗтиһад итте. Ләкин безем шәригатемез, динемез кайда ул сатылырга, — әлхәмделиллаһ, шәригать көчле, һәрвакыт үзенең куәтендә булып, Духовный собрание шәригать илән дуб-дугъры барадыр. Вә дәхи, һәр каюңызга мәгълүм бит, кәчән сәнәләрдә Хәйрулла гаедкә барган икән, гаед мәсҗеднең ишегалдында укылдыгыннан, теге Хәйрулла мәсҗед эченә кереп утырган да, шунда торып, гаед намазыны укымый калган иде. Гаедтән соң мөәззин Ярулла әфәнде[3] мәсҗедкә кергәч, Хәйрулла мөәззингә ябышкан. «Сән безне намаз укытмый калдырдың», — дип сүгеп, төрткәләп йибәргәндә, мөәззин, мискин, һаман бер сүз дә әйтә алмый калган иде.

Вә дәхи: шул Хәйрулла абзый үзенең егерме биш ел тереклек итеп торган гыйффәтле, гыйсмәтле, Казан мещанины Фәхретдин Әмиров кызы Бибифатима абыстайны аерып җи-

---

*Сөкүт итү* — дәшми калу.
*Әһле ислам голямасы* — мөселман укымышлылары, муллалар.
*Иҗтиһад итү* — тырышу.
*Кәчән сәнәләр* — узган еллар.
*Гыйсмәтле* — тыйнак.

бәргән иде. Йиде-сигез баланың әнкәсе иде. Шуны аерганда, ничөн сез, муллалар, бер дә хатын тарафыны карамадыңыз? Ул бичарага хәкарәтләр итеп, сүгеп, рәнҗетеп, еглатып аерганда, ник тик тордыгыз? Хәзердә Фатима абыстай берәүнең тәрбиясендә бер заэалә сыенып торадыр. Хәлбуки ике ир баласы бар, берсе өйләнгән, берсе, өйләнмәсә дә, йиткән. Шулай булса да, аналары янына барырга, күрешергә Хәйрулладан рөхсәт бирелмәгән сәбәпле, аналарын асла күрмәйүб йөриләр. Аналары тәрбиясе алар өстенә фарыздыр.

Әй муллалар, сез ничөн шул Хәйруллага әйтмәйсез: «Син, Хәйрулла, аналарын аерсаң да, балаларны аналарыннан аера алмайсән». Аналарын карасыннар, тәрбия итсеннәр, чөнки оҗмах аналар аяк астында табыла, дип пәйгамбәремез әйткән сүзне ничөн укып әмре мәгъруф итмәйсез? Ана кеше балалары илән бер шәһәрдә торып вә мәга һәза әнкәләре янына бармайуб, килмәйүб йөретергә Хәйрулла нинди мулладан нинди шәригать ишетте икән? Сез, хәзрәтләр, шундай җирләрдә нәһи мөнкир әмре мәгъруфта булырга* кирәк иде. Сезне Хәйрулла ашка чакырмаса, башкасы да булыр бит. Үзеңезгә мәгълүм, Аллага шөкер, шәһәремез зур, — ашарсыз, туярсыз, курыкмагыз.

«Фикер» гәзитәсендә шәригатькә хилаф сүз язылган булыр, «Фикер» сахибе мәгъсум дәгел, хатасы да булыр. Ләкин шуны белергә кирәк: гәзитәдә язылган һәрбер сүз шәригать булып китми, безим шәригатемез алай гәзитә сүзләре илән бозылмый, мәнсүх булмый. Шәригатемез — Коръәне хәдистер, Коръәне хәдис та кыямәт барачак, анда бер дә шикшөбһә юктыр.

Сез Уральск муллаларына сүземез будыр: бастыра торган китапларыңыз булса, без басып бирүгә иҗтиһад итәмез, сезләр безнең матбагамызны китаплар, рисаләләр язып бастырып нурландырыңыз. Мөмкин кадәр тәрәккыйлеккә иҗтиһад итеп йөргән «Фикер» идарәсенә бер карыш озын тел чыгарып, халык

---

* Начар эшләрдән тыючы булырга.

*Хәкарәт иту* — мыскыллау, хурлау.

*Заэалә* — кечкә генә.

*Асла* — бөтенләй диярлек.

*Әмре мәгъруф иту* — белдерү.

*Мәга һәза* — шул ук вакытта.

*Шәригатькә хилаф* — мөселман дине кануннарына каршы.

*Сахибе мәгъсум дәгел* — хуҗасы кимчелексез түгел.

*Мәнсүх булу* — юкка чыгу.

*Коръәне хәдис* — Коръән сүзләре.

*Та кыямәт* — дөнья беткәнчегә кадәр.

арасына фитнәләр төшереп йөрмәңез дәю, ушбуны — ачык хатны җәнабеңезә язып, берәр-берәр җавапларыңызны да сорыймыз. Сезнең сүзләреңезне мәмнүнән гәзитәмездә басармыз.

## ГАЙНИҖАМАЛ ХӘЗРӘТНЕҢ ДӘХИ БЕР ЯЛГАНЫ

Укучыларымызга мәгълүмдер, күптән түгел генә безнең шәһәрнең имамнарыннан Гайниҗамал хәзрәтнең ялкаулыкка чакырган кыйссаларыны язган идек. Имди шул ук хәзрәт дәхи бер ялган кыйссаны бер мәҗлестә сөйләп, мөридләренең агызларыннан сулар акыздыгыны язамыз. Сөйләгән сүзе бу:

«Фикер» гәзитәсенең мөхәррире кяфер, мәлгунь, аңа ышанмагыз. Мин егерме кеше табармын, типографиясен барып ватыгыз. Хатыннарга качу кирәк. Нитәк ки ривайәтләрдә кәлмешдер ки, бервакыт Хәсән Басри хәзрәтләре бер кызны урамда күреп гашыйк булмыш та шул кызның артыннан үенә чаклы ияреп бармыш. Кыз, үенә җиткәч, әйләнеп караган да, Хәсән Басрины күргәч, ни өчен минем артымнан килдең, дип сораган. Хәсән Басри, мин сиңа гашыйк булдым, дигән. Кыз дәхи, минем каю төшемне яратып гашыйк булдың, дип сорагач, Хәсән Басри хәзрәтләре, күзләреңә гашыйк булдым, дип әйткән. Кыз, туктап тор алайса, мин хәзер чыгармын, дип үенә кереп киткән. Кыз, үенә кергәч, пычак илә күзләрене чыгарып, соңра аларны бер тарелкага салып, Хәсән Басри хәзрәтләренә чыгарып биргән дә үзе үлгән. Менә шулай качарга тиеш!..

Әй монафикъ погромчы! Ике тиенгә дин сатучы. Карамалыда туймаенча, шәһәргә тәмгы итеп килүче синең бу сүзеңнең ялганлыгы: «Һарут, Марут исемле ике фәрештә бер кыз илә зина кыйлып, әле булса газап кыйлыналар, кояш баткандагы кызыллык шуларның канының кызыллыгы», — дигән яһүди кыйссасы кебидер. Син буны сөйләп кемне ышандырмакчы буласың.

Иң әүвәл мизанга салып карыйк. Әгәр ул кыйсса дөрест булып, качарга шул рәвештә тиеш булса, дәхи ничә төрле гөнаһ эшләгән булып табыла. Әүвәл, күз чыгарып, үзеңне-үзең үтерү хәрам, мордар булып китүдер. Икенче, Аллаһе Тәгалә

---

*Мәмнүнән* — канәгатьлек белән.

*Кяфер, мәлгунь* — динсез, ләгънәтләнгән (Иблис кавеме).

*Нитәк ки ривайәтләрдә кәлмешдер ки* — телдә сөйләнеп йөртелгән кебек.

*Үенә* — өенә.

*Монафикъ* — икейөзле.

*Тәмгы итеп* — ачкүзләнеп.

*Мизан* — үлчәү.

*Мордар* — кабахәт, үләксә.

һичкемгә кешенең күзе төшкән йирне кисеп алырга кушмаган, кушмаганны эшләмәк — дәхи иң олугъ гөнаһлардандыр. Өченче, Хәсән Басри хәзрәтләре ул, синең шикелле, Мөхәммәтҗан хаҗидан бурыч кичтерү өчен хәтем чыгып, Коръән сатарга, үзенең мәсҗеден ташлап, икенче мәсҗедкә талаша-талаша бара торган кеше булмаган. Ул, синең шикелле, бер тиенләп ярлыларны да тунап йөрмәгән. Аның ничек кызга күзе төшсен.

Юк, син, алай итеп, Шәрулла байның[1] бер тәңкәсенә кызыгып, погром ясауга чакырып йөрүне кызык күрмә. Ул ялган кыйссаларың үз башыңа булмасыннар.

«Фикер» гәзитәсенең типографиясе алтмыш мең сум торадыр. Ул типографиядә «Фикер»дән башка «Әлгасрел җәдит» һәм «Уклар» журналлары һәм русча телдә «Уральский дневник» гәзитәсе басыла, дәхи нәкадәр төрле эшләр эшләнәдер. Юк, ул кеше нәрсәсен барып кырып вату ансат кына булмас. Синең үзеңнең былтыр гына бер урыс өстенә сигәч тә, мировойга тарттырып, ун тәңкәлек туныңны буяган өчен илле тәңкә түләттең. Алтмыш мең тәңкә түләргә көчең йитсә, килсәң дә килерсең, бәлки, милләт файдасына тырышам дип, гомердә бер кешегә зәррә кадәр хәер күрсәтмәгәнеңне бердән чыгарсаң да гаҗәп түгел. Ләкин агяһ бул, һаман котылмазсән, синең шикелле милләт микробларының хәлләрене инде һәркем беләдер. «Фикер» мөхәррирене үлтерсәңез дә, аның урынына икенче булыр. «Фикер» мөхәррире үлгәнче үзенең фикерләрене вә шәригатьне ничек төшендекене һичкемнән курыкмаенча язачактыр.

Бундан соңра сәнең дә кем идекеңне сөйләп, халыкка тәмам танытырмыз.

## УРАМДА

Урамга чыктым. Карасам — ике кечкенә балага күзем төште. Бу балалар берсен-берсе болай дип хурлашалар:

Берсе: — Фатих — катык, Фатих — катык! Фатих б...к корсак! Ыр-р-рый, ыр-р-рый... Ачуың киләме?! — ди.

Икенчесе [ачуланып]: — Гаяз — көн аяз, Гаяз — көн аяз! Гаяз, эчең быкырдый, тычкан шыкырдый... — дип сузып-сузып әйтә.

Бу көлкене беразерактан карап торгач, яннарына бардым. Ни күзем берлән күрим: безнең иң яхшы, иң үткен мөхәррирләремез икән. Исем дә китте, гакылым да китте. Уф, уф!!!

---

*Мировой* — судья.
*Зәррә кадәр* — тузан бөртеге кадәр.
*Агяһ булу* — белеп тору, сизгер булу.

## ХАКНЫ БЕЛЕП ИНКЯР КЫЛУ

Уральск шәһәренең 4 нче мәсҗед имамы Гайниҗамал хәзрәт «Бәянел батыйль»[1] гәзитәсенең 41 нче номерында качу хакында бик озын фәтвалар яздырган, фәтвасында, ят хатынга карау дөрест, дип язса да, «Фикер» гәзитәсенең мөхәрриренә ни өчендер бик каты кызып сөйләгән сүзен онытып, качмау хәрам, дип сөйли. Шул арада: «Фикер» сахибе[2] шәригатьне таптый, аннан Алла ерак кыйлсын», — дип, дога да кыйлып куя.

Менә саташтыру ничек була! Алла хәйлә вә мәкерләреннән җөмләмезне хәлас әйләсен. Укучылар, сезгә никадәр сөйләсәк тә, кыскачасы шулдыр: бу мулла шәригатьне белми дәгел, беләдер. Ул ялган сөйләүнең дә хәрам идекен, әлбәттә, белсә кирәк. Әмма үзе Шәрәфи тегүче өендә бернәрсә булмады дип җавап биргән. Шәрәфи тегүче өендә булган вакыйга шәһәрдә һәркемгә мәгълүмдер. Ул мәҗлестә хәтта, «Фикер» сахибе ягыннан төшкән өчен, Фәссахетдин карыйны да куып чыгарганнар. Йә, ни өчен шул эшнең башында торып, Гайниҗамал хәзрәт, бернәрсә дә булмады, дип җавап биргән?

Менә шуннан ачык мәгълүм буладыр: Гайниҗамал хәзрәт кебиләр һәрвакыт үз кәефләре яратанча йөреп, алар бәгъзе вакыт шәригатьтә дөрест түгелне дә эшлиләр. Ялган гуаһлык шәригатьтә бик олугъ гөнаһ була торып, Гайниҗамал хәзрәт аны эшләүдән чирканмагач, качу хакында ни өчен дөрестне әйтсен? Гайниҗамал хәзрәт хакны белеп инкяр кыйладыр. Аның кашында качмау хәрам, ялган гуаһ булу хәлаль, кымыз хәрам, кеше малын ашау хәлаль. Пиршиннәрне, Макарларны, урыс булсалар да — дуст күрә, «Фикер» сахибләрене, мөселман булсалар да — дошман күрә. Әле күптән түгел, өйләрен вә өй эчендәге нәрсәләрен килеп яза башлагач, Мортаза байдан егълый-егълый йөз тәңкә акча барып алган, ди. Ул йөз тәңкәне кызыл кар яугач түләрмен, дип, бик зур догалар укып, сакалларын селкетеп алган, дип сөйлиләр. Әле беркөн генә мәсҗедендә халыкка карап егълаган: «Мине «Фикер» сахибеннән ник мәсхәрә иттерәсез?» — дигән. Мәхәллә халкы да, хәзрәтләренең монафикъ икәнлеген белмәгәч, нишләсеннәр? — «Фикер» сахибен судка бирмәкче булганнар. Уйнаш итү күңелле, бала табасы гына читен дигән шикелле, әүвәлдә «Фикер» типог-

---

*Фәтва* — бер эшнең дөреслеге яки дөрес түгеллеге турында кистереп әйтү.

*Җөмләмезне хәлас әйләсен* — барыбызны да коткарсын.

*Гуаһлык итү* — шаһитлык итү.

рафиясен вату дип сөйләү жиңел булса да, хәзер җаваплаша башлагач, эш читенләшеп: «Илаһым, «Фикер» сахибеннән ерак кыйл, байлар кесәсенә якын кыйл», — дип егълый-егълый, мәхәллә халкына жаловаться итәргә калды. Ул — шулай: «Дөнья — кулиса, әйләнә дә бер баса». Моннан берничә ел әүвәл урысча хәрам, осуле җәдит хәрам, дип йөргәннәр иде. Анда да шул курчак уены корып, бәхәсләр чыгарып, ашлар күбәйсен дип котыртып, халыкны уйкуга гына калдыру иде. Хәзер дә шулай ук: үзендә бер мискинлек вә муллалык күрсәткән булып, халыктан азмы-күпме яумас микән, дип сөйләргә тотындылар. Иншалла, халкымыз бу гафләт уйкусыннан уянып, бу ялганчыларның хәйлә вә мәкерләрен аңласалар кирәк.

## ШӘҺӘРЕМЕЗДӘГЕ ЗУР ТӘМГЫЛЫ МУЛЛАЛАРӘ БЕР-ИКЕ СҮЗ

Без, җөмлә саф күңелле, һичбер кешегә сәбәпсез зарар уйламаучы мәхәллә кешеләре, бу арада бәгъзе тәмгылы муллаларның, байларга ярамак нияте илә нәфесләрен сузып, «Фикер» гәзитәсенең мөхәррире — кяфер һәм аның атасы Мотыйгулла хәзрәт тә — кяфер, дип сүз чыгарып йөрүләренә бик зур хафадамыз. Ни өчен дисәңез, ул газизләремезне кяфер, дигәч, безләрдә күптән иман юк, диерсез.

Юк, хәзрәтләр, алай иттереп, сезнең шикелле, тәмгыга нәфесне җибәрмәйүб, үзалдына бер хезмәт тапкан сәбәпле, бер кешене кяфер дип йөрү бик зур кабахәтлектер.

Газиз иман капкасының ачкычы сезнең кулыңызга бирелмәмештер. Сез үзеңез теләгән кешеләрне иман капкасыннан кертеп, теләмәгәнне чыгарып җибәрүгә нинди права таптыңыз? Юк, сездә бернинди дә права юк. Сез тик «Фикер» мөхәрриренең, сәдака алмаенча, тәмгысыз үзбашына эш иткәнен күрә алмайсыз.

Сезнең бу эшеңез менә ушбу кыйссага охшыйдыр.

### Качыр илә Үрмәкүч

Көннәрдә бер көн сәхрада Качыр, утлап ашап йөргәндә, бер агачның төбендә оя ясап тора торган Үрмәкүчне күреп:

— И Үрмәкүч карендәш, нишлисең? — дип сорады.

---

*Гафләт* — наданлык.
*Тәмгылы* — ачкүзле.
*Права (право)* — хокук.

Үрмәкүч:

— Агач күләгәсендә рәхәтләнеп ышыкланып торырга бер оя ясыйм һәм мәгыйшәтем өчен бер тозак корамын, — диде.

Качыр (Үрмәкүчтән бу сүзне ишеткәч, көлеп):

— И Үрмәкүч, мин синең бу кадәр гакылсызлыгыңа хәйран булам. Дөньяда киченмәкнең бик җиңел тарикълары була торып, син бу кадәр биналар, стройкалар төзеп вә тозаклар корып маташасың. Менә миннән гыйбрәт ал: мин, ерткыч хайваннар падишаһы арысланга мөлязәмәт кыйлып, анарга төрле-төрле хикәяләр сөйләп, аңа монафикълык вә мөдаһәнә итәмен. Бик рәхәт вә тыныч көн кичерәмен. Арысланның яралап ташлаган хайваннарыннан теләгән төшемне ашап, хозур кыйлып йөримен.

Үрмәкүч:

— И бичара, надан Качыр? Син иренчәклегең аркасында үзеңне бер бәлагә салган икәнсең. Бер-ике локмә өчен ерткыч бер хайванга үзеңне-үзең кол кыйлгансың. Никадәр монафикълык вә ялган сөйләүне муеныңа алгансың. Хәлбуки бер көн булыр, сәламәт халык күрер, ул ерткыч хайван, синең аз гына кимчелегеңне күреп, сине парә-парә кыйлып ташлар. Вә моннан катгы назар, и бичара хайван, иренчәклекнең кәсафәтендә, бер-ике локмә иткә вә тәрилкә ялаучылыкка үзеңнең хөррияте шәхсияңне сатып, бер ерткыч хайванга кол булгансың. Үз теләвеңне куеп, һәрбер йөрү вә тырышуыңны шул ерткычның теләгәненчә кыйлмакка мәҗбүр булгансың. Мин, әлхәмделиллаһ, ушбу йортымда полный хозяин, һәр эшемне үземнең ихтыярым илә эшлим. Ушбу тозагыма төшкән ауны, кәмал кәеф вә хозурым илә, теләгәнчә, күкрәгемне киереп ашыйм. Кешедән калган валчык вә табак яламакны минем бөек һиммәтем һичбер вакыт кабул итмәс. Минем тозагыма төшкән бер чебен синең рияланып вә монафикъланып вә ялган сүзләр сөйләп ерткыч хайванны көлдереп вә аның һәрбер у...на «ярхәмекә Алла» диеп, курка-курка ашап, ләббәйкә диеп торуларыңнан мең мәртәбә артык.

---

*Мәгыйшәт* — тормыш.
*Тарикъ* — юл, чара.
*Мөлязәмәт кыйлу* — хезмәт итү.
*Монафикълык вә мөдаһәнә* — икейөзлеләнү һәм ялагайлану.
*Локмә* — бер кабым ризык.
*Парә-парә кыйлу* — өзгәләп, ерткалап ташлау.
*Моннан катгы назар* — моны искә алмаганда да.
*Иренчәклек кәсафәтендә* — ялкаулык сәбәпле.
*Кәмал* — тулысынча.
*Һиммәтем* — табигатем.
*Ләббәйкә* — ни боерасыз, мин әзер мәгънәсендә.

* * *

Менә бу хикәяттән аңлашыладыр ки, һәр кешенең үз трудасы вә хәлаль кәсебе илә тапкан бер телем икмәге кеше ишегендә йөреп, байларның йөрми торган сукыр тиеннәренә күз йибәреп, юк шәригатьләр чыгарып, фәлән кеше кяфер, фәлән — фасикъ, син генә яхшы дип мактап яхшы булудин артыктыр дип беләмез.

Сезгә алай итү кирәкмәс иде, чөнки, безнең белүемезчә, «Фикер» гәзитәсенең мөхәррире һәртөрле тарафдин хәбәрләр язып вә һәр фәннән без мужикларга һәр атна дәрес биреп торадыр, ягъни төрле-төрле гәзитәләр, журналлар вә китаплар бастырып, җәмәгатьнең уйкудин күзләре ачылса вә «Качыр илә Үрмәкүч» кыйссасындагы кеби монафикъларның алдауларыннан котылсалар икән дип тырышадыр.

Шуңа күрә сезнең болай каршы торуыңызны бик зур гөнаһ дип беләмез. Бу эшләреңезне ташлап, тәүбә кыйлмак, кайтмак кирәк. Сезгә һәм безгә ни җитмәгән? Сез һәркаюларыңыз бер мәсҗедтә имам булып торасыз. Сезнең урыныңызга үзеңез бар заманда һичкем күз йибәрми. Без исәк һәркаюмыз, Аллага шөкер, төрле-төрле кәсепләр илә шөгыльләнеп йөримез.

## ИДАРӘДӘН

Мөхтәрәм рәфикъләремезә гарзы тәшәккер.

«Бәянел хак» клишесе астындагы гәзитәнең тәшвикъ вә тәргыйбләре саясендә идарәмези берничә карагруһларың ватмак эстәдекләри хосуста «Таң йолдызы», «Борһане тәрәкъкый», «Әлгаләмел ислами» гәзитәләре гаять инсаният вә өхүввәт сүзләр яздылар.

Рәфикъләремезең бу хосуста безә вә мәгънән милләтә күстәрдекләре мәгунәт ичүн без, бөтен һәйьәт идарә, бер агыздан: «Яшәңез, мөхтәрәм рәфикъләр, яшәңез, карендәшләр!» — сүзләре илә ибраз мәүдәт вә тәшәккер идиюрез.

Инсан ата берлек илә карендәш улмаз, бәлки фикер вә мәсләк берлеге илә карендәш улыр. Бинаән галәйһи Гариф хәзрәтләри вә Садыйк хәзрәтләри, безә дин чишмәсе күстәреб, милләти янә шунларың бак аләтендә ничә вә ничә гасырлар изеп, гакыйбәт татарның намене билә җир йөзеннән калдырмайа чалыйшан «Бәянел хак»тан башка барча гәзитәләр бере дигәри илә кардәшчә генә мөгамәлә итмәледер. Без гәзитә галәменә шу хәясыз милләт кортларыннан качып кердек дәгелме?

---

*Фасикъ* — бозык.

Артык анларың тавышларын ишетмәйә вә анларын онытмайа карар вирмәдекме? Бөйлә исә, бәр фараз: анлар кәндиләринә «Бәянел хак» кеби бер мөтәгассыйб тарафдар булып та, янә безә аяк чалмак эстәсәләр, янә бези әсфәлес сафилинә инмәйә дәгъвәт итсәләр, без анларын әл берлекилә дүкеб вә, яхуд «ләкем мәсләккем вә ляна мәсләк?» кеби бер йомшак сүз сөйләб, һәр нәсылсә озаклашдыралым.

Йитәр дин исемендән инсан таламак, йитәр шәригать исемендән халыкны каралтмак, йитәр болганчык суда балык ауламак! Батсын мөтәгассыйбләр! Яшәсен яңа, яшь милләт каһреманнары!

## *Тәрҗемәсе:*

## ИДАРӘДӘН

Хөрмәтле иптәшләребезгә рәхмәт белдерү.

«Бәянел хак» клишесе астындагы гәзитәнең котырту һәм өстерүләре аркасында редакциябезне берничә карагруһларның ватарга ниятләнүләренә бәйләнештә «Таң йолдызы», «Борһане тәрәкъкый», «Әлгаләмел ислами» газеталары гаять кешелеклелек, кардәшлек хисләре тулы сүзләр яздылар.

Иптәшләребезнең безгә һәм чынында милләткә ярдәм итәргә теләүләре өчен без, бөтен редакция, беравыздан: «Яшәгез, хөрмәтле иптәшләр, яшәгез, карендәшләр!» — сүзләре белән дуслык хисләре һәм рәхмәтебезне белдерәбез.

Кеше ата берлек белән туган түгел, бәлки фикер һәм тоткан юлы белән кардәш була. Шуңа күрә Гариф хәзрәтләре һәм Садыйк хәзрәтләре, безгә дин чишмәсен күрсәтеп, милләтне тагын да шуларның коралы белән ничә һәм ничә гасырлар изеп, нәтиҗәдә татарның исемен дә җир йөзендә калдырмаска тырышкан «Бәянел хак»тан башка барлык газеталар бер-бере белән кардәшләрчә генә эш итәргә тиешләр. Без газеталар дөньясына шушы оятсыз милләт кортларыннан качып кердек түгелмени?

Аларның тавышларын бөтән ишетмәскә, аларны онытырга карар бирдек түгелме? Шулай булып, уйлап карыйк: алар, үзләренең «Бәянел хак» ише бер фанатик яклаучылары булгач, яңадан да безгә аяк чалырга маташсалар, янә безне алар белән кычкырышу кебек түбәнлеккә сөйрәсәләр, без аларны бергәләшеп юлдан алып ташлап, яки «безнең юл беләнме, әллә түгелме?» дигән сорау куеп, ничек тә аларны ераклаштырыйк (изолировать итик).

Җитәр дин исеменнән кеше талау, җитәр шәригать исеменнән халыкны каралту, җитәр болганчык суда балык тоту! Батсын фанатиклар! Яшәсен яңа, яшь милләт каһарманнары!

## ИДАРӘДӘН ҖАВАПЛАР

Хөрмәтле Фатих әл-Әмирхан әфәнде! «Әлгасрел җәдит» журналына махсус йибәрдекеңез «Коммуна» әсәре — заманымызда табгы вә интишаре гаять мөһим бер әсәрдер. Шуның өчен Сездән риҗа итәмез, мәзкүр әсәреӊ дөрест басылмасы өчен беловойга язып йибәрәсез; бер бозып, бер сызып язган черновоеңызны аңламак, хосусән мөрәттибләр өчен, бик мөшкелдер. Мадам ки, тәрҗемәсенә һиммәт итмешсез, бер дә беловойга язмага да иренмәңез.

Яңа Яндуфкада гыйззәтлү Әхмәтсафа әфәнде! «Фикер»гә мөхбирлек итәргә дәртеңез булса, мөмкин кадәр файдалы вә хикмәтле нәрсәләр язарга тырышыңыз, мәктүбләреңезең арасында мөляхәзәсезрәк язылганнары да булганлыктан, сайлап вә чүпләп кенә басарга тугъры киләдер.

## «ТӘРҖЕМАН»НЫҢ КЯЗИБЕ

Үзенең нәфесе эстәдекенчә милләти әгъфаль идеб фаидә казанмайа үгрәнмеш «Тәрҗеман» бабай 85 нче номерлы гәзитәсендә, бер-ике сәтыр ап-ачык ялган гыйбарәләр илә, белмәм нә сәбәптәндер, безә һөҗүм итмәк эстәмеш.

У димеш ки:

Муазәнәсезлек шу дәрәҗәйә варды ки, гәзитәләрең берендә шәригатьтә мәстурият юктыр, кадын-кыз ачык йөрмәк ляземдер фикере язылып, дигәрендә хәҗ шәрифең мәгънәсез бер шәй улдыгы тәрсим-рәсем илә игълан иделде.

Уиләме, «Тәрҗеман» бабай, сүзеңездә яңылмый йөрмисез? Юхса, гәзитәләрнең чугалмасына хөсед идеб, берәр бең мөштәриеңез кәмүр занилә бездән укучыларымызый нәфрәт итдермәкме эстәюрсез?

Без кайу номерда шәригатьтә мәстурият юк дидек вә кайу гәзитәмездә хәҗ шәрифең мәгънәсез улдыгыны яздык? Бөйлә сарих кязиби истигъмалә нә өчен хаҗәтеңез дөшде?

---

*Табгы вә интишаре* — басылуы һәм халык арасында таралуы.
*Риҗа иту* — сорау, өмет иту.
*Мәзкур* — әлеге.
*Беловойга язып* — акка күчереп.
*Черновой* — каралама.
*Хосусән мөрәттибләр өчен* — бигрәк тә корректорлар өчен.
*Мадам ки* — шулай булгач.
*Тәрҗемәсенә һиммәт итмешсез* — тәрҗемәсен тырышып эшләгәнсез.
*Мөхбирлек иту* — язышу, хәбәрчесе булу.
*Мөляхәзәсезрәк* — игътибарсызрак, талымсызрак.

Әйе, беленңез ки, без тиешлечә хиҗабең лөзүмилә вә хәҗең фарзыйтилә каилез: мөселманларың хөррә кадынлары кәнизәк кадынлардан имтияз улынмасы кадәр хиҗаб заруридер.

Хәҗ исә һәр мөселман улан коллара фарыздыр. Бунлары без асла инкяр итмәдек. Фәкать, сезең кеби бушбугазларың гәзитәсенә парә исраф идәрәк фаида өмид идән затлар кеби, Хиҗазә мәгъфирәт тарызы кидеб, тиешсез йирләрә бөек мәблә̆гъ маллар быракыб килдекләрене тәрсим әйләдек.

Йә, сез нә япдыңыз, бакалем: дөньяда бөтен мәгърифәт ике нөсхә «Ха-ха-ха» журналында[1] тупланып бетдеме, имеш? Юхса Сөләйман ака илә Иван аканың мөкяләмәсе[2] тукталды да, анлара башка дөньяда мәгърифәтле затлар калмады дәгъвәсендәме булыныюрсыз?

Бөйлә дәвам идәр исәңез, намеңез «карагруһ дистәсе»* (яки бюрократия хадимәләре) арасында языларак тарихларда калачагыны якын беленңез. Әгәр дөшенер исәңез, сүзең татарчасы будыр. Илерүдә җавабыңызә күрә идарәи кәлям идәчәкемези вәгъдәләшмәдилек иктифа идәрез. Косуратымызы гафу боерасыз, әфәндем.

### *Тәрҗемәсе:*

## «ТӘРҖЕМАН»НЫҢ ЯЛГАНЫ

Милләт белән үзе теләгәнчә эш итеп файда табарга өйрәнгән «Тәрҗеман» бабай 85 нче номерлы газетасында, берике юл ап-ачык ялган гыйбарәләр белән, белмим ни сәбәптәндер, безгә һөҗүм итәргә тели.

Ул болай ди:

Үлчәми эш итү, сөйләү шул дәрәҗәгә җитте ки, газеталарның берсендә шәригатьтә тәртип, эзлеклелек юк, хатын-кыз ачык йөрергә тиеш дигән фикер язылып, икенчесендә изге хаҗның мәгънәсез бернәрсә булуы рәсемдә сурәтләп күрсәтелде.

Шулаймы соң, «Тәрҗеман» бабай, сүзегездә ялгышып китмисезме? Югыйсә, газеталарның күбәюеннән көнләшеп, яздырып алдыручы укучының (подписчикның) берәр меңе кимер дип куркып, безгә карата укучыларыбызда нәфрәт уятырга тырышасызмы?

Без кайсы санда шәригатьтә тәртип юк дидек һәм кайсы газетабызда изге хаҗның мәгънәсез булуы хакында яздык? Мондый ап-ачык ялган куллану сезгә нигә кирәк булды?

* Русчадагы «черная сотня» — «черносотенцы» мәгънәсендә.

Әйе, шуны белегез, без кирәк кадәр йөз өртүнең тиешлеге һәм хаҗның фарызлыгын белеп әйтәбез: мөселманнарның иреkле хатыннары кол хатыннардан аерылып торыр дәрәҗәдә йөз өртү кирәк.

Хаҗ исә мөселман булган һәр Алла колына фарыз. Боларны без һич тә инкяр итмәдек. Фәкать, сезнең ише бушбугазларның газетасына акча исраф итеп файда өмет иткән кешеләр кебек, хаҗга гөнаһларыннан арыну өчен китеп тә, тиешсез урыннарга зур акчалар түгеп кайтуларын рәсемләп күрсәттек.

Йә, сез нәрсә кырдыгыз, күрик әле: дөньяда бөтен мәгърифәт «Ха-ха-ха» журналында тупланып беттеме әллә? Яисә Сөләйман ака белән Иван аканың гәпләшүе тукталды да, алардан башка дөньяда мәгърифәтле кешеләр калмады дигән дәгъвәдә каласызмы?

Болай дәвам итсәгез, исемегез «карагруһлар дистәсе» (яки бюрократия ялчылары) арасына язылып, тарихларда калачагын яхшы белегез. Аңлар булсагыз, татарчасы менә шулай. Булачак җавабыгызга карап, идарәнең сүзен әйтәчәгебезне вәгъдә итү белән канәгатьләнәбез. Җитешсезлекләребезне гафу итәсез, әфәндем.

## ГҮЗӘЛ БЕР ХАКЫЙКАТЬ

«Бәянел хак»ның 50 нче номерында «Кабих бер ифтира» сәрләүхәсе илә* кабих гыйбарәле бер лакыйрди язылып, гүя «Бәянел хак» идарәсеннән безгә: «Гәзитәңезне җибәреп торыңыз; мөхәррир кычкырышына идарә гаепле булмаса кирәк» сүзләре язылган мәктүб килгәне ялган икәнене исбатка тырышылмыштыр.

Хәер, безгә бөйлә мәктүб килде, әмма «Бәянел хак» идарәсеннән килде. Без башканы белмибез. Әгәр ышанмасаңыз, мөхәррирләреңездән Әхмәтҗан абзый яки Мөхәммәтҗан абзый килеп карасын. Яисә секретарь Габдерәкыйп Габдерәкыйпов килеп карасын. Кайсыгыз язгансыз — шунда беленер. Һәр нә исә, килүеңез бушка китмәс, язган язуыңызның карасын пычак берлән кырып алып китәрсез. Бездә сезнең «Бәянел хак» чыга башлагач та мөбадалә теләп язган мәктүбеңез дә бар, кирәк булса, анысын да биреп җибәрермез.

---

* «Кабахәт бер яла» исеме белән.

*Һәр нә исә* — ни генә булмасын.

*Мөбадалә теләп* — алмаштыруны (бер-беренә үз газеталарын җибәреп торуны) теләп.

Тагы безне хулиган-фәлән дип кимсетмәкче булгансыз. Сезнең бу эшеңез — «Бәянел хак» гәзитәмезне вә мөхәрриремезне Әхмәтҗан Сәйдәшев дип атамак кабиленнәндер. Вәхаләнки, безнең гәзитәмез «Бәянел хак» вә мөхәрриремез Әхмәтҗан Сәйдәшев түгел икәне сезгә һәм бөтен дөньяга бик ачык мәгълүм бер хәкыйкатьтер. Бинаән галәйһи безне хулиган дип атамакыңыз — үзен эләктерә башлагач: «Урламагыз, урламагыз!» — дип кычкыра торган карак сүзе төслүк бер сүздер. Бик кызык сез, Әхмәтҗан абзый, үзеңездән чыккан нәҗесне кеше өстенә сылап, җиңел генә котылмакчы буласыз. Тукта әле, иптәш, «Фикер»нең һәйьәт идарәсе үлмәгән. Алай юкны-барны лыкылдасаңыз, әллә нәрсәләр ишетерсез. Сез үзегез дә, «Фикер» идарәсеннән һәрнәрсәне көтәмез һәм бу кадәр тәрәкъкый кыйла алмас дип уйлаган идек, тәрәкъкый итте бит, дип язасыз. Дөрест. Шулай шул. Тәрәкъкый дә итәмез, һәр нәрсәне көттерәмез дә. Бөтен мөхәррирләр иң көчле, иң куәтле баш бюрократия берлән талашып ятканда, без бер бетерешкән бюрократ Әхмәтҗан бабайдан куркыйкмыни? Тагы язармыз, тагы басармыз, — без мөһаҗим улмай, анчак мөдафигъ улдыкымыз җәһәттән хәкыйкан бәхтиярез*.

## ТУГЪРЫ СҮЗ

Дәүликам стансасында фазыйләтле Ибраһим әфәнде Сәйфуллин җәнабләре «Бәянел хак» гәзитәсенең кабахәт мәсләктә улып, укучыларыны җәфа итдеке тугърысында безә бик озын мәкалә язмыштыр. Бу хакта гәзитәмездә бик күп кәррәләр язылдыгына күрә, Ибраһим әфәнденең бу мәктүбене дәреҗ итмәюрез. Фәкать кыскача фикерене укучыларымыза аңлатыр исәк, зарар итмәз.

Ибраһим әфәнде әйтәдер:

«Бәянел хак» гәзитәсенең нашире Ахмакҗан бабай гаять мөтәгассыйб вә монафикъ адәмдер. Гәзитәсенең ике тарафы «Аркадия» бакчаларында матур апаларның игъланнары һәм һәр-

---

* Һөҗүм итүче (сугышны башлаучы) булмыйча, тик каршы торып аны кире кагучы булуыбыз белән чын бәхетлебез.

*Кабиленнән* — шикелле.

*Вәхаләнки* — чынлыкта.

*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.

*Нәҗес* — шакшы.

*Һәйьәт идарәсе* — редколлегия, редакция.

*Фазыйләтле* — хөрмәтле, яхшы кеше.

*Кәррә* — тапкыр.

*Мәктүбне дәреҗ итмәюрез* — хатны басмыйбыз.

*Мөтәгассыйб вә монафикъ* — фанатик, үҗәт һәм икейөзле.

төрле эчемлек вә сыраларның игъланнары илә тулып торса да, хатыннар качып йөрсен, качмасалар, урыска охшау була, ди. Хәлбуки үзе матур-матур марҗалар янына сәергә чакырып, һәркөн гәзитәсендә игълан баса. Әгәр Ахмакҗан бабай монафикъ вә җаһил кеше булмаса иде, бу тарика эш кыйлмаз иде.

Ибраһим Сәйфуллин карендәшемезең бу сүзләре гаять дугърыдыр. Укучыларымыза гыйбрәт.

## АЛЫРГА АШЫГЫҢЫЗ!

Звериноголовскидә вакытлы аптик ачылды. Сукырайта торган, баш авырттыра торган, эч күптерә торган, сару кайната торган вә башка төрле дарулар сатыладыр.

Аптик иясе бер мөсафир хаҗи исемләнмеш кешедер. Даруларының бәгъзесе Азия балчыгы, Африка үләне, Амрика ташы вә Аурупа агачларының экәләләреннән гыйбарәттер.

Аптикчеләр: хаҗи исеме таккан бер мөсафир, фатир сахибәсе, татар микробы, өй корткасы.

Шул ук фатирда һәртөрле сөйдергеч имнәре, боздыргыч тылсымнары, туздыргыч дәвалары, саранча догалары, васыйлян бөтиләре, «Бәянел хак» гәзитәләре табарга мөмкиндер. Мөштәриләр сакаллы сабый вә җаһилә хатыннар улып, сатучыларның сүзенә камил ихлас илә ышанмаклары шарттыр.

Хилафынча булса, мәзкүр дарулар әсәр итмәячәктер.

## АХУН ХӘЗРӘТЛӘРНЕҢ САТЫЛУЛАРЫ

Бай: — Хәзрәт, кыз балаларны русча укытырга вә качмаенча йөртергә ярыймы?

Ахун: — Юк, юк! Кыз-хатынга уку хәрам. Хосусән русча уку хәрам; соңра да хиҗаб, әлбәттә, фарыз!

---

*Сәергә* — барырга.
*Җаһил* — надан.
*Тарика* — юл белән.
*Сахибә* — ия (хуҗа хатын).
*Васыйлян* — кавыштыру.
*Мөштәри* — сатып алучы.
*Җаһилә* — надан (хатын-кыз).
*Хилафынча* — киресенчә.
*Мәзкүр* — шул, әлеге.
*Әсәр итмәү* — тәэсир итмәү.
*Хосусән* — бигрәк тә.
*Хиҗаб* — хатын-кызның ирләрдән качуы, йөз яшерүе.
*Фарыз* — һичшиксез тиеш (эш).

Бай: — Безгә бирәчәкеңез улан 180 сумны зәкяттән исәпләп, дога идүеңезне үтенәмез.

Ахун: — Бәрәкалла! Бик яхшы, Алла кабул итсен.

Бай: — Тәкъсир, янә бер сүз сорар идем.

Ахун: — Рәхим идеңез.

Бай: — Тәкъсир... ә... ә... без ресторан илә сәүдә итмәкче идек. Шунда кызлар тотмакмыз; шәрган ничек булыр икән?

Ахун (исәпләп торып: «180 сум агызмы бер якка да бордырмай»): — Дөрест ул! Чөнки синдә кәсеп, синең аңардан башка кәсебең юк. Дөрест, дөрест! (Йөз сиксән сум гайрәте илә.) Дөрест!

## ЯҢА ДӘГЪВА

Күптән түгел Казанда «Азат» гәзитәсе вафат булган иде[1]. Шуның фидиясе кемнәргә бүленгәне мәгълүм булмады. Мирас малы бүлендеме икән? Уральскидә бер варисмы яисә фидия алучымы минем «Азат»тан бер-ике тәңкә алачагым бар, дип дәгъва кыйлып йөри.

## ТИМЕРЧЫБЫКСЫЗ ТЕЛЕГРАМ ХӘБӘРЛӘРЕ

Казан. «Бәянел корсак» гәзитәсенең идарәсендә Ахмакҗан бабайда «көфер» пичәтләре сатыладыр.

Соратканнарга һәр тарафка буш җибәреләдер.

Саратов. Татарларга шәһәрнең яхшы урамнарына кереп йөрергә ярамый, дип фәтва бирелгән. Шуның өчен Саратовтан узып киткән мөсафирлар, шәһәрнең яхшы урыннарында гына гиздекләренә күрә, бер дә бу шәһәрдә татар юк икән дип хөкем итеп китәләр. Толчок илә Идел буенда кара эшче татарларның хисабы юктыр.

Уфа. Бәдертдин Нәзирев харчәүнәсе хаҗәтханә ясалып, имтиханга барган кешеләр шунда яшел тышлы китапны алып, хаҗәтләрен бетереп кайтачаклар, имеш.

Мәкәрҗә. Бу ел мөселманнар җәмгыяте булмас, ахрысы, надан татар бәтчәләре Фоли-бержер бакчасында үзләренең кәефендә, кайсы рестораннарда гыйш-гыйшрәт итәләр. Бәгъзесе, Казанда, үзем киткәч, хатын Черек күл, Аркадия бакчаларына чыгып, егетләр илә гуляйт итәр дип тизрәк кайтырга ашыгалар. Казанда Ахмакҗан бабай Черек күл ишеге төбендә каравыл торып, чапансыз мөселман хатыннарын бакчага

---

*Тәкъсир* — руханиларны олылау сүзе.
*Шәрган* — шәригатьчә.

кертмәскә тырышса да, Мәкәрҗәдә байларның күңеле тыныч таба алмый. Нәгъләт суккыры! Бу ел чапан кигән хатыннардан да гуляйт итүче күп икән.

Багъчасарай. «Тәрҗеман» бабайның социалистлар корсагын яра язганнар. «Тәрҗеман» бабай көч илә ялынып котылып калган.

## «ӨЛФӘТ»КӘ ҖАВАП

«Өлфәт» гәзитәсенең 34 нче номерында сарих киная илә безем «Уклар» журналында «җим» вә «мим»ләри мәдех әйләмәк дугърысында гаять мөтәгассыйбанә «Сибирияле Х.Мәхмүдев» имзасилә бер тәнкыйть язылмыштыр.

Шулаймы? Ярый, шулай булса, тик Петербурда татар байларының аркасын сыйпап кына яту лязим икән. Фәкать тәнкыйтьне «Миръат»[1] китапларыннан башламак жирәк иде, чөнки анда безем «Уклар»да язылганның мозагафы илә мәүҗүддер...

Хәер! Тәнкыйтьтән максуд хакыйкате күстәрмәк дәгел идеке мәгълүм, йа...

Вакыт кәлүр. Һәп әсрар мәйдана чыкар.

Фә зәрһүм фи хаузиһим йәлгабун*.

## «ЗАМАНЫМЫЗНЫҢ ӘДИБ ВӘ МӨХӘРРИРЛӘРЕНӘ ГАИД» МӘКАЛӘСЕНӘ ГАИД

Сибирияле Х. Мәхмүдев әфәнде хәзрәтләре!

«Өлфәт»нең 33 нче, 34 нче номеруларында заманымызның әдиб вә мөхәррирләренең җөмлә яздыкларыни тәнкыйть боермышсыз. Гүзәл; фәкать Сездән бер сөалем вар: мадам ки, Сез гадимел мисле бер зате гали имешсез, нә ичүн мөхәррирләр вә әдибләрең яздыкларыни шу сурәттә тәнкыйть илә генә кифаяләндеңез? Сезең шәәне галиеңезә күрә, бу мөхәррирләри берәр-берәр хозуры галиләреңезә җәлеб идеб тәнбиһ итмәк лязим иде дәгелмә? Гүзәл; мөхәррирләр, Сезчә, фәна вә ярамаз адәмләр улсын, ләкин Сез кәндиңез милләте нә япды-

---

*...аларны буш сөйләшүләре белән күңел ачуларында калдыр. (Коръәндә 6 сүрәнең 91 аяте ахыры.)

*Сарих* — ап-ачык.

*Мәдех әйләмәк* — мактау.

*Мөтәгассыйбанә* — фанатикларча, үҗәтләнеп.

*Имзасилә* — имзасы белән.

*Лязим* — тиеш.

*Миръат* — көзге.

*Мозагафы илә мәүҗүд* — артыгы белән бар.

*Һәп әсрар* — барлык (яшерен) серләр.

ңыз? Милләтең халь вә истикъбаленә нафигъ мәнзум яки мәнсур бер әсәреңез мәйданда вармыдыр? Күстәреңез, бер кәррә моталәга идәлем дә, башкаларың яздыклари мәтрүк вә манси калсын.

Сезең шимдилек яшеңез тәхминән 30 дан әксәк улмаз. Инсаның гомери галибән 100 сәнәи тәҗавез итмәз. Әгәр кәчмеш гомереңез кеби киләчәк гомереңези дә үзеңездән бөекләре италәи лисаны тавилеңез илә кәчерерсәңез, вай хәлеңезә, вай! Һәр мөхәррирең кәндинчә бер мәсләке, бер юлы вардыр; бинаән галәйһи, анлари тәнкыйтьтә мөсарәгать итмәзсәңез дә, хата итмәмеш удыр идеңез. Мөхәррирләр мәҗнүн дәгелдерләр, анлар бәйтуллаһи тәхкыйрь итмәзләр; «тәхкыйрь итде, хурлады» диянләрең даирәи инсафтан годул идеб, даирәи тәгассыбә чыкыб сөйләдекләре һәр гакыйлә мәгълүм бер хакыйкатьдер. Дин вә диянәт сатмак чук әйи бер кәсебдер. Ихтимал ки, Сез дә шу файдалы сәүдәи итмәйә мәраклысыз, — мөбарәк улсын, борадәр, сәүдәңез, мөбарәк улсын! Дин димәк — бетмәз-төкәнмәз бер хәзинәдер. Алыңыз, сарыф итеңез, таҗирләрнең дөньясы тәэмин улынмышдыр. Гавам арасында мәмдухдыр. Тарих сәхифәләрендә мәзмүм исә, нә бәэс!..

Һәр языйҗи кәнди яздыкларының Сибириядә бер татарың хушына китмәдекени вә яки Садыйк мулланың тәкъфир идәҗәкени дөшенеб, каләмне зынҗырлаяҗак исә гәзитә сәхифәләренә кемләр язаҗак? Вә җәнабеңезә тәнкыйть итмәйә нәләр калаҗак? Сезең шу тәнкыйть юллы яздыкыңыз мәкаләңезең тәнкыйть вә тәфтишә моктах дәгел идекенә сибирияле Х.Мәхмүдевтән башка кимләр кул куяҗак? Әвәт, безем яздыкларымызда да косур һәм дә бөек косурлар ула билүр. Без мәкаләләремезең сәрләүхәсенә: «Иштә, бу мәкалә вә йә бу шигырь җәмигъ нәкаис вә косуратдан мөнәззәһдер», — дия язмадык, йа! Без галәме мәдәниятең элифбаҗиларыйыз. Айлар, еллар кәчәр, әлифбадан кәчәрез, бөедекчә бөерез. Берзаман «Фәзаилеш шөһүр»ең әдәби бер рисалә вә «Бәдәвам» илә «Кисекбаш»ың милли шигырь мәҗмугаләре йирен тотдыкларыни да онытмамалый!..

*Тәрҗем/се:*

## «ЗАМАНЫБЫЗНЫҢ ЯЗУЧЫ ҺӘМ ЖУРНАЛИСТЛАРЫ ТУРЫНДА» ДИГӘН МӘКАЛӘ ТУРЫНДА

Сибирияле Х.Мәхмүдев әфәнде хәзрәтләре!

«Өлфәт»нең 33 нче, 34 нче номерларында заманыбызның язучы һәм журналистларының барлык язганнарын тәнкыйть

иткәнсез. Гүзәл; бары Сездән бер соравым бар: инде Сез охшашы күрелмәгән бер бөек кеше икәнсез, ни өчен язучы һәм журналистларның язганнарын шул рәвешле тәнкыйть белән генә чикләндегез? Сезнең югары дәрәҗәгезгә күрә, ул язучыларны берәм-берәм үз яныгызга чакырып, кисәтү ясау кирәк түгел идеме? Ярый, язучылар, Сезнеңчә, начар һәм яраксыз кешеләр булсыннар, ләкин Сез үзегез милләткә нәрсә эшләдегез? Милләтнең хәзергесе һәм киләчәге өчен файдалы чәчмә яки тезмә бирәр нәрсәгез бармы? Күрсәтегез, бер тапкыр тикшереп карыйк та, башкаларның язганнары бөтенләй ташлансын, онытылсын.

Хәзер Сезнең яшегез якынча 30 дан түбән булмас. Кешенең гомере, күбесенчә, йөз елдан узмый. Әгәр, үткәндәге кебек, киләчәктә дә үзегездән бөекләргә озын телегезне озайтып үткәрсәгез, вай хәлегезгә, вай! Һәр язучының үзенә бер мәсләге, тоткан юлы бар; шуңар күрә аларны тәнкыйтькә ашыкмаган булсагыз да ялгыш булмас иде. Язучылар юләр түгел, алар Алла йортын (кәгъбәне дигән сүз. — *Ред.*) кимсетмиләр, хурламыйлар; «кимсетте, хурлады» дип әйтүчеләрнең, инсаф чикләреннән чыгып, кирелек, тискәрелек белән генә сөйләүләре акылы булган һәр кешегә билгеле хәкыйкать бит. Динле булып күренү бик яхшы бер кәсеп ул. Ихтимал, Сез дә шул файдалы кәсепкә керешергә кызыга торгансыздыр, — котлы булсын, туганкай, сәүдәгез, котлы булсын! Дин димәк — бетмәс-төкәнмәс бер хәзинә ул. Алыгыз, динне шуңа тотыгыз, аның белән сату итүчеләрнең дөньясы тәэмин ителгән. Гади халык арасында мактаулы. Тарих битләрендә хурлана икән, аннан ни зарар!..

Һәр язучы, үз язганнарының сибирияле бер татарга ошамаячагына яки Садыйк мулланың кяфер дип әйтүенә карап каләмен чылбырлап куйса, газета битләрендә кемнәр язар? Сезгә тәнкыйть итәргә нәрсә калыр? Сезнең шушы тәнкыйть итеп язган мәкаләгезнең үзенең тәнкыйтькә һәм тикшерүгә мохтаҗ булмавына сибирияле Х.Мәхмүдевтән башка кем кул куяр? Әйе, без язганнарда да кимчелекләр һәм зур кимчелекләр булырга мөмкин.

Без мәкаләләребезнең башына: «Бу мәкалә яки бу шигырь барлык кимчелекләрдән пакь», — дип язмадык лабаса! Без культура дөньясының әлифбачысы гына әле. Айлар, еллар үтәр, әлифбадан үтеп, югары күтәрелербез. Бервакытларда «Фәзаилеш шөһүр»нең бер әдәби әсәр, «Бәдәвам» һәм «Кисекбаш»ларның милли шигырь җыентыклары урынын тотканлыкларын да онытмаска кирәк.

## УРАЛЬСКИДӘ ХӨРРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Үткән 20 августта көндез сәгать 12 чамаларында Городской театр залында, таратылган Дума члены В.В.Недоносков җәнабләре, үзен сайлап җибәргән халыкны җыеп, аларга вәкилләрнең манифестын укыды. Һәм халыкның тапшырган эшләрен җиренә китерә алмаганлыгында, билгеле, үзенең гаепсезлеген күрсәтеп, бюрократиянең халыкның теләкләрен бервакытта да бирергә нияте юклыгы вә искечә: «Ул нинди халык? Без аларны танымыйбыз», — дип торганлыгын ап-ачык аңлатып, гаять үткен, гаять тәэсирле хотбәләр сөйләде.

Халык Недоносковны театрга кадәр кулдан-кулга күтәреп, хөрмәтләп китерделәр. Театрның эчендә чебен оча алмаслык дәрәҗәдә халык тулган иде. Һәрбер ишек төпләренә, бюрократларны кертмәс өчен, халыкның үз арасыннан хосусый гаскәр дә сайланып куелды. Недоносков нотык сөйләргә тотынып-тотынмас, әллә кайдан 30 лап атлы казак килеп чыгып, театр әйләнәсен чолгап алдылар. Бераздан 10–15 баш жандармалар эчендә шәһәрнең атаманнары вә политсәмистерләре һәм шуларга охшашлылары да килеп төшеп, борынгы горурлыклары вә күтәрелгән борыннары илә театр ишегеннән шарт-шарт басып кереп китмәкче булдылар; үзләренең уйларынча, анда кереп, Недоносковны әллә нинди статья буенча арестовайт итмәкче иделәр. Ләкин теге халык гаскәре боларга юри кунакка караган күз берлән карадылар, боларны ишектән керту түгел, якын да җибәрмәделәр. Бичаралар, ары бәрелделәр, бире төртелделәр, — гөнаһ шомлыгы, халык гаскәре җибәрми. Бюрократлар, аптырагач: «Әллә безне танымыйсызмы? Без — начальство бит! Без үзлегебездән килмәдек, закон куша бит», — диделәр. Халык та: «Беләбез, беләбез, безгә кем икәнегезне сөйләмәгез! Без сезне бик яхшы таныйбыз», — дип җаваплhistoryандылар!

Әлхасыйль, алар бик озак тартышсалар да, бернәрсә дә чыкмагач, бичаралар, тәпи-тәпи генә, килгән юллары берлән киттеләр. Теге, театр әйләнәсен чолгап алган казакларның да яртысыннан күбрәге, үзләрен ни өчен чакырганнарын аңлагач та: «Без кеше үтермибез!» — дип кайтып киткәннәр иде. Недоносков та һәр хәрефе халыкның ихласын арттыра торган хотбәсен сөйләп бетерде. Халык аны тагын уч төпләренә күтәреп чыгардылар. «Урра! Урра!! Да здравствует свобода! Бетсен халык каныннан алтын ясау!» тавышлары «Сәет Баттал»

---

*Хотбә* — речь, вәгазь.

китабындагы[1] әллә кем батырның нәгъръсе шикелле бөтен шәһәрне яңгыратты.

Недоносковны шул күтәргәннән-күтәреп, шәһәребезнең иң зур урамы буенча, кызыл флаглар күтәреп, революционный җырулар җырлап, квартирына кадәр алып бардылар. Урамның тротуарында да, уртасында да кап-кара халык диңгезе дулкынлана иде. Һәммәсенең күзе уртада хөррият манарасы төсле күренеп барган Недоносковта иде. Бу бер моңгарча күренмәгән хөррият бәйрәме булды.

Монда хиссиятле күңелләргә әллә нинди моңлыклар, әллә ни төсле дәртләр бар иде. Моның инсанга иткән тәэсиреннән еламыйча түзмәк мөмкин түгел иде.

27 августта тагы бер митинг булачак. Утаман бу митингка каршы бик каты бармак селкеп торадыр. Ни булыр? Тагы язармын.

## «ҖАВАБ»Ә ҖАВАБ

Рифгатьлү кардәшем Хөҗҗәтел-Хәким әфәнде хәзрәтләре!

Бәндәңезә бөйлә сыгук канлылык илә вә гадәләткяранә мокабәләңездән зиядә мәмнүн вә мәхзуз улдым. Бән җәнабеңезең һәр дөрлү тәүбих вә ачы кәлимәләреңези дә тәхәммел итмәк әмәлилә кәндемең Сезә каршы улан җөзьи бер наразыйлыкыми бәян вә ифадә итмеш идем. 31 нче номер «Фикер» җәридәсендәге бәнди язмайа башлыча сәбәб — Сезең: «Әразый мөкаддәсәмези башка милләтләр билә ихтирамә мәҗбүрләр икән. «Уклар» журналы тәхкыйрь идиюр», — мәалендәге бер җөмләңездер. «Уклар» журналында бәндәңезең дә эпиҗә мөдахәлә вә мөшарәкәте улдыкындан, бу җөмләңез дубдугъры бәңа тукынды.

Әгәр Сезең у җөмләңезең Уральск халкына нә кадәр каты тәэсир идәчәкени билсәңез, өмид идәрем ки, уны язмага пәк у кадәр гаҗлә итмәмеш улырдыңыз.

Мәгълүмеңездер ки, буйдан мөкаддәм Казандагы «Бәянел хак» гәзитәсе: «Фикер» гәзитәсе хатынларә ачык вә сәрбәст йөрмәйә әмер идиюр, у гәзитәнең мөхәррирләри вә мөхибләри кяфердер!» — дия, шәригатьчә һич мөкәлләф улмайан хиҗабә әһәмият виреб, безем Уральск әһалисен бөтен-бөтенә гольянә кетүрди. Һәм дә буйдан сәбәб, шәһәремездә нә кадәр фетнәләр чыктыгы гәзитә укыянларә мәстүр дәгелдер. Шуның кеби, Сезең дә: «Иш-

---

*Нәгъръ* — каты кычкыру.

*Утаман* — бу урында: казаклар атаманы, башлыгы.

тә бәйтуллаһи тәхкыйрь идиюрләр», — җөмләңез астында без: «Фикер» матбагасына һөҗүм идеңез!» — җөмләи мөстәтәрәсени күриюрез. Бәнем җибилли холкым тәрәкъкый пәрвәр матбагайа дәгел, матбагалара изһары мәхәббәт вә мәвәддәт итмәйә бәни иҗбар итдекендән, бән Сезең кеби вөҗданлы бер әфәндийә бер кәррә хитаб итмәйә җәсарәт итдем. Әвәт, Сез у җөмләңези, ихтимал ки, гаразы хәер-хаһанә илә дә язмыш улырсыз, ләкин безем шәһәр халкы ишанларның заһиренә фәкать бактыклары кеби, Сезең дә җөмләңезең заһир мәгънәсе илә тәфсир идәрләр. Анлар һәр шәйнең ич тарафина күз салмайуб, анҗак заһирына хасры нәзар итмәйә алышмышлардыр. Шул сәбәбдән яхшыйы ямандай, вә яманый яхшыдан тәфрыйка мокътәдир дәгелләрдер.

Безә лотфән тәкъдим итдекеңез «Интикад» нам әсәреңези гаибанә тәбрик идәрем, бервакыт моталәгасилә дә мөшәррәф улсак кәрәк.

Һәр нә исә, бәнем язлыгым бушә кәтмәде, Сезең иҗмалән тәрҗемәи халеңези вә тәэлиф итдекеңез әсәрләри беркадәр аңламайа муаффәкъ улдым. Буңа мокабәл бәңа да кәнде тәрҗемәи халеми язмак мөнасиб исә дә, гәзитә сәхифәсендә бер кешейә сөйләнәчәк сүзең, һич лязим дәгел икән, бөтен дөньяйә сөйләнәчәкени аңладыгымдан, шимдилек язмаюрым. Билмеш улыңыз ки, бәнем сибирияле бер татар дидекем Сези чит күрдекемдән дәгел, бәлки, Сезең сибирияле татар идекеңез хакыйкать улдыкындан, вә Сезең «татар вә Сибирия» ляфызларилә бер дөрлү улсың мохасамәңез юк идекени аңладыкымдандыр. Хуш, сагъ улыңыз!

### *Тәрҗемәсе:*

## «ҖАВАП»КА ҖАВАП

Бөек кардәшем Хөҗҗәтел-Хәким әфәнде хәзрәтләре!

Бәндәгезне мондый суык канлылык белән һәм гадел рәвештә кабул итүегезгә бик шатландым. Мин Сезнең һәртөрле шелтә һәм ачы сүзләрегезне дә күтәрү уе белән үземнең Сезгә карата кисәкчә ризасызлыгымны язган идем. 31 нче номер «Фикер» газетасындагы мәкаләне язуга төп сәбәп — Сезнең: «Изге саналган җирләребезне башка милләтләр дә хөрмәт итәргә мәҗбүрләр икән, «Уклар» журналы аларны хурлый», — дигән мәгънәдә бер җөмләгездер. «Уклар» журналына бәндәгезнең дә азмы-күпме катнашы булганга күрә, бу җөмләгез туп-туры миңа килеп тиде.

Әгәр Сез ул җөмләгезнең Уральск халкына никадәр каты тәэсир итәчәген белсәгез, өмет итәм ки, аны язарга ул кадәр ашыкмаган булыр идегез.

Мәгълүмегездер ки, моннан элек Казандагы «Бәянел хак» газетасы: «Фикер» газетасы хатыннарга ачык һәм иректе йөрергә куша, ул газетаның язучылары һәм аның яклылар кяферләр!» — дип, шәригать буенча һич мәҗбүр ителмәгән хиҗабка (хатын-кызларның йөзләрен каплап йөрүләренә. — *Ред.*) әһәмият биреп, безнең Уральск халкын бөтенләй аякка бастырды. Һәм шуның аркасында шәһәребездә никадәр фетнәләр чыкканы газета укучыларга яшерен түгелдер. Шуның кебек, Сезнең дә: «Алла йортын (кәгъбәне) хурлыйлар», — дигән җөмләгез астында без: «Фикер» типографиясенә һөҗүм итегез!» — дигән җөмлә яшеренгәнен күрәбез. Минем табигый холкым прогресс яклы типографиягә генә түгел, гомумән барлык типографияләргә мәхәббәт белән һәм дусларча карарга мине мәҗбүр иткәнлектән, мин Сезнең кебек вөҗданлы бер әфәндегә бер мәртәбә искәртеп әйтергә батырчылык иттем. Әйе, Сез ул җөмләгезне, бәлки, яхшы теләк белән дә язгансыздыр, ләкин безнең шәһәр халкы, ишаннарның бары тышкы якларына караган кебек, Сезнең җөмләгезнең дә тышкы мәгънәсен аңлау белән генә чикләнә. Алар һәрнәрсәнең эчке ягына күз салмыйча, бары тышкы ягына гына карап эш итәргә күнеккәннәр. Шул сәбәптән яхшыны яманнан, яманны яхшыдан аерырга көчләре җитәрлек түгелдер.

Безгә тәкъдим итә торган «Интикад» исемле әсәрегезне күрмәс борын ук котлыйм, күреп, тикшереп чыгу хөрмәтенә дә ирешсәм кирәк.

Ничек кенә булса да, минем язганым бушка китмәде, Сезнең кыскача биографиягезне, язган әсәрләрегезне бераз аңлауга ирештем. Моңа каршы миңа да үземнең биографиямне язу урынлы булса да, газета битләрендә бер кешегә сөйләгән сүз бөтен дөньяга сөйләнә икәнен аңлаганга күрә, хәзергә язмыйм. Белегез ки, минем сибирияле бер татар дип әйтүем Сезне чит күрүдән түгел, бәлки Сезнең чыннан да сибирияле бер татар булуыгыздан һәм «татар һәм Сибирия» сүзләренә бертөрле дә каршылыгыгыз юк икәнен аңлавымнандыр. Хуш, сау булыгыз!

## УРАЛЬСКИДӘ ДУМА ЧЛЕНЫН ВӘ ТӘВАБИГЫН НАГАЙКАЛАУ

27 августның якшәнбе көне Уральск халкының бик озын вакытлар исеннән чыкмаслык бер көн булды. Бу көн халык полициянең нагайкаларын, кылыч сыртларын, йозрыкларын гәзитәләрдән укып кына түгел, бәлки үз күзләре берлә күреп

---

*Тәвабигъ* — иярүче.

татыдылар. Бу якшәнбедә булачак митинг губернатор тарафыннан 29 август сиһшәнбе көнгә калдырылган һәм шул көннең булуына рөхсәт (разрешение) булган иде. Бу якшәнбе көн көндез сәгать икедә үк казакларның трубасы «Всадники други, в поход собирайтесь, радостный звук вас ко славе зовет!»* дип уйнап, казакларны походка чакыра иде. Сәгать 4 ләрдә, митингны бүген үк ясарга кирәк дип, үзләренең вәкилләренең үткән якшәнбедә сөйләп бетерә алмаган докладын бу көн тәмам тыңлап бетерү нияте берлә бер меңләп халык җыелган иде. Бәгъзе бер эшчеләр, без 29 ында эш берлән шөгыльләнәбез дә митингка килә алмыйбыз, дип сөйлиләр иде. Шул арада халыкның саны һаман артмакта иде, бераздан халык В.В.Недоносковны чакырырга кеше җибәрделәр. Озакламый Недоносков та килеп җитте. Монда Недоносков халыкка митингның 29 август сиһшәнбе көнгә тәгаен кыйлынганын һәм хәзер җыелышудан шул мөгайян көндә җыелышу артык икәнен сөйләде.

Әйтеп китәргә кирәк, шул вакытта халык кулында прокламацияләр дә бар иде, полиция шул җирдән ерак түгел бер җирдә генә торып, хәзергә халыкка катышмый иде, кисәктән генә бер тарафтан казаклар килеп чыкты. Боларны күргәч, теге полиция халыкка таба юнәлде. Недоносков, янә җыелышны мөгайян сиһшәнбе көнне ясау мәслихәт икәнен тәкрарлап, үзен һәртөрле вакыйгалардан саклау нияте илә чорнап алган халык арасында өенә таба китте. Менә инде бу җирдә нагайка шәриф башланды.

Бәгъзе риваятьләргә караганда, мужиклар казакларга таш ыргытканнар икән дә, «нагайка!» командасы шундин соң бирелгән, имеш. Кайсы кешеләр, бер дә сәбәпсез нагайкага ябыштылар, диләр. Тагы бертөрле кешеләр, дөрест, халык арасында бәгъзе берәүләре полиция һәм казакларга таш ыргытты, ләкин ул ыргытучыларны үзләре дә, андый килешсез эшләре өчен, яңаклаганнар, диләр. Хәтта шулкадәр эшләр булды ки, бөтенләй кылычсыз простой казаклар да халыкны кыйнаганда кыйнаучыларга дәрт берлән булышлык иттеләр.

Недоносковны чорнап алган бер кисәк халык, нагайка бик каты әләктерә башлагач, Недоносков берлә бергә Общество трезвости чәйханәсенә качып керделәр. Ләкин бу аларны кот-

* «Җайдак дуслар, походка әзерләнегез, шат авазлар сезне данга чакыра!»
*Мөгайян* — тәгаенләнгән.
*Шәриф* — кадерле (монда: ирония).
*Общество трезвости* — Эчкечелеккә каршы аеклык җәмгыяте.
*Мөхасарә кыйлынган* — әйләндереп алынган.

кармады. Дүрт тарафы казаклар берлән мөхасарә кыйлынган халыкны камап куып, сөртендереп бетергәч, полиция... чәйханәгә атылып кереп, андагы гаеплеләрне-гаепсезләрне, бер дә тикшермичә, төрткәләп, суккалап чыгара башлады. Чәйханәнең биек баскычыннан каты-каты сугулар берлән полиция халыкны түбәнгә озата иде.

Түбәндә икенче жандарлар яңа-яңа нагайкалар берлән сыйлыйлар иде. Мәрхүм Дума члены Недоносков чәйханә эчендә дә бик яхшы изелеп, яхшук җәрәхәтләнгән иде, тагы баскычтан төшкәндә дә каты-каты сугуларга очрады. Хәтта урамга чыккач, публика күз алдында да кыйнадылар. Аны дәрхаль арестовать итеп, конвой астында төрмәгә озаттылар. Тагы Пулин фамилияле бер семинарист та бик каты кыйналды.

Полиция урамда күренгән һәрбер кешене бик каты куып, күзенә кем күренсә, шуны кыйнап йөрде. Бу кыйналуга бер дә митинг берлә эш итмәгән кешеләр дә эләкте. Шул җөмләдән яңа гына стачкадан кайтып, митингны тамаша итеп торган Шапошниковның доверенный приказчигы да таяк ашады.

Бигрәк тә бушка кыйналган кешеләрдән берсе: Невский чиркәүдә тыныч кына чукынып, вечерня артыннан җырлаудан башка гөнаһы булмаган певчий Голубцев та нагайкадан чибәр үк өлеш алды. Ул, урамдагы тавышны карамакчы булып чиркәүдән чыгып, митинг урынына килгәч тә, «вот этот самый!» тавышы берлән бер полицейский моның өстенә атылды да кыйнарга тотынды. Бичара Голубцевны алдагы явыз язмышлардан әллә ничек полицмейстер генә саклаган. Әлхасыйль, монда тора алмыйча, ятарлык дәрәҗәдә кыйналганнар, намәгълүм бер мөддәткә арестовать ителгәннәр бик күп булды.

Кайсыбер халыкны кыйнауга ярдәм итүчеләр: «Без бүген сум егермешәр тиен акча хасил иттек әле», — дип мактанып йөриләр икән. Полициячә әйткәндә, «бунт» ярты сәгать кадәр аз бер мөддәт эчендә таратылды, бичара халык казакларга каршылык итәргә уйлап та карамады.

Бу урында командующий Уральский областьның военный губернаторы иде. Кич берлән төрмә көчле каравыллар берлән сакланды. Иртәгесен шул каравылчыларга тагы 50 казак барып кушылды.

---

*Дәрхаль* — шунда ук.
*Вечерня* — кичке гыйбадәт.
*Певчий* — чиркәү хорында җырлаучы.
*Әлхасыйль* — кыскасы.
*Намәгълүм бер мөддәткә* — билгесез вакытка кадәр.

## АЛДАНМАҢЫЗ!

Бу сәнә Макарья ярминкәсендә «17 октябрь партиясе»нә хезмәт итә торган «Бәянел хак» гәзитәсенең нашире карт бабай[1] һәркемнең номерларына кереп, гәзитәсенә алучы яздырып, акча җыйнап йөрмеш идекене кичән номерларымызда язмыш идек. Имде дәхи бу кешенең пәнҗәи агушына грифтар улан* бер сәүдәгәрнең безә агызыннан сөйләдекене язамыз.

Сәүдәгәр номерында ялгыз ултырыр икән, «Бәянел хак» нашире бабай номер ишегеннән кереп сәлам вирер, сәламне алып, исәнлек-саулык сорашкач, бабай сәүдәгәргә гәзитәсенә язылмасыны тәклиф итмәйә башлар, соңра араларында ушбу сүзләр сөйләнер:

Сәүдәгәр: — Бабай, гаеп итмә, гәзитәңезә языла алмаймын, чөнки безнең үдә бабамыз гәзитә укуны яратмый һәм безгә гәзитә укытмый.

Бабай: — Юк инде, хәзер гәзитәне һәркем укый, хәтта хәзер инде гәзитә уку савап саналадыр. Мин бабаңа хат язармын. Кая, языл, — дип, сәүдәгәрнең 2 рубля 50 копеек акчасын җәберләп алмыштыр.

Моның кеби дәхи бик күп кешеләрне алдап, үзенең гәзитәсенә, җәберләп, алучы җыйнамышдыр.

«Бәянел хак» гәзитәсе милләтемезең тәрәккыйсенә каршы чыктыгыннан өчен милләтемезә иң зарарлы гәзитәләрдән саналадыр. Бу гәзитәне карагруһ таифәсе генә укырлар. Милләти сәвән вә милләтең тәрәккыйсенә иҗтиһад идән кешеләргә бу гәзитәне югалтырга тырышмак лязимдер! Бу гәзитәнең алучысы бер дә улмаса да, анарга казнадан да акча биреләдер. Күптән түгел земство акчасына алып таратыла торган «Бәянел хак» гәзитәләрене Казан губернасында Мулла иле авылында бер йиргә өеп яндырылышлар идеке гәзитә укучыларә мәгълүмдер. Рус халкында буның кеби гәзитәләргә һич илтифат итмиләр. Бу җөмләдән менә «Казан мөхбире» 138 нче номерында язадыр:

Казанда «17 октябрь партиясе»нә хезмәт итәр өчен чыгарыла торган «Газета правых»ның мөштәриләре һәм дә укучы-

---

* Ерткыч тырнагына дучар булган.

*Кичән* — узган.

*Тәклиф иту* — үгетләү, өндәү.

*Чыктыгыннан өчен* — чыкканга күрә.

*Таифә* — партия, төркем.

*Иҗтиһад идән* — тырышлык иткән.

*Газета правых* — уңнар газетасы.

*Мөштәри* — язылып алдыручы.

лары бик аздыр. Бинаән галәйһи бу гәзитәнең мөхәррире урам буенча йөреп мөхәррирләр эзлидер.

21 августта Казыйм бикнең конторына кереп, мөштәриләр табып бирергә үтенгән, контордан моңа бер сум биргәннәр икән, мөхәррир, ачуланып: — «Сез миңа 20 мөштәри яздырыгыз!» — дип кычкырган һәм дә сүгешә башлаган. Моның болай «17 октябрь партиясе»ндәге кешеләрчә кыйлануына контор кешеләре ачуланып, куып чыгарганнар.

Казыйм бик бу партиянең зур кешеләреннән булганы да хәтердә булсын.

*

Безгә дә, шунлар кеби, һәр алдауга ышанмаска кирәк, алданмаңыз, карендәшләр, гафил улмаңыз...

*«Һәйьәт идарә»*

## ГАБДЕРӘКЫЙП ХӘЗРӘТНЕҢ ВӘГАЗЕ

Күптән түгел шәһәремезнең 3 нче мәсҗед имамы (күңелен Алла белсен), халык эчендә ишан аты алган Габдерәкыйп хәзрәт[1], Уральски шәһәренә якын Җимбите базарына кунакка (тугърысын әйткәндә, корсагын тултырып, кесәсен калынайтып кайтырга) барган иде. Җимбите халкы, читтән кәлән кунакларны, хосусән хәзрәтләрне сыйларга бик юмарт булганлыкларыннан, Габдерәкыйп хәзрәтне дә бик хөрмәт иткәннәр.

Габдерәкыйп хәзрәткә буннан әүвәл без һич зарар китермәгән идек. Аның берничә вакыйгаләрен аерымачык белсәк тә, бәгъзе мөнәсәбәт илә сөкүт әйләмеш идек. Шулай була торса да, ул үзе, белмим, бездән нә зарар күрмештер, безә каршы сугыш флагы күтәреп мәйданга чыкмыштыр.

Менә Җимбите базарындагы даими мөхбиремез язадыр: Габдерәкыйп хәзрәт мәҗлесләрдә «Фикер» гәзитәсене бик кабахәт ляфызләр илә сүгеп йөрде. Һәм бәгъзе мәҗлесләрдә ушбу сүзләрне сөйләде: «Әүвәл — Алла, икенче мин риза түгел, «Фикер» гәзитәсен укымаңыз», — дип.

Бу сүз ничек була, бу сүз бит мин Алладан бер генә дәрәҗә ким дигән сүз була түгелме? Нәмруд[2] та халыкны, мин күк Алласы илә сугышам, дип ышандырган; имди бу заманда да

---

*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.
*Сөкүт әйләмеш* — эндәшми тору.
*Мөхбир* — хәбәрче.
*Ляфыз* — сүз.

алай ышандыру мөмкин булырмы икән, хәер, кара халык, бәлки, ышаныр да, әмма, «ликөлле Фиргавен Муса» кабиленнән*, һәр заман батыйльне сүндергүче хак сөйләүчеләр була кәлмештер. Хосусән заманымызда андаен ялган вә ифтира илә халыкны ышандыручыларны күрсәтүче хак вә тугъры юл илә баручылар күбәймештер. Әүвәл — Алла, икенче мин дигәнчә, әүвәл — мин, икенче — шәригем Алла дисә дә барыбер улыр иде. Нә исә варсын, һөнәрләрен күрсәтә торсын, яңа фикерлеләр дә калышмасалар кирәк.

## ТАТАР ДИНЕНЧӘ МӨСЕЛМАН БУЛУ

Имане иҗмали: «Амәнте билишани вә биҗәмигый ма ати мин фәммиһи вә җәмигый ма җаә вә салә мин сәбилиһишшәриф».

Имане тәфсийли: «Амәнте булмәҗүсияти вә җәмигый гадатиһил-кабихияти вә кәләпүшиһи, вә бишбилле-бишмәтиһи, вә җиләниһи, вә чапаниһи, вә читегиһи, вә кәвешиһи, вә каләнсәвәтел-кадимәти, вә фалиһи, вә мәгъҗүниһи, вә әфиуниһи, вә «Бәдәвам»иһи, вә «Тишекбаш»иһи[1], вә моракабәтиһи, вә ханәкаһиһи, вә вирдиһи, иләх»**.

## ЯҢА КАМУСТАН БЕРНИЧӘ ЛӨГАТЬ

*Казый* — ришвәт вә вәкыфләр ашаучы дигән сүз.
*Мөфти*[1] — эшсез вазифа ашаучы дигән сүз.
*Бай* — кеше талап, корсак үстерүче дигән сүз.
*Тәкәббер* — Казан татары дигән сүз.

---

* «Һәр Фиргавен — Муса түгел» дигән шикелле.

** Кыска иман: «Мин инандым ишанга һәм аның авызыннан, шәрафәтле юлларыннан килгән һәм аккан барлык нәрсәләренә».

Озын иман: «Инандым мин мәҗүсияткә, аның барлык кабахәт гадәтләренә, кәләпүшенә, биш билле бишмәтенә, җиләненә, чапанына, читегенә, кәвешенә, борынгы бүрегенә, фалена, мәгъҗүненә (исертә торган дару), әфьюнына, «Бәдәвам»ына, «Тишекбаш»ына («Кисекбаш»ына), моракабәсенә, ханәкаһына, вирденә һ.б.».

*Батыйль* — ялган.

*Ифтира* — яла ягу.

*Шәрик* — иш (бу урында: ярдәмче).

*Моракабә* — экстаз халәте.

*Ханәкаһ* — ишаннарның мөрит кабул итә торган бүлмәсе.

*Вирд* — билгеле вакытларда укыла торган догалар, аятьләр.

*Камус* — сүзлек.

*Лөгать* — сүз.

*Вәкыф* — берәр кеше тарафыннан җәмәгать файдасына бирелгән мирас малы.

*Надан* — Казан байлары дигән сүз.

*Ахун* — корсак үстерүче дигән сүз.

*Мулла* — халыкны наданлыкка чакырып, бәлеш ашап, кымыз эчеп йөрүче дигән сүз.

*Мөәззин* — мәет юучы, кеше күмүче бер каты йөрәк дигән сүз.

*Хәлфә* — малай кыйнаучы, балалар суктырып, җан газаплагучы дигән сүз.

*Мужик* — урам буйларында, чат башларында гайбәт сөйләп утыручы дигән сүз.

*Әби* — сүз йөртеп, бер өйдән икенче өйгә чәй эчәргә баручы вә яки өйләнгән яшь егет илә яшь кыз арасын бозыштыручы дигән сүз.

*Кайнана* — киленне жаркой итеп ашаучы вә килен өчен үлмәс борын кабер казып куючы дигән сүз.

*Шәкерт* — утыз ел мәдрәсәдә ятып, әлифне таяк дип белмәгән кеше.

*Бай баласы* — көндез йоклап, төн буенча матур апайлар янында гуләйт итеп, ата малын бетерүче дигән сүз.

*Мәдрәсә* — акчасыз кешеләргә фатир төшә торган җир дигән сүз.

*Игътикяф* — наданнарга чаршаудан үрмәкүч оясы шикелле тозак кору дигән сүз.

*Хәтем* — Коръән сатып, акча җыйнау дигән сүз.

*Сәүдәгәр* — үләксә тиресе ташучы дигән сүз.

*Ишан* — баш кыйшайтып вә көфер мөһерләре сатып, теләгән кешене оҗмахка вә теләмәгән кешене җәһәннәмгә кертәмен дип йөрүче дигән сүз.

*Мөрит* — әүвәл ат карагы булып, соңра мыегын кырып, ишанга кул биргән кеше дигән сүз.

*Дәҗҗал* — бер ягында — җәннәт, икенче ягында җәһәннәм булган замана ишаны дигән сүз.

## ХИССИЯТЕ МИЛЛИЯ

Көз җитте. Мәдрәсәләремездә укулар башлана. Уку дигәч тә, чын уку дип уйланмасын. Безнең бәхетсез мәдрәсәләремез, һаман шул укытучы битлеген киеп, култык астына китап-

---

*Игътикяф* — берәр изге саналган урыннан (мәсәлән, мәчеттән) чыкмый, берникадәр вакыт гыйбадәт кылып яту.

*Хәтем* — Коръән уку.

*Көфер мөһерләре сату* — кяфер, динсез дип тамгалау, сүгү.

*Хиссияте миллия* — милли тойгылар.

лар кыстырган булып, 25 җирдән аш ашагач, абыстай янына корсагын күтәреп кайтып җиту авыр булганлыктан гына мәдрәсәгә туктап, бераз хәл җыяр өчен генә бер чирек сәгать 5–6 кабат мендәр өстендә утырып, бераз хәл җыйгач чыгып китә торган мөдәррисләр кул астыннан һәмишә чыкмагандыр.

Шәкертләремез, хөррият кояшы туып дөньяны яктырткач, борынгы истибдад караңгылыгында кеше төсле булып күренгән мөдәррисләрнең кем икәнлекләрен таныдылар. Шул мөдәррисләрнең, укытамыз дигән булып, шәкертләрне һич чыга алмаслык наданлык урманына кертеп адаштырганнарын аңладылар. Һәм шәкертләрнең тәхсиле кәмаләт вә гыйлемнән максудлары бер такым сыра мичкәсе булган байларның этләре хөкемендә бер хайваннары булу булмаенча, азат, сәрбәст, һәр байдан бай, үзенә-үзе һәр падишаһтан артык падишаһ була алулары икәнлеген төшенделәр.

Инде ул шәкертләрнең шул аңлауларын вә үзләренең хөр икәнлекләрен белү хисләрен күңелләреннән кисеп ташланмаган тәкъдирдә, алар һаман бөтен көчләре, тешләре вә тырнаклары илә үзләрен шул залим мөдәррисләрнең вә надан, зур корсаклы байларның кулларыннан коткарырга тырышачаклардыр. Шәкертләр бу көннән алып үзләренең милләт эчендә иң кадерле, иң дәрәҗәле бер затлар икәнлекләрен аңлап вә аңлатып, үзләренең иң түбән теләнчедән дә түбән бер мискиннәр түгеллекләрен күрсәтәчәкләрдер. Инде шәкертләр бер саран байның күз карашларын тәгъкыйб итеп: «Безгә ничек карар икән, мәрхәмәтле карармы икән, мәрхәмәтсез карармы икән, алафранка киенгәнемне күрсә, ашка чакырырмы икән?» — дип калтырап тормаячаклардыр.

Алар, бу хурлыкларны күргәнче, нинди кәсеп итсәләр дә, үзләрен-үзләре кул көчләре берлә туйдырачаклардыр.

Милләт образованный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә гаҗиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ. Милләт аталарга, аналарга, мөгаллимнәргә, мөгаллимәләргә, мө-

---

*Истибдад* — деспотизм.

*Тәхсиле кәмаләт вә гыйлем* — камиллек һәм гыйлем табу.

*Сәрбәст* — ирекле.

*Тәгъкыйб иту* — күзәтү.

*Алафранка (а ля франка)* — французча.

*Образованный* — белемле.

*Шәхси мәнафигъ* — үз интереслары.

*Мөрәбби вә мөрәббия* — тәрбияче.

рәббиләргә вә мөрәббияләргә, чын мөхәррирлек табигатьләренә вә сәляхиятләренә мохтаҗ. Безнең милләт тә, башка милләтләрдәге кеби, хамисез, мәлҗаэсез, фәкыйрь вә эшче халыкның файдаларына тырышучы, биш фәкыйрь кешене бер бай этенә алмаштырыр вакытлар үткәнлеген аңлаучы вә аңлатучы егетләргә мохтаҗ. Безнең милләт тә Пушкиннәргә, граф Лев Толстойларга, Лермонтовларга мохтаҗ. Кыскасы гына, безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәкъкыйләренә сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнәргә, бардакханәдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ.

Бу әйтелгәннәр булмаганда, безнең тормышымыз күңелсез, үлек чыккан өй төсле моңлы, тынсыз-тавышсыз, рәхәтсез булачактыр. Болардан башка безнең гомеремез бер дә бәйрәмсез, гомерлек мәшгулият яки бер дә җәйге кояшсыз мәңгелек көз көне төсле үтәчәктер.

Яшьләргә, баягы хәзрәтләрнең мендәр өстендә ял иткәннәренә генә канәгатьләнмәенчә, уку кирәк. Бу аларның иң мөкаддәс, иң беренче вазифаларыдыр.

Бу — безнең һәртөрле чалмалы бурлаклар тырнагыннан азат булуымызга вә бюрократия золымыннан, башка милләтләр илә берлектә, безнең дә котылуымызга иң беренче вә иң тугъры юлдыр.

Укымак — дөрестнең ялганны, яктының караңгыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. Укымак — фикерләрне җирдән күккә йибәрмәк. Укымак — үз янында булып торган нәрсәләрдән бигрәк, фикерләрне булачакларга сузмак. Укымак — үткәннәрдән кичеп, киләчәкләр — истикъбальләр турысында пәйгамбәрлек итмәк. Укымак — хәзерге көннәрне киләсе көннәр өчен, бу көнге мәсьәләләрне киләчәктәге мәсьәләләрне чишү угърында ташламак, димәктер. Укымак — бүгенге дустлардан киләчәктәге кара көннәр өчен аерылмак, димәктер. Укымак — үзеңне һәрнәрсәне белергә та һәр максудка ирешергә вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр. Укымак — «иҗтиһад мөнкариз»[1] кеби сүзләрдән ха-ха-ха илә көлеп, гакыл пычагын

*Сәляхият* — сәләтлелек, талант, булдыклылык.
*Хамисез* — яклаучысы булмаган.
*Мәлҗаэсез* — сыена торган урыны булмаган.
*Бардакханәдән чыкмаган* — фәхешханә белән бәйләнеше булмаган.
*Мәшгулият* — бер дә буш тормау, нинди дә булса шөгыле булу.
*Истикъбаль* — якты киләчәк.
*Угърында* — юлында (юлына мәгънәсендә).

гыйлем вә мәгърифәт кайрагына чынлап кайрамак дигән сүздер. Укымак — утыз ел мәдрәсәдә ятып, бер татар баеның эштән чыккан кызы илә бер аулак бүлмәгә кереп яту, соңра шул байның бер асрау малае булып тору дигән сүз түгелдер.

«Укымак» ләфзы астында моның кеби хисапсыз мәгънәләр чыкса да, барчасы үз халкымызга хезмәт итмәк дигән сүзгә кайтадыр. Укымак — халыкның бәлешен ашап, канын эчеп, үзеңне симертеп, ел саен бер бай кызы үтереп яки аерып, хайванлык итеп яту дигән сүз түгелдер.

Беләмен ки, безнең шәкертләремез бу мәгънәләрнең барчасын аңлаганнардыр, алар шуңгар күрә үзләрен теләнче ясап чыгара торган, тугърысын әйткәндә, теләнче фабрикасы булган мәдрәсәләренә ләгънәт укып чыгып киткәннәрдер.

Шәкертләремезнең бу хәрәкәтеннән милләт әллә нинди зур өмидләр вә сәгадәтләр көтсә дә — урынлыдыр; яшьләремезне кайда укытырга вә ничек укытырга икәнен белсәк, милләт өчен җаннарын корбан итүчеләр вә үзләренең бил бәйләп керешкән юлларыннан, әллә нинди куркынычлар, әллә нинди хәвеф-хәтәрләр очраса да, кайтмый торганнар һәм шулай булырга сәләхиятлеләр дә анчак яшьләремездер.

Без шәкертләргә, үземезгә кирәк кадәре динемезне вә әдәбиятымызны аңлагач, вакыт кичермичә, хөкүмәтнең реальныйларына вә гимназия казаннарына кереп пешеп, кеше булып чыгарга кирәк. Русларның үз балалары кайсы мәктәпләрдә укыса, безгә дә шуларның итәкләренә ябышып керергә тырышырга тиештер.

Хәзер дә милләткә чынлап, риясыз, нифакъсыз хезмәт итүчеләр шул мин теләгән юл илә укыган яшьләремездер.

Без яшьләремезне Бохарага җибәрсәк, ишәк, Истамбулга җибәрсәк, полицейский вә шпион булып кайтачаклары моңгарчы кайтканнары илә сабит вә мөдәлләлдер.

Әле Мәкәрҗә базарында да җыелышлар[2], шураи өммәтләр булып үтте. «Мөсадәмәи әфкярдән барыйкаи хакыйкать зоһур идәр»* дигән шикелле, шул җыелышларыннан берәр төрле файда чыгып китсә, шаять, без шәкертләргә дә гомеремездә, элек дәфга уларак, чын гыйлем илә сәламләшеп, гыйлемнең алдына

---

* Фикерләр бәрелешүеннән хакыйкать яшеннәре туар.

*Анчак* — бары тик.

*Риясыз, нифакъсыз* — ялагайлык, икейөзлелектән башка.

*Сабит вә мөдәлләлдер* — исбат ителгән, дәлилләнгән.

*Шураи өммәт* — бер пәйгамбәрнең дингә өндәгән халкы. Бу урында мөселман динендәге халыкларның киңәшмәләре (шул ук «Иттифакыль-мөслимин»не төзегән Мәкәрҗә съезды) күздә тотыла.

*Элек дәфга уларак* — беренче тапкыр буларак.

тез чүгеп, кулларын үбеп, моңарчы гыйлем дип, гыйлемгә табан-табанга зыйд вә кире нәрсәләр берлән баш катырып йөргәнемез өчен гафу үтенер көннәр җитәр.

Тырышыңыз, карендәшләр, шәкертләр, тырышыңыз! Муллаларның мендәр өстендә корсак шиңдереп утыруларына гына канәгать итмәгез. Бөтен өмидемез, бөтен риҗаэ вә илтимасымыз анчак сезгә гаиддер*.

## МУЛЛАЛАР

Муллаларны һичбер мөгайян вазифасыз-нисез гавам халкын сакларга кушу бөтенләй ач мәчене май сакларга кушу төсле үк бер ахмаклыктыр дип беләм. Сары май табагы янында торган мәче төсле, мулла да, указ алгач, як-ягына карый, күрә ки: үзенә аерым вазифа (мәгаш) юк. Мулла да, ахрысы, фәрештә түгел, аның да остабикәсе бар, баласы-чагасы бар, фатир түлисе бар, — ни эшләсен, ачка үлсенме?

Берзаман мулла абзый үзенең кул астында, күзе алдында, теләсә ничек тунарга мөмкин булган сарык көтүе төсле, бернәрсә аңламаган Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан абзыйларны күрә дә, әйдә шуларны тунарга, әйдә каезларга! (Кай җирләре кычыта.)

Ну, болай булгач, мулла гаеплеме? Әллә безнең милләт гаеплеме? Әлбәттә, милләт гаепледер. Чөнки милләт шул муллага үзенә җитәрлек мәгаш бирсә, билгеле, мулла мәхәллә обжоры булмас иде.

Шуның шикелле үк, безнең теге песине дә, каравылга куймастан борын, майга бик яхшы туйдырсаң, ул да үзенең каравыллый торган маен ашамас иде.

Менә безнең муллалар шул законсыз, шәригатьсез теләнеп ашарга хәзер бөтенләй үк гадәтләнеп киткәннәр.

Хәтта бәгъзе бер җуан корсаклы муллаларга: «Сезгә жалование чыгачак, фәлән-төгән», — дип әйтсәң, Алла сакласын, алар синең авызыңа да сугып җибәрерләр, аның өчен ки, әүвәл үк: «Жалование берлә мулла булу дөрест түгел», — диләр; 2 нче: жалованиенең хәзерге теләнеп җыйган акчалары кадәр булмавыннан куркалар.

3 нче: аларның сөягенә теләнү дәрте шулкадәр урнашкан ки, алар каршында теләнми ашаган бәлеш — бәлеш түгел, теләнми эчкән кымыз — кымыз түгел.

---

* Үтенеч һәм сорауларыбыз бары тик сезгә генә юнәлгән.

*Зыйд* — кире, каршы.

*Мөгайян вазифасыз-нисез* — билгеле бер эш, хезмәт хакы алмыйча.

Син аларга теләсәң Сөләйман пәйгамбәр дәүләтен бир, — алар теләнерләр, һәмишә теләнерләр.

Беләсезме, алар шул жалование алу дөрест түгел дигән фәтвалары илә һәм теләнү тугрысындагы сөбатлары илә бичара фәкыйрь, сәфил сала муллаларын ач калдырырга сәбәп булалар.

Сала муллалары, мискиннәр, жалованиене бик дөрестләрләр иде, ләкин баягы бәнарис чапанлы, калын муен, җуан корсаклы муллалар бөтенләй аяк чалалар.

Гавам халкы исә, әлбәттә, шәһәр муллалары белмәгәнне сала муллалары кайдан белсен, дип әйтергә тешләрен кайрап ук торалар.

Тагы да бер мулла биш вакыт намазда, җомгаларда, гаедләрдә имам тора, никах, талак эшләрен карый, казыйлык итә, туганнарны, үлгәннәрне, никяхланганнарны яза. Шул арада ук мәдрәсәгә кереп мөдәррис тә була. Бер бай кеше үлсә, зиярәткә дә бара.

Җә, бер кешегә бу кадәр хезмәт бирелсен дә, ул кешегә ни өчен жалование алу дөрест булмасын?

Әүвәл бер кешегә шулкадәр эш бирү дөрест түгел, инде бирелгәч, аңар жалование бирмичә, теләндереп йөртү дөрест түгел.

Бер култыкка ике үгез башы сыймавы, бер көймәче ике көймәнең койрыгын тота алмаганы һәркемгә мәгълүм була торып, бер муллага әллә тагы егерме төрле эш биргәннәр.

Шулай булгач, ул мулладан нинди укыту, нинди иҗтиһад, нинди хәер көтәргә кирәк? Минем уемча, муллаларны жалованиеле ясарга кирәк — бер; һәм аның өстендәге йөкләрнең һәрберсен аерып, үзенең ияләренә тапшырырга, йөкләтергә кирәк — ике. Никях, талак кеби эшләрне караучы казый үзенә башка, мөнбәргә менеп хотбә сөйләүче хатиб, вагыйз үзенә башка, мәдрәсәгә кереп дәрес укытучы үзенә башка булсын, һәм боларның һәрберсенә аерым-аерым жалованиеләр бирелсен.

Татарларның маллары зәкят, фидия, фитра кеби кәкре-бөкре канаулар буенча муллаларның кесәсенә агып кергәнче, җәм-

---

*Фәтва* — кистереп әйтү, боерык.
*Сөбат* — нык тору.
*Сәфил* — түбән.
*Бәнарис* — ефәк.
*Талак* — ир белән хатынның аерылышуы мәсьәләсе.
*Казыйлык итү* — шәригать законнары буенча судьялык итү.
*Хотбә* — Коръән күзлегеннән чыгып, мөнбәрдән чыгыш ясау, речь сөйләү.
*Хатиб* — оратор.
*Вагыйз* — үгетләүче.

гыяте хәйрия исемле бер күлгә җыелсын да муллаларга туры, тиешенчә генә алып бирелсен.

Үзенә башка хатиб, вагыйзләр дигәнемез дә, безнең хәзергә чаклы булган муллаларымыз төсле, мөнбәргә менеп, баласын тирбәтеп йоклатучы хатын шикелле, халык аңламаган тел илә көйләп, җырлап, халыкны гор-гор йоклатмасыннар, тик өч мәртәбә «әлхәмделиллаһ»ны гарәпчә әйтсәләр җитәр. Вагыйзләр безнең үземезнең ана телемез илә безгә, динемезгә, дөньямызга кирәкле вәгазьләр сөйләсеннәр. Халыкның тамырлары буенча каннарын йөгертеп, күз яшьләрен чыгарып, әллә кай җирләрен чеметтереп-чеметтереп алсыннар. Мөнбәргә менгәч, фәлән мәкам берлә җырлау, төгән көй илә көйләү бик зур ояттыр.

Иске муллаларга алай гавам халкын көйләп тирбәтеп йоклатканчы, бер дә кешесез сахрага чыгып, гарәп шигырьләре көйләсәләр, артыграк булыр иде.

Туктагыз әле, бер хикәят исемә төште. Әүвәл замандарак бер мулланың мөнбәрдә хотбә укыганын күргәч, бер мужик җылаган, ди. Мәсҗедтән чыккач, икенче мужик теге җылаучы мужиктан: «Ни өчен җыладың?» — дип сораган, ди. Җылаучы мужик: «Былтыр минем бер кәҗәм үлгән иде, бу хәзрәтнең сакалы да мәрхүм кәҗәмнең сакалына охшаганлыктан, кәҗәмне сагынып җыладым», — дип әйткән, ди. Әгәр мулла, мөнбәргә менгәч, үз ана телемез илә җанга әсәрле вәгазьләр сөйләсә, теге мужикны җылатырга кәҗәдән башка да бер нәрсә булган булыр иде.

Без требовайть иткән хатиб жалованиеле булгач, билгеле, аштан калудан куркып, байларның кәефенә килмәгән сүзне әйтми тормас.

Хатибның сүзләре дару хөкемендәдер. Даруны, шифа биргәч, ачы булса да эчәләр бит; шуның шикелле, байлар да калтырап-тетрәп тормаган хатибның сүзләрен йотып калырлар, файдаланырлар.

Муллаларның берсе бигрәк тук, икенчесе бигрәк ач булуының һәм дөрес укыта алмауларының, байларга сатылып, һәртөрле бозыклыкларга юл күрсәтеп, милләтне ашауларының һәммәсенә сәбәп жалованиесезлектер.

Шуның өчен мин үз тарафымнан, муллалар жалованиесез хезмәткә көчләнмәсеннәр, дип әйтергә батырчылык итәмен.

Озакламый аерым мөдәррис, аерым казыйларның ничек бу-

---

• *әмгыяте хәйрия* — ятимнәргә, фәкыйрьләргә ярдәм итәргә тиешле ирекле оешма.

*Мәкам белән* • *ырлау* — Коръәнне төрле җирдә төрле тавыш һәм көй белән укыйлар. Монда шуңа ишарә.

лулары хакында да язачагымны вәгъдә итеп, хәзергә каләмемне чәнчеп куямын.

## «КАЗАН» ЧӘЙХАНӘСЕНДӘ ГОЛЯМА ҖӘМГЫЯТЕ

Ике мәхәллә кешеләре арасында бер өү сатып алу хакында низагъ чыкдыгы сәбәпле, дәгъва торгызучының бере тарафыннан 23 нче сентябрьдә шәһәрнең голямасе «Казан» миһманханәсенә чакырылып, бу эшнең шәригать җәһәтенчә ничек идеке хакында мөназарә булып узды. Ахунд М.Төхфәтуллин[1] бәйгы шираэдә тәмам ризалык шарт итдекене* сөйләсә дә, мәшһүр Гайнетдинемез, сүзгә каршы төшәрәк, ахунд М.Төхфәтуллин закон кагыйдәсенә тарта, ул шәригатьне боза, дип кычкырышмакчы булган, диләр. Әлбәттә, Гайнетдин хәзрәткә бер тәңкә яуса, һәрнәрсә шәригать була. Моның хакында «Уклар» журналындагы бәет[2] бик тугъры киләдер.

### БӘЕТ

Карагыз сез безем хәзрәт миенә:  
Миендә мәгърифәт дәрде бииме?..  
Бөтенләй мөртәсәм фикре миендә:  
Кымыз, шурпа, бәлеш, тәңкә, тиен дә.

Ахыры «Уклар» журналының 4 нче номерындадыр. Бу хосуста тәфсыйль «Фикер»нең киләчәк номерында язылыр.

## УРАЛЬСКИДӘ ДУМАГА САЙЛАУЛАР

Безнең шәһәр халкы бер дәрәҗә тәрәккъый тапса да, карагруһ таифәсенең гаять тырышып кире тордыкларыннан бик яктырып җитә алмыйлар. Бу ел сайлаулар вакытында карагруһлар бик тырыштылар. Әмма никадәр тырышсалар да, мәгънә чыгара алмадылар, выборщик спискасын бөтенләй чын мөрит ялганчы кешеләрдән генә тәгаен кыйлсалар да, эшләре максуд-

---

* Сату-алу мәсьәләсендә бер якның өстенлеген тану өчен фикер алышучылар арасында фикер берлеген шарт итеп куйганлыгын...

*Голяма* — укымышлылар, галимнәр.

*Өү* — өй.

*Миһманханә* — гостиница, кунакханә.

*Мөназәрә* — фикер алышу.

*Мөртәсәм* — рәсемләнгән.

*Бу хосуста тәфсыйль* — бу хакта җентекләбрәк.

*Таифә* — төркем, партия.

*Выборщик спискасы* — сайлаучы вәкилләренең исемлеге.

*Чын мөрит* — ишан иярчене.

ларынча булмады. Ләкин, үзләренең максудлары хасил булмагач, өсткә чыккан партиягә дошманлык итеп, аны таратырга бөтен иҗтиһадларыны сарыф иттеләр. Тырыша-тырыша, Камил Мотыйгыйны спискадан чыгардылар. Чыгардылар, әмма нинди файда таптылар? Һәмишә Думага аларның кешесе сайланмады. Эшче халык өчен җанын фида итәргә разый булган кеше китте. Инде бу көн мөселманнарны дәхи алдарга тотындылар. Бичара мәзлум халык үзләренең сайланмыш депутатларына наказ бирергә дип йөргәндә, бунлар: «Ул нәрсәгә кирәк? Без әле дә бик тыныч ятамыз. Безгә тынычлык кирәк», — дип котыртырга тотындылар.

Әй, иптәшләр! Алданмагыз, болар сезнең дошманнарыңыздыр, болар тик үз файдалары өчен генә тырышып, сезне әсирлектән чыкмасын дип тырышучылардыр. Гайрәтеңездә сабит булып, теләгән нәрсәләреңезне язып, үзеңезнең кирәкләреңезне сорап, вәкилеңезгә җибәреңез.

Торгыл, күтәрел, эшче кешеләр[1],
Каршы тор дошманга, ач кешеләр!
Яңгыра дөньяга, үч авазы!
Алга, алга, алга!..

Эш вакыйган бу тарика улыб, Камил Мотыйгый партиясе галиб чыкса да, мәзкүр дошманнар аркылы төшеп, губернаторга шикаять итеп вә гайре мөтәнаһи донослар йөртеп, Камил Мотыйгыйны иртәгә сайлау булачак көнендә генә выборщиклыктан чыгарттылар. Бу хәл шәһәр әһалисенә гаять тәэсир итеп, күптөрле кыйль вә кальга сәбәп булды. Уральскидә ике кеше бергә очраса, шул хәлне сөйләмәктәдерләр.

## УРАЛЬСКИДӘ ДАРЕЛМӨГАЛЛИМИН

Әлхәмделилла, бу көнне дә күрдек. Уральск әһалисе, башка шәһәрләрдән калышмакны мөнасиб күрмәйүб, Уральскидә бер дарелмөгаллимин ачмак ниятилә эшкә тотындылар. Хода ахы-

---

*Дәхи* — тагын.
*Мәзлум* — изелгән, җәберләнгән.
*Сабит булу* — нык тору.
*Бу тарика улыб* — болай, бу рәвештә булып.
*Галиб чыгу* — җиңеп чыгу.
*Мәзкүр* — әлеге.
*Гайре мөтәнаһи* — башка бик күп.
*Шәһәр әһалисе* — шәһәр халкы.
*Кыйль вә каль* — гайбәт, сүз йөртү.
*Дарелмөгаллимин* — укытучылар хәзерли торган мәктәп.
*Әһали* — халык.
*Мөнасиб күрмәйүб* — тиеш күрмичә.

рын хәерле мөбарәк итсен. Дарелмөгаллимин ачмакка тырышмак һәркемгә фарыз улса кирәк. Шуның өчен бу хосуста олугъкечүк эшкә тотынып, барча җәмәгать гайрәт әйләмәк лязимдер. Хәзергә дарелмөгаллимин өчен бер өй тәгаен кыйлмак тиешле, соңра хәраҗате хакында мәслихәтләр вакытында күрелер, ялңыз бездә тырышу вә гайрәт улсын. Гайрәт вә һиммәт эленнән һич шәй кортылмаз*.

Ушбу көндә җәмәгать дарелмөгаллимин өчен бундан ун сәнә әүвәл вәкыф итеп калдырылган ике бөек биналарның берсене мәслихәт күреп торалар. Һәм бу биналар дарелмөгаллимин өчен бик мөнасиб күренәләр. Бу вәкыф биналарының опекунының[1] сүзенә ышанылса, доходы үзләренең расходына да җитми, имеш. Хәтта Гомәр Хөсәенев[2] сорагач, опекун үзенең яныннан бер мең сумнан артыграк расходланганын сөйләгән. Менә шуның өчен, җәмәгатьнең бәгъзе ачык фикерлеләре җыелышып, дарелмөгаллимингә ушбу өйләрне тәгаен кыйлып, Духовный собраниегә гариза вирергә карар бирмешләр. Гаризалары, иншалла, кабул улыныб, эшләре билфигыль вөҗүдкә чыкса кирәк. Дарелмөгаллимин ачу өчен шәһәремездә мәшһүр Мортаза бай Гобәйдуллин «Казан» миһманханәсене егерме мең тәңкәгә сатып алмакчы булган иде. Моны Мортаза байдан үземез дә ишеттек. Әгәр Мортаза байның агызыннан ушбу сүзләр рия илә генә чыккан булмаса, ушбу ачылачак дарелмөгаллиминнең хәраҗатенә шул егерме мең тәңкәсен тотар, вәгъдәсенә хилафлык кыйлмаз, дип уйлыймыз. Соңра башка байлар да кулларыннан килгән кадәр бу эшкә ярдәм итмәктән кире тормазлар өмидендәмез. Шулай итеп, йөз мең рубля кадәр акча җыйналса, мәзкүр ике өйләрнең берсене дарелмөгаллимин вә икенчесене дарелмөгаллимат ясамак мөмкин булыр. Шул вакыт Уральск бер гыйлем җире, заманында мәшһүр улан Гыйрак шәһәре кеби булыр. Аллаһы Тәгалә насыйб вә мөяссәр итсен.

Уральск җәмәгатенең мөфти әһлелислам хозурына Духовный собраниегә җибәрергә хәзерләгән гарзыхальләре будыр.

Безнең Уральскидә дә бәгъзе үзләренең интересларыны

* Тырышлык һәм омтылыш кулыннан бернәрсә котылмас.

*Әйләмәк лязим* — итәргә тиеш.

*Хәраҗат* — чыгым.

*Вәкыф* — берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек.

*Бөек* — монда: зур.

*Билфигыль вөҗүдкә чыгу* — чынлап та гамәлгә ашу.

*Мәзкүр* — әлеге.

*Мөяссәр* — җиңел, җайлы.

саклап йөри торган затлар дарелмөгаллимин вә әлмөгаллимат мәдрәсәләренең булуына каршы төшмәсәләр ярар иде.

Хәрап итде безне, аһ, бу җәһаләт,
Нәләр япды безә, аһ, бу сәфаләт*.

## ДӘХИ БЕР ФЕТНӘ

Духовное собраниедән Уральскинең 3 нче мәсҗед вәкыфләре хосусында отчет сорап бирергә хәзерләнгән гарзыхальләргә кул куйгучылар[1] җөмләсеннән Әхмәтшаһ Сираҗетдинев, Нурәхмәт Һидиятуллин, Фәтхетдин Рәхмәтуллин (тамак аркасында булырга кирәк) «Уральский листок» гәзитәсендә: «Без ул морадтан кайттык. Шәригатьтә вәкыфне бер нәрсәнең файдасыннан икенче нәрсә файдасына күчерергә ярамый икән», — дип хат язганнар.

Бу нинди эш, бу никадәр кара йөрәклек! Вәкыфне мәсҗед файдасыннан чыгарып, бөтенләй дарелмөгаллимин файдасына тәгаен кыйлу һичбер вакыт сөйләнгәне юк. Бу, шәригатьтә дөрест булмаганы кеби, законча да мөмкин дәгелдер. Мәхәллә халкының морады бер җәмгыяте хәйрия ясап вә шул вәкыфне үзләренең кулына алып, дарелмөгаллиминне һәм мәсҗедне тигез карамактыр. «Фикер»нең үткән номерын яхшы укып караучыларына бу бик заһирдыр. Бу кешеләрнең максудлары тик фетнә чыгару гынадыр. Аллаһы Тәгалә кәляме кадимендә фетнә чыгару кеше үтерүдән дә катырак гөнаһтыр, димеш. Бөйлә фетнә чыгаручыларның Алла җәзаларын бирсен. Исерекбашлар шәрреннән Хода Тәгалә хәзрәте җөмләмезе мәхфуз вә мәсун әйләсен**.

Күрең бу талиб илә бу ләһәбне, —
Олугъ дәрья янында хошек ләбне[9]!

---

* Харап итте безне, аһ, бу наданлык,
Ниләр китермәде һәм бу түбәнлек.

** Явызлыгыннан... барыбызны да сакласын.

*Дәхи* — тагы.

*Хосусында* — хакында.

*Гарзыхаль* — хәлне сөйләп биргән гариза.

*Дарелмөгаллимин* — укытучылар хәзерләүче югары уку йорты яки курслар.

*Заһирдыр* — ачыктыр.

*Кәляме кадим* — үзе әйткән, иң беренче әйткән сүз.

*Талиб* — таләп итүче (шәкерт — укучы, талиб — белем таләп итүче дип атала).

*Ләһәб* — тәкате калмаган кеше.

*Хошек ләб* — кипкән ирен.

## УРАЛЬСК ХӘБӘРЛӘРЕ

Уральскидә мәшһүр Мортаза бай, «карак башында ут яна» мәкале кабиленнән, «Фикер» гәзитәсенең үткән номерында басылган «Сырой егет» фельетонын үз муенына алып, моны Нурәхмәт хәлфәдән күрә, имеш. Шуның өчен без бу урында Мортаза байга тәнбиһ кыйламыз: безнең Нурәхмәт хәлфә илә һич галякамыз юк. Ул синең якының, син аны рәнҗетмә. Көчең җитсә, безне теләсәң нишләт. Әмма бигөнаһ кешеләргә юк гаепләр тагып йөрмә. Синең ул «Сырой егет» фельетоныннан[1] да кызыграк хәлләрең бар. Ул хәлләреңне Нурый язмый, заман язар.

Гакыйль исәң, нәфсеңә өймә, сакыйн!
Мәкренә җаныңны якмагыл, сакыйн!
Сиңа бакый калмаячактыр заман, —
Гәр шәкый ул, гәр сәгыйд ул, и җәван!*
Мортаза бай! Син төзәлмәссең бугай,
Син нигә бигрәк саран булдың болай?!

## УРАЛЬСК ХӘБӘРЛӘРЕ

Бу сәнә «Фикер» гәзитәсенә һәм «Уклар» вә «Әлгасрел җәдит» журналларына 1907 сәнәсе өчен октябрь башыннан язмайа башладылар. Октябрь башыннан бирле яңа алучыларымыз 1500 гә җитте. Буны иске мөштәриләремез гайрәтилә дәляләт итүләре дип уйлыймыз. Шуның өчен 1907 сәнәсе башыннан «Фикер»не көндәлек, «Уклар»ны атналык вә «Әлгасрел җәдит» журналыны айда ике дәфгалек итмәк ниятендәмез. Алла мөяссәр әйләсен. Хәер хаһ мөштәриләремезгә бик чук тәшәккерләр идәмез.

Гайнетдин карый[1], үз мәсҗеден ташлап, икенче мәхәлләгә барып хәтем итүчелеген һәм үз мәсҗедендә Габдулла карыйның[2] хәтем итүене тыючылыгын шәригатьчә мөнасиб булмас-

---

* Бәхетсез булсаң да, бәхетле булып, рәхәттә яшәсәң дә, и егет!
*Тәнбиһ кыйлу* — искәртү.
*Галяка* — бәйләнеш, алыш-биреш.
*Бигөнаһ* — гөнаһсыз.
*Гакыйль* — акыл иясе, акыллы.
*Нәфсеңә* — үзеңә.
*Сакыйн* — сак бул.
*Бакый* — мәңге, мәңгелек.
*Дәляләт итү* — юл күрсәтү, өндәү.
*Дәфга* — мәртәбә.
*Мөяссәр әйләсен* — җиңеллек бирсен.
*Чук тәшәккерләр* — күп рәхмәтләр.
*Карый* — Коръәнне яттан укучы.
*Хәтем итү* — Коръән уку.

ка кирәк дип, Льбищиннән кәлән мөсафир Мөхәммәтшәрәф әфәнде Манжиков җәнабләре безә хәбәр бирәдер. Вакыйган, хәтем чыгуны Җаек суы буенда балык тоту шикелле күргән кешеләр буны эшли алырлар. Шәригатьтә дөрест булуы — анысы икенче мәсьәләдер. Буны һәр инсаф иясе уйлап караса, белүр.

Фәтхетдин хаҗиның өендә ни бар нәрсәләрен бурыч ияләренең соравы буенча мәхкәмә язып киткән. Ихтираз партиясенә гыйбрәт!..[3]

## ИГЪЛАН

### *1907 сәнә өчен*

Айлык рәсемле, кызыклы, көлкеле, гыйбрәтле, мәгънәле,
яңа «Уклар» журналының мөштәри дәфтәре ачылды.

Һәркем үзенең сурәтен көзгедә күргән шикелле күрәсе килсә, бу журналга карасын. Ләкин авызы кыйшык кешенең авызын туры күрсәтмәгән өчен көзгене атып бәрмәсен.

---

Әгәр бер кемсәне җен, шайтан сихерләсә, албасты басса, шүрәле кытыкласа, бичура тынычсызласа, бу журналны укыя.

Кем дә кем бу журналны такса яки күтәрсә, аңгар кылыч, мылтык үтмәгәй.

## ЧИТ МӘМЛӘКӘТ ХӘБӘРЛӘРЕ

### *Төркия*

Солтан Габделхәмит[1] авырый. Авыруы көннән-көн көчләнеп, артып торадыр.

Габделхәмитнең бу авыруы бу көнге авыру гына түгелдер. Ул Государственный Дума (Мәҗлес мәбгусан)ны каплаган, Мидхәт вә Мәхмүт пашаларны үтерткән[2] көннән бирле хәстәдер.

«Мәче кемнең маен ашаганын белә» дигән мәкаль бик дөрест мәкаль булырга кирәк. Габделхәмит тә: «Милләт бу золымнар, бу бозыклыкларым өчен миннән үч алмый калмас, ми-

---

*Мөнасиб булмаска* — туры килмәскә.
*Вакыйган* — чыннан да.
*Мәхкәмә* — суд (вәкиле).
*Ихтираз* — саклану, саклык белән эш итү.
*Мәҗлес мәбгусан* — депутатлар мәҗлесе.

не үтерер», — дип курка-курка, бөтенләй гакылыннан салмыштыр.

Габделхәмит утыз җылдан бирле Милләт мәҗлесен каплаткан гөнаһы өчен үзен-үзе «Йолдыз сарай» исемле бер зур төрмәгә ябып куйды. Шул «Йолдыз»дан чыга алмыйча ятуы анын залимлыкына вә үзе кыйлган начарлыкларны үзе белгәненә ачык бер дәлилдер.

Яшь төрекләр Габделхәмитнең «Йолдыз» шикелле, ишеклетәрәзәле, тантаналы, солтанәтле төрмәдә ятуына гына риза булмыйлар. Алар солтанның ишексез, тәрәзәсез, җир астындагы төрмәгә кереп ятуын интизар берлә көтәләр. Анда кергәч, Габделхәмитнең золымы, кабахәте халыкка тәҗавез итә алмас, диләр.

Нә исә, солтан Габделхәмитнең вафаты җир йөзендәге иң зур, иң начар бер мөстәбиднең җир йөзен үзенең бетүе илә пакьләмәке дигән сүздер. Бетсен-батсын истибдад, яшәсен хөррият!

## УРАЛЬСКИДӘ ҖӘМГЫЯТЕ ХӘЙРИЯ БАШЛАНУЫ

Хәерле булсын җәмгыяте хәйрия. Бу җәмгыять шәһәремездә улан милләт угылларыны голүм вә мәгариф үгрәтеп, тәрәккъый иттермәйә насыйб булсын, шулай булсын, амин, амин!

Уральскидә җәмгыяте хәйрия башланадыр. Бу башлауларны башка шәһәр халыклары җиңел генә булган дип уйламасыннар тагын. Бунын җәфа вә мәшәкатьләре күп булды. Эшнең артыннан йөргән кешеләр җәфаландылар, хафаландылар, сәламәтлекләрен югалтып, агырып та алдылар. Ни булса да булды. Аллаһы Тәгалә бу эшнең артындин йөрүчеләрнең дөньяда, ахирәттә әҗерләрен вирсен. Бу җәмгыяте хәйрия башлануы Уральски халкының телләрендә озак заман хикәят булып сөйләнәчәктер. Һәм күп кешеләрнең ядында дастан булып калачактыр.

Бунын башлануында булган вакыйгаларне укыган кеше Уральскидә дә Бәләбәй өязендәге кеби муллалар вар икәнлегенә ышаначактыр. Шәһәремезнең бер игътибарлы гына мулласына җәмгыяте хәйриягә член (әгъза) булу өчен кул куйдырырга баргач, бер сифилис агърыкы илә мөбтәля улыб яткан байга барып мәс-

*Солтанәтле* — мәһабәт, зур.
*Интизар берлә* — зарыгып.
*Тәҗавез иту* — ябырылу, һөҗүм.
*Мөстәбид* — деспот.
*Истибдад* — деспотизм.
*Җәмгыяте хәйрия* — ярдәм җәмгыяте.
*Голүм* — гыйлемнәр.
*Агърыкы илә мөбтәля улыб* — авыруына дучар булып.

лихәт кыйлышмыйча кул куймыйм, дигән. Ул сифилис илә мөбтәля бай: «Кул куйган кешеләр иң әүвәл кырык мең тәңкә акчаларын хәзерләсеннәр», — дип әйтә, имеш, һәм, бу сүзе илә бер җуан корсаклы байны да котыртып, кул куйдыртмаган. Инде тамак артыннан йөрүче гавам халкы, буны күреп, җәмгыяте хәйриядән кыр кәҗәләре шикелле өректеләр — кул куючы бик аз табылды.

Халыкның күбесе: «Муллалар кул куйса, без дә куямыз», — дигәч, муллаларга йөрергә башлаганнар иде. Иң әүвәл Габдерәкыйп хәзрәт йөрүчеләрнең борынына нос куеп чыгарган. Аннан соңра мәшһүр кулламачи, гадәд тулмаенча никях укучы Садыйк муллага барганнар икән, ул: «Мин, халык куйса, кул куям», — дигән. Шуннан соңра, йөрүчеләр, өмидләрен кисеп, Гайниҗамал хәзрәт шикеллеләргә бөтенләй бармаганнар. Бу эштә маклерлар да тыгылмый калмады. Кара чутыр Галим абзый да: «Без биш йөз кеше җыйналышып гариза бирәмез, җәмгыяте хәйрия булмасын», — дип, үзенең әгъваннарыны котыртып, «дуңгыздан бер кыл» дигән кабилдән, чәй эчеп йөргән.

Мәгълүм Шәрулла бай да: «Әгәр җәмгыяте хәйриягә Камил Мотыйгый, Нигъмәтулла Бәхтизин вә Госман Коләхмәтевлар катышмасалар, мин керәм», — дип, халыкны куркытмакчы булган. Менә шундаен фетнәләрне уздырып, югарыда мәзкүр өч кешеләрнең гайрәте илә җәмгыяте хәйрия һаман булачак булды.

Берничә мәгърифәтле кешеләр җыйналышып, җәмгыяте хәйриянең уставларын тәртип кыйлып, явочный порядка буенча рөхсәт алып, озакламый эшкә тотыначаклардыр. Хак Тәгалә хәзрәте хәерле нәтиҗәләр тугъдырмайа мөяссәр итсен.

Эт өрер — кәрван йөрер.

*

Бундаен имамнар Уральск кеби зур шәһәрләрдә һәм юк дәгелдер, җәһаләт безне һәркайда чолгап алган.

## ДӘХИ НИЛӘР КҮРЕРМЕЗ ИКӘН?

Уфада чыга торган «Әлгаләмел ислами»[1] гәзитәсенең әүвәлге мөхәррирләре, чыгып, язудан туктадылар. Бу җәһәттән «Әлгаләмел ислами» бетте дисәк тә ярый. Мәсәлән, бер кибет банкрот булгач, икенче кеше ул кибетне алып, фирмасын әүвәлге көенчә калдырадыр. Шуның шикелле, «Әлгаләмел исла-

*Гадәд тулмаенча* — яшь тулмыйча.
*Әгъван* — ярдәмче.
*Дигән кабилдән* — дигән шикелле.
*Мөяссәр иту* — җиңеллек биру.
*Җәһаләт* — наданлык.

ми»нең әүвәлге мөхәррирләре китеп, идарәсе билкөлли үзгәрде. Яңа кешеләр сәүдә итәргә бик оста кешеләр, ахрысы. Әүвәлге номердан ук товарларын бик мактарга тотындылар. Монсен ары гәзитәмезнең мәсләге, яхшыланачак, дип яздылар.

Шулук номерында, театрда уйнаучы егет илә кыз алдымбирдем дип сөйләшкәннәре өчен, шәригатьчә никах буладыр дип, театрга каршы бер мәкалә бастылар. Менә яхшы мәсләк, куәтле булсын яңа сәүдәгәрләр, театр хәрам ул, нигә кирәк ул, шулай тәкъвалык сатарга кирәк.

Дәхи шул ук номерда «Хәят» үлде, «Иршад» үләргә якын[2], без дә үләмез инде дип язып, алучыларны куркытмакчы да булганнар.

Дөнья булгач, кеше төрле хәлгә килә шул. Менә безнең хәлфәмез Һади абзый да үзенең «Йолдыз»ында[3] «Бәянел хак»ны мактап яза башлады, һәм аны мактап ушбуның шикелле бәетләр дә яза башлады.

«Бәянел хак» мәсләге туп-тугъры юл,
Чөнки аның кесәсендә акча бик мул.

Һади хәлфә торып торсын, ул искедән мәгълүм кеше, ул бер алай, бер болай була. Менә син җир сораучы вә үзенә социалдемократ исемен тагучы «Азат халык»ның җарылуына[4] гаҗәплән. Ул, үзенең социаллыгын ташлап, Һади хәлфәнең кочагына барып керде. Инде икәүләшеп Ахмакҗан бабайны мактап, аның Мәскәү малын талап тутырган кесәсенә кермәк булалар, ахрысы...

Әз-зарурате заманә:
Хәрра гофтәм әмәк,
Зәһәрра гофтәм нәмәк,
Хукра гофтәм тагай.*

## ТӨРЛЕ ХӘБӘРЛӘР

### *Яңа гәзитә вә журналлар һәм мәкаләләр*

Исмәгыйль Гаспринский тагы да «Милләт» исемле бер гәзитә[1] чыгарырга карар биргән. Әүвәлге номеры алдымыздагы рамазан бәйрәмендә чыгачак, имеш. Бик яхшы! Фәкать, бер яктан, «Ха-ха-ха» гәзитәсе шикелле кыска гомерле вә, икенче тарафыннан, ике җәпле бер кармак кына булып калмаса ярар иде.

Оренбургта берничә милли хикәяләр язуы илә мәшһүр Шакир Мөхәммәдев җәнабләре тарафыннан атналык «Карчыга»

---

* Замананың кирәкле шәйләре (нәрсәләре):
Ишәкне әйтәбез эшчән дип,
Агуны әйтәбез тоз дип,
Дуңгызны әйтәбез тагай (!) дип.

*Билкөлли* — бөтенләй.

*Тәкъвалык* — дин кушканны гына эшләү, диндарлык.

исемле бер журнал[2] чыга башлады. Әүвәлге номеры идарәмезгә килде. Яхшы-яхшы гына рәсемнәре вә көлкеләре бардыр. Сәбат вә дәвамыны телимез...

«Таң йолдызы»нда бу арада Рәшит әфәнде хосусында[3] гүзәл-гүзәл мәкаләләр дәреҗ ителде.

«Йолдыз» гәзитәсендә «Мөгаллиме әүвәл» берлә «Сәвадхан»ның шәдәдле мәхарәбәләре язылды. Һади абзыйның «Мөгаллиме әүвәл»енә бик кызыгучылар күп икән. Әгәр бер кеше Һади абзый шикелле итеп әлифба китабы язса, Һади абзый аны судка бирәчәк. Сакланыңыз!

Шул ук «Йолдыз»ның соңгы номерының фельетонында Тимербай исемле бер казакъ мулласымы, әллә попугаймы, үзенчә бик кызык бер мәкалә язып, попугайлык саткан.

## ТЕЛСЕЗ ТЕЛЕГРАФ ХӘБӘРЛӘРЕ

### *Гәзитәләр*

Петербург. «Тылмач» исемле гарәпчә бер гәзитә[1] чыга башлады. Татарлар бу гәзитәне: «Татарга тылмач кирәкми», — дип, укыймыйча киреләнеп торалар.

Оренбург. «Чүкеч» журналының[2] ияләре бәгъзе вакыт, чүкечләре бик агыр булганлыктан, урынына төшерә алмый, ялгышлык илә икенче җиргә төшереп куялар. «Аптыраган үрдәк күте илә күлгә чумар» мәкале кабиленнән, дустны дошманнан аермаенча, кем очраса шуңа чүкечләре илә кундыра башламасалар ярар иде дип куркалар.

Багъчасарай. «Тәрҗеман» бабай[3] үзенең гәзитәсендә яңа гәзитәләр тугърысында «Әдәби вә мәгыйши тәнкыйтьләр» исемендә мизан ясап, бу көнгә кадәр «Шәркы рус», «Азат», «Хәят», «Иршат», «Азат халык» вә «Тәрәкъкый» гәзитәләрене битирмәк илә морадларыны хасил итдеке өчен Багъчасарайда бер «бал» ясамыштыр. Дәһа башка гәзитәләрне дә шул мизан илә үлчәп битирмәйә карар вирмеш. «Уклар»ны «Тәрҗеман» бабайга төзәп, «Уклар» мөхбирләренең буңа аеруча дикъкать боермаларыны Багъчасарай әһалисе халисанә тәмәнни идийүр*.

---

* Халкы ихласлык белән көтеп торадыр.

*Сәбат* — фикердә нык торучанлык.

[1] *Хосусында* — хакында.

[2] *Дәреҗ ителү* — басылу.

[3] *Шәдәдле мәхарәбәләр* — авыр сугышлар.

[4] *Мәкале кабиленнән* — мәкалендәгечә.

[5] *Мәгыйши* — тормышчан.

[6] *Мизан* — үлчәү.

## КУРКЫНЫЧЛЫ ХӘБӘР

### *Кыямәт*

Казаннан килмеш дөрест хәбәрләрә күрә Күлтәсинең һәйьәт китапларында сөйләнмеш тәҗазеб кагыйдәсе үзрә кыямәт кубуы, сентябрь аенда Казанда билфигыль вакыйгъ улмыштыр. Казан Ярык («Азат халык») планетасы илә бер мәшһүр «Йолдыз» тәҗазеб идешеп, Казан Ярык көррәсендә кыямәт кубмыш вә «Йолдыз» да, шу тәҗазеб вакытында үз бруҗеннән кузгалып, мәркәзгә якынлашмый; ничә кат кузгалып, ахырында урыныннан күчкән нәрсә дәхи берсенә барып кушылып, кыямәт кубармы яки бара-бара мәркәз улыб («Йолдыз» Кояшка әйләнеп) калырмы? Инде халык бик куркуда, тик ятып, кыямәт кубу юллары ясаган өчен Күлтәсигә[1] дә рәнҗүче күп. Болай булганда, куркырлык та шул, һәркаюмыз бәхилләшеп, берләшергә кирәк буладыр. Шуннан башка чара табылмаз, ахры.

Кыямәт якын килде — җир сораучы ярылды;
Галимнәр тәүбә кыйлды, — Алаһ, дигел бәдәвам,
Замана ахры булды — хәятләр мәмат булды;
Көлгәннәр йөзтүбән китте, — Алаһ, дигел бәдәвам.
«Фикер»дән көлгән иде, — һич сәбәпсез, бер «Азат»,
Инде ул китте назад, — Алаһ, дигел бәдәвам.

## ТИМЕРЧЕ

Оренбургта Тимерче Сандугач[1] исемле бер кеше тарафыннан чыгарыла торган «Чүкеч» журналы һаман шул иске-москы тимерләрне сугып шакылдый. Эшли, эшли, көне буе эшләгәне 3 тиен көмешлек булмый.

Анысы теләсә ни булсын. Бу мөхәррирнең үзе тимерче булып, журналы «Чүкеч» булуы бик кызыктыр. Тагы да Сандугач фамилиясеннән булып, ала карга төсле сайравы «тәкый

---

*Кыямәт* — заман ахыры, дөнья беткән көн.
*Һәйьәт* — монда: астрономия фәне мәгънәсендә.
*Тәҗазеб кагыйдәсе үзрә* — үзара тарту көче законы буенча.
*Билфигыль вакыйгъ улмыштыр* — чынлап та булган.
*Көррә* — шар (көррәи Әрыз — Җир шары).
*Шу* — шул.
*Бруҗ* — йолдызлар төркеме (зодиак билгесе, йолдызлар тамгасы — унике төркем йолдыз унике айга исем булып йөри).
*Мәркәз* — әйләнәнең уртасы, үзәк. (Монда: кояш мәгънәсендә.)
*Дәхи* — тагын.
*Бәдәвам* — берөзлексез.
*Хәятләр мәмат булды* — тормыш бетте.

гаҗәб»рәктер[2]. Бу «Чүкеч»че тимерченең күзенә, ахрысы, һәрнәрсә дә тимер булып күренә торгандыр. Чөнки ул «таң»чыларның социализмын[3], «Әлгасрел җәдит»нең әдәбиятын[4] чүкечләмәкче булды. Үзенең «Чүкеч» исемле иске тимер кисәкләрен генә сатасы килде. «Әлгасрел җәдит» мөштәриләренә көнләште. Минем мөштәриләрем дә шулчаклы булса, озак гомерле булыр идем, диде.

Ничә әйтсәң дә, тимерче шул, һаман корым эчендә, ялкын эчендә торып исергән инде. Төшендә дә чүкеч, өнендә дә чүкеч, язганы да чүкеч, сызганы да чүкеч, журналы да «Чүкеч», — бу нинди бетмәгән чүкеч икән! Тимерче Соловьевның үз башына булган чүкеч булмаса гына ярар иде.

## ГАҖАИБ!

Шәһәремезнең Хәсәнҗаннары, маклер Галимнәре, тагы шундый кара йөзлеләре «Бәянел хак» укыйлар иде. Ләкин бу көннәрдә без «Бәянел хак»ның йөзен дә күргәнемез юк, һай, бичара! Әллә, «Чапан! Чапан!» дип кычкыра торгач, мискиннең авызына чапан җиңе тыгып тончыктырдылар? Әллә ул «Бәянел хак», чапан берлән йөзен каплаганлыктан, безгә күренми микән? Гаҗаиб! Әле беркөн генә япь-яшь мөхәррирләр берлән йөзгә-йөз сөйләшеп, кычкырышып йөргән «Бәянел хак» шулай ук чапан бөркәнә башлады микәнни? Качса кача бирсен, аның йөзе бик ямьсез иде. Бик кара иде. Үз гаебен үзе белгәндер әле, — исеңез китмәсен!

## ӘДӘБИЯТ АХШАМЫ, ЯКИ ЛИТЕРАТУРНЫЙ-МУЗЫКАЛЬНЫЙ ВЕЧЕР

Шәһәремезнең яшь интеллигентләре, Уральскидә иң әүвәл мәртәбә итеп, әдәбият ахшамы ясарга ният иткәннәр. Әдәбият ахшамы татар халкын «Фәзаилеш-шөһүр»[1], «Тишекбаш»[2], «Мөһиммател мөслимин»[3], «Бәдәвам[4]» китапларыннан башка, хәзерге тормыш, хәзерге китеш өчен иң кирәкле, иң мөһим булган яңа-яңа, үз ана телебездәге китаплар илә таныштырачак вә күрештерәчәктер. Әдәбият ахшамы карт аталарымызның чын йөрәгеннән чыккан «Тәфкилеф», «Әллүки», «Сакмар суы» көйләрен, үлгән җиреннән яңадан терелтеп, туган вә туачак балала-

---

*Гаҗаиб!* — искиткеч, шаккатарлык нәрсә!
*Ахшам (акшам)* — кичә.
*Литературный-музыкальный вечер* — әдәби-музыкаль кичә (концерт).

рыбызның күңеленә яңга-яңга милләт хисләре, истикъбаль дәртләре салырга хезмәт итеп, милләт балаларының үлгән күңеленә, саба җиле шикелле, рух өрәчәктер.

Әдәбият ахшамы үзебезнең көйләребез, үзебезнең моңлы мотивларымызны кабахәт фәхешханәләр почмагыннан түгел, үзебезнең яшь зыялыларыбыз авызыннан ишеттерәчәктер.

Әдәбият ахшамы татарларны гомердә булмаган Зәркум[5] батырлар, Дию батыр, Аждаһа баһадирлар берлә түгел, бәлки булган һәм кыйлган начар мөгамәләләре йөрәкләремезне ярып, бәгырь канымызны эчкән Ишан батыр, Мулла батыр, Ахун баһадирлар берлә таныштырачактыр.

Милләт балалары, «Бакырган» ахырын укыганда, Әхтәм сәхабәнең башын кискән Кабил батырга каршы барырга дәртләнгәннәре шикелле, әдәбият ахшамында милләт вә тәрәкъкый сәхабәләренең башын кискән вә аларның бара торган изге юлларына Искәндәр коймасы корган, һәртөрле мыегын кырган, баш такырайткан, чуашлар киеме кигән һәм шул килешләре берлә генә мөселман булган манигы тәрәкъкыйләргә каршы төшәргә дәртләнәчәк вә һәвәсләнәчәкләрдер.

Шуның өчен дә татар кардәшләремезгә милли музыка вә җырулар тавышын ишеткәндә: «Ах, Дәҗҗал чыккан икән инде!» — дип, пич башына менеп, колакларына мамык тыгып, күзләрен бәйләп, өстләренә дә 9 кабат юрган, 5 кабат толып ябынып, «Кяһәф» сүрәсе укып ятмаска тиештер.

Үз халкымызның зарарына тырышкан һәрбер чалмалы бурлакны (батюшка) гөнаһ кичерүче, гөнаһсыз санап, шул ук халкымызның файдасы өчен җан бирергә хәзер булган һәр тар чалбарлы, һәр билсез кыска киемлене дә фасикъ, азган дип хөкем итәргә тиеш түгелдер.

Шулай ук халык каршында җен теле төсле ят телләр илә мөнбәргә менеп җырлауны изге эш дип, әдәбият ахшамындагы халыкның ана теле илә шул ук мөнбәрдәге сүзләрне шамил булган шигырьләрне яман дип, кыек күз берлә карамаска кирәктер.

Бер дә исеңез китмәсен: Мәккәи мөкәррәмәдәге кәгъбә янында гөнаһ кыйлу мөмкин булган шикелле, Киевтәге монастырь янында саваплы эш кыйлу мөмкиндер.

---

*Истикъбаль* — якты киләчәк.

*Саба җиле* — көнчыгыштан искән йомшак җил.

*Сәхабә* — Мөхәммәт пәйгамбәрнең замандашы булып, аны күргән кешеләрне шулай дип атаганнар.

*Манигы тәрәкъкыйләр* — алга китүгә тоткарлык итүчеләр.

*Фасикъ* — бозык, динсез.

*Шамил булган* — үз эченә алган.

*Мәккәи мөкәррәмә* — изге Мәккә шәһәре.

Шуның өчен дә теге җырлаучыларның берсе мәсҗедтә вә берсе «Казан» миһманханәсендә яки башка бер урында булуында бер хикмәт тә юктыр.

Мәсҗедтә ишаннар гына халык күрмәгән арада күзләренә төкерек сөртеп җылыйлар, әмма бичара татар абзыйлар йоклаудан башканы белмиләр.

Әмма әдәбият ахшамында, иншалла, безнең татарлар да күзләренә төкерек, маңка сөртмичә үк әсәрләнеп җыласалар кирәк. Кыскасы гына, милләтнең тәрәкъкыйсенә вә башка милләтләрнең аяклары астында тапталмавына кирәкле нәрсәнең һәммәсе дә сәваплы вә хәерле бер эштер.

Зинага чакыра торган музыка хәрам булса да, алга китәргә, тәрәкъкыйгә чакыра торган музыка мөстәхәб, хәтта важиб уктыр.

Китапча иттереп әйтсәк, «мөкаддимәи хәер хәердер».

Безнең татарларда, иң әүвәл мәртәбә әйткәндә, һәрбер нәрсәгә каршы тору ата-бабадан калган бер гадәттер. Алар, иң әүвәл чыкканда, осуле җәдит берлә укуга да каршы тордылар. Кара тактаның эченнән «тавык аягы» да эзләп маташтылар. Бара торгач белделәр ки, кара тактаның эчендә «тавык аягы» түгел, «чебеш аягы» да юк, имеш!

Инде татарлар арасында аз вакытта күп нәрсә белдергән осуле җәдиткә инкяр иткән, аз заманда күп җиргә алып бара дип, поездга (ахырзаман алдыннан чыга торган атсыз арбага) утырмаган кешене һичбер таба алмассыз.

Татарлар әүвәлдәрәк хатын-кызга язу өйрәтергә ярамый дип, «Таләбел-гыйльми фәризатен галә көлли мөслимин вә мөслимәтин»* хәдисен дә сүгеп маташтылар.

Бара-бара ул сүгүләренең дә урамда ыштан салып йөрү шикелле бер оят вә килешмәгән эш икәнлеген аңладылар.

Андин соң, үзләренең хатыннарын күрәселәре вә күрсәтәселәре дә килмәгәнлектән, мискинәләрнең өстләреннән бикләп чыгып, Лут пәйгамбәр заманындагы форма илә, мыексыз җегетләр артындин селәгәйләрен агызып йөргән сартларга ияреп, безнең татарлар хатыннарына бөтен мәхлукат файдаланган якты кояшны күрсәтү хәрам дип тә талаштылар. Хәмед-

---

* Белем алу һәрбер мөселманга — иренә дә, хатынына да — мәҗбүридер.
*Миһманханә* — кунакханә, гостиница.
*Мөстәхәб* — эшләнүе гүзәл эш.
*Важиб* — эшләнүе мәҗбүри эш.
*Мөкаддимәи хәер хәердер* — изге эшнең башлангычы да изге.
*Хәдис* — пәйгамбәр сүзе.
*Мәхлукат* — җан ияләре.

ләр улсын, инде алар, акрын-акрын, чапанның ат җабуы шикелле бер нәрсә икәнлеген белделәр. Хәзер татарлар үзләренең сарт түгеллекләрен дә яхшы ук төшенделәр.

Инде без өмид итәбез ки, шаять, татарлар тик үзләренең файдалары өчен генә, тик үзләренең сәгадәт вә икъбальләре өчен генә ясалачак әдәбият ахшамына да ул кадәр сыртлары берлә тормаслар.

Әле безнең татар кардәшләр 3 яшьлек бала хөкемендә генәдер. 3 яшьлек балага да үзенең сәламәтләнүе өчен дару эчерсәң яки тышка яланаяк, яланбаш чыкма, дисәң, билгеле, каршы торадыр.

Шуның шикелле, татарларга да, болай итсәгез, сәламәт булырсыз, тегеләй итсәңез, үзеңез өчен яхшы булыр, дисәң: «Э... э... кирәкми, э... э...» — дип киреләнәләр.

Ә ишаннар мискин сакаллы сабыйларның кулларыннан һәммә тәтиләрен («иннәмәл хәятет дөнья лягабен вә ләһүен вә тәфахир» иләх* аяте кәримәсен исеңезгә төшереңез), һәммә уенчыкларын алдап алып бетерәләр. Аларны, оҗмах исемле бакчага алып барабыз, дип кызыктыралар.

Әгәр безнең сакаллы балалар тәтиләрен бирмәсәләр, ишаннар ул нарасыйларны, алайса, җәһәннәмгә салабыз, сезне җәһәннәмдәге бүкиләргә ашатабыз, дип куркыталар.

Бала, мискин, ни эшләсен, ышана да тәтиләрен биреп бетерә. Нә исә, сөйләсәң сүз күп булыр. Яшәсен әдәбият ахшамы! Яшәсен милләт!

## ЛӘТЫЙФӘ

Үткән сәнә «Казан мөхбире»ндә игълан кыйлынган Бәдигъ мөәззиннең ата күркәсен[1] «Карчыга» мөхәррирләре адашып йөргән җиреннән тапканнар да «Әлгаләмел ислами» гәзитәсенә мөхәррир итеп куйганнар.

Бу күркә, әлбәттә, юаш күркә түгел. Ул, юаш булса, Бәдигъ мөәззиннән качып та китмәгән булыр иде.

Бәлки, укучылар: «Аңа ник күркә дип әйтәсез, аның исеме вә фамилиясе Баһаветдин Максудов ич!» — дип бәхәс тә итәрләр.

---

* Дөнья тормышы — уен, көлке, мактану һ.б.

*Хәмедләр улсын* — шөкерләр булсын.

*Сәгадәт вә икъбальләре* — бәхет һәм якты киләчәкләре.

*Аяте кәримәсен* — Коръәннең киң күңеллелек, юмартлык күрсәткән аяте мәгънәсендә.

*Ләтыйфә* — көлкеле кыска хикәя, парча, анекдот.

Ләкин бу мөхәррирнең, күркә кеби, һәрбер сызгырганга голдырдавын һәм кем очраса шуны «мәхҗүб улырсыз» дип куркытып кабаруын күргәч, без аның ата күркә булуында шөбһә итмибез, һәм «Карчыга»ның мондый күркә тотканы өчен шатланабыз.

## КЫЗЫККА ОЧРАУ

17 ноябрьдә, әллә нинди бер эшем булып, «Казан» миһманханәсенә кич сәгать 7 дә барган идем. Барсам, һәрвакытта җәмгыять була торган өстәлдә башына борчак чүмәләсе төсле ишелгән чалма, өстенә әллә ничә җиренә май тамган һәм Нух пәйгамбәр көймәсеннән төшеп калган чапан дип уйларлык бер чапан кигән, муенына да пычранып беткән ленталы бер медаль таккан бер мулла утырган. Бу мулланың сакалының аклыгы һәм тәрбиясез ат ялы шикелле чорналып, чуаланып бетүе, йөзенең бакыр шикелле кызыллыгы, тешләренең коелып беткәнлегеннән авызының чәп-чәп итеп торуы — кыскасы гына, һәр җире, һәр әгъзасы моның бик надан, бик затсыз бер татар мулласы икәнлеген үзеннән сорамыйча да белдереп, сөйләп торалар иде.

Бу мулла мин килгәнче монда күпме утыргандыр, мин анысын белмим; мин кереп бераз торгач та, хәзрәт, сарык абзарындагы бүре шикелле, як-ягына карангалап: «Әй, йәмәгать! Монда киленез!» — дип кычкырынгалый башлады. Шундагы чәй эчеп утыручы татарлар, мондый зур хәзрәтнең тавышын ишеткәч, бик тиз йөгерешеп өстәл янына килделәр.

Халык килгәч, хәзрәт «әһ-әһә» дип бер-ике [тапкыр тамак] кырынгалап, аягүрә торды да ушбу түбәндәге сүзләрне сөйли башлады:* «Менә, ягъни мәсәлән, йәмәгать, мин монда ни өчен килдем, мин шуның өчен килдем: хәзер шәһәремездә әллә нинди гәзитчеләр чыгып, һәрбер гаепле кешенең гаебен үзләренең гәзитләрендә яза башладылар. Менә мин абластнуй ахун, мин һичбер мәртәбә хөкүмәт тарафыннан замичән булганым юк, Аллага шөкер, менә сакалым агарганчы хезмәт иттем. Гәзитчеләр эшләпә кияргә кушалар, чалмалылардан көләләр, галимголяманы хурлыйлар, хәтта ки динемезнең башлыгы булган мөфтине дә төя ясап төшергәннәр. Аллаһы Тәгалә хәзрәте Коръәндә: «Вә ля тәҗәссесү футәһиликү вә ля ягътәбә бәгъзекем

---

* Моның сөйләгән сүзләре күп булса да, мин яраклысын гына сайлап алдым. (Г.Тукай искәрмәсе.)

*Мәхҗүб улырсыз* — пәрдә каплагыз, пәрәнҗә киегез.

*Замичән (замечен) булганым юк* — начар эш өчен күзәтү астына алынганым юк.

бәгъза»*, — дип, ягъни: «Шимди бер-береңездән көлмәңез». Мин гәзиткә исемем язылудан куркам, тагы мине дә гәзиткә язарлар. Йәмәгать! Сездән үтенәм: зинһар, гәзиткә һичкемнең гаебен яздырмаңыз; тырышыңыз, мин сездән үтенәм, зинһар, ахуннарны язмасыннар. Гәзитчеләр: «Хатыннар качмасыннар», — дип әйтәләр, аларның бу сүзләренә ышанган кешеләр — кяфер. Менә Коръәндә: «Йа әйеһәннәбие, къоль ли әзваҗикә вә бәнатикә ямнинә галәйһиннә мин зәлабиһиннә»**, — дигән.

Ахун бу Коръән аятьләрен шулкадәр сындыра, шулкадәр изә иде ки, бөтенләй урмандагы куе корган агачлар арасыннан аю йөргән төсле иде, яки Коръән — ярма, хәзрәтнең тешләре — тегермән ташлары кеби иде.

Кәләмулланы бу кадәр яңгылыш укыганлыгыннан бу хәзрәтнең «Фәзаилеш шөһүр»дән имтихан биреп кенә имамлыкның рәсүлулла урынына калу икәнлегеннән хәбәре булмаганлыгы кояш шикелле заһир иде.

Моның мөфтине төя дип төшерүне яратмавы яки мөфти аркылы тагы бер-ике медаль алу яки мине дә кайрандагы карт кәҗә сурәтендә төшерерләр дип куркуы иде.

Минем шул вакытта вөҗданым: «Һай, бу хәзрәтне болай мәҗлескә китереп сөйләткәнче, тимерчегә алып барып авызын чүкечләтеп, бераз Коръән укырга, татарча сүз сөйли белергә өйрәтсәң, нинди яхшы булыр иде», — дип тора иде.

Ахун сөйләгән вакытта, Фатих Шәрипов, Фәйзерахман Шаһиев, кәвешче почетный гражданин Шәрәфи абзый шикеллеләр: «Бик дөрест, хәзрәт, бик дөрест», — дип лыкылдыйлар иде; яңга фикерле шәкертләр: «Бик ялган, хәзрәт, бик ялган!» — дип кычкыралар иде.

Әгәр бу мәҗлестә минем шикелле берничә яшьләр булса, ахун сөйләгәндә, һәммәсе беравыздан «мырау-мырау», «мияу» кычкырып, мәче музыкасы уйнаячаклар иде.

---

* Бер-берегез артыннан шпионлык итмәгез, юкса һәлак булырсыз, бер-берегезне шелтәләмәгез.

** И пәйгамбәр, хатыннарыңа, кызларыңа әйт, алар кимчелекләрен кисеп ташласыннар (бетерсеннәр).

*Шимди* — хәзер.

*Кәләмулла* — Алла сүзе (Коръән).

*Рәсүлулла* — пәйгамбәр.

*Заһир* — ачык.

*Кайран* — аран (*казакъча*).

## «ТӘРҖЕМАН»НЫҢ ТАТАРЛАРГА ГАЛЯКАСЕ

Минем уемча, «Тәрҗеман»ның без татарларга галякасе (бәйләнүе) бөтенләй юктыр. Чөнки, әүвәлән, аның теле — безнең телемезгә бөтенләй кире бер Кырым теледер. Икенче, ул хәзерге хөррият диңгезе ташыган вакытта да һаман черносотенный мәсләк тотып, һәммә бюрократларның, хәтта ишаннар вә муллаларның хаер хаһыдыр. Әбүҗәһелнең[1] рәсүлулла кеби бер әгъля хәзрәтнең каршында торып та күңеленә иман нуры кермәгән шикелле, «Тәрҗеман»ның да заманымыз кеби хөррият заманында борынына хөррият исе кермидер. Әгәр дәрхәкыйкать «Тәрҗеман» хөррият дусты булса, «Уральск менласы ишанлари бетермәк эстәюр вә «Таң йолдызы» бюрократлари халыкка дошман булган һәрбер зур корсаклари бетермәк эстәюр» (ягъни бетермәк кирәкмәс) мәалендә бер сүз язмас иде. Безнең татарларга татарларның уяныр заманында 25 сәнә тагы катырак йокларга сәбәп булган «Тәрҗеман»ны алганчы, Истанбулдагы истибдад корбаны булган «Сабах», «Икъдам», «Тәрҗемане хакыйкать» гәзитәләрен[2] алу тиештер.

«Тәрҗеман» гәзитәсе, гыйльме кәлям берлә, кирәкмәгән «могътәзилә ля әдрияләрне» рәд кыйлучы[3] татар шәкертләре төсле, һаман 25 елдан бирле «Новое время»[4] берлә кычкырышып ятты.

Ул шуның берлә үзенчә мөселманлык, диндарлык сатты. Ләкин «Тәрҗеман» татарларның андый хәйлә вә дәсисәләргә генә мөкиббән китәр заманы үтмәгән дип уйламасын. Әллә кайчан үткән! Без моннан егерме биш ел борын, ак күмәч булмаганда, ипи ашаган һәм кыйбатлы тәмәке булмаганда — махорка чорнап тарткан төсле генә, «Тәрҗеман»ны укыдык һәм ихлас багъладык. Инде бөтенләй үзгәрдек!

«Тәрҗеман» гәзитәсе, ялгыз чапканда, үз койрыгыннан алда килә торган ат шикелле, безнең күзебезгә һаман алда төсле күренә иде. Ләкин, хәмедләр улсын, хәзер мәйданга «Таң йолдызы», «Вакыт», «Фикер» шикелле тагы да йөгерек атлар төште. Без «Тәрҗеман»ны шулар скачкасына кушып карадык. Шунда кем алда, кем артта икәнен күрдек.

---

*Әгъля* — иң бөек.
*Дәрхәкыйкать* — чынлыкта.
*Мәалендә* — мәгънәсендә.
*Истибдад* — деспотизм.
*Гыйльме кәлям* — схоластика.
*Рәд кыйлучы* — кире кагучы.
*Дәсисә* — мәкер, коткы, интрига.
*Хәмедләр улсын* — шөкерләр булсын.

Инде «Тәрҗеман», зинһар, үзенең «мөтәфәррика» кыйсмендәге мизаны берлә* безне үлчәп тә азапланмасын, «Милләт»[5] исемендәге зилләт тә чыгармасын һәм шулар берлә безне алдарга да уйламасын, «Камусы гыйльми»[6] дә сатмасын. Барыбер без алданмыйбыз, алданмыйбыз дигәч алданмыйбыз! Вәссәламе галя мәниттәбәгаль һөда!**

## ЯНӘ «ТӘРҖЕМАН»ГА

Без әйтәмез: бер кеше 20 миллионлы бер халыкның там яртысын дошман күреп, калган яртысын дуст күрәм дип дәгъва кыйлса, аның бу дәгъвасы ап-ачык бер ялгандыр.

Менә шул нигез өстенә бина итеп, без «Тәрҗеман» гәзитәсенең «хиҗаб» кеби кирәкле бер мәсьәләдә телсез шәйтан шикелле тик торуын вә кулыннан килгәнчә хиҗаб күтәрүне кагуын бик зур вөҗдансызлыкка хәмел итәбез.

Татарларның яртысы булган ирләр — мөэминнәр-мөселманнар, инсаннар булган шикелле, икенче яртысы булган хатыннар да шулай ук мөэминә-мөслимә вә инсаннардыр.

«Тәрҗеман» иясе, мин милләтемә хезмәт итәм дигән булып, 25–26 сәнәдән бирле ирләр өчен бер гәзитә чыгарып торды[1]. Соңга таба «Мәшһүр хатыннар»дан[2] урлаган материаллар, әллә нинди негр сурәтләре берлә тулган һич эшкә яраксыз «Галәме нисван» да[3] чыгара башлады.

«Тәрҗеман» иясе нәрсә язса да, ни чыгарса да, һәр заман мөштәриләрнең кәефен карап, байларның тарелкәсен ялап, шул байларның самовар куючы малайлары булган мулла вә ахуннарның гаебен яшереп азапланды. Тагы дөрестрәге: кара сыерга акбур сөртеп ак күрсәтмәкче яки кара карганы сабын берлә юып агартмакчы булды.

«Тәрҗеман»ның теләсәң генә кайсы номерын тотып иснәп карасаң да, тик мөштәри мөляхәзәсе илә генә чыккан гәзитә исе килеп үк торадыр.

---

* «Төрлеләр» бүлегендәге үлчәве белән.

** Туры юлга ияргән кешеләргә сәлам!

*Зилләт* — хурлык, гарьлек.

*Там* — төгәл.

*Хиҗаб* — хатын-кызларның йөзләрен каплаучы пәрдә (яулык, шәл һ.б.)

*Хәмел итү* — юрау.

*Мөштәри мөляхәзәсе илә* — язылып алучылар санын күбәйтү исәбе белән.

«Тәрҗеман»га мөтәгассыйб вә вәхшиләрнең хушына китмәслек бер сәтыр таба алмассың.

Чынлап та, «Тәрҗеман»ның кайсы җире мөтәгассыйбларны рәнҗетсен? «Камус»ымы? Тигәнәк аралашкан «Ак гөлдәстә»семе[4]? Әллә «Йөз сәнә соңра»сымы? Әлбәттә, боларның һичберсе җәһаләт тарафдарларының кәефен җибәрмидер.

«Тәрҗеман» мөхәррирен без хиҗаб күтәрүнең хатыннар мәдәниятенең ачкычы икәнен белми дип әйтә алмыйбыз. Ул, әлбәттә, беләдер. Тик, баягыча, мөштәри аулау гыйшкыйлә мөбтәлядер.

## УРАЛЬСК ХӘБӘРЛӘРЕ

Бу арада гына лично-почетный потомственный[1], тагы әллә нинди, әллә нинди бер гражданинның өендә голямаләр (муллалар) мәҗлесе булган. Шунда Галиулла әфәнде илә русларның 16 җирдәге җәмгыяте хәйриясенә член булган мәгълүм Уральски Сәйдәшеве арасында бик яхшы мөназәрә булган. Галиулла әфәнде ул татарның һәр сүзенә мең җавап, һәр авызын ачуына мең савап биреп, гомердә ишетмәгәннәрен ишеттергән.

Мәҗлестә сөйләнгән сүзләрнең тәфсыйлен язарга шәһәр хәбәрләре фасылы сыйдырмаганлыктан, киләчәк номерда тәфсыйлен язачагымызны вәгъдә итәбез.

*

Инде «Казан» миһманханәсен 24 хуҗа кулыннан икс елга Садыйк Гобәйдуллин алды. Бу зат яшьләрдән улдыгыннан заманга муафикъ сурәттә тәрбия кыйлыр дип уйлыйлар. Ләкин «Казан» миһманханәсенең рәваҗ вә тәрәкъкыйсенә шатланып иҗтиһад итә торган кешеләргә бердәм салкынлык күрсәттеләр. Ахрысы, һаман чи көе камыр илә өч тиен пәрәмәч, биш тиен чәйдән башка артык мәгънә чыгара алмас.

*Мөтәгассыйб* — тискәре, реакционер.
*Сәтыр* — юл (газета, китап юлы).
*Җәһаләт тарафдарлары* — наданлык яклылар.
*Мөштәри аулау гыйшкыйлә мөбтәлядер* — язылып алучыларны күбәйтү кайгысына тартылган.
*Мөназәрә* — бәхәс.
*Тәфсыйлен* — нечкәләп.
*Фасыл* — бүлек.
*Муафикъ* — ярашлы.
*Рәваҗ вә тәрәкъкыйсенә* — алга китүенә.
*Иҗтиһад итү* — тырышу.

## «ЧҮКЕЧ»ТӘН

«Чүкеч» журналына кызучы кешеләргә:

Тимер кызган саен чүкечләргә яхшы буладыр. Менә күрдеңезме, мин әйттем бит, тимерче мин хәйсе һөвә тимерче*; аңгар һәрнәрсә, һәркем тимер булып күренә, дип.

Вакыйган, нинди дөрест сүз әйткәнмен икән[1]! Ул тимерче, мискин, үз гомерендә чүкечләүдән, тимерчелектән башка һөнәрне тәҗрибә итмәгәнгә, әллә никадәр нәрсәләрне яңгыш чүкечләде.

Җөмләдән берсе: ул «таң»чыларның социализмын чүкечләп азапланган иде дә, «таң»чылар аның чүкеченә каршы әллә нинди үткен кораллар хәзерләделәр.

Шундин соң тимерче аңлады ки, инде чүкечләр, тимерчеләр базары беткән икән! Менә берзаман тимерчемез, «таң»чыларга табан кычкырып, инде бер дә чүкечләргә уйламаска ант биреп, чүкечен ташлап, тәрке силах итте.

И тимерче, тимерче!
Тимереңне кимерче.
Каты тимер тешли-тешли,
Теш казнаңны җимерче.
Тимер ашап симерсәләр,
Зинһар, син үк симерче.
Соңгы көндә чүкечләргә
Тимер тапмый тилмерче!

## ҖЕН БЕРЛӘ УБЫР

Җен Убырга:

— Син ник мине җил тегермәне дип хурлыйсың? Әллә мине «Өлфәт» гәзитәсе дип беләсеңме?

— Ә син миңа ни өчен «Җамусы бәхри»[1], «Зилләт» гәзитәсе[2] дип ат кушасың? Ник «ха-ха-ха» дип көләсең? Мин дә бит Бакчасарайдагы акча сарае, акча малае түгел[3]!

---

* Тимерче булуы белән тимерче.

*Вакыйган* — чыннан да.

*Тәрке силах итү* — коралны ташлау.

# ГАҖӘП ТҮГЕЛМЕ?

Бу дөньяда Гафифә исемле фахишәләр, Салих исемле фасикълар, Садыйк исемле кязибләр, ханәкаһ исемле тәрәтханәләр, «Бәянел хак» исемле бәянел батыйльләр, «Йолдыз» исемле тычкан утлары, ишан исемле ишәкләр, солтан исемле сыртланнар, Габделхәмит [1] исемле аюлар, Әхмәтҗан[2] исемле әллә нинди ахмак җаратылган җаннар, Рәшид вә Мөршид[3] исемле мозыйль вә риялылар, мөрит исемле мөртәтләр, «Мөгаллим» исемле мөҗәһһилләр вә мөгаффилләр, «Азат халык» исемле кол вә черносотенный халыклар, «Хәят» исемле мәматләр, Гаспринский исемле гасфурлар, мөфти исемле мужик-мыштыблар, кирәкмәгән озын башкортлар, Тимербай исемле агач попугайлар, имам Садыйк әл-Иманколый исемле имам кязибел имансызыйлар, Дурново[4] исемле дурной вә дураклар, Каульбарс[5] исемле кан эчүче юлбарыслар, мөхәррир Тимершаһ[6] исемле гади чүкечле тимерчеләр, «Карчыга»[7] исемле карчыклар, әбиләр журналлары биниһаять күп бит.

Гаҗәп түгелме? Ник болар үзләренең чын исемнәре берлә генә исемләнмиләр икән? Барыбер ялган исем такканнары мәгълүм бит инде! Нигә яшерәләр?

---

*Гафифә* — пакь, намуслы хатын-кыз.
*Салих* — изге.
*Фасикъ* — бозык, азгын.
*Садыйк* — туры сүзле.
*Кязиб* — ялганчы.
*Ханәкаһ* — ишан бүлмәсе.
*«Бәянел хак»* — хакны, дөресне сөйләүче.
*Бәянел батыйль* — ялган сөйләүче.
*Солтан* — патша, хөкемдар; мәһабәт, олы, зур дигән мәгънәсе дә бар.
*Габделхәмит* — мактаулы бәндә.
*Әхмәтҗан* — данга, мактауга ия кеше.
*Рәшид* — туры юлда булучы, турылыклы.
*Мөршид* — туры юл күрсәтүче, турылыкка өндәүче.
*Мозыйль* — аздыручы, туры юлдан яздыручы.
*Риялы* — икейөзле.
*Мөрит* — иярүче, шәкерт (монда: ишан мөрите мәгънәсендә).
*Мөртәт* — динен ташлаган, башка дингә күчкән (күчермә мәгънәсе — хыянәтче).
*Мөҗәһһил вә мөгаффил* — надан, аң-белемсез калдыручылар.
*Мәмат* — үлем.
*Гасфур* — чыпчык.
*Садыйк әл-Иманколый* — сүзлек мәгънәләре: дөресен сөйләүче, иманы (идеалы) нык, шуңа колдай турылыклы дигәнгә туры килә.
*Дурной* — тиле, акылсыз.
*Биниһаять* — чиксез.

## МОСАЛӘХӘ

Хәзер инде «Шатыр-потыр-апчыхи» гәзитәсе[1] берлә «Фикер» бер дә кычкырышмыйлар, чөнки Әхмәтҗан абзыйның 10 язганына, 15 сүгүенә каршы «Фикер» гәзитәсе бер мәртәбә генә җавап кайтарган иде. Әхмәтҗан абзый, Гайса каршындагы Дәҗҗал шикелле[2], тоздай эреп китте, чыдый алмады, «Фикер»не Окружный исемле казыйга илтеп суктырмакчы булды. Әгәр дә «Фикер» тагы бер-бер сүз әйтсә, Әхмәтҗан абзый Петербургтагы Печатный эшләрне карый торган министрга кар өстеннән җәяү, яланаяк җөгереп барачак, имеш. Шуның өчен, Әхмәтҗан карт хәзердән үк, ихтималдан ихтираз өчен, читеген салган, ди. Үзе күлмәкчән, ди, пич башына менеп, аягын салындырып утырган, ди. Петербург шикелле җырак җиргә чапканда, корсак мишайт итмәсен дип, бабай пич башындагы тараканнар берлә бергә сохарилар гына кимерә, ди. Һәр ничек жиңеләймәкче була, ди. Күзләре Уральскигә терәлгән, ди. Тагы «Фикер»нең сүгүен көтә, ди.

Әхмәтҗан картның «Фикер»не җиңүгә ышанычы тик «Фикер»нең Азиягә якын булуы гына икән. Ни тәкки Куропаткинның[3] Японияне җиңүгә ышанычы Япониянең азияле булуы гына иде.

Шул рәвешчә үк, Әхмәтҗан абзый вакытында «Фикер»нең йозрыгын үзенең аркасы берлә кыйнаса кирәк.

## ТЕЛЕГРАМНАР

Багъчасарай. Исмәгыйль Гаспринский «Тәрҗеман»ының «Мөтәфәррика»сына «Камусы гыйльмия вә фәнния» дәреҗ иткән шикелле, «Милләт» гәзитәсенә «Әхтәри»[1] дәреҗ итәчәк.

Әгәр «Камусы гыйльми» яки «Әхтәри» бетеп калса, Кәламулла (Коръән) басачактыр.

Петербург. Рәшит бабай яртысы керәшенчә, яртысы чуашча уларак «Кирлимар вә Чабаксар» исемендә бер журнал нәшер итә башлаячактыр. Аның «Әт-тилмиз»[2] нам гәзитәсе дә, татарлар һәммәсе бердән гарәп телен кабул итсәләр, милләткә бик зур файда итәчәктер, диләр.

---

*Мосаләхә* — килешү.
*Печатный эшләрне* — матбугат эшләрен.
*Ихтималдан ихтираз* — берәр сәбәп килеп чыгу ихтималыннан саклану.
*Ни тәкки* — шуның кебек.
*«Мөтәфәррика»сына* — «Төрлеләр» дигән бүлегенә.
*«Камусы гыйльмия вә фәнния»* — «Гыйльми, фәнни сүзлек».
*Дәре• иту* — урнаштыру.

Оренбург. Тимерче Соловьев җәнабләре[3] үз кулы берлә четырехсветный бер трахтир ясый башлады. Шуңгар күрә, кулына «Чүкеч» алып, шул трахтирның такталарын кадаклыйдыр. Бухгалтерия гыйльменә маһир Алмаев хәзрәтләре[4] трахтир салырга ничә кадак киткәнен ысчут берлә шалт-солт салып торадыр.

Оренбург урамындагы һәммә малайлар, ысчут тавышы берлә «Чүкеч» тавышының бик кызык чыгуын тамаша итеп, гаҗәпләнеп торалар.

## ШАРТЛАР

«Мөселман иттифакы»на кереп, үзеңне мөэмин вә мөселман дидерәсең килсә, менә шул түбәндәге нәрсәләргә иман китерергә кирәк: 1) байлык; 2) җирлелек; 3) алпавытлык; 4) кәләпүшлелек; 5) Истанбул эчендәге форма илә һәр мөтәкәббирнең күңеленә ригаять итеп тормаклык; 6) җизнилек, кайненелек; 7) кодалык-кодачалык; 8) туганлык-тумачалык; 9) кияүлек-каенагалык; 10) баҗалык вә гайре моның шикелле мөэмәнен биһ булган нәрсәләр бик күптер. Бу әйтелгәннәрнең һәммәсе дә «миллилек» дигән масдардан иштикакъ кыйлынып алынганнардыр. Бу иттифакъ та инсаннарга инсаният ноктаи назарыннан* карамыйча, кодалык вә кодачалык ягыннан карарга тиештер. Шуның өчен Исмәгыйль Гаспринский бер «Тәрҗеман»ында: «Бән һәр валидәләри сәвәрем, әмма үз валидәми дәһа чук сәвәрем», — дия багърыйур**. Ләкин Исмәгыйль абзый үзенең торуы капитал өчен, ятуы капитал өчен, миллилек сатуы капитал, «Мөселман иттифакы» ни эшкә ярамаса да, мактавы капитал өчен, нәфсе заты вә мөхәррирлеге капитал өчен булуын, гомум тарафына киткәндә: ишаннар вә муллаларның мәсҗедләргә кереп, ап-ачык капиталга табынуын, Алланы онытуын, капитал шомлыгыннан һәр мөселманның исламияткә кире

---

* Кешеләргә кешелек ноктасыннан.

** «Мин һәр ананы сөям, әмма үз анамны тагын да күбрәк сөямен», — дип кычкыра.

*Мөэмин вә мөселман* — «мөэмин» сүзенең төп мәгънәсе Коръән тәкъдим иткән Аллага һәм аның җирдәге вәкиле Мөхәммәт пәйгамбәргә ышануны, аның юлыннан баруны аңлата; «мөслим» сүзе исә Аллага һәм пәйгамбәргә буйсынуны аңлата.

*Мөтәкәббир* — үзен эре тотучы.

*Ригаять итү* — охшарга тырышу.

*Мөэмәнен биһ* — иман китерә торган, ышанылырга тиеш.

*Масдардан иштикакъ кыйлынып* — төптән, нигездән ясалып.

*Нәфсе заты* — үзе, үз шәхесе.

эшләр эшләргә мәҗбүр булуын, кызларның зинага, сәүдәгәрләрнең ялганга, мөхәррирләрнең алдауга, шагыйрьләрнең әллә нинди зарарлы кешеләрне мактауга көчләнүен, ике сәүдәгәр, ике эшче, ике мулланың, көндәш хатыннар шикелле, исламият кушмаган рәвештә мохасәдәсен вә шул капитал өчен исламиятне, инсаниятне бер якка ташлауларын күрсә, «Тәрҗеман»да андый сүзләрне язарга оялыр иде.

Капиталистический строй бетеп, дөньяга социалистический тормыш чыкмыйча, капиталның һәр хакыйкатькә пәрдә булып торуы бетмичә, мин үземезне мөселман дип йөрүдә бер мәгънә дә тапмыйм.

Бу тормышка кальбән разый булган кеше мөселман да түгел, мөэмин дә түгел, инсан да түгел, диясем килә.

Бу тормыш бар вакытта үзләрен мөселман дип йөрүчеләр, түгел Коръәннең эчендәге әмерләренә буйсыну, бәлки, катыргасы арасына язылган сүзләрен дә ишетмиләр.

Шулай булгач, социализмның рәваҗы өчен үзеңнең бил багълап эшкә керешергә гайрәтең җитмәсә дә, һич булмаса, сүкмәскә вә күңелдән дошман булмаска кирәк.

## КАЗАНДА НИКЯХ МӘҖЛЕСЕ

Яхшы гына зур бер мәҗлес. Мәҗлеснең бер түрендә Сәмәнетдин хәзрәт, икенче түрендә Мөштәри хәзрәт утырганнар да, берсе никях укый, берсе бу рәвешчә иҗабе кабул сүзләрен әйтә: «Син, кем, Әхмәдһади Максуди, Биби Кәүкәбел фәна Календаретдин кызыны[1], вәли-вәкил булып, «Азад»етдин бине Социалистетдин угылына бирдеңме?»

— Бирдем, хәзрәтләр! Бирдем.

— Ә син, мулла Галиәсгар Камалетдин угылы, вәли-вәкил булып, «Азад»етдин Социалистетдин угылына «Кәүкәбел фәна» Календаретдин кызыны алдыңмы?

— Алдым, алдым.

Хәерле булсын Хәмидәнең никахы!

---

*Мохасәдә* — көнләшү.

*Кальбән* — күңелennән.

*Рәваҗы* — уңышлы таралуы.

*Сәмәнетдин* — акча ярат учы.

*Мөштәри* — сатып алучы, подписчик.

*Иҗабе кабул* — өйләнешүчеләрнең алу-барулары турында ризалыкларын белдерүләре.

*Кәүкәбел фәна* — зәгыйфь йолдыз.

* * *

«Уклар» гали фикерле бер татарны бик нечкәләп тикшерә вә тәфтишли торгач, бик зур нәрсәләр кәшеф итте. Чөнки «Уклар» бу юлы татарның корсагына карады[1]. Караса, ни күзе берлә күрсен! — ушбу рәсемдә тасвир кыйлынган хакыйкатьне тапты. Һәр нә исә, без мондый, эченә һәрнәрсә сыя торган киң эчле мөселманның күп булуына куанамыз. Ләкин, тәәссефкә, һәркемнең белдеге кеби, тук корсак укуга бик йомшак, бик чукрак буладыр.

## СӘДӘХӘ

Күптән түгел «Казан» миһманханәсендә җәмгыять булып, шундагы җәмәгать җәмгыяте хәйрия файдасына акча сала башладылар. Шул вакыт бер кеше мәшһүр Фатих абзыйга[1] карап:

— Йә, селкен, Фатих абзый (ягъни акча сал)! — диде.

Фатих, бу сүзгә ачуланып:

— Сез күпме салсагыз да, сезнең ул акчаларыгыз «сәдәхә»дән китми, — диде.

Фатих абзыйның бу сүзе, тыштан караганда, бик мәгънәсез төсле күренсә дә, төптән уйлаганда, бик хикмәтле һәм мәгънәле сүздер. Чөнки дөньяда ике төрле бирү бар: берсе — сәдака, икенчесе — «сәдәхә».

Сәдака дигәне җәмгыяте хәйриягә, ач вә ялангачларга, мәктәп-мәдрәсәләр, дарелмөгаллиминнәр салырга, гәзитә вә журналларга бирүгә әйтеләдер.

Әмма «сәдәхә» дигәне — тимер сандыгында 10 мең, 20 мең тәңкә акчасы яткан ишаннарга, аларның мәхдүмнәренең һәртөрле кирәк урыннарына, трахтир түбәләре ябарга, бильярд, карталарга бирүгә әйтеләдер.

Менә инде Фатих абзыйның «сәдәхә»дән китми» дигән сүзен аңладык бит.

Фатих абзый шикелле кырган мыеклы кеше белми әйтәме соң?

Тагы да Фатих абзый үзе Капчыклы Шашы[2] авылыныкыдыр. Ул авыл кешеләре, ирләре, бала-чагалары — һәммәсе иген

---

*Тәфтишләү* — җентекләп тикшерү.

*Кәшеф итү* — ачу.

*Тәәссефкә* — кызганычка.

*Сәдәхә* — сәдака (монда юри надан хәзрәтләрчә бозып әйтелгән), хәер акчасы.

*Миһманханә* — кунакханә, гостиница.

*Җәмгыяте хәйрия* — мәхрүм-гаҗизләргә матди ярдәм итү оешмасы.

*Дарелмөгаллимин* — укытучылар хәзерләүче мәктәп яки курслар.

чәчү урынына теләнчелек берлә кәсеп итәләр. Шул сәбәпле Фатих абзый «сәдәхә» нәрсә икәнен бигрәк ачык беләдер.

«Сәдәхә» — керәшен сүзедер.

Һәртөрле ярамаган эшләргә акча бирүгә итлакъ улыр.

## УРАЛЬСК ХӘБӘРЛӘРЕ

Шәһәремезнең яшьләре якында булачагы мөхакъкакъ булган «Әдәбият ахшамы»на үзара репетицияләр ясап хәзерләнә башладылар.

*

Үткән номерымызда вәгъдә кыйлынган лично-почетный потомственный, әллә нинди яшелле-күкле гражданинның өендәге мәҗлеснең тәфсиле бу номерымыздан да «илляһем-фаляһем» кагыйдәсе буенча калды.

*

«Казан» миһманханәсенең яңа хуҗасы[1] половойларны, конторщикларны кырка башлаган.

Сакаллыларның сакалларын, мыекларын, сакалсызларының кашларын, култык астларын кыркырга, йолкырга керешкән.

Ягъни аның мәгънәсе: 8 тәңкә ала торганнары хәзер — биш, биш тәңкә ала торганнары — өч, өч тәңкә ала торганнарына көч килгән.

Әгәр бу хуҗаның күз алдында бер арыслан бер чыпчыкның авызыннан корт алса, хуҗа әфәнде шуңар гаҗәпләнер иде микән, юк микән? Әллә, бу арыслан барыбер минем шикелле икән, дип карар да китәр иде микән?

Ләкин арыслан, вәхши бер хайван булса да, чыпчык авызыннан корт алып вакланмыйдыр.

Шулай шул инде! Безнең татар байлары баюны тик хезмәтче кысуда, приказчикларны ач тотуда гына дип беләләр. Юк исә эшчене кыркудан борын, миһманханә тәртипләрен яхшырак төземәк кирәк иде.

Яңа хуҗа хәзер миһманханәдәге песигә дә ашны талон берлән бирә башлады, диләр.

Нә исә, хуҗаларга Ходай инсаф бирсен. Амин.

---

*Итлакъ улыр* — әйтеләр.

*Мөхакъкакъ* — мәгълүм, ачык билгеле.

*«Илляһем-фаляһем»* — «коткаручы Аллам».

*

Мәхлукулла байның[2] килене кунакка кайтып киткән җиреннән бу көнгәчә кайтмаганлыгының сәбәбе Мәхлукулла байның киленен бик кысып тотдыгыннан икәнлеге хакында хәбәр алдык. Ләкин кешенең семейное положениесенә керешәсемез килмәгән өчен, ул хәбәрне бөтенләй басуны лязим күрмәдек. «Алла бирмәгәнне мулла бирмәс» мәкале бик тугъры сүздер.

*

«Казан» миһманханәсе, яңа хуҗа кулына төшкәч, бигрәк шакшыланып китте. Өченче көн без берничә кеше чәй эчәргә кергән идек, алдымызга җумаган нәҗес приборлар китереп куйдылар. Соңра икенчеләрне сорап алдык. Аш сорагач, дәхи шурпасыз чи көе пилмән һәм аның янына сасы керән китерделәр. Көчкә ашап чыктык.

## МӨСЕЛМАННАРНЫ НИ ӨЧЕН ОСОБЫЙ ГРУППАГА БҮЛӘЛӘР?

Үткән номерда хәбәр бирдекемез коммерческий банкының залында дүшәнбә көн икенче кәррә частный предвыборный собрание булып узды.

Бу собраниедә иң әүвәл выборщикларны төрле группага бүлү мәсьәләсе каралды. Купецлар, һөнәр ияләре (ремесленниклар), приказчиклар, кара хезмәтчеләр группасы. Бу биш группадан өчәр кешене выборщиклыкка тәгаен ителер, диделәр. Собраниедә булган мөселманнар буңа риза булмадылар. Әүвәлге собраниегә караганда руслар бик аз булды. Коләхметов җәнабләренең: «Мөселманнарны ни өчен особый группага бүләсез?» — дип соравына каршы руслардан Колотилин, торып: «Чөнки мөселманнарның юлы башка, аларның шәригать эшләрен руслар белми, шуңа күрә без аларны особый санамакчы булган идек», — дип җавап бирсә дә, мөселманнар бу эшкә, ягъни өч кенә кеше сайларга ризалык күстәрмәделәр. Юкарыда зикер ителмеш группалардан улган кешеләр һәркаюсы үзенең группасыны җыйнап, бу хосуста мәслихәтләр итешмәк өчен мәҗлесләр ясамакчы булып таралдылар.

Русларның приказчикларын Кувшинов, сәүдәгәрләрен Лукашов һәм Бляхин, интеллигентләрен Краузе, мөселманнарны гәзитәмезнең мөхәррире К.М.Төхфәтуллин җыйнамакчы булды.

---

*Кәррә* — тапкыр.
*Зикер ителмеш* — телгә алынган.

Имде мөселманнар үзләренең хосусый собраниеләрендә уйлашып, барчасы бер иттифакъка килеп, башларын кушып, үзләре теләгәнчә эш кыйлмаклары бик тиешледер. Шәһәремездә русларның күбрәге «17 нче октябрь» вә гайре шуның кеби, үзләренең хакларын гына саклый торган партиядән булганга күрә, мөселманнарга гафил булып калырга ярамаз.

Тырышырга кирәк, карендәшләр!

Уяныңыз да тартышыңыз. Тартышуда гына табарсыз сез үз хакыңызны![1]

## МӨҺИМ ЭШ — ИМАМНАР ҖӘМГЫЯТЕ

Пенза губернасы Чембар* өязе Мучали волостеның «Алты авыл» исеме илә мәшһүр (Мучали, Решетин, Телятин, Ковылкин, Кикин вә Качкару) авылларының имамнары, бер иттифакъка килеп, үзара бер җәмгыять ясамышлар. Җәмгыятьтә Оренбург духовный собраниесенең садирнәшаны улан мөфти әһле ислам әлхаҗ әл-хәрмин Мөхәммәдьяр Солтанов хәзрәтләренә гариза язып вирмәгә карар вирмешләр.

Гаризаларында ушбу кирәкле нәрсәләр язылмыш:

1 нче: без түбәндә язылачак имамнар вә мөәззиннәр гыйззәтлү мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов хәзрәтләренә гарыз идәмез шул хосуста кем: безләр, мәхәллә хезмәтчеләре булдыгымыздан, һичбер кәсеп кыйлырга вакытымыз юк һәм кәсеп кыйлырга мәхәллә халкы риза да түгел идеке үзеңезгә мәгълүмдер. Бу ел һәркемнең хәле бик начар улдыгыннан, халык тарафыннан бер залла бирелә торган сәдака вә иганәләр бөтенләй югалды. Вазифамыз да юк. Нишләргә кирәк? Хәлемез бик начарланды.

Иганә сорап, губернаторга гариза виргән идек. Кабул итмәде. Иганә крестьяннәргә генә бирелә, имамнарга бирелми, дип җавап кайтарды. Шуның өчен безләр таләп кыйламыз: ничек тә булса безләргә иганә йибәреңез.

2 нче: буйдан соңра имамнарга вазифа (жалованье) тәгаен кыйлынса иде, чөнки бу рәвештә халык өстенә ятып, анларның

---

* Чембар — чыганакта: Чамбар.

*Иттифакъка килү* — берләшү, бер сүзгә килү.

*Вә гайре* — һәм бүтән.

*Гафил булып* — белмичә, ваемсызланып.

*Садирнәшаны* — башлыгы, мөфти.

*Әлхаҗ әл-хәрмин* — хаҗда булган, хаҗи.

*Гарыз идәмез* — белдерәбез.

*Бер залла* — аз гына, теләмичә генә.

аз гына сәдакаларына күз тотып ятмакымыз бик тиешсез эштер дип беләмез. Без, ихтыярсыз, нинди фәкыйрь улса да, мәхәллә кешеләреннән алуны тәмгы кыйламыз. Шуның өчен нә вәгазенә әмре мәгъруф — берсе дә тиешле рәвештә булмый, халыкның җонын сыйпап кына торырга лязимдер. Ушбу хәлне вә иске тормышны үзгәртеп, имамнарның мәгыйшәтене тәэмин (обеспечить) итмәкеңези теләймезләр.

Имзалар:

1. Решетин карьясендә ахунд Гайнетдин хан Сүвәров.
2. Бер мәсҗед имамы Гайнетдин Мөстәгыйн угълы.
3. Телятин карьясендә имам мелла Шәрифҗан Бакиев.
4. Мелла Сәлахетдин Шәрәфетдинов. Ковылкин карьясендә мелла Хөснетдин Камачкин.
5. Кикин карьясендә мелла Габделгалләм Каниев.
6. Качкару карьясендә мелла Сәлахетдин Бикашев.
7. Мучали карьясендә мелла Мәгъсум Бикашев.
8. Мөәззин Садыйк Хансүвәров.
9. Мөәззин Минһаҗетдин Бикашев.

### ***«Фикер»:***

— Әй,бичара имамнар!

— Вай, бичара җир фәрештәләре!

Сезләрә бу рәвештә хәрәкәт әллә кайчан тиеш иде. Сез үзеңез тырышмасаңыз, сезнең өчен кем тырышачак. Сез буңа кадәр бик кыенлык илә гомер итдекеңез аңлаган кешеләрә мәгълүмдер. Сезнең кыенлык илә тордыкыңыз өчен дә милләтемез харап улды.

Бетү дәрәҗәсенә ирешге.

— Чөнки сез, жалуньягыз булмаганга күрә, милләтемезне төрле хәйләләр илә алдап, тәмам изденез; буны, инсафыңызга кайтып, инде сөйләргә тотындыңыз.

— Әле яхшы.

— Соң булса да, бөтенләй булмаудан яхшырак. Инде сезгә буйдан соңра үзеңезнең хәлеңезне дә гакылга муафикъ сурәттә күзәтеп, милләтемезне алга җибәрергә вә мәңгелек йокыдан уйгатырга тырышу кирәкдер.

— Эстәңез!

---

*Тәмгы кыйлу* — өметләнү.

*Әмре мәгъруф* — яхшылык эшләргә боеру.

*Мәгыйшәт* — тормыш, тереклек итү.

*Гакылга муафикъ* — акылга туры килерлек.

*Эстәңез!* — тырышыгыз!

— Ни эстәсәңез, шуны табарсыз! Үзеңезне вә сезгә ияргән мәхәллә халкыны төзәлтмәкнең чарасы үз кулыңыздадыр.

— Дикъкать итеңез:

Никто не даст нам избавленья —
Ни бог, ни царь и не герой,
Добьемся мы освобожденья
Своею собственной рукой...

## УРАЛЬСКИДӘ САЙЛАУЛАР

Предвыборный собраниеләр була башлады. Шинбә көн кич Общество трезвости чәйханәсендә приказчиклар җыелышы булды. Бу җыелышның председателе Шишсоватов приказчиклар особый группага бүлену мәсьәләсене чыкарды. Колотилиннар, Дмитриевләр аерылуны мәслихәт күрделәр. Җыелышта мөселманнар бик аз иде, рус халкы бик күп җыйналган иде. Думага барырга хәзер торучы үзе дә арттан гына карап, мәҗлесне сынап торды. Аның хосусында сүз сөйләүче вә аны илтифатка алучы булмады. Юкарыда зикер ителмеш кешеләр — «күп белүчеләр» үзләренең сүзләрен тәмам итдектән соңра, гәзитәмезнең мөхәррире[1], торып, ушбуны сөйләде:

— Граждане!

Аерылу һәрвакыт начарлыкка илтәдер.

Аерылмаңыз!

Хәзер сезгә үзеңезгә файдалы кешеләрне выборщик сайларга кирәк. Әгәр сезнең фикереңезгә байлар вә интеллигентлар каршы килмәсә, аларны да кабул кыйлыгыз.

Хөррият, ирек — барча кешеләргәдер; бай, фәкыйрь, галим, җаһил, ир вә хатын һәм милләт аерылмаенча, һәркемгә бертигездер.

Буңа каршы Дмитриев, торып:

— Без байлар илә кушылмыймыз, йитәр инде анларны ялавымыз, — диде.

Камил Мотыйгый:

— Бән байлар илә аларны байлыклары, капиталист булдыклары өчен кушылыгыз, димәдем. Юк!

Әгәр фикерләре муафикъ булып, сез теләгән кешеләрне алар да теләсәләр, шул вакыт кушылыгыз, дидем.

— Долой провокаторов!

— Долой вредных людей для народа!

— Граждане, төшенеңез, бән ни әйтәм!

---

*Общество трезвости* — эчкечелеккә каршы җәмгыять.
*Зикер ителмеш* — телгә алынган.
*Җаһил* — надан.

Бу сүзгә җәмәгать, бик разый улып, бик озак кул чаптылар. Җыелышта Дмитриев вә Колотилиннарның дәрәҗәләре вә кем идекләре мәгълүм улды.

Соңра җыелыш, үзләренең араларыннан сайлау эшләрен карап йөрмәк өчен, комиссия ясауны мәслихәт күреп, бер унлап кеше тәгаен итеп, җыелыш тәмам булды.

Икенче көн — 10 декабрь якшәнбә көне — Пушкинский домда көндез сәгать бердә рабочийлар җыелышы булды. Бу җыелышта халык дәхи дә күбрәк булды, мөселманнар да әүвәлге җыелышка караганда бер-ике кеше артык иде. Пушкинский дом бөтенләй тулды. Артта Краузе кеби күзлекле кешеләр дә карап торалар иде. Халык җыелышка председатель сайларга тотындылар. Бәгъзеләр, Краузене сайлыйк, дигән иде, бөтен җәмәгать «Не надо!» дип кычкырып һәм сызгырдылар. Соңра Гутманны мәслихәт күргәннәр иде. Ул җыелышның башында була алмады. Соңра килеп, кичегеп калды. Кеше табылмагач, җәмәгать, чар-начар, Колотилинны сайладылар. Ул, председатель булгач, бик озак төшендерергә азапланып, үзенең фикерене җәмәгатькә бәян итәргә тотынды. Ләкин халык бер дә төшенмәде. Бик күп төрле болгатулар вә халыкны ялңыз сүз илә исертүләр булганны күреп, Камил Мотыйгый, халык эченнән торып, урындыклар өстенә басып, ушбу яндыргыч сүзләрне каты тавыш вә чын ихлас илә диде:

— Граждане!

Уйлагыз!

Хәзерге вакыт сезнең өчен бик газиз вакыттыр.

Сез үзеңезнең хәлеңезне төзәтергә теләсәңез, хәзер сезгә тырыша торган вакыт тәмам йитте.

Шуның өчен сезгә, иң әүвәл, үзеңезгә лаек вә сезнең хәлеңезне белеп, сезне кызганырдай кешене депутатлыкка сайламак тиеш. Сез хәлеңезне төзәтергә тырышмасаңыз, башка кеше сезнең өчен тырышмас.

Сезгә котылуны һичкем бирмәс —
Нә Алла вә нә падишаһ, вә нә баһадир;
Сез котылмакга йитәрсез
Үзеңезнең кулларыңыз илә...[2]
Сезгә көрәшү лязим!
Көрәшү!
Сакланыңыз хәйләкәр адәмнәрдән!

Шул сүзләрене бетерер-бетермәс, җәмәгать «браво!» тавышлары илә җир селкетеп кул чабарга тотындылар. Камил Мотыйгый да, шуннан артык сөйләргә вә җыелышта тормак-

---

*Чар-начар* — ихтыярсыз, теләр-теләмәс.

ны хаҗәт күрмәйүб, бәгъзе иптәшләрене алып чыгып китте. Аның артыннан барча җәмәгать чыгып таралдылар. Руслардан берничә кеше Камил Мотыйгыйның артыннан «Уральский дневник» редакциясенә барып, халык исеменнән тәшәккерләр иттеләр. Бу кешеләр: «Без кара халык бит, берәүне дә танымыйбыз, сез төшендермәсәңез, бәлки, әллә нинди ауларга төшкән булыр идек. Рәхмәт сезләргә, мондан соңра булачак мәҗлесләремезгә килмәкеңези риҗаэ итәмез», — диделәр.

3 нче мәҗлес. Шул ук көндә кич сәгать алтыда «Казан» миһманханәсендә мөселманнар җәмгыяте булды. Председательлеккә Госман әфәнде Коләхметов җәнабләрене сайладылар. Вакытның бик кыйммәтле вакыт идеке, тик торырга инде бер дә ярамаганлыгы вә уйлашырга кирәк идеке, вә бу ел Думага мөселманнанмы яки рустанмы сайлау лязим идеке хакында төрле сүзләр булганнан соңра, җыелышны ясаучы Камил Мотыйгый, бу эшләрне халык илә мөшавәрә кыйлышып, артыннан йөрергә комиссия ясарга вә шул комиссиягә хәзер ышанычлы, булдырырлык кешеләрне тәгаен итмәкне мәгъкуль күрде. Җәмәгать, буңа разый булып, ушбу кешеләрне тәгаен иттеләр: Госман Коләхметов, Шәрәфетдин Каниев, Гомәр хәлфә Хөсәенев, Камил Төхфәтуллин, Мөхәммәтгали Мусин, Хәкимҗан Сөләйманов, Салих Сабитов, Бәдреттин Миңлебаев, Мисбахетдин Хәмидев, Мортаза Гобәйдуллин, Зиннәтулла Мөхәммәтҗанов, Сөләйман Мәсгудев, Камалетдин Кантиев, Габдулла Төхфәтуллин, Җәләлетдин Нәзирев, Фатих Шәрипов. Барчасы уналты кеше.

Бу кешеләр һәр җәмгыятьләргә йөреп, сайлау эшләрендә бик иҗтиһад итеп йөрергә муеннарына алдылар. Булар, үзара җыелышып мәслихәтләр итешер өчен, җомга көн кичке сәгать алтыда җыелырга карар бирделәр.

Шуның илә җыелыш, бик тәртипле сурәттә узып, тәмам булды. Җыелышта шәһәрнең бәгъзе хәзрәтләре, мөәззиннәре, байлары, хәлфә вә шәкертләре, вә башка һөнәр ияләре, вә эшче халык бик күп булды. Мәхкәмә тарафыннан бер чиновник вә бер палисәйски җибәрелмеш иде. Инде киләчәк җыелышларда да мөселманнар гайрәт вә һиммәт күстәреп, файдалы эш чыкарырга насыйп вә мөяссәр булсын.

---

*Тәшәккер итү* — рәхмәт әйтү.
*Риҗаэ итәмез* — үтенәбез.
*Миһманханә* — кунакханә.
*Лязем идеке* — кирәклеге.
*Мөшавәрә* — киңәш.
*Мәхкәмә* — монда: шәһәр идарәсе.
*Һиммәт* — тырышлык.
*Мөяссәр булсын* — язсын, насыйп итсен.

# ҖӘМГЫЯТЕ ХӘЙРИЯ

Адәмнәр диңгезенең тормыш дулкыннары арасында бер йомычка төсле, җил кайда иссә, шунда таба селкенеп йөргән кешеләрнең һәммәсе дә йомшак кына вә сөйкемле генә бер бәхет җиле илә бер сәламәтлек җәзирәсенә чыгулары мөмкин түгелдер.

Бик күп кешеләр шул мохтаҗлык, фәкыйрьлек дулкыннары арасында күмелеп, һич төпсез-нисез тирән диңгез астына төшеп киткән яки, диңгездә агып йөргәндә, җарлары гаять тә текә вә биек һәм шома булган бер коры җиргә очрап, шул җардан менәм дип тырмашып, тырнаклары каерылып бетеп, актыкта ике дошман арасында аптырап калып изелгәндер.

Заманымызның мәдәният вә образованиесе тудырган мохтаҗлык туфаны арасында һичбер кешенең ялгыз башына гомер итүе мөмкин булмыйдыр.

Һәр мохтаҗлыкка каршы — тырышу вә эш эшләү; күкрәген киереп кенә рәхәт вә тыныч, азат торып булмыйдыр.

Аңсыздан йә бер авыру, яки башка бер бәла-каза ирешеп, адәмнең хәятын әллә ничәгә бөгә вә сындырадыр.

Һич кеше һичбер кешенең ярдәм соравына колак салмыйдыр; гүя кыямәт көнендәге кеби, һәр кеше үз нәфсе илән генә мәшгульдер.

Һәркемнән бернәрсә сорасаң: «Ул минем үземә кирәк, сине кызгансам, үзем кызганычка калам», — дип җавап аласың.

Фәкыйрьлек, мохтаҗлык бик авыр. Аны җиңеләйтүче юк. Вакыйган, мәдәният мәркәзләре һәммәсе үзенә бертөрле шатлык илә шат, бертөрле күңеллелек илә күңелләнеп торадыр.

Мәдәнияттә торучыларның бер кыйсьме мәдәниятлек ләтафәте вә матурлыгы илә кәефләнеп торадыр, ләкин бер кыйсьме мәдәниятнең зәһәре илә агулангандыр. Менә шул сәфаләт зәһәренең актык тамчысына кадәр эчеп, фикрән вә бәдәнән авыру вә хәстә булган бер кеше шәфкатьле вә хәер хаһ бер кулның үзен сөюенә вә башыннан мәрхәмәт илә сыйпавына мөзаһһәр булмаса, билгеле инде, ул кешенең китә торган җире мискинлек вә хурлык зинданы яки юклык вә бетмәк мәзарыдыр.

---

*Җәзирә* — утрау, җир кисәге.
*Ләтафәт* — нәфислек.
*Сәфаләт* — түбәнлек.
*Фикрән вә бәдәнән* — уй-фикер һәм тән ягыннан.
*Мөзаһһәр булмаса* —ирешмәсә.
*Мәзар* — каберлек.

Бер дә шиксез, бу бичараларның бәхетсез хәлләреннән ушбу күз алдымыздагы һәйьәте бәшәрия, ягъни инсаннар җыены тоткын ителәдер.

Бу күз яшьләренә, бу гөнаһсыз адәмнәрнең хурлыклы хәлләренең барчасына шул һәйьәте иҗтимагыяләрнең һиммәтсезлеге вә инсаниятсезлеге* сәбәптер.

Мөтәрәккъый милләтләр бу мәсьүлиятне, бу тоткынлыкны күптән сизгәннәр. Алар, һич булмаса, үз милләттәшләренең аянычлы хәлләрен бөтенләй бетерү булмаса да, бераз җиңеләйтү өчен, җәмгыяте хәйрияләр ясап, милләт эчендәге байларның лотеф вә гыйнаятьләренә махсус бер хөрмәтле акча сандыгы хәзерләгәннәрдер.

Инсаният хисләренең иң киң мәгънәсе илә сахәи хәергә чыккан бу җәмгыяте хәйрияләр шул җәмгыяте хәйрияне ясаган милләтнең өмид кәгъбәләредер.

Хурлык, фәкыйрьлек тавышы шунда барып туктар, ярдәм сорау фөрьядлары шул урында кабул ителер.

Авыру түшәгеннән яңа гына баш күтәргән, ләкин мәгыйшәт дәрте берлән күңеле тырналган бер балалар атасына эш табып бирмәк яки эш тапканчы аның мохтаҗлыгыны үтәп тормак һиммәтле кешеләр өчен тәгърифе мөмкин түгел бер рухани рәхәт вә ләззәттер.

Ул нинди гали күңелләрдер ки, бу мәгънәви зәвекъ вә ләззәтне сизеп, үзләренең тырышып тапкан байлыкларыннан бер ярдәм өлеше аерып чыгаралар. Бу затлар нинди гали затлардыр ки, милләтләрнең шөкер вә сәнасыннан ясалган бер хөрмәтле көрсигә утырып торалар.

Менә инсан дип, шул рәвешчә үзенең тырышып тапкан яки бәхетле бер очрау (тәсадеф) аркасында тапкан бер байлыгыннан үзенең милләтенең фөкара вә әйтамә сыйнфына да өлеш чыгарган кешеләргә әйтәләр.

---

* Социаль төркемнәрнең тырышмавы, кайгыртмавы һәм кешелексезлеге.
*Һәйьәте бәшәрия* — кешелек коллективы.
*Мөтәрәккъый* — культуралы.
*Мәсьүлият* — җаваплылык.
*Лотеф вә гыйнаятьләр* — мәрхәмәт һәм ярдәмнәр.
*Сахәи хәер* — изгелек мәйданы.
*Өмид кәгъбәләре* — өмете юнәлә торган нокталары.
*Фөрьяд* — ачынулы аваз.
*Мәгыйшәт* — тормыш, яшәү, тереклек.
*Тәгъриф* — сөйләп аңлату.
*Шөкер вә сәна* — шатлану һәм мактау.
*Көрси* — урындык.
*Фөкара вә әйтамә* — фәкыйрьләр һәм ятимнәр.

Безнең татар халкы моңар кадәр дә бөтенләй сәдакасыз-нисез тормадылар, муллаларга, мөәззиннәргә, шәкертләргә, мәдрәсәләргә, ишаннарга, Мәдинә габдессаттарларына* вә гайре урыннарга бер дә кызганмыйча сәдакалар сачтылар. Алар мәсҗед алдындагы теләнчеләрне дә күздән ташламадылар. Әлхасыйль, кулында хәерче капчыгы яки маңлаенда теләнчелек вывескасы, ягъни чалмасы булган һәр кешегә тиешле-тиешсез акча тараттылар.

Татарлар Коръәннең «Тәсаддык» аятеннән баш тарталар дип әйтер хәл юк. Әлхәмделилләһи, баш тартмыйлар, ләкин үзләренең гаять наданлыкларыннан, хөрмәтле сәдакаларыннан күп-күп ялганчыларга өлеш чыгаралар иде.

Шуның өчен аларга, һәр милләттә булдыгы кеби, сәдакаларны бер җиргә җыеп, җәмгыяте хәйрия ясау лөзүме күптән хис ителмәктә иде. Һәр кеше аерым-аерым үзенең милләттәшләренә ярдәм итә иде һәм моны сөя-сөя эшли иде.

Ләкин шул һәр кешенең биргән акчаларын бер тәртип астына алып, бер җиргә җыеп, тагы да файдалырак рәвештә сарыф ителү күзгә алынмый иде.

Шөкер, мең шөкер булсын ки, мөселманлыкның өстенә салынган бу рәтсезлек, бу беспорядканы моннан соңра тәхәммел итәргә түземнәре калмаган берничә гайрәтле интеллигентлар вә сәүдәгәрләр чыгып, «Уральск мөселманнары җәмгыяте хәйриясе» исеме илә бер хәйрат сандыгы ясадылар.

Моның шикелле хәерле вә киләчәгемез өчен өмидле бер изге эш һәрбер үзен мөселманмын дип йөргән татарны мыек астыннан гына бер куаныч илә көлдергәне шикелле, таланган, ертылган киемле, саргайган йөзле бичара бер теләнченең: «Абзый, бер генә тиен бир инде! Әрвахлар хакы өчен», — дип кычкырган кызганычлы тавышы да вөҗданлы, йомшак күңелле бер мөселманның күңелен җәрәхәтләми калдыруы мөмкин түгелдер.

Менә шул җан кискеч, аянычлы тавышларны моннан соң мөселманнар арасыннан югалтыр өчен, бер шәфкатьле ана шикелле, мәйданга чыгып, җәмгыяте хәйрия ясаган кардәшләремезне әүвәлән инсаният яки, хаслап әйткәндә, миллият намена тәбрик итәмез.

Шул кешеләр шикелле һиммәтле затларның меңнәр яшәвен теләгәнемез кеби, җәмгыяте хәйрия төсле мөкаддәс бер

---

* Хаҗга баргач, Согуд Гарәбстанындагы Мәдинә шәһәре хәерчеләренә сәдака өләшү мәгънәсендә.

*Әлхасыйль* — кыскасы.

*«Тәсаддык» аятеннән* — сәдака бирергә өндәгән аятьтән.

*Лөзүме* — кирәклеге.

*Тәхәммел итү* — күтәреп йөрү.

*Хәйрат сандыгы* — ярдәм сандыгы (кассасы).

эшкә каршы торучы монафикъларның кадалуын яки тәүфикъка килүләрен телимез.

Әгәр җәмгыяте хәйрия, безнең дуст вә дошманнарымыз арасында теләнеп йөреп, дошманнарымызны куандырган вә дустларымызның күз яшьләрен чыгарткан теләнчеләрнең бетүе өчен чынлап тырышса, мөселманнарның йөзенә сөйләп-язып бетерә алмаслык бер аклык китергән буладыр.

Җәмгыяте хәйрия, Алланың гыйнаяте илә капчыклы теләнчеләрне бетергән шикелле, мәдрәсә вә дарелфөнүн исемен пычратып, ала каргалар төсле үләксә артыннан йөгерүче, бер бай мәсҗедтә колак какса да: «Мине ашка чакыра, ахрысы: кулын югары күтәрде», — дип, җыгыла-сөртенә йөгергән чалмалы теләнчеләрне — шәкертләрне дә бетерсә, татарлык исемемезгә ягылган караны тәмамән кырып, юып ташлаган буладыр.

Тота белүчеләр булса, милләтнең акчасы мәктәп вә мәдрәсәләргә дә, шәкертләргә дә, гәзитәләргә дә — һәммәсенә йитәчәктер. Милләт акчасы ялгыз милләт файдасы өчендер.

Милләт акчасының ханәкаһ конюшнясендәге ялкау сыерларның авызына гына агып торуы дәвам итсә, без бетәчәкбез. Әгәр милләт акчасы илә шул ук милләтнең кирәкләрен карасак, бик тиз алга да китәчәкбез.

Бинаән галәйһи һәрничек җәмгыяте хәйриянең сумасын күбәйтергә, мондин соңра сәдакаларның урынсыз җирләргә акмавына һиммәт итәргә кирәк.

## ТЕАТРУНЫҢ ФАЙДАСЫН ХАЛЫККА НИЧЕК ТӨШЕНДЕРӘМЕЗ ҺӘМ ХӘЗРӘТЛӘРДӘН НИЧЕК ДӨРЕСТЛӘТӘМЕЗ?

«Казан» миһманханәсендә яхшы гына, тугъры гына фикерле бер әфәнде илә үзара мосахәбә кыйлып утырганда, җәнабләреннән түбәндә язылачак тугъры сүзләрне ишеттем:

Әүвәлән, без халыкны һәм «җәмгыяте хәйрия»нең членнәрен «җәмгыяте хәйрия» акчасына театру ясарга һичбер рәвешчә күндерә алмаганымыз шикелле, аларга театруның безнең киләчәк көннәремез өчен файдалы вә өмидле бернәрсә икәнен дә сөйләп аңлата алмыймыз.

---

*Монафикъ* — икейөзле кеше.
*Дарелфөнүн* — югары уку йорты.
*Ханәкаһ* — ишан булмәсе, шулай ук суфи-дәрвишләр тора торган урын.
*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.
*Мосахәбә кыйлып* — сөйләшеп.
*Җәмгыяте хәйрия* — ярдәм җәмгыяте.

Икенче, без мондагы тарилкә ялаучы хәзрәтләрдән театру ясауның дөрестлегенә һичбер төрле фәтва ала алмыймыз.

Шуның өчен безгә иң яхшы тәдбир будыр ки, әүвәлән, театру хәрам дип кычкырып йөрүче хәзрәтләрнең иң башлыгын «Казан» миһманханәсенә варенье, катлит, пәрәмәч, силәнкә, пылау кеби ашлар илә чуарланган чәйгә чакырып, ул хәзрәткә бер кызыл кәгазьне[1] һәйбәтләп яудырырга кирәк. Шул чәй янында хәзрәтемез Коръән дә укып җибәрсен. Шундин соң карагыз да торыгыз, теге хәзрәтемез, «эһем, эһем» дип кырынгалап, як-якка карангалар да акчаны сәгать кесәсенә җомарлап салыр.

Тәмам акча хәзрәтнең кесәсенә кереп яткач кына, бу мәҗлестән максуд хәзрәттән театруны хәлальләндермәк икәнлеген сөйләргә кирәк.

Шундин соң, мин әйтте диерсез, хәзрәт «хәрам» дигән сүзнең «х» хәрефен генә калдырып, «ра», «әлиф», «м» урынына «лаль» дигән сүзне утыртып куяр.

Күп хәкимнәрнең тәҗрибәсе берлән сабиттер ки, безнең муллалар, кызыл кәгазь шәрифкә каршы барганчы, үлмәкне артык күрәләр.

Менә инде ун тәңкәгә алган бик свежий бер хәлалемез дә булды, димәк ки, театру бөтенләй хәлальләнде.

Сүз рәте теге «җәмгыяте хәйрия» членнәренә килсә:

Әүвәл кайдан да булса акча җыйнаштырып, театру уйнап, членнәрне бесплатный билет берлә кертәсең дә, пәрдә төшкәч, саф йөз тәңкә файда күрсәтәсең.

«Җәмгыяте хәйрия»нең членнәренең театрудан өркүләре «җәмгыяте хәйрия» акчасын кызганып кына икәнлеге билгеледер.

Әгәр һәр театру уйнаган саен, ул абзыйларга йөзәр тәңкә файда күрсәтсәң, аларның дүрт куллап театруны кабул итәчәкләре хосусында, пәйгамбәрлек итеп, гаибтән хәбәр бирергә дә мөмкиндер.

Бәс, бу тәдбир берлән театру уйнарга һичбер манигъ-фәлән калмады.

Мин үз тарафымнан бу фикернең тугърылыгына кул куямын, тик кызыл кәгазь кайсы хәзрәт бәхетенә чыгар икән? Әллә фәтва берлә сәүдә итүчеләр шул акчаны үзара бүлешерләр микән?

---

*Фәтва алу* — карар чыгарту, рәсмиләштерү.
*Тәдбир* — чара.
*Хәлальләндермәк* — дөрес дип әйттерү.
*Сабиттер* — беркетелгән.
*Гаибтән* — күз алдында булмаган нәрсәдән, киләчәктән.
*Манигъ* — тоткарлык.

#ҺӘРКИМИҢ КӘНДИНЧӘ ВАРДЫР ЛЯ МӨХАЛЬ ӘНДИШӘСИ*

«Борһане тәрәкъкый» гәзитәсенең[1] 52 нче номерында «Надан шәкерт» имзалы бер кеше «Борһане тәрәкъкый»дән башка һәммә татар гәзитәләрен кагып килә дә шул арада «Фикер»нең сәяси баш мәкалә язмагыннан зарлана.

Дөрест шул, «Фикер» гәзитәсе көн саен, сәгать саен мәсләк алыштыра торган яки, «Таң» гәзитәсенең баш мәкаләләрен күчереп, башын — аякка, аягын башка әйләндереп язуга гына әһәмият биргән гәзитә түгелдер.

«Фикер» гәзитәсе, милләтемезнең ирләрен вә хатыннарын әүвәләң укытмыйча, белдермичә, аларга җен шәһәре төсле мәҗһүл булган революция фикерен толковать итмидер.

«Фикер» гәзитәсе социализмның мөкәддәс икәнен беләдер. Белсә дә, заман икътизасынча гына хәрәкәт итәдер.

Инсан тар гына бер кисмәк эчендә вакытында тыштагы кеби йөгерү-сикерүләргә кодрәте килмәгәне шикелле, моның кеби тар бер заманда да иҗраэсе намөмкин булган эшләрне фәкать хыялламактан башкага хәле килмидер, безнең мәкянга ихтыяҗымыз заманга ихтыяҗымыз илә бер дәрәҗәдә икәне мәгълүмдер.

Әүвәл милләт укысын, белсен, француз, нимсәләр кадәр күзе ачылсын. Шундин соң Карл Маркс мәзһәбенә яки ортодокс мәзһәбенә керергәме — анысын үзе белер.

«Фикер» гәзитәсе: укыйк, ди, белик, ди, мәктәпләр салыйк, ди, ир вә хатын мөсави булсын, ди, социализмны чынлап аңларга әүвәлән мәктәп вә мәдрәсәләр кирәк, ди.

Социализм никадәр мөкаддәс булса да, уку вә укытудан алда түгел, ди. Һәм халыкка аңлатуы җиңел булган вә үзе дә заманга муафикъ булган җәмгыяте хәйрияләр ачыйк, ди; мөтәмәддин милләтләр әүвәлән укып тәрәкъкый итеп, андин соң гына шул һәр тәрәкъкыйнең мөнтәһасе булган социализмны мәйданга чыгарырга тырышалар.

---

* Һәркемнең, һичшиксез, үзенчә фикере, төшенчәсе бар.

*Борһане тәрәкъкый* — үсеш, алга китеш билгеләре.

*Мәҗһүл* — билгесез, таныш түгел.

*Заман икътизасы* — заманның кушуы.

*Иҗраэсе намөмкин булган* — тормышка ашырылуы мөмкин булмаган.

*Мәкян* — урын, җир, дәрәҗә.

*Нимсә* — немец.

*Мәзһәб* — юл, юнәлеш.

*Мөсави* — ир белән тигез.

*Мөтәмәддин* — мәдәниятле, культуралы.

*Мөнтәһа* — ахыр чиге.

Тукта әле, без дә алар юлыннан барыйк, Хуҗа Насретдин шикелле, атның артына карап атланмыйк. Халыкның, укый торгач, үткенләнә торгач, шул социализм фикеренә барып төшмичә хәлләре юктыр. Социализм кеби бер мөкаддәс мәзһәбкә кергәндә, матурланып, кеше булып, галим вә мәгърифәтле булып керик.

Без надан көенчә социалист булып мәйданга чыксак, койрыгына тутый кош җоннары кыстырган ала карга төсле, бөтен дөньяны көлдерербез. Без «таң»чыларның, шул мәсләккә кереп, татарларга: менә дөньяда шундый мәзһәб тә бар дигәннәренә рәхмәт укыймыз һәм үз юлларында сабитлекләре өчен ябылуларын вә куылуларын тәкъдир итәбез.

Ләкин һәммә мөхәррирләремезнең шулар сүзен сөйләп, ябылып, асылып бетүен яратмыйбыз. Ул чакта милләтемез бөтенләй ятим кала, димез, сәфил кала, хур була, димез.

Бездә мөхәррирләр тәмле хыялларга корбан булырга түгел, кирәк эшләремезгә дә аздыр.

Әгәр безнең мәктәпләр вә мәдрәсәләремез хәзер булмыйча, кыйбатлы мөхәррирләремез һәлак булып бетсәләр, дөньяда тик корчаңгы мөхәррирләр генә калачактыр.

Зинһар, дип әйтәм, әүвәл, һәртөрле тәдбир берлән, мәдрәсәләр ачып яки балаларымызны төркем-төркем башка милләтләр мәдрәсәсенә йибәреп укытыйк. Аннан каләм иясе булып чыгучыларымыз күбәйсен, солдатның өстенә дә шинель, астына да шинель, баш астына да шинель дигән шикелле, алай тартсак та, шул бер-ике мөхәррир, болай сузсак та, бер-ике язучыбыз гына булмасын.

Мөхәррирләр гаскәрләр кебидер: сугышка чykканда, запас гаскәребез булмаса, әсир булырмыз, хур булырмыз.

Сәрләүхә урынына язылган «Һәркимиң кәндинчә вардыр ля мөхаль әндишәси» мәкале буенча, «фикер»челәрнең дә үзләренең күз тотып чыккан бер мәсләкләре бардыр.

«Фикер» фикерендә вә мәсләгендә хөрдер. «Надан шәкерт» вә галим шәкертнең һичбер тәнкыйтьләренә мохтаҗ дәгелдер.

Законнар вә шәригатьләр заманына күрә үзгәргән шикелле, «Фикер» дә беркөнне юлын үзгәртер: «Надан шәкерт» теләгәнчә булыр. Ләм ля йәҗүз? Әмма хәзергә «Фикер», мә-

---

*Сабитлек* — нык тору.
*Сәфил* — түбән.
*Тәдбир* — чара.
*Сәрләүхә* — исем (мәкаләнең исеме).
*Лям лә йәҗүз* — рөхсәт ителерме, дөрес булырмы.

гаттәәсеф, «Надан шәкерт» тешләгәнчә булмамакта мәгъзүрдер зан идәрем, гафу боеру илә. Бу сүзләрдән «Фикер»нең үткән нумирларында, сәяси мәкаләләр булмаган вә киләчәктә дә булмас дип, әлбәттә, уйланмас. «Фикер»нең моңарча чыккан нумирларын дикъкать берлә укыган кешеләр бөтенләй сәясәттән буш дип әйтә алмаслар дип уйлыйм. «Фикер»дә правительствога каршы ачы-ачы сүзләр булган шикелле, бик залим мөтәгассыйб татарларның да күзләрен бәйләп, ике якларына икешәр ялангач кылычлы җәллад куеп иман яңарттырылды.

Ни булса да булсын, Уральск мөхәрриренең халыкка иткән хезмәтен «Надан шәкерт» мактаган мөхәррирнең итә алуын мин һәр гакылның гакылына бәгыйд күрәм.

«Надан шәкерт»нең баш мәкалә урынына язылган «Гәзитләрнең хәле вә халык» мәкаләсе бик артык сәяси мәкалә микәнни? Ә?

«Таң»чыларның баш мөхәррире Гаяз әфәнде шагыйрьдер. Шагыйрьләрнең «мин ни өчен балык түгел икән, йөзәр идем», мин ни өчен «козгын түгел икән, очар идем» дип шагыйранә әйткән сүзенә карап, «Надан шәкерт» әфәнде җилкәсенә мунча себеркеләре бәйләп очарга башлаган икән. Көш! Көш! Көш!

Һәр нә исә, инсан үзенчә мөкаддәс дип таныган юлыннан язмаска тиеш. Бинаән галәйһи, «Надан шәкерт» «фикер»челәрне галим шәкерт булгач та сүгәргә ашыкмасын. Шул хәлдә «фикер»челәр аны һич рәнҗетмәсләр. Бу да хакыйкатьтер.

---

*Мәгаттәәсеф* — кызганычка каршы.
*Мәгъзүр* — берәр сәбәп белән бер эшне эшли алмаучы.
*Зан* — ачык булмаган уй.
*Мөтәгассыйб* — берәр эшкә нык бирелгән кеше, патриот.
*Бәгыйд* — ерак.

# 1907

## ТӨШ КҮРДЕМ

Төшемдә гүя ... гостиницасында имешмен. Күз алдымда бер стенной календарь тора. Карадым. Карасам, кызыл рәкымнәр илә декабрьнең 31 нче көне дип язылган.

Кич, имеш, шул гостиницаның һәрвакытта җәмгыять ясала торган бүлмәсендә кандилләр ягылган. Җәмгыяте хәйрия мәҗлесе өчен өстәлләр вә урындыклар хәзерләнгән. Җәмгыяте хәйрия мәҗлесе булачак, имеш.

Бу хәзерлекләрне күргәч, мин күземне һаман ишеккә генә терәп тордым. Менә җәмгыяте хәйриянең секретаре, менә хәзинәчесе, менә зур әгъзалары керәләр дип, йөрәгем леп-леп итеп сикереп тора иде, имеш.

Шулай бик интизар берлә көтә торгач, берничә минуттан соң максудым хасил булды.

Әлхәмделилләһ, ишектән җәмгыяте хәйриянең секретарь вә хәзинәчесе вә болардан башка зур кешеләре аллы-артлы килеп керделәр, имеш.

Шундин соң биш-ун минут үтмәде, ни күзем берлә күрим һәм ничек дип языйм: халык арасында, колаклары чабата чаклы булыр, бик зур бер ишәк[1] килеп керде, имеш. Мин, кешеләр арасында ишәкнең өйгә керүен беренче мәртәбә күргәнгә, бөтенләй гаҗәпләндем, төсем югалды, куркып киттем, имеш.

Курыксам да, бераз ис җыйгач: бу арада Бохара әмире сәяхәттә йөри бит, шул әмир бер сәбәп илә безнең шәһәргә килгәндер дә, тышта кырык градус суык булгач, әмирнең юлдашы булган кадерле ишәкне салкында калдыруны лаек күрмичә, бу гостиницага җылытырга кerткәннәрдер, дип уйладым, имеш.

Бу бик кызыклы төш инде. Ләкин тагы да гаҗәбрәк җире бар: теге минем җылынырга кергән ишәгем бик кызык кына итеп, кәмиттә өйрәткән ат шикелле чүмәшеп, бер урындыкка утырды, имеш; утыргач, бу ишәк бакыра башлады, имеш. Бакырган саен, колагы үсә бара, имеш. Берзаман моның колагы эченнән дөбер-дөбер бер тавыш килә башлады, имеш.

---

*Рәкым* — цифр.
*Интизар* — зарыгып көтү.
*Максудым хасил булды* — максатыма ирештем.

Мин бу колак эчендә нинди тавыш бар икән дип уйлап торганда, шул колак эченнән әллә нинди сары бишмәтле итчеләр, кырган мыеклы мөритләр, кәвешче-читекчеләр коела башлады, имеш. Бу кешеләр колак эченнән чыккач та: «Шәригать! Шәригать!» — дип кычкыралар, имеш.

Сары бишмәтле итче, кулына пычак алып, бер куй суя башлады, имеш. Ул, шуны суйганда: «Мин шәригать суям», — дип кычкыра, имеш. Кәвешчеләр, колактан чыкканда, кулларына чүкечләр тотып, кәвеш тегә-тегә чыгалар, имеш.

Алар да: «Без шәригать тегәбез», — дип кычкыралар, имеш. Бер мөрит тә, шул оядан чыкканда, мыегын кыра-кыра чыга, имеш. Ул һәм шулай мыегын, бритвасын «шәригать!» дип кычкыра, имеш. Һәм шуңгар халыкны ышандырмакчы була, имеш.

Шул колакны да колак иясе ишәк дин чишмәсе дип дәгъва итә, имеш. Ул ишәк кешечә сөйләшә, имеш. Колактан берзаман бер аксак каешчы төште, имеш. Ул да үзенең каешларын «диянәт» ди, имеш. Колактан кешеләр агуы һаман туктамый, имеш. Бераздан ике хәлфә төште, имеш. Алар да үзләренең наданлыкларын «диннән» дип кычкырышалар, имеш.

Озакламый шул колактан коелган адәмнәр, тавыш биреп, сихерле колак сахибе ишәкне садыре мәҗлес интихаб иттеләр, имеш. Бу ишәк садыре мәҗлес булгач та, муенына колокол тагылды, имеш. Ишәк үзенең ләззәтле тавышы берлә кычкыра, имеш, колоколын шалтырата, имеш, бии, имеш. Колагын күзенә тартып китереп, ниһаятьсез озын колак яфракларыннан карап, театруның хәрамлыгына фәтва бирә, имеш. Каешчы — үзенең эшлияләреннән, итче — сары бишмәтеннән, мөрид мыегыннан карап, кәвешче кәвеш эченнән кулын тыгып актарып-актарып фәтвалар чыгаралар, имеш. «Театру мотлакан хәрам», — диләр, имеш.

Теге ике хәлфәләрнең бере үзенең галиманә, җаһиланә, мөтәгассыйбанә, гарифанә чыгарган «Төлке теле»[2] исемле китабыннан фәтва эзли, имеш. Счет суга, имеш.

---

*Сахиб* — ия.

*Садыре мәҗлес интихаб иттеләр* — җыелыш председателе итеп сайладылар.

*Ниһаятьсез* — чиксез.

*Фәтва бирү* — бер эшнең дөреслеге (яки дөрес түгеллеге) турында дин исеменнән өзеп әйтү.

*Мотлакан хәрам* — һич тә ярамый.

*Галиманә* — белгечләрчә.

*Җаһиланә, мөтәгассыйбанә* — наданнарча, фанатикларча.

*Гарифанә* — белгән булып.

Шуннан берничә минуттан соң теге колактан коелучылар төрле-төрле сурәтләргә керә башладылар, имеш: кайсы — эт башлы, сыер аяклы; кайсы — аю сурәтле, кәҗә сакаллы; кайсы — ярты торна, ярты мәче, имеш. Пушкин китабындагыча: кайсы рак булган, имеш. Үрмәкүчкә атланып чаба, имеш. Тагы бер төрлесенең башы әтәч, гәүдәсе эт, имеш. Теге хәлфәләр җил тегермәне булдылар, имеш, канатларын селти-селти тансавайт итәләр, имеш. Берсе төя башлы, бурсык аяклы, имеш.

Берзаман болар кычкырыша башладылар, имеш. Бу кычкырыштан эт тавышы, мәче мырылдавы, сызгыру, торна авазы, бүре улавы, сыер мөңрәве, кеше тавышы, тамак кыруы, тегермән канатының ыжылдавы, шакылдаулар — әллә ниләр, әллә ниләр ишетелә, имеш. Тавышны иң әүвәл садыре мәҗлес ишәк үкереп башлап җибәрә, имеш. Һәммә хәшәрәтләр шуңгар ияләр, имеш. Ул ишәккә ишәк дип әйтергә ярамый, имеш. Шунда тамаша кыйлып торучы бер гайрәтле кеше: «Долой бу ишәкне моннан!» — дип кычкырды, имеш. Аны теге букәйләр кыйный башладылар, имеш. Ул гайрәтле кеше бер дога укыды, имеш тә, тегеләргә өрде, имеш. Алар сихерләнгән, имеш, аларны казакъ хатыныча җаулык чорнаган бер убырлы карчык сихерләгән, имеш. Теге кешенең догасыннан соң тегеләр асыл сурәтләренә кайттылар, имеш.

Җәмгыяте хәйриягә дип килгән председательләр, секретарьлар, ни өчен килгәннәрен онытып, бу бичара сихерле колактан чыккан кешеләрне тамаша итәләр, имеш; бик озак карап торгач, председательләр мәҗлестән чыктылар, имеш. Алар чыккач, теге колактан коелган адәмнәр кире колакка кереп яттылар, имеш. Колактан,ерактагы урман эченнән килгән тавыш шикелле генә: «Җәмгыяте хәйрия акчасыннан театру ачу хәрам! Хәлаль диючеләр — кяфер, кяфер! Мәдрәсә дә ачмыйбыз; әлхәмделилла, болай да яхшы торабыз, рәхәтләнеп ашыйбыз, йоклыйбыз, наданланабыз, этләнәбез, төрле сурәтләргә дә керәбез; әлхәмделилла, әлхәмделилла!» — дигән тавышлар ишетелә, имеш.

Ах, шул кызык җиргә җиткәндә генә, хезмәтче малай чәйгә уятты. Яңа ел алдыннан күргән төш хәерле була, диләр иде. Шаять, яман төш булмас. Шәйтани түгелдер әле. Инде йокыга ятканда, кулыма чыбыркы тотып ятам. Төшемдә ишәк күрсәм...

---

*Рак* — кысла.

## ТӘШӘККЕР

Былтыр «17 нче октябрь партиясе»нең[1] башында йөреп, сайлау эшләрен беренче мәртәбә генә күргән аңсыз халыкны һәммәсен бер капчыкка төяп, бюрократларга тоттыра язып кына калган тиречегә вә аңгар ияргән берничә салам башларга быел да алданмаганнары өчен, без Уральск мөселманнарына күңелдән тәшәккер итәбез.

Быел ул әфәнде дин саклау исеменнән үзенең тиреләре илә корсагын сакларга халыкны чакырса да, халык сарык тиресе ябынып килгән бүрене таныдылар.

Аңгар алданмадылар, иярмәделәр.

Халкымызның фәкыйрьләре быел үзләренең сайлау кәгазьләрен үз файдаларына вә киләчәк көннәренең яктылыгына вә бәхетлелегенә салдылар.

Кайсыбер фатиха вә бәддога сатучылар теге тиреченең корсагын саклашырга бармаган халыкны җәһәннәмнәр, җәхимнәр берлә куркытсалар да, халык ни сәбәптәндер җәһәннәмнән дә курыкмадылар.

Ахрысы, халык чиркәү картларына ярдәм итүдә, русларның 3 йөз еллардан бирле ашатып та туйдыра алмаган попларын ашатышуда, һәммә китапларымызның урыс хәрефләре берлә язылуына риза булуда, Черевanskийның кыргызларны мәҗүси диюенә кул куюда вә башка да шуңгар охшашлы, ислам диненә зарарлы нәрсәләргә кул чабуда җәннәт юклыгын аңлаганнардыр; христиан диненең диннәр башлыгы булып, башка диннәрне теләсә ничек командовайт итүенә собрание ясауда да ислам өчен бер рәваҗ юклыгын белгәннәрдер.

Шуның өчен халык үзенең программасында һәммә милләтләргә, һәммә диннәргә бертигез хокук бирелүен требовайт иткән партияләргә кушылдылар. Кыскасы гына, быел халык «17 нче октябрь партиясе»нә вә башка уң партияләргә колак асмайуб, «сулларның сулы» партиясенә җан атып кушылмайа муаффәкъ улдылар. Яңлышлык берлә адашканнары да кирәдән тугъры юлга киттеләр.

Тиречe[2] әфәнделәр, аю, маймыл, кәҗә, ишәкләрнең музыка уйнарга утырганнары[3] төсле, үзара иске мунчага җыелып: «Әх-

---

*Тәшәккер* — яхшылыкка каршы рәхмәт белдерү.
*Фатиха* — изге дога.
*Бәддога* — явыз дога.
*Җәхим* — тәмуг.
*Рәваҗ* — алга китеш.
*Муаффәкъ улдылар* — ирештеләр.

мәтҗан абзый, син выборщик бул, юк, Мөхәммәтҗан абзый, син бул, син карт кеше; юк, Миңлебай абзый, син булчы, син мәчет карты», — дип төртешә, тартыша, берничә аксак-туксакларны выборщик тәгъйин иттеләр.

Итсәләр дә, кечкенә балаларның бер-берсенә: «Син утаман булган бул, ди, мин солдат булыйм, ди», — дип уйнаган уеннарыннан бер дә аермалары булмады.

Бу карагруһлар әүвәлдә йөзләп булсалар да, бара-бара берничә шара-бара гына калганга, мөселманнарның йөзенә кара яга алмадылар. Алар, үз уйларынча, бер дә кәләпүшсезләргә һәм русларга кушылмаска вә Думадагы рус, әрмән, яһүди, татар депутатларына йөзе бер тәңкәлек чуклы кәләпүшләр алып баручы бер кәләпүшле вә яшел читекле мөселманны гына Думага җибәрмәкчеләр иде. Бу, әлбәттә, кәләпүш берлә сату итүче мөритләргә зур файда булачак иде.

Әгәр боларга иярүчеләр күп булып та, шулай курчак уены уйнап йөрсәләр, шөбһәсез, рус ватандашлар илә мөселманнар арасына зур бер салкынлык төшәчәк иде.

Күп шөкерләр улсын ки, мөселманнар алданмадылар. Сайлау эшләре яхшы гына бер сурәттә үтеп китте.

## УРАЛЬСК ХӘБӘРЛӘРЕ

Хәсәнҗан Хөсәенев җәнабләре әллә кайсы матбагадан «Бәянел хак фи хаккыл хиҗаб» исемле бер китап бастырган.

Китапны бик мактыйлар, кәгазе бик яхшы — ертылмый торган кәгазь, диләр. Хәсәнҗан абзый һәр көнне бер дистәсен сүтеп, чәй-шикәр төреп җибәрә, имеш. Ит базарындагы итчеләр дә бу китап чыкканнан бирле кәгазь сатып алмый башлаганнар, ди. Итләрен бу святой китап берлән генә төреп җибәрәләр, ди.

Бу китап, хиҗаб хакында булганга күрә, һаман чапан эчендә төренеп кенә тора, имеш, дип сөйлиләр.

Бу чапанлы китап, «Казан» миһманханәсенә кереп килгәндә, яңгылыш егетләр очрагач, тагы Хәсәнҗан кибетенә качкан, ди.

Инде бер җиргә дә чыкмый, ди.

Әмма итчеләргә һәм аларның покупательләренә ничек күренә икән? Мин үзем, кыйраәтханәгә ничә тапкыр кереп, мәзкүр китапны сорасам да: «Ул монда юк. Андый чапанлы китап монда киләме соң! Әле беркөн генә качып киткән иде», — диделәр.

---

*Тәгъйин итү* — билгеләү.
*Хиҗаб* — йөз өреткеч пәрдә.
*Кыйраәтханә* — уку залы.
*Мәзкүр* — әлеге.

## КАБЕРГӘ КИТКӘН «ФИКЕР» ЯҢАДАН ТЕРЕЛЕП КАЙТТЫ

«Фикер» гәзитәсе хөкүмәт әмриләә туктатылдыктан соңра, рәфикымез «Вакыт» гәзитәсе, нә өчендер яман фал ачып, «Фикер» гәзитәсе хакында ушбу сүзләри нәшер әйләде:

«Уральскидән алдыгымыз телеграмга күрә куелган «Фикер» газитәсе вә «Әлгасрел җәдит» илә «Уклар» журналлары барчасы туктамышлардыр:

— Йөз мең сумага, 5 меңнән артык мөштәригә малик көндәлек вә мөселман гәзитәләренең иң бөеге саналган «Фикер»нең кабергә сәфәренә тәәссеф улыныр...»

Гаҗәба! «Фикер» газитәсенең тукталуы сәбәпле аның кабергә сәфәре нә өчен лязим икән? «Вакыт» мөхәррирләре мантыйк кагыйдәләрен, ахрысы, оныткannардыр. Һич улмазса, туктатылу илә үлү арасында бик зур мөбаинәт бар идекене илтифатка алу кирәк иде.

Нә исә хәмед улсын, «Фикер» гәзитәсе вә аның иптәшләре «Әлгасрел җәдит» вә «Уклар» журналлары яңадан дәвама башладылар.

## ИДАРӘДӘН

Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин җәнабләренең кулыннан администрация тарафыннан мөхәррирлек вә нәширлек хокуклары алынгач, табигый, «Әлгасрел җәдит» мәҗәлләсенең мөхибләре кайгырдылар. Гәзитләремез дә беркадәр тәәссеф итеп яздылар. Бу кайгыга иштиракь әсәре күрсәттеләр. Безгә мәгълүм түгел, ихтимал, бәгъзе золмәт сөючеләрдән шатланучылар да булгандыр. Шуңгар күрә без бәян итәбез ки, «Әлгасрел җәдит»нең мөхибләре вә дустлары күңелләрен хуш тотсыннар. Вә дошманнары да куанмасыннар: без, «Әлгасрел җә-

*Әмриләә (әмере илә)* — боерыгы белән.
*Рәфикъ* — иптәш.
*Мөштәригә малик* — яздырып алучысы (подписчигы) булган.
*Тәәссеф улыныр* — үкенеч белдерәбез.
*Гаҗәба!* — Бик гаҗәп!
*Лязим* — кирәк, тиеш.
*Мантыйк* — логика.
*Мөбаинәт* — аерма.
*Хәмед улсын* — шөкер булсын.
*Мәҗәлләсенең мөхибләре* — журналын сөючеләр.
*Тәәссеф итү* — кайгыру.
*Иштиракь әсәре* — уртаклашу тойгысы.

дит»нең ушбу 3 нче нумирыны мәйданга куйдыкымыз кеби, аны һаман да дәвам иттерәчәкмез.

«Әлгасрел җәдит»нең әүвәлге мәсләкенә вә хөррият пәрвәрлекенә аслан хәләл* китермәячәкмез.

Без, Уральск шәһәренең кояшларын сүндереп, халкыны караңгыда калдырып адаштырырга кулымызда аз гына бер икътидар, тәнемездә җан бар вакытта аслан разый булмаячакмыз.

Бинаән галәйһи моңгар чаклы «Әлгасрел җәдит»не каләмнәре берлә тәзйин итеп килгән чит шәһәрләрдәге мөхтәрәм мөхәррирләремезнең янә әүвәлгечә язып торуларыны риҗаә итәмез.

Безнең мәйданымыз милләт каһарманнарының мөбарәзәсе өчен ачыктыр. Килсеннәр, ул шанлы вә намле каләмнәрен уйнатсыннар!

Милләт, бичара, һәлакәтнең чигенә җиткән, актык сулышларын ала. Тик каләмнән генә хәят, тик каләмнән генә нәҗат көтә.

Һайдәңез, борадәрләр! Языңыз, языйк, таратыйк, галәме исламга нур сачик, нурланыйк, тырышыйк!

И каләм! сәндин кәлүр һәп бәхтемез, икъбалемез;
Бәкләнүр дүрт күз илә лотфеңдә истикъбалемез**.

## ТӘКРАР ӘЙТӘМЕЗ

Мәгариф — хәяттыр. Мәгариф — хәяттыр. Мәгариф — хәяттыр.

Һәр бәхетне, һәр сәгадәтне, һәр нәҗатны анчак голүм вә мәгърифәттән генә көтмәк кирәктер.

---

* Тоткан юлына һәм азатлыкны яклавына һич тә кимчелек.
** И каләм! бәхет һәм якты киләчәгебез синнән килер;
Якты киләчәгебез дүрт күз белән рәхмәтеңнән көтелә.
*Икътидар* — сәләт, көч-куәт.
*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.
*Тәзйин итү* — матурлау, бизәү.
*Риҗаә итү* — үтенү.
*Мөбарәзә* — бергә-бер чыгып көрәшү.
*Намле* — абруйлы.
*Хәят* — тормыш, яшәү.
*Нәҗат* — котылу.
*Борадәр* — туган.
*Галәме ислам* — мөселман дөньясы.
*Нәҗат* — котылу.
*Анчак* — бары тик.
*Голүм* — гыйлемнәр.

Зыялыларыбызга һәр ничек, җәсарәтле пожарныйлар кеби, җәһаләт ялкыны эчендә дөрләп янган милләтне, тизрәк утка атылып, коткарырга тырышу фарыздыр.

Пожарны читтән тамаша кыйлып кына көлеп тормак — ирлек түгелдер.

11 нче номер «Фикер»дәге Тартар кошының[1]:

Гыйльме рәгъбәт сал, татар, —
Ит син шуны алтатар;
Корсын туплар! Мәктәпләр —
Сезнең арсенал, татар, —

дигән сүзләре тәмамилә бу «Мәгариф — хәяттыр» мәкаләсенең мәзмүнедер. Өмид анчак мәктәпләрдә генә!

## ШИГЫРЬЛӘРЕМЕЗ

Безнең татарларның шигырь сөйли торган бәхерләре гаять гүзәлдер. Бер татар шигырен әллә ничә төрле көйләргә җырларга мөмкиндер. Безнең татарлар җырлый торган көйгә рус шагыйрьләренең бик күп шигырьләре килеп кенә торадыр. Мәсәлән, Пушкиннең бер шигырен татар көе берлә җырлыйбыз:

Еду, еду в чистом поле,
«Җизнәкәй» (2 кәррә),
Колокольчик динь-динь-динь...
«Балдызым, ялгызым» (1 кәррә).

Моннан башка да рус шагыйрьләренең шигырьләре татар көенә бик матур киләдер. Моны әле мисал өчен генә күрсәттек. Тагы да гарәпләрчә вә гомум исламча мәмдух булган «Касыйдәи бөридә»[1]не дә теләсәк нинди татар көе берлә җырлап буладыр. Димәк, татар милләтендә мөстәгъмәл бәхер бик яхшы бер бәхердер, анысына сүз юк...

Әмма шунысы бар ки, әксәр татар шигыренең бер мисрагы икенче мисрагына аслан тәгаллекъсез ударак сөйләнмештер.

---

*Җәсарәтле* — йөрәкле, батыр.
*Җәһаләт* — наданлык.
*Гыйльме рәгъбәт* — гыйлемгә күңел.
*Тәмамилә* — тулысы белән.
*Мәзмүн* — эчтәлек; тәңгәл килү.
*Бәхер* — үлчәм.
*Кәррә* — тапкыр.
*Мәмдух* — мактаулы (кабул ителгән).
*Мөстәгъмәл* — кулланыла торган.
*Әксәр* — күбрәк.
*Мисрагъ* — шигырь юлы.
*Аслан тәгаллекъсез* — бөтенләй бәйләнешсез.

Мәсәлән:

Сары атым саз буенда,
Җиз камыты муйнында;
Синең илә даным чыкты, —
Җаным чыксын куйнында.

Йә, бу шигырьнең шагыйре үзенең мәхбүбәсенең куеныннан чыкмаска бик нык вәгъдә беркетә; шул вәгъдәне сөйләгән вакытта сары атларны, җиз камытларны, саз буйларын зикер кыйлуы гаять килешсездер. Тагы да бер шигырьнең яртысын ишеткәнем бар:

Канәфер исе киләдер,
Бадьян бар мәллә бүркеңдә.

Йә, моның соңгы мисрагы мөтәгалликъ булуын-булмавын бер якка калдырсак та, шул ике юл да бер-берсенә бөтенләй киредер. Шагыйрьнең яратканының бәртәкъдир бүркендә бадьян булса, аннан ни өчен канәфер исе килсен?

Моны язган вакытымда алдымда русларның «Народные песни» дигән бер җыру китабы тора. Бу китапта безнең татар шагыйрьләренең һич тәгаллекъсез сары атлары яки бер-берсенә монакыйз канәфер белән бадьяннары аслан кушылмагандыр. Иң начар дигән җыруында да бер фикерне башлап, ахырына кадәр сөйләнеп чыгылмыштыр. Моның мисалын язарга хаҗәт юк, чөнки бер гами рус җырлаганда аз гына колак салып тору җитәдер.

Шул ук вакытта бер ягымда бер кәгазьгә язылган бер казакъ «үләңе» ятадыр. Ул исә ушбу түбәндәге сүзләрдән гыйбарәттер:

Карагым, айналаен, сез кызгалдак,
Сездэргэ бәргән экән мал менэн бак;
Җапанда җалгыз җөреп калганымнан,
Аерылган эгэзенэн мэн бер ылак.

Күз күреп, кулым җэтпей — көенәмен,
Мэн дэ бер суда җөргэн җалгыз шабак;
Курбының арманы нэ, сезде кочкан,
Авызың бал, телең шэкэр, куйның оҗмак.

---

*Мәхбүбә* — сөйгән кыз.
*Зикер кыйлу* — телгә алу.
*Мисрагы мөтәгалликъ* — куплеты (монда икеюллык) бәйләнешле.
*Бәртәкъдир* — әгәр дә.
*Монакыйз* — капма-каршы.
*Гами* — гади кеше.
*Үләң* — җыр.

Оҗмакта хур кыздары җүрсә болай,
Олардай хөллә киеп өңшәң пырак;
Җүзеңде сагат саен бер курмэсэм,
Мән үйдә торалмаймын, җалгызсырап*.

Күрдегезме? Бу казакъ шагыйре үзенең мәхбүбәсен ничек мактый белгән! Моннан күренәдер ки, безнең татарлар шигырь ягыннан казакълардан да артта калган икән.

«Фәвакиһелҗөләса» китабындагы[2] Габделҗәббар әл-Кандалый әфәнденең шигырьләре ул кадәр үк тәгаллекъсез булмаса да, шактый әдәпкә вә әдәбиятка хилаф җирләре бардыр. Суфи Аллаһыяр вә Утыз Имәни хәзрәтләре бертөрле назымлырак шигырь сөйли белмешләр исә дә, тик тәсаувыф бабында гына сөйләгәннәр. Әгәр ул әфәнделәр дөньяга вә аның халкына да бераз илтифат итеп дөньядан киткән булсалар, хәзерге көндә исемнәре тагы да артык хәер илә зикер ителер иде.

Ник соң безнең татарлар, дөньяда шулкадәр гасыр гомер итеп, бер җүнлерәк шигырь яза алмаганнар? Әллә шифаһән сөйләүчеләр булып та, язып алучылар булмыйча, ул шигырьләр шагыйрьләре берлә бергә кабергә күмелдеме? Ихтимал, шулайдыр, язып алучы булмагандыр, чөнки «Әсма, яки Гамәл вә җәза» китабындагы Сәлим бабайның шигырьләре[3] шул ихтималмы уйга китерерлектер.

Әле истән чыккан икән, тагы бер ярты казакъ, ярты татар Акмелла хәзрәтләре[4] бар икән. Ул да шигырь язган, ләкин һаман да аның шигырьләренә бик күп тәгассыб катышкандыр, һәм дә безнең татар рухына, татар халкына бер дә тәэсире юктыр, шигырьләреннән тик казакъ исе, күчмә халык исе чыгып торадыр.

Безнең 17 нче октябрьдән соң мәйданга чыккан ике бөек шагыйрьләремез[5] үрнәкне шул мәрхүм Акмелладан алганнар

---

* Җанашым, айналаен, сез кызгалак,
Сезгә биргән икән мал белән бәхет;
Дөньяда йөреп ялгыз калганыма, —
Инәсеннән аерылган мин бер бәти.

Күз күреп, кулым җитми — көенәмен,
Мин дә бер суда йөзгән ялгыз чабак;
Дус-ишнең ни гаме бар, сезне кочкан —
Авызың бал, телең шикәр, куйның оҗмах.

Оҗмахта хур кызлары дисәң, булыр,
Алардай хөллә киеп менсәң пырак;
Йөзеңне сәгать саен бер күрмәсәм,
Мин өйдә торалмаймын ялгызсырап.

*Назымлырак* — рифмалы тезмә (шигырь).
*Тәсаувыф бабында* — суфичылыкка бәйләнешле.
*Хәер илә зикер ителү* — мактап искә алыну.
*Шифаһән* — телдән.
*Тәгассыб* — искелек, фанатизм.

булырга кирәк, чөнки шигырьләрен галибен шул казакъ бәхре илә язалар.

Хәмед улсын, 17 нче октябрьдән соң һәр тарафтан яхшы ук шагыйрьләр баш күтәрделәр. Моннан соң да күтәрелерләр. Ләкин мәсьәлә шунда: 17 нче октябрьгә чаклы ни өчен татарда һичбер шигырь булмаган? Аңар чаклы хөррият юк иде дисәң, бездән башка халыкларга да аңар чаклы хөррият юк иде.

## АНА МӘКТҮБЛӘРЕ

СҮЗ БАШЫ.

— Балалар — безнең шатлыкымыз... Балалар — безнең бәхетемез вә сәгадәтемез... Балалар безнең гомер нигеземезне тазарталар, балалар хезмәт өчен безнең көчемезне арттыралар.

Бу сүзләр һәрбер атаның да, һәрбер ананың да йөрәгеннән ләззәтле-ләззәтле генә өзелеп чыккан сүзләрдер.

— Бөтенләй аптырадым инде, нишләргә бу балалар берлән?! Һәрвакыт авырыйлар. Сабакны начар укыйлар... Усаллар, шаяннар... Бик шуклар, рәтсезләр!..

Менә бу җөмләләр ата-ананың йөрәкләрен кисеп чыккан сүзләрдер.

Болар ата-ананың бер кисмәк бәхет балын бозган бер кашык дегеттер.

Балалар якты дөньяга килгәндә, гадәтән, бер бәхетлелек диңгезе булып киләләр. Ләкин әнә шул балаларны туган минутыннан алып балигъ булганга кадәр ата-ана үзләренә бәхет вә башка инсаннарга да шатлык булырлык итеп тәрбия итүе бик читен, ай-һай, бик читен!

Аһ, безнең татар халкында бер дә генә бала тәрбия итү нәрсә икәнен белмиләр! Сәүдәгәрнең угылы булса: «Җә, минем угылым мулла булмас, тизрәк тире-җарыга тотындырырга кирәк, кул арасына керсен», — ди.

Сәүдәгәрнең кыз баласы булса: «Җә, безнең кызымыз остабикә булмас, кул арасына керсен», — диләр. Мулла баласы булса: «Җә, минем угылым әллә ниләр укып азмасын, аннан-моннан мантыйк күргәләсен дә үз урыныма мулла булыр», — ди.

Әйтерсең лә бу дөньяга ирләр — мулла булырга, кызлар остабикә булырга гына туганнар!

---

*Галибен* — күбрәк.
*Хәмед улсын* — шөкер булсын.
*Гадәтән* — гадәттә.
*Мантыйк* — логика.

Баланы, ир баланы, әйбәт кенә тәрбия ителсә, ата-ана өчен, гомернең куркынычлы һөҗүмнәре вакытында шул бала шул ата-анасын сакларга күкрәп, нәгъръә орып чыккан бер арыслан буладыр.

Кыз баланы бик матур гына тәрбия ителсә, бөтен дөнья байлыкларына сатылмаслык егетләрне, картларны, хәтта хатыннар вә карчыкларны үзенә таба тартып тора торган әллә нинди җазибәле бер фәрештә буладыр. Аның бер сүзен ишетер өчен, бер генә йөзен күрер өчен меңнәрчә җаннар атылып кына торадыр. Ул үзе шикелле тагы әллә ничә фәрештә кызлар вә әллә ничә арыслан йөрәкле, гайрәтле егетләр тәрбия итә аладыр.

Менә мин укыган кызларның, ана булгач, ни рәвештә хат язышканнарын мисал өчен русчадан икътибас итеп язамын.

## Беренче мәктүб

### *Гайшә — Фатимага*

Сөекле дустым! Минем гомеремдә әле әллә нинди бер көтелмәгән эш чыгып китте. Минем үзем белә бертуган агам бар иде. Ул кисәктән генә вәйран булып үлеп китте дә миңа тәрбиягә үзенең түп-түгәрәк ятим 5 яшьлек кызы Газизәне калдырды. Газизәнең миннән башка бер дә якын кешесе юк. Шуның өчен мин аның һәммә тормыш мәшәкатьләрен үз муеныма алырга бурычлымын. Әмма ни эшлим икән? Балалар тәрбия итәргә миндә бер дә әйтерлек көч юк. Мин аны нинди булса да бер мәктәпкә бирергә уйлаган идем. Ләкин минем хәлем бик киң түгел. Әгәр барлы-юклы хәлем берлә азапланып, барча малымны аны укытырга сарыф итим дисәм, соңыннан нишләрмен дип куркам. Шуның өчен син дустыма киңәш итәм. Син минем хәлемне бик яхшы беләсең, һәм тәрбия эшендә дә осталыгың бар. Хат яз. Миңа киңәш бир. Ходай өчен, зинһар, дип әйтәм, хатыңны озынрак яз.

## Икенче мәктүб

### *Фатима — Гайшәгә*

Дустым! Миңа синдә синең сеңлең Газизәнең тәрбиядә торуы бик ят тоелды. Мин, синең җаныңның шәфкать сөючән икәнене белгәнгә күрә, ул ятимне тәрбиягә алмассың дип бер дә шикләнмим.

---

*Нәгъръә ору* — көчле тавыш белән кычкыру.
*Җазибәле* — үзенә тарта торган, магнитлы.
*Икътибас иту* — файдалану.
*Вәйран булу* — әрәм булу, үлеп киту.

Бу бик изге эш булыр: син ул мискинәнең анасы урынына торырсың һәм аны ахырда бик яхшы вә файдалы бер кыз ясап җитештерерсең. Мин беләм инде: син бу эштә бераз куркырсың. Үзеңнең бу эшкә көчең җитүенә шикләнерсең. Һәм курыкмаслык та түгел, дустым: бала тәрбия итү уңгай эш түгел бит, тәрбия итә белми тәрбияләсәң, халык кашында да, халикъ кашында да җавап бирергә кирәк!

Ләкин курыкма, дустым. Гәрчә синдә бу кеби изге эшкә кирәге кадәр осталык булмаса да, бара-бара өйрәнерсең әле. Мин ышанам: син үзеңнең изге эшкә булган гыйшкың вә һәртөрле авырлыкларга түземлелегең аркасында, инша Аллаһ, барча мөшкилләрне җиңеп, өстен булырсың. Бала тәрбия итә белмәсә дә, бала алган булды тагы, дигән шелтәгә грифтар булудан котылырлык гайрәт итәрсең дип беләм.

Син тәрбияче һәм ана сурәтендә итә башлаган бу яңы гомереңнән тагы үзенә башка бер кызык табарсың; әле син моңгар хәтле миңа язган хатларыңда һаман гомереңнән зарланыбрак яза торган идең. Бәлки, син алай язмагансыңдыр да, әллә ничек мин шулай аңладым.

Сүзнең кыскасы: мин үземнең озын-озын тәҗрибәләрем берлә тапкан белекләремне синең белән уртаклашырмын. Һәм бу мәшәкатьле тәрбия эшендә сиңа куана-куана киңәшләр күрсәтермен. Хәзергә сау бул.

*Дустың Фатима*

Менә бу ике ханым әфәнделәр шул рәвешчә бик озак хат язышалар.

Мин боларның хатларын «Фикер»гә дәреҗ иттерә торачагымны вәгъдә итәмен.

## Өченче мәктүб

### *Гайшә — Фатимага*

Мин сиңа язарга ашыгам ки, Газизә сеңлем миндә инде. Бу эшнең ничек-ничек булганын сөйлим әле.

Опекун миңа Газизәне Казанга китерәчәген һәм аннан минем алып китүемне теләвен бәян итте.

Миңа бу сәфәр никадәр читен булса да, һаман да Казанга барып, опекун берлә Газизә килә торган поездны көтәргә тугъры килде. Анда опекун миңа Газизәне тапшырды да, дәрхаль кире өенә кайтып китте.

*Халикъ* — Алла.
*Дәреҗ итү* — бастыру.
*Дәрхаль* — шунда ук.

Күрдем ки, бу хәл баланың төсен бер дә бозмады вә күңеленә бер дә әсәр итмәде. Ул миңа да, опекунга да бер дә илтифат итми иде. Тик тирәбезне чолгап алган нәрсәләргә генә текәлеп-текәлеп кенә карый иде. Хәтта вагонда ул миңа асла карамыйча, тик вагон тәрәзәсеннән генә карый иде.

Өйгә кайткан чакта, ул шулкадәр арыган, шулкадәр изелгән иде ки, азрак сөт эчкәч тә, изелеп йокыга китте. Мин исә, бу баланы үземә ничек ияләштерим икән дип уйлый-уйлый, төн буенча йоклый алмадым.

Качан иртә берлән торгач, мин аның акрын гына мендәре янына бардым. Ул, урыныннан торып утырып, гаҗәпләнеп кенә һәр якны карады да кисәктән җылап җибәрде. Мин аңар: «Курыкма, сеңлем, мин синең апаең: миндә бик күңелле, бик кызык торырсың», — дигәләп, күңелен җуатырга тырышсам да, файда итмәде. Шулай да булса, ахырда тәмле бәлеш кисәге биреп тынычландыра алдым.

Шулай итеп, ул миңа үзен киендерергә һәм җуындырырга да ирек бирде. Шундыйн соң ул, урындыкка утырып, иң башта тәрәзәдән урманнарны, кырларны карарга тотынды.

Мин, аны ничек тә булса үземә якынлаштырыр өчен: «Әйдә, сеңлем, кырларга барыйк, чәчәкләр өзәрбез яки тавыклар ашатыйк», — дисәм дә, ул һаман башын гына селкә иде. Шул вакытта минем исемә төште ки, минем сурәтләр төшергән бер кечкенәрәк китабым бар иде; шул китабымны чыгардым. Бала, китапны күргәч, җанланып китте. Иң әүвәл мин аңар бу сурәтләрнең нәрсәләр икәнен, «бу шундый нәрсә, бу мондый нәрсә» дип аңлата башлаган идем, ул, минем сүземне кисеп: «Миңа син кирәкми, бу сурәтләрне мин үзем дә беләм, үземдә дә мондый китап бар», — диде. Хәзер ул шул китап берлә җуанып тик утыра. Мин дә, бу форсаттан файдаланып, сиңа хат язам.

Хәзер минем хәлем бик кәефсез.

Бу кызчык белән нишләргә инде? Аны ни белән шөгыльләндерергә һәм ничек аны үземә бәйләргә?

Беләмсең, дустым, минем башыма ни килде хәзер? Мин синнән Газизәне үзеңә алуыңны үтенер идем. Чөнки син, әүвәлрәк мөгаллимә булганлыктан, балалар берлә эш итәргә ияләнгәнсең; тагы син үзеңнең ике кызыңны, һәртөрле тәрбияләр өстенә, кичке вә көндезге дәресләр берлә тәрбия итәсең. Шулай булгач, син бу Газизәне дә өченче кызың итеп тәрбия итә алырсың дип уйлыйм. Минем бу үтенечемә каршы син ни әйтәсең? Әлбәттә, мин үзем дә аны тәрбия итүне бик яратам — ул бик нәфис кыз. Мин аны бик сөямен дә. Ләкин күңелем сизәдер ки, мин бу

---

*Асла* — бөтенләй.

эшкә ярамыйм. Бу балачыкны ни берлә җуатыйм, ни берлән күңелен ачыйм икән, аңгар ничек эндәшим икән, дип, һаман уйлап торуым минем тынычлыгымны вә кәефемне бозадыр.

Киңәш бирче, зинһар. Тизрәк хат язчы. Мин ни эшлим икән?

*Гайшә*

## Дүртенче мәктүб

### *Фатима — Гайшәгә*

Миңа синең хисапсыз каты ышануың һәм Газизәне миңа бирмәкче булуың бик каты тәэсир итте.

Билгеле инде, мин ул Газизәне тик синең сеңлең булганы өчен генә дә тәрбиягә алыр идем.

Әмма шулай да мин сиңа чын күңелемнән мәслихәт бирәм: ул кызны үзеңдә калдыр! Ышан син миңа! Ул сиңа, иткән хезмәтләрең өчен, мәгънәви сурәттә әллә никадәр шатлыклар вә бәхетлелекләр китерер.

Синең гомерең инде моңарча вак-төяк нәрсәләр берлә генә үткән гомер төсле булмас; бәлки, мондыйн соңгы гомереңнән зур хикмәт чыгар.

Әгәр инде читенлегеннән шикләнсәң, бу бик җиңгел төзәлә торган эш. Ул турыда, Газизәне бергәләп тәрбияләү өчен, мин сиңа һәртөрле булышлыклар күрсәтергә хәзермен.

Мин бераз заманнар мөгаллимә вә мөрәббия булып торганлыгымнан, миңа һәртөрле яшьтәге балалар берлә эш итәргә туры килгәне шикелле, шулардан зур тәҗрибәләр алуым да аз булмады.

Синең берлә барча тәрбия бабында белгән гыйлемнәремне, осталыкларымны уртакларга хәзермен.

Балалар тәрбиясе турысында файдалы нәсыйхәтләремне вә киңәшләремне бер дә кызганачак түгелмен.

Син тик Газизәнең кыйланышларында вә йөрешләрендә бер ят үзгәреш күрсәң яки тәрбиягә кирәкле бер мәсьәләдә шөбһәләнсәң, һаман миңа бәйнә-бәйнә язып хәбәр биреп тор.

Миңа да буш сәгатьләремдә синең берлә язышып мосахәбә кыйлуы бик күңелле булып, рәхәтлек бирер.

Җә, инде сүзне синең хатыңга борыйк; хәзер мин сине бераз кыздырып алмакчы булам.

Газизәнең әле синдә тора башлавына бер көн булмаган, синең инде кәефең дә китеп өлгергән!

---

*Мөрәббия* — тәрбияче хатын-кыз.
*Бабында* — мәсьәләсендә.
*Мосахәбә* — әңгәмә.

Син чыдамлык берлән кораллан, иң әүвәл баланың ышанычын вә мәхәббәтен үзеңә тартып алырга тырыш. Шул вакытта сиңа баланы тәрбия итү уңгайланыр.

Балалар мәхәббәт вә сөйкемле күз карашларга бик мохтаҗ булалар. Алар үзләренең шатлыгын вә хәсрәтен уртаклашырга бер кеше кирәклеген сизәләр.

Бала тәрбияләүдә яхшы нәтиҗәләргә барып җитү өчен, иң элек, баланың табигатен, әхлакый һәм йөреш-торышын нечкәләп белергә кирәк. Менә иң читене — баланың ушбу хасиятләрен аңламактыр. Моны аңлау баланың туган минутыннан бирле һаман янында гына торып, баланың һәр хәрәкәтен, һәр селкенүен тикшереп кенә йөргән үз анасына да уңгай түгел.

Баланың рухын бик ачык аңлау өчен, һаман аның хәрәкәтләрен күзләп, аның яхшы вә яман холыкларының һәммәсен дә аерып белергә тырышырга кирәк. Балага үзең теләгән рәвешне бирергә теләсәң, бик озак вакытлар чыдарга вә сабыр итәргә һәм акрын гына эш йөртергә тиештер.

Һәр сабый баланың да үзенә махсус бер холкы вә табигате буладыр. Хәтта бер урында үскән бер ата, бер ананың балаларында да әхлакта вә табигатьтә аерымлыклар күренәдер.

Бу кызчыкның холкына вә рухына якынлашыр өчен, мин сиңа аның янында күбрәк булырга, аның берлә шөгыльләнергә, сәер кыйлырга, бигрәк тә аның берлә күбрәк сөйләшергә киңәш бирәм.

Тагы да аны һәрвакыт башка балалар берлә уйнаганда сынарга кирәк, ләкин шул рәвешчә ки, ул синең караганыңны сизмәсен. Балалар, читтән берәүнең карап торганын сизсәләр, әллә нинди хөрриятсез, чынлыксыз булып китәләр.

Шулай ук баланың инабәтен вә ышанычын үзеңә алырга тырыш; ул бала анасынамы яки анасы урынына калган тәрбиячесенәме үзенең барча яшерен серләрен сөйләргә һәм дә үзенең файдаларын, хәтта ки яңлышларын сөйләргә курыкмаска тиештер.

Яңлышлыкларга килгәндә, бик зур саклык кирәк: һәрвакытта гадел булып, баланың яңлышының нидән килгәнлеген, сәбәбен тикшерергә һәм ничек тә булса да баланың гаебен вә гөнаһын җиңгеләйтә торган хәйләләр эзләргә кирәк.

Ләкин бигрәк тә, дустым, балага сөйкемле сурәттә вә ачык йөз берлә күрен, һичбер вакытта аны үзенең бер йомышы берлә яныңа килгән вакытта төртеп җибәрмә.

Гәрчә ул, кечкенә Газизә, синең бер кәефсезрәк вакытыңда яки хәстә вакытыңда, яки дә бер ашыгыч эш вакытыңда сиңа

---

*Сәер кыйлу* — йөрергә чыгу.
*Инабәт* — ышаныч, таяныч.

бер-бер нәрсә сорарга яки бер йомыш берлә килсә дә, зинһар, аны кууны теләвеңә бирешмә. Әгәр син аны шулай төртеп җибәрсәң, ул үзен-үзе сөючән яшь баланың бөтенләй күңелен суындырып, үзеңнән еракландырырга сәбәп булырсың.

Бик белмәк кирәк ки, безнең үземезнең шәхси кәефсезлекемез яки саусызлыгымыз безнең балаларга булган сөйкемле күз карашыбызны үзгәртергә тиеш түгел.

*Фатима*

## Бишенче мәктүб

### *Гайшә — Фатимага*

Сиңа шатлык берлән бәян итәмен ки, инде минем берлән Газизә арасында шактый ук якынлашулар була башлады. Хосусән теге китап берлән якынлаштык. Без икәү, сәгатьләрчә вакытлар утырып, ул китапны актарабыз. Газизә миңа сурәтләрнең нәрсәләр, нәрсәләр икәнен сөйли. Бәгъзе бер сөальләре илә ул кайсы вакытта мине шактый кыенлыкка төшерә. Тик шунда гына бәла: кич берлән аны мендәргә яткыру бик читен, иртә белән исә уятыр хәл юк, торгызыр хәл юк. Тагы мине шунысы тынычсызлый: аның бер дә һазымы юк. Хәтта бөтенләй бер локъмә ашамый диергә ярый. Аны үзем берлә бергә озын-озын сәерләргә алып чыгыйм дисәм, мондый салкын һавада җил тияр-фәлән дип куркам. Ул аннан башка да зәгыйфә генә, нечкә генә кыз.

Ләкин минем сиңа бу хатны язып киңәш сорарга уйлаганым аның укуы турысында иде. Бер җыл аркылы Газизәгә мәктәпкә барырга кирәк булыр. Инде мин белмим, аны үзем укырга-язарга өйрәтә башлыйм микән? Хәзердән үк өйрәнсә, мәктәптә җиңелрәк булыр иде димәкче булам.

*Гайшә*

## Алтынчы мәктүб

### *Фатима — Гайшәгә*

Син ул кызны укытырга бикяр ашыгасың. Хикмәт шунда: синең укыту сәләхиятләрең бераз искергән. Син мәктәптән чыккандин бирле укыту һөнәрләре тагы да алгарак китте ин-

---

*Хосусән* — бигрәк тә.
*Һазым* — аш үтү, аппетит.
*Локъмә* — бер кабым.
*Бикяр* — юкка.
*Сәләхият* — сәләт.

де. Мәсәлән, син аны укырга, язарга, исәпләргә өйрәтерсең дә, әмма соңыннан ул мәктәптә һаман шул син өйрәткәнне тыңлар һәм син өйрәткәнне укыр. Бу исә аңгар, әлбәттә, күңелсез булыр. Аның зиһене иске нәрсәне белүдән ялкыр. Балалар бер дә ишетмәгән яңы нәрсәне генә бик ихлас берлә тыңлыйлар.

Минемчә, сиңа аны җисмани вә рухани тарафларыннан тәрбия итәргә кирәк; болай итмәк баланы мәктәпкә хәзерләгәндә иң әүвәл тиештер. Син тырыш: ул, синең тәрбияңдә торган бала, иң элек һәрничек тазарсын вә куәт җыйсын, — болар аның мәктәптә укыган вакытында бик кирәк булачак нәрсәләрдер.

Андин соң, син Газизәнең һазымы начар дип зарланасың. Бу хәл аның өйдә генә күп утырып, яхшы һавага чыкмаганыннан киләдер. Аңар, әлбәттә, күп сәер итү һәм күп вакыт яхшы һавада һәр көн иң азында сәгать ярым булырга кирәк. Шуның берлә бергә, аңар бераз хәрәкәтләнергә, җөгерергә, туп уйнарга яки тимер көрәк берлә җир казырга кирәк. Сиңа боларның барчасын эшләү бик җиңел, чөнки синең кул астыңда гына урман бар. Шулай ук бала өчен суда йөзү, бәгъзан каек ишкәләү, велосипедта йөрү, гимнастика бик файдалыдыр. Ләкин шулай кирәк ки, аның кигән киемнәре тар булып, хәрәкәт вакытында кысмаслык булсын.

Тагы да: ул йоклаганда саф вә нәфис һавада, хәтта, әгәр мөмкин булса, ачык тәрәзә янында йокласын. Шулай итеп тәрбия иткәндә, аның һазымы да һәм йокысы да яхшы булыр. Аңар, бергә мәшгуль булыр һәм бергә уйнар өчен, үзе берлә яшьтәш бер дуст табылса, гүзәл булыр иде.

Янә дә шундый бер тәртип куярга тиеш ки, ул бер мөгайян сәгатьтә йокыга ятып, мөгайян вакытта торсын. Ягъни ул махсус бер вакытта ятсын, нәкъ шул махсус вакытта уянсын. Син моны эшләгәндә, билгеле, аның тарафыннан бераз каршылык күрерсең, ләкин син бу тугърыда асла аның җалынуларына, күз яшьләренә карама, син аны бик каты көчлә ки, ул син әйткән вакытта йоклап, син кушканча торсын. Соңра, йокыдан торгач, ул иң элек җуынырга һәм киенергә бурычлыдыр. Шундыйн соң гына аңгар иртәге аш бирергә кирәк.

Болай булгач, бу эшләр инде аның гадәте шикелле булып китеп, син бер дә зәхмәтләнмәссең.

Һәм ашау тугърысында да шундый ук уртачалык, шундый ук тигезлекне карарга кирәк. Саф, ачык һавада хәрәкәт итү, аның эчендәге ашларны үзгәртеп, бәдәнен куәтләндерәдер вә

*Җисмани вә рухани тарафларыннан* — тән һәм аң ягыннан.
*Бәгъзан* — кайчакта.
*Мөгайян* — билгеле.

күкрәгең җиңелләндерәдер дә, шуның артыннан аның җисеме көчле бер тую сорый башлыйдыр. Әгәр баланың иртәге аш берлә көндезге аш арасында яки көндезге берлә кичке аш арасында ашыйсы килсә, син аңа бер стакан сөт яки һәртөрле яңы пешкән җиләкләр генә бир. Мин синнән тик бер нәрсәдән саклануыңны үтенәм: син Газизәгә хәмер* яки сыра бирә күрмә. Дөрест, аңа иң әүвәлге бер йотымлык хәмер яки сыра зарар китермәс тә, ләкин аның нәфесе, ихтимал, һаман шуларны тели башлап, аның ул ике нәрсәгә якынлашып китү ихтималы бар.

Кызны өстәлгә ни килсә дә шуны ашарга гадәтләндер. Әгәр, мәсәлән, ул бер-бер төрле ашны яратмаса, син аны көчләп ашарга кушма. Шул ук вакытта син аңгар шундыйн башка бернәрсә дә бирмә. Икенче вакытта аңгар ул ашны татып карарга ачлык үзе көчләп кушар. Һәм ул шуны ашарга гадәтләнеп китәр. Балаларны һәрнәрсәгә күндерергә теләгәнеңне алар үзләре сизмәсеннәр. Мәсәлән, бер баланың күңеленә борчак бер дә ошамый. Әллә нигә ул аның төсен яратмый, һәм шуның өчен ашамый. Шул вакытта бу баланың атасы җүри бер тәрилкә борчак боткасы китертә дә шуны бала алдында: «Бу минем иң сөйгән ашым», — дип сөйләнә-сөйләнә ашый. Бала бу сүзне гаҗәпләнеп кенә тыңлап тора да үзе дә әкрен генә борчакны ашап карыйдыр. Вакыйган, борчакта бер дә ул кадәр начарлык тапмый. Шундин соң ул тагы борчак сорый. Шулай итеп, аның борчакка булган нәфрәте бөтенләй югаладыр.

Баштарак сиңа аны һәртөрле тәртипләргә өйрәтергә һәм гомернең дөрест вә тугъры юлына кертү читен булыр. Ләкин син чыдамлыгыңны югалтма: син эшеңдә аягыңны каты басуың вә үз-үзеңне тота белүең илә аңгар бик күп файдалар китерерсең.

## ПАРТИЯЛӘР

«Т» гәзитәсе[1] 38 нче номерында С. Р., С. Д.[2] партияләренең шәргы шәрифкә мөхаләфәтен дәгъва итәдер. Ләкин ни сәбәпле шәргыгә мөхалиф икәнен ачык әйтмидер.

Минем беләсем килә: ул партияләрнең кайсы җире шәргы шәрифкә кире икән? Әллә ислам шәригате ач мужикларга

* Бу, әлбәттә, Европа тормышына карап әйтелгән сүздер. (*Г.Тукай искәрмәсе.*)

*Бәдән* — тән.

*Вакыйган* — чыннан да.

*Шәргы шәрифкә мөхаләфәтен* — кадерле (изге) шәригатькә каршы килүен.

тукларның җирен алып бирмәслек кадәр үк яки эшчеләрнең эш вакытларын кыскартмаслык вә эш хакларын арттырмаслык ук тар микән?

Тагы да «урталар уңнардан гадел, суллардан гакыйль» димештер. Гәзитәнең бу гыйбарәтеннән сулларның уңнардан да, урталардан да гаделрәк булулары аңлашыладыр.

Суллар гадәләт тарафында бик куәтле булулары берлә исламга мөхаләфәт итеп, кадетлар гакыллы хаиннәр булып, исламга муафәкать итәләр микәнни? Алай дигәнчә, бу гәзитә: «Суллар дәгъваләрендә хаклыдырлар, фәкать аларның теләкләре заманыбызда иҗрасе нәмөмкин теләктер», — димәк берлә генә канәгать итсә, яхшы булмасмы иде?

Әгәр суллар, безнең теләгемез булуы бик ерак дип, гомумән, юлларыннан кире кайтсалар, хөррият өчен кемнәр тартышачак? Хөкүмәтне, забастовкалар вә һәртөрле чуалулар чыгарып, халыкның бу ысуле идарәдән наразыйлыгын фигълән күрсәтеп, Дума ачарга мәҗбүр иткәннәре өчен сулларга тәшәккер иделми, кемнәргә иделер? Дума кадетлар аркасында ачылмагандыр бит?! Мин милләтчеләрнең програмы да, кадетларныкы да, сулларныкы да шәргыгә хилаф дип әйтә алмыйм.

Исламның миллиятне сакларга кушуы табигый улдыгы кеби, кызганырга лаек инсаннарны да ифрат дәрәҗәдә кызганырга кушуы да табигыйдер.

Миллият сакларга уңнарымыз, хөррият сакларга сулларымыз да булсын; бу — кяфер, теге — дәһри дип кычкыру «карт мөхәррир»[3] авызына якышмаса кирәк.

Правительствоны сулларның хәзерге тартышулары гына җиңә алмаганы кеби, кадетларның да ялт-йолт икейөзлеләнеп йөрүләре генә җиңә алмаячактыр. Правительствоны анчак гомум халыкның агаруы вә шөгурләнүләре бервакыт үз-үзенә бетерәчәктер.

Кояш бик якты нурын чәчсә, исе чыкмыйча боз астында катып яткан тирес исләнеп, галәме вөҗүдләп галәме гадәмгә* арбалар вә вагоннар илә түгелеп, дөнья пакьләнәчәктер.

Бу исә табигыйдер.

Чын рус кешеләре дә чын. Кадетлар да чын. Суллар да чын.

---

* «Терек дөньядан тарих чүплегенә» мәгънәсендә.

*Гакыйль* — акыллырак.

*Гадәләт* — гаделлек.

*Муафәкать итү* — уңай карау, ярашу-килешү.

*Иҗрасе нәмөмкин* — гамәлгә ашыру мөмкин булмаган.

*Наразыйлыгын фигълән* — риза түгеллеген чынлыкта.

*Анчак* — бары тик.

*Шөгурләнү* — акыл белән төшенү.

Кара кош та оча. Карга да оча. Чыпчык та оча. Черкидә дә канат бар, ул да оча. (Ләкин очу берлә очу арасында фәрекъ бар.) Арысланның гайрәте, төлкенең хәйләлелеге, куянның куркаклыгы, дуңгызның нәҗеслеге бар. Һичберсенә дә ачуланып булмый. Алла шулай яраткан.

Боларның кайсы шәригатькә хилаф?

## ДУМАНЫҢ ХӘЛЕ

Думаның хәзерге хәле мәче тырнагындагы тычкан хәленә бик охшашлыдыр.

Тычканны мәченең бер иркенгә җибәргән булып, тагы барып басканы кеби, бюрократия дә Думада чын хөррият сөючеләрне, сөйләткән булып, сөйләп бетерер-бетермәс шып иттереп басып аладыр.

Мәҗлеснең башлыгы Головин[1] да, «хатын, туныңны ки — мин сине чыбык берлә кыйныйм» дигән мискин ир кеби, үзе чын-чыннан хөкүмәт берлән мөбарәзәгә барган кешеләрнең башы була торып та, «гаскәрия назыйре» кеби бер затның алдында сагыйрь булырга мәҗбүр булды. Головинның бу тәнәззеленең мәҗбүрлек вә зарурәте заманнан улдыгыны мөляхәзә иткәндә дә, итмәгәндә дә, бу эш Думаның шәүкәтен вә мәһабәтен югалтты.

Без Думаны моннан мөкаддәм бер номерымызда да шул ике хайван хәленә охшашлы дигән идек, ләкин хәзер безнең бу тәмсилемездә хаклы икәнемезне Зурабов[2] нотыкы тугърысында булган вакыйгалар бигрәк тә ачык күрсәткәнлектән, янә шул тәмсилемезне тәкрарладык.

Инде хөкүмәткә бер дә тимичә генә яңлыш тиелеп китсә, каршысына тез чүгәргә мәҗбүр булган Думаның дәвам итүе дә, итмәве дә барыбер кебидер.

Бер кеше, комган берлә салкын су алып коенганда, суны тәненә тигезмичә, читкә түккәндин соң: «Әле дә ярый тимәде», — дип куана, имеш. Думаның урта партия кешеләренең хәрәкәте дә шул кешенең коенуы кабиленнән генә булырга охшыйдыр.

---

*Фәрекъ* — аерма.
*Мөбарәзә* — бергә-бер чыгып сугышу.
*Гаскәрия назыйре* — хәрби министр.
*Сагыйрь булу* — кечерәеп калу.
*Тәнәззел* — түбән төшү.
*Мөляхәзә итү* — игътибар белән уйлап карау.
*Шәүкәт* — олылык.
*Мөкаддәм* — алда.
*Тәмсил* — чагыштыру.
*Тәкрарлау* — кабатлау.
*Кабиленнән* — кебек.

Ни булса да, Думаның хәле бик кызганычтыр. Дума ике ут арасындадыр. Хөкүмәт берлә бик каты сөйләшер иде — халык бик кара, халык бик ышанычсыз, хөрриятнең җаннар корбан итәрлек дәрәҗәдә мөкаддәс нәрсә икәнен аңлап җитмәгән. Аңласа да, бик азы аңлаган.

Дума хөкүмәттән халык файдасын яхшылык берлә сорар иде, бу янә дә дошманга: «Абзый! пычагыңны бир әле, мин сине...» — дигән шикелле буладыр.

Дөнья яратылгандин бирле һичкемнең башына Дума башына төшкән кадәр авыр вә мөшкел вә чишүе мөхаль дәрәҗәсендә бер мәсьәлә төшмәгәндер. Дөрест, моны чишәргә имкян бар да, ләкин, ифрат дәрәҗәдә ачы улдыгы кеби, янә ышанычсыз имкяндер.

Нишләмәк кирәк? Нинди тәдбир итәргә кирәк. Будыр ки, бер дәрман бармы?

Бу да «Фикер»нең бер фикередер.

## 4 МАЙ — ҖОМГА

Бу көн мәгариф назыйренең гомуми укыту хакында биргән закон ляихәсе каралды.

Бу закон ляихәсен бер комиссиянең каравына бирергә 198 депутат заявление бирделәр.

Владимир Гисин[1]: «Гомуми укыту гаять мөһим эш. Чөнки безнең Думамыз аның өстенә бина кыйлынган бу яңа стройның нигезе тик гомуми укыту саясендә генә таза вә мәхкәм булачактыр», — диде.

Соңра мәгариф назыйре Думага, үзенең закон ляихәсен галәлгаҗлә мөхакәмә итә башлавы өчен тәшәккер әйтеп, халыкны гомуми укыту, аның сәяси вә икътисади тормышы өчен гаять кирәклеген һәм Русиядә гомуми укытуның соңга калганлыгын, мәмләкәтнең хәзерге хәле вә китеше өчен гомуми укытуның бигрәк тә лөзүмен, вә ул изге эш өчен һичбер төрле акча аямаска тиешлелеген һәм министерствоның бу гомуми укыту тугърысында моңгарча нинди тәдбирләр вә эшләр эш-

*Мөхаль* — мөмкин булмаган.
*Имкян* — мөмкинлек.
*Тәдбир иту* — чара кууру.
*Назыйр* — министр.
*Ляихә* — проект.
*Саясендә генә* — аша гына.
*Мәхкәм* — нык.
*Галәлгаҗлә мөхакәмә итә* — тиз арада, ашыгычлык белән тикшерә.
*Лөзүмен* — кирәклеген.
*Тәдбир* — чара (кору).

ләгәнен вә моннан соң эшләячәген тәфсыйлән бәян итеп, бу закон ляихәсенең Дума тарафыннан һәрничек тизрәк каралып, бу алдымыздагы көзгә бу законның халык вә тормыш эченә идхал ителүе кирәклеген сөйләде.

Мәгариф назыйре, сүзенең хатимәсе уларак, диде ки: «Мәшһүр хәкимнәрдән Әфләтун[2]: инсан фитърәтендә инсафлы вә җуаштыр. Ләкин аны начар вә намөкәммәл тәрбия вәхши хәйванга охшашлы ясыйдыр, димештер. Шуңар күрә барча халык гомуми укыту вакытында балаларына: «Укыңыз, балалар! Үз Ватаныңызның намуслы гражданы булыр өчен, качан ки сез пешкәч, җитешкәч, Ватаныңызның талигын хөкем итәрсез», — диергә тиештер».

Министрның бу нотыкы үзенең фигыленә аслан мотабикъ булмаганлыгы* күренгәч, ораторлар, торып, сүз нәүбәте сорап, языла башладылар.

Суллардан Архангельский: «Министрның бу ляихәсе ачык вә мөкәммәл түгелдер. Шуның өчен бу ляихәне, комиссиягә бирүдән элек, Дума үз күзеннән үткәреп, бу мәсьәләгә Думаның әксәрияте ничек караганлыгын белдереп, комиссиягә бер тарызы хәрәкәт күрсәтү тиеш», — диде.

Бундыйн соң польский депутатлардан Хоминский илә Гралювский гомуми укытуның лябед лязим улып, аның өчен акча аямау кирәк, дип, мәгариф назыйренең сүзен тәкрарласалар да, аның «балалар Ватанның намуслы гражданы булсын» дигән сүзен тәнкыйть итеп: «Хөкүмәт үзе школларга политика кертә», — дип, Польшадагы школларның хөкүмәттән күргән тыгызлыгын сөйләп, мәгариф назыйренең ляихәсен комиссиягә бирүне куәтләделәр.

Депутат Мельников: «Гомуми укыту кирәк, чөнки крәстияннәр моны гаять интизар берлә көтәләр», — диде.

Депутат Мәхмүдев[3], кадетларның предложениеләренә муафәкать итеп**: «Мәзкүр ляихәне комиссиягә бирергә кирәк, чөнки Думаның гомуми заседаниесендә бу мәсьәләне чишү мөмкин түгелдер», — дип, ахырда мөселман мәдрәсәләренең вә мөселман мөгаллимнәренең авыр вә кызганычлы хәлләрен бәян итте.

---

* Чыгышы (рече) үзенең гамәленә (вазифасына) һич тә лаек түгеллеге.
** Тәкъдимнәренә тәңгәл китереп.
*Идхал ителү* — кертелү.
*Хатимәсе* — нәтиҗәсе, йомгагы.
*Фитърәтендә* — кеше тумыштан ук.
*Талигъ* — киләчәк, бәхет.
*Әксәрият* — күпчелек.
*Тарызы хәрәкәт* — эшләү юлы, юнәлеш.
*Лябед лязим улып* — үтә кирәкле булып.

Соңра С.Р.лардан Тигранян, торып, мәгариф назыйренең укыту эшләрен вә бу тугърыда иткән тәдбирләрен бик каты тәнкыйть итә.

Депутат Возначинский (Н.С. һәм үзе әүвәлдә учитель булып торган кеше): «Халык учительләренең хәле бик начар, чөнки хөр фикерлерәк учительләрне школдан куып чыгаралар...»

Пуришкевич моның сүзен кисеп, уңгайсызлый башлагач, председатель, Пуришкевичкә замечание ясап, бу эшеннән туктамаса, залдан куылачагын тәнбиһ итә.

Соңра Хәсәнев[4], торып, бөйлә сөйләде: «Мөселманнар школга булган мәхәббәтләрен бөтенләй югалттылар. Вакыйган, халык аңламаган бер нәрсәне уку безгә бик фәна тәэсир итәдер һәм безгә, учительләргә, ул бик читендер. Чөнки школларны ябарга һәм учительләргә школдан чыгарга лязим булып, образование һаман бездән еракланадыр.

Без, 31 мартның правилосын үзгәртү кирәк дип, министерствога бер генә мәртәбә мөрәҗәгать итмәдек. Безгә: «Бу сезнең ихтыярыңыз», — дип кенә җавап бирәләр. Без, әлбәттә, безнең ихтыярымыз икәнен беләбез, ләкин без миссионерлар күрсәткән юл берлә укырга теләмибез, бәлки үз халкымызның телендә укуны телимез һәм безнең укый торган китапларымызның русча хәреф берлә түгел, гарәп хәрефе берлә басылуын сорыйбыз. Әгәр министерство үзенең 31 март правилоларыннан ваз кичмәсә, ул вакыт барча мөселман авылларындагы школаларның ябылуы вә 20 миллионлык бөек бер милләтнең образованиедән мәхрүм калуы лязим буладыр». (Уңнардан: «Төркиягә барыңыз!» — дигән тавыш чыгадыр.)

Хәсәнев, уңнарга җавап биреп: «Сез безне Төркиягә китәргә мәҗбүр итәрсез», — дип, мөселманнарның таләпләрен игълам итәрәк: «Без һәрбер мөселман авылында мөселманча тел берлә укыла торган школлар булуын һәм учительләрнең камил тәгълимгә маһир кешеләр булуларын телибез. Без рус теле өйрәнүдән һичбер вакытта кире торачак түгелмез, чөнки без беләбез ки, безгә рус телен белү лябеддидер. Ләкин без рус телен кайвакытта күңелемез теләсә, шул вакытта укырга телимез. (Суллар кул чабалар.) Школда бөтенләй ят тел берлә укыту булганда, аңгар ничек халыкның мәхәббәт вә ихласы

---

*Тәнбиһ итү* — искәртеп кую, кисәтү.
*Бөйлә* — болай.
*Вакыйган* — чыннан да.
*Фәна* — һәлакәтле.
*Камил тәгълимгә маһир* — тулы итеп, яхшы укытырга сәләтле.
*Лябеддидер* — котылгысыз, бик кирәк.

булсын? Моның берлә руслар берлә якынлашырга мөмкин түгелдер. Әгәр укытуны үземезнең ана телендә бирергә рөхсәт бирсәләр, без ул вакытта тизрәк якынлашырмыз. Правительство үзенең чыгардыкы ул правилоларыннан ваз кичәргә кирәк. Һәм ул ваз кичәр. Чөнки без бу таләбемездә сәбат вә мәтанәт күрсәтәчәкмез. Вакыйган, борын истибдад (самодержавие) мәхкәм вакытта мондый правилоларны иҗра итәргә* мөмкин иде, ләкин хәзердә конституционный строй...» — дигән вакытта уңнардан депутат Созонович, торып: «Самодержавие хәзер дә бик мәхкәм!» — диде.

Хәсәнев: «Юк, хәзер конституционный строй, самодержавный түгел». Шул вакытта уңнар тарафыннан көчле тавыш; председатель звонить итә. Пуришкевич, кулларын болгап: «Дөрест түгел!» — дип кычкыра. Уңнардан Клиповский әллә ни кычкыра. Уңнар: «Долой оратора!» — дип кычкыралар. Урталар илә суллар ораторны алкышлап кул чабып, уңнарга карап: «Сез — скандалистлар! Бу — провокация!» — дип кычкырып, ораторга карап, сүзендә дәвам итүен үтенәләр. Хәсәнев уңнарга: «Мин кафедрадан сезнең «долой» дигәнеңезгә карап чикелмим», — дип, кафедрадан китәдер.

Соңра председатель, уңнарның өч депутаты Созонович, Клиповский, Пуришкевичне бу көнге заседаниедән чыгарыр өчен, Думага предложение бирде. Дума да бертавыш берлә кабул итте.

Уңнар Думаның хөкеменә буйсынмыйлар, һаман тавышлыйлар, теге 3 депутат та залдан чыкмыйлар. Алар да кычкыралар. Председатель перерыв игълан итә. Перерывтан соңра мәзкүр 3 депутат һаман урыннарыннан чыкмыйлар. Председатель, бу каршылыкны күргәч, Думага бу өч депутатны 15 заседаниедән калдыруны предложение ясый. Мондыйн соң бу 3 сөрелгән депутатлар, председательдән рөхсәт алып: «Безне Дума самодержавный стройны яклап сөйләгәнемез өчен куды», — диделәр.

Председатель боларга: «Юк, сезне Дума ул сүзләреңез өчен түгел, бәлки мәҗлеснең тәртибен боза торган мөгамәлә вә хәрәкәтләреңез өчен куды», — дип җавап бирде.

Председательнең баягы предложениесен Дума кул чабып кабул итте. Тик социал-демократлар гына сөкүт итеп калдылар.

Шул вакыт Пуришкевич утырган җирдән генә: «Мине көч берлә чыгарсыннар, мин үз ихтыярым илә чыкмыймын», —

---

* Элек деспотизм (самодержавие) нык торган вакытта мондый тәртип кагыйдәләрен эшкә ашырырга.

*Сәбат вә мәтанәт* — ныклык һәм түземлелек.

*Чикелмим* — төшмим.

*Сөкүт итү* — дәшми, катнашмый калу.

диядер. Шул вакыт председатель перерыв игълам итә. Перерывтан соң тегеләрнең икесе килмиләр. Пуришкевич тагы урынына килеп утыра. Председатель: «Инде мин, бу Пуришкевичкә көч истигъмаль иткәнче, заседаниене ябамын», — дигәч, заседание ябыладыр. Калган мөзакәрә сиһшәнбә көнгә каладыр.

## ТӘНКЫЙТЬ — КИРӘКЛЕ ШӘЙДЕР

Кеше бер әсәрне болай өсттән генә укып чыккан вакытта, шул әсәрнең иң яхшы вә мәгънәле сәтырлары илә мәгънәсез вә биһудә сәтырларыны тәфрикъ итә алмыйдыр. Әгәр уртадан бер мөнтәкыйд чыгып, шул ук әсәрне иләктән сөзеп чыгарып, яхшысын бер якка, яманын бер якка аерып: «Иштә мөхәррирнең бу сәтырлары шулкадәр гүзәл вә лөзүмледер»; яки: «Бу сәтырларны, бу сәбәпкә бинаән, язмамыш улса гүзәл улыр иде»; яки: «Бу әсәр, бу сәбәпкә бинаән, асла матбугат галәменә чыкмамыш исә гүзәл улыр иде», — җөмләләре кеби сүзләр илә зарифанә вә битарафанә тәнкыйть итсә, табигыйдер ки, бу мөнтәкыйднең тәнкыйте дә әсәрне укымыш адәмнәрнең нәзарына тәсадеф итәчәктер. Бу тәнкыйтьне укыдыктан соңра, әсәрне моталәга итмеш адәм, никадәр хәйран улып тормыш исә дә, фикере тугъры бер мәркәзгә барачактыр.

Тәнкыйть, безем заманыбыз кеби, китаплар, рисаләләр, гәзитәләр, журналлар тагълар кадәр өелеп бармакта улан бер заманда, кирәкле генә дәгел, лябеддә минһедер.

Һәр көн арамызда төрле-төрле яңа исемнәрдә рисалә вә китаплар таралмактадыр, һәрнәрсәнең дә хосулы хәдденнән тәҗавез итсә, табигый, зарарлыдыр. Шуңа күрә безнең дә үз тәнкыйтемез цензорыннан үтмичә, «тисә — тиенгә, тимәсә — ботакка» кабиленнән таралмакта улан әсәрләремез эчендә

*Истигъмаль иту* — куллану.
*Мөзакәрә* — сөйләшү, дискуссия.
*Шәйдер* — нәрсәдер.
*Сәтыр* — юл (язмада, басмада).
*Биһудә* — буш, мәгънәсез.
*Тәфрикъ итә* — аера.
*Мөнтәкыйд* — тәнкыйтьче.
*Иштә* — менә (бу).
*Лөзүмледер* — кирәкледер.
*Бу сәбәпкә бинаән* — шушы сәбәптән.
*Зарифанә вә битарафанә* — матур рәвештә һәм битарафлык белән.
*Нәзарына тәсадеф* — карашына туры килешле.
*Моталәга итмеш* — тикшергән, күздән кичергән.
*Лябеддә минһедер* — котылгысыздыр.
*Хосулы хәдденнән тәҗавез итсә* — җитештерелүе чиктән ашса.

садәдил кариине кирам өчен зарарлылары улуы да ихтималдыр. Мәдрәсәдәге бер максады аслыйга восул өчен генә укылмакта улан нәху, мантыйк гыйлемнәрен шәкертләремез, васита дия генә ышанмак җиренә, әллә ничәшәр еллар илә чуалып, шул гыйлемнәрнең үзләрен максады аслый дия белеп харап булдыклары кеби, безнең дә әдәбият галәмемезгә дә, зыялану вә нурлануны шул тагълар кадәр матбугъ рисаләләр өелүдән гыйбарәт дип белеп, максады аслыйдан мәхрүм калу куркусы бардыр.

Васитаны максудтан тәфрикъ итә алмау, кирәк кем генә өчен булса да, хәвефле бер бәладер. Атлар, арбалар, фәйтуннар инсанның хәрәкәтенә васитадыр. Өйләр, киемнәр дә һава үзгәрүдән сакланыр өчен генә васитадыр. Яхшы аш вә эчемлекләр дә инсанның бәдәненә хезмәтен вә сәламәтен саклар өчен генә файдалы булмаклә анчак васитадыр.

Әгәр инсан шул яхшы ат, яхшы арба вә фәйтун һәм яхшы толып вә туннарга, яхшы йортларга хуҗа булуның үзен яхшылык вә дөньяда торудан асыл максат дип белсә, бу вакытта ул нәрсәләр файдалы булу гына шулай торсын, бәлки зарарлыдыр.

Китап вә рисаләләр таратуның да, нур вә мәгълүмат тарату җиренә, бәгъзан, җәһел вә сүи әхлак тарату тарафы да бардыр. Китаплар вә журналлар таратыр өчен, заманымызда, әлбәттә, нәширләргә, эшләренә көллән муаффәкъ булыр өчен, көллиятле акчаларга ихтыяҗ бардыр.

Китап, гәзитә вә журналларны соратучы халкымызның күбесе кара халык булганга, аларның да ләззәтләнә вә тәм таба торган нәрсәләре түбән вә тупас нәрсәләрдер. Әгәр гәзитә вә журналлар таратылуларында гүзәл нәтиҗәләргә муаффәкъ булыйк, дисәләр, билгеле, аларга да түбән дәрәҗәле, тупас нәрсәләр язып, «мөхтәрәм мөштәриләрнең тәләззезләренчә эш күрергә лязим буладыр. Мин үземезнең арамызда бер журнал, бер гәзитә беләмен ки, болар, тәмам-тәмам шул «мөхтәрәм мөштәриләре»нең теләүләренчә, әдәп таптап, яхшук акчаланып вә файдаланып торалар. Бәлки, алар, үзләренчә, милләткә файда

---

*Садәдил кариине кирам өчен* — хөрмәтле гади укучылар өчен.
*Максады аслыйга восул* — асыл максатка ирешү.
*Нәху, мантыйк* — синтаксис, логика.
*Васита* — чара.
*Инсан* — кеше.
*Анчак*— фәкать.
*Җәһел вә сүи әхлак* — томаналык һәм әхлаксызлык.
*Көллән муаффәкъ булыр өчен* — тәмам уңышлык китерер өчен.
*Көллиятле* — күп, зур.
*Мөштәриләрнең теләззезләренчә* — сатып алучыларның зәвекъләренчә.

итәмез ди торганнардыр: анысы табигый инде. Менә инде шул матбугатта аз булса да хөрриятне сүи истигъмаль итмәсәк, бәлки, эшемез алга китәр иде.

Безнең, мәсәлән, дарелголүмнән яңа укып чыккан бер яшемезгә иң ибтида уларак нинди әсәрләрне укымак кирәк? Моны сайлый белергә, тәнкыйть булмаса, мөмкин түгелдер. Чөнки аңар яхшы рисалә табу бөтенләй борчак басуы өстендә бер билгеләнгән борчакны табу кадәр читендер. Ул әгәр, мәсәлән, ун ел кадәр ни ләкте шуны укып, зиһененә төрле-төрле рәвештә язылган файдасыз рисаләләрнең мәфһүмнәрен урынлаштырса, мондин соң аңар бер файдалы рисалә очраса да, ул аның мәгънәсен йә бөтенләй аңламас, йә һичнәрсәгә дә татбикъ итә алмас. Әгәр бер рисаләне укып та, тиз генә тәнкыйтен дә табып алса, аңар бик уңай буладыр.

Ләкин тәнкыйть итүченең дә кем очрады шул булуы тагы ярамыйдыр. Мөнтәкыйд булыр өчен, әлбәттә, үзләре дә әдәбият галәмендә күп ат уйнаткан тәҗрибәле вә әхлаклы адәм булуы матлүбтыр. Юк исә бер гаразы шәхси илә дә тәнкыйть итүчеләр күптер.

Нә исә, тәнкыйть — кирәкле вә лөзүмле бер шәйдер. Әфкяре гомуми берлә уйнарга ярамый.

---

*Сүи истигъмаль итмәсәк* — урынсыз файдаланмасак.
*Дарелголүмнән* — университеттан.
*Ибтида* — башлангыч.
*Мәфһүмнәрен* — мәгънәләрен.
*Татбикъ итә* — яраштыра.
*Матлүбтыр* — таләп ителәдер.
*Гаразы шәхси* — шәхси файданы күздә тоту.
*Әфкяре гомуми* — гомум (җәмәгать) фикере.

# 1908

## БӘЙРӘМ, БЕЗ ВӘ РУСЛАР

Безнең милләтнең бәйрәме ел тәүлегенә анчак ике генә дәфга буладыр.

Димәк, без бик эшчән, тырышчан бер халык икәнбез. Чөнки ел буе дөньяның һәртөрле авырлыкларын, михнәтләрен күтәрәмез дә, шул авырлыкларны өстемездән ике тапкыр гына төшереп, тынычлап торабыз.

Дуст-ишләремез, кардәш-кабиләләремез илә күрешергә вә йөрешергә дә вакытымыз булмый, имеш. Безгә муллалар: «Дөнья кумагыз! Дөнья кумагыз!» — дип, никадәр кычкырып вәгазь әйтсәләр дә, тыңламыйбыз, имеш. (Бездә җомга көннәргә дә бер дә игътибар юк: ул көннең бәйрәмлеге бер дә күңелдән хис ителми; халкымыз бүген җомга, бүген бәйрәм дип, яңа киемнәр киеп, руслар якшәмбене олугълаган кеби олугъламыйлар; тик шунда татар кибетләренең ябыклыгыннан гына бу көнгә бер үзгәреш килә.) Кибетчеләрдән башка мөселманнар (мин складларга күз салмыйм әле) һаман эшләрендә. Безнең ватандашларымыз русларның атлаган саен бәйрәмнәре була. Алар, якшәмбене чынлап бәйрәм итдекләре кеби, әллә нинди исемнәр илә әллә нинди бәйрәмнәр итәләр. Хәтта бер юморист: «Ел тәүлегендә 365 көн була, руслар 300 көн бәйрәм итәләр, 65 көн эшлиләр», — дисә, бу сүз бөтенләй үк көлкегә охшап бетмәячәктер.

Моннан русларның ялкау, эшсез вә бөтен гомерләрен уйнап-көлеп үткәрүче бер халык икәнлеге, безнең исә кәеф, хозур вә тәгътилләргә әһәмият бирми торган булуымыз күренәдер. Соң, без күп эшләгәч, алар күп кәеф сөргәч, безнең алга баруымыз, аларның артка калулары тиеш ләбаса!

Хакыйкатьтә нидәндер болай түгел: без һаман артта, һаман фәкыйрь, һаман сәфилбез. Без шул инә берлә кое казыйбыз, руслар — машина берлә. Без төя җигеп барабыз, алар локомотив җигәләр. Алар воздушный шарлар берлә очалар, без, җилкәләремезгә мунча себеркеләре бәйләп, куллар селкетеп торабыз.

---

*Анчак* — фәкать.
*Дәфга* — тапкыр.
*Тәгътил* — ял иту.
*Сәфилбез* — түбәнбез.

Алар мәгыйшәт сәфәрендә бергәләшеп бер йөк тартып алып бармакчы булсалар, һәммәсе дә алга тарталар; без, йөкне төрлебез төрле якка тартып, һаман бер урында әйләнәбез. Безнең бәгъзе аңлыракларымыз алга таба атламакчы вә йөкне дә алга җибәрмәкче булсалар, аларның аякларына «чалма» дигән әллә нинди чуалчыклы тамырлар чолганып, алар җыгылалар. Руслар үз милләтләренең рухларын һаман алга алып баручы гаскәрләргә (шәкертләргә) тәмле вә ләззәтле ашлар ашатып, татлы ширбәтләр эчертәләр, без шул гаскәрләрнең мигъдәләрен мышаяклар, һәртөрле кирпеч ватыклары, чүлмәк китекләре, үлгән чебеннәр, тараканнар, мәче койрыклары белән тутырабыз. Безнеңчә, мигъдә тулгач, бары да бер!

Безнең эшләр һаман аларга кире: без кыш көне — арба, җәй көне чана җигәбез; аларның суда кимә берлә барганыны күреп, без коры җирдә көймә җөргезмәкче булабыз, ишкәкләр берлә ишеп, туфрак очырабыз.

Мәгыйшәт сәфәрендә безгә зур сулар очраса, без су өстенә намазлыклар, чапаннар җәябез, алар тимердән күперләр салалар.

Без иске, керле, каралган киемнәремезне бер дә салмыйбыз. Шул сәбәпле бетлибез, юл өстендә изүләрдән, ыштан бөрмәләреннән бетләр чүпләп утырабыз: тагы артка калабыз. Алар атна саен вә хәтта ике көнгә бер кием алыштыралар.

Ләкин без бер дә тик тормыйбыз, ел буе эшлибез дә эшлибез. Алар нишлиләр соң? Алар, юморист (көлдергеч) әйткәнчә, 300 көн кадәр бәйрәм итәләр. Бәйрәмнәрендә гүя безнең югарыда сөйләнгән комедияләремезне карап, рәхәтләнеп көлеп торалар; тәмам көләселәре килми башлагач, туйгач, 65 көн бер дә безгә илтифат итмичә эшлиләр. Без нишләгәнмез? Без ел буе аюның дуга бөгүе кеби эшләгәнбез. Ягъни без эшләү сурәтендә тәмам 365 көн уйнаганбыз да, инде уйнап арып, ял итәбез. Безнең эшле көнебез дә көлке, бәйрәм итүебез дә көлке. Безнең бәйрәм итәргә хакымыз юк.

Бәйрәм дип, күбрәк вакытта бер замандагы алга барышны искә төшереп тәбрик итүгә әйтеләдер. Безнең һаман бер көпчәк әйләнәсендә әйләнүебезгә алга бару дип әйтеп булмый, ерак киттек дип, үзебезне үзебез тәбрик тә итеп булмый.

Ярар инде. Бүген бәйрәм көн. Мондый кайгылы уйлар уйлап маташырга миңа да килешми, укучыга да күңелсез. Әйдәгез, корбан итенә җитешеңез! Гайде сәгыйд котлы вә мөбарәк булсын!

---

*Мәгыйшәт сәфәрендә* — тормыш юлында.
*Мигъдә* — ашказаны.
*Гайде сәгыйд* — бәхетле, шатлыклы гает (бәйрәме).

## АВГУСТ БАШЫ

Көн караңгы. Бөтен дөньяны кара кайгы болытлары каплаган. Шул вакытта Казанда дәһшәтле «Яшен» күз камаштыра торган якты нурлары илә ялтырый. Ялтыраганыны күреп, хыянәтләренә яшерергә тырышып йөрүче хаиннәрнең, «Яшен» сугудан куркып, бөтен вөҗүдләре калтырый.

«Яшен» — хаиннәр өчен афәттер.

«Яшен» — яхшы күңелләр өчен рәхәттер.

«Яшен»нең ялтыравы һәркем өчен бертигез булган шикелле, сугуы да һәрбер явыз җанлы өчен бертигездер.

«Яшен»нең сугуыннан милләт җилкәсенә кимерүче профаннар, үзене шәп кеше итеп йөрүче саламторханнар, җәмәгать хакына кул сузган куштаннар, һәрбер сорыкорт дошманнар, мәктәп-мәдрәсәләрне бикләп, ялкауланып ятучы муллалар, эшсез ятучы мирзалар, хыянәтче байларның һичберсе әмин дәгелләрдер.

«Яшен»нең юлы тугърыдан-тугърыдыр, сугуы электрик зарбәседер.

«Яшен» профан, саламторхан вә хаиннәрне үзенең сугуы илә куркыткан шикелле, караңгыда адашып калганнар өчен үзенең яктылыгы илә юллар күрсәтәчәктер.

Ялтырый милли болытларның арасыннан «Яшен»;
Бәлки, рәхмәт яңгырыдыр — яшьнәсен ул, яшьнәсен.
Юл табар золмәттә калганнар — төшерсен шәүләсен;
Таш йөрәкләр һәм «Яшен» күргәч укыр «ләхәүлә»сен.

## ЯҢА ГӘЗИТӘЛӘР

Казанда иске-москылар илә кәсеп итүче талчокчыларның һәм Печән базары урамнарында җил вә һава илә сату итүче вәисиләрнең үзләренә махсус берәр гәзитә чыгарырга йөрдекләрене «Яшен» идарәсенә хәбәр бирәләр.

Талчокчыларның гәзитәсе — «Шурум-бурум», вәисиләрнеке «Мөҗаһидел ислам фиркаи наҗияэл мөэминин әлмисактан бирле мөселман»* исемле булачак, имеш.

---

* «Ислам динендәгеләрне коткару өчен сугышучы, яратылышыннан бирле мөселман булган партия».

*Вөҗүдләре* — эч һәм тышлары.

*Әмин* — тыныч, имин.

*Зарбә* — сугу, удар.

*Золмәт* — караңгылык.

*«Ләхәүлә»сен* — курыкканда укый торган догасын.

## КАЗАНДА БАЗАР БӘҺАЛӘРЕ

Печән базары мәсҗеденең кыйммәте яхшы. Хәердар муллалар бик күп. Араларында узышулар булачактыр. Кемнең үлчәве җиңелрәк булып беренче килсә, мәсҗедкә хуҗа булачактыр.

### БӘДӘЛЧЕЛӘР БАЗАРЫ

Бу ел бәдәлчеләр уңган. Печән базарында төркем-төркем йөриләр. Ләкин мөштәриләр азрак күренә, бу хисаптан бәһаләре арзан булырга охшыйдыр.

### МӨХӘРРИРЛӘР БАЗАРЫ

«Әхбар» ябылганнан бирле мөхәррирләрнең курсы бераз төште. «Бәянел хак»тан башка мөштәри хәзергә күренми. Ул да комиссиягә генә ала.

Шулкадәресе шаян тәшәккердер ки*, һич талымламый.

## ТӨРЛЕЧӘ ДӨНЬЯ ТАНУ

Татар хатыннарыча:

Дөнья бер җефәк күлмәктер. Кояш илә ай икесе дә ике книтилле калфаклардыр. Татар хатыннарының һәрберсе шул калфакларны кимәк арзусындадырлар.

Мулла вә хәзрәтләрчә:

Дөнья бер шурпалы бәлештер ки, диңгезләр шул бәлешнең шурпасыдырлар. Төбендәге балыклар исә бәлешнең ит, дөге вә җимешләредер. Кояш илә ай байлар тарафыннан аларга сузылган һәм тиздән биреләчәк берәр тәңкәлек көмеш акчалардыр.

«Дингә мишәйт»челәрчә[1]:

Дөнья бер кантурдыр ки, анда Вәли мулла һәм Ф.Сәймани кеби иске мунча фәрештәләре адәмиләрнең көфер вә иманын язарга вә пичәт басып торырга мәэмүр улмышлардыр.

---

* Шуңа да рәхмәт.

*Хәердар* — хәер өләшергә яратучы.

*Бәдәлче* — акчага ялланып, кеше өчен хаҗга баручы.

*Мөштәри* – сатып алучы, ялланучы.

*Книтилле (кәнитилле)* — вак тәңкәләр тезелгән.

*Арзусындадырлар* — теләгендәләр.

*Көфер вә иманын* — Аллага ышану-ышанмавын.

*Мәэмүр* — чиновник.

Цензорларча:

Дөнья зур бер язма китаптыр ки, кояш илә ай шуның ярамаслык җирләрен карап торалар* (Ашмарин[2]).

Социалистларча:

Дөнья бер хәбесханәдер ки, кояш илә ай — алмаш-тилмәш хәбесханә тирәсендә әйләнеп йөргән сакчы солдатлардыр.

Мөхәммәтгали шаһча[3]:

Дөнья Ляхов[4] җәнабләре ихтыярында булган бер нәрсәдер ки, ул бозса — боза ала һәм төзесә — төзи ала. Кояш илә ай икесе дә караңгы нәрсәләр булып, нурны Мөхәммәтгали шаһ таҗындагы кыйбатлы бриллианттан гына алып торалар**.

## ХИКӘЯ

Алпавытның һич тә дөньяда булмаган сыйфатта алтын башлы, алтын сачлы баласы дөньяга килде.

Алпавыт семьясы үзләренә килгән кунакларга һәрберенә бу баланы күрсәтәләр вә дөньяга каршы гүя аның илә ифтихар итәләр иде.

Баланың атасы, анасы, агасы, апасы, даясе — һәммәсе дә аның ни берлә вә ничек уйнаганын дикъкатьлечә тикшерәләр һәм шуннан баланың зурайгач кем булачагына вә ни кәсеп итәчәгенә хөкем итәләр иде.

Әгәр бала кайчакта шаярып, чүкечне вә йә лампа пумаласын камырга яки катыкка манып, гүя язу язган кеби, идәндәге кыйбатлы паласларны пычратса, атасы: «Бу бала, шөбһәсез, дәвәйгәч, «Чүкеч» мөхәррире[1] булыр», — дия хөкем итә иде.

Кайвакыт бала үзенең кәгазьдән ясалган кечкенә уенчык өен иптәш балаларының берсенә тотып торырга биреп, бераздан аннан алып, икенчесенә, янә шул ук өйне, аннан да алып, өченче, дүртенче, бишенчесенә биреп уйнаса, анасы: «Бу бала, шөбһәсез, «Бәянел хак» нашир вә мөхәррире[2] булыр», — дия кисеп куя иде.

Әгәр кайвакыт бала иптәш балаларына яисә үзеннән берничә яшь зуррак кыз балаларга: «Мин тәти бит, ә?» — дип

---

* «Минем фикеремчә исә, дөнья бер китаптыр ки, басылып чыгарылган вакытта мөсадәрә кыйлынган булса иде, йә гүзәл булыр иде». (Ашмарин.) *(Г.Тукай искәрмәсе.)*

** Әлбәттә, Мөхәммәтгали төшмәс борын язылган иде. *(Г.Тукай искәрмәсе.)*

*Хәбесханә* — төрмә.

*Ифтихар итү* — мактану.

*Дая* — бала караучы, няня.

*Мөсадәрә кыйлынган* — конфискацияләнгән.

сөальләр бирсә, апасы шундук: «Бу энем, Алла боерса, Сәгыйть Рәмиев кеби поэт булыр», — дип, алдан хәбәр бирә иде.

Әгәр сабый бала күкрәгенә кечкенә колоколлар вә тәти калайлар тагып уйнаса, агасы: «Бер дә шиксез, минем энем Буага мөдәррис вә дамелла[3] булыр», — дип өзеп үк әйтә иде.

Әгәр бала гакылсызлык белән кулындагы «Иман шарты»н ертып, чәйнәп ташласа вә аяк астына салып таптаса, даясе: «Ай бәбкәм! Син, Ходай кушса, дәү булгач, Кәҗә Якуб[4] булырсың, җәме!» — дип, баланың авызыннан үбеп ала иде.

## ЛӨГАТЬЛӘР

*Мәсҗед* — муллаларның өч ишекле кибете.

*Мәдрәсә* — хатынсыз яшьләрнең кыш уздыру өчен җыелып ята торган фатирларыдыр.

*Мәктәп* — кара өй. Ләкин мужикларның кара өйләреннән бераз аермасы бар: мужикларның кара өенә бәрәннәр вә бозаулар ябалар, мәктәптә исә адәм балалары яталар.

*Хәлфә* — камчы вә кәвешкиләр илә балаларның сыртларыны яручы.

*Мөәззин* — фидия вә фитыр бәрабәренә ялланган мәсҗед сторожы.

*Бай* — Мәскәүдән, яхуд башка бер урыннан көтәргә мал ала белүче кеше.

*Корсак* — кеше хакыны җийәр өчен булган бер аппарат.

*Ишан* — Алла илә бәндә арасында васита булып, алдан хәбәр бирүче бер кеше.

*Бохари* — зур чалма киеп, әфьюн ашап, вак салучы.

*Мөҗавир* — Русия мөселманнарының акчаларыны аулаучы Хиҗаз мәчеләре[1].

*Хафиз* — унбиш-егерме сумга ялланып, мәсҗед саен хәтем әйтеп, Коръән сатып йөрүче.

*Зәкят* — малның кере. Шуның өчен һәрвакыт зәкяткә көйгән, черегән, тутыккан, ватылган һәм җимерелгән нәрсәләр генә биреләдер.

*Кредит* — сумына ун тиен, егерме тиен түләү нияте илә мәскәүләрдән бурычка алынган маллар.

---

*Лөгатьләр* — сүзләр (сүзлек).

*Васита* — ике арада йөрүче, арадашчы.

*Вак* — насбай (тел астына сала торган тәмәке).

*Мөҗавир* — кабер сакчысы.

*Хафиз* — Коръәнне яттан белүче.

*Фанатик* — ишаннар тарафыннан күзләре чыгарылган сукырлар.

*Интеллигент* — кием калыбы.

*Бутишник* — Казан татарларының бик курка торган бер затлары.

*Көтепханә* — Казан татарларының фаразынча, эшсез кешеләр кереп утыра торган бер урын.

*Зурлар* — Казанның Печән базарында кибете булган кешеләр.

*Гласный* — мәгълүм бер көндә, билгеләнгән бер сәгатьтә шәһәр Думасы залына җыелып, руслар сөйләгәнне тыңлап яки алар сөйләгәндә йоклап утырып, руслар эшләгәнгә пичәт басып утыручы Казан татарлары.

*Казан татары* — гайбәт белән көн уздыручы кеше.

*Татар кибетчесе* — кибеткә кергән бер алучыны сүгеп чыгарырга ялланган кеше.

*Татар хатыны* — ирләрне борчыр өчен яратылган мәхлуктыр.

*Галим* — «Сөлләм», «Казый»лары илә «Шәрхе мәвакыйф» шикелле схоластикаларны күңелдән белеп, фәтва китапларыны ялгыш-йолгыш моталәга кыйлырлык дәрәҗәдә гарәпчә грамотный булган кеше.

*Татар кызы* — берни белмәс, дөнья күрмәс бер мәхлук.

*Асрау* — татар байларының гайре рәсми кече хатыннары. Өмме вәләд булганнан соң гына рәсмияткә чыга.

*Кәләпүш* — мөселман икәнлекне белгертер өчен киелә торган мәҗүс каләнсәвәсе.

*Кәвеш* — ягъмурлы көннәрдә өсткә былчырак чәчрәтер өчен эшләнгән аяк киеме.

*Чапан* — тартып-сузып ирләргә киюе дөрестлек илә фәтва бирелгән җефәк кием.

*Бүрек* — карга оясы.

---

*Бутишник* — постта торучы полицейский; урам чатларында будкасы булганга «бутишник» дип атаганнар, ягъни будка хуҗасы.

*Гласный* — шәһәр Думасы члены.

*Моталәга кыйлырлык* — аңларлык.

*Гайре рәсми* — законлашмаган.

*Өмме вәләд* — бала анасы.

*Мәҗүс каләнсәвәсе* — мәҗүсиләр бүреге.

*Фәтва* — нәрсәне дә булса раслау яки кире кагу турында әмер.

## ЧЫБЫКСЫЗ ТЕЛЕГРАМ ХӘБӘРЛӘРЕ

ҮЗ МӨХБИРЛӘРЕМЕЗДӘН

Фас: Фас халкы бер җиргә җыелып, Мәүла Хафизны, яхуд Мәүла Габделгазизнеме солтан итеп куярга тиешлеге хакында киңәш итештеләр. Ахырдан, икесене тәмам хәлдән тайганчы сугыштырып, кайсы җиңсә, шуны куярга карар бирделәр.

Оренбург: Мәдрәсәи Хөсәениягә яхшы мөгаллимнәр китерелә дип реклам таратылып, акчалар җыелган булса да, көз көне саный башлагач, чебешләрнең саны чыкмады. Бәгъзе фәннәрне укытырга мөгаллимнәр булмадыкыннан 33 шәкерт, биргән акчаларыны кайтарып алып, мәдрәсәне ташлап качтылар.

Мәдрәсә авыруы бу ел Оренбургка күчкән икән.

## КЕМНӘРНЕҢ НИ ДИСӘҢ КОТЛАРЫ ЧЫГА?

Баланың — «Бүкәй килә» дисәң; муллаларның — «Указыңны алалар» дисәң; байларның — «Җәмгыяте хәйриягә акча сорыйлар» дисәң; «Башка милләт»нең — «Япон килә» дисәң; мөәззиннең — «Быел берәү дә үлми» дисәң; социалистларның — «Околодочный килә» дисәң; татар шәкертенең — «Тәмәке тартканыңны фәлән хаҗи күргән» дисәң; төрекләрнең — «Аксак Тимер гаскәре килә» дисәң; Морат вә башка бәдәлчеләрнең[1] — «Хөкүмәт наемщикларны бетерергә кушкан» дисәң; татар хатынының — «Ирләр күрә ич» дисәң; Тимершаһның[2] — «Көлке журналы чыгаралар» дисәң; Мөхәммәтгали шаһның — «Ляховны Русия хөкүмәте кире алдыра» дисәң; Сәйдәшевнең — «Игълан бирүчеләр «Бәянел хак» татарның «Русское слово»сы түгел икәнен белгәннәр инде» дисәң; Һади Максудиның — «Мөгаллиме әүвәл»еңне[3] бер көтепханә урлап бастырган» дисәң; пьянчукларның — «Аракы аптекларда гына сатылачак» дисәң; авыл мужикларының — «Муллаңызга Казаннан әллә нинди сурәтле китаплар килгән» дисәң; Яурупа дөвәле могаззамәсенең — «Бөтен дөнья мөселманнары панисламизм юлы белән хәрәкәт итәләр һәм сез белгәнне белергә бик каты тырышалар» дисәң; Йосыф Акчуринның — «Рисаләңә яңлыш бер татарча сүз кергән» дисәң[4]; Пуришкевичнең — «Русиянең барча гайре рус әһалисе вә хосусән яһүдиләр, руслар илә бер хокукта булып, чын Русия гражданнары булдылар инде» дисәң.

---

*Околодочный* — полицейский.

*Дөвәле могаззәмә* — бөек дәүләтләр.

*Рисалә* — китап, әсәр.

*Гайре рус әһалисе* — руслардан башка халыклар.

*Хосусән* — бигрәк тә.

# ТӨРЛЕ ХАЙВАННАР ТУГЪРЫСЫНДА БЕРАЗ МӘГЪЛҮМАТ

(«ХӘЯТЕЛ ХАЙВАН»НАН)

Тутый. — Бу хайван «Кәримев, Хөсәенев» матбагасында хәреф кассалары астында, кургашын исе арасында мәгыйшәт итәр.

Башлыча тереклек итә торган ашы «кешедән ишеткәнне кат-кат чәйнәү» нам бер үләндер. Үзе мәче нәселеннән булып, бәгъзан «йоклаган милләтләр» башы очында вә очырмаларда мыраулап йөргәнен ишетергә мөмкиндер.

Мулла Ш.К.[1] — Бу хайван Җаекъ нәһре буенда Оренбург шәһәрендә мәгыйшәт итәр. Башлыча тереклек итә торган ашы «Чүкеч сабы» нам бер үләндер.

Бу хайван, үлән ашаганына карамаенча, бер тарафтанерткучы дадыр. Фәкать шунысы бар: аның бер-бер җан иясенә ерту нияте илә һөҗүм итеп тә, аз гына да булсын җәрәхәтли алганын ривайәт итмиләр. Аның ерткучылыгы анчак шул габәс омтылуы җәһәтеннән генәдер. Күбрәк һөҗүме инсафлырак мөхәррирләргәдер.

Гыйбраһим[2]. — Бу хайван, йорт хайваны булса да, күчмә мәгыйшәтне сөя торган бер хайвандыр. Шәйлә ки: ул бүген Петербургта, иртәгә Сибириядә, берсекөнгә Истанбулда яки Казан вә Уфада буладыр. Үзе җуаш вә «өлфәт»ле хайван булып, кешеләр вә галәлхосус байлар кулына ияләшүчән буладыр.

Башлыча тереклек итә торган ашы «мәсләксезлек» нам бер «яшел» үләндер. Рәсеме беренче номер «Яшен»дә дәреҗ ителмеш иде.

Минһаҗел Һинди[3]. — Бу хайван күркә нәүгыннән бер коштыр. Хвалын өязендә мишәр карьяләре тирәсендә күбрәк буладыр.

---

*Хәятел хайван* — хайваннар дөньясы.
*Мәгыйшәт итү* — яшәү.
*Нам* — исемле.
*Бәгъзан* — кайчакта.
*Җаекъ нәһре* — Урал елгасы.
*Ривайәт итмиләр* — сөйләмиләр.
*Анчак* — фәкать.
*Габәс* — бушка.
*Шәйлә ки* — менә болай.
*«Өлфәт»ле* — кулга ияләшүчән, сөйләшүчән.
*Галәлхосус* — бигрәк тә.
*Дәреҗ ителмеш* — кертелгән, басылган.
*Нәүгыннән* — төреннән.
*Карья* — авыл.

Башлыча тереклек итә торган ашы «Дарелфөнүн саламы» нам бер үләндер. Гәүдәгә таза булса да, зарарсыз гына бер мәхлуктыр.

Кәҗә Аякыф[4]. — Бу хайван Казанның Яңа бистә ягында мәгыйшәт итеп, башлыча тереклек итә торган ашы «Бәдьэл мәгариф» нам бер үләндер. Күп вакытта мәдрәсәләргә кереп, осуле җәдидә китапларын ашап чыкканын ривайәт итәләр.

Рәсеме киләчәк номерга дәреҗ ителер.

## МИН ШУШЫЛАР ИЛӘ МИЛЛӘТЧЕ

1) Шакир Хәмитев[1] шырпысы илә генә тәмәке тартам.

2) Тәмәкенең дә «Госманлы сигарасы» исемлесен махсус Истанбулдан алдырам.

3) «Исмәгыйль Гаспринский сабыны» илә битемне җуам.

4) Шул кешенең үк канфиты илә чәй эчәм.

5) «Новое время»гә каршы пешмәгән мәкаләләр язудан артык хасияте булмаса да, әлбәттә, әлбәттә, «Вакыт» гәҗите укыйм.

6) Мөндәриҗатыннан Кара диңгез ары ягы исе генә чыгып, фи хәдде затиһи ялган татар журналы гына булса да, «Шура»сына да акча түлим.

## ТӨШЕМДӘ КҮРГӘННӘРЕМ

Иртәгә «Яшен» чыгасы дигән көнне кич йокыга яткан идем.

Шул кичне йокымда, дулкын артыннан дулкын килгән кеби, миңа да төш артыннан төш күренде дә торды.

Шәйлә ки: өч минут йоклыйм да бер төш күрәм, биш минут йоклыйм да тагы бер төш күрәм — тәмам аптырап беттем.

Төшемдә күргәннәрем арасында үземчә кызыклы вә, аз булса да, көлкеле дип белгәннәремне менә бу номеру «Яшен»гә бастырам, ахры.

### *Беренче төшем*

Төшемдә җәннәтел фирдәвеснең эчен күрдем. Һәр тараф нур. Стеналар да нурдан, түшәмнәр дә. Җанлылар да нурдан, җансызлар да. Хур кызлары да нурдан, вилдан вә гыйльманнар да[1].

---

*Дарелфөнүн* — югары уку йорты, университет.

*Бәдьэл мәгариф* — мәгърифәт башлангычы, башлангыч белем.

*Мөндәриҗат* — эчтәлек.

*Фи хәдде затиһи* — заты, үзе.

*Җәннәтел фирдәвес* — оҗмах.

Бер тарафта балдан вә сөттән гыйбарәт Кәүсәр елгасы[2] агып ята. Икенче тарафта зифа вә мәһабәт буйлы туба йыгачлары үсеп утырмакта. Һавада кәбаб булып пешкән матур-матур кошлар, һәрбере: «Мине ашагыз, мине ашагыз!» — дип кычкырып очып йөриләр. Болар тавышлары илә яшел ефәк киемле оҗмах әһелләренең колакларыны шаулаталар.

Боларны күрдем; соңра күземә кып-кызыл якуттан салынган бер хөҗрә күренде. Хөҗрәнең ишеге алтын илә йолдызлы-йолдызлы итеп нәкышләнгән хәрир чаршау илә капланган. Мин, хөҗрәнең эчендә кем бар икән дип, чаршауның бер читен әкрен генә ачтым. Ярыктан карасам, анда мәрхүм Әхмәт бай[3] утыра. Янындагы наз вә нигъмәтенә, хурларның әллә нинди, йөрәкне өзеп китә торган сәмави вә илаһи тавыш илә җырлауларын һич тәгъриф итеп бетерә алмыйм.

Бәс, хөҗрәдәге Әхмәт байны мин дөньяда замандук танырганга, чаршауны ачып җибәреп: «Әссәламегаләйкем!» — дип сәлам биреп, эчкә кердем. Әхмәт бай җәнабләре үзенең гарык булдыгы тәләззез вә рәхәт эченнән башын күтәрде дә, миңа озын мөддәт тегәлеп карап торгач: «Вәгаләйкем әссәлам!» — диде. Исәнме-саумыларны кат-кат әйтешкәч, ул миңа урын күрсәтте. Мин дә алтын-көмеш сәрирләрнең берсенә утырдым.

Утыргач, арамызда бәр вәҗһе ати мөкяләмә башланды:

— Син дөньядан килдеңме әле?

— Әйе, дөньядан, бай абзый.

— Безнең Орынбур ни хәлдә?

— Орынбур әүвәлгечә, үзгәреш юк.

— Ничек юк?

— Ягъни һаман син киткәндәге рәвештә; мәсәлән, «Вакыт» һаман «Новое время» илә кычкырыша, «Чүкеч» һаман сүгенә.

— Мин балаларыма, кыямәт таңы атканчы җитсен дип, һәртөрле азыклар калдырган идем. Шул ничек, җитәрлекме? Черемиме? Күселәр, тычканнар ашамыймы?

— Ул нинди азык?

— Әй ахмак! Мин дөньяда вакытымдук киная белән сөй-

---

*Кәбаб булып* — кыздырылып.
*Хөҗрә* — бүлмә.
*Хәрир* — ефәк.
*Сәмави* — күккә хас, гаҗәеп.
*Тәгъриф итү* — аңлатып, сөйләп бирү.
*Гарык булдыгы тәләззез* — ләззәт, татлылыкка чумган.
*Озын мөддәт* — озак кына.
*Сәрир* — тәхет, урындык.
*Бәр вәҗһе ати мөкяләмә* — нәкъ түбәндәгечә сөйләшү.

ләргә ярата торган идем; шуны да аңламыйсыңмы? Үз исемемә салдырган Мәдрәсәи Хөсәенияне әйтәм.

Хәзер мин, Әхмәт байның киная сөйгәнене аңлагач, үзем дә бер нәүгы киная иләː

— Әйе, әйе, син калдырган азык өстендә ак башлы күселәр, тычканнар күп күренә; ахрысы, ашый торганнардыр.

— Ә Мәмдүх бай[4] ни эшләп йөри, ул ни карый?

— Ул да шул, төнлә сәгать 3тә рестораннан чыгып: «Менә бу минут минем үземә махсус трамвай килсен, хәзер 2 мең тәңкә бирәм», — диеп, гайрәт вә һиммәт күрсәткән кеше төсле, җөри шунда һиммәтләр күрсәтеп.

— Ә «Вакыт» мөхәррире[5] үз гәзитәсендә шул тычканнар вә күселәргә каршы бер-бер тәдбир күрсәтмиме? Мин дөньяда вакытымда аңар ихсаннар иткән идем. Ул миңа миннәтдар иде. Лязим вакытта, мин үлгәч, минем азыгымны саклаудан да кире тормаячак иде, ул ни эшләгән?

— Казанның сулрак гәзитәләре вә Орынбурның «Чүкеч»е: «Тычканнар вә күселәргә бер-бер тәдбир итәргә кирәк. Аларны тәмам һәлак итәргә кирәк», — дип сөйлиләр дә, «Вакыт» мөхәррире аларга каршы: «Сез вөҗданны үзеңездә генә дип беләсезме, ул ак башлы тычканнарда намус вә вөҗдан кисәге юкмыни?» — дип игътиразлар итә. Хәтта шуларны мөдафәга иткән мәкаләсенә чын үз имзасын куя.

Тычканнарга җил дә тиерттерми. Сез тактикасызлар, фәлән-төгән, ди.

Сүз шул җирдә икән, уяндым.

### *Икенче төшем*

Төшемдә мәрхүм Мөхәммәтзаһир Бигиевне[6] күрдем.

Мәрхүм уртача гына зурлыкта бер сарайда, имеш, дим. Сарай тактадан эшләнгән. Түшәм такталарына күзем салсам, аның һәр тактасына «Гөнаһе кәбаир» дип алтын илә язылган. Идәнен карасам, аның да һәр тактасына «Өлүф, яхуд Гүзәл кыз Хәдичә» дип язылган. Соңра 4 як стенаны да карадым.

---

*Бер нәүгы* — бертөрле.

*Һиммәт* — кызу дәрт; бу урында «бозыклыкка, фәхешкә атлыгып тору» мәгънәсендә.

*Тәдбир* — чара.

*Ихсан* — ярдәм, яхшылык-изгелек.

*Миннәтдар* — мораль бурычлы, рәхмәтле.

*Игътираз итү* — бәхәскә керү, каршы килү.

*Мөдафәга итү* — яклау.

Стенасы яңарак кына ясалганга охшап, һәрбер тактасына «Мавәраэннәһердә сәяхәт» дип язганнар.

Мәрхүм шул сарай уртасында, бер кечерәк кенә өстәл янындагы урындыкка күзен түбән салып, кәефсез бер кыяфәт илә генә утырган.

Мәрхүм шулкадәр күңелсез булырга кирәк ки, мин ярты сәгать кадәр үзен тамаша итеп торганчы күрмәде.

Бераздан башын күтәргәч, мине күрде: «Ә, исәнме, әфәнде, син дөньядан килгәндерсең?» — диде.

Аның шул сүзеннән соң безнең арабызда түбәндәге сүзләр башланды:

— Ник, бу ахирәтмени әле? Миңа дөньядан килгәндерсең дидегез?

— Әйе, ахирәт; бу — минем ахирәттәге сараем.

Шул вакыт мин карап күрдем ки, сарайның түбәсендә ачык урын бар. Әгәр шулар ямалса, сарай булачак. Заһир әфәндедән мин моның сәбәбен сорамыйча, эчемнән генә тындым.

Соңра ул, сүзгә башлап:

— Минем «Мөртәт» илә «Катилә»м басылдымы әле?

— Юк.

— Ник юк? Мин ахирәттә булсам да, дөньядан мин китеп, берничә еллардан соң хөрриятләр булган, имеш; анда һәртөрле әсәрләр бастырырга хөкүмәттән рөхсәт булып, яхшы гына нәширләр дә мәйданга атылганнар дип ишетәм. Ник минем ул әсәрләрем алай басылмыйлар?

— Шулай, басылмыйлар. Синең энең Муса Бигиев үзенең һичкемгә кирәкмәс таҗвидләрен вә башка да иске китапларын атна саен бастырса да, сезнең китаплар тугърысында сабыр берлә эш күрә әле.

Мин шул сүзне әйткәч, Заһир әфәнденең тәмам төсе бозылды. Кәефе китте дә: «Ул Муса нишләгән?» — дип куйды.

Мин: «Аһ, әдәбият бәһарымызның иң әүвәлге чәчкәләре! Ник алай кояш төшмәгән җирдә яталар икән!» — дигәндә уянып киттем.

## МӘКАЛЬЛӘР

Исәп кирәк, хисап кирәк. Иске гласныйларны[1] чыгарып түгәргә ничә ат кирәк?

Биисе килмәгәннең көе килми. Татар бае гәзит сөйми.

Ике чабата — бер кием, ике шалкан — бер тиен. Татар хатынының бар белгәне — күлмәк тектерү дә кием.

---

*Бәһарымызның* — язызның.

Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың. Китәргә бәдәл кирәк булгач, җәдитчеләрне дә хурларсың.

Көяз туңмас — калтырар. Татар башы һәрвакыт кояш кеби ялтырар.

Ат азгыны тайга иярер, татар мулласы байга иярер.

Өе биек, өйрәсе сыек. Кесәңдә акча булмаса, никадәр яхшы сөйләсәң дә, агызың кыек.

Карама кешенең үзенә, кара сүзенә. Татар болай һич аңламас, төртеп күрсәтмәсәң күзенә.

## СЛОВАРЬДАН ФАЛ АЧУ

Фал нәрсә икәне һәркемгә мәгълүмдер. Авыл вә шәһәрләрдә әбиләр, «Мөхәммәдия[1]» көйләрлек кадәр мәгърифәте булган кызлар, кулларына «Йосыф китабы»[2] вә «Мөхәммәдия» тотып, шуларны баш түбәләренә куеп, соңра ачып фалланалар.

Көннәрдә бер көн мин, әҗнәби телләреннән алынган сүзләрне тәгъриф иткән словарьны тотып утырганда, уйладым: «Тукта, үзем белгән вә хәзерге заманымызда азмы-күпме шөһрәт тапкан кешеләр тугърысында шушы словарьны ачып фалланыйм әле, нәрсәләр чыгар икән?» — дидем. Словарьны иң элек Акчурин Йосыф тугърысында ачтым: «Төркиядә солдатлык дәрәҗәсе» дигән сүз килеп чыкты. Мин аны инде генералдыр дип уйлый идем. Фаразыма муафикъ булмады.

Соңра Исмәгыйль Гаспринский хакында ачтым: «Хәзердә Кырым татарлары каршында мәкъбүл озын вә биек папаха» дигән сүзгә күзем төште. Бунысына бераз ышана төштем. «Булса булыр шул, зур кеше бит, андагы татарларның башларына менеп утыргандыр», — дидем. Бунысы тугърырак чykканга, күңелем үсте дә, Шаһтәхтинский[3] тугърысында ачтым. Ни күзем илә күрим! Тәмам тәмамына өстенә каплаган да куйган: «Шундый бер фиркадер ки, татарлар (вә анларның уң гәзитәләренең) гөманынча, аңар кыяматтә нәҗат юктыр», — дигән.

Шаһ хакында ачтым: «Иранда үсә торган зарарлы вә зәһәрле бер үләндер» дигән сүз күренде. Бу сүзнең тәфсире илә күп чуалмыйча, аннан узып, Мотыйгый[4] тугърысында ачтым: «Мәгънәсез гакыл сату, бушбугазлык» дигән сүз чыкты. Ул кеше шулай ук булыр микәнни дидем дә икенчегә күчтем.

---

*Бәдәл* — кеше өчен ялланып хаҗга баручыга бирелә торган акча.
*Әҗнәби* — икенче халык.
*Тәгъриф иту* — аңлату.
*Мәкъбүл* — кабул ителгән.
*Фирка* — төркем, группа.
*Нәҗат* — котылу.

Фатих Кәрими хакында ачтым: «Бер сәүдә фирмасының вәкиле» дигән сүзгә очрадым. Башта бераз ышанмаска да ният кыйлган идем, соңыннан, аның хәзер үзеннән эш күрмәгәнлеге, бәлки нәширләр әмере илә заказ мәкаләләр язганлыгы хәтергә килгәч, ул хакта да канәгать иттем.

Соңра Муса Бигиев хакында ачтым. Гаҗәпләнүемнән үзем дә көлеп җибәрдем: «Интеллигентный монах», ягъни зыялы монах дигән сүз чыкты.

З.Бәшири хакында: «Кыска аяклы маймылларның бер нәүгысе» дигән сүз, Ф.Сәймани хакында: «Сыер итенең бер нәүгысе» дигән сүзләр күренде. «Алар шулайдыр шул инде», — дип, Риза казый[5] хакында тәфәәэл кыйлдым: «Сакит вә юаш» дигән сүз чыкты. «Бервакыт Рәшит казыйга[6] каршы бик каты дулаган булса да, бу сүз дә дөресттер инде», — диюп, мөфти[7] хакында ачтым: «Үлгән тән» дигән сүз күренде.

Бу да шулай ук булыр микәнни?

## ГӘЗИТӘЛӘРДӘН

«Бәянел хак» гәзитәсенең 409 нчы номерында медицинский академия профессорларыннан тыйб докторы потомственный почетный купец Әхмәтҗан абзый[1] җәнабләре хифзысыйххәт бабыннан бик мөһим вә бик истифадәле мәкаләләр яза башлаган. Йөрәге тибрәнмәгән, каны йөрмәгән, күңеле болганмаган кешеләргә ушбу мәкаләләрне бер дә калдырмыйча укып баруны тәүсыя итәмез. Хосусән, Әхмәтҗан бабайның язган нәрсәләре һәммәсе дә үз башыннан кичкән вә тәҗрибә кыйлып белгән һәм башка докторлардан ишеткән сүзләрнең Әхмәтҗан абзыйның хәтерендә калган нәрсәләреннән гыйбарәт булганга күрә бик әһәмиятледер.

Хәстә гәзитәләрнең башларына авыру килде исә, һәркаюсы хифзысыйххәтне тәҗрибә кыйлып караучан булалар. Шул сәбәптән анларның бу хакта яңлышу ихтималлары юктыр.

Мәсәлән, мин сезгә мисал өчен генә әйтим:

Мәрхүм «Азат» гәзитәсе дә ахыр сулуында хифзысыйххәт

*Нәүгысе* — төре.
*Тәфәәэл кыйлдым* — фал ачтым.
*Сакит* — тын, тик торучы.
*Тыйб* — медицина.
*Хифзысыйххәт бабыннан* — сәламәтлек саклау мәсьәләләреннән.
*Истифадәле* — файдалы.
*Тәүсыя иту* — тәкъдим иту.

бәхәс кыйлды һәм шул хөррияте даим булган мөддәттә* вафат булды. «Казан мөхбире» дә иске кабыгыны салыр алдыннан хифзысыйххәт хакында күп язган иде. «Борһане тәрәккъый»нең дә ахыргы номерларында шул хәл күренде.

Бик мөҗәррәбтер.

Туктаңыз әле, бер хикәя хәтеремә килде: бервакыт бер кешенең аягы шешкән. Бу кеше, әүвәлге заманның гадәтенчә, мөгаббиргә барган. Мөгаббир бу кешегә, аягына бал ягып, белен ябарга кушкан. Мәзкүр адәмгә шифасы тигән.

Соңра беркөн бер төш күргән, төшене юрату өчен яңадан мөгаббиргә барган. Мөгаббир: «Угылың булыр», — дип, төшене җурап җибәргән. Вакыйган да бу кешенең угылы булган.

Соңра бу кеше: ушбу тәҗрибәләрне күргәннән соң, үзе дә мөгаббир булырга фараз кыйлып, кибет ачып, мөгаббирләр киеме киенеп утырган. Бер кара кол килеп, буннан төшене җурарга үтенгән. Мәзкүр адәм әүвәл кара колның акчасыны алган да «угылың булыр» дип төшене җураган. Хәлбуки, кара колның, угылы булу түгел, хатыны да юк икән.

Соңра бу кеше: «Кая, күбрәк акча бир, яхшылабрак журыйм», — дигән. Кара колдан акчаны алган да: «Бар, кайтып аягыңа бал илә белен яп», — дигән. Кара кол, буңа каршы тәшәккер итеп, яңагына берне биргән.

Безнең «ирексез табиб» әфәнде дә, шул рәвешчә, үз тәҗрибәләрене язып, табиблеккә керешкән.

Мәкаләсенең әһәмиятле җирләреннән бәгъзесенә бу урынга дәреҗ иттек.

Һәлакәттән саклану өчен, хәйванатнең һәр нәүгысендә үзенә махсус тәдбирләре була, мәсәлән, кошлар (каргалар, чәүкәләр, козгыннар, тилгәннәр, бөркетләр, каракошлар, карчыгалар, лачыннар) үзләренчә, балыклар (чуртан, шыртлака, ерж) үзләренчә, ерткучы җанварлар (арыслан, юлбарыс, аю, бүре, төлке, мачылар) үзләренчә, йорт хайваннары (ат, сыер, сарык, кәҗә) үзләренчә, корт-кырмыска (кандала, борча, чебен-черки) кеби җан ияләре дә үзләренчә саклананалар...

«Адәмнең тәнендә һәркемгә мәгълүм ак вә нечкә тамырлар бик күп. Шулар, табибләр гыйбарәтенчә, «нерва» дип атала. Әгъзаларда вә тәннең эчендә булган хәрәкәтләрнең барчасы да шул вак тамырларның ярдәме берлә йөртелә.

---

* Азат булып торган вакытында. Монда: сүз уйнату.

*Мөҗәррәбтер* — сыналган нәрсәдер.

*Мөгаббир* — төш юраучы.

*Һәр нәүгысендә* — һәр очракта, һәр төрендә.

*Тәдбир* — чара.

Боларның һәркаюсы үзенә махсус хәрәкәттә. Мәсәлән, бәгъзеләре, телефон вә телеграф мисалында, баш миенә (кыңгырау шалтыратып) хәбәр биреп торалар. Бәгъзеләре, фантал трубалары мисалында, ашаган тәгамнән тәнгә хаҗәт булган нәрсәләрне суырып (качать итеп, икенче башыннан пожарга су сиптергән шикелле сиптереп), төрле әгъзаларга йөртеп торалар...»

## ХӘЗЕРГЕ ЗАМАНЧА СӨЙЛӘШҮЛӘР

*

— Йә, иптәш, тор инде! Бу кадәр бертоташтан йокларга депутат Аллабиргәнев түгелсеңдер бит?

— Кит әле, зинһар! Баш очымда Зариф Бәшири шикелле мыраулама.

*

Ике шәкерт:

— Иптәш, зинһар, кара әле, бу мәсьәләне һич хәл кыйлып булмый: бер дә чыкмый.

— Нишләп чыкмасын?! «Нур»[1]мыни ул чыкмаска?

*

Ике мөгаллим:

— Мөгаллим булгач, балаларны күз ачып йомганчы кеше итәчәкмен.

— Ярар, ярар, «Фикер» шикелле алдан мактанып куйма[2]!

*

Ике кеше арасында низагъ:

— Һи, «Тәрҗеман» баш! Кешегә гакыл өйрәтеп яткан буласың.

*

Бер низагъ соңында берсе нәсыйхәт бирә:

— Йә, иптәш, андый гына эшләр дөнья булгач була ул, «Чүкеч» белә «Ислах» түгелсездер әле[3]. Гомер буе сүгешеп тормассыз.

---

*Тәгам* — ризык.

*

— Иптәш, мин Габдулланың сөйләгән сүзенең берсенә дә төшенә алмадым.

— Төшенергә бит, ул «Тәрәкъкый» теле[4] белә сөйли ич.

*

Хәзерге заманча бер вакыйгадан хикәя:

— Бер көннәрне мин октябрист Вәлигә барган идем: аның янында Пуришкевич Исхак белә Шульгин Гәрәй бар иде. Безнең арада Австрия политикасы хакында речьләр башланып китте. Октябрист Вәли ул тугърыда бөтенләй «Бәянел хак»ча икән. Шульгин Гәрәй бөтенләй политиканы «Вакыт»чарак борып җибәрде. Англия политикасы белә бөтенләй Извольскиләнеп китте.

# 1909

## АХЫР КҮРЕШҮЛӘР

Габделмалик бине Мәрван үзенә хәлифәлек дәрәҗәсе килү хәбәрен ишеткәндә, Коръән уку белән мәшгуль иде.

Хәбәрне ишеткәч: «Ә, мин хәлифә булдыммыни? Алайса, и Коръән! сине актык тотуым, актык укуым булсын», — диде дә Коръән белән мәңгегә исәнләште.

Бер милләтче зыялының җибәргән җаучысы кыз тарафыннан ризалык хәбәрен китергәндә, зыялы әфәнде «хөррияте ниса» хакында китаплар моталәга итеп һәм эченнән тәмам хатыннар хокукын саклаучы булып утыра иде. Хәбәрне ишетте дә: «И хөррияте нисван! Сине актык әйтүем булсын!» — дип, хатынына чапан алырга уйлап, баягы китаплар яныннан торып китте.

Бер татар депутаты үзенең сайлану хәбәре килгәндә: «И халыкка хезмәт! Әмма мөкаддәс нәрсә соң син!» — дип мыгырдап утыра иде. Хәбәрне ишеткәч: «И көненә 10 тәңкә! Син сау булсаң, мин сәламәт. Яшә, кызыл яфрак!» — дип кычкырды.

Бер яшь төрек[1] «Хөррият игълан кыйлынды» хәбәрен ишеткәндә: «Төркиядә һәр милләтнең хокукы мөсави улур; әрмәнләр, юнанлар, болгар — һәпсе төрекләрлә бер хокукда улачаклар; һичкимиң диненә, лисанына вә миллиятенә тәгадди иделмәз», — дигән сүзләр илә тулы мәкалә язып утыра иде. Хәбәрне ишеткәч: «Юк, юк, мәктәбләрдә гайре мөслимләрә төрек лисаны илә укыдил сун!» — диде.

---

*Хөррияте ниса* — хатын-кыз азатлыгы.
*Моталәга итү* — уку-тикшерү.
*Хөррияте нисван* — хатын-кызлар азатлыгы.
*Кызыл яфрак* — ун сумлык кәгазь акча.
*Мөсави улур* — бертигез булыр.
*Юнан* — грек.
*Лисан* — тел.
*Тәгадди иделмәз* — кул сузылмас.
*Гайре мөслимләрә* — мөселманнан башкаларга.

## АКТЫК СҮЗЛӘР

### *(Өзкеру мәутакем билхәер*)*

Бер кыз: «Әй, җегетләр, җегетләр!» — диде дә үлде дә китте.

«Милләт» гәзитәсе: «Нәдер бу, нәдер бу, нәдер бу?» — диде дә үлде дә китте, ди.

«Азат» гәзитәсе: «Хифзыссыйхәт кирәк, сәламәт булырга кирәк, үләргә ярамый!» — диде дә үзе назад китте дә барды, ди.

«Өлфәт» гәзитәсе: «Җимерелә дә җимерелә», — диде дә үзе җир астына уелып төшеп китте, ди.

«Әхбар» гәзитәсе: «Ай Фәүзи абый, вай Ләмига туташ!» — диде дә үзе дә «замана хикәясе» булып сөйләнергә генә калды, ди.

«Азат халык»: «Миңа кабердән хатлар килә, миңа мөтәвәффа Ильминскийләр мәктүб җибәрә», — диде дә кабергә төште дә китте, ди.

«Ватан хадиме»: «Тупрак! Тупрак! Тупрак!» — дип, өч мәртәбә кычкырды да, ди, үзе дә, тупрак булып, аслына кайтты, ди.

«Әддин вәл-әдәб»: «Йа әйятеһән-нәфсел мотмәиннәте ирҗигый иля раббики...»** аятенең мәгънәләрен язды да үзе Тәңресенә кайтты да китте, ди.

«Ха-ха-ха» журналы: «Камил әфәнде 5 бең рубля парә сорайур; ихсанлы байлар вирерләр»***, — дип, бер кәррә көлде дә вафат булды, ди.

«Тәрбия» журналы: «Әй балалар тәрбиясе — кечкенә генә баланың Кольцовтан тәрҗемәсе!» — диде дә тәрбиясез генә дәфен ителде, ди.

«Карчыга» журналы: «Әмма Бәдигъ мөәзиннең күркәсе! — әй, Кук әфәнде!» — диде дә үзе «кук!» итеп шартлады, ди.

«Яз» журналы: «Яз! яз!» — диде дә язгы ташу белән акты да китте, ди.

«Таң» йолдызы», «Тавыш», «Таң мәҗмугасе»: «Тартышыгыз, тартышыңыз, тартыш!» — диделәр дә чылбыр өзелде дә китте, ди.

---

* Үлгәннәрегезне яхшылык белән телгә алыгыз.
** И нык иманлы җан, Тәңреңә кайт!
*** Мең сум акча сорый; ярдәмле байлар бирерләр.
*Хифзыссыйхәт* — сәламәтлекне саклау.
*Мөтәвәффа* — үлгән.
*Дәфен ителү* — күмелү.

## МАТБУГАТ КАҺАРМАННАРЫ

**(Русчадан)**

*Матбагачы* — матбугат эшен бәкъкаль кибетенә әйләндереп, файда күрүче.

*Мөрәттиб* — бәйрәм булмаган көннәрдә матбагадан матбагага йөгерүче вә бәйрәм көннәрне сыраханәдән сыраханәгә йөгерүчедер.

*Мөхәррирләр* — болар ике сыйныфка бүленәләр: бер сыйныфы мәшһүрләр, икенчесе шөһрәтсезләр.

Ике сыйныф арасында аерма шул гына: әүвәлгеләре фәкать кул белән генә язалар, икенчеләре исә мәшһүр мөхәррирлеккә җитәргә ашыгып, кул белән дә, аяк белән дә язалар.

*Мосаххих* — теләсә дә, теләмәсә дә, һәрнәрсәне укып күздән үткәрергә мәхкүм булган бер матбугат корбаныдыр.

*Мәсъул вә баш мөхәррир* — гомер буе утырып, эскәмья җылытып, бер урыннан кузгалмаенча кәсеп итүче заттыр.

*Китапчы* — китапларны шүрлектә вә мөхәррирләрне тырнагында тотучыдыр.

## «БЕЗНЕҢ ЗАМАН»

Харис Фәхретдинев нәшер иткән, бер школьник язган мәнзум комедиядер.

Мөндәриҗаты шуннан гыйбарәт:

Мин урамга чыгам,
Баганага сөялеп торам,
Тамагымны да кырам.
Ну, яман безнең заман,
Яшьләр бозыла һаман.
Куда конь с копытом,
Мин дә кыстырдым ботым.

Бу школьникның яшьләрдән көләм дип азаплануы нинди көлке булып чыкканлыгын күрер өчен, бу көлке бер пәрдәдә мәнзум комедияне алып укырга эшсез кешеләргә тәүсыя итәмез.

---

*Матбагачы* — типография хуҗасы.
*Бәкъкаль* — бакалея.
*Мөрәттиб* — хәреф җыючы, наборщик.
*Мосаххих* — корректор, төзәтүче.
*Мәхкүм* — хөкем ителгән.
*Мәсъул* — җаваплы.
*Мәнзум* — тезмә белән язылган.
*Мөндәриҗат* — эчтәлек.
*Тәүсыя иту* — тәкъдим итү, киңәш бирү.

## ТАТАРЧА ТЕАТР

19 июньдә җомга көн кич Панаевский бакчаның ябык театрында «Хуҗа һәм приказчик» нам пьеса тамашага куелды. Кич бик аяз вә бик матур булып, выставкага килгән мөсафирлар да күп булганга, халык бик күп иде. Театру сафыннан тәрәкъкый иттерүне үзләренә идеал итеп алган бу труппа артистлыктан башка эш илә шөгыльләнмәгәнгә, табигый инде, эч пошканнан гына театр уйнарга керешкән любительләргә кыяс итәрлек дәрәҗәдән күптән үткән вә үзенә тамашачы күңелен җәлеп иткәндер.

Шунлыктан болар «Хуҗа һәм приказчик» шикелле эшләнүе җитмәгән пьесаны да матур итеп чыгара белделәр.

Галимҗан ролен уйнаучы Кариев[1] үзенең җанлы хәрәкәте вә килешле кыйланышы вә кирәк урыннарда төсен вә сүзнең «тон»ын үзгәртә белүе илә хәзер генә базардан сәхнәи тамашага тотып кертелгән бер татар бае иде.

Садыйк ролен уйнаучы Сакаев[2] әфәнде дә бу юлы көтелмәгән дәрәҗәдә яхшы уйнап, кияү булырга йөргән бер аксакал татар баена тәкълид итә белде.

Карт байның үзенең кибетендәге буш тартмаларга мал тутыру өчен генә бер 17 яшәрлек кызга өйләнергә теләве һәм дә мәскәүләргә каршы корган хәйләләрен сөйләве Сакаев авызыннан бигрәк табигый рәвештә чыктылар.

Галим ролен уйнаучы Мортазин[3] да тәмам-тәмам борынына яңа гына хөррият исе керә башлаган бер приказчик иде.

Сафия ролен уйнаучы ханым, бик әкрен вә тотлыгып сөйләп, һич кирәкмәгәнгә йөзен яшереп һәм дә мөмкин кадәр публикага арты белән торырга азаплануы илә ул кадәр яхшы түгел иде.

Галимҗанның хатыны Бибисара (Сәмитова)[4] 17 яшьлек Бибиҗамалның әнкәсе булыр өчен артык яшь кыяфәттә, вә ана булачак урында яшь киленнәр хәрәкәте күрсәткәнгә, ул рольгә муафикъ түгел кеби күренә иде.

Гыйззәтуллина[5] ханымга килсәк, әлбәттә, аның үз ролендә күрсәткән мәһарәтен сөйләргә дә хаҗәт юк.

Фәкать шунысы бар: аның чын көче, чын мәһарәте «Кызганыч бала»да Шәфыйка ролендә, «Бәхетсез егет»тә Гайни ролендә, «Оят»та Мәгърифә рольләрендә бигрәк ачык, бигрәк якты күренә.

---

*Нам* — исемле.
*Тәрәкъкый иттерүне* — алга җибәрүне.
*Кыяс итү* — чагыштыру.
*Тәкълид итү* — охшату.
*Мәһарәт* — осталык.

## МИЛЛӘТЧЕ

Бер милләтче, гәзитәдә Болгариянең тәмам истикълял игълан иткәнен укыгач вә кенәз Фердинандның Төркиядән аерылу шәрәфенә әллә кайчангы иске болгар ханнарының таҗын киеп төшкән рәсемен күргәч, гаять дәртләнде. Бөтен күңеле миллият хисе белән тулды. Аның күз алдына Спас өязендәге Шәһри Болгар вә анда моннан ничә-ничә йөз еллар элек гомер иткән бабаларымыз килә башладылар.

Милләтче әфәнде үзе шагыйрь кеше иде. Ул дәрхаль үзендә шул дәкыйкада хасил булган хисне түбәндәге берничә юл шигыре илә тышка да чыгарды:

### МИЛЛӘТ

Зур, кадерле нәрсә бу милләт дигән,
Күп олугълар дөньяда: «Милләт», — дигән.
Күп батып яткан халык тапты нәҗат
Үз арасыннан туган бер мөнҗидән.
Алга китте бер-береннән көнләшеп
Әһле дөнья, чыкты хикмәт көнчедән.
Бервакыт мин, бәлки, суллыкка чыгам;
Туктале, эчсенче милләт җаме җам*:
Ник килешми модный таҗлар башына?
Таҗ киде Болгар кенәзе музидан.
Күрсәтер изге уемны күз яшем,
Айрылыр арзанлы таш чын энҗедән.

Менә шушы шигырьне язган көнне бу милләтче, ничектер иттифакый, бер ресторанга барып кереп, калын корсаклы, энҗеле кәләпүшле, бишбилле бишмәтле карт бер татар баеның һәйбәт матур рюмка илә коньяк эчеп утырганын күрде дә:

— Ә! Менә милләт җаме җам эчте* инде, мин дә суллыкка чыгам, — дип, дәрхаль ресторанның кара залына чыкты. Анда һәртөрле гамәле вә крәстияннәр арасына кереп, үзенең пачкасы 3 тиенлек папиросын кабызып җибәрде.

Шул ук милләтче бервакыт, иске татар хәрчәүнәсенә ке-

---

* Җәмшит кясәседер ки, төрек шагыйрьләре аның илә әкъсаи сәгадәтне тәгъбир итәләр. (*Г.Тукай искәрмәсе.*)

** «Милләт иң югары бәхеткә иреште» мәгънәсендә.

*Истикълял* — бәйсезлек.

*Дәрхаль* — шунда ук.

*Нәҗат* — котылу.

*Мөнҗи* — коткаручы.

*Әһле дөнья* — дөнья халкы.

*Иттифакый* — очраклы рәвештә.

реп, пәрәмәч кушты. Пәрәмәч килгәч, аның камыры эчендә батып яткан «милли» тараканнарны күрде. Ул, аны күргәч:

Күп батып яткан халык тапты нәҗат
Чәй эчәм дип килгүче бер мөнҗидән, —

дип, баткан тараканнарны бармагы берлән чыгарып ташлады.

Соңра пакь калган пәрәмәчне бик каты керәнгә манып ашарга тотынды да, керән ачысыннан күзләреннән яшьләре атылып чыкты. Бу вакыт милләтчебез:

Күрсәтә изге уемны күз яшем,
Айрыла арзанлы таш чын энҗедән! —

дип куйды.

Берничә көннән соңра милләтчебез мөселман көтепханәсенә керде дә, анда «мәшһүр» бер шагыйрьнең миллият хисе булган һәр кешегә уку фарыз булган бер мәҗмугасендә түбәндәге шигырьне күрде:

Милләтем улганга татар,
Мин дә булдым бер татар;
Кая барсалар да, калмыйм,
Ташламам бән бунларый.

Моны укыгач, милләтче әфәнде:

Зур, кадерле нәрсә бу милләт дигән,
Бакчы, нинди зур кеше: «Милләт», — дигән! —

дип җырлый-җырлый чыгып китте.

Көннәрдә бер көн милләтче әфәнде бер татар баена ашка барды. Аш табынында «урысча да, татарча да галим кеше» булган бер татар учителенең кәләпүшчән вә искерәк татар киемендә утырганлыгын күргәч:

Ник килешмидер яланбашлык моңар,
Ул, учитель булса да, кәпәч кигән? —

дип куйды.

## «БЕЗНЕҢ ЗАМАН» ВӘ СӘГЪДИ АБЗЫЙ

Сәгъди абзый үтерә «Безнең заман»ны мактап. Ул әйтә: «Безнең заман» үзе яңа, мөхәррире яңа, нәшире яңа, тагы гыйлавә итәбез: матбагасы яңа, кәгазе яңа, хәтта шул китапны җыйган наборщикның сакалы яңа», — ди.

---

*Гыйлавә итәбез* — өстибез.
*Матбага* — типография.

Әлбәттә, «көлле җәдидин ләзизен» мәфһүменчә*, һәрбер нәү зоһур вә оригинальный нәрсәне мактау табигыйдер.

Әгәр, мәсәлән, мин, барып, Сәгъдинең яңагына шалт иттереп суксам, Сәгъди абзый мине дә фельетон тутырып мактарга вә намемне әллә ничә нәселләргәчә оныттырмаска тиештер. Ник? Аның өчен мин яңа эш эшләдем: ул аслан көтмәгәндә — шалт берне яңакка!

Гадәттә олугъ юлдан гына йөри торган бер сыер, тратуарга кереп, халыкны сөзеп-сөзеп йөгерсә, Сәгъди абзый аңар да шундый зур дәрәҗәләр бирергә бурычлы.

Ник? Аның өчен бу — яңа эш: сыеры да яңа, мөгезе дә яңа, койрыгы да яңа, тояклары да яңа, тратуарга керүе дә яңа. Әлхасыйль, менә бу китап тугърысында «яңа әсәрләр» дип куярга ярый.

---

* «Һәр яңа нәрсә тансык, татлы була» дигәндәй.
*Нәү зоһур* — яңа чыккан.
*Әлхасыйль* — кыскасы.

# 1910

## САБЫН АШАГАННАР

*(Хикәя)*

Казанның карт бер хәзрәтенең тиле-миле генә надан бер мәхдүме урамнан бара икән; шул вакыт бер тәрәзәдән берничә татар яшьләренең җыелышып күмәч белән сыр (эремчек) ашаганнарын күргән.

Бу эш рамазан шәрифтә һәм дә көпә-көндез эшләнгәнгә, мәхдүм, вакыт үткәрмичә өенә кайтып, атасына:

— Әти, әнә тегендә Гариф мөәззиннең күзлекле угылы үзенең иптәшләрен җыйган да, рамазан шәрифтә көпә-көндез сабын ашап утыралар, — дип жалува бирә.

Шуннан берничә көн генә соң карт хәзрәт мәсҗедтә сөйләгән вәгазе артыннан ушбу түбәндәге сүзләрне сөйли:

— Җәмәгать, ахырзаман җитте, яшьләр бозылды, әнә теге Гариф мөәззиннең күзлекле угылы үзенең иптәшләре белән рамазан шәрифтә көпә-көндез сабын ашыйлар икән, бу эшне минем мәхдүм үз күзе белән күреп кайткан. Әнәтерәк Гариф мөәззиннең күзлекле угылы: «Әйдәгез, ашыйк», — дип әйтә икән, иптәшләре дә ашый икән.

Мәсҗедтәге халык вәлвәләгә төшәләр.

Шулай торганда, яшь бер хәзрәт тамак төбе белән генә:

— Хәзрәт, ашасалар ни булган? Сабын әтгыймәдән түгел. Ул рузаны бозмый, — дип куя.

## ИКЕ ХӘЗРӘТ ВӘ ИЗВОЗЧИК

*(Хикәя)*

Ике хәзрәт фәкыйрь генә бер мужикта эчләре шартлаганчы ашап чыгалар да, икендегә җитешә алмабыз дипме, ни өчендер извозчик ялламакчы булалар.

Берсе кычкыра:

— Извозчик! Фәлән җиргә 15 тиен!— ди.

Извозчик:

— Юк, хәзрәтләр, иллешәр тиен бирерсез инде, — ди.

Хәзрәтләр:

---

*Вәлвәләгә төшү* — аптырашып шау-шу килү.

*Әтгыймә* —ашамлык.

— Ул ниткән сүз, без һичбер вакыт 15 тиеннән артык түләгәнемез юк, ерак җир түгел ич.

Извозчик:

— Ерагын ерак түгел дә, хәзрәтләр, сез хәзер генә менә бу йорттан ашап чыктыңыз. Әгәр мин шуны күрмәгән булсам, сезне 15 тиенгә дә алып кайтыр идем; хәзер сез атка авыр буласыз.

Хәзрәтләр:

— Ай ахмак! Кара, ниләр сөйли бит!

## ГАҖӘП ТАЛАНТЛАР

### *(Истигъдаде фәукылгадә)*

Һади Максудиның[1] — бик матур мәузугъ (тема)лардан бик тозсыз мәкаләләр язарга;

Рәшит казыйның[2] — үз-үзен мактарга;

Шәһидуллиннең[3] — игълан җыярга;

Хәмзә ахунның[4] — донос ясарга;

Вәли мулланың[5] — вәкыф малы ашарга;

Чәйдәшевләрнең[6] — үзләре сөймәгән кешеләрне миссионер дип атарга;

татар хатынының — кеше арасын бутарга һәм битен акбурга буярга;

сәтрәле кызның — тәрәзә аркылы күргән һәр кешесенә гыйшык тотарга;

татар малаеның — егетлек дип, исереп ятарга;

бай малаеның — үзенең мактанудан башка бер эш тә белмәгәнлеген каһарманлыкка санарга;

татар шәкертенең — милләт кайгыртып, «Сарай» пәрәмәче ашарга;

татар хәлфәсенең — нифакъ сатарга;

татар мөхәрриренең — фәлсәфә сатарга;

Маймыл Хафизның — осуле җәдиткә каршы авыл никрутлары да ул кадәр начар итеп чыгара алмаслык җырулар язарга фәукылгадә истигъдадлары һәм гаҗәп талантлары бардыр.

## «ЯШЕН» МӘРХҮМ

«Яшен» мәрхүм үлем түшәгендә яттыкларында, бәндәләре хазир вә назир* идем. Бичараның актык сулышлары якыная иде.

---

* Мин үзем шунда булып, карап, күзәтеп тора идем.

*Истигъдаде фәукылгадә* — гадәттән тыш сәләт, булдыклылык.

*Вәкыф малы* — берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал.

*Сәтрәле* — йөзен пәрдә белән каплаган.

*Нифакъ* — икейөзлелек.

Мин, мөселман булдыгымнан, «Яшен» мәрхүмнең тере заманда динчеләрнең теңкәсенә тиеп үзәгенә үткәнгә, имансыз китүеннән бик каты куркып, бичараның янында һаман «әшһәде әнла илаһә» кәлимәи мөбарәкәсен* укып тора идем. «Яшен» мәрхүмне шул кәлимәне тәкрар итәргә көчли идем.

Ләкин ул, минем тәлкыйнемә бер дә илтифат итмичә, һаман да «йә» һәм «шин» хәрефләрен тәкрар итә иде.

Мәрхүм һаман, тәне суынып җаны чыкканчыга кадәр, ушбу хәрефләрне кат-кат әйтте дә торды:

— «Йә» «шин», «йә» «шин», «йә» «мим».

Тәңре тәбарәкә вә Тәгаләдән фәрман** булды. «Яшен» мәрхүм, вафат булып, үлеп — дөньядан кайтып, дарел фәнадан дарел бакага рихләт әйләде. Инна лиллаһи вә инна иләйһи раҗигун***.

Әмма мин аның үләр алдында сөйләгәне «йә», «шин», «мим»нәренең мәгънәсен һич тә аңламый калдым.

Заман кичте. Сулар акты. Менә көннәрдә бер көн мәйдане матбугатка «Ялт-йолт» журналы килеп чыкты. Ул ялт-йолт итте, һәм руи зәмин яктырып китте.

«Ялт-йолт» чыгып ялтырагач, табигый уларак, минем исемә мәрхүм «Яшен» килеп төште. Чөнки «Яшен» дә ялтырый иде бит.

Мин тагы «Яшен» мәрхүмнең үләр алдыннан сөйләдеге «йә», «шин», «мим»нәре тугърысында гайре ихтыяри тирәнтирән моталәгаләргә чума башладым.

Уйладым, уйладым, уйладым, уйладым да ахырында белдем ки, «Яшен» мәрхүмнең үләр алдыннан мәзкүр «йә», «шин», «мим» хәрефләрен тәкрар кыйлуы «яшим мин», һаман да «яшим мин», «үлмим мин» дию булган икән.

Һәм вакыйган: сез бу «Ялт-йолт»ны кайдан ялтырый дип беләсез? Ул һаман да шул яңадан терелгән «Яшен» нурыннан ялтырый.

Яшәсен «Яшен», яшәсен «Ялт-йолт»!

---

* «Алла үзе шаһит» дигән хөрмәтле сүзен.

** Һәркемгә газиз һәм бөек Алладан әмер.

*** Алладан килгәнбез, Аллага кайтабыз.

*Тәлкыйнемә* — әйтеп торуыма.

*Хәрефләрен* — «бу урында авазларын» мәгънәсендә.

*Дарел фәнадан дарел бакага* — дөньядан ахирәткә.

*Рихләт әйләде* — күчте.

*Руи зәмин* — җир йөзе.

*Гайре ихтыяри* — ирексездән.

*Моталәга* — уйлану, тирәнтен тикшереп төшенү.

*Вакыйган* — чыннан да.

## КЕШЕ — ХАЙВАННАР

*Үрдәк* — чапан эчендә симергән бай хатыныдыр. Ары да авып, бире дә авып, сатай-матай йөрер.

*Мәче башлы ябалак* — татар суфи вә хафизыдыр. Үзенең ризыгын караңгыда гына табар.

*Күке* — «Кәримев-Хөсәенев» ширкәтедер[1]. Үзе оя ясамыйча, йомыркасын кеше оясына гына салыр.

*Төя* — иске татар шәкертедер. Ул үзенең өркәчләренә үлгән кешеләр төяр дә, каберстанга баргач, лып итеп чүгәр.

*Төя кошы* — Чыгътай хәзрәтләредер[2]. Искеләр алдында: «Әттаибе минәз-зәнби — мин», — диер. Башкалар алдында: «Ул болай гына», — диер.

*Сыер* — ишан мөритедер. Дөнья сахрасында барча утлап хасил иткәнен ишан хәзрәт чүлмәгенә барып саудырыр.

*Дуңгыз* — «Дингә мишәйт»тер[3]. Гомерендә бер мәртәбә дә аңар тәрәккъый күкләренә күтәрелеп карау мөяссәр булмас, һаман шул чүплегеннән борынын күтәрә алмас.

*Эт* — С.Р.[4] Кыйнасалар да, суксалар да, ач тотсалар да, хуҗалары — бөлгән байларга рәнҗемәс әрсез хайвандыр. Хуҗалары калган вә яланган сөякне ташласалар, ул шуңар һәр заман койрыгын селкеп рәхмәт әйтүдән ялыкмас.

*Качыр* — төрек белән татар арасында калган «Шура» әдипләредер[5].

*Куян* — татар кызыдыр. Кешедән дә куркыр, песидән дә куркыр, каргадан да куркыр, үзеннән үзе дә куркыр.

*Чакал* — мөәззиндер. Ул үзенә мәетләрдән башка ризык таба алмас.

*Сарык* — бернәрсә белмәс мөкаллид татарлардыр.

*Кәҗә* — мулладыр. Шул сарыклар алдында сакалын селкетеп, көтү башында йөреп рәислек итәр.

*Песи* — тәнкыйтьчеләремездер. Алар матбугат вә әдәбиятымызга зарарлы идән асты хайваннарына сәясәт күрсәтерләр.

*Тычкан* — болар әдәбият вә матбугатны кимермәк нияте илә идән астыннан чыксалар да, бер кәррә тәхзир ителгәч, идән

---

*Хафиз* — Коръәнне күңелдән ятлаган һәм шуны рамазанда мәчетләрдә укып көн күрүче кеше.

*Ширкәт* — сәүдә берләшмәсе, сәүдә компаниясе.

*Әттаибе минәз-зәнби* — гөнаһтан тәүбә итүче.

*Тәрәккъый* — алга киту.

*Мөяссәр булу* — насыйп булу.

*Чакал* — шакал.

*Мөкаллид* — аңламыйча, сукырларча иярүче.

*Сәясәт күрсәтү* — җәза бирү.

*Бер кәррә тәхзир ителгәч* — бер тапкыр куркытылгач.

ярыгыннан башларын да чыгарып карарга җөрьәт итә алмаслар. Д. Җ. Т. кебиләр шушы җөмләдәндер.

## КЕРЕШҮ ХОТБӘСЕ

Әлхәмде лимән халәкаль-инсанә минәт-таши вәттупрак. Вә зәййәнәһү билбаши вәлборный вәлколак. Вәлләгънәтел лиш шәйтан әлләзи зәййәнәл-болака «Билпьяныл хап»[1]. Вә нәууарәл-Печән базарә биләнвагыйн нәҗасати вәлпычрак. Вә әмләә бәлдәтел Орски биәнвагый сәфсәтатин Әхмәд әл-Исхак[2]. Вә бәшарә фирмәтел Кәримеф әл-Хөсәенефи билкаулил-мөбәшаре «Шарт»! Вә зәййәнә «Әддинә вәл-мәгыйшәтә» биәнвагыйль-айгырат. Вә зәййәнә идарәтә — «Әшшура» биәнвагыйль-мөхәрриринәм-саламинәс-сыйрак. Вә нәууарә вөҗүһә инсаинәл-хәшарәти биәнвагыйль акбурәти вәлакшарат. Вә һөннә ямшинә фильярминкәтит-Ташаяк. Вә нәббәхә галя әшрафина Мөхәммәтҗанәл-хафизә вә Низамиял-аксак[3]. Вә әгътана мәбгусәйниш-Шәрмәхүтефә вәл-Байбулыймә кәбирәл-колак[4]. Вә әгъҗәза билҗәүгый вәл-гаташи «Труппәтәнәссәйарә» фи көлли биладиәр-Русияти вә фи көллил-мәкянәт. Вә галләмәл мәймүнәл-гавамәз-Зөттатария[5] биәнвагыйль-мәкамәт. Вә бәррәкәл-Мәмдүх байә[6] бихөббиш-шәһәвати минән-нисаи вә бикөлли ләзаизил-хайванәт.

Вәлләгънәте сөммәл-ләгънәте галәл-имамәйнил-һөмамәйнил-җүләрәйни — «әссуга сигәнәйнил»-җаһиләйнил-мәкруһәйнил-мәнфүрәйнил-мәхрумәйни мин җәмигый фәзаилил-инсанияти әл-Ишмиил мөбарәки вә Такырҗанил-Хәсән[7]. Вә галя мән табигыһем минәл-мөридинәл-мәрдүдинә кәсирән кәсира.

Әмма бәгъдә фә-йа Гыйбадуллаһ! Игъләмү әннәд-дөнья җифатен вәталибеһа вәгашикыһа инсан. Хосусән Зәйнуллаһи вә Хәйбуллаһил-ишан[8].

Аллаһөммә әнсыр мән нәсырәт-тәрәкъкыя вәл-иртикаэ. Вә йөссир ләна баһил-иртика. Аллаһөммә әнсыр нисаинәт-тайибат. Лиәннәһөннә гафиватен-хөррат. Вәлиәннәһөннә йөзәййинәт-театрат. Вә йәскунур-риҗалә лилгыйффәти вәссаламәти вә лиәнвагыйт-тәрәкъкыят. Вә ля төгассир ләһөннәттансавайт. Иләх...

*Тәрҗемәсе:*

## КЕРЕШҮ СҮЗЕ

Кешене таш һәм туфрактан яраткан, аны баш, борын һәм колак белән зиннәтләгән затка мактау. Болакны «Пьяныл хап» белән, Печән базарын төрле пычрак һәм шакшылар белән нур-

ландырган, Орск шәһәрен Әхмәт Исхакның төрле чүп-чарлары белән тутырган, Кәримев-Хөсәеневләр фирмасына «Шарт» дигән сүз белән сөенеч биргән, «Дин-мәгыйшәт» редакциясен төрле айгырлар белән, «Шура» редакциясен төрле салам сыйрак язучылар белән зиннәтләгән, ямьсез йөзле хатын-кызларыбызның (алар Ташаяк ярминкәсендә йөриләр) йөзләрен төрле акбур һәм акшарлар белән нурландырган шәйтанга ләгънәт. Ул (шәйтан) безнең олыларыбыз өстенә Мөхәммәтҗан хафиз белән Низамый аксак дигән этләрне өстерде. Депутат итеп (Дәүләт Думасына) җибәрү өчен безгә Шәрмәхүтев белән озын колак Байбулыймны бирде. Безнең труппабыз «Сәйяр»не Россиянең барлык шәһәрләрендә һәм барлык урыннарында ачлык, сусызлыктан гаҗиз итте. Гавам Зөлтатари дигән маймылга төрле мәкамнәр (Коръән укый торган көйләр) өйрәтте. Мәмдух байны хатыннарга мөнәсәбәттә җенси тотнаксызлык һәм һәртөрле хайвани ләззәтләр сөю белән зурлады.

Юләр, «суга сигән», консыз, җирәнгеч, кешелекнең бөтен яхшы сыйфатларыннан мәхрүм булган ике муллага — Ишми мөбарәк белән Такырҗан Хәсәнгә ләгънәт соңында ләгънәт булсын. Һәм аларга ияргән мөритләргә дә күптән күп ләгънәт булсын.

Моннан соң, и Алла колларым! Белегез ки, дөнья бер үләксәдер, кешеләр исә аңа гашыйклар. Бигрәк тә Зәйнулла һәм Хәйбулла ишаннар.

И Алла! Алга китүебезгә, югары күтәрелүебезгә булышлык итүчеләргә ярдәм бир. И Алла! Безнең гүзәл хатын-кызларыбызга ярдәм бир! Чөнки алар саф-пакьләр, азатлар. Чөнки алар театрны матурлыйлар һәм ирләрне дә намуслы булырга (бозык эшләр эшләмәскә), сәламәтлеккә һәм культурага әйдиләр. Син (Алла) аларга танцыны авыр кылма һ.б.

## АКЫЛЛЫ БАШЛАР

Бер татар приказчигы: — Тамчы, тамчы тамар да күл булыр, — дип әйтте дә, ди, байның кассасын аз-азлап чиертергә тотынды, ди. Күп тә үтмичә, самавырчы малайлыктан «Печән базары бае»лыкка тәрәкъкый итте, ди.

Бер татар бае: — Асылынсаң асылын агачның асылына, — дип әйтте дә, ди, Мәскәүгә барып, йөз меңлек бурычка чумды, ди; шул елда ук шарт итте, ди.

Бер татар кызы: — Гыйшык тоту пәйгамбәрләрдән калган, — дип әйтте дә, ди, урамнан узган бер кәкре шәкерткә «гыйшык» булды, ди.

Бер татар мулласы: — Татысын әле матбугат безнең тоякларның тәмен! — дип әйтте дә «Исабәт» язды[1], ди. Тоягы канагач кына, тимер кадакларга типкәнен сизде, ди.

Бер татар фирмасы: — Шәригатькә ябышкан ким-хур булмас, — дип әйтте дә, ди, «шәргый сабын» ясатты, ди.

Бер татар мөхәррире: — Ары лап-лап, бире лап-лап, сөңге саплап, киез каплап — ул нәрсә? — дип әйтте дә «Табаныл хак[2]» дигән җавап ишетте, ди.

Бер татар карчыгы: — Сөлек һәрнәрсәгә шифа, — дип әйтте дә, ди, бер зур корсаклы бай тарафыннан хәрап ителгән асрауны приказчикка бирерлек итә алды*, ди.

Бер татар шагыйре:

Сәна лил-халикый габра вә әфлакъ!**
Пич астыннан песи чыкты прахлап.
Сәмават әүене тотты могалләкъ,***
Песине судка алдылар богаулап.

Кыйлып габра мәдарен зиммәи хут,****
Песине нишләтә инде бүген суд, —

шигырен укыды да, ди, аннан мең өлеш начар иттереп, «Сөбател гаҗизин»гә тәкълид итте, ди[3].

Шуннан «Замана шигырьләре» килеп чыкты, ди.

Бер мишәр: — Шәйтан гына ярлы, — дип әйтте дә, ди, «Йолдыз»дагы әдәбиятымызга мишәр теле катыштыруны килештерми язылган мәкаләгә каршы мәкалә язды, ди. Мәкаләсендә биш-алты данә здоровый мишәрләрне бармак белән төрткәләп күрсәтте, ди. Шулай итеп, мишәрләрнең байлыгын һәм «шәплеген» исбат итте, ди.

Һинди Минһаҗ[4]: — Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, барыбер дарелфөнүн салынмас; ахры, 60 мең чакрым юл йөрдем дип булса да, Собраниегә хисап бирми булмас, — дип әйтте дә, ди, Уфага китте, ди.

---

* Бу — күптән түгел Казанда булган кызыклы бер вакыйгага ишарәдер. (*Г.Тукай искәрмәсе.*)

** Җирне һәм күкне яраткан Аллага дан һәм мактау!

*** Күк йортын терәксез тора торган итте.

**** Җирне хут балыгы аркасына урнаштырды.

*Шәргый сабын* — шәригатьчә эшләнгән сабын.

*Тәкълид иту* — ияру.

*Дарелфөнүн* — югары уку йорты.

## ФӘЛСӘФИ СҮЗЛӘР

«Җәүһәр җирдә ятмый», — дигән булалар, вәхаләнки ул үзе җирдән чыга.

«Кешегә баз казысаң, үзең төшәрсең», — дигән булалар, вәхаләнки кабер казучылар көненә икешәр кешегә баз казыйлар да, үзләре төшмиләр.

«Сүзең көмеш булса, тик торуың алтын», — дигән булалар; алай булса, телсезләр һәммәсе миллионер булып беткән булырлар иде.

«Аз ашасаң, күп ашарсың», — дигән булалар, вәхаләнки татар эшчеләре гомерләре буенча аз ашыйлар да, берсенең дә күп ашар дәрәҗәгә җиткәннәре күренми әле.

«Бирмәсә дә — бай яхшы», — дигән булалар, вәхаләнки Кәримевләрнең бай булуыннан дөньяда берәүгә дә яхшылык килгәне юк әле.

«Үлемгә каршы дәва юк», — дигән булалар, вәхаләнки терек тору үлемгә каршы иң яхшы дәва.

«Канәгать — үзе хәзинә», — дигән булалар; сата башласаң, бер тиенгә дә алучы булмагач, мин аның хәзинәлеге белән нишлим?

«Байлар сәдакага йөрми», — дигән булалар; әллә Оренбургның Госманов, әллә кай җирнең Ишмөхәммәтевләрен бай түгел дип уйлыйлармы?

Хәзрәтләремез: «Дөнья — үләксә, аңар гашыйк — эт», — дигән булалар; әллә үзләрен эт дип беләләрме?

Билсез казакиле шәкерт: «Милләткә хезмәт итәргә кирәк», — дигән була да, үз башындагы чүпләрен китап базарына ата, әллә «милләт» дигән нәрсәне чүп кәрзинкәсе дип уйлыймы, бичара?

Иске татар шарт итеп кикерә дә: «Әлхәмделилла!» — дип кычкырган була; әллә бичара мигъдәсе бозыклыкны бик зур нигъмәт дип беләме?

«Гашыйк булсаң, рәкыйбләр бик күп чыга», — дигән булалар. Алай булгач, үз-үзеңә генә гашыйк булырга кирәк, һичбер рәкыйб хафаланмас. Көн буе көзгегә карап утырып рәхәтлән.

«Сабыр төбе сары алтын», — дигән булалар. «Шура» идарәсенең 75әр тиен генә бәһа куеп, «Басылмаган шигырьләр мәҗмугасе» вә «Тел ярышы» кеби чүпләр таратуына милләт

---

*Вәхаләнки* — чынлыкта.
*Әлхәмделилла!* — Аллага дан булсын!
*Мигъдәсе* — ашказаны.
*Рәкыйб* — конкурент.

сабыр итә дә, сабыр төбеннән сары алтын түгел, сары бәрәңге дә чыкмый әле.

«Ли көлли имриин ма нәва: фәмән кяинат һиҗрәтеһү иләтдөнья йосыйбеһа вә ила имрәәтин янкихеһа»*, — диләр.

Вә хәлбуки Әхмәтҗан Биктимерев подвалдан вә Вагыйз Нәүрузи сухтәлектән[1] чыкканнан бирле мөхәррир булырга ният итәләр, ләкин мөхәррир түгел, «мәхрәр» дә булганнары юк әле.

«Әйткән сүз — аткан ук», — дигән булалар, хәлбуки Фатих Әмирхан әфәнде Риза казый тугърысындагы сүзләрен кире ала.

«Безнең милләт неблагодарный, ягъни үзенә хезмәт иткән кешеләрен оныта», — дип язгалыйлар. Вә хәлбуки күптән түгел генә Болак күпере астында бер зур кешемезгә памятник[2] салынды.

Имза: фәйләсүфләр.

Идарәдән: «Ялт-йолт» журналына хәзер «фәлсәфи сүзләр» нам бер кыйсем ачылып, зур фәйләсүфләремез кулына тапшырылганлыктан, мөхтәрәм кариәләремезнең әнзаре галияләре** алдына һәр номерда гаять тирән вә бөек мәгънәле фәлсәфәләр дәреҗ ителәчәктер.

Инабәт. — Әгәр берәүгә аны кыйлмасаң: «Син миңа ышанмыйсың!» — дип ачуландыра торган сүздер. Монда мөмкин кадәр кеше ачуыннан курыкмаска тиешледер.

Өч кешедән дөньяда качып котылып булмый: берсе — кендек әбиседер ки, ул сине теләсәң дә, теләмәсәң дә дөньяга тартып чыгарыр. Икенчесе — җаучы карчыктыр. Ул сине, аласы кызыңны күрсәң дә, күрмәсәң дә, алырга теләсәң дә, теләмәсәң дә — өйләндерер. Өченчесе — мөәззиндер. Ул сине, теләсәң дә, теләмәсәң дә — җуар да күмәр.

«Әйләнеч булса да, юл яхшы», — дип, һәммә китап мөштәриләре «Юл» көтепханәсенә тулалар.

Сәдакать — безнең анчак үземездән башкалардан гына таләп итә торган бер нәрсәмездер. «Кәҗә бәете» сахибенең:

Ул кәҗәне кайда күрсәң, шунда кыйна, —
Язык булмас, бәлки сәвап булыр имди, —

* «Һәрбер ирнең үз теләге: әгәр дөньяны теләсә — аңа ирешә. Әгәр берәүгә өйләнергә теләсә — өйләнә».

** Укучыларыбызның югары карашлары.

*Сухтәлек* — шәкертлек.

*Кыйсем* — бүлек.

*Инабәт* — ышаныч.

*Сәдакать* — турылык.

*Сахиб* — ия.

дигән мисрагы «Факъталу-әлмөшрикинә хәйсе вәҗәд-төмуһем» аяте кәримәсеннән мокътәбәс* дип, төрле кыйль вә кальләр йөри.

Ләкин сахибе «Кәҗә бәете[3]» бу тугърыда үзе сөкүт итә. Бу сөкүт гаҗәп түгел: татар мөхәррирләре арасында кеше язган мәфһүмне үз итү бар эштер.

Мәсәлән: Закир Һади язган китапларны бер «корсаклы мөхәррир» үз исемен куеп нәшер итте. Хәррас Айдаров язган «Моназәрә» китабын безнең арыслан йөрәкле «Фикер» мөхәррире[4] үзенеке итә язды.

Ләкин бу кемнеке булса да, сәхибенә фәхер вә гыйззәт түгелдер.

«Рәхмәте илаһия гомуми»дер. Ләкин М.ә.Б. мәрхүм Заһир әфәнде рисаләләренә нидәндер шул гомуми рәхмәттән бер тамчы да тиермидер[5]. Ул рисаләләргә дөньяга чыгуга ирек бирмичә, һаман әгърәфта тотадыр.

Халык исә «Катилә» белән «Мөртәд»нең киң рәхмәте илаһия сәясендә азат ителәчәген көтәдер.

Һади Максуди әфәнде үзенең яңа чыккан «Төрки нәху»ендә болай дип әйтә:

«Өтерләр, күбесенчә, мәшһүр затларның исемнәренең һәр ике ягына куелалар: халыкларны тугъры юлга күндерү өчен «Аллаһе Тәгалә» хәзрәтләре «Мөхәммәт пәйгамбәр» хәзрәтләрен юллаган; «Йолдыз» гәзитәсе Казан шәһәрендә чыга кеби».

Ләкин монда шуны әйтәсем килә: әстәгъфирулла, мин үзем мөселман булганым хәлдә, Аллаһе Тәгаләне өтерләр, бөтерләр, көтерләрсез дә таныр идем.

«Йолдыз» гәзитәсе дип әйтү максуд булганда, бүтән Зөһрә вә Фатима йолдызларыннан аерма өчен, әлеге өтерләр, шөтерләр, мөтерләр кирәк булса да, Аллаһе Тәгалә вә Мөхәммәт пәйгамбәр хәзрәтләре алардан мөстәгънәдерләр.

Өтерләр мәшһүр затларның ике тарафына куелса куелыр, ләкин «Йолдыз» гәзитәсе үзен халикъ вә мәгъбудемез Аллаһе

---

* «Мәҗүсиләрне кайда күрсәгез, шунда үтерегез». Коръән аятеннән алынган.

*Мисрагъ* — куплет, строфа.

*Кыйль вә кальләр* — сүзләр.

*Сөкүт итү* — эндәшмәү.

*Мәфһүм* — мәгънә, эчтәлек.

*Фәхер вә гыйззәт* — мактаныч һәм зурлык.

*Әгърәфта тота* — оҗмах белән тәмуг арасында тота, ягъни «югалтмый да, бастырып та чыгармый» мәгънәсендә.

*Рәхмәте илаһия сәясендә* — Алла рәхмәте аркасында.

*Алардан мөстәгънәдерләр* — аларга мохтаҗ түгелләр.

Тәгалә вә нәбиемез Мөхәммәт Мостафа (гъм)* кадәр үк мәшһүрмен дип уйлый күрмәсен.

«Пьяный шап[6]» Большой Мещанскийдә чакта батмас кеби күренә иде. Хәзер бичараны аннан әллә нинди бер усал көч күчергән дә Болак буена китергән.

Безнең фәйләсүфнең фикеренчә, хәзер «Пьяный шап», Болак елгасыннан ике генә адым еракта булганга, аз гына бер ихтыятсызлык сәбәпле, Болакка җимерелеп төшеп, алдымыздагы кышта шунда ятачак. Язлар җитеп, сулар ташыды исә, завод-мунча сулары илә бергә агып китәчәк (белмим, кая!).

*Фәйләсуф*

***Тәсхыйх:***

Үткән номерда «Фәлсәфи сүзләр» мәкаләсендә «Тел ярышы» дигән сүзләрне «Тиле ярыш» дип укырга кирәк.

## «ГЫЙШЫК» УТЫ

Аһ, җаным! Яңа алган америкaн кәвеш олтаным!

*Ул* — синең ике данә мәскәуский дуга кеби кәкре кашларың!

*Ул* — кап-кара чәчләреңнең озынлыгы һәм куелыгы! Гүя Сембер заводларында җитешкән чем-кара атлар койрыгы!

*Ул* — синең китайский чынаяк төсле зур күзләрең!

*Ул* — синең галанский мич кебек йөзләрең!

*Ул* — синең тәрәзәләргә яуган боз кебек сөйләшкән җылы сүзләрең!

*Ул* — синең Бохар кавыннарыннан да җомры башларың! Ул — синең чынаяк төсле күзләреңнән дөге-дөге тамган яшьләрең! Ул — биш тиенлек пыртманит кеби генә кечкенә калфагың! Ул — Җаекъ, Орынбур ягыннан килгән куй мае берлән генә сачыңны майлавың!

*Ул* — синең, Ак идел камышлары арасына качып чебен аулаган бакалар төсле генә, пәрдә артыннан матур егет сайлавың!

*Ул* — синең нарасый балалар уйнаган кузна кеби матур борыннарың! Ике җилкәңә ябышкан ике сөлек кеби салынган толымнарың!

*Ул* — синең кара урманнарда ап-ак каеннар башындагы карга оялары кеби кабарып торган күкрәгең!

*Ул* — Шам шәриф[1] мәдрәсәләре почмагына корылган чар-

---

* Безне бар итүче һәм табына торганыбыз бөек Алла һәм пәйгамбәребез (аңа сәлам булсын).

*Ихтыятсызлык* — саксызлык.

*Тәсхыйх* — төзәтү.

шаулар кеби киң аклы ситса күлмәгең! Анең эчендә — аят-ел-көрсиләр язылган яшел чардуганлы ап-ак кабер ташы кеби тәнең!

*Ул* — синең борай боткасы уртасында май чокыры кеби гүзәл авызларың!

*Ул* — авызда Мәккәй Мөкәррәмә вә Мәдинәң Мөнәүвәре төяләре авызындагы «зәгъфераннар» кеби чәйнәлгән сагызларың!

*Ул* — синең, барышнялар итәге кеби, ләштер-лөштер генә өстерәлеп йөрешләрең!

*Ул* — Сәет Баттал газинын[2] киерелгән җәясе кеби, авыз җырып көлешләрең!

*Ул* — аглиский ак тарак төсле, рәт-рәт тезелеп торган вак кына тешләрең!

Әйтсәнә, и җаным! Кайчан булырбыз икән мин — әфәнде, син — ханым?!

Күрерменме тыгызлап чорнаган чолгаулы читегемне мышный-мышный салдырган чакларың?!

Кайчан җитәр, чияләп бәйләгән путамны чишә алмасаң, яңагыңнан аллы-гөлле утлар чыгарачакларым?!

Кайчан насыйп булыр икән ак мунчалардан эссе, гатырша майларыннан исле кочагың?!

Син җаный-җанашымны күпме мактасам да, бу дөнья сүзләрен җитәрлек тапмыйм.

Бигрәк тә мондый көйсез нәрсәләр белән тик эчеңне генә пошырырмын дип уйлап, шушы түбәндәге көйле нәрсәләрне язарга каләм тибрәтәм.

Көйле нәрсә:
Ундыр җаный бармагы, ди,
Уникедер балдагы;
(Ай җаный, ичмасам,
Уң битеңдин тешләсәм!)
Тагы да берне кияр иде,
Инде урын калмады.
(Ай алма кисәгем!
Тибеп-тибеп кисәрем!)
Мендем тауга, тоттым карга,
Саескан түгел, чәүкә;
(Ай җаный, ичмасам,
Уң битеңдин тешләсәм!)
Җегет күргәндә дә качмый,
Нишләп җөри ирдәүкә.
(Ай алма кисәгем!
Тибеп-тибеп кисәрем!)

---

*Аглиский (английский)* — инглизләрнекедәй.

Син җаныйның дидарына җан вә дилдән гашыйк булып вә син җаныйның васфыны язудан көйләп тә, көйсез дә гаҗиз калып, каләм тибрәткүче Шүрәле дию белгәйсез.

## БОЗАУ КАДӘРЛЕ ЗУР ФӘЛСӘФӘ

### *(Яхуд акчасыз игълан)*

«Гасыр»ымызның белем — «мәгърифәт»кә «юл» ачарга вә башка милләтләрдән «үрнәк» алырга, киләчәктә үземезгә «икъбал» вә «сәгадәт» «йолдыз»лары тугъдырырга «вакыт». Вә бер-беремезгә «ярдәм» итәргә вә һәр эшләремез үз арамызда «шура» берлән эшләнергә тиештер.

Безнең «тәрәкъкые»мез «икътисад»и хәлемезнең парлакъ булып, «ялт-йолт» итеп торуына багышдыр. Шулай булмаганда, без бүген яки «сабах»та «Идел» белән аккан йомычка кеби, «дин-мәгыйшәт» юлында агып юк булачакмыз. «Гасре җәдит»-емездә бер-беремезгә «фикер»ләр бирешеп тормак лязимдер.

«Тәгатые әфкяр»дә уйларымызның бер-беренә бәрелүләре кара болыт арасындагы уттан булган «уклар», «яшен» кеби, тиз генә сүнмәве матлубтыр.

Күз алдымызда һәр «заман» «хакыйкать» булып, «хак»ны кычкырып, «игъланел хак» итмәк тиештер (хәтта сыра заводы ачылу хакында булса да).

Без шушы олугъ мәмләкәтемезнең сакчысы вә чын гражданы вә бөтен мәгънәсе белән «ватан хадиме» булырга тиешлемез.

Әгәр без, «мелла Насретдин» үзе утырган агач ботагына балта чапкан кеби, милләтнең «ислах» тамырына балта чапсак, бүтән халыклар безнең өстемездән «ха-ха-ха» итеп көләрләр.

---

*Дидар* — йөз, бит.
*Дил* — күңел.
*Васфыны* — сыйфатын.
*«Икъбал» вә «сәгадәт»* — «якты киләчәк» һәм «бәхет».
*«Шура»* — «киңәш».
*«Тәрәкъкые»мез «икътисад»и хәлемезнең парлакъ* — «алга китүебез» «экономик» хәлебезнең якты.
*«Сабах»та* — «иртә»дә.
*«Дин-мәгыйшәт* — «дин-тормыш».
*«Гасре җәдит»емездә* — «яңа гасыр»ыбызда.
*Лязимдер* — тиештер.
*«Тәгатые әфкяр»дә* — «фикер алышулар»да.
*Матлубтыр* — таләп ителәдер.
*«Игъланел хак» итмәк* — «хакны игълан» итәргә.
*«Ватан хадиме»* — «ватан хезмәтчесе».
*«Ислах»* — «төзәтү».

Бохара, Хивә, Хуканд вә гайре ерак җирләрдәге вә җәмигъ «Шәркы рус»тагы карендәшләремезнең әхваль вә «әхбар»ыннан «мәгълүмат» алып торыйк (хосусән дин башчыларымыз).

Югыйсә без һаман да бер-беремезнең максудларымызны «тәрҗеман» аркылы гына аңлашып торсак— «милләт» бетте.

Русларның тәхте пай гәзитәләре кеби, без дә һәр тарафка үз расходымыз илә «Казан мөхбир»ләре җибәрик.

«Асия» хакында да тәрәкъкый «борһан»нары күренергә тиеш инде. «Һиммәт» кирәк.

Мөхәррирләремез арасыннан да тик «шөһрәт» өчен генә язучы вә үзләре «җанлы җеназа» кеби рухсыз кешеләр вә «каләм» урынына «чүкеч» вә сәнәк тотып яза торган тупаслар чыгарылуы «дин вә әдәп» җәһәтеннән дә мәгъкульдер.

Җәнабе хак үзенең «феюзат»е илаһиясен күңелемезгә агызып, без мискин-бичараларны «иршад» итмәсә, безнең шәүкәтемез кояш чыгар алдындагы «таң йолдызы» кеби «тавыш»сыз-тынсыз гына сүнеп, галәме мәдәнияттәге әһәмиятемез бер «зәнбур» кадере дә калмаячактыр.

Милләттәшләр!

Наданлык түбәнлегендә бик күп йөрдек; инде гыйлем вә гыйрфан куәте белән канатларымызны үткен «карчыга» кеби селкеп, күкләргә очарга да ярый.

Затән, безнең ашын ашаган, яшен яшәгән картларымызны, корыган агачтан дуга ясарга мөмкин булмаган кеби, тугъры юлга күндерүе мөшкилдер.

Шуның өчен без алар белән вакыт үткәрмик, бәлки безнең күз тоткан өмидемез — киләчәк яшьләрне «тәрбия» вә «тәрбиятел әтфаль» булырга кирәктер.

Дөньяда «азат» вә «азат халык» булып яшәр өчен, әлбәттә, каумемезнең яртысы булган вә киләчәктә милләт аналары бу-

---

*Җәмигъ «Шәркы рус»тагы* — барча «Россия Көнчыгышы»ндагы.
*«Әхбар»ыннан* — «хәбәрләр»еннән.
*«Тәрҗеман»* — «тәрҗемәче».
*Тәхте пай* — башкала.
*«Казан мөхбир»ләре* — «Казан хәбәрче»ләре.
*Тәрәкъкый «борһан»нары* — алга китеш «билге»ләре.
*«Һиммәт»* — «тырышлык».
*Җәнабе хак* — хаклык иясе (Алла).
*«Феюзат»е илаһиясен* — «мул» рәхмәтләрен.
*«Иршад»* — «туры юл».
*Шәүкәтемез* — дан-шөһрәтебез.
*«Зәнбур»* — «шөпшә».
*Гыйрфан* — аң-белем.
*Затән* — асылда, нигездә.
*«Тәрбиятел әтфаль»* — «балалар тәрбиясе».

лачак «галәме нисван»ымызны укыту тугърысында сөйләүне бөтенләй артык та күрәм инде.

Ничә йөз еллардан бирле мәдәни русларга катышып гомер иткән без татарларга инде хәзер, җәһаләт сәбәпле, «Урал» сәхраларында адашып йөргән бәдәви кыргызлар кеби калмаска тиешле.

Әле, «инә калынлыгы ут, җеп калынлыгы төтен» дигән төсле булса да, мәмләкәтемездә хөррият шәме янганы күренә. Шуның «нур»ыннан бил-истифадә үз арамызда мәхәббәт вә бер-беремезлә «өлфәт» идешмәлиез.

Мәдәният вә заман икътизасы алдында горурланган вә «тилмиз» кеби тезләнмәгән бер халык һичбер вакыт алга бармас.

Чү! Бу минем бозау кадәрле генә зур дип башлаган фәлсәфәм, әле шушы арада гына бер асрау кызны һәлак итеп, үзенең приказчигына, акчалар өстәп, кияүгә биргән Печән базары бае Закир Сумин корсагы кадәр була язды. Җитәр инде.

Актык сүзем.

Мөхтәрәм укучылар!

Шушы кадәрле тирән моталәгаләр вә киң һәм җуан моракабәләр соңында уйлап чыгарган вәгазь вә нәсыйхәтләремне дә игътибарга алып, миңа бер «тилмиз»нең мәдрәсә попечителе татар баена иткәне кадәр дә хөрмәт итмәсәгез, белегез дә торыңыз — мин сезгә бәддога кыйлам.

Ярабби, авызыгыз, Сибгатуллин авызы төсле, бияләй кадәр булсын да бугазыңыз киез итек балтыры кадәр калынайсын! Ул гына җитмәсә, Мәкәрҗәнең «Фоли Бержер» вә «Германия» шамшамиткәләре арасында исерек әтәч кеби кычкырып һәм биеп йөрегез.

Һә! Шулай булмаска, мин сезгә Ярулла әл-Моради да гәзитләрдә яза алмаслык фәлсәфәләр яздым бит.

## ТОЛСТОЙ ХАКЫНДА МӘШҺҮР ТАТАРЛАРНЫҢ ФИКЕРЛӘРЕ

Сәгыйть Рәмиев:

— Толстой — мин, мин — Толстой. Дөньяга ләгънәт көле

---

*«Галәме нисван»* — «хатын-кыз галәме».

• *әһаләт* — томаналык.

*Бәдәви* — күчмә.

*Бил-истифадә* — файдалану.

*«Өлфәт» идешмәлиез* — «дуслык» итешик.

*Икътизасы* — таләбе-теләге.

*«Тилмиз»* — «шәкерт».

*Моракабә* — уй-фикер йөртү.

*Шамшамиткә* — шансонетка, ресторяннарда, трактирларда ачык эстрадада шаян яки әдәпсез җырлар башкаручы хатын-кыз.

чәчәм. Һәм шуның өчен мин — Толстой шикелле, вә Толстой — минем шикелле; дәлил кирәк булса, менә шигырь: «Бәрдемсуктым — ачылды, ләгънәтләре чәчелде... Әлхасыйль, мин — Толстой, Толстой — мин. Ул да үлмәде — мин дә үлмим.

Әхмәтһади Максуди:

— Толстой — карт алпавыт, имеш. Хатынына үпкәләп, йортыннан качкан, имеш. Безнең авыл халкы аны белми, имеш. Аның китапларына миллион сум бирсәләр дә, ул, халыкны шаккаттыру өчен, алмаган, имеш. Әмма миңа шул акчаның уннан берен генә бирсәләр дә, халыкны шаккаттырыйм дип тормас идем, алган булыр идем. Без шулай бөтен нәселемез белән акыллы кешеләр инде. Безнең Садретдин, әлеге Дума әгъзасы Садретдин, минем энем дә, миллион сум түгел, кимрәк булса да алган булыр иде. Хәтта безнең Сәлахетдин дә алган булыр иде. Без алай халыкның шаккатуын теләмимез. Толстой — яхшы кеше, ләкин, бичара, минем «Мизанел әфкяр»не моталәгә кыйлып чыкмый вафат булган, имеш. Мантыйктан хәбәрсез килеш үлеп киткән, имеш. Ходай һидаять бирмәгәч, шулай була, имеш.

Мөхәммәтхан Чәйдәшев[1]:

— Талыстуй, Талыстуй, әмма аның үлеме аркылы игълан җыярга юл ачыла бит. Атнасына өч чыга торган «Чүплег»емдә яңадан бер кат урысча мәкалә дәреҗ итәргә мөмкин була бит. Талыстуй үлде, да здравствует сыра заводларының игъланнары!

Печән базарының Шәмретдин хаҗи[2]:

— Тулстуй, Тулстуй, дип гәҗит тутыралар, мин сиңа әйтим, урыс алпавытында шундый әкәмәт эшләр була инде ул, мин сиңа әйтим. Китап тавары күп булган булырга кирәк; милиум (миллион) сум биргәннәр икән дә, «юк, фаидә (файда) аз бирәсез» дип сатмаган, ди. Тамак тук, мин сиңа әйтим, өст бөтен, мин сиңа әйтим, маена чыдый алмыйча, йортыннан качкан, ди, мин сиңа әйтим.

## МИЛЛӘТКӘ ФАЙДА УРЫНЫНА ЗАРАР

Хәтеремдә ачык калмаган: «Төхфәтел мөлүк[1]»тә намаз сафлары тәртибе бабында: «Әрриҗале, сөммелмораһикунә, сөммәссыйбьяне, сөммәннисаэ, сөммәл хөнса»*, — дигән бугай.

---

* Ирләр, алардан соң яшүсмер егетләр, алардан соң ир балалар, алардан соң катын-кызлар, алардан соң хөнсалар (гермафродитлар).

*Әлхасыйль* — кыскасы.

*Моталәгә кыйлу* — җентекләп уку.

*Мантыйк* — формаль логика.

*Һидаять бирү* — туры юлга төшерү.

Моның гайнән дөрест булып-булмавында минем эшем юк. Дөрест булмаса, «Вакыт» язышучысы Б. Ш.[2] белән «дингә мишәйт»челәр бу тугърыда моназәрә кыйлышып карарлар әле. Ләкин безнең «Җамид Фигури» намендә мәшһүр шагыйремез үзенең язган мәктәп китапларында мәзкүр «Төхфәтелмөлүк»кә шактый игътибар белән карый шикелле.

Бүген кулыма «Вакыт»ның 701 нче номеры төште. Күрәм — игълан: «Кызларга махсус милли шигырьләр!» «Җамид Фигури» әсәре.

Бу шагыйрь моннан элек надан, шовинист булмаган һәр табгы сәлимнең йөзен «Кәримев-Хөсәенев»нең «Җәгърафия мөгаллиме» тышына ямаган кызыл кәгазе кеби кызартырлык бер «Ирләргә махсус милли шигырьләр» язып чыгарган иде. Инде, менә сиңа кирәк булса, хатын-кызлар өчен дә язган!

Шәхсән минем шагыйрь әфәндегә «рәхмәт»тән башка сүзем юк. Шагыйрь әфәнде ихсанлы кеше, һиммәтле кеше.

**ШИГЫРЬ**

Милләте булганга татар,
Ул да булган бер татар;
Кая барсалар да, калмас,
Ташламас ул бунларый...

Шөбһәсез, ул — милләт кешесе. Аның өчен җаны фида!

Әгәр дә ул милләтенә кирәкле дип тапса, түгел кызларга «милли шигырьләр» язу гына, хәтта тавыкларга махсус «милли шигырьләр» дә язып ыргытыр! Куркыныч кеше, әфәнделәр! Булмас димәңез.

Тик сүз ахыры уларак шуны гына әйтәм:

Хәдис шәрифтә әйтә: «Әлмөслиме мән сәлимәл-мөслимүнә гань ядиһи вә лисаниһи»*, — ди. Хәлбуки «Вакыт»та шушы игълан чыкканнан бирле Казанның бөтен китапчылары «Җамид Фигури»нең яденнән вә лисаныннан бизар булдылар**. Бу исә милли шагыйрьгә бер дә ярашмый.

Ничек дисезме? Очень просто: шәһәремезнең бөтен карчыклары вә бөтен хөнсалары гайре мөтәнаһи күп булып җые-

---

* Мөселман кеше мөселманнарны теле белән дә, кулы белән дә рәнҗетмәс.
** Кулыннан һәм теленнән интегеп-йөдәп беттеләр.
*Гайнән* — нәкъ шулай.
*Моназәрә кыйлыш* — сүз көрәштерү.
*Җамид* — туң, каткан.
*Табгы сәлим* — төзек табигатьле, нормаль кеше.
*Ихсанлы* — ярдәмле.
*Һиммәтле* — булышучан.
*Гайре мөтәнаһи* — чиксез.

лышканнар да Казан көтепханәләренә тулганнар. Кычкырышалар, даулашалар, егълашалар!

Карчыклар әйтә: «Нигә ул, мөнәҗәт язучы, без карчыкларга да «милли бәетләр» чыгармаган?» — диләр.

Хөнсалар: «Нигә безне мәхрүм иткән?» — диләр.

Китапчылар исә: «Сабыр итеңез, әле мәктәп китаплары сезоны үтмәгән; ул — булдыклы кеше! Бәлки, сезгә дә бирәр нәрсә язар», — диләр.

Карчыклар вә хөнсалар аяк тибеп кычкыралар: «Юк, сез, китапчылар, җүри безне кимсетәсез, прилавка астыңызда безгә дигәннәре дә бардыр әле!» — диләр.

Китапчылар белән карчык вә хөнсаларның бу талашлары көндез сәгать икедә башланып, палитсә ярдәме белән көчкә кичке сәгать 8 дә басылды. Ул көнне Казан китапчылары, бер тиен дә сату итә алмыйча, авызларын салындырып, өйләренә кайттылар.

Җә инде, бу хәл, әзаэ мөэмин булмый, нәрсә соң? Яхшылыкка түгел бу, шагыйрь әфәнде, яхшылыкка түгел. Бу милли сәүдәне туктату булып, моннан милләткә дә хисапсыз зарар.

Болынга бозау керсә — «түчә!», игенгә чыпчык төшсә — «көшш!», базга песи керсә — «прс!» дисең.

Әмма әдәбиятка шушындый кешеләр керсә — ни дисең? Аптырап, уйлап торасың да, бер дә кууны аңлатырга сүз тапмагач, язучының колагына гына: «Энем, моннан болай мондый нәрсәләр язмаска тырыш!» — дисең.

## ФӘЛСӘФӘ

### *(Монысы бәтидән зур түгел)*

Мөсриф кеше белән мөкътәсыйд арасында аерма шул гына: берсе — хәзерге минутның яхшы үтүен тели, икенчесе — киләчәк көннәрнең матур булуын көтә.

Гади карак берлән Мәскәү малын ашаучы бай арасында аерма шул гына: берсе — камалы якалы туннар киеп, суфиланып, намазларга йөргән булып урлый, икенчесе — бер дә риясыз гына, туп-туры урлый.

Цензор белән он иләүче хатын арасында аерма шул гына: берсенең иләге төбендә эшкә ашмаганрак нәрсәләр кала, берсенекендә иң кадерле нәрсәләр генә кала.

---

*Әзаэ мөэмин* — мөселманны рәнҗетү.
*Мөсриф* — малны урынсызга туздыручы.
*Мөкътәсыйд* — малны саклап тотучы.

Ярминкә белән рамазан арасында аерма шул гына: берсе — бай һәм куписларныкы, икенчесе — кариләр, шәкертләр вә барча пуркиләрнеке.

Риза казыйның дәрес китаплары илә «Рәүнәкыль ислам» вә «Дөррәтен насихин» арасында аерма[1] шул гына: соңгылары — сәләфе салихин тарафыннан язылган, әүвәлгеләре — егерменче гасыр «сәләфе салихине» тарафыннан язылган.

Һади Максуди фәлсәфәсе: «Иртә белән чыккан кояш Печән базары татарларын шаккатыру өчен чыга. Һәм дә граф Лев Толстой, Ясная Поляна урысларын шаккатыру өчен, милиуннардан ваз кичә».

Бу фәлсәфәгә тәнкыйть: юк, алай түгел. Мусин кечкенә тау кадәрле корсагы белән, кыйммәтле фәйтунга утырып, халыкны шаккатыру өчен базарга чыга.

Аптырар Аптырарович, исерек татарларны шаккатырыр өчен, кичен 2шәр йөз тәңкәгә төшереп, шансаниткәләр сикертә.

«Кара, безнең Һади Толстойдан да зур икән!» — дидертер өчен, Һади Максуди «Йолдыз»да Толстойга тел тиереп маташа.

## МӨФТИ[1] ҖҮБӘЛӘЕ

— Шакирҗан бабай, җаңа җыл мөбарәк булсын! — дип, үземезнең авылның чукрак Шакирҗан картның колагына барып кычкырдым.

— Алаймы, алаймы, җүбәләй дисеңме? Мөфти хәзрәткәдер инде ул, — дип, чукрак карт гомер дә мин әйтмәгән сүзгә кереште.

Мин тагы:

— Юк, бабай, җаңа җыл мөбарәк булсын, дим! — дип, колагына кычкырдым.

Бабай һаман үзенчә ишетте:

— Ию, ию, тиеш, бик тиеш: 25 ел мөфти булып торып, һич зарарын тиермәде. Җүбәләй тиеш, җүбәләй тиеш!..

— Юк, бабай, җүбәләйдә эшем юк. Җаңа җыл мөбарәк булсын, дим! — дип, яңадан бер кат тамак төбем ертылганчы кычкырып карадым.

— Ию, ию, җүбәләй тиеш, җүбәләй тиеш! Медальләре дә күп, ди, «Әннәсолул хәдидә[2]» чыккан елны аны да бушлай тараткан икән, ди, хаҗ сәфәрендә дә булган икән, ди, — дип,

---

*Кари* — Коръәнне яттан укучы, Коръән хафиз.
*Пурки* — шәкертләрне мыскыллап әйтә торган сүз.
*Сәләфе салихин* — борынгы заман изгеләре.

бабаем һаман мөфти юбилейсе белән саташуында дәвам итә иде.

Аптырагач, мин дә, тәбригемне онытып, бабай сүзен куәтләргә керештем. Бабаемның колагына ятып:

— Бик дөрест әйтәсең, бабай, медальләре дә күп, хаҗ сәфәрендә дә булды, — дип кычкырдым.

Бабаем башын селекте һәм:

— Ию, ию, сәфәрдә булган дисеңме? Питрбурда булган дисеңме? Шулай, шулай, җүбәләй кирәк! — дип, миңа карады.

Бабайның болай әйтмәгән нәрсәләрне ишетүеннән бизар булып көлеп җибәрдем дә, авызымны бөтенләй колагына тиереп:

— Ию, шулай дим, шулай дим! Тфү, карт пәри! — дип, күземнән яшьләрем килгәнче кычкырдым.

Бабай тагы башын селекте:

— Ә? Шәфигуллинне кыйнап чыгарган иде дисеңме? — дип, колагына кулын куеп, минем янымгук килде.

Мин ике кулымнан труба ясадым, «Ля хәүлә вә ля куәтә!»*не укыдым да, бөтен көчемне җыеп, бабайның колагына:

— Алай димим. 25 ел мөфти булып торып, күзгә күренерлек бер зарар да китермәде, дим, — дип акырдым.

Ахры, бабам ишетте, тешсез авызы белән бик купшылап елмайды да:

— Ию, ию, һич зарарын күрмәдек. Ул да бик зур эш, ул да бик зур эш, — диде.

Бу сүземне ишеттерә алганымнан мин шулкадәр шатландым ки, бабайның үзенә җүбәләй ясыйсым килде. Яңадан кулларымны трубаландырып тоттым, яңадан «Ля хәүлә вә ля куәтә!»не укыдым да бабайның мөбарәк колагына:

— Бабай, менә син дә бик зарарсыз кеше. Колагың ишетми башлаганга 25 ел тулгач, сиңа да бер «җүбәләй» ясармыз, җәме? — дип, бөтен көчем белән бакырдым.

Бабамның җыерчыклы битләре нурланып китте. Бу сүземнең бабайның кәефен китергәнлегендә шөбһәгә юл юк иде. Ул:

— Юк ла, кирәкмәс лә, — дип, бераз назланган иде дә, минем, артык игътираз итмичә, китә башлаганымны күргәч, артымнан:

— Милләт теләсә, ясасагыз ясарсыз тагы! — дип кычкырды.

---

* «Ля хәүлә вә ля куәтә!» — «Көч-кодрәт юк!»; шушы сүзләр белән башланган дога.

*Бизар булу* — аптырау, йөдәү.

*Игътираз итмәү* — каршы килмәү.

## ГАЛИӘСГАР ӘФӘНДЕ КАМАЛНЫҢ 10 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЙСЕ

Ушбу сәнә 5 ноябрьдә «Новый клуб» залында «Сәйяр» мөселман артистлары тарафыннан Галиәсгар әфәнденең 10 сәнәлек әдәби вә милли каләм хезмәте шәрәфенә аның «Бәхетсез егет» драмасы илә «Бүләк өчен» комедиясе куелды.

Бу юбилейне мәхәлли хөкүмәтнең әмере илә афиша вә летучкаларда игълан итмәк мөмкин булмаганга, спектакльгә килгән халык бу мотантан булуы матлуб кичә өчен бик аз диярлек дәрәҗәдә генә иде.

Галиәсгар әфәнденең бу ике әсәре чын татар тормышыннан бик белеп алынган тасвирлар булып, хосусән «Бүләк өчен»дәге, угылын өйләндерә торган татар хатынының халәте рухиясен белү, аның издиваҗ кеби олугъ бер эшкә ничек бер уенчык кына итеп караганын күрсәтү вә шул хатын авызыннан кыз атасы тарафыннан киләчәк бүләкләрне әлхәм укыган кеби яңлыштырмый, гармонично санату фәкать, фәкать Галиәсгар әфәнденең нечкә хиссенә вә тирән күрүенә генә хас бер эш булганга, аннан соң «Сәйяр» труппа артистларының сәхнәдә һәрвакыт, һәр җирдә, һәр шәһәрдә күрсәтәчәк мабиһил-ифтихарлары шушы Галиәсгар әфәнде әсәрләре булганга, шул сәбәпле алар күп уйналганга, бу әсәрләрне уйный белүдә артистлар бөтенләй мөтәхассыйс булып киткәнгә, табигый, уен яхшы чыкты.

«Бүләк өчен» уйналып, пәрдә төшкәч, бөтен халык күңелендә бу уеннан калган гүзәл бер хис аларны үз-үзләрен бөтенләй оныттырганга, бөтен залга тәбрик һәм кул чабу тавышлары яңгырады. «Яшә, Галиәсгар әфәнде! Яшәсен Галиәсгар әфәнде! Яшәсен татар әдәбияты! Яшәсен миллият!» тавышлары залны тетрәткәндә, бөтен яшьләр урыннарыннан сикерешеп торып, Галиәсгар әфәндене җәбрән вә каһрән өстерәп, сәхнә эченә атып, әллә ничә кәррә кулларына күтәрделәр, һәр күтәргәндә, тагы күк күкрәгән кебек кул чабулар, «яшәсен!»нәр бөтен залны әллә ничә-ничә дәкыйкалар тотып торды.

---

*Мәхәлли хөкүмәт* — җирле властьлар.
*Мотантан* — шатлыклы, тантаналы.
*Матлуб* — теләнгән, көтелгән.
*Издиваҗ* — өйләнү.
*Мабиһил-ифтихар* — мактаныч.
*Мөтәхассыйс* — оста, белгеч.
*Җәбрән вә каһрән* — ирексезләп һәм көчләп.
*Дәкыйка* — минут.

Мөхтәрәм мөхәрриремезгә итмәсе тиешле вә лязим булган бу тантаналар бераз басылгач, «Мәгариф» көтепханәсе шәрикләре исеменнән ушбу нотык сөйләнде:

«Мөхтәрәм Галиәсгар әфәнде Камал!

Бүген Сезнең милли әдәбиятымызга каләм илә хезмәт итә башлавыңызга һәм дә мәктәп-мәдрәсәләремезне аяныч хәленнән чыгарып, яңа юлга салуга, яңа рухта тәрбия ителә башлавына вә милли әдәбиятымызның таралуына халкымызның иң беренче ярдәмчесе булган «Мәгариф» көтепханәсене тәэсис итүеңезгә 10 ел тулды.

Сезне бу олугъ көн илән чын күңелемездән тәбрик итәмез, бу хөрмәтле көнгә ядкяран бу кечек һәдиямезне кабул итүеңезне үтенәмез. Вә моннан соң да күп еллар ялыкмый шул юлда дәвам итүеңезгә ышанамыз.

Ихтирам илә «Мәгариф» көтепханәсе әгъзаларыннан — Әмин Мостафин, Кәрим Хәнәфи, Гыйльметдин Шәрәф».

Аннан соң ушбу нотыкта мәзкүр һәдия — гүзәл вә кыйммәтле көмешләнгән альбом тәкъдим кыйлынды.

Һәдия бирелгәч, хазирун янә тәбрик итеп кул чабып, «яшәсен!»нәр белән алкышлап, аз гына тавыш басыла төшкәч, Галиәсгар әфәндегә «Сәйяр» труппа тарафыннан рәүнәкъле вә мөзәйян кәгазьдә ушбу адрес тәкъдим ителде:

«Мөхтәрәм әдибемез Галиәсгар әфәнде!

Татар тарихы безнең белмәгән заманнардан бирле дәвам итә. Татарларның әүвәлге заман тарихларында төрле хасиятләр күренә иде. Соңгы гасырларда татарлар үзләренең иттифаксызлыклары аркасында үзләренең парлакъ мәүкыйгъларын югалттылар. Шул хәл ничә еллар дәвам итте. Татарлар йокладылар. Шундый караңгылык арасында соңгы көннәрдә бер яктылык күренә башлады. Татарлар ушбу заманда үзләренең дөньяда барлыкларын дөньяга белгертә башладылар. Соңгы заманнар-

---

*Шәрик* — компаньон.
*Тәэсис итү* — оештыру, нигезләү.
*Ядкяран* — истәлек итеп.
*Һәдия* — бүләк.
*Хазирун* — шундагы халык.
*Рәүнәкъле вә мөзәйян* — бизәкле һәм матур.
*Иттифаксызлык* — оешмаганлык.
*Парлакъ* — данлы, шанлы.
*Мәүкыйгъ* — урын.

да Европада мөнтәшир мәдәнияттән татарларның да артка калмаганлыкларын күрсәтә торган вакыйгалар дөньяга чыга башлады.

Европа мәдәниятендә мәүҗүд тәрәкъкыятнең әсәрләре* татар галәмендә дә күренә башлады. Татарлар үзләренең әүвәлге мәүкыйгъларын югалтмадылар. Үзләренең хәлләрен, үзләренең дөньяда торырга мөстәгыйд кавемнәр идекләрен белдерттеләр. Европалыларның асаре тәрәкъкыятеннән улан** театрлар да татарлар арасында күренә башлады.

Без, берничә кешедән гыйбарәт труппа, театр хезмәтен әда кыйлу өчен дөньяга чыктык. Безнең дөньяга чыгуымызга Сез, Галиәсгар әфәнде, сәбәп булдыңыз. Үзеңезнең 10 еллык хезмәтеңез аркасында, безнең театрымызны юлга салырга Сез сәбәп булдыңыз. Сезнең язган әсәрләреңез шул мөддәт эчендә сәхнәдән чыкмыйчы дәвам итте. Сезнең әсәрләреңездән «Бәхетсез егет» бу көн утыз җиденче мәртәбә сәхнәгә куеладыр. Шул мөддәт эчендә бөтен җан вә тәнемез илә Кырым, Кавказ һәм Русиянең башка шәһәрләрендә Сезнең әсәрләреңезне без, «Сәйяр» труппа артистлары, бөтен гали хисләремез илә вөҗүдкә чыгарыр өчен иҗтиһад иттек. Без, «Сәйяр» труппа артист вә артисткалары, Сезнең ушбу гали хезмәтләреңезне тәкъдир итәмез. Яшә, Галиәсгар әфәнде! Яшәсен Сезнең куәи тәхририяңез!

«Сәйяр» труппа артистларыннан:

С.З.Гыйззәтуллина, Ф.Сәмитова, Ф.Әхмәдева, Ә.Мостафина, Г.Кариев, В.Мортазин-Иманский, Г.Мангушев, Ә.Кулалаев, Г.Болгарский, К.Шамил».

Буны сөйләгәннән соң, тагы тынычсызлык, тагы шау-шу, тагы тәбрик, тагы «яшәсен!»нәр кычкыру башланды.

Зал бераз тынычлангач, Галиәсгар әфәнде, халыкка каршы торып, аларның тәбрик вә алкышларына каршы кыскача гына рәхмәт сүзе сөйләде. Шуннан соң халык, һич шөбһәсез, Галиәсгар әфәндегә каршы эчләрендә әллә нинди олугъ мәхәббәт уянганы хәлдә, күңелләре тулып таралыштылар. Ихтимал, шул халык арасында иң нечкәргән күңеллесе мин булганмын.

---

* Культурасында булган алга китеш билгеләре.
** Алга китеш-үсеш билгеләре булган.
*Мөнтәшир* — таралган.
*Мөстәгыйд* — сәләтле.
*Әда кыйлу* — үтәү.
*Мөддәт* — вакыт, ара.
*Вөҗүдкә чыгару* — дөньяга чыгару, тудыру.
*Куәи тәхририя* — язучылык көче, сәләте.

Затән гаммәи халык алдында күп сәнәләр хезмәт иткән бер кешегә кычкырып торып: «Син мөхтәрәмсең, синең эшең халык файдасына булды. Синең язганнарың мәңге безнең күңелемездә калачак!» — дип игълан ителгән мөкаддәс бер чакта, мәгъһүд кешегә үз рухының матур ягын вә идеалының изге икәнен халык көзгесеннән үз күзенә күрсәткән чакта күңеле тулмаган кеше таш йөрәкле булырга тиештер.

Минем күңелемдә Галиәсгар әфәнде әсәрләренә моннан әллә ничә еллар элек, ярты сабый вакытымдук, мәхәббәт орлыклары чәчелгән иде. Аның әсәрләрен бу елларда сәхнәдә күрә-күрә вә муаффәкыятьле чыкканнарына тәгаҗҗеб итә-итә, шул мәхәббәт һаман үсә бара, тамыр җәя барадыр.

Мин юбилей кичәсендә Галиәсгар әфәндене, алгы сафтан торып, тамагым карылганча кычкырып тәбрик иткәнем кеби, хәзер дә тәбрик итәм: «Мөбарәк Сезнең 10 еллык хезмәтеңез!»

Һәм дә татар тормышының, Казан мещаннарының иң безгә мәҗһүл почмакларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәтергә каләменең көченнән килгәнлегенә хәйрат итәрәк, аны, Галиәсгар әфәндене, «татар Островские» наме мөкәррәм вә мөстәхәкъкы белән тәгъзыйм итеп*, сүзне бетерәм.

## МӨКАДДИМӘ

Үземезнең яңа үсеп килмәктә булган милли әдәбият бакчамыздан җыеп, яшь балаларымыз кулына шуның чәчәкләреннән ясалган бер чәчәк бәйләме (букет) тоттырмак күптән үк безгә лязим иде.

Моның кирәклеге фикере аңлы мөгаллимнәремезнең башында эшләнеп чыгып, аннан милли гәзитәләремез сәхифәләренә дә гакес иткән иде.

Шушы сәнәдә берничә дуст-ишләр шул матур вә мөкаддәс хезмәтне хосусый миннән илтимас иткәнгә вә һәм ниндининди чәчәкләрдән җыелганда мәзкүр букет гүзәл вә килешле булачагы хосусында минем тәмиземә (саплый белүемә) ышан-

* Хөрмәтле һәм лаеклы исеме белән олылап.

*Затән гаммәи халык* — асылда халык массасы.
*Мәгъһүд* — шушы.
*Тәгаҗҗеб итә-итә* — гаҗәпләнә-гаҗәпләнә.
*Мәҗһүл* — билгеле булмаган, яшерен.
*Хәйрат итәрәк* — хәйран калып.
*Мөкаддимә (мөкаддәмә)* — сүз башы.
*Гакес итү* — чагылу.
*Илтимас итү* — үтенү.

ганга, мин дә бу хөсне занга тәшәккер итеп, ушбу «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабыны тәртип иттем.

Монда төрле багъбаннарымызның хәссас күңелләрендә җитешкән әдәбият гөлләреннән берәр-берәр чәчкәләр алынды.

Безгә сабый балаларымызның кулында моңарчыга кадәрле булган әрекмән, кычыткан вә балтырганнарны алып, алар урынына шушы китап кеби чәчәк бәйләмнәре бирергә тиештер. Таки балаларымызның күзе гүзәл нәрсәләр күрергә вә борыннары да хуш вә татлы исләр иснәргә иярләшсен.

Кечкенәдән гүзәл нәрсәләр укыган балаларның күңелләре дә назик вә ләтыйф булып, анчак гүзәл вә мөкаддәс нәрсәләрне генә сөючән буладыр.

Моның киресенчә: кечкенәдән тупас вә ямьсез нәрсәләр күреп үскән балаларның язгы ачык күк кеби саф күңелләре томанланып, рухлары яхшыны вә начарны аермый, һәрнәрсәгә бертигез карауччы буладыр.

Әдәбиятымызның иң гүзәл кыйтгаларын гына сайлап яки сайларга тырышып та, вә гүзәл булып та, балалар рухына килешмәслекләрен калдыра торып та, уртача вә түбәнрәк тәхриратка бөтенләй әһәмият тә бирми торып та һәм әдәбият казанымыз өстендәге зөбдәләрне генә җыя торып та, шушы «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» кеби олугъ бер китап мәйданга куярга мөмкин икәнен күргәч, яшь әдәбиятымызның байлыгына вә киңлегенә хәйран иттем вә шатландым.

Татарда тел юк, әдәбият юк диюче мөтәгассыйбларны (бөтен мәгънәсе илән) кызгандым. Әйе, бездә әдәбият бар һәм дә бай әдәбият!

Ләкин ни сәбәптәндер бу көнгә чаклы мәктәп вә мәдрәсәләремездә милли әдәбият вә ана телемезгә бертөрле курку аралаш нәфрәт белән карыйлар иде.

Бик искедән бирле килгән бу караш, мәктәпләрдәге сабыйлар башына урнашып, алардан аларның балаларына дигән кеби, бөтен милләтемезгә тамыр җәйгән иде.

Шунлыктан безнең мөхәррирләр вә шагыйрьләремезнең күз

---

*Хөсне занга тәшәккер итеп* — яхшы карашка рәхмәт әйтеп.
*Багъбаннарымыз* — бакчачыларыбыз.
*Хәссас* — сизгер.
*Таки* — «әйдә шулай булсын» мәгънәсендә.
*Назик вә ләтыйф* — нечкә һәм гүзәл.
*Анчак* — тик, фәкать.
*Кыйтга* — (өзек), үрнәк, парча.
*Тәхрират* — язма әсәрләр.
*Зөбдә* — каймак.
*Мөтәгассыйб* — искелек яклы, тискәре кеше, фанатик.

яшьләренә манчып язган каләмнәрендин чыккан әсәрләренә «чүп» дип вә язучысына да «эшсез» дип кенә карыйлар иде. Шундый карашлар зарарыннандыр ки, без әле Гаяз әфәнденең «Инкыйраз»ы кеби сәтырына — сәтыр алтын белән тегелеп язылган гали әсәрләрнең һаман икенче кәррә табгы ителгәнен мәгаттәәссеф күрә алмыйбыз. Вә хәлбуки боларның һәр шәһәр татарының өстәлендә, һәр авыл мужигының пич башында берәрданә булып торулары лязим вә хәтта фарыз иде.

Бу китапны тәртип иткәндә, мин һәр никадәр балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итүне беренче максуд итеп тотсам да, икенче тарафтан, әдәбиятның мәктәпкә керүе аркасында аңар гомум милләт тарафыннан әһәмият бирелмәсме вә шул саядә әдәбият Русия мөселманнары арасында тиешле кадәр таралып китмәсме дигән өмидем дә бар иде.

Бу китап өчен мин үземчә яхшы вә матур дип белгән кыйтга вә шигырьләрне генә сайларга тырыштым. Русларның «вкуста шәрик юк» дидекләренчә, бәлки, минем бу интихабымны тәнкыйть итүчеләр булыр, ләкин мин андый кешеләргә алдан ук:

Кара карлыгач буласың,
Кара камзулың кигәч;
Кеше теләсә ни әйтсен,
Үземнең җаным сөйгәч, —

дип җырлап кына җавап биреп куям.

Рус тәрбия голямасының соң заманда мәйданга китердекләре «Живое слово» нам кыйраәт китабы минем «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең тарзы тәртибендә рәһбәр итеп* тотылды.

Бу китап мөгаллимнәр нәзарында кабул табып китсә, мин ул мөхтәрәм әфәнделәрдән аны укытыр өчен күп мәшәкатьләнүләрен хәзергә көтмим. Ягъни аларга моңар кадәрле күрелмәгән ят бер кыйраәт китабының үзе ят булганы кеби, аны балаларга укыту рәвеше дә ят тоелачактыр.

Шунлыктан алар хәзер балаларга бу «Милли әдәбият дәресләре»не дә, бүтән китапларны укыткан кеби, беррәттән, су эчергән кеби укытып чыгарсалар да, өстләреннән бурычларын төшерерләр хисап итәм.

---

* Төзү рәвешендә үрнәк итеп.
*Шул саядә* — шуның аркасында.
*«Вкуста шәрик юк»* — «һәркемнең зәвыгы бертөрле булмый» мәгънәсендә.
*Интихаб* — сайлап алу.
*Тәрбия голямасы* — педагогия галимнәре.
*Кыйраәт* — уку.
*Нәзар* — караш.

Соңга таба, тәрәкъкый вә мәгърифәтемез арттыгы нисбәттә, башка кыйраәт китаплары һәм башка мөгаллимнәр чыгып, башка тәгълим рәвеше берлән тәгълим итәрләр.

Шулай да һәр мөгаллим, үз икътидары дахилендә, балалардан укыдыклары нәрсәләр тугърысында сөальләр итсә вә балалардан үз сүзләре белән сөйләтсә вә бәгъзе җиңелрәк шигырьләрне хифыз иттерсә, зарарсыз булыр иде.

Мин моннан әүвәл язганым «Яңа кыйраәт» китабымны, аның мөндәриҗәты үз тәхрир вә тәрҗемәләрем генә булганга, һәр шигырь вә мәкаләләрен бертөрле мәгълүм максат белән дәреҗ иткән идем.

Мәсәлән, аның әүвәлендә дәреҗ ителгән «Табигать вә инсан» мәкаләсе вә «Аллаһе тәбарәкә вә Тәгалә» шигыре белән, бисмилладан соң мөсаммәне, ягъни Аллаһе Тәгаләне, балага таныту вә соңгы шигырь белән балада Аллаһе Тәгаләгә каршы мәхәббәт уяту максаты; икенче, «Туган авыл» кеби шигырь белән пәйгамбәремезгә мәхәббәт хисе кузгату, аннан соң шул тирәдәге мәкаләләр белән балада ата-анасына мәхәббәтне көчләндерү. Аннан да күчкәч, «Туган тел» шигыре белән туган тел вә әдәбиятымызга мәхәббәт уяту. Бераздан «Чыршы», «Җил илә Кояш», «Яңгыр илә Кояш» мәкалә вә шигырьләре белән баланы дөнья вә табигать хакында уйлату һәм аны сөйдерүне күзгә алу. Тагы бераздан «Ике Сабан» хикәясе, «Эш» вә «Япон хикәясе» шигырьләре белән балаларны эш вә иҗтиһадка тәргыйб итү.

Аннан да соң мотлакъ рәвештә берничә мәсәлләр язып үткәч, балаларга галәме табигатьнең һәртөрле хәл вә эшләрен күрсәтер өчен (балаларга бераз күңелсезрәк булса да), «Кояш», «Җир», «Су», «Һава», «Елның дүрт фасылы» кеби фәнни вә гыйльми мәкаләчекләр язылды.

Аны да үткәч, «Шүрәле», «Бәйрәм бүген», «Пар ат» кеби шигырьләр вә «Казан шәһәре» мәкаләләре белән балаларымызда миллият вә милләт мәхәббәте тугъдыру өмид ителде.

Ләкин бу «Милли әдәбият дәресләре»ндә «Яңа кыйраәт»тә булганы кеби мәгълүм бер максат вә мәсләк тотылмады. Чөнки, югарыда язганымча, бу китап төрле нәмүнәләрдән жы-

---

*Тәгълим* — укыту.

*Икътидары дахилендә* — көче җиткәнчә.

*Сөаль* — сорау.

*Хифыз иттерү* — күңелдән бикләтү.

*Иҗтиһадка тәргыйб итү* — тырышырга кызыктыру.

*Мотлакъ рәвештә* — гомумән.

*Галәме табигать* — табигать дөньясы.

елган бер китаптыр. Бер чәчәк бәйләмендә кайсы төстәге чәчәкне уртага вә кайсысын читкә кую вә бер альбомда да кайсы рәсемне кайсы биткә сыйдыру бик ул кадәр әһәмиятле булмаганы кабиленнән, бу китапта фәкать ямьсез тәхрират кермәвенә генә тырышылды. Шулай да булса, ягъни мәгълүм бер мәсләк тотылмаса да, педагогиканың «җиңелдән авырга» кагыйдәсенә бераз игътибарга алынып, китапның башына аңлавы җиңел, садә гыйбарәле шигырьләр вә кыйтгалар куелып, авыррак гыйбарәлеләрне мөмкин кадәр арткарак кичектерелде. Шигырь вә кыйтгаларда булган бәгъзе читенрәк сүзләрне аңлатыр өчен, сәхифә төбенә шәрех тә төшерелде. Төшерелми калып та, фәһеме авыр булган гыйбарәләр булса, аларны балаларга тәрҗемә итеп аңлатуны мөгаллим әфәнделәрдән үтенәмен.

152 сәхифәлек булган бу китап «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең беренче кыйсьмедер. Хода насыйп итеп тә, киләчәк кыйсемнәр тәртип ителсә, аларга күбрәк хезмәт кертеләчәк вә шаять мәшһүр кешеләремезнең тәрҗемәи хальләре вә рәсемнәре дә дәреҗ улыначактыр. Болардан башка милли тарихымыздан, милли тормышымыздан рәсемнәр кертү өчен дә иҗтиһадта кимчелек ителмәячәктер.

Хәзергә ушбу кадәр илә сүземне тәмам иттем.

## ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫ

### ЯЗУЧЫДАН

Бу хәзерге кулыңызга алдыгыңыз «Халык әдәбияты» моннан аз гына мөкаддәм мәйданга куелган «Халык моңнары» исемендәге рисаләмә тәмамән багълыдыр.

Бу ике рисалә бер-берсенә тәгаллекъгә берсе ачкыч вә икенчесе йозак кабиленнәндерләр.

Шул сәбәпле бу рисаләләрнең берсен алып укырга тәнәззел боерган мөхтәрәм кариәләремнән икенчесен дә әлдә итмәкләрене үтенер идем.

«Халык әдәбияты» намендәге бу рисаләм Казанда «Шәрекъ

---

*Фәһеме* — аңлавы.
*Кыйсьме* — өлеше.
*Тәрҗемәи халь* — биография.
*Рисалә* — әсәр, кечкенә китап.
*Тәгаллекъгә* — бәйләнештә.
*Тәнәззел боерган* — түбәнчелек иткән.
*Кариә* — укучы.
*Әл* — кул.

клубы»нда, ушбу сәнә 15 апрельдә укыдыгым (итлакъ җаиз исә) лекциямнең мәзмуненнән гыйбарәттер.

Лекциядә җыруларымызның берничәсе генә, анчак лязим урында мисал өчен алынганнары гына зикер ителде. Анда, әлбәттә, «Халык моңнары» нам бөтен бер мәҗмуга тәшкил иткән җырларымызның барчасын укып чыгарга тугъры килмәде.

Менә хәзер җырларымыз хакында байтак мөляхәзәне җәмигъ булган «Халык әдәбияты»ны укыганда, шактый күп мөнтәхәб җырларымызны эченә алган «Халык моңнары»ны да алга ачып кую файдасыз булмаса кирәк дия, сүзне бетердем.

*Г.Тукаев*

**ИГЪТИЗАР**

Халык әдәбияты хакында хәзер сөйләячәгем лекция сымак нәрсәм өчен мин алдан озак тәхкыйкат вә тәдкыйкат илә хәзерләнмәгән идем.

Көннәрдән бер көн бер иптәшемә уйнап кына: «Мин халык әдәбияты тугърысында лекция укыйм», — дип әйткән идем. Ул, шуңар ышанып, Тукаев лекция укыячак икән, дип, мөгътәбәр гәзитәләремезнең берсенә язып та өлгергән.

Мин, ул иптәшем яныннан чыкканда, уйнап әйттем, ышанып калма тагы, дип әйтергә онытканмын.

Менә шулай итеп, яңлыш, уеннан уймак чыгып куйгандай булып, мин, теге гәзитә хәбәрен тәкзибкә-фәләнгә керешмичә, чынлап та халык әдәбияты хакында үземнең белгән вә хис иткән кадәр фикерләремне сөйләргә җәсарәт итәм.

Бу эш миңа көтелмәгәндә генә килеп чыккан булганга, җырулар вә көйләремез тугърысында тарихи вә әсаслы мәгълүмат бирә алмыйм.

Безнең җырланмакта булган көйләремезнең һичберсе дә бер-бер сәбәпсез, бер-бер нәрсәнең тәэсиреннән башка чыкмаган булса да, мәгаттәәссеф, аларның сәбәпләрен вә тарихларын тикшерергә кулымда материал булмады.

---

*Итлакъ җаиз исә* — әйтергә яраса.
*Мәзмун* — конспект.
*Анчак лязим* — бары тик кирәкле, тиешле.
*Зикер ителү* — телгә алыну.
*Мөляхәзәне җәмигъ булган* — фикерләрне эченә алган.
*Мөнтәхәб* — сайланган.
*Игътизар* — гафу үтенү.
*Тәхкыйкат вә тәдкыйкат* — тирәнтен тикшерүләр.
*Тәкзиб* — ялганга чыгару.
*Җәсарәт итү* — батырчылык итү.
*Әсаслы* — төпле, нигезле.

Җырларымыз вә көйләремезнең тарихын вә мәнбәгъләрен тикшерергә берзаман махсус хезмәт куярмын да, шаять, халыкка шул тугърыда әсаслырак мәгълүмат бирермен дигән өмидем бар әле.

Хәзер сөйләгән сүзләремнән исә бер-бер төрле тирән мәгълүмат көтүчеләр булса, бик каты алданырлар шикелле тоела.

Озын вә кыска көйләремез тугърысында халык авызында төрле сүзләр сөйләнә. Аның барчасын да җыеп язу шактый озак заман эстидер. Шулай да сүз арасында халык авызындагы сүзләрнең үземә ишетелгән кадәресен бераз язып китәргә ярый.

### «ТӘФКИЛЕВ» КӨЕ

Борынгы Тәфкилев фамилияле бер мөфтинең урысча укый торган бик матур бер кызы бер француз җегетенә гашыйк булган була. Кыз француз җегетен, ата-анасы күрмәгән чакта, өенә дә китерә.

Бервакыт шулай, мөфти хәзрәт өендә кыз белән җегет күрешеп торган чагында, өстләренә мөфти хәзрәт үзе килеп керә.

Кыз, аптырауда калып, үзенең мәгъшукын зур пыяла шкаф эченә яшерә.

Алай да мөфти хәзрәт җегетне күрә. Таягын алып, җегетне кыйнарга килә башлый.

Җегет исә, тиз генә шкафны ватып чыгып, тәрәзәдән сикереп кача.

Шкафны ватканда, җегетнең битенә вә кулына пыялалар керә. Идәнгә җәелгән хәтфә паласлар өстенә каннар тама...

Минем исемдә шулкадәр генә калган.

Аннан соң җегет белән кыз арасында нинди маҗаралар булгандыр, миңа мәгълүм түгел. Ләкин «Тәфкилев» көенең моңлылыгына караганда, җегет белән кыз арасында мотлак бер фаҗига булгандыр дип фикергә килә.

### «АШКАЗАР» КӨЕ

Гыйшык вә мәхәббәт сәбәпле кияүгә барган бер башкорт түрәсе кызының кияве, Ашказар дигән суның буена ау ауларга китеп, шунда суга батып үлә. Моның вафат хәбәре мәгъшукасына ишетелгәч, ул бик кайгыра. Хәсрәтен ничек изһар итәргә дә аптырый.

Беркөнне бу кыз, башкорт кызлары арасындагы барча җырчы кызларны чакырып, алардан вафат булган кияве хатирәсе-

---

*Мәнбәгъ* — чыганак.
*Мотлак* — шиксез.
*Изһар итәргә* — тышка чыгарырга.

нә бик моңлы бер көй чыгаруларын үтенә. Әгәр дә күңеленә муафикъ бер моңлы көй чыгара алсалар, аларга әллә ничә баш төяләр һәдия итмәкче була.

Кызлар төрлечә көйләр чыгарып карыйлар, ләкин берсе дә түрә кызының күңеленә ошамыйлар.

Бу җырчы кызлардан бернәрсә дә чыкмагач, түрә кызы, бертөрле рух вә илһам белән рухланып, хәзерге «Ашказар» көен җырлап җибәрә. Җырчы кызлар хәйран калалар.

### «САК-СОК» КӨЕ

«Сак-Сок» бәете вә көенең нидән чыкканлыгы Сак-Сокның үз бәетләреннән дә күренә.

Бәетләрдән аңлашылдыгына караганда, бер ана үзенең ике баласын: «Сез Сак-Сок булсагыз иде», — дип каргый. Шул ук минутта балалар, Сак-Сок дигән ике кош сурәтенә кереп, кара урманга очып китәләр.

Балаларны каргаганда, аталары өйдә булмый бугай. Ул, кайткач, балалар кайда, дип, хатыныннан сорый. Хатын: «Каргап очырдым», — ди дә үкереп җылый башлый. Ире шелтә итә.

Балалар исә искән җилләр аркылы гына аталарына үзләренең хәсрәтле сәламнәрен җибәреп торалар.

Менә бу шуннан чыккан көй.

### «КАСИМСКИЙ ИБЫРАЙ»

Бу — Касим шәһәрендәге чамадан тыш мөсриф бер байга чыгарылган көй, Касимский Ибырай гуләйт итә-итә дә актык тунын да сата. Ахыр гомерендә бик хосранлы рәвештә вафат була.

«Касимский Ибырай» көе шул сәбәптән чыга.

### «ҖИЗНӘКӘЙ»

Бу көй бер кияүнең үзенең балдызына гашыйк булуыннан чыга. Кияү, хилафе шәргы рәвештә, балдызын да никахлап алып, ике кардәшне бергә җыймакчы була.

— Агач башы базыктыр,
Балдыз алу языктыр;
— Язык булса — ни миңа,
Язык казык башына... —

җыруы шушыңар дәлаләт итә.

---

*Һәдия* — бүләк.

*Мөсриф* — исраф итүче, мал, акча туздыручы.

*Хосранлы* — үкенечле.

*Хилафе шәргы* — шәригатькә каршы.

*Дәлаләт итү* — дәлил булу.

## «БАШМАК» КӨЕ

Бу «Башмак» көе дә мөфти вә мирзаларымыздан зур фамилияле бер кешегә чыгарылган көй булырга кирәк.

Ләкин тәгъйин кемгә вә ни хосуста чыгарылганын, мәгаттәәссеф, тәфтиш итә алмадым.

Бу көй, зан идәрсәм, берзаман хөкүмәт тарафыннан җырланырга мәнгы да ителгән иде бугай.

Көйләр тарихы хакында бар белгәнем шушы кадәр генә булганга, хәзер мин аннан күчәм дә максудым булган халык әдәбиятына киләм. Шул тугърыда булган мөляхәзәләремне сөйләмәкче булам.

## ХАЛЫК ӘДӘБИЯТЫ

Халык әдәбияты, халык шигырьләре дип инша итүче шагыйре беленмәгән яки уйлап чыгаручысы вә әүвәл кем тарафыннан сөйләнгәнлеге мәгълүм булмаган хикәя вә масалларга әйтеләдер.

Бу нәүгы әдәбият, әле дөньяда язу сәнгате булмаган чактук, авыздан авызга сөйләнеп, бабадан — атага, атадан балага ишетелеп, буыннан буынга калып килгән әдәбияттыр. Әгәр дә «су», «чиләк», «бүрек», «арба» дип әйткән сүзләрне иң әүвәл кем чыгарган дигән сөальгә җавап биреп булмаса, «Аклы ситса күлмәгеңне кигәнеңне күрмәдем» җыруын яки «Эт симерсә, иясен тешләр» мәкален иң элек кем чыгарган дигән сөальгә дә җавап биреп булмыйдыр.

Халык әдәбияты, бер дә кәгазьгә язылмаса да, буыннан буынга ишетелеп, халык күңелендә бер дә онытылмый торадыр.

Халык әдәбияты китапка керсә дә, язылса да, анчак бер, халык җырларын вә әдәбиятын җыеп, китап рәвешендә таратуны теләүче бер кеше тарафыннан гына кертеләдер. Шул кеше үзе ишеткән вә тапкан кадәр җыр вә масалларны язып нәшер итәдер.

Халык әдәбиятының ничек булганын күрсәтер өчен, мин монда халык авызындагы кыска гына бер хикәяне алып яздым.

---

*Тәгъйин* — тәгаен.
*Тәфтиш иту* — тикшерү.
*Зан идәрсәм* — уйлыйм ки.
*Мәнгы ителү* — тыелу.
*Мөляхәзә* — фикер йөртү, уйлау.
*Инша итүче* — чыгаручы.
*Масаллар* — мәсәл-әкиятләр.
*Нәүгы* — төр(е).
*Анчак* — тик, фәкать.

Бер авыл кешесе, төн буе ашасын өчен, урманга атын җибәрә икән. Иртә берлән, эшкә җигәргә дип атны алырга барса, ни күзе белән күрсен: атын шапырма тиргә баткан, төн буе әллә ничә йөз чакрымнарны бер дә туктамастан чапкан кеби, тәмам хәлдән тайган көе таба. Бу кеше, атны алып кайтып, ничек кирәк алай эшләтә дә, кич булгач, тагы шул ук урманга җибәрә. Иртә берлән урманга барса, атны тагын шулай эштән чыккан килеш таба. Атның бу хәлгә төшүенә һичбер сәбәп тапмый гаҗәпләнә. Бичара кеше, атының шулай газапланып арыгаюыннан тәмам гаҗиз калгач, авылда бер ак сакаллы карттан бу тугърыда сораша башлый. Карт бу кешегә киңәш бирә: «Син, — ди, — бүген кич атыңны урманга җибәргәндә, аркасына сумала ябыштырып җибәр», — ди. Теге кеше карт кушканча эшли.

Кеше иртә белән атны алырга барыйм дип капкасыннан чыкса, күрә ки, ат үзе кайтып килә. Өстенә ат аркасындагы сумалага чытырдап ябышып каткан Шүрәле атланган. Беленә ки, төн буена атны чаптырып газаплаучы шушы Шүрәле икән. Дәрхаль авыл халкын чакырып, Шүрәлене ат өстеннән алалар. Шүрәлене күсәкләр белән бик каты кыйныйлар. Шүрәле үлми. Авыл халкы, бу усал Шүрәлене ни рәвешчә, ничек итеп үтерү тугърысында күп киңәштән соңра, аны базга салып, өстенә керосин сибеп яндырып үтерергә карар бирәләр һәм шулай эшлиләр. Шүрәле бичара яна, кычкыра, фөрьяд итә, ахырында янып көл була. Ләкин җаны чыкканчыга кадәр бу авылны каргый: «Ярабби, бу авыл утыз өйдән артмаса иде», — ди.

Менә Казан артында бер авыл бар, ул авылның салына башлаганына йөз елдан артык бер заман булса да, һаман да 25–30 өйдән артмый. Теге Шүрәлене яндыручы авыл шушы авыл, имеш. Бу авылга Шүрәленең үләр алдындагы каргышы төшкән, имеш.

Менә бу кеби хикәяләр халык хикәяте, халык әдәбияты дип аталалар. Чөнки моны сөйләүче кем? Гайнетдинме? Сәйфетдинме? Котбетдинме? — асла мәгълүм түгел. Бу — фәкать гомумхалык хыялы, халык хикәясе.

Ихтар: әгәр дә шушындый ук хикәя бер-бер мөхәррир йә шагыйрь тарафыннан бизәкләп вә матурлап язылса, инде ул «халык әдәбияты»лыктан чыга. Бу җөмләдән Пушкинneң «Алтын

*Дәрхаль* — шунда ук, шул ук вакыт.
*Фөрьяд итү* — ялвару.
*Асла* — бөтенләй.
*Ихтар* — искәрмә.

балык» вә «Алтын әтәч» кеби хикәяләрен санарга мөмкин. Мондый хикәяләрнең башта халык авызында сөйләнүе дә вә халык рухынча язылуы да аның «халык әдәбияты»лыктан чыгуына манигъ була алмый. Чөнки, бәя әйткәнемезчә, халык әдәбияты дип, язылган вә мәзбут нәрсәләргә әйтелмичә, авыздан авызга сөйләнеп йөртелгән нәрсәләргә генә әйтеләдер.

Бу булды халык хыял вә хикәясенең бер нәмүнәсе. Яхшы. Менә сезгә халык шигырьләреннән дә бер нәмүнә:

Минем сөеп җиккән атым
Кара берлән тимеркүк;
Сагынганда айга карыйм —
Ай да ялгыз минем күк.

Менә бу — шигырь, һәм дә хәкыйкатән шигырь. Ләкин кем моны инша иткән? Һич тә билгеле түгел. Моны инша итүче, сөйгәненең йөзен искә төшереп, айга карый да, соңра бик матур рәвештә, шагыйранә генә: «Ай да ялгыз минем күк!» — дип куя.

Сүз башында әйткәнемезчә, менә мондый шигырьләргә халык җырлары дип әйтелә. Бу җыруның әүвәлендәге ике юлы, ягъни: «Минем сөеп җиккән атым кара берлән тимеркүк», — дигән сүзләренең соңгы ике юлга бик ябышуы булмаса да, соңгы: «Сагынганда айга карыйм — ай да ялгыз минем күк», — дигән мәгънәле вә хисле сүзләрнең астына нинди истигъдадлы шагыйрь дә кул куюдан тартынмас дип уйлыйм.

Аннан соң безнең халыкта җырлар өчен әүвәлге ике юлның күп вакытта бер дә әһәмияте дә булмыйдыр. Әүвәлге ике юл анчак скрипкә уйнаганда бер кәррә кыл тартып кую кабиленнән генә бер нәрсәдер.

Мәсәлән, гавамнан берәү җырлый: «Сандугачлар су ташый, кайда икән су башы». Ул бу сүзләрен җыруга санамый, бәлки тыңлаучыга үзеннән бернәрсә көттерә.

Тыңлаучы: «Бу нәрсә әйтмәкче була икән?» — дип көтеп торган чагында гына, ул: «Безнең җанкәй ялгыз башы, Хозыр булсын юлдашы», — дип куя.

Шулай көтмәгәндә генә килеп чыккан бу матур сүзләр тыңлаучының колакларына вә күңеленә, әлбәттә, хуш килә.

Бу тарыз җырлау табигый рәвештә сайланган булса да,

---

*Мәзбут* — язу белән беркетелгән.
*Нәмүнә* — үрнәк.
*Хәкыйкатән* — чын-чыннан.
*Истигъдадлы* — талантлы.
*Гавам* — гади халык.
*Тарыз* — рәвешле.

бик муаффәкыятьле сайланган. Әүвәл юк кына сүзләр берлән тыңлаучының колагын торгыз да аннан соң мәгънәле сүз әйт. Бик яхшы бит! Шулай көтеп алган кадерле була.

Бу сүзләр безнең җырларымызның күп тарафы шулай — әүвәлге ике юлы соңгы ике юлга ябышмаган булганлыктан гына сөйләнде.

Югыйсә безнең һәр дүрт мисрагы да бер-беренә ябыша торган җырларымыз да бар.

Мәсәлән:

Җаныем, җаныем, җанашым, авыртмыймы җанбашың?
Авыртсалар, ай, җанбашың, үзем түшәк, җанашым.
Мин сөямен үзеңне, кашың берлән күзеңне;
Мин сөйгәнне син шуннан бел: һич тә алмыймын күземне.

Ләкин болар мөстәсналәр диергә ярый.

Инде халык җырлары вә халык әдәбияты дип нәрсәгә әйтелгәне, шаять, азрак аңлангандыр дип уйлыйм.

*

Халык җырлары — безнең бабаларымыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр. Әйе, бу — кадерле мирас, кыйммәтле мирас! Мәгъмур Болгар шәһәрләре, Болгар авыллары, бер дә булмаган төсле, кырылдылар да беттеләр, эзләре дә калмады.

Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә һәртөрле бәлая вә казаядан, муллалар әйтмешли, мәсун вә мәхфуз уларак калдылар, алар сәламәт әле, алар яңгырый әле.

Халык җырларының шулай җәүһәр вә якутлардан да кыйммәтле бернәрсә булганы өчен дә аларга әһәмият бирергә кирәк. Аларны югалтмаска иҗтиһад итәргә кирәк.

Белергә кирәк ки, халык җырлары — халкымыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә рәушан көзгеседер. Бу — бертөрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр.

Менә шушы дәгъване, ягъни халык җырларының сихерле

---

*Муаффәкыятьле* — уңышлы.
*Мисрагъ* — җыр, шигырь юлы.
*Мөстәсна* — аерым очрак, чыгарма.
*Мәгъмур* — төзек.
*Мәсун вә мәхфуз уларак* — сакланып.
*Рәушан* — якты.

күзге икәнен күрсәтер өчен, хәзер берничә җырлар җырлап күрсәтәмез.

Мәсәлән:

Байлар кияр каракүл, без киябез эшләпә;
Ходай бәхетне бирмәсә, баеп булмый эшләп тә.

Менә бу җыру — халкымызның бу дөньядагы «байлык» вә «фәкыйрьлек» дигән ике нәрсәгә карашы. Анынча, «Ходай бәхетне бирмәсә, баеп булмый эшләп тә».

Кимим — бүркем булса да, җыламыйм — күңлем тулса да;
Ходай кушкач, нихәл итим, чыдыйм — авыр булса да.

Менә бу — халыкның Ходай тәкъдиренә чын күңелдән тапшырылуын һәм, никадәр авыр булса да, үзен-үзе чыдарга көчләвен күрсәтә.

Ак келәтнең тәрәзәсе сиксән сигез өлгеле;
Начар кызларга бәйләнсәң, хур буласың билгеле.

Менә халыкның «ак келәтнең тәрәзәсе» кеби юк кына нәрсә белән сүз башлап та, «начар кызларга бәйләнсәң, хур буласың билгеле» кеби, чын хакыйкать сүзне шартлатып әйтеп тә бирә алуы. Монысын, мотлакан, халыкның әдәби икътидары диергә ярый.

Җөрмә монда, кайт иленә, иленә иген игәрсең;
Стаканыңны ат итеп бутылкаңны җигәрсең.

Менә монысы халыкның үткен гакыллылыгын, русча әйткәндә, остроумиесен күрсәтә. Чынлап та, сукасын, сабанын, әвенен, хатынын, бала-чагасын онытып эчеп утырган бер сала мужигына, шулай итеп, каладан китәргә киңәш бирмичә, ни дип әйтергә кирәк?!

Дөрестен әйткәндә, халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул. Ул әле әллә нинди кара көчләр басканга күрә генә бу күренештә йөри. Ләкин бу хәл, вакытлы гына килгән бер авыру кеби, гаризый бер хәлдер. Фарсилар: «Гаризра игътибар нист», ягъни «вакытлы вә гаризи булган нәрсәгә игътибар юк», — диләр. Хуш. Тагын бер җыру:

Әй тал үсә, тал үсә — башын киссәң, тагы үсә;
Тутасычөн кайгырмыймыз: сеңелләре тагы үсә.

Менә бу җыру чын-чын халык хәләте руханиясен күрсәтә. Бу җыруны чыгарган кеше, әлбәттә, «апасы» белән мөнәсәбәт-

---

*Мотлакан* — шиксез.
*Икътидар* — көч-куәт.
*Гаризый* — читтән килгән.

тә булган булырга кирәк: ул аның өчен бер дә кайгырмый. Сөаль: «Ни өчен кайгырмый?» Җавап: «Сеңелләре тагы үсә». Күрәсез бит, бу җыруны җырлаучы гами: «Тутасычөн кайгырмыймын», — дип кенә туктамый, бәлки үзен-үзе зурайтып: «Тутасычөн кайгырмыймыз», — дип куя. Зур кеше, имеш!

Әгәр санасак, мондый мисалларны хисапсыз күп таба алырмыз.

Бая әйткәнчә, сихерле күзгедән каралса, ягъни халык җырларын дикъкать белән укылса, халыкның күңелендә нәрсәләр сакланганын барчасын күреп буладыр.

Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык — шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык. Чү, аз гына бернәрсә шылт! иттеме, инде аның тугърысында иртәгә урамга бәетләр чыга. Мәсәлән, Гайнетдин дигән кеше үземе яки кызымы бер гаеп эшләгән икән — бетте инде, урамда бәетен җырлыйлар. Фараз итик: җәй көне авылда Гайнетдин абзый үзенең гаиләсе белән чәй эчеп утыра. Тәрәзәләре ачык, кояш төшкән. Бу гаилә бернәрсәдән хәбәрсез, тыныч кына утырган чакта, менә берзаман боларның тәрәзәсе төбеннән әллә никадәр үсмер җегетләр Гайнетдинне мыскыллап җырлап үтәләр:

Тау башында тимер букән, типкәләмә, Гайнетдин;
Без чыгарган бәет түгел, үпкәләмә, Гайнетдин!

Гайнетдин бичара вә гаиләсе кызарыналар, күзгә-күз карашалар, вәссәлам! Нишлисең, тегеләрнең авызларына тастымал тыгар хәл юк!

Кыргыз* халкында булган кеби, бер-берсенә каршы җырлашу безнең халыкта әле һаман да бар. Ләкин, кыргызлардагы кеби, шома вә яхшы чыкмый. Кара-каршы җырлашканда, безнең халык бер-берсенең исемнәрен җырга катыштырып һәм һич кирәкмәгән, мәгънәсез сүзләр катыштырганлыктан, җырлары ямьсез чыга.

Мәсәлән, кара-каршы җырлашканда болай җырлыйлар:

Аклы да гынай ситса, Закир абый,
Буй-буй ыштан, Җамалый кода;
Арага гына, Сәйфетдин абзый,
Төшкән дошман, Якуп агай-эне.
Ходай да гына кушкан, без кавышкан,
Җамалый кода, Закир абый, Якуп агай,
Нишләтер, ди, безне ул дошман!

---

* Кыргыз — бу урында «казакъ» мәгънәсендә.

*Гами* — гади, беркатлы кеше.

*Маил* — һәвәсле, яратучан.

Менә бу җыру булып чыкмый, бәлки шактый озын бер хат укып чыгу белән бер була. Ничек булса булган; әлхасыйль, халык, һичкемгә мохтаҗ булмыйча, үз хиссиятен үзе мәйданга чыгарган, «җырның җыртыгы юк» дигән дә, җырлый биргән, бәетләр дә чыгарган.

Халык җырлары, бөтен мөһмәляте вә җитлексезлекләре белән бергә, әлбәттә, үземезгә генә сөекле булырга тиеш һәм сөекле дә. Чит милләтләр өчен безнең җыру мәгънәсез вә хәтта көлке дә булса булыр. Мәсәлән, шушы җыруны русчага тәрҗемә итеп карыйк:

Калфагым бар, шәлем юк,
Шәл алдырмый хәлем юк;
Синнән башка сөйгәнем юк,
Сине алмый хәлем юк.

Русча:

У меня колпак есть, но нет шали,
Необходимо мне купить шаль.
По мне нет любимой, кроме тебя,
Необходимо мне жениться на тебе.

Шулай, һәрбер кош үз тавышы белән ләззәтләнә. Хәлне кире әйләндереп куйсак та, барыбер шулай булып чыга; мәсәлән, русларның сөеп җырлаганнары «В саду ли в огороде девица гуляла» җырлары безнең колакка да ул кадәр хуш килми бит. Керпе үз баласын йомшагым һәм аю үз баласын аппагым дип әйтә, ди. Бу гарәпләр мәкале; гарәпләр моны: «Көлле тайрин ястәлиззе бисаутиһи»*, — диләр.

Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр. Русларның Пушкин вә Кольцов кеби иң зур шагыйрьләре дә, халык җырларына тәкълид итеп, бертөрле «искусственныя** песни», ягъни «сонгый җырлар» яздылар. Болай халык җырларына тәкълид итеп язган шигырь, тәкълид итмичә язылган шигырьләрдән хис, мәгънә, тасвир ягыннан һич тә ким булмавы өстенә халыкның үз көе, үз вәзене, үз формасы илә язылганга, халык күңеленә бигрәк гүзәл тәэсир итә вә урынлашадыр. Бу җөмләдән Кольцовның «Ник йоклыйсың, мужик?», «Сукачы җыруы», Пушкиннең «Кызлар җыруы» саналалар.

Ә бездә халык җырларына тәкълид итүчеләр билгомум

* Һәр кош үз тавышы белән ләззәтләнә.
** Искусственныя — күплекнең иске формасы.
*Әлхасыйль* — кыскасы.
*Мөһмәляте* — буш, мәгънәсез өлешләре.
*Билгомум* — гомумән.

булдымы? Әлбәттә, безнең Кольцовларымыз, Пушкиннәремез булмаганга, мин: «Халык җырларына тәкълид итүчеләр билгомум булдымы?» — дигән сөальне тәкрар итәм дә: «Ник булмасын, булды», — дип, үз сөалемә үзем җавап бирәм. Менә иң элек мәдрәсә шәкертләре тәкълид иттеләр:

Каләш-шәйхе фишшифа дип
Укыганың мантыйкмы?
Ма вәҗәдте, валлаһ, җаный,
Синнән гайре артыкны*.

Гыйльме хикмәт укыр өчен
Бару кирәк Бохарга;
Ярның исе алышынмас
Мисек-ганбәр, җофарга**.

Каля рәсүллуллаһ дип
Укыганың «Мишкать»ме***;
Имиең тотсам, кулым тими,
Әллә киемең биш катмы?

«Әл-хикмәтел-балига».
Мин тәэлиф әл-Мәрҗани;
Филмәшрикый вә филмәгърибы
Ля нәзыйрекә, җаный****.

Менә боларны «сонгый җырлар»ымыздан санарга ярый. Үткән сәнәләр нәшер ителмәктә булган бер көлке журналда, «Авыл җырлары» сәрләүхәсе астында, шундый «сонгый җырлар» күренгәли иде.

---

* «Шифа» китабында шәех әйткән дип
Укыганың мантыйкмы (формаль логикамы)?
Табалмадым, валлаһи, җаный,
Синнән бүтән артыкны.

** Фәлсәфә укыр өчен
Бару кирәк Бохарага;
Ярның исе алышынмас
Һичбер төрле хуш искә.

*** Пәйгамбәр әйткән диеп
Укыганың «Мишкать»ме?
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

**** «Камилләшү серләре» —
Мәрҗани төзеп чыгарган китап;
Көнчыгышта да, Көнбатышта да
Сиңа тиң юк, җаный.

*Тәкрар итү* — кабатлау.

*Мисек* — кабарга дип аталган сукыр тычкан сыман җәнлекнең махсус бизләреннән алынып ясалган хуш исле матдә.

*Ганбәр* — кашалот карыныннан чыга торган бик хуш исле сыекча.

*Җофар* — куе, йомшак, ялтыравыклы нәфис йонлы җәнлек.

*Сәрләүхәсе* — исеме.

Исемдә калган кадәресен язам:

Җомры тояк тайларда,
Матур кызлар байларда;
«Әхбар» тәэмин иткән байлар
Җөри икән кайларда.

Безнең урам аркылы
Ага суның салкыны;
Тарта Казанның яшьләрен
Рәмиевләр алтыны.

Башыңдагы чабатаңның
Сиксән сигез серкәсе;
Бу дөньяда шөһрәт алды
Бәдигъ мәзин күркәсе...

Вә гайреләр.

Менә бу «сонгый җырлар» да вакытында бик оригинальный вә нәүзоһур нәрсәләр иде.

Чөнки көленергә тиеш бер нәрсәдән бер-ике юллык сүзләр белән тиз генә көленеп ташланыла иде. Бу озын-озын мәкаләләр хезмәтеннән артыграк эш күрә иде.

Башта әйткәнемезчә, халыкның бу тарыз җырлавы бик муаффәкыятьле сайланганлыктан, моның безнең һөҗүвиятемезгә-сатирамызга да файдасы тиде.

Халык җырларына билгомум тәкълид ителгәне язылды инде, ә шигырьләремездән халык җырларына тәкълид итүчеләр булдымы? Бу сөальгә дә: «Булды», — дип җавап бирергә тугъры килә. Безнең шагыйрьләремез дә мәйданга «сонгый җыр» дип әйткән шигырьләр китерделәр. Әмма муаффәкыятьле чыктымы-юкмы, ансы тәнкыйтьчеләр нәзарына калдырыла.

Мисал өчен мин монда Миргазиз әл-Укмаси җәнабләренең бер «сонгый шигырен» вә башкаларның да берәр шигырен укып күрсәтәм.

Татар тормышыннан.

**КИЛЕН**

Мәэюсь карый, аның күзләрендә
Туйганлык бар залим дөньядан;
Истикъбальләреннән өмид кискән,
«Ник тугъдым, — дип егълый, — анадан».

---

*Нәүзоһур* — яңалык, яңа килеп чыккан.
*Билгомум тәкълид ителгәне* — гомумән иярелгәне.
*Нәзарына* — карамагына.
*Мәэюсь* — өметсез.
*Истикъбаль* — якты киләчәк.

Кайнанасын күрә төшләрендә,
Җәллад булып килә каршына;
Башын кисә, имеш, — моның гайбе:
Тоз салмаган, имеш, ашына.

Иртә тора таңнар сызылганда,
Кош-корт яңа канат какканда;
Иңләп бу берьялгыз хезмәт итә,
Һәркем таң йокусын тотканда.

«Чү, сүз булмасын, — ди, — кайнанамнан,
Рәхмәт әйтсен», — ди-ди эшли эш;
Аргач, ял итәргә курка, мискин:
«Тагын башланыр, — дип, — әр-каргыш».

Әгәр ялгыш булса бер хатасы,
Кайнанасы дөнья куптара;
Яшеннәр яшьни, күкләр күкри,
Дөньяларны җимрә, актара.

Зәһәрләнә, төсе зәңгәрләнә,
Гыйфритләнә килен өстенә;
Бичара килен — япь-яшь кызга
Зәгъфырандай сары төс иңә.

Мәэюсь карый, аның күзләрендә
Туйганлык бар залим дөньядан;
Истикъбальләреннән өмид кискән,
«Ник тугъдым, — дип егълый, — анадан».

Бу булды бер. Тагы да мәгъруф шагыйрьләремездән Сәгыйть әфәнде Рәмиевнең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» исемле китабыннан тәмам мәгънәсилә «сонгый шигырь» булган шушы җыруны күчерәм:

Без эчәбез дә җырлыйбыз,
Акча бетсә, урлыйбыз;
Ходай безгә шулай язган,
Ярамый дип тормыйбыз.

Сәгыйть әфәнденең пьесасында бу җыруны берничә исерек җегетләр урамнан җырлап китәләр. Аны алар җырламый, бәлки Сәгыйть әфәнде бу җыруны, аларның халәте рухиясенә карап, авызларына сала. Менә бу шунлыктан «сонгый җырулар» җөмләсенә керә.

Инде шушы сәтырларны язучы кешенең дә шулай халык җырларына тәкълид уларак язганы бер шигырен дә нәкыль итәм:

---

*Мәгъруф* — танылган.
*Сәтыр* — юл (китап юлы).
*Нәкыль итү* — күчерү.

**МИЛЛИ МОҢНАР***

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, —
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңле ниләр сизгәнен,
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр берлән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып, җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була, — диде, — «Әллүки!»

Шушы мисал итеп китергәнем шигырьләр — барчасы да сонгый җырулардыр. Бу «сонгый җырлар» халыкның үз рухынча, үз формасынча, үз вәзене белән язылганнардыр. Шуңар күрә боларны «Зиләйлүк» вә яки «Әллүки» көйләренә туп-тугъры җырлап була.

Аңлашыла ки, бездә дә әдәбиятымызның нигезе булган шул халык җырларына, берничәшәр генә булса да, кирпеч салучылар булган һәм бар икән.

Халык җырларын, халык әдәбиятын колакка ишетелгәнчә генә хөкем итеп, бу мотлак шулай икән диеп булмый. Мәсәлән:

Җитен күлмәкне җил ала,
Илтеп дәрьяга сала;
Безнең болай утырулар
Сагънып сөйләргә кала, —

җыруын шушы килеш отылып алынса, бу мотлак шушылай җырлана икән диер хәл юк, аны икенче кәррә ишеткәндә, ихтимал:

Җитен күлмәкне җил ала,
Илтеп дәрьяга сала;
Гакылың булса, уйлап кара:
Бу дөньяда кем кала? —

дип тә ишетерсең.

---

* Зиләйлүк көенә. (*Г.Тукай искәрмәсе.*)
*Кәррә* — тапкыр.

Халык җырлары, халык әдәбияты кайчакта шулай аерым шәхесләрнең кәефенә карап төрлеләнә дә. Хикәя вә мисалларда да хәл шушылай ук. Мәсәлән, бер хикәя сөйләүче үзенең хикәясен: «Бар иде урман буенда бер карт белән бер карчык», — дип башласа, шул ук хикәяне икенче кеше: «Бар иде, ди, диңгез буенда бер карт», — дип башлый.

Халык җырларының вәзене вә җырлану рәвеше — һич үзгәрми торган бер генә вәзен вә бер генә рәвештер:

Сажидәнең камчат бүрке —
Күз өстендә күләгә;
Монда уйнаган монда калсын,
Анда кайтып сөйләмә, —

дигән җыру, әлбәттә, әллә кай заманнарда, әле безнең 17–18 яшьлек гүзәл Сажидәләремез башларына зур камчат бүрек киеп йөргән заманда җырланган. Инде хәзер, заманымыздагы кечкенә генә калфаклы туташларымыз тугърысында җырланганда да, барыбер шул ук вәзен, шул ук рәвеш белән җырланадыр.

Башка халыкта ничектер, бездә бер ел үтми ки, анда берьбер төрле яңа көй чыкмасын. Бу хәл бабаларымызның мәҗүс заманнарыннан бирле үк дәвам итеп килми микән? (Бу урында бернәрсә хәтергә килә: безнең халык җырларында халкымызның мәҗүс заманнарында җырлаган җырлары дип хөкем итәрлек бер җыру да сизелми. Барча җырларымыз ислам кабул иткәннән соңгылар гына булырга охшыйлар. Мисал өчен: «Иртә генә тордым, ай, таң берлән, битем юдым ап-ак кар берлән; ахирәт тә күрке иман берлән, дөнья күрке сөйгән җар берлән». Безнең хәзерге җырларымызның күбесендә «ислам», «тәкъдир», «Ходай» сүзләре күренә. Гаҗәбан, мәҗүс замандагы җырлар бөтенләй онытылып бетте микәнни?)

— Син бу ел чыккан яңа көйне ишеттеңме әле? Әнә фәлән абзый Мәкәрҗәдән яңа көй отып кайткан, — кеби сүзләр халык арасында һәрвакыт ишетелмәктәдер.

Бу ел яңа көй чыктымы, халык инде былтыргы иске көйне җырламый вә уйнамый башлый. Авыл урамнарында җегетләр, көз көне никрутлар яңа көйдән тәмам ихласлары кайтып, туеп бетмичә торып, аны авызларыннан ташламыйлар.

Татар көйләре, шулай ел саен алмашынып торганлыктан, төрле исемнәр илә һич тә санап бетергесез дәрәҗәдә күптер. Казандагы иске әдәбиятны сөючеләр, төрле көйләрне язып, әллә ничәшәр китап вә рисаләләр язып тараттылар. Ләкин

*Мәҗүс* — халыкларның табигать көчләренә табынуы белән бәйле заманнары (язычество).

*Гаҗәбан* — бик гаҗәп.

һаман да көй исемнәрен санап бетергәннәре юк әле. Бу китапчылар һәммә Русия мөселманнарына мәгълүм вә уртак булган «Тәфкилев», «Әллүки», «Салкын чишмә» вә «Ашказар» кеби көйләргә җырлар язып таратсалар да, өязләрнең вә аерым авылларның үзләренә махсус булган җыр вә бәетләренә тия алмадылар әле. Фәлән авылда Себер киткән кызга, төгән авылда асылып үлгән яки баткан җегеткә үзенә махсус көйләр вә җырулар белән чыгарылган бәет вә моңнар һич тә җыеп бетермәслектер.

1905 ел җитеп, хөррият сәгате сукканчы, һәркемгә мәгълүм улдыгы үзрә, без Русия мөселманнарында әллә нинди бер гомуми онытылу бар иде. Шул онытылу арасында милли көйләремез, милли моңнарымыз да онытылып бара иде; әгәр бер кеше алдында «Сакмар суы», «Әллүки» кеби бер озын көйне җырлый башласаң: «Куйсана шул картлар җыруын! Яңа көйне җырла!» — дигән сүзне ишетә идең.

Әйе, хөррият булды, яшьләр чыкты. Алар халык арасына чумды. Алар шушы онытылып яки һичкем тарафыннан әһәмият бирелми башлаган милли моңнарымызны терелдерделәр. Китаплар яздылар. Әүвәлдә итальянский гармуннан башка уен коралы күрмәгән татарларга әллә нинди оркестрлар җыеп, әллә нинди чүмеч төсле мандолиннардан милли көйләр уйный башладылар. «Куйсана шул картлар җыруын! «Әпипә»не әйттер», — диюче кешенең, теге чүмечләр белән уйнаучы унлап җегетләрнең иске «Зиләйлүк»ләрне уйнаганын ишеткәч, колаклары торды. Аркасыннан каннар йөгерде. Әүвәлге фикеренең ялгышлыгын сизде. Бөтен көй вә моңнарымызга мәхәббәт итә башлады. Казандагы «Шәрекъ клубы»на бу хезмәте өчен милләт исеменнән рәхмәт укымаска мөмкин түгелдер.

Безнең халыкның җырлау вә көйләвендә, минемчә, үзенә бер төрле хосусият бар кеби.

Башка милләтләрдә булдыгы кеби, бездә калын тавыш илә вә мөмкин кадәр көчләнеп вә авызны бик зур итеп ачып җырлау бер дә мәкъбүл түгел. Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы мәкъбүл вә мөстәхсән күренә. Мәсәлән, мин дөм чукрак булып та, җырлап утыручы бер татарның авызына карасам, мин аны җырлый дип белмәс, бәлки бер нәрсәне кызу-кызу сөйли икән дип хөкем итәр идем. Әгәр дә шул чукрак хәлемдә бер русның җырлап утырган хәленә карасам, мин аның авызының җыртылганчы ачылуыннан вә үзенә көчлек килүеннән, мотлакан, бу җырлый дип уйлар идем.

---

*Мәгълүм улдыгы үзрә* — мәгълүм булганга.
*Мәкъбүл вә мөстәхсән* — тиеш һәм күркәм.

Минем исемдә калган: мәдрәсәдә чакта һәр шәкертнең хөсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде. Аның шулай мыек астыннан гына җырлавы безнең хушымызга бигрәк китә иде.

Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек, шуның безнең күңелгә охшарына күңел ышанмый. Көемезнең алтынын кояр шикелле тоела. Бу тугърыда күп мөсахәбәгә кителсә, эшнең музыка вә аны аңлау мәсьәләсенә җитәчәге сизелә.

Минем образованием бик бала рәвештә — малютка булып калган. Юк аның тоткан нәрсәсен куптарырлык кулы. Юк аның уйлаган вә сизгән нәрсәсен дәлилләр берлән сөйләрлек теле. Юк аның караган нәрсәсен аркылы тишәрлек күзе. Шул сәбәптән, җәһаләтемне билигътираф, ул хакта күп сөйләүдән туктыйм.

Халык җырларына әһәмият бирергә кирәк, дип кат-кат әйтелде инде. Ни өчен әһәмият бирергә кирәк? Шуның өчен ки, чын халык телен, чын халык рухын безгә тик халык җырууларыннан гына табып була.

Аннан башка кайдан табасың? Безнең матбугат исемендә йөртелгән иске китапларга вә басмаларга кайтып карыйкмы? Иске китапларымыздан «Фәзаилеш-шөһүр»гә, «Йосыф китабы»на мөрәҗәгать итикме? «Фәзаилеш-шөһүр» белән «Йосыф китабы» кем телендә? Алла белә, җен телендә. Бу китапларны кем дәрес китабы итеп тоткан? Татарлар.

Киләбез «Таһир-Зөһрә»гә.
Сазың күп моң кылады,
Ишеткән таң калады;
Гариб гашыйк, якын кил:
Исмеңез кем булады?

Бу кем телендә? Кыргыз телендә. Бу кем китабы? Татар китабы. Бу — татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер.

«Тәрҗеман» гәзитәсен алабызмы? Бармы анда бер генә татарча сүз! Көчләре беткәнче: «Без «Тәрҗеман» бабай артыннан калмыйбыз», — дип маташкан иске өлфәтче вә башка

---

*Хөсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән* — яхшы карашын казанган.
*Мөсахәбәгә* — сөйләшүгә.
*Җәһаләтемне билигътираф* — наданлыгымны танып.

да берничә мөхәррирләрнең тәхрирләрен алыңыз. Бармы аларда татар рухы вә татар сүзе?

Андый мөхәррирләребез татарларны төрекләштерергә аз тырышмадылар. Ләкин булдыра алмаслыкларына тәмам күзләре җиткәч кенә туктадылар.

«Тәрҗеман»ның гына ара-тирә җылаганлыгы ишетелә.

«Борһане тәрәккъый» тагы, яңлыш-йоңлыш булса да, төрек җөмләләре тәртип итеп маташкан булып, нинди көлкеләр эшләмәде.

Үз араларында төрекчә сөйләшеп маймылланучы шәкертләр, башларына фәс киеп, «госманлыез, әфәндем» дип йөрүче хиффәтләребез дә аз булмады.

Ләкин мондый комедияләр вакытында булды да, узды да китте.

Гәзитәләр дә, «бундан», «буйлә» кеби сүзләрне генә калдырып, татарча языла башладылар, китап вә рисаләләр дә татарча чыга; без татарлар һаман да татарлар булып калдык. Төрекләр — Истанбулда, без — монда.

Хәерле юлга!

## ХАТИМӘ

Халык җырлары чын үземезнеке генә булганга, анда читләрдән гарәп, төрек, сарт кебиләрнең тәэсире булмаганга, мин аларга әһәмият бирәм һәм мәхәббәт итәм. Шунлыктан, халык җырларына мәхәббәтемнең бер әсәре булсын дип, шушы мөляхәзәләремне язарга җөрьәт иттем.

Мин кечкенәдән үк җырчы идем. Кайда ишетсәм дә, җырлау тавышын салкын кан белән тыңлый алмый идем. Мәдрәсәдә хәлфәләр, кече атна кичләрдә, бер кадак симәнкә, ярты кадак чикләвек алып ясаган мәҗлесләрендә дә мине онытмыйлар иде. Мин, самавыр артына гына утырып, алар кушкан көйләрне җырлап бирә идем, шул җырлавым бәрабәренә хәлфәләрдән берәр уч симәнкә һәдия кыйлына иде. Мин, кулымдагы симәнкәне беткәнче яргач, тагын җырлый идем.

Мәдрәсәдүк мине җырчы диләр иде.

Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телемезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин соң сарт «Бәдәвам»нәре, сарт «Кисекбаш»ла-

---

*Тәхрир* — әсәр, язган нәрсә.
*Хиффәт* — тиле, юләр.
*Хатимә* — соңгы сүз.

ры, кызылбаш «Тасриф»ләре, гарәп «Нәху»ләре белән туган телемезне сөймәк кеби бер олугъ нигъмәткә малик була алыр идеммени?

Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем
Син туган тел аркылы.

И туган тел! Һәрвакытта
Ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган
Шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган
Иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үземне,
Әткәм-әнкәмне, Ходам.

Соң.

---

*Нәху* — синтаксис.
*Нигъмәткә малик* — байлыкка ия.

# 1911

## ӘСТЕРХАН МӨЗАКӘРӘЛӘРЕ

— Әссәламегаләйкем, туганкай.

— Вәгаләйкемәссәлам.

— Туганкай, безне танымый торгансыз? Ихтимал, рус диеп тә белгәнсез? Минем озын сачемә карама, туганым, мин мөселман; мин, мин — «Идел» мөхәррире[1]. Бу кулыңда нинди кәгазьләр?

— «Ялт-йолт» журналы.

— Һи-һи-һи... «Ялт-йолт» журналы, имеш! Һи, туганкай! «Ялт-йолт» журналын язучылар кем дип беләсез? И туганнар! «Ялт-йолт» журналын язучылар мальчиклар, наданнар, Урманчиевләр, Әсгарләр[2], Тукаевларны кем дип беләсең? Һи-һи-һи, туган! Һай, мин сиңа сөйлим алайса: алайса, исемең ничек?

— Габдулла Фәләнев.

— Туганкай Габдулла, мин, мин, һи-һи, мин бүген праздновать итәм, тагын ачыграк әйтсәм, кәефләндем. Туганкай, исемеңез ничек әле? Сез «Идел» гәзитәсен аласызмы? Толстойга язган шигыремне укыдыңызмы? Һи-һи, туганкай! Без татар бит. Тукаевлар гарәп вәзене белән шигырь язган булып маташалар, минем шуларны өйрәтә-өйрәтә чәчем агарып бетте инде. «Мин, су, димен, ул — җон ага...»[3] Әй, туганкай, син ни атлы әле?

— Габдулла, дидем ләбаса.

— Әйе, алай икән, туганкай, мин сезне таныйм, мин сине беркөн театрда күргән кешегә охшатам. Әле, туганкай, шуны да әйтеп узыйм, чынын гына әйткәндә, түгел Әстерханда, бөтен Русиядә дә кеше юк дисәм, хата булмас. Толстой хакында миннән башка бер адәм шигырь язучы булмады. Мин, мин, туганкай, Толстой язган әсәрнең бер генә кәлимәсен укымаган булсам да, Толстойны, «Арыслан» исеме белән[4] атап, бөтен дөньяга белдерттем. Үземнең «галәм» белән андый мөгамәләдә булуым сәбәпле, үз наданлыгымнан бөтен дөньяны көлдерттем.

— Җүләр!

— Нинди җүләр? Әле Шекспир, Байрон, Гете, Гейнеләрнең исемнәрен дә татарча язмакчы булам. Мин «Таң»чы[5], милли!

— Әйе, синең «кебек» бер мөтәрҗим Гогольнең Яичницасын «Тәбә» дип татарчага кәлҗемә иткән иде[6].

---

*Мөзакәрә* — фикер алышу, әңгәмә.
*Вәзен* — шигырьдә ритм, такт, иҗек саны.
*Кәлимә* — сүз.
*Мөтәрҗим* — тәрҗемәче.

# ЯҢА ӘСӘРЛӘР

«Хәмитнең хәяты» — Мәҗит Гафури әсәре. Кәримев-Хөсәенев нәшере. Бәһасе мәгълүм түгел.

Мәҗит Гафуриның бу әсәре, аның «Яшь гомерем»ендәге «Электрик фонарена»[1] һәм дә мәзкүр китап әүвәлендәге бәгъзе гүзәл тасвиратны истисна иткәндә, ул язган әсәрләрнең иң яхшысы вә иң тормыштан алынып язылганыдыр дисәк, җаиздер. Бу әсәрдәге бәян ителгән хәлләр, тасвирларның бер кыйсьме мөхәррирнең үз тормыш вә әхваленә гаид кеби күренсә дә, билгомум бөтенебез чапкыр тормыш артыннан җитмәгән вә ничектер куарга да керешә алмаган шәкертләрнең хәл-әхваленнән гыйбарәттер.

Татар баласы бер надан гаиләдә туа. Үсеп 11–12 яшенә җитә. Ата-анасы, инде укыр вакыты җитте дип, аны әллә нинди «мәдрәсә» атлы адашу, саташу, җәһаләт мәнбәгы булган бер җиргә илтеп тыгалар. Тагы да ачыграк әйткәндә, гыйлем җәүһәрен чүплек башыннан эзләргә мәҗбүр итәләр. Әлбәттә, ул аны таба алмый, башына җыен чүп-чарны гыйлем дия тәлкыйн итеп тутырадыр. Мәсьәләне шушы үткән чирек гасырга гына татбикъ итеп, шул ноктаи нәзардан караганда, мәзкүр бала, саф вә пакь зиһенен чүп-чарга мәкян иткәннән соңра, заманныңмы яки сукыр бер иттифакыятьнеңме сәүкы белән*, «ачык фикерлерәк», сыйныфыбызча «низамлы» дип саналган бер мәдрәсәгә эләгә. Анда да ул файда күрәлми, чөнки бичараның тагы әллә ничә ел гомере әүвәлдә башына төягән юкбарны бертөрле рәткә тезү, тәртипкә кертү белән генә кичә.

Чүп булгач чүп инде. Ул таралып ятса да, тәртипкә салынса да — барыбер чүптер.

Бәхетсез баш, әйткәнемез рәвештә көн үткәргән чагында, фәйзы илаһиме, тагы бер иттифакыятьме диик, аңар «гәзитә»

---

* Очраклылыклар, вакыйгаләр барышы белән.

*Мәзкүр* — искә алынган.

*Тасвират* — сурәтләүләр.

*Истисна итү* — аерып алу.

*Җаиздер* — дөрестер.

*Әхваленә гаид* — хәлләренә карый торган.

*Җәһаләт мәнбәгы* — наданлык чыганагы.

*Тәлкыйн итү* — инандыру, ышандыру.

*Татбикъ итү* — кайтарып калдыру.

*Ноктаи нәзар* — караш ноктасы.

*Мәкян* — урын.

*Низамлы* — тәртипле.

*Фәйзы илаһи* — Алла рәхмәте.

*Иттифакыять* — очраклылык.

кыяфәтендә зәгыйфь кенә бер шәмнән зәгыйфь кенә шәүлә вә яктылык төшәдер.

Әмма һәйһат! — ул зәгыйфь нур инде җегет булган мәзкүр баланың тормыш кадәрле тормыш дөньясын яктырта алмый. Ул яктылыкның зураю вә киңәюенә дә баягы чүпләрдән туган җәһаләт, шөбһә вә тәрәддөдләр манигъ булалар. Тагы безнең гасыр иттифакыяте: хөррият кояшы чыга. Ул, әлбәттә, баягы, баштагы нурга кушылып, янәдән бераз яктылык арттыра.

Инде мотлак әйтмибез, фитърәтендә зур газем вә олугъ касыдлар* өчен туган бу шәкертнең күңелендә үзенең чынлап та шәм һәм дә халыкны яктырту өчен булган шәм икәнлеген игътираф, аңлау туа. Моның болай икәнлеген «Хәмитнең хәяты» мөхәррире миңа вә халыкка тел белән сөйләмәгән булса да, без аны мөхәррирнең моңарчыга кадәрле матбугъ әсәрләреннән күрәбез.

Әсәр «эз» булса, мин аның арысланмы, куянмы эзе икәнен ачык белә алам.

Шәм, дидекме, әйе, ул — шәм. Ул үзенең зәгыйфь нурын да үз милләте белән бүлешә, уртаклаша. Яна-яна, ниһаять, мае бетә, сүнәргә якынлаша. Тагы да мин киная иткәнем майны өстәргә әлеге язганымыз наданлык, «тәртипкә генә салынган чүп» зарар итә.

Укыр иде: бердән, үзенең халыкка мөгаллиманә вә мөәддибанә язган тәхрираты белән күңеле үскән. Мөгаллимнең хөббе нәфсе гомумән мөбтәди булудан тартынучан була бит. Юк, бу да түгел, бигрәк, бигрәк әрәмгә гомер үткән. Иң начары: җан картайган. Һәр нәрсәгә «барыбер» дип карый башлаган. Югарыда чапкыр тормыш дигән идек. Шулай, табигать вә тормыш үз юлында чапкан. Мискин шәкерт ялгызы куркыныч, тын, күңелсез бер сахрада калган. Тормыш та юк, кызык та юк.

Бу әсәрдә булган өйләнү вә бәгъзе вак мәгыйши муаффәкыятьсезлек тугърысында сүз озайтмыйча, куркыныч сахрада калган бичара шәкертнең гакыйбәтен генә әйтәм: тормыш

---

* Яратылышында зур теләк һәм бөек максатлар.

*Һәйһат!* — «Кая ул!» мәгънәсендәге ымлык сүз.

*Тәрәддөдләр манигъ* — икеләнүләр торкарлык.

*Игътираф* — тану.

*Әсәр* — бу урында «эз» мәгънәсендә.

*Мөгаллиманә, мөәддибанә* — укытучыларча, әдәпкә өйрәтүчеләрчә.

*Тәхрират* — язмалар.

*Хөббе нәфсе* — үз-үзен сөюе.

*Мөбтәди* — башлап укучы.

*Мәгыйши муаффәкыятьсезлек* — тормыштагы уңышсызлык.

*Гакыйбәтен* — соңын.

юк, кызык юк. Инде бичара җегет ни эшли! Ни эшләсен? Әлбәттә, тормышының иң куркыныч дошманы булган әҗәлдән истимдад итә. Аның куенына атыла: «Мин үземчә иң мәсгудмен. Таза кальб, саф күңел белән бер Аллага кайтам...» — ди. Чөнки әйткәнемез сахрадагы ялгыз, ярдәмсез кешегә бүре авызына керү дә, ачлыктан үлү дә фәрекъсездер.

Менә бу — һәммәмезнең үк дип әйтмим, күбемезнең тормышы. Шуңа күрә бу әсәрне укырга тәүсыя итәм.

## ИСЕМНӘРЕМЕЗ ХАКЫНДА

### *(Ярым җитди)*

Көлле мәүлүдин юләде галя фитърәтел-ислами, фәминә әбәваһе йөһәввиданиһи вә йөнәссыйраниһи вә йөмәҗҗисанаһи.

### ХӘДИС ШӘРИФ

Хәдис шәрифнең мәгънәсе заһир:

Һәр тугъмыш бала ислам, ягъни тәслим фитърәтендә туа. Баланың язмышы, ул тугачук, аның ата-анасына тапшырыла, тәслим ителә.

Бала зәгыйфь; мәүҗүдат галәмендә бер әсир. Аңар, әлбәттә, берәүгә-берәүгә тәслим ителүдән бүтән чара юк. Ул бичара ата-анасына тәслим ителә.

Укучы әфәнде! Кара әле, абзаң нишләтә?! Сез, бәлки, хәдис тәэвил итү Муса Бигиев белән Зыя әл-Кәмали һөнәре генә дип уйлагансыздыр. Туктагыз әле, уйлагычыгыз сынар!

Мин әле тик, Һади хәлфә[1] кебек, вәкарь саклап дәшмичә генә торган идем. Хуш. Бала шулай тәслим ителә. Аның атасы яһүди булса, бала киләчәктә яһүд милләтенә хезмәт итәрлек рәвештә тәрбия ителә.

Атасы нәсрани булса, янә, нәсрани милләтенчә тәрбия кыйлынып, киләчәктә үз милләтенә файдалы бала булуы күзгә алына.

---

*Истимдад итү* — ярдәм эстәү, көтү.
*Мәсгудмен* — бәхетлемен.
*Кальб* — йөрәк.
*Фәрекъсездер* — аермасыздыр.
*Тәүсыя итү* — киңәш бирү.
*Хәдис шәриф* — пәйгамбәр сүзе.
*Заһир* — ачык.
*Тәслим фитърәтендә* — кемгә дә булса тапшырылырга тиешле хәлдә.
*Мәүҗүдат галәме* — реаль дөнья.
*Хәдис тәэвил итү* — пәйгамбәр сүзен үзгәртеп аңлау.
*Нәсрани* — христиан динендәге кеше.

Мәҗүсиләр тугърысында (1904 сәнәдә эш күрсәткән) япон балаларын күрсәтсәм, җитсә кирәк. Әйе, алар мәҗүс милләтенчә тәрбия кыйлынганнар.

Менә без, татар балалары да, татар милләтенчә тәрбия кыйлынганбыз.

Юк, бу сүз хата, бик зур хата! Без татар милләтенчә тәрбия кыйлынмаганмыз, бәлки татар диненчә тәрбия алганбыз.

Без моны анадан тугач та үземезгә кушылган исемнәрдән истидлял итә алабыз. Менә исемнәр: Гайнетдин, Сәйфетдин, Котбетдин, Нуретдин, Баһаветдин, Гыйльметдин, гайре мөтәнаһи...

Бала тугъды. Атасы ат кушарга мулла чакырды. Атасы чәпчим риза булып җитмәгән булса да, анасы чаршау аркылы гына: «Хәзрәт! Баланың исемен Гайнетдин куш!» — диде.

Бәс, Гайнетдин дигән сүзнең мәгънәсе ничек? «Гайн» ләфзының 8 төрле мәгънәсе булса да, бу урында Гайнетдин, ягъни диннең нәкъ үзе, гайне үзе дигән мәгънә морад.

Инде, әфәнделәр, мин сезгә бер сөаль бирәм: сезгә урамда җөргән вакытыбызда бишбилле бишмәтле, тездән генә чалбарлы, кырган мыек, озын сакаллы, чалбар бавы салынган, яшел читекле бер татар очраганы бармы?

Очраган булса, моның исеме — Гайнетдин, бу үзе дә Гайнетдин, ягъни килеш-килбәте, кием-салымы белән диннең гайне үзедер. Димәк, исеме җисеменә муафикъ.

Аннан соң, мөхтәрәм укучылар, иренсәгез дә җавап бирә күреңез:

Сез, «Бу эш шәригатькә сыймый; дәһриләр динне бетерәләр: менә мин аларны!» — дип йозрыгын төенләп, ава-түнә җөргән исерек татарны күргәнеңез бармы?

Күргәнеңез булса, менә бу кеше Сәйфетдин инде, ягъни бу — диннең кылычы. Кем белә, бәлки, зөлфекарыдыр да!

Мөхтәрәм укучылар!

Сез яңакларыябышкан, күзләре чекрәйгән, өстенә җилән, башына керле чалма кигән бер пишкадәмнең үзенә җиһанда тиң тапмаган сыман аска карап җөргәнен күргәнеңез бармы?

Күргән булсаңыз, бу абый Камалетдин булыр, ягъни дин-

---

*Истидлял иту* — нәтиҗә ясау.

*Гайре мөтәнаһи* — чиксез.

*«Гайн» ләфзы* — «гайн» дигән сүз.

*Исемнең җисеменә муафәкате* — исеме кешенең үзенә туры килүе.

*Зөлфекар* — бик озын һәм гаять үткен кылыч (фольклорда).

*Пишкадәм* — мәдрәсә программасын тәмамлагач, муллалыкка урын көтеп ятучы шәкерт.

нең кәмале вә ниһаяте булыр. Артык юк. Эзләмә. Иҗтиһад габәс вә мөнкариз.

Шулай, исеме җисеменә муафикъ.

Исемнең җисемгә муафәкате бик матлуб вә мөгътәбәр бер эштер.

Мәсәлән, бер шәкерт болай дип җырлый:

Исме җисменә муафикъ
Һәм Камилә, Мөршидә;
Булмыйдыр түзеп куралмый,
Көн дә барып күршегә.

Истанбулда ниндидер бер пашаның угылы туа. Шуның шатлыгына паша йортында зур зыяфәт була. Зыяфәттә бер шагыйрь дә иштиракъ итә. Пашаның угылына Гали исеме кушылачак булгач, шагыйрь әфәнде угъланга төбәп шушы түбәндәге шигырьне сөйли:

Эстәрем: исмиң кеби, затыңда да
Мәгънаэ голувият улсын мөнҗәли;
Шимдидән нәкъш ит шу пәнди кальбеңә:
Садә исмиң улмасын, угълым, Гали*.

Ягъни, и паша угылы! Синең исемең дә җисемеңә муафикъ булсын!

Бу китергәнем дәлилләр белән мин исемнең җисемгә муафикълыгы мәмдух вә матлуб икәнлеген исбат иттем бугай.

Аңлашылды ки, без татарларның тәрбиясе — дин тәрбиясе. Һәр абзый, һәр агай, һәр бабай диннең ни булса да бер кирәк нәрсәсе: Гыймадетдин, Мифтахетдин, Микъразетдин (терәге, ачкычы, кайчысы).

Дингә изафә кыйлынган исемнәремез хакында җитәрлек сабсата саттым инде.

Соң, Аллага мозаф исемнәр хакында ни дибез? Болар да исәпсез күп ич: Габдулла, Миңнулла, Лотфулла, Гайнулла, Шәмсулла, Гобәйдулла, Гыйбадулла, Сәйфулла, Әхмәдулла, Хәкимулла, Галимулла вә гайре вә гайреләр.

---

* Телим: исемеңдәге кебек, үзеңдә дә бөеклек мәгънәсе балкып торсын; шушы юлны хәзер үк күңелеңә сызып куй, улым: Гали дигән исем сиңа гади исем булып кына калмасын.

*Кәмале вә ниһаяте* — иң югары дәрәҗәсе һәм чиге.

*Габәс* — файдасыз.

*Мөнкариз* — беткән, сүнгән.

*Матлуб* — теләк итеп тотыла торган.

*Зыяфәт* — аш-су мәҗлесе.

*Иштиракь иту* — катнашу.

*Мәмдух вә матлуб* — мактаулы һәм кирәкле.

*Дингә изафә кыйлынган* — «дин» дигән сүзгә ияртелгән.

*Аллага мозаф* — «Алла» дигән сүзгә ияртелгән.

Бу Аллага изафәнең мәгънәсе, минемчә, болайдыр:

Безгә тугач та үземезгә мөстәкыйль бер адәм булырга исем җәһәтеннән үк юл калдырылмый.

Без — Габдулла, ягъни ниндидер бер Алла бәндәсе.

Без — Гобәйдулла, ягъни ниндидер Ходай колчыгы.

Без — Гыйбадулла, ягъни ниндидер Алла коллары.

Без — Әхмәдулла, ягъни Алланың бер әхмәте!

Без — Рәхмәтулла, ягъни Алланың бер мәрхүме.

Менә бу ямьсез, мәгънәсез, тозсыз, мөрәккәб исемнәр — һәммәсе дә безнең диндар Бохара җимешләре булган хәзрәтләремез хезмәте!

Монда, әлбәттә, исемнәр җисемнәргә муафикъ. Һәммәбез Алла бәндәсе һәм оҗмахка керәчәк Гозәер галәйһиссәлам ишәге, ягъни Ходай ишәге.

Тикшерә башлагач, туктамыйк инде: соң бу Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан, Нигъмәтҗан, Сәлимҗан, Галимҗан, Гарифҗан, Салихҗан, Шакирҗан исемнәре ничек? Салих, Шакир, Мөхәммәт, Әхмәт кеби саф гарәп сүзләре катына бу «җан» сүзләре кайдан килеп катышкан?

Җан — «рух»мы? Җан — Коръәндә мәзкүр җен нәүгыннән булган җанмы? Җан — «җанмак»тан әмерме? Әллә «минем җанымда» (катымда) дигән сүздән алынганмы?

Түгел, түгел, бу әйтелгәннәрнең берсе дә түгел!

Безнең муллалар Бохара җимешләре яки бәрәңгеләре икәне бәян ителгән иде. Мәгълүмдер ки, Бохараи кабих мәхфузә билләүате шәһәрендә сартлар яшь угъланларга «җанкәем», «җанашым» дип үк әйтмәсәләр дә, авызларына шәһвәт күбекләре чыкканы хәлдә: «Фәлән җан! төгән җан!» — дип хитап әйтәләр, мәсәлән, Хәким исемле бер гүзәл бала күрсә, сарт: «Хәким!» — дип хитап әйтә алмый, бәлки, күзләрен майландырып: «А Хәким җан!» — дип җибәрә.

Менә шул фәкать, фәкать хәйваният вә шәһваният хисеннән туган «җан» ләфзын безнең муллалар түкми-чәчмичә Русиягә алып кайтканнар. Алып кайту белән генә канәгатьләнмичә, безнең Чыңгыз, Тимер, Туктамыш, Алтынбик, Япанчы кеби гүзәл милли исемнәремез урынына шул Сәлим«җан», Галим«җан» кеби мөрәккәб, ямьсез, татарлар өчен хурлык, әйтергә тел teləми торган исемнәрне тудырганнар.

---

*Әхмәт* — беренче.
*Мөрәккәб* — кушма.
*Нәүгыннән* — төркеменнән.
«*Җанмак*»*тан әмерме*? — «Янмак» дигән сүздән боерык формасымы?
*Шәһваният* — җенси.
*Ләфзын* — сүзен.

Кем белә, бәлки, остазлары сартлар кеби, шуннан хушланганнардыр да.

Мин бу сүзләрне без татар балаларына анадан тугачук әллә нинди истикъбалемез өчен яман фаллы вә мәшьум исемнәр тагылганына эчем пошканнан яздым.

Һәр нәрсәнең гүзәлен яратабыз бит. Бәс, мин телимен ки, Бохари муллаларның бөтен черек нәрсәләренә безнең арада бәһа беткән кеби, киләчәктә ул әфиюн башлар уйлап чыгарган ямьсез исемнәр дә татар балаларына кушылмасын.

Гарәп теле — бай телләрнең дә баерагы. Татар исемнәрендә «Тәлгать»ләр толугъ итсен, «Фаикъ»лар тәфәүвекъ итсен, «Фатих»лар фәтех итсен, «Рифгать»ләр тәрәффегъ итсен.

Тәрбиямез дә коры, рухсыз, мәгънәсез, һич файдасыз рәвештә «дини» генә булмыйча, дини вә милли тәрбия булсын. Мөселман булганымыз вакыт татар икәнемезне дә онытмыйк.

Аллаһе Тәгалә исемемезне, җисемемезне вә рухымызны ислах әйләйә!

## ХИКӘЯ ЯЗАРГА ТЕЛӘҮЧЕ ЯҢА ӘДИПЛӘРГӘ ҮРНӘК

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе җүнле генә җегет иде. Икенчесе «Бәянел хак» мөгайян мөхәррирләреннән[1] иде.

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе «Хак»[2] былчырагы белән кешегә тәкфир ыргытмый иде. Икенчесе Мостафа Лотфи иде.

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе җырлау һәм тәганнидә маһир булып, моганнилекнең фәрде камиле иде. Икенчесе исә билгакес: Камил Мотыйгый иде.

---

*Истикъбаль* — якты киләчәк.
*Яман фаллы вә мәшьум* — начарлык юраучы һәм шомлы.
*Толугъ итсен* — тусын.
*Тәфәүвекъ итсен* — өстенлек алсын, күбәйсен.
*Фәтех итсен* — җиңеп чыксын.
*Тәрәффегъ итсен* — югары ашсын.
*Ислах әйләйә* — төзәтсен иде.
*Мөгайян* — билгеле.
*Тәкфир ыргыту* — «син кяфир» дип йөзгә бәрү.
*Тәганнидә маһир* — моң, музыкага оста.
*Моганнилекнең фәрде камиле* — җырчылыкның бердәнбер осталыгы.
*Билгакес* — киресенчә.

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе үз урынын белә, ... иде. Икенчесе хәзер юбилей ясамакта булган мөфти[3] иде.

*

Бер кешенең ике угылы булып, икесе дә мулла иде. Берсе Габдерразакъ атлы иде. Икенчесе Габдессабур атлы иде. Болар икесе дә корбан итләрен яраталар иде.

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе мәгърифәтле, галим иде. Ә берсе просто татар мөгаллиме иде.

*

Бер кешенең ике котырган эте бар иде. Берсе үз ботын үзе тешли иде. Икенчесе бөтенләй Ишми иде.

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе ишетмәгән-күрмәгән эшләрен ялганлап язмый иде. Икенчесе Рәшит казый иде.

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе кешелектән чыккан хулиган иде. Икенчесе дә милләтен вә динен саткан уфалы бер имам иде.

*

Бер кешенең ике угылы бар иде. Берсе ярты татар, ярты сарт иде. Икенчесе татар имлясын төзәтеп бетергән Нугайбәк Гыймад иде.

## ИДАРӘДӘН ҖАВАПЛАР

Кызыллы-яшелле кара белән бер мәкалә язып җибәрүчегә:

— Ай-яй, иптәш, бик матур караларың бар икән. Әнә шул яшел кара белән кызыл караңны бергә кушсаң, өченче төрле тагын бер матур төс хасил булыр. Менә шуннан соңра, җаным, бик матур нәрсәләр яза алырсың. Ләкин идарәгә килгән язулар, карасының матурлыгына карап түгел, бәлки мөндәриҗәсенең әһәмиятенә бинаән тәкъдир ителгәнгә, без синең язу-

---

*Мөндәриҗә* — эчтәлек.
*Бинаән* — карап.

ларыңны тәкъдир итә алмадык. Әгәр шул матур караларың белән авыл җегетләренә кызлар хаты язып салсаң, бик яхшы чыгарырсың. Вакыйган, синең шуңар истигъдадың булырга кирәк, без сиңа күбрәк шуның белән шөгыльләнергә тәүсыя итәмез. Мәкаләң журналга дәреҗ ителмәгән өчен ачуланма, җәме?!

*

«Сабырсыз» дип имза куярга кушучыга:

— Сабырсызланмагай иден, әллә нишләсәң дә, бер хатың да дәреҗ ителми. Идарәгә мәкаләләр җибәргән булып, безнең саруны кайнатмавыңны үтенәбез. Аңладыңмы?!

Ф.С. әфәндегә:

— Мәкаләләрең өстәл астындагы кәрзинкәгә дәреҗ ителде.

*

Казанда Х.Н. әфәндегә:

— Мәкаләң чибәр генә булса да, бәгъзе бер әдәпкә хилаф сүзләр булдыкыннан дәреҗ ителмәде.

*

Петрапаулда Уразаев әфәндегә:

— Мәкаләләрегез, бердән, бик озын; икенчедән, бик әһәмиятсез, өченче, фәкать бер кеше хакында гына улып, шәхси сыман күрелдекеннән басылмады.

*

Әстерханда М.Б.-гә:

— Синең, шаять, моңарчы берәр гәзитә вә журналда: «Имзасыз мәктүбләр дәреҗ ителми», — дигән сүзне күргәнең бардыр. Без дә шул сүзне тәкрар әйтәмез: ачык имзасы идарәгә мәгълүм булмаган һичбер язу дәреҗ ителми. Хәер, имзаң булса да, дәреҗ итмәгән булыр идек. Чөнки ул кешенең әүвәлдә чәче озын булып, соңыннан алдыруы, безнеңчә, һичбер әһәмияткә малик түгел. Андый төк, җоннар хакындагы мәкаләңне безнең идарәгә түгел, бәлки «Җон вә бишмәт»[1] идарәсенә җибәр. Үзеңә фатиха кыйла-кыйла басарлар. Моннан берничә ел элек «Игълан фәкать»[2] гәзитәсе дә кешеләрнең чәчләрен вә башка һәртөрле җоннарын тикшерә башлаган иде дә, ничектер, сизенеп, туктап калды. Шулайтеп, ул мәсьәләне син түгел, Әхмәтҗан абзаң да хәл кыйла алмаган иде.

*Малик* — ия.

Әстерханнан килгән башка мәктүбләрдә дә шул — ул хәтле мәгълүм кешенең чәче хакында күбрәк бәхәс итеlә. Аның нәрсәсенә исеңез китте, әллә моңарчы шәһәреңездә озын чәчле кеше юк идеме?

*

«Бәянел хак» ник көндәлек булды?» гонванлы мәкалә басылмый.

## МӨКАДДИМӘ

Арамызда әдәбият вә шигырь дигән сүзләрнең мәфһүм галисе аңлана башлаганнан бирле, мәшһүр инглиз шагыйре лорд Байронның исемен ишетмәгән кеше аздыр дип уйлыйм; исемен ишетүчеләр булса да, яшь әдәбиятымызда аның әсәре дә күренгәне юк иде.

Бу көннәрдә Сәгыйть әфәнде Сүнчәләй тарафыннан Байронның «Шильон мәхбүсе» исемле поэмасы (шигыре) татарчага шигырь белән тәрҗемә кыйлынуын ишеттем вә тәкъдим итүенә күрә укып чыктым.

Лорд Байрон әсәрендә мәгънәләр үз милләте вә үз мәмләкәте чигеннән үтеп, бөтен көррәи әрызның хәссас вә көчле күңелләрен сил ташуы кебек басмыш вә тутырмыштыр. Мәсәлән, дөнья сараена әллә ничә гасырлар мөддәтендә бер генә кат тәшриф итеп, анда да күп торасы килмичә, галәме мәләкүткә сәфәр иткән Пушкиннең яртыдан артык гомере мәзкүр Байрон җәнабләренә тәкълид вә аның рухыннан илһам эстәү белән үтмештер.

Хис, мәгълүмат вә көчле рухы белән Пушкиннән калышмаслык Михаил Юрьевич Лермонтов хәзрәтләре үзенең гали бер шигырендә шушы сәтырларны яза:

Лорда Байрона бы достигнуть я хотел!*

Дикъкать итсәк, бу шул оетырдыр ки, бер шагыйремез аның «Аһ, мин кояшка менсәмче!» дип әйткән шагыйранә хыялыннан аермасы юктыр.

---

* Лорд Байронга тиңләшергә теләр идем мин.
*Гонванлы* — исемле.
*Мөкаддимә (мөкаддәмә)* — сүз башы.
*Мәфһүм гали* — зур, төпле фикер.
*Мәхбүс* — тоткын.
*Көррәи әрыз* — Җир шары.
*Хәссас* — сизгер.
*Мөддәтендә* — буена, арасында.
*Тәшриф итү* — аяк басу.
*Галәме мәләкүт* — мәңгелек дөньясы.

Лермонтовның Байрон рухына гыйбадәте, баш июе артыграк куәтле булганга, ул кыска гомеренең чигенә кадәр Байрон тәхте тәэсиреннән чыга алмаган.

Гляжу назад — прошедшее ужасно;
Гляжу вперед — там нет души родной!*

Иштә Лермонтовның дөньяга вә тормышка карашы. Ягъни ул да Байрон белән бер хисле вә бер җанлы: дөньяда мәңге табынырлык бер изге идеал юк, һәммәсе төпсез, нигезсез, ди. Ул да, Байрон кеби, дөньяга каршы көлми, бәлки, каш җыерып, ачу аралаш күзләр белән карый.

*

Менә шушы бөтен дөньяга «байронизм» мәзһәбен тудырган вә, бәгъзе көчсез кешеләр күңелендә туып та, аларның күңел вә каләм ягыннан гаҗизлекләре сәбәпле дөньяга чыга алмый яткан бөек, югары вә гүзәл бер хисне руи земингә агызып җибәргән кешенең кулга алырлык берәр әсәре безнең татар теленә күчерелгәне бар идеме? Әлбәттә, юк иде. Инде бу бурычны Сәгыйть әфәнде үтәде.

## АЗ ГЫНА ТӨЗӘТҮ

Мөгътәбәр «Йолдыз»ның 699 нчы номерында Габди әфәнде, «Мияубикә» исемендә бер әсәремне интикад иткәндә, сүз арасында болай дип әйтә: «Бу әсәр шигырь түгел, бәлки нәзым вә мәнзумә генә, һәм безгә шигырь белән нәзымны аерырга[1] күптән вакыт инде».

Минемчә, соңгы җөмләдән мөхтәрәм укучылар, «Мияубикәле язучы нәзым белән шигырьне саташтыра икән» дигән фикергә заһиб булу ихтималлары бар. Шуның өчен изах итәмен ки, «Мияубикәле шагыйрь саф поэзия, чын шигырьгә әйләндердем» дип ышанганга күрә, «шигырьгә әйләндерелде» дип куйган.

Бинаән галәйһи Габдинең югарыдагы сүзләре мөхәррир

---

* Артка карыйм — уткәннәр коточкыч;
Алга карыйм — анда җанга якын нәрсә юк.

*Тәхте тәэсиреннән* — йогынтысыннан.
*Иштә* — менә шундый.
*Руи зәмин* — җир йөзе.
*Интикад* — тәнкыйть.
*Нәзым вә мәнзумә* — тезмә сүз.
*Заһиб булу* — китү.
*Изах итү* — ачыклап бирү.
*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.

яки матбага хатасына тәнбиһ кеби түгел, бәлки ялгыз бер интикадчының фикере генә дип тәлкыйн ителсен.

## РУСЧАДАН ДӨРЕСТ ТӘРҖЕМӘЛӘР

Русча: Я перешел через мост.

Тәрҗемә: Мин чыктым аркылы күпер.

Русча: Соглашение между Францией и Испанией будет подписано в конце текущей недели.

Тәрҗемә: Килешү арасы Франция һәм Испания булыр имза ителгән ахырында агып барган атнаның.

Русча: Это глухое место.

Тәрҗемә: Бу чукрак урын.

Русча: Лев Толстой умер.

Тәрҗемә: Арыслан җуан үлде.

Русча: Жили-были дед да баба.

Тәрҗемә: Торды-булды бабай да әби.

Русча: Дай сюда поднос!

Тәрҗемә: Бир монда борын астын!

Русча: Разрешена постройка новой каменной мечети взамен существующей деревянной, сильно обветшалой и тесной.

Тәрҗемә: Рөхсәт бирелгән салу яңа таш мәчет алмашынуга булып торган агач, көчле искергән һәм тарның.

Русча: При одновременной подписке на газету и журнал, подписчики уплачивают вместо 10 р. только 8 р.

Тәрҗемә: Каршы бервакытлы астына язганда гәзитә өстенә һәм журналга астына язучылар түлиләр урынына 10 тәңкә тик 8 тәңкә.

Русча: Около Приштины албанцы напали на местных властей, спасавшихся лишь благодаря прибытию войск.

Тәрҗемә: Янында Приштинә арнаудлар өсткә җыгылдылар урын өстендәге көчләргә, котылмышларга тик рәхмәт укый-укый каршы килгән гаскәргә.

Русча: Было мне годов восемь.

Тәрҗемә: Булды миңа яшьләр сигез.

Русча: След рыбы.

Тәрҗемә: Эзе балыкның.

Русчадан тәрҗемә итдегем бу үрнәкләрне мин үземнең мөтәрҗимлек эшендә мәһарәтемне гаммәгә күрсәтер өчен яздым.

---

*Тәнбиһ* — искәртү.

*Тәлкыйн ителсен* — аңлансын, кабул ителсен.

*Мөтәрҗимлек* — тәрҗемәчелек.

*Гаммә* — халык.

Ничә еллардан бирле «Баянел хак» кеби милли вә олугъ көндәлек гәзитәләрнең хәбәрләр кыйсьмендә югарыдагы үрнәкләрдән бик күп начар дәрәҗәдә тәрҗемә ителгән сәтырларга очраганым булганга, үземне, билифтихар вәлгорур, бөтен татар гәзитә вә журналлары идарәсенә мөтәрҗим буларак тәкъдим итәмен.

## ӨЧ БАШ

Күп акчаларга кызыктырып баш кистерүләр вәхши кавемнәрдә бик искедән бирле бар эштер.

Хикәядә укыгансыз бит[1]: ниндидер Җәнадил шәһәренең кяфер «пашча»сы, Гали батырның башын кисеп китерер өчен, үзенең бер пәһлеванына ярым дәүләтен, аның өстенә бик матур кызын да биргән.

Мәми авыз кяфер батыры әмма кызык булган соң! Мискин, ул Мәдинә шәһәренә килгән дә Гали батыр башы урынына яңлыш Әхтәм сәхабәнең генә башын кисеп кайткан.

Ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха! ха! Эчемне тота алмыйм. Әй, кяфер батыры юлда: «Гали башы минем кулда», — дип куана бугай!

Теге пашчасы да аңгыра. Гали батыр башын алып килгән дип, шул әкәмәт батырга кызын биргән була. Туй иткән була.

Надан дисәң надан шул: пашча башың белән Гали батыр башын таныма, имеш!

Әбәү!

Әхтәм сәхабә Мәдинәдән югалып, 3 әр көн мәсҗедләрдә күренми башлагач, бөтен Мәдинә шау килә: «Кая киткән? Кая киткән?!»

Аның каялыгы билгеле инде. Ул, Гали батырны кызганганлыктан, кяфер батырына үзен Гали дип әйтеп, көче җитмәсә дә, аның белән сугышкан. Сугышкан да, башы киселеп, шәһит киткән. (Р. Г.)

Ну Гали батыр да кызык иткән! Ул үзенең «башын» кисеп, туй итеп ятучы кяферне, аның шәһәренә барып, кыз яныннан чакырып чыгарган. Үзенең сугышырга килгәнлеген бәян иткән.

Теге кяфер батыры әллә нинди ляфләр белән мактана башлаган икән, Гали батыр аның колагыннан тотып һавага аткан. Шундый көч белән аткан ки, һавада очып йөргән карга вә тилгәннәр-

---

*Сәтыр* — юл (язмада).

*Билифтихар вәлгорур* — мактанып һәм горурланып.

*Пашча* — патша; монда ирония белән бозып әйтелгән.

*Р. Г.* — Рәхмәтуллаһи галәйһи — аңа Алланың рәхмәте булсын.

*Ляф* — буш сүз, мактану сүзе.

нең, кяфер батырына бәрелеп, канатлары сынган. Алар җиргә җыгылып төшкәннәр. (Бу кадәресене күргән кешеләрдән сорадым.)

Әле мин баш кисү гадәтен вәхши кавемнәргә генә иснат иттем дә калдырдым.

Ләкин ул гадәт Европада хәзер бик худта.

Гәзитә укыган кешеләргә Париж вә Петербург кеби шәһәрләрдә мирас вә башка юк нәрсәләр өчен кеше үтерергә «кеше» яллыйлар, башлар кисәләр, ләкин Европада һәрнәрсә европалашкан кеби, баш кисү дә шомара.

Тик ул, шагыйрь Бальмонт әйтмешли:

> Этот ту же песню тянет, только он ведь просвещенный;
> Он оформит, он запишет, дверь запрет он на крючок*, —

кына була.

Булса булсын инде. Күп мәгълүмат сатмыйм. Менә хәзер безнең кыска гомеремездә күз алдында бер Гали батырның башын кисәргә кешеләр яллыйлар. Башта сөйләгән хикәя белән моның аермасы шул гына; моның пашчасы Җәнадилдә тормый, Таһранда тора.

Батыры да коры «Гали батыр» гына түгел, бәлки Мөхәммәтгали батыр[2]. Моның пашчасы да, халкы да кяфер түгел, бәлки мөселман, җитмәсә шига мәзһәбендә.

Мөхәммәтгали батырның башын кисәргә хәзер Таһран шәһәрендә хисапсыз күп батыр сайлана. Батырның башын китереп, чын-чын Мөхәммәтгали батыр башы, Әхтәм ... түгел лә, бер әлләкемелдәүлә, яки әлләкемелмалик** башы түгеллеген исбат иткән кешегә ике йөз мең сум акча биреләчәк. Күп акча бит! Бу акча хәзерге заманда артык күпкә хисапланмаса да, көчсез, ялгыз бер Гали батырдан курыккан Җәнадил патшасының ярты дәүләте кадәр бардыр әле. Акчасы бар, кызы юк, диерсез. Мин: «Акчасы булса, кыз табылыр, — дим, — табылмаса, Казанның Яңа бистә карчыкларына кушарбыз», — дим. Чөнки алар шундый зур «эш»нең хакыннан килгән батырга түгел, Төркстаннан адашкан чалбарсыз, бүрексез сартларга да менә дигән, шыгырдап тора торган кызлар табалар.

Укучы әфәнделәр шуны да белсеннәр ки, минем бу җиргә кадәр язып килгән сәтырларым анчак мөкаддимә рәвешендә бернәрсә генәдер, югыйсә минем төп максудым бөтенләй башка.

---

* Бу да шул ук җырны җырлый, ләкин ул бит укыган; ул формалаштырыр, язып куяр, ишекне элгеч белән бикләр.

** Әлләкемелдәүлә... әлләкемелмалик — бу кушма сүзләрдәге «дәүлә», «малик» дигән кисәкләре «патша», «хөкемдар» дигәнне аңлата һәм исемгә кушылып языла.

*Иснат иту* — терәп, (шуларга) кайтарып калдыру.

Укучылар, әгәр мине Әхтәм белән Җәнадил кыйссасын гына сөйли дисәләр, бөтенләй хата итәләр.

Түгел, мең кәррә түгел. Ул кыйссаларны 20 миллион Русия мөселманнары һәммәсе укымасалар да, 10 миллион Идел буе татары бары да укыган инде, хәтта күңелдән бикләгән.

Әгәр мәзкүр микъдар халык надан вакытта шул кыйссаларны укып гомер сарыф итмәгән булса иде, хәзерге борадәран Җаһилефләрнең Казанда беренче диярлек трехсветный магазиннары кайдан салыныр иде дисез?

Бары да без кыйсса укыганныкы. Бары да без батырлар белән селәгәй агызганныкы! Шулай булмаганда, алар дегет, ислемай, мичкә, китап, тәсбих, догалык, бәрәңге, гатырша мае сатып кына баемаганнар бит, андый һәр нәрсәсе мөкәммәл кибетләр Печән базарында хисапсыз күп бит. Башкалар берсе дә үзләренең миләре кебек череп баемаганнар. Ә болар? Болар тынчып баеганнар.

Гаяз әфәнденең «Кыямәт»ендә әйтмешли, алар хәзерге Кышири[3], Гафури, тагы әллә кемиләр кеби «мөтәмаймуллар»га 5 тәңкә сәдака белән «шөһрәт» бирәләр дә, тик баеп, үзләренең шәһвәте акчавияләренә көч биреп яталар. (Биэсәл-мөхәррире вә бәэсән-нашире!*)

Моннан да күчәм. Чөнки бу сүзләр дә болай гына, сүз җае чыккач кына сөйләнде. Асыл мәсьәлә баш кисү тугърысында иде бит. Ике баш санадым, әмма өченчесе һаман чыкмый әле.

Мәкаләм «Өч баш» сәрләүхәсе астында иде.

Төп максуд менә нәрсә.

Кадерле укучылар! Сезнең бәгъзеңез «Әгәр бер биэргә «дин вә мәгыйшәт»че төшсә, ничә чиләк су чыгарылырга тиеш?» кеби фәтвалар язылган «Дин вә чүплек»[4] журналын укыганыңыз бардыр бит. Күрәсез, укыйсыз, ләкин мәзкүр журналда бер бик кызыклы нәрсәне күрми калдырасыз, чөнки сез, укысаңыз да, маңлай күзе берлән генә укыйсыз, ә мин, сәвап вә әҗер өмид иткәнлегемнән, «Дин вә чүплек»не күңел күзем берлән укыйм. Бабайлар: «Күңел күзе булмаса, күз ботак тишеге генә», — дип дөрест әйткәннәр шул. Ләкин, укучы әфәнделәр, моннан соңра «Дин вә чүплек»не күңел күзеңез белән каравыңызны риҗаэ итәм.

Әллә өстәлгә куеп карарга җирәнәбез дисезме? Моңар акыл бар: кулыңызга күн бияләй киеңез, борыныңызга мамык тыгы-

* Язучысы да начар, бастыручысы да начар.

*Мәзкүр микъдар* — шул кадәр.

*Мөтәмаймул* — маймыл, тәмам шул.

*Шәһвәте акчавия* — акчага кызыгу.

*Биэр* — кое.

*Риҗаэ иту* — үтенү.

ңыз. Һәр шәһәрдә үзенә күрә чүплек башы була бит, әйбәтләп шунда җәеп кенә караңыз. Таки борыныңызга сатлык Моратлар белән эштән чыккан Ф.Сәйманиләр сасысы кермәсен!

Менә күз алдыңызда «Дин вә чүплек» журналы; дуңгызның арт саны дигән кебек, менә аның иң актык сәхифәсе. Актык сәхифәсе дигәч, эченең актык сәхифәсен карамаңыз, хикмәт тышында, ягъни оболочкасында.

Анда болай инә-җеп саплап тегү авыр булганга, тегү машинасы ихтирагъ иткән «Зингер»нең осуле җәдит игъланы бар.

Бу игълан бөтенләй иҗек белән уку авырлыгын әйтеп, кара тактаны игълан итү кеби гөнаһлы бер игълан булса да, Вәли мулла[5] моны ни өчендер журналына керткән. Әле теге, баягы динен кыстырмаган.

Куен сәгатьләре тугърысында Маузер никадәр мәшһүр булса, тегү машиналары хакында Зингер аннан да мәгълүмрәк.

Ул үзе Америкада, ягъни җир астында. Ничек дисезме? Шулай, менә, мәсәлән, безнең Печән базарыннан җирне казып, казылган урыннан ике потлы бер герне, калын арканга бәйләп, җир астына төшерсәң, нәкъ Зингер дигән еврейнең борынына бәрелә инде. Безнең җәгърафия шулай ди. Хәлфәбез дә, әллә ничек кулына җәгърафия китабы төшергәч, шул фикергә килгән иде. Чөнки Җир хәлфәнең тозлы аш ашап, азрак йоклап торгач, тәмләп чәй эчкәндәге лимоны төсле түгәрәк бит. Ул әле, лимон очын кисеп, самоварга да саладыр иде. Күп сөйли димәсеннәр өчен, анысын әйтмим әле.

Әмма көйгән лимон кабыгының исе шәп тә соң!

Менә шул җир астындагы еврей үзенең осуле җәдит машиналары хакында Американың үзендә, Европада, Азиядә, Африкада вә хәтта Австралиядә игълан тарата.

Моның игъланын — урамда булсын, өйдә булсын — һәркем күргәндер дип уйлыйм. Күрмәгән кешеләр өчен тәгъриф итми. Игъланның клишесендә бик һәйбәт бер аяк машинасы. Машинаны яңа гына төшкән бер килен үзенең килешле аяклары белән басып утыра. Килен дигәч тә, сезнең күз алдыңызга Гайнетдин мәми авызның усал анасы килеп, кайнана таягы астында көн күрә торган Миңсылу килмәсен. Аның рекламында, йөзендә вә күзендә үк сәгадәт галәмәте булган тулы йөзле, европейский киемле бер невеста утыра.

Бу игълан, Әхмәт вә Мәхмүт байлар хисапсыз күп сәдака өләшкәндә, Вәли муллага да тими калуы мөхаль булган бер

---

*Ихтирагъ итү* — уйлап табу.
*Тәгъриф итү* — аңлатып бирү.
*Мөхаль булган* — мөмкин булмаган.

яшел кәгазь шикелле, ничектер, «Дин вә чүплек»кә дә кергән; кермәскә, бу игълан бөтен дөньяны тоткан «динен» дә, «мәгыйшәтен» дә баскан. Чөнки Зингер ширкәте һәр номер игъланга бәрфараз, өчәр генә тәңкә түләсә дә, Гани угылы* фәкыйрьгә бер атналык әфиюн була. Ул әфиюн белән ул минутында йөз мәртәбә Бохараи шәрифкә бара, бәтчәләр коча, иләх... Кирәкми аэропланың, кирәкми очкычың!..

Мин баярак Вәли мулла Зингер игъланы тугърысында, «мәгыйшәтен» генә караган, «дин»ен кыстырмаган, дигән идем бугай. Юк, ул хата. «Ат тоягын куйганда, бака ботын кыстырыр» дигән кеби, Вәли мулла да, Зингер баеганда, үзенең «дин»ен китереп кыстырган. Ни эшләгән дисез инде.

Ни эшләгән булсын! Зингернең кургашын клишесендәге мин тасвир иткән яшь киленнең башын кискән. Тәмам 15–20 номердан бирле карап киләм инде, «Дин вә чүплек»нең ахыр битендәге яшь киленнең башы юк. Бер башсыз гәүдә машина тегеп утыра. Күңел күзе белән карасаңыз, укучылар, сез дә күрерсез.

Кызык, валлаһи! Бөтен татар хатыннары йөзенә арыш капчыгы киертергә тырышкан Ахмакҗан картлар хәзерге көндә «Жигули» сырасына гәзитәләрендә мәдхияләр язалар. Чәчен тап-такыр кырган шикелле, тиресе һәм мие белән күптән башын кырып ташларлык кына чүбек башлы Вәли муллалар Зингернең матур марҗасының башын кырган булалар!

Актык сүз буларак шуны әйтәм: әй Вәли мулла! Менә Ахмакҗан абзаң чәй сәүдәсе вакытыннан бирле үк килгән гадәләте белән «Жигули» бутылкасының башын да, фәләнен дә кырмыйча, туп-туры игълан итеп килә бит. Син дә, бер мәртәбә ширкәттән акча алгач, Зингер марҗасын башсыз калдырырга ирекле түгелсең. Аның башы матур, синең башың төсле ярты пот чүпрәк чорнамаган.

Юк, мин ифрат җитди әйтәм: «Вәли мулла! Кая югалттың син Зингер марҗасының башын? Падсуд пайдуш, указ гуҗмут**. Монда законлы җир».

Чынлап та, ул «сурәт»[не] ни өчен кырасың? «Мән саввара сурәтән...»*** дипме? Аны син ясамаган. Кяфер ясаган. Әллә

---

* Гани угылы фәкыйрь — монда сүз уйнату: «гани» — «бай» дигән сүз; бай улы фәкыйрь булып чыга.

** Хөкемгә тартылырсың, указыңны алырлар.

*** «Мән саввара сурәтән...» — «Берәү сурәт төшерсә...»

*Бәрфараз* — уйлап карасаң.

*Иләх (ила ахириһи)* — һ.б. (һәм башкалар).

*Гадәләт* — гаделлек.

Зингер марҗасының башы киселмәсә, «Дин вә мәгыйшәт» айгырларының шәһвәтен кузгатыр да, мөэмин арасында фитнәгә сәбәп булыр дипме? Алай булырга ул ит түгел. Кургашын гына, клише генә бит; әллә кургашын булса да, кәгазьгә төшкәч, матур булганлыктан, сезнең шуңар карап миегездә әллә нинди «Бибифаразия» абыстайлар мөртәсәм булып, үзеңезгә госел ваҗиб булудан куркасыңмы?

Ни булса да, өч данә интересный башлар. Берсе Җәнадилдә, икенчесе Таһранда, өченчесе Оренбургта.

Моннан чыккан нәтиҗә шул гына: «Дин вә чүплек»челәр тарафыннан, кече хатын дип, олугъ хатын дип вә башка юллар белән, елына әллә ничәшәр мең үскән кызлар һәлак ителгәне җитмәгән кеби, алар тагы әллә кайдагы Зингер марҗалары башын кисәргә керешкәннәр.

## АМЕРИКАДАН ВӘЛИ МУЛЛАГА ТЕЛЕГРАМ

Безнең Америка халкы, җирәнгәнлектән, сезнең «Дин вә мәгыйшәт»не Америка җиренә кертмиләр. Шул сәбәпле безнең Зингер ширкәтенең Америкадагы баш идарәсе синең безгә булган хыянәтеңнән хәбәрсез торды. Әгәр «Ялт-йолт» журналы укымаган булсак, һәнүз әле синең башсыз чыгарган марҗаңа елга әллә ничәшәр сум түләп торыр идек. Дин белән мәгыйшәтнең бу заманда бергә җыелып бетә алмавы сезгә дә, безгә дә мәгълүмдер. Бинаән галәйһи, син «мән саввара сурәтән» хәдисенә мөхаләфәт итеп булса да, безнең игъландагы марҗаның башын кырмыйча журналыңда басарга дип, бездән акча алдың вә алмактасың. Шулай булгач, син безнең гафләттән истифадә итеп, андый хыянәт эшләмәскә тиеш.

Кыямәт көнне безнең җансыз марҗабыз тирәсендә, урманда үлгән мужик янында иснәнгән аю шикелле, тик әйләнеп җөр. Барыбер син аңар җан кертә алмассың. Шәкертләреңне чакырып өшкертерсең, һаман да җан кертә алмассың. Сукыр суфилар чакырып төкертерсең, һаман да җан кертә алмассың. Җан кертә алмасаң, мәңгегә җәһәннәмдә җанарсың; әмма җан әбәдән кермәс. Бәс, син дә әбәдән җанарсың. Анысында безнең эшемез юк. Җан, көй, ләкин безнең марҗамызны моннан соң башлы итеп чыгар! Югыйсә без бу көннән игъланны туктатабыз вә,

---

*Мөртәсәм булу* — рәсемләнү, сурәтләнү.
*Госел ваҗиб* — юынып пакьләнү кирәк.
*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.
*Хәдисенә мөхаләфәт итеп* — пәйгамбәр сүзенә каршы килеп.
*Гафләттән истифадә итеп* — күрми-белми торганнан файдаланып.
*Әбәдән* — мәңге.

башсыз чыккан игъланнарны лэгу санап, акчаны суд белән кире сорыйбыз. Яхшы бел ки, без динен мәгыйшәткә саткан кешеләр белән шулай мөгамәлә кыйлабыз. Рустан дуңгыз асрарга аласың икән, аның башын кисеп асрама. Гомумән, баш булмау кимчелеге «Дин вә мәгыйшәт» мөхәррирләренә генә мәгъфудыр.

«Зингер ширкәте баш идарәсе».

**ВӘЛИ МУЛЛАДАН — АМЕРИКАГА**

Мая сам ни бидал. Набуршик вашы баришнә галава ысламал. Пичатник тужы минә ничава ни калякал. Динга, пожалыста, пускайти. Избини, тәпире галава будит. Мая читатыл ругатса. Зачим, гаварит, сам мулла, гаварит, «сурәт» пичатыш, гаварит. Тәпирә мая ява ысматрит ни будит. Тәпирә ваша абъявлиния галава поставим, дингә пускайти*.

Вәли мулла.

Оренбург. Вәли мулла, матбагага үзе кереп, Зингер игъланына баш ясаткан. (Әстәгъфирулла!)

Нью-Йорк. Яңа, башлы клише җибәрдек. Күзеңезне ачып караңыз.

Оренбург. Яңа клише. Мәскәүдә генә ясалып, Америкадан ук килмәгән, имеш.

Казан. «Дин вә мәгыйшәт»нең тышындагы Зингер игъланы марҗасының башы яңадан урынына утырган.

**«ЯЛТ-ЙОЛТ»**

Укучыларга мәгълүмдер ки, моннан ун номер, бәлки артык мөкаддәм Зингер марҗасының кырылган башы хакында журналыбызда «Өч баш» сәрләүхәле зур вә һәркем көлмәсә дә җылмаерлык бер мәкалә язылган иде.

Бөтен укучы халык вә шаһиде гадил булган кояшлар, айлар, йолдызлар күрмәгән бичара кызның башы кырылганын без «Ялт-йолт» белән ялтыратып күрсәткән идек. Берничә ай үтте. Ки күрәбез: әле шушы арада чыккан «Дин вә мәгыйшәт» номерларында Зингер марҗасы башлы булып чыга башлады. Бу хәлдән матбугатның, вә хосусилә көлке матбугатның, никадәр куәткә

---

* Мин үзем күрмәдем. Наборщик сезнең туташның башын җимергән. Басучы да миңа бер сүз дә әйтмәде. Зинһар, акча җибәрегез. Гафу ит, хәзер баш булыр. Минем укучы тиргәнә: ни өчен, ди, үзең мулла була торып, ди, сурәт бастырасың, ди. Хәзер минеке аны карап тормас. Хәзер сезнең белдерүгә баш куярбыз. Акча җибәрегез.

*Лэгу* — буш, файдасыз.

*Шаһиде гадил* — гадел шаһит.

*Хосусилә* — бигрәк тә.

малик икәнлеген аңларга мөмкин. Көлке матбугат шулкадәр көчле ки, кисек башларны яңадан муенга утырта ала.

«Ялт-йолт», әлбәттә, бу хезмәтне Зингергә файда булсын дип түгел, фәкать башсызлыктан көлү үз вазифасы булганга гына ифа итте. Чөнки, Зингернең Вәли муллага биргән телеграмында әйткәнчә, «баш юклык кимчелеге анчак «Дин вә мәгыйшәт» мөхәррирләренә генә якышып», Зингер марҗасында булса көлкедер.

Холәсател кәлям, моңар кадәр «Дин вә мәгыйшәт» тышында башсыз марҗа күреп туеп, инде башлысын күрәсе килгәннәргә мәзкүр журналның соңгы номерларын карарга тәүсыя ителер.

### КӨЛЕП ЯЗМЫЙБЫЗ, КӨЛЕП ӘЙТМИБЕЗ

Без «Ялт-йолт»та: «Зингер марҗасының башын кырган өчен «Дин вә мәгыйшәт» мөхәррире Вәли муллага: «Падсуд пайдуш!» — дисәк, көлеп әйтәбез.

Без «Ялт-йолт»та: «Бәянел хак» мөхәррирләренең русчадан тәрҗемәләре ни төсле икәнен, «поднос» — «борын асты», — дисәк, көлеп әйтәбез.

Без «Ялт-йолт»та: «Печән базар халкы итальяннар белән сугыша», — дип әйтсәк, көлеп әйтәбез.

Әгәр дә без «Ялт-йолт»та: «Журналымыз 15 көндә бер чыга. Бәһасе җылына 3 сум, ярты җылга тәңкә ярым, өч айга бер сум. Шул хакка алыңыз. Сезгә дә җәбер, безгә дә золым булмас», — дисәк, көлеп әйтмибез.

## «ЯЛТ-ЙОЛТ» ИДАРӘСЕННӘН СӨАЛЬЛӘР

Петербург губернасы Чабаксар өязе Мыштырмыш авылында Мурдахайҗан Кылмуллин сорый:

— Элек заманнарда кешеләр төрле сурәтләргә кереп, мәсәлән, маймул сурәтенә әверелгәннәр, һәм шул сурәттә алар, хакыйкатьтә чын кеше икәнлекләре беленмичә, әллә ничәшәр ел зар-сәргәрдан булганнар, имеш, диләр. Шул дөрестме?

Җавап:

— Менә Казанда Җиңгәчи, Уфада Кәмали[1] әллә ничә, әллә ничә еллардан бирле, кем каргышы беләндер, мәймүн сурәтендә гомер итәләр... Прахуд Мәхүб[2] тә элек мәймүн сурәтендә

---

*Ифа иту* — үтәү.
*Холәсател кәлям* — озын сүзнең кыскасы.
*Тәүсыя ителер* — киңәш бирелер.
*Зар-сәргәрдан* — аптырап-тинтерәп йөрүче.

күп сәргәрдан булып йөргәндин соң, әлкыйсса, Казан муллалары һәм бер татар гәзитәсенең фатихаи хәйриясе бәрәкәтендә сихере кайтарылды. Яңадан кеше сурәтенә кайтып, «тәүфикъле», эчми, тартмый торган чибәр сәүдәгәргә хатын булды. Димәк, синең сөалеңә «дөрест» дип җавап бирәбез.

Мәскәү губернасы Олугъ Мәңгәр волостеның Шилметдин Җонлыбияләев яза:

— Иске китапларда Муса галәйһиссәламнең таягы кырык аршын озынлыкта булган, шул таяк җылан да булган, агач булып хөрмә дә биргән, коедан су алырга җеп белән бау да булган, имеш, дип язалар. Бу булган эшме? Заманымызда да шундый могҗизалар була аламы?

Җавап:

— Була ала. Менә, мәсәлән, Муса әфәнде Бигиев таягының озынлыгы меңнәрчә чакрымдыр, диләр. Чөнки, шулай булмаганда, ул меңләр чакырым үзеннән еракта гы ялкау муллаларны корсакларына төртеп уята алмас иде? Андин соң, аның таягы ислахе дин мәсьәләсен кирәгенчә аңлаганга — җимешле агач вә аңламаганга — җылан булып күренәдер.

Таягының җеп белән чиләк булуы, әлбәттә, Муса әфәнденең Коръән вә хәдистән файдалы мәгънәләр чыгаруыдыр. Димәк ки, шәҗәрәи ислам (ислам агачы — дәрәхте ислам) безнең заманда да могҗиза була булып чыга инде.

Саратов губернасы Пенза өязе Зимничә авылының Гөрләбетдин Чәркин яза, малай:

— Мәсҗедтә төнлә мөселман җеннәре торалар, имеш, дигән сүзләр халык арасында сөйләнә, шул бармы?

Җавап:

— Үткән гарәфә кич Петербург мәсҗедендә әллә нинди пәри кызлары, пәри җегетләре тансавайт иткәннәре күренгән, ди. Шулай да иртә белән шунда гаед укыганнар. Бер дә андый-мондый нәрсә күренмәгән.

Петербургтан махсус алынган бу хәбәрне миңа җибәрделәр. Димәк ки, халыкның ул игътикады дөрест. Тик шунысы бар: әлегә Петербургта рәсми мәсҗед шәриф булмаганга, анда һәр гаед өчен тансавальныймы, бүтәнме зур бер зал алып, гаедне шунда укыйлар. Шөбһә менә кайда!

---

*Әлкыйсса* — озын сүзнең кыскасы.
*Фатихаи хәйриясе бәрәкәтендә* — изге догасы нәтиҗәсендә.
*Ислахе дин* — динне яңарту, аңа реформа ясау.
*Шәҗәрәи ислам* — мөселманнарның нәсел агачы.
*Игътикад* — ышану.
*Мәсҗед шәриф* — изге мәчет.

Самар губернасы Лаеш волосте Тәтеш авылыннан Бытбылдыкетдин әфәнде яза:

— Дәҗҗал белән Мәhди дигән затлар[3], иске игътикадлылар әйткәнчә, бервакыт килеп чыгарлармы?

Җавап:

— Кем белә, мин сиңа әйтим. Менә Төркиядә әллә нинди чалмалы мәhдиләр ел саен чыгып тордылар да hәммәсе ялганчы булдылар. Менә хәзер, чын Дәҗҗал булырга кирәк, Тырабլисе-гарәб тарафыннан бер нәмәрсә чыкты.

Фәкать шапкалы Мәhди вә хәлифәи мөслимин Вилhельм дә чын Мәhди булмады. Китапта Мәhдинең тәгърифе бүтән булса да, «чалмалы Мәhди»ләрдән эш чыкмады инде. «Әлбәттә, шапкалы бези кортарачак» игътикадындагы бичара төрекләр мәгъдур вә мәэюс калдылар (валлаhе әгъламе бис-саваб).

Сараш губернасы Пирмә авылыннанмы, әллә кайдан, шул як авыл муллалары качып эчкәндә, «Осуле кадимче»[4] дигән шигырьне җырлап эчәләр дип, аңар гаҗәпсенгән сыман яза.

Җавап:

— «Осуле кадимче» шигырен укыган кеше, әлбәттә, аның эчке мәҗлесе өчен шактый килешле бер шигырь икәнен икърар итәр, бу муллаларны Фәхрелислам Агиев тәнкыйтендәге «көндезге сәхәр»че, рузасыз мирза малайларыннан өстен табар иде.

Чөнки рузасыз мирза балалары үзләренә hичбер мөнәсәбәте булмаган:

Бетте баш — кипте яшь... —

шигырен чәй мәҗлесендә җырлап утыралар. Ул кайгысыз мирза малайларына ул җыру нәрсәгә? Кайсының башы беткән? Кайсының яше кипкән?!

— Яшь кипкән!

Ә җыласалар, чынаяк кадәр күзләреннән дөге-дөге яшьләр тамарга тора.

Беләмсең, муллаларда хәзер никадәр тәрәкъкый? Алар моннан биш-алты ел элек кенә кымыз hәм аракы (тфү! тфү!) эчкәндә (әстәгъфирулла!), «Мөхәммәдия», «Әминтәзәк»[5] җырлыйлар иде.

Ә хәзер? Хәзер — «Осуле кадимче»! Чиләгенә күрә капкачы. Шулай hәр эшне урынын белеп эшләргә кирәк.

Чурт белә, каяндыр берсе:

— «Гыйшык тоту» чын нәрсәме, Таhир-Зөhрә, Бүз егет булганнармы? — дип сорый.

---

*Тәгърифе* — аңлатмасы.
*Мәгъдур вә мәэюс* — алданып hәм өметсезлектә.
*Валлаhе әгъламе бис-саваб* — дөресен Алла белә.
*Тәрәкъкый* — алга китеш.

Җавап:

— «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет»тәге дәрәҗәдүк «гыйшык тоту» элек заманда булса булгандыр. Әүвәлгеләр, мискиннәр, бик яхшы күңелле булганнар. Әмма заманымыздагы «гыйшык» ушбу түбәндәге ике вакытта җырланган ике җырдан аңланса кирәк:

Өйләнгәнче:

Алҗапкычың ал мәллә,
Алдында алма бар мәллә?
Сандугач кебек сайрыйсың,
Аузыңда кош бар мәллә?

Өйләнгәч:

Алҗапкычың ал мәллә,
Алдында бәрәңге бар мәллә?
Ала карга күк сайрыйсың,
Аузыңда бозау бар мәллә?

Аңар ни кирәк инде тагы — бер Алла бәндәсе бездән:

— Италия ни сәбәптән Төркиягә һөҗүм итте? — дип сорый.

Җавап:

— Италиянең симергән, эшсезлектән әлсерәгән байлар партиясе корсакларын бер кәррә киерделәр дә:

Ашасым да килә, ай, әллә ни,
Тыраблиста пешкән алманый... —

дип җырлый башладылар. Җырның калган кыйсьмен җырлатмадылар да, киттеләр:

— Әйдәгез Тыраблиска! алтын алма өзәргә! «Иркә»ләрнең ашыйсы килә!

Әйдә барыйк Самарга
Бакыр акча санарга...

Киттеләр... Италия крәстияннәре протест иттеләр... Чөнки алар ач, аларга ашарга кирәк, сугышырга кирәкми... Аларның җугарыдагы иркә җырларга телләре бармый.

Ашлык уңмаган. Мал-туар сатылып ашалган, угыллары — солдатта, яки фабрикаларда, семья зур. Шәһәрдә дә эш юк: байкот! Бичара крәстиянгә, сөяк капчыгы булган аты белән арбасына карап, моңлы гына:

Ашасым дай киләй, ай, әллә ни,
Өй түрендә торган арбаный... —

дип җырларга гына кала.

Берсе тагын «Икътисад» журналыннан[6] сорыйсы сүзен бездән сорап маташа:

---

*Кәррә* — тапкыр.
*Кыйсьмен* — бүлеген.
*Икътисад* — экономика.

— Ни сәбәптән безнең уртача вә чибәр генә көн күрүче сәүдәгәр кисәкләрендә вә эшчеләр гаиләләрендә көннән-көн фәкыйрьлек арта? — ди.

Җавап:

— Моннан ун-унбиш ел элек кенә кичләрдә гаиләсенә кайтып җәелгән ашъяулык, кайнаган самавыр, атасы кайтканына шатланган балалар янына утырып, ике кулы белән генә күмәчне (бисмилла әйтеп) сындырып, кулында чәйле чынаяк тәлинкәсе тоткан хәлдә, «шыр-р-рт» иттереп теше белән шикәр сындырган кешеләр хәзер нәкъ шул вакытта дуңгызлар җирәнерлек пивнойларда каткан сохари тешләп утыралар.

Кайсы урамнан кайтсалар да, әлеге алдавыч яшелле-сарылы вывеска:

Ары барма, җаный, кайт бире,
Һәр урамда урыс трактиры...

Бәс, без гаиләләрдә фәкырне күбрәк шуннандыр дибез. Татар акча тапмый түгел, таба.

## СӘГЪДЕ ВӘКЪКАС ӘФӘНДЕГӘ

Сәгъде Вәкъкас әфәнде, моннан берничә нөсхә элекке «Шура» журналында бер мәкалә язып, ике юллы татар шигырендә бер юлның ахыргы сүзе «нәрсәгә» булып, икенчесенең ахыры «мәсьәлә» булуын вәзне шигырь җәһәтеннән дөрест күрми.

Әле моңар кадәр бездә бертөрле һәркемне икънагъ итәрлек вә тәхриратны бер нәүгы кагыйдә астына җыярдай «кавагыйде лисан» — «теория словесности» — мәйданга килмәгән булса да, мин «нәрсәгә» белән «мәсьәлә»нең вәзен булырга яраганлыгын дәгъва итәмен. Бу дәгъвама игътимаде галәннәфсем сәбәп, һәм үз файдама хәтеремдә берничә мисаллар да бар.

Мисаллар:

Провозглашать я стал любви
И правды чистые ученья:
В меня все ближние мои
Бросали бешено каменья.

Менә бу дүрт сәтырлык шигырьдә вәзен сүзләре «ученья» белән «каменья» икеседер. Сәгъде Вәкъкас әфәндечә, Лермонтов, яңлышып, «ученья» белән «каменья»не бер-беренә каршы вәзен ясаган булырга кирәк. Чөнки «ученья»гә «мученья» яхшырак вәзендәш иң!

---

*Вәзне шигырь* — шигырь үлчәме.
*Икънагъ итәрлек* — канәгатьләндерерлек.
*Тәхрират* — язылган, иҗат ителгән әсәрләр.
*Игътимаде галәннәфсем* — үз-үземә ышануым.

Төрекчәдән:

Собхыдәм дугъмыш күрәнчә афтабе әнвәри,
Нурдан якыпарә бер айинә сандым хавари.

Сәгъде Вәкъкас әфәнде фикеренчә, монда да «әнвәри» һәм «хавари» кафияләре яңлыш булып чыгадыр. Чөнки бер сәтырның ахыры «әнвәри» булгач, икенчесенеке, әлбәттә, «канвәри», «шәнвәри» булырга тиештер.

Гарәпчәдән:

Вәәҗмәле минкә лям тара катты гайнин
Вәәхсәне минкә лям тәлиден-нисаэ
Холикътә мөбәррәән мин көлли гайбин
Кәәннәкә кад холикътә кәма тәшаэ.

Сәгъде Вәкъкас әфәнде фикеренчә, бу шигырьдә дә «нисаэ» белән «тәшаэ» сүзләре вәзенгә килмәгәннәр. «Нисаэ»гә каршы шагыйрь әфәнде «кисаэ» дигән булса, артыграк булмасмы иде?!

Татарчадан:

Мин, димен мин[1]! Мин, дидисәм,
Миңа бер зур көч кирә.
Әнә алар, шаһлар, кануннар
Булалар бер чүп кенә.

Бу шигырьдәге «көч кирә» белән «чүп кенә» сүзләре дә бер дә ятышмыйлар кебек.

Мин, сүз ахыры уларак, ушбуны әйтәм: һичбер шагыйрь, шигыренең бер юлы ахырын «такмак» дип язгач та, каләмен колагына кыстырып, мич арасыннан кыштыр-кыштыр «шакмак» эзләп йөрергә мәҗбүр түгелдер.

Шулай ук һичбер назыйм бер юл ахырын «сукмак» дип туктаткач та, өйалдына чыгып, «тукмак» эзләргә бурычлы түгелдер.

Такылдамак белән мәүзүн сүз сөйләмәк икесе башка-башка булырга кирәк.

**ШИГЫРЬ**

Бер үлчәүдә: кырау, сорау, мияу, мырау,
Һәм кылтырау, һәм шылтырау, һәм кыңгырау;
Вә «өркетик», вә «беркетик», вә «куркытыйк»,
«Бетик», «көтик» берлән «сатыйк» һәм «кыт-кытыйк»!

Менә, шигырьдә юл ахырлары вәзен җәһәтеннән дөрест булса да, шигырьнең эчендә мәчеләр кычкырып, тавыклар кыткакларга тотынсалар, бер дә күңелле түгел инде!

---

*Кафия* — рифма.
*Назыйм* — тезмә әсәр язучы, шагыйрь.
*Мәүзүн сүз* — тезмә сүз.

## ГАРӘПЧӘ ЯҢА МАСДАРЛАР

Иске вә яңа гарәп лөгать вә әдәбияты никадәр бай булса да, яңарган без татарларның яңа әдәбиятында бәгъзе мәгънәләрне ифадә өчен һаман да җитеп бетмидер.

Мәсәлән, гарәпләрдә «ялгызлашмак»ка «тәфәрред», «сүзләшмәк»кә «тәкәллем» диләр. Әмма безнең татар әдәби телендәге хәзер генә пәйда булган «руслашмак», «төрекләшмәк», «уңланмак», «сулланмак» шикелле сүзләргә гарәпчә масдарлар табып булмый иде әле.

Менә мин, милләтемә олугъ файдалар килүен өмид итеп, ушбу түбәндәге берничә мәсадирны әнзаре гаммәгә куймакчы булдым.

### *Масдарлар*

*Руслашмак* — тәвәррес.
*Төрекләшмәк* — тәвәррек.
*Японлашмак* — тәяппен.
*Суллашмак* — тәвассыл*.
*Нимсәләшмәк* — тәнәммес.
(Вә ма эшбәһә заликә вә кыйсь галәйһи әлбакый**.)

«Уңлашмак» масдарының заммәсе***, «вау»га авыр булганга һәм саңгырау кяфләр гарәпчәдә булмаганга күрә, үзгәртелмәде. Әлбәттә, «тәвәуң» булачак иде.

## ТАТАРЧАГА САРЫФ, НӘХҮ ЯЗУЧЫЛАРГА ИХТАР

Әфәнделәр, сез язасыз да сызасыз. Әлбәттә, эшеңез җиңел түгел. Сезгә милләт рәхмәт укый. Хәтта «Мөхәммәдия» укыган кебек көйләп үк укый. Чөнки сез, андый нәрсәләр язганда,

---

* Гарәпләрнең теле кызыл булгач, «уңлашмак» сүзен нишләп кабул итсеннәр?! (*Г.Тукай искәрмәсе.*)

** Шуның кебекләр; калганнарын шуңа чагыштыр («яраштыр» мәгънәсендә).

*** *Заммәсе* — өтере; гарәпләрдә кыска сузык авазлар тартыклар һәм озын сузыклар янына «хәрәкә» дип аталган диакритик — билгеләр кую юлы белән ясала.

*Масдар* — исем фигыль; сүзнең баш формасы, инфинитив.
*Лөгать* — сүзлек.
*Ифадә* — аңлату.
*Мәсадир* — масдарлар.
*Әнзаре гаммәгә* — халык каравына.
*Нимсәләшмәк* — немецләшү.
*Кяфләр* — «к» хәрефләре.
*Сарыф* — морфология; *нәхү* — синтаксис.
*Ихтар* — искәрмә.

төрле гарәп вә хосусән рус мәнбәгъләренә мөрәҗәгать итеп, аз күкрәк көче сарыф итәсезмени? Ля йөгадде вә ля йохса!

Менә әле бу көннәрдә, русча грамматика актарып утырганда, минем башыма бик файдалы бер фикер төште. Әкрен генә төшкәндер дип уйламагыз тагы: «шап!» итеп төште. Икенче алай кеше башын авырттырып йөрмәсен дип, мин ул фикерне, сыйрагыннан тотып, «Ялт-йолт» сәхифәләренә олактырам.

Һәркемнең башы үзенә кыйбат. Мөхәммәтгали башы булып, әле ул да 200 мең сум тора. Кем белә, бәлки, минеке миллион тәңкә тора торгандыр. Әле бит мин, ит базарына чыгып та, башымны бүкәнгә куеп хак бирдергәнем юк.

Мин шул бер сөйләшә башласам, Казан маклерлары шикелле, авызны яба алмыйм. Әйтәчәк фикерем шушы:

Мин грамматикада «Өч токым» дигән гаҗәеп бер фасыл күрдем. Грамматика диер ки:

«Тора торган (имена существительные) өч токымга бүленәләр: ир токым, хатын токым, урта токым.

Әгәр бер әйбер хакында «он, этот» дип әйтергә яраса, ул әйбер мужской род, ягъни ир токым була. «Апрель», «сарай», «чай» кеби.

Әгәр бер әйбер хакында «она, эта» дип әйтергә яраса, ул әйбер женский род, ягъни хатын токым була. «Школа», «душа» кеби.

Әгәр бер әйбер хакында «оно, это» дип булса, ул әйбер средний родтан, ягъни урта токымнан буладыр.

Ир токым булган сүзләрне шуннан беләбез ки, ул сүзләр каты һәм йомшак сәкен белән, сәкенле «й»гә бетәләр (югарыдагы ир токымнарга караңыз).

Хатын токым булганын шуннан беләбез ки, ул сүзләр «а» һәм «я» хәрефләренә туктарлар.

Урта токым булганын шуннан беләбез ки, ул сүзләр «о, е, мя» хәрефләренә туктарлар».

Бу кагыйдәне күчергәч, хикмәти Хода, кая карасаң, анда без фәкыйрь милләтнең бер җире җитмәгәнлеге заһир була! дидем.

Соң безнең телдә нигә бер генә токым?! Без ник бер генә токым?! Дүртәр хатын да алучыларымыз бар лабаса! Менә минем башымны яра язган кайгылы фикер шушы инде. Сез теләсәңез — минем кайгыма иштиракь итәсез, теләмәсәңез — юк. Ләкин мин үзем:

---

*Мәнбәгъләренә* — чыганакларына.
*Ля йөгадде вә ля йохса!* — Санап бетергесез!
*Сәкен* — тукталыш (тартык).
*Заһир булу* — ачылу.
*Иштиракь иту* — кушылу.

Инсан улан, өстенә җон кунса да, хәүф итмәсен;
Батыйнән хәүф итсә итсен, заһирән белгертмәсен, —

мәаленчә, бер нәрсәдән дә курыкмыйча, хәзер шушы мәкаләмдә үк хатын токым белән урта токымны үз телемезгә илхакъ итәргә керешәм.

Татар телендә өч токым бар: ир токым, хатын токым, урта токым. Безнең токымнар да, югарыда күрсәткәнем русча токымнар нинди хәрефләргә туктаган булса, шул хәрефләргә туктап, шулар белән бер-береннән аерылалар. (Бу кагыйдәдән фәкать «хатын», «сыер», «кыз» дигән сүзләр генә мөстәснадыр.)

Мисаллар: ул, ула, уло; бу, буа, буо.

Җөмлә тәркибләре: ула хатын үзея матура булса да, сүзләре ямьсезәдер һәм ула гаять наданәдер. Тегея кыз тегүчиха кыз. Уло койо тирәнөдер. Буо сөлге кызыло башлыйодыр. Тегейө бүлмә тародыр.

Һәркем беләдер ки, «Ярты алма»[1] китабындагы «тидия» гыйбарәсе «тиди» (әйтте) мәгънәсендәдер. Шулай булгач, Хәсән Галиләр[2]: «Элек заманда бездә хатын кеше әйткән сүз хакында «тидия» дия, имешләр. Ирләр әйткән сүз булса, «тиди» диер улмышлар», — дия, бер кәшеф ясый алмаслармыни? Димәк, бездә дә әүвәлдә «сказала, сказал» сүзләре булган була.

Хәер, теге фикер башыма «шап!» итеп төшсә дә, бушка китмәде. Тик торганда телемезгә ике токым арттырдым һәм «тидия» кеби лисанымыз тарихында мөһим бернәрсә кәшеф иттем.

Габдулла Гыйсмәти әфәнде[3] үзенең «Ана теле» нам кыйраәт китабында балаларга мисал өчен «кылт итеп исемә төште» дигән сүзне язмаган булса, минем дә исемә бу фикер «шап!» итеп үк төшмәгән дә булыр иде. Ул кыйраәт китабында: «Кылт итеп искә төшү җаиз булгач, шап итеп искә төшү лимә ля яҗүзе?» — дигәндер шул; хакы бар. Югыйсә әдәбиятымызның аслы, җәүһәре булган безнең Казан телендә фикерләр «келт» итеп кенә искә төшәләр иде.

---

*Батыйнән* — эчтән.
*Заһирән* — тыштан.
*Мәаленчә* — (шуннан) аңлашылганча.
*Илхакъ итү* — кушу.
*Мөстәснадыр* — аерылып кала.
*Кәшеф* — ачыш.
*Лисан* — тел.
*Кыйраәт* — уку.
*Җаиз* — дөрес.
*Лимә ля яҗүзе?* — Ник дөрес түгел?

# 1912

## БЫЛТЫРНЫҢ ХИСАБЫ

Былтыр «Ялт-йолт», тәмам төгәл утыз яшенә җитеп[1], ир уртасы кеше булды. Шушы яңа ел башында милләт акча бирсә (елга өч сум, ярты елга сум илле тиен), башлы-күзле булам дигән була. Өйләнгәч, вакытында чыгасың, вакытында керәсең, вакытында эшлисең, дип сөйләнгәли.

Былтыр Оренбург ачларының хәлләре хәлдән дә, чиктән дә тыш начарланды. Әгәр аларны Борһан Шәрәф әфәнде «Йосыф китабы» белән көйләп юатмаса, эшләр начар иде. Хәзер ачлар, җырлаганда, үз-үзләрен юатып:

Ачлык булу гаеп түгел — пәйгамбәрләрдин калган, —

дип җырлыйлар.

Былтыр Шәрәфетдин Шәһидуллин: «Син үзеңдә яхшы мал барын игълан итмәгәч, халык аны кайдан белсен!» — дип, моңарчы коммерция галәменә мәгълүм булмаган шәп сүз әйтте.

Былтыр Һади әфәнде[2] Италия-Төркия сугышының безгә нәмәгълүм бер сәбәбен ачты. Аның фикеренчә, Казанда, мәсәлән, дүрт Гали бар. Аларның икесе бай, икесе ярлы. Төркия белән Италия икесе бер мәҗлестә очраганнар да, араларында мәзкүр дүрт Гали тугърысында сүз башланган. Сүз арасында Төркия: «Мин ул Казандагы Галиләрне беләм. Ул Галиләр бик бай», — дип әйткән, ди.

Италия, моңар каршы төшеп: «Юк, син белмисең; ул Казандагы Галиләр икесе дә ярлы Гали!» — дип кычкырган да Төркиягә һөҗүм иткән, ди. Менә шуннан киткән сугыш, киткән сугыш. Әмма сәбәп — нинди юк эш! Берсе ярлы Галиләрне белгән, икенчесе — байны.

Былтыр «Новое время»дә Мишниковның[3] шушы мөһим бер мөляхәзәсе басылды: «Мин шәхсән һичбер милләткә дошман түгел. Мин милләтләрнең һәммәсен чын күңелдән сөям. Һәм сөймәскә сәбәп тә юк. Мәсәлән, бер-беренә гашыйк булган әллә ничә пар егет белән кыз урам тутырып йөрсәләр, шул вакыт бер пар икенче парга дошман буламы? Әлбәттә, юк. Мин дә инглиз, француз, немец аерымлыкларына шулай гына карыйм.

---

*Нәмәгълүм* — беленмәгән.
*Мәзкүр* — әлеге.
*Мөляхәзә* — уй-фикер йөртү.

Сез әйтерсез: менә син яһүдиләргә дошман ич, диерсез. Дөрест, мин аларга дошман. Ләкин аерым булганлыклары өчен түгел; фәкать русларга катышып, рус канын агулаулары өчен дошман. Мәсәлән, мин дегетне аерым хәлендә бик яратам. Әмма бал кисмәгендә балны каралтканын ярата алмыйм».

(«Ялт-йолт»: Син карт бүрене дә без аерым хәлендә бик яратабыз. Әмма матбугат кисмәгенә кереп, аны үзеңнең керле нәрсәләрең белән каралтуыңны ярата алмыйбыз.)

Былтыр Троицкий Мирфәйзә[4] «Буф»та үзенең тамак төбенә «нәүми җариясе» тыгып, анысы эчтән нечкә тавыш белән озын вә кыска көйләрне җырлады. Мирфәйзә юри, җырлаган төсле, иренен генә селкетә иде.

Халык исә: «Бу кадәр җуан кешедән ничек мондый нечкә тавыш чыкты икән?» — дия хәйран калышалар иде.

Былтыр Габди[5] үзенә «шәкерт» диючеләргә мисле булмаган дәрәҗәдә бер үткен сүз әйтте. Гыйбарәләре тәкърибән шушылай бугай: «Торалар да, Габди шәкерт ул, диләр. Соң, «Ля тәнзыр иля мән каля вәнзыр иля ма каля»* дигән мәкальне һәр бала да белә ләбаса!»

Былтыр Мәкәрҗәдә күп кешеләр җиңгәсе булган җиңгәчи татар байбәтчәләре, татар гуляклары арасында бер узыш ясады. Мәсьәлә: кемнең һәммә кешедән артык акча биреп, бер кичне «мәхәл»не бикләтеп, үзе генә калуында иде. Бәйгегә күп татар катышты. Бирделәр 3 йөз тәңкә, бирделәр 4 йөз, бирделәр 5 йөз, бирделәр 6 йөз, 7 йөз; ахирел әмер бер Оренбург байбәтчәсе 8 йөз тәңкә бирде дә, шул кич «мәхәл»дә үзе генә калып, шат вә хәндан улды. Узучының кем икәнен язмыйм. Чөнки аны белмәгән кешедән: «Шуны да белми!» — дип көләргә дә ярыйдыр.

Былтыр Камчылы ишан[6] үзенең хәстә асравын өшкереп, кәрамәте вә шифалы төкерегә белән мискинәне сәламәтләндерде. Ул гына да түгел, «Ходайның рәхмәте» илә, кызга корсак та үсте.

Былтыр Мостафа Лотфи, инде үзенә берәр тәңкә бирми башлаган халыктан берәр тиен генә сорап, «Хак» исемендә ялганчы урам гәзитәсе чыгарып карады. «Хак»ыннан аерылгач, хәкыйкатьне амбаллыктан тапкан, дип сөйләделәр.

---

* Кем әйткәнгә карама, нәрсә әйткәнгә кара.

*«Нәүми җариясе»* — яшь кыз.

*Тәкърибән* — якынча.

*«Мәхәл»* — фәхешханә.

*Хәндан* — куанычлы, бәхетле.

*Амбаллык* — хәммаллык, грузчиклык.

Былтыр Том дарелфөнүне самигъ вә мөдавимнәреннән Мөхәммәт Вагыйзен-Нәүрузи хәзрәтләре, «Мәдәният» исемендә гәзитә чыгарам дип, мәдәниятсезләнеп йөрде.

Былтыр Байбурин Дума мөнбәреннән татарлар файдасына 88 нотык йоклады.

Былтыр, Бәдигъ мәзин күркәсеннән күреп булырга кирәк, арамызда Америкага китүчеләр күбәйде. Бәгъзеләре «Йолдыз»-га мөхбир дә булдылар.

Былтыр Түнтәр тарафыннан Дәҗҗал мәлгунь[7] чыгып, теләгәннәрен — оҗмахка, теләгәннәрен тәмугка кертеп йөрде.

Былтыр Троицкидә «Акмулла»[8] исемендә туганнан бирле көлми торган бер бала туды.

Былтыр Маймыл Хафизга пәри-җен ияләште. Чөнки ул бер үк вакытны өендә «Сөбател гаҗизин» дә укый, шунда ук театр сәхнәсендә дә күренә[9]. Печән базары мәчетенең мөселман җеннәре күтәреп йөртәләр, күрәсең.

Былтыр Аксак Низаминың[10] тавыш-тыны басылды. Өченче ел ул:

Хафиз абзый, ник басасың
Низаминың «Карга»сын?
Йөз сумыңны бир тизерәк,
Эшләр судка бармасын, —

дигән мәнзумә язган иде.

Бәлки, шул акчаны алгач, авызы тыгылгандыр. Бездә динчеләр авызы шуның белән тиз каплана.

Былтыр Төркиягә Италия мөһим бер ультиматум бирде:

— Төркия хөкүмәте! Белеп торыңыз ки, без сезне таларга барабыз. Безгә бу талау бик мөһим. Моны киләсе елга да кичектермибез. Чөнки сезнең хәзер Тыраблиста бер полк та гаскәреңез юк. Эшкә ярарлык бер тубыңыз юк. Безнең гаскәр вә азык ташуыбызга манигъ булырлык флотыңыз юк. Без рәхәтләнеп ташыйбыз. Без утыз елдан бирле бу хыялга мөбтәля булсак та: «Өлгерербез әле!» — дип тордык. Ләкин сез хөрriяттән соң уяндыңыз. Әгәр без талауны кичектерсәк, сезнең берничә елда Тыраблиста «алынмас истихкямнәр» ясамавыңызга кем кәфил?

*Том дарелфөнүне* — Томск университеты.
*Самигъ* — ирекле тыңлаучы.
*Мөдавим* — даими йөрүче.
*Мөхбир* — хәбәрче.
*Мәнзумә* — көйле әсәр.
*Манигъ* — тоткарлык, киртә.
*Мөбтәля булу* — дучар булу.
*Истихкям* — крепость.
*Кәфил* — гарантия бирә.

Без, итальяннар, мөтәвазыйганә вә рәкыйганә икърар итәмез ки, бездә андый җәсарәт тү-түүүү!

Хатире гатыйр-гатыйфәт пәнаһиләрендәдер* ки, безне күптән түгел яланаяклы хәбәшләр дә шәрран-яра кыйнап кайтардылар.

Сезнең кеби намуслы вә шанлы милләт илә безнең кеби органлы вә шарманлы (шарманкалы) милләткә сезнең дә хәзерлегеңез бар вакытта сугышмак, әлбәттә, мөхальдер. Без әле дә курка-курка гына барачакмыз.

Димәк, без талыйбыз, бу — хак. Пәйгамбәреңез: «Каилел хакка вә ләу кянә мөрра»**, — димештер.

Былтыр Фас ашханәсе тәрәзәсеннән ташланган сөякне Һирман вә Франс атлы ике «зур маэмай»[11] талашмыйча гына бүлештеләр.

(«Ялт-йолт»: надир эш!)

Былтыр Магулстан исемендә олугъ вилайәт[12], Кытайдан аерылып, үзенә аерым падишаһлык булды.

Әгәр бер карак, урлаган әйберен култык астына гына тыккан булып, үзе кулларын болгап сугышса вә хәрәкәт итсә, аның әйбере һәрвакыт җиргә төшеп, үзеннән аерыладыр. Кытай хөкүмәте моңарчы Монголияне яхшылап кесәсенә яшерә алмыйча, култык астында гына кыстырып, үзе хәрәкәтсез яткан иде. Моның мисалын һәрбер хәрам әйберен эчкә яшерә алмаган дәүләтләр хәрәкәтендә күргәнемез бар.

Былтыр, өенә карак кергәндә, хатыны белән сугышкан авыл мужигы кеби, Төркия зыялылары, Италия Тыраблисны талап ятканда, үзара җәнҗал вә скандал белән миләрен череттеләр.

Былтыр хаҗҗел хәрәмәйнил мөхтәрәмәйни вәлкоддесишшәриф, получил образование в Египте, имеет место муллы вә мудариса, редактор четырех изданий, основатель женской школы, женатый, ходящий двумя ногами, ловящий ветер двумя рука-

---

* Яхшы хәтер — изгелекнең сакчысыдыр.
** Ачы булса да, туры әйт.
*Мөтәвазыйганә* — түбәнчелек белән.
*Рәкыйганә* — (алдыгызда) бөгелеп, иелеп.
*Җәсарәт* — батырчылык.
*Шәрран-яра* — ачыктан-ачык.
*Мөхальдер* — мөмкин түгелдер.
*Фас (Фец)* — Марокконың башкаласы.
*Һирман вә Франс* — Германия һәм Франция.
*Надир* — сирәк.
*Магулстан* — Монголия.
*Олугъ вилайәт* — зур өлкә.

ми, шарлатанствующий во всех городах* әфәнде хәзрәтләре белән Шаляпин лакееның дуэле булды[13].

Сорарсыз: кем үлде? «Ялт-йолт» укучыларга барыбер: кирәк лакей, кирәк Хиффәтуллин үлде.

Былтыр Чәйнәшев Әхмәтҗанга гаед саен мәсҗетдә нотык сөйләп, халыкны изгелеккә өндәү юлы ябылды. Чөнки инде ул торып сөйли башлагач та, халыктан берәү тора да аңар гәзитәсендәге «Жигули» игъланын искә төшерә; галимрәге булса, «әтәәмерунән насә билбирри вә тәнсәүнә әнфесәкем»** аятен укып җибәрә.

Былтыр, мөфтигә җүбәләй ясалып, моңарчы кибетләрдә чәчелеп вә аунап яткан чалма, тәсбих, «Мөхәммәдия», намазлык, чапан, комганнарны мөфти алдына өеп чүмәлә ясадылар.

Былтыр, «Идел» фельетонында «Живой труп» тәрҗемә ителә[14] башлагач, укучылар Төркия шпионнарын сагынып җылаштылар.

Былтыр Иран хөкүмәте мәмләкәтне ислах итәргә Америкадан Шустер нам бер затны китерткән иде. Ул, ислах өчен Америка гаскәрләре китертүне ераксынып, якындагы Русия гаскәрен генә кертүне мәгъкуль күрде.

Былтыр Һади Атласов «тик тора алды»[15].

Былтыр Петербургта «В мире мусульманства»[16] дигән әллә нинди рус исемендә бер чын мөселман пәйда булды. Ул әллә ниләр эшли: «Шырутел ислам» бастыра. Багана-багана хәдисләр дәреҗ итә. Мусульманин, ди, панисламизм, ди, единоверцы, ди. Әлхасыйль, бигрәк җете кызыл мөэмин булып кыйлана. Мөселманнар: «Ай-һай, тиз уңмаса ярар иде», — дип шиктә торалар.

Былтыр да «Дин вә мәгыйшәт»нең башы хаез, уртасы нифас, ахыры истинҗа иде***.

Былтыр Галиәсгар Камал безнең шәһәрнең серләрен чит шәһәрләргә сөйләде дә куйды. Электә чит шәһәрдә йөргәндә, синең яныңа киләләр дә:

— Казан ничек? Халкы ничек? Андагы «Шәрекъ клубы» ничек? Фәлән ничек? — дип йөдәтеп бетерәләр иде. Әлбәттә,

* Хаҗ кылган, Коддес Шәрифтә (Иерусалимдә) булган, Мисырда укыган, мулла һәм мөдәррис, дүрт газета-журнал редакторы, хатын-кызлар мәктәбе оештыручысы, өйләнгән, ике аякта йөрүче, ике кулы белән җил аулаучы, бөтен шәһәрләр буенча шарлатанлык итүче.

** Кешеләрне изгелеккә өндәп тә, үзегезне онытасызмы.

*** Бу журналның күрем күрү, бала тудыру, аннан соң пакьләнү кебек мәсьәләләргә карата мәкаләләр белән тулып чыгуына ишарә.

*Ислах* — реформа.

*Дәреҗ итә* — урнаштыра.

эчләреннән Казан вә аның мөтәгалликатенә бик мактаулы җавап көтәләр иде.

Бирмәсәң — оят бәдбәхеткә, бирсәң — кыен,
Ул акчаны тапкан бит ушбу муен, —

дигән шикелле, Казан вә казанлылар тугърысында ялганлап, сүз белән сүз истигъмаль итәсе килми иде. Ялганламасаң, аларның хөсне заннарын бозу була иде. Менә хәзер аларга «Безнең шәһәрнең серләре» — укысыннар да белсеннәр, кемнәр барын күрсеннәр.

Былтыр Ахмакшәрик Сапсатасатаров[17] нам бер учительгә татар җене кагылды. Мәзкүр әфәнде, көздән бирле котырып, «Татар халкы», «Татар кызы», «Татар бүреге», «Татар кәвеше», «Татар катыгы», «Татар мөгезе» исемнәрендә көн саен диярлек әллә никадәр чүпләр бастырып, китап кибетләрен бөтенләй шуның белән тутырды. Мондый кешеләрне «сары йортка» ябалар ябуын, ләкин бер җәһәте бар: бу кадәр һәр китабын татарның бер нәрсәсе белән исемләгән, үзенчә милләтче бер мәҗнүнне япканда да, «татар диванаханә»сенә ябарга кирәк. Ул исә, мәгаттәәссеф, бездә юк. Ни эшлисең? Иректә йөри шул!

Былтыр «Русское слово» Дорошевиче белән «Вакыт» Дорошевиче[18] Шәриф Камал әфәнде эш ташладылар.

Былтыр Кавказда бик шәп исемнәр белән бик начар гәзитәләр чыгып, үзләренә махсус күбәләк гомерләре белән шып туктадылар.

Былтыр Мөхәммәтгали шаһ[19] һәр көн, йокыдан торгач: «Башым җилкәмдә микән?» — дип капшап карады.

## МӘКАЛЬЛЕ КИҢӘШЛӘР

«Кем чанасына утырсаң, шуның җырын җырларсың» дигәч тә, «барабыз»га утыргач, Печән базары буенча ямщик шикелле җырлап үтмә.

«Ярлының угылы булганчы, байның колы бул» дигәч тә, баеның һәр төчкерегенә «ярхәмекә Алла» дип торма вә һәр йөткерүенә авызына кәләпүшеңне куйма.

«Үзеңнән югарыга карап фикер ит» дигәч тә, Казанның дүрт катлы йортлары түбәсенә, башыңнан бүрегең төшкәнче, авызыңны ачып карап торма (авылдан яңа килгән агай булсаң да).

---

*Мөтәгалликат* — аңа бәйләнешле нәрсәләр.
*Сүз истигъмаль итү* — урынсыз файдалану.
*Хөсне зан* — яхшы караш.
*Мәгаттәәссеф* — кызганычка каршы.
*«Ярхәмекә Алла»* — «Алланың рәхмәте булсын».

«Тамчы-тамчы тамганнан күл булыр» дигәч тә, баеңның кассасын ваклап чиертмә: күл дә булмас, ни дә булмас, тотылырсың — шул булыр.

## ЯҢЛЫШ УЙЛАНМАСЫН

Мәгълүмдер ки, 37 нче номер «Ялт-йолт»тагы «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» сәрләүхәле шигырь мәзкүр журналга басылудан мөкаддәм «Йолдыз» гәзитәсендә дәреҗ ителгән иде.

Шул вакыт «Йолдыз» идарәсе шигырьдәге «әүлияләр» дигән сүзгә махсус галәмәт куеп, гәзитәнең итәгенә: «Дустлар» мәгънәсендә аңларга тиеш», — дигән бер шәрех төшерде. Шигыремнең кичекмирәк басылуы матлуб булганга, «шәрех»не гәзитә басылыр чакта күргән булсам да, идарәчә «әһәмиятле» шәрехне төшертә алмаячагымны белеп, шул көе табгы иттердем.

Менә шул ук шигырьне «Ялт-йолт» журналы да, «Йолдыз»дан кисеп алып, гайнән үзенә күчергән. Күчергән, ләкин баягы кирәкмәгән шәрехне төшереп калдырырга хәтереннән чыккан.

Шунлыктан мин ушбу сәтырлар илән игълан итәргә мәҗбүрмен ки, минем шигыремдәге «әүлияләр» сүзе үзенең чын дөрест мәгънәсе белән, «изгеләр» мәгънәсендә генә аңланырга тиеш.

Теге «шәрех»нең без «Ялт-йолт»ка чит идарәдән җиһаз күчергәндә ияреп килгән үрмәкүч оясы дип кенә каралуын барча укучыларымыздан риҗаэ вә тәмәнни идәрем.

## ХӘЗЕР ҖИЛӘК-ҖИМЕШ ВАКЫТЫ

Карбыз — Пуришкевич[1] вә әтбагының башы. Эче тулы кара орлык.

Кавын — бу җимеш татар голямасының башы. Моның орлыгын ярган кеше сиксән хокыб тәмугда яначак. Һәр хокыб сиксән мең ел бугай.

---

*Сәрләүхәле* — исемле.
*Мәзкүр* — әлеге.
*Мөкаддәм* — элек.
*Дәреҗ ителү* — басылу.
*Матлуб* — тиеш, кирәк.
*Табгы иттерү* — бастыру.
*Гайнән* — үзгәртмичә.
*Сәтыр* — юл (язмада).
*Риҗаэ вә тәмәнни идәрем* — үтенәмен.
*Әтбагъ* — иярченнәр.
*Голяма* — галимнәр (муллалар).

Чөгендер — бу бик иҗтиһад белән эчүчеләрнең борыннары урынына чыга торган җимеш.

Бәрәңге — мужикларның гаять тә сабырлылыгы өчен килеп чыккан сабыр төбе.

Кабакъ — кабактан бер дә кайтмаучыларның башы. Андый пьяницаларга «кабак тастымалы» вә «кабакъбаш» диерләр.

Кәбестә — гомум монафикъ муллалар башы, чөнки ул баш катлау-катлау. Һәр катлавында бер кирегә атлау.

Арыш, богъдай, солы, арпа башлары — чын галимнәр башы. Мәгънә вә авырлык — башларында.

Торма — гомер буе корсак үстергән бай. Төптән юан, баш юк.

Сарымсак — яһүдинең ашказанында үсәр бер җимештер.

Миләш — исереп, дин ачуы чыккан агай-эненең күз алмасы.

Шомырт — татар мөхәррире хыялына матур кыз тасвиры төшкәч, аның күз урынына куя торган җимеше.

Борчак — маклерның авыз капчыгыннан бертуктамый коела торган орлык.

Җир җиләге — мөтәвазигъ кешене, халык яратса да, өстеннән таптап йөрүләренә мисал бер җиләктер.

Кура җиләге — «үз дәрәҗәмне беләм, үземне поставить итәм» дигән мәгърурдыр. Күңелеңне авырттырганына чыдамасаң, аннан хәер күреп булмас.

Суган — исерек байларның «тегенди» җирдән кайтканда алтын сәгатьләре урынына тагып кайта торган җимешләре; энҗеле кәләпүш урынына карбыз кабыгы киеп кайтулары 4 нче ел «Ислах»та[2] язылган иде. Алай иске нәрсәләрне күп актарсаң, Себер китәрсең. Бәлки, Себер дә китмәссең дә, ихтимал, «Сибирия» мөхәррирләренә охшарсың.

Шалкан — кызлар күкрәге. Авыл егетләренең күн бияләй кеби каты кулларына шулай тоела, ди. Йомшаграк куллы кеше помидор диер иде. Ләкин авыл Гайнетдине белән бәхәс итеп буламыни? Ул: «Икмәктер, кояштыр, шулай булмаса, иманым кяфер китсен!» — ди дә авызыңны каплый.

Кызыл вә кара карлыганны, бүтән исем табудан «гаҗиз» булганлыгымнан, ашый торган мәрҗән дип кенә атыйм.

Барлык җиләк-җимешнең хәлен чорт белеп бетерә аның!

Аны мин түгел, башына җилпуч күтәреп: «Малина! Малина! Хорош! Малина! Биктури! Биктури!» — дип кычкыручы мөтәхассыйс Казан татары да белә алмас.

---

*Монафикъ* — икейөзле.
*Мөтәвазигъ* — түбәнчелекле.
*Мөтәхассыйс* — белгеч, специалист.

## ДИНЧЕЛӘР КУАНЫШТЫЛАР

Оренбург муллалары үткән рамазанда, руза тотмаган кешеләрне тотып ябарга ярдәм итешер өчен, палисәдән городовойлар сораганнар.

Палисә отказайт итмәгән. Шулай итеп, Форштадта[1] берничә кешене вә бер-ике мөсафирне, «җинаять» урынында тотып, часка япканнар.

Менә бу инде эш: «Кыйл Ходайга гыйбадәт, югыйсә бирер җантимер кирәгеңне!» Вә «инналлаһә ләйөәййи-де һазәддинә билҗантимер вәлпристеф»*.

Мондый кызыктан соң инде Оренбург урамнарында түбәндәге картиналар да күренергә мөмкин.

Өйлә азаны әйтә. Шул вакыт мөселман кеше сату итә. Җантимер мөселманга килә дә:

— Князь, иди молиться, мулла кричит.

— Ни магу, таргувайт нады.

— Да иди же, гололобый!

— У минә пакупатель уйдут и тәхәрәт тә нит, как магу молиться?

— Я ничего не знаю, раз ты мусульман, должен пять раз молиться**.

Бичара мөселман, артына җантимер типкәне хәлдә, мәчет эчендә югала...

Безгә хәбәр бирелүенә караганда, моннан соң җомгаларда мәчет капкасына ике җантимер куелып, мәчеттән «фарызын гына» укып качуны бетерәчәкләр.

Җантимер, мәчеттән чыгучыны колагыннан тотып:

— Князь, ты суннет тоже читал?

— Да, я фсю читал, даже Каран слушал.

— Так иди домой!***

---

* Алла бу дингә полицейский һәм пристав белән куәт бирер.

** — Князь, намазга бар, мулла кычкыра.

— Бара алмыйм, сату итәсе бар.

— Йә, бар инде, такырбаш!

— Минем алучым китеп бара, тәһарәтем дә юк, ничек намазга барыйм?

— Минем анда эшем юк, син мөселман булгач, биш тапкыр намаз укырга тиешсең.

*** — Князь, син сөннәтне укыдыңмы?

— Әйе, укыдым, укыдым, хәтта Коръән дә тыңладым.

— Алайса бар, өеңә кайт.

*Палисә* — полиция.

*Часка (частька)* — полиция участогына.

*Җантимер* — жандармны Тукай шулай дип атый.

*Фарыз* — мәҗбүри укыла торган дога.

Мондый эшләр, табигый, «Дингә мишәйт»нең[2] алты-җиде еллык кәгазь пычрату тарихында иң парлакъ сәхифәне ишгаль итәргә* тиештер. Ләкин һәр муаффәкыять бер фидасыз булмый. Динчеләр бу эшләре белән исламның кылыч белән таратылмаганлыгын инкяр итәләр. Күз алдымызда күренә ки, ислам көпә-көндез кылыч белән таратыла.

Кайда китте ислам китапларының вә «Дүнә вә Мишәйт»[3]-нең исламның кылычсыз таралуын дәгъваләре!

Ит үзеннән кортлый, ди. Шуның күк, бу кибәк баш динчеләр үзләрен үзләре таптаганын аңламыйлар.

Белмим тагы, әллә зуррак түрәләр янында йөргән хәзрәтләр җантимер кылычын гына кылычсынмый торганнардыр. Ләкин мин бөтен мөтәгассыйб динчеләр белән касәм итеп әйтәмен ки, җантимер кылычы — кылыч. Үткен һәм озын.

Әгәр ышанмасалар, мин шул кылыч белән «Галиәкбәр агай»-ның «дини закуска» итеп сыраханәгә ташыган ат казылыгын кисеп күрсәтә алам. Кисү түгел, майларын агызырмын, мин сиңа әйтим!

Ул да җитмәсә, Вәли хәзрәт! Вәли мулла[4]! Монда кара әле: шул кылыч астына борып-борып төреп, башындагы «гарәп таҗ»ыңны сал. Җә, сал әле, сал. Менәтерә, хәзрәт, билләһи дип әйтәм, мыегың кыргандагы җоннар кеби, чалмаң парә-парә килер!

Бәс, аңлашылды ки, сез «Дүнә вә Мишә»челәр эчеңез, күңелеңез, үзеңез, сүзеңез белән халыкны биздергәч, муен белән бил арасындагы «ислам»ыңызны кылычлар белән саклый башладыңыз, әбәү мәхәббәтсезләр, ырррый! ырррый!

## ХАКСЫЗЛЫКТАН КОТЫЛДЫК

Без Думага депутат сайларга никадәр хаклы булсак та, ул закон йортына клоун һәм дә талантсыз клоун сайларга хаксыз идек. Безнең аз-аз гына сайланмый калган «кияү»емез, гакылында булган үткенлектән туган урынлы замечаниеләре белән, эштән йә эшсезлектән туйган вәкилләрне көлдерүче вә җуатучы Пуришкевичкә аз гына да охшамый бит.

Моның Думага барган көнне беренче сүзеннән үк вә үзенә махсус мәгънәсез караган күзеннән үк, депутат булу түгел, Дума сторожыннан да аңсыз вә шыр тиле бер адәм икәнлеген аңлыйлар. Аңлагач, ни эшлиләр? Ни эшләсеннәр, үткән

* Иң якты битне алып торырга.
*Муаффәкыять* — уңыш.
*Мөтәгассыйб* — тискәре, фанатик.
*Касәм* — антым.

номерымызда ишарә иткәнемезчә, биттабгы, кайсы депутатлар безнең бу болванымыз белән уйнарга, шаярырга башлыйлар, чөнки ул кешене вә аның кешечә кыйланганын вә җүләрлекнең мөҗәссәме булганын күргәндә, кирәк син вәкил бул, кирәк бүтән бул, синдә уйнау, шаяру хисе генә туа ала. Не грешно смеяться над смешным*.

Менә депутатлар арасына шул җүләремез утырган. Менә Марков Икенче килеп, аның корсагына таяк төртә. Җүләр таякка ырылдап маташкан гафләттән истифадә итеп, Замысловский җүләр башына, кәгазь капчыктан җыртып, клоун бүрке киертә. Пуришкевич әкрен генә җүләрнең сюртук** артына җептән койрык тагып маташа.

Йә, Казан мөселманнары эш урыны булган Думада шундый картина ачылырга сәбәп булырга хаклымы иделәр? Тыштан карaганда, мәзкүр депутатлар теге җүләрдән көлгән кеби күренсәләр дә, бу бит бөтен татар халкының тәмизен вә аңын үчекләү! Бер шәһәр, тик бер Казан халкы 20 миллион халыкка оят булачак бу эшне эшләргә хаксыз һәм бик каты хаксыз иделәр.

Бәлки, Казан мөселманнары бу хаксызлыкка ушбу рәвешчә бер пессимистический җавап та бирә алыр иделәр:

— Без инде моннан элекке өч Думаның өчесендә дә гакыллы кешеләр җибәреп карадык. Барыбер безнең файдага әллә ни эш чыкмады. 4 нче Думага исә без һич тә игътибар итмибез, шуңар күрә без анда, өмидсезлегебезнең ачы бер көлкесе булсын дип, җүри җүләрне, җүри болванны сайладык. Үземезчә: 4 нче Дума үз дәрәҗәсен, үз мәгънәсезлеген сизсен, дидек.

Ләкин бу җавап, безнең кеби кечкенә, кара вә мәгърифәтсез милләт тарафыннан Дума кадәр Думага артык ихтирамсызлык булганга, тагы да бер хаксызлык, димез. Күз алдымызда рабочий вә сул партияләрнең дә шушы Думага, тырышыптырышып, үзләре яхшы дип белгән депутатлар сайларга маташулары вә сайланучыларның да, эш эшли алудан бөтенләй үк өмид өзмичә, шул Думага барулары торганда, безнең илтифатсызлыгымызның хаксызлыгы тагын да ачыграк күренәдер.

Тәмам 20 октябрь көне җиткәнче әфкяре гомумияи татария*** шушы хаксызлыкларның булганлыгына вә һичбер ма-

* Көлкедән көлү гөнаһ түгел. (Русчасы рус хәрефләре белән басылган.)
** «Сюртук» сүзе рус хәрефләре белән басылган.
*** Татар халкының гомуми фикере.

*Биттабгы* — табигый.
*Мөҗәссәме* — гәүдәләнеше.
*Гафләт* — гамьсезлек.
*Истифадә иту* — файдалану.
*Тәмиз* — пакьлек, арулык, намуслылык.

нигъсыз вакыйгъ булачагына канәгать итеп вә бөтенләй ышанып торды. Чөнки Сәйдәшев вә Шәехгаттар җыйган мәҗлесләрдә Казан халкының рухы түгел, бәлки нифакъ вә риясы мәзкүр икене сайлаган ук иде. Эш беткән үк иде. Аларның җиңел үтүенә нифакъ гаскәренә главнокомандующие ителергә мөстәхикъ бер-ике мөгътәбәр вә, аннан да бигрәк, монафикъ, димәк, артык булган бер-ике хәзрәт сәбәп булды.

Югыйсә халыкның чын рухы үзенең көчле вә һәр нәрсәне җиңүче вә нинди кара көчне дә инсафка китерүче нәфрәте белән, шул сайланучыларны булмыйча, кемнәрне сасы Болак буена китереп кыскан иде соң? Кисәктән менә сиңа «төрҗәгун»! Шулар вәкил, шулар без яраткан, без ышанган кешеләр!

Юк, моңар чын гакыл һәм рухның тирәндәге бер төше ышанмый иде. Бу һаман әле үзенең чалбар тектерүеннән алып Думага кемне сайлау кеби саф дөнья эшләрен мулла авызына карап көтеп торучы бер кыйсем халык эшенә генә охшый иде.

Ниһаять, 20 октябрь көне җитте. Сайланганнарның «тәкъдиренә» русларның зур катышы булачак булды.

Менә зал буенча кияү белән каената, рус нөфүзлеләренә барып, берсен берсе чагарга вә әллә нинди түбәнлекләр белән яманлашырга вә начар хатыннар кеби кыйланырга тотындылар. Алар татарлар арасында да шул гадәтләрен иҗра кыйлмадылар түгел, кыйлдылар, ләкин бездә бу «гади эш» булгангамы, никтер күзгә чалынмады.

Әмма мәдәният дөньясында безгә нисбәттә «тәҗрибәле картлар» булган руслар аларны хәзер аңладылар. Хәзер иңнәре, буйлары ничә аршын икәнлеген үлчәделәр. Үлчәделәр дә аларга бер шар да салып әрәм итмәделәр. Алар провалились!* Һәм без дә, әлхәмделилла, сөммә әлхәмделилла, югарыда әйткән хаксызлыктан котылдык.

Чынлап та, Галиәсгар Сыртланов, Садретдин Максудов, Кәлимулла Хәсәневләр җәүлан иткән шул Дума мәйданында шундый кешеләр өстерәләчәк булса, безгә ни әйтергә кала!

---

* Провалились (рус хәрефләре белән басылган) — сайландылар.

*Манигъсыз* — токкарсыз.

*Вакыйгъ булу* — эшкә ашу.

*Нифакъ вә рия* — икейөзлелек һәм ялагайлык.

*Мөстәхикъ* — хаклы.

*Кыйсем* — төркем.

*Нөфүзле* — сүзе үтә торган.

*Иҗра кыйлмау* — йөртмәү.

*Әлхәмделилла, сөммә әлхәмделилла* — Аллага шөкер, тагын бер кат Аллага шөкер.

*Җәүлан итү* — йөрү.

Мин үзем Кәмал бәкнең[1] «Кәлабе җәһлә кандый гиздекең назендә сахралар»* бәетен генә әйтер идем.

Асылында шигырь «кәлабе золмә» дип башланса да, безгә «кәлабе җәһлә» диергә тугъры килә. Чөнки «кәлаб»тан бер-бер керән телле кеше бу елгы берничә татар вәкилләрен ирадә итсә, «кәлабе золым» тәгъбире алар хакында дөрест булмый.

Европа парламентларында йозрык вә алтатар белән депутатлар бер-беренә золым итсәләр дә, безнең Думада, әлхәмделилла, андый кызулык булганы юк. Марков Икенче җәнабләре берәүнең борынына сукса да вә ул берәү аның күзенә сугып җавап кайтарса да, бу хәлләр (сөммә әлхәмделилла) Дума эчендә түгел, бәлки әллә кайда, әллә кемдә булган исерек мәҗлестә генә!

Пуришкевич исә, Дуров вә Бим-Бомнар кадәр үк булдыра алмаса да, Думада клоунлык кына итә. Ул һичкемгә золым итми.

Хәтта бер-ике Думадан бирле тамак шеше белән сүздән калган сул депутатларны каһкаһәгә җиткәнче көлдереп, кайчакта шешләрнең тишелүенә вә мәзкүрләрнең сөйләүләренә генә сәбәп була.

Русларда да эш шундый гына булганда, безнең татар депутатларына золым итү кая да, ни кая?

Хәзерге вакыт шигырьдәге мөнәсәбәтләрне тикшерү вә аңа килүе мөхтәмәл бәхәсләргә җавап биреп маташу вакыты булмыйча, дахилдә Думага сайлау, хариҗдә Балкан сугышы кеби әһәмиятле вакыт булганга, янәдән мәкаләгә күчәргә тиешлеге исемә төшеп: «Хаксызлыктан котылдык», — дия тәкрар итәмен, сүзне бетерәм.

## ТЕГЕННӘН-ШУННАН

Петербургта «Синий журнал» дигән, тышлык кәгазе күк төстә булган атналык бер мәҗәллә бар. Әлбәттә, бу төс журналның үзендә булган бер хасиятне-фәләнне күрсәтми; просто күк журнал, күк күгәрчен кеби, атнага бер мәртәбә оядан очып чыга да вәссәлам! Югыйсә сез аны хәзрәтнең яшел чапаны — тәкъвалыкка, яшел әфиюн йоту — тәмәке тартучы түгеллеккә, бәлки

* Син күңел ачып йөргән матур сахралар надан этләргә калды.
*Кәлабе золмә* — явыз этләргә.
*Кәлабе җәһлә* — надан этләргә.
*Ирадә итү* — күздә тоту.
*Каһкаһә* — кычкырып көлү.
*Мөхтәмәл* — ихтимал булган.
*Дахилдә* — ил эчендә.
*Хариҗдә* — ил тышында, читтә.
*Мәҗәллә* — журнал.
*Тәкъвалык* — диндар, шәригать кушканча гына эш итүче булып күренергә тырышу.

аны тартучыларны орышучылыкка дәлаләт иткән кеби, күк төсен дә шулай дип уйламагыз. Милли галәмәт дип тә саташмагыз.

Бу журнал, кич караватта ятып укыганда, йокыга китәр өчен валериановый тамчылардан да файдалырак, чөнки ул дөньяның гаҗаиб вә гараибатын яза. Дөньяның әллә кай җирләренә мөгез чыгара. Җирне күтәргән үгез мөгезе тишелеп чыккан диерсез! Журналның мөндәриҗатының мисалларын күрмәк теләсәңез, «Йолдыз»-ның фәнни кәшфиятен укыңыз. Җир йотсын — шундый, күк капсын — шундый! Пычагыма кирәк, ант итәм тагы! Эш вә асыл мәсьәлә журналның төсендә вә мәсләгендә түгел, бәлки аның ушбу арада гына «Балканда славян шатлыгы» наме белән бал* ясавында.

Анда гына да түгел, «Биржевыя ведомости» әйтмешли, Балканнарда кан коелганда, «Балканда славян шатлыгы» дигән бал* ясап, аңар халык килмичә, килгәннәре акчаларын кире алып, балның* провалиться итүендә!..

Дөрест, Төркия — хәстә кеше, ул «авырый». Ләкин бит Гаяз әфәнденең соңгы «Мулла бабай» романындагы[1] Гали бай хатыны Зөһрә абыстай да авырый, Гали бай анасы үлсә, мәдрәсә шәкертләренә симез «хосул» төшә. Бичара шәкертләр Зөһрә абыстайны өннәрендә дә, төшләрендә дә үлгән итеп күрәләр. Үз-үзләрен инде хәмелгә барганнар, кесәләрендә акча шылтырый кеби хис итәләр, фәкать кесәгә кулны тыгып кына «күмәчкә ике тиен юк» дигән хакыйкатьне икърар итәргә мәҗбүр булалар. «Көндә өмид, көндә куаныч, ләкин Зөһрә абыстай үлми дә үлми иде» (бигыйбарәтиһи бугай).

Вакытсыз азан әйткән мәзиннәр яисә вакытсыз чиркәү каккан звонарьлар** була инде. Ул гына түгел, котырган әтәчләр дә булгалап, алар йокысының дәкыйкасе алтын булган мужик халкын алдап уяталар.

Менә бездә бер җырчы[2] мөхәррәмел хәрам эчендә мәсҗедләрдә мәүлид шәриф укып җөри. Бу кем инде? Югарыдагы мәзинме? Звонарьмы, йә булмаса котырган әтәчме?

Юк, берсе дә түгел, просто Томскидә ул кешене губернатор җәнабләре публично кычкыртмаган. Кычкырсаң, үз бүлмәңдә генә кычкыр, дигән. Беләсез инде, ул буш, акчасыз кычкыра торган кеше түгел. Безнең көтүдән кайткан үгезләр, Бохараның ишәкләре просто бесплатно кычкырсалар да, бу әфәнде һәммәсен акчага исәпләргә өйрәнгән.

---

* «Бал» сүзе рус хәрефләре белән басылган.

** «Звонарь» сүзе рус хәрефләре белән басылган.

*Дәлаләт иту* — күрсәтү, белдереп тору.

*Гаҗаиб вә гараибат* — гаҗәп хәлләр һәм кызыклар.

*Кәшфият* — уйлап табулар, ачышлар.

*Дәкыйка* — минут.

Все-таки акча тотылган: юл расходы. Инде ничек икенче шәһәргә барып кычкырасы?

Болай итәсе: покрауда елка утырткан тиле кеби, рәсүлулланы мөхәррәмел хәрамда туган ясыйсы.

Бу нәрсәгә?

Мәгълүм:

Сәдәхә, син сәдәхә,
Әмма соң син сәдәхә,
Ай лүли сәдәхә!
Сәдәхә, дәхә, дәхә!

«Синий журнал» да, безнең җырчы да бу эшләрен мәгълүм бер максуд белән эшләгән булсалар да, боларның кыйсьмәтләре, табигый, ике төрле.

Чөнки руслар фәһемле вә аңлы халык булганга, әтәчнең нинди табигатьтәлеген белеп, йокыдан тормыйлар. Икенчеләре без булганга, «кикриге мәрҗән төсле», «койрыгы нәкъ урак» булганлыгын игътибарга алып, вакытсыз эшләр дә кыйлабыз.

Бу тугърыда җитәр. Әмма матбугатны тәгъкыйб итеп барсаң, аннан да күңелле нәрсәләргә очрыйсың.

Мәсәлән, бу көннәрдә генә, яһүдиләрнең черкигә чыпчык кеби рәхимсез дошманы иеромонах Илиодорның, православиедан яһүдилеккә чыгып, үзенең моңарчы булган тәгъкыйбаты өчен мәзкүр милләттән гафу үтенгәнлеге гәзитә хәбәрләрендә күренде.

Әгәр бездә бу көннәрдә генә Аксак Низами диган иң иске, иң кадим бер каһармане дин «Йолдыз» гәзитәсе аркылы җәдитлеккә чыгып, моңарчы тел тиергән вә чәйнәгәне өчен әшрафемездән гафу үтенмәсә, бу хәбәрнең безнең өчен әһәмияте дә булмас иде. Аксак Низами да мәдрәсәдә үскән бәрәңге, Илиодор да духовный семинария җимеше булганга, икесе дә үзләренең бүтән кешеләрдән генә түгел, бөтен голяма вә фәйләсуфлардан артык икәнлекләрен дәгъва кыйлулары бертөсле булганга, болар бер-беренә ифрат дәрәҗәдә охшашлылар. Икесенең дә үз «акыллы баш»лары белән тапкан мәзһәбләре вә ышанган диннәре өчен һәрвакыт фида булырга торган кеби булуларын әйтәсе дә юк инде.

Соң, болар дин өчен шаулаганнармы? Дин өчен дип акыллыбашланганнармы?

Әлбәттә, моның, мондый хәрәкәтләрнең дин өчен булма-

---

*Рәсүлулла* — Алла вәкиле, Мөхәммәт пәйгамбәр.
*Кыйсьмәт* — өлеш, язмыш.
*Фәһемле* — аңлы, зиһенле.
*Тәгъкыйб итү* — күзәтү.
*Тәгъкыйбат* — эзәрлекләүләр.
*Әшраф* — зур кешеләр.

ганлыгы, Илиодорның санынnan аерылачагын сизеп, дингә түгел, сенатка ачу иткәнлегеннән, беткә ачу итеп тунны утка ягуыннан күренә. Монда фәкать шәхсият вә дөньяви гараз*.

Аксак Низами да үзенең җәдитлеккә чыгуы дөньясы, мәгыйшәте бозылганлыктан икәнлеген икърар итә: ул «Йолдыз»да тәкърибән болай ди:

«Голямага тел тидерү сәбәпле, дөньям янды, сакалым көйде. Әгәр кадимлек мәсләге хак булса, дөньяма зарар килмәс иде. Инде Муса Бигиевләрдән-фәләннәрдән гафу үтенәм... иләх». Шуның өчен мондый көпә-көндезге алдануларга безнең җаныбыз ачыганга игълам итәбез ки, кадерле халкымыз бу кеби пычрак бер гасырда, төрле базарларда вә хәрчәүнәләрдә мисез башыннан пәйгамбәрлек сатучы төрле кешеләргә вә, Илиодор кеби, халыкның иске хорафаттан, тыңлавымы, ышануымы күңелле булган өчен, аерыласы килмәгән иң надан кыйсьмен иярткән Илиодор кебиләргә ышанмасыннар иде. Нәҗат, җан рәхәте вә тугъры юлны андый кешеләрдән түгел, анчак гыйлем вә мәгърифәттән генә эзләсеннәр иде.

Руслар руслар инде. Без, «хатәмен-нәбиин» аятенә иман иткән мөселманнар, һичбер вакыт Печән базарыннан пәйгамбәр вә мәзһәб башлыгы эзләмәскә тиешлемез.

«Йолдыз» мөхәррире мәдрәсәдә «гыйлем» кеше булып чыгып, соңыннан русчаны да адреслык өйрәнеп, шөһрәт сөю сәүкыннән башка бер истихкакъ белән булмаса да, «Дөнья мәгълүматы», «Русларны русча өйрәтә торган китап» һәм камил истихкакъ белән язылган «Тәһарәте ислам», «Истиншакы ислам», «Госелел мәрьәт» китапларын чыгарып, әлбәттә, татар арасында сәватлы адәмнәрдән булды. Үгез ишәкне: «Синең мөгезең юк», ишәк үгезне: «Синең колагың кечкенә», — дип, үзендә бар нәрсәләр белән мактанышкан кеби, ул «Вакыт» мөхәррирләреннән берсенә: «Синең сәватың юк», — ди. Әлбәттә, «көлле хизбин бима ләдәйһим фәрихун»** инде.

Ләкин «нәшир вә мөхәррире Әхмәтһади Низам угылы Максудов» дип гәзитә имза иткән шул кешегә бирәү:

---

* Шәхси интереслар һәм дөнья максатлары.

** Һәр төркем үзендә булган белән шатлана.

*Сан («сан» сүзе рус хәрефләре белән басылган)* — дәрәҗә.

*Тәкърибән* — якынча.

*Иләх* — һ.б.

*Игълам иту* — белдерү.

*Нәҗат* — котылу.

*Хатәмен-нәбиин* — иң соңгы пәйгамбәр (Мөхәммәт).

*Сәукыннән* — омтылышыннан.

*Истихкакъ* — хакы (хаклылык) булу.

*Сәватлы* — белдекле.

— Син мөхәррир түгел, синең тәхрирең юк, булса да төрле еллар зарфында язылган җитди вә көлке мәкаләләрең барысы да, әрдәнәгә өелгән утын төсле, һәммәсе бер үлчәүдә, бертөсле. Әнә «Вакыт» мөхәррире Фатих әфәнде Төркиядәге вакыйга вә хәбәрләрне, гүя тере җанварлар тоткан кеби, җанлы итеп Кара диңгез аркылы йөздереп җибәргән диерлек фельетоннар яза. Аларны «Вакыт» идарәсендә пешереп, халык өстәленә җан азыгы иттереп куялар. Төркия ихтилалы елны Йосыф Акчурин да үзенең «Вакыт»ка язган «Истанбул мәктүбләре» белән шундый матур эш эшләде. Аннан соң «Вакыт»ның баш мәкаләләрендә милләтне иң йөдәткән, иң аптыраткан мәсьәләләрдә тиешле юллар күрсәтелә. Син шул вакытта бер фәс белән бәргәндә ничә болгар егылачагын «фараз» итәсең? — дисә, мөхәррир әфәнде ни дип җавап бирер иде икән?

Ул сүзгә оста кеше, фараз итәр дә җавап бирер; бәлки, артыграк ышандырыр өчен, өч бармагын бергә оештырып (төрекләр мисаллы) күзгә төртеп тә сөйләр, ләкин мин мөхәррир әфәндегә «фәла тәгыррәнәкем әлхәятет дөнья»* аятен укырмын да, берзаман миссионерларның кирәкләрен биреп, автономия язып, «Өлфәт»кә 4 мең мөштәри җыйган Рәшит казыйга хәзерге халык нәзары ничек булганлыгын фараз итеп карарга киңәш бирермен.

«Сибирия» гәзитәсе әллә нинди сакаллы хатыннар язган «Хатын-кыз дөньясы» ачкан. Ләкин, ышанучылар булса, гүзәл ният. Бервакыт Сәгыйть әфәнде Рәмиев, «Катын-кыз» имзасы белән[3] язылган бер шигырьнең ушбу түбәндәге сәтырларын укып, тәмам мәмнүният вә изтирабка килеп, янында утырган шагыйрьдән[4] шөбһәләнеп: «Әй шәйтан, син язгансың ла моны!» — дип, гәзитәне атып бәрүе хәтергә килә!

**СӘТЫРЛАР**

Алар сәмин булса, бездә сәминә бар,
Алар әмин булса, бездә әминә бар,
Мөселманда булмаса да булмас, әмма
Башкаларда «бог»ка каршы «богиня» бар.

---

* Сезне дөнья тормышы алдамасын.
*Тәхрир* — язучылык көче.
*Зарфында* — эчендә.
*Ихтилал* — революция.
*Мисаллы* — шикелле.
*Мөштәри* — (газетаны) яздырып алучы.
*Изтираб* — дулкынлану.
*Сәмин* — кыйммәтле, бәяле (ир кеше).
*Сәминә* — кыйммәтле, бәяле (хатын-кыз).
*Әмин* — ышанычлы, куркусыз (ир кеше).
*Әминә* — ышанычлы, куркусыз (хатын-кыз).

Аннан соң мәзкүр гәзитә әллә нинди 1905 елдан калма фельетоннар дәреҗ итә дә, фельетон башына «Сибирия»нең фельетоны» дип куя. Шулай итмәсә, ул фельетонны «Вакыт»-ныкы дип белерләр дип курка микәнни?

Монда минем яшьлектә булган бер вакыйгам белән Хуҗа Насретдиннән бер хикәя исемә төшә.

Әүвәлгесе: шәкертләрне көлдерер өчен кулыма: «Бу кулның малики вә сахибе фәлән-фәлән угылыдыр», — дип яза торган идем.

Икенче: бер төнне Хуҗа Насретдиннең йортына караклар кереп, бернәрсә дә таба алмагач, уяу яткан Хуҗа Насретдин каракларга:

— Анда нәрсә эзлисез? Төнлә түгел, көндез дә мин анда бернәрсә таба алмыйм, — дигән.

Шуның кеби, һәр сәхифәсенең читенә дүрт яктан линейка куелган «Фазаилеш-шөһүр» вә «Рәүнәкыль ислам»нарда китап эчендәге «мөбарәк» мәгънәләр качмасын өчен булырга кирәк дип зан ителә.

*

Бер иптәшем кереп, миңа килгән «Дин вә мәгыйшәт»не ала да: «Мин инде бер ай «Дин вә мәгыйшәт» укыганым юкка күрә, инде заман үзгәргәндер, бәлки, динчеләр Муса дәгъваләрен аз булса да ибталь иткәндер дип ышансам, алар һаман «Галиел кари», Тантави, ди, вә «Җамигыр рөмүз» гыйбарәләре күчереп бетерә алмыйлар», — ди.

Мин әйтәм: «Ишәкнең дәлиле җөгән булса, динчеләрнең дәлиле дә әллә кемнәр, әллә нинди мосаннифлар ич», — дим, ул да разый була язып китә.

Ул киткәч, мин ихтыярсыз шушындый фикерләргә киләм:

Әмма бездә «бабай мич башыннан белмичә егылып төшмәгәндер» хөсне занына игътикад көчле соң! Мәсәлән, соңгы төрек сугышын гына алыйк. Төрекләр сугыш башында ук Черногория хөдүдендәге истихкямнәрне ташлап качтылар. Без: «Тө-

---

*Дәреҗ итү* — урнаштыру, бастыру.
*Маликы вә сахибе* — иясе һәм хуҗасы.
*Зан итү* — юрау.
*Ибталь итү* — юкка чыгару.
*Мосанниф* — китап төзүче.
*Хөсне зан* — яхшы караш.
*Игътикад* — ышану.
*Хөдүд* — чикләр.
*Истихкям* — крепость.

рекләр — искедән сугышчы халык; белмичә эшләмәгәннәрдер», — дидек. Кырыккәлисә китте, шулай уйладык. Мостафапашаны алдылар, Сәланик, Үскүб китте, без һаман шул фикердә калдык: «Алты йөз елдан бирле хөкүмәт тоткан төрекләр белмичә эшләмәсләр», — дидек. Инде актык истихкям Чаталҗага болгар гаскәре иреште. Инде без һаман өмидсезләнмимез: «Төрекләр, юри чигенгән булып, болгарларны ватаннарыннан ераклаштырып, Чаталҗа мәйданына китереп кыстылар», — дибез. Бәгъзе «политиканнарыбыз» моны Наполеонга каршы Кутузов планы кеби итеп тә тасвир итәләр.

Дин мәсьәләсендә дә шулай ук. Безнең динчеләрнең бөтен дәлил вә сәнәтләре: «Фәлән мөфәссир белми әйтмәгәндер, фәлән мөхәтдис дөрес ривайәт иткәндер, мәсәлән, «Сахихел бохари» сахибе һәр хәдисне язганда, бер мәртәбә госел коенган, әлбәттә, ул хата язмагандыр», — дип кораллаңалар.

Шулай инде: шулкадәр аш ашаган, яшь яшәгән бабай, җитмәсә, кызының угылларын тере чакта күреп, алдына утыртып сөйгән бабай, һәм сакалы тегермәндә генә агармаган, бәлки үлемнән хәбәр бирер өчен, тиз үләчәген вәгъдә итәргә агарган сакаллы бабай, мич башында йоклаганда, яңлыш егылып төшсен дә, син аннан авызың җырып көлеп утыр.

— Угылым Сәлимҗан, кызым Миңсылу, сезгә сүзем шул: «Курыкма, бабаңыз мич башыннан белмичә егылып төшмәгәндер!..»

*

Биш-алты елдан бирле кыйлынмакта булган дога — пайтәхеттә мөселман мәнафигын күзәткән русча гәзитә чыгару нияте халисанәсе, ахыры карар табып, үзенә юл ачты. Гәзитәләрнең язуына караганда, Әсәдуллаев белән Мохтаров дигән байлар мәзкүр гәзитәгә 16 шар мең сум вәгъдә иткәннәр.

Сигез кат күк капусы, «Кадер кичәсе» булмаганда да, шундый изге теләкләргә каршы һәрдаим ачылып торуын җәнабе Ходадан риҗа итәбез.

*Сәнәт* — таяныч.
*Мөфәссир* — Коръәнгә аңлатмалар язучы.
*Мөхәтдис* — хәдис (пәйгамбәр сүзе) китаплары төзүче.
*Сахибе* — авторы.
*Мәнафигын* — файдасын, интересларын.
*Нияте халисанәсе* — ихласлы нияте, яхшы нияте.

# 1913

## 1912 ЕЛНЫҢ ОНЫТЫЛГАННАН КАЛГАН ГЫНА ХИСАБЫ

1912 елда Италия белән Төркия вә дүрт берләшкән дәүләт белән Төркия һәм «Вакыт» белән «Йолдыз» мөхарәбәләре[1] вакыйгъ булды.

1912 елда Ишми ишан[2]: «Мөселманнар» «һиляле әхмәр»гә иганә җыялар», — дигән яңа форма донос ихтирагъ боерды.

1912 елда Аксак Низами — җәдитлек вә иеромонах Илиодор яһүдлек кабул иттеләр.

1912 елда караңгы Казан өстенә «Кояш» чыгып[3], «Йолдыз»ны сүндерде.

1912 елда бәлеш, пылау исе килә торган «Шура» белән хәез-нифас аңкытучы «Дин вә мәгыйшәт»кә каршы укыганда хуш ис иснәү хисе бирә торган «Аң» чыкты[4].

1912 елда Сәйдәшев белән Иманай чүт-чүт кенә Думага китми калдылар, чорт возьми!

1912 елда Гаяз әфәнде татарларга бераз «чаршау арты» тормышын да язып күрсәтте[5].

1912 елда Садри Максудов профессиясеннән аерылды[6].

1912 елда татарда әдәбиятка мәхәббәт артып, Печән базары зобанилары татар мөхәррирләренең битен тимер кендекләр белән сыйпый башладылар[7].

1912 елда күп интендантлар каторгага хөкем ителеп, бер «шәп мөхәррир» булырга нияте халисә белән керешкән кеше плагиатта тотылды[8].

1912 елда һәрвакыт үз-үзен шәп ди торган Габди[9] Лермонтовның «Перчатка» вә Надсонның «Слово» дигән шигырьләрен бер татар шагыйренә иснад итеп, «Җанлы курчаклар»ны да чын татар әсәре ясап һәм дә үзе тугърысында «ля тәнзыру ила мән кала вәнзыру ила ма кала»* мәкален китереп, ягъни мин үзем начар булсам да, сүзем шәп дип сөйләп, полный глупость вә буш-башлыгын исбат боердылар. Инде 1913 елда тәнкыйть язам дип көрәк күтәрергә оялачагы кителә.

---

* Кем әйткәнгә карама, нәрсә әйткәненә кара.

*Мөхарәбә* — сугыш.

*Ихтирагъ боеру* — уйлап чыгару.

*Хәез-нифас* — күрем күрү, бала тудыру һ.б.

*Нияте халисә* — чын теләк.

*Иснад иту* — нисбәт бирү.

1912 елда Шәһидуллин печән үлчәве каршыннан тотынып, Печән базарыннан үтеп, гакыйбәт, Проломныйга җитеп, талчукка кадәр булган бөтен Казан сатучы вә талчукчыларының тәрҗемәи халь вә монакыйбен* бастырды[10]. Шул каһарманнарына тагын бер зиннәт уларак, Зариф[11] дигән кабахәт сурәтне шагыйрь вә мөхәррир дип гыйлавә итте.

Инде 1913 елгы «Яман вә тозсыз» календарена[12] баскычтан ботына су тамызмыйча самавыр алып менә ала торган самавырчы малайлар, базарга җибәрсәң, бер читеге өстеннән штан балагы салынмый торган асраулар, никадәр җегет белән кызларны «Йосыф-Зөләйха» мисалында кавыштырып, висале җанан иттергән изге карчыклар вә Шәһидуллин хәзрәтләренең үзе бөтен тәрҗемәи халь вә рәсемнәре белән дәреҗ ителәчәк, имеш.

1912 елда, Ватан бәйрәме[13] мөнәсәбәте белән татарларны яһүдиләрдән кала икенче дәрәҗә рус дошманы санап, рус халкын котыртып яткан «Телеграф» гәзитәсе шул ук халыкның патриотлыгын вә ватанпәрвәрлеген игътираф итәргә мәҗбүр булды.

1912 елда гакылы тагы да күбәеп, артып, ташып киткәнлектән, Муллин Борһан абзыйның бүреге тагы бер подаука кадәр генә зурайды.

1912 елда 12 ай булды. Гадәт буенча, агай-эне арасында күп кеше шартлап, күп кеше бай булды.

1912 елда «Болгар», «Сарай», «Амур» поварлары арасында пәрәмәч пешерүдә узыш башланды. Бу өч номер кешеләре, күп пәрәмәчләр арасыннан берничә пәрәмәч сайлап, Парижда вә Лондонда булмаячак выставкаларга җибәрәчәкләр. Әгәр алтын, көмеш, чуен медаль бирелә калса, пәрәмәччеләр Габделкадир Сәгъдиев, Мөхәммәтҗан Галиев вывескалары кеби, медальле вә пәрәмәч сурәте төшерелгән зур вывескалар ясатачаклар, имеш.

1912 елда агай-эненең эчү эшендә руслардан артык тәрәккый икәнлеген сизгәнгә, Колесников Проломный кадәр Проломныйдан, олугъ башын кече итеп, Печән базарына күчте.

1912 елда «Шәрекъ клубы»ның лото бүлмәсе дигән чуваш мунчасында төтенгә коптить ителүче җүләр балыкларның саны бик күп артып, телеграм чыбыгына элеп киптерәсе генә калды.

1912 елда «Ялт-йолт» журналы, ике ел бертоташтан көлүен рәсми сурәттә тәмам итеп, 3 нче ел хахылдарга башлады.

---

* Биографияләрен һәм күркәм эшләрен.
*Гакыйбәт* — ахырда.
*Гыйлавә итү* — өстәү.
*Висале җанан* — ике гашыйкның бергә кушылуы (өйләнү).
*Дәреҗ ителү* — кертелү, басылу.
*Игътираф итү* — тану.
*Шартлау* — банкротка чыгу мәгънәсендә.

## ЮБИЛЕЙ МӨНӘСӘБӘТЕ БЕЛӘН

Кичә минем өчен төн үткәрү әллә ничек, милләтемезнең җансыз тормышы кеби, күңелсез вә эчпошыргыч булды. Исемә төште ки, шундый чакта бераз көйләсәм, шыңгырдасам, күңелем ачыла торган иде.

Бәс, мин, яңа теле чыга торган баланың аңлашылмас такмагы кеби, вәзенсез-нисез бер бәет такмакларга керештем. Бәет кечкенә чакта укыган бер кадим китабыннан иде бугай. Бәетнең мәфһүмендә дөньяда тигезлек юклыгы вә кешеләрнең мөхтәлиф хәлләрдә булуы сөйләнгән. Фәкать сәтырлар тәртибе һәм вәзен тугърылыгы минем хәтердән чыккан. Шунлыктан телемә килгәнчә генә җырладым.

Бу дөнья һич тигез түгел,
Адәмнәр дә игез булмый;
Ходай шулай яраткач шул,
Берәү башы сигез түгел.
Кеми галим, кеми җаһил,
Кеми надан, кеми «гыйлем»;
Күрше килене чибәр хатын,
Күрексез лә безнең килен.
Кеми дәүләт ияседер,
Яшел хөллә кияседер;
Әнә ул ат көтүләре —
Фәлән байның биясе бит.
Кеми динсез, кеми динле,
Кеми мәсҗед сарый килми;
Кеми салих, кеми фасикъ,
Кеми приют, кеми кызлар гимназиясе сала —
Ходай тигез яратмаган!

(Чү, теге якта тыңлап яткан әби, шигыремнән әсәрләнеп, үкереп җылый...)

Бу минем төнлә эч пошу саташуы белән сөйләнгән шигырьләремнән көлмәсләр дип беләм, чөнки көтепханәләр шүрлегендә моннан да вәзенсез вә тозсыз шигырьләрне алып, минеке белән чагыштырырлар, бәлки. Шул вакыт, әлбәттә, минем бу бәетләрнең кадере беленер.

---

*Вәзен* — шигырь үлчәме.
*Мәфһүм* — мәгънә, эчтәлек.
*Мөхтәлиф* — төрле-төрле.
*Сәтыр* — юл (шигырьдә).
*Җаһил* — надан.
*«Гыйлем»* — гыйлемле, галим кеше; ирония белән әйтелә.
*Хөллә* — кыйммәтле матур кием.
*Сарый* — якта.
*Салих* — турылыклы, изге.
*Фасикъ* — бозык, явыз.

Шулай инде, дөньяның, мәсәлән, кошларыннан вә хәшәрәтеннән генә дә акыллы кешегә гыйбрәт алырга мөмкин. Аларда да тигезлек юк. Мәсәлән: черки дә оча, чыпчык та оча. (Күгәрчен дә оча, чәүкә дә оча. Карга да оча, козгын да оча.) Шулар белән бергә, бөтен кошлар ханы булган каракош — орел да оча. Ләкин һәрберсе үз канаты куәтенчә.

Инсаннарның дөньяда торган чактагы таләпләре дә, күңелләрендәге теләкләре дә шул кошларның очышына охшыйдыр.

Мәсәлән, Наполеон таләбе бар. Әнвәр бәк[1] таләбе бар. Боларның таләбе мәгълүм: бөтен дөньяны үзләренә мөсәххәр итү. Гади генерал вә забитлар таләбе бар; боларның таләбе дә яшерен түгел: үзләренә атакланган көллиятле мәгашне* кулдан җибәрмәү илә бәрабәр, хәрби шаннарын саклау һәм ватан угърында күреләчәк читенлекне ничек булса да өстән төшерү, кирәк булса, утка да керү.

Бер миллионлы байның таләбе — акчасын ике миллионга җиткерү (йөз меңленеке ике-өч йөз меңгә мендерү). Инабәт белән эш итүченең таләбе ничек тә абруйдан төшмәү, ригайә күрү.

Приказчикның — байга ярау, авыл мужигының — җәй көне эшләгәч, кыш көне тук булып тору.

Түбән сыйныф эшченеке — бүген тук йоклап, иртәгә саулык-исәнлектән эшкә тору.

Каты җилләр исеп киткәндә, төрле зурлыктагы кошлар кунган төшләреннән очышып чыккан кеби вә һәрбере үзләренең очудагы икътидарларын күрсәткән төсле, милләтләр дә бертөрле гомуми эш чыгып, тәрәккъый җилләре иссә, үзләренең таралышкан урыннарыннан чыгып, бер җиргә җыелалар, теге гомуми эш хакында милләтнең һәр фәрде үз фикерен сөйли. Теге кошларның очышы кеби, үзенең аңы, икътидары вә голүе табигате** ни дәрәҗәдә икәнен изһар кыйла. Шуннан аерым фәрдләр танылa вә бәһаләре куела, таләпләре аңлашыла.

Менә әле Казан мөселманнары, Романовлар юбилее кеби, инде тагы бер тәкрар ителмәс кеби олугъ тарихи вә ватани

---

* Билгеләнгән зур хезмәт хакын.

** Көче-сәләте һәм табигатенең бөеклеге.

*Мөсәххәр итү* — буйсындыру.

*Забит* — офицер.

*Угърында* — юлында, хакында.

*Инабәт* — ышаныч.

*Ригайә* — хөрмәт-ихтирам.

*Икътидар* — көч, сәләт.

*Фәрде* — аерым кешесе.

*Изһар кыйлу* — күрсәтү.

вакыйгадан истифадә итеп, падишаһ хәзрәтләреннән ни-нәрсә истирхам итәргә һәм, олугъ нәселнең исемен тәэбид итү белән бергә, милләткә дә файдасы тиярлек нинди мөәссәсә торгызуны сорау тугърысында сүз кузгаттылар.

Сүз кузгалып кына калмады, зур мәҗлесләр булды. Бу мәсьәләне мөзакәрә өчен бөтен шәһәр мөгътәбәраны җыелды. Хатиблар мөнбәргә чыкты, һәркем дәрәҗәи фикриясен күрсәтте. Әлхасыйль, монда черки дә очты, чебен дә, чыпчык та, «каргалар» да вә, ниһаять, орел да очты. Кемнең таләбе нәрсә вә голүе табигате ни дәрәҗә икәнлеген белдек.

Шулай белдек ки, мондагы бер сыйныф халык шушы вакыйгада, шушы, моннан соң колагымызны күрмәгән кеби күрмәячәгемез, 300 еллык падишаһ нәселе юбилее вакыйгасында приют сорамакчы булганнар иде. Җамали агайның Тегәрҗеп урамына бакалея кибете ачарга мәхәлли мәэмурлардан рөхсәт алуы кеби, һәрвакыт мәйданга килә ала торган приютны сорарга уйлаганнар иде.

Менә бу хәл инде черки очуы була. Бу хәл инде узган юбилейнең кыйммәтен корым тазартучының бриллиант тәкъдир итүе кеби аңлау була иде. Бу хәл инде милләтнең чын ихтыяҗына вакыйф булмау, бөтен авыл янганда, белмәмешкә салынып, чабата киндерәсе үрү була иде... Киребеткәнлек була, чебен очуы була иде.

Таләпсезлек вә түбән табигатьлелек була иде. Бәгъзеләре: «Яшьләргә барыбер гимназияне бирмәсләр!» — дигән булалар иде.

Ләкин яшьләр бу тарихи вакыйганың чын кадерен аңлау белән, милләтнең дә ихтыяҗын сизү белән, аларга Шекспирнең зур каһарманнарыннан берсе булган Гамлетның «Быть или не быть!» дигән сүзе белән генә җавапланганнар иде.

Күк капусы ачылганын күргән бер башкорт, вакыттан истифадә кыйлып, дога кыйлган:

---

*Истифадә итү* — файдалану.
*Истирхам итү* — үтенеп сорау.
*Тәэбид итү* — мәңгеләштерү.
*Мөәссәсә* — учреждение.
*Мөзакәрә* — киңәшү.
*Мөгътәбәран* — игътибарлы, күренекле кешеләр.
*Хатиблар мөнбәргә* — ораторлар трибунага, кафедрага.
*Дәрәҗәи фикрия* — фикер дәрәҗәсе.
*Әлхасыйль* — кыскасы.
*Мәхәлли мәэмур* — җирле власть ияләре.
*Вакыйф булмау* — төшенмәү.
*Быть или не быть!* — Яшәргәме, үләргәме!

— Йа Рабби! Иртәгә бер телем ак күмәч белән май ашасам иде!

Әнә ул приютчыларның да таләбе шул башкортныкыннан югары түгел инде.

Романов юбилее мөнәсәбәте белән, падишаһ хәзрәтләренә депутация барган, нәрсә истирхам итәләр: «Безнең Печән базарында хәерче кызлары күбәйде, шуларны бер йортка җыеп асрыйкмы? Аның янына бер мәдрәсә дә салып куябыз».

Әмма яшьләр, күк капусы ачылганда, зуррак дога кыйлмакчы булганнар иде. Кабул булмаса булмас.

Янә тәкрар итәмез: «Быть или не быть!»

## ИКЕ ИХТАР

1) Мөгътәбәр табибләрнең катгый киңәш вә карарларына буйсынып, 26 февральдә Казанның Клячкин шифаханәсенә кереп яттым. Шуңар күрә үзем тәэсис итешкәннән бирле мәхәббәт белән эшләп килдегем «Ялт-йолт» журналының секретарьлеген башка кешеләргә тәслим иттем. Шуңар күрә журналда моннан соң басылган һәммә мәзмуннар өчен үземне мәсьүл күрмәячәкмен.

2) Әле генә үткән 52 нче номердагы баш мәкалә[1] гәрчә минем мәкаләм булса да, хәзер мин андагы мәгънәләрдән шактый читтә торам. Чөнки ул мәкалә — гимназия вә приют мәсьәләсенең беренче генә шаулашы вакытында вә әллә кайчан язылып ташланган язудыр. Ул вакыттан хәзерге көнебезгәчә күп сулар акканга вә һәр ике мөәссәсә кыйсьмән икенче төсләр алганга, табигый, мәкаләи гаҗиземнең хакыйкате хазирә белән оешмаганлыгын сизәм.

Моннан ике ай элек миңа гүя бөтен халык бердән «намаз!» дип кычкырган, мин исә сикереп торганмын да, ястүме, ахшаммы — тикшермичә, бернәрсә укыганмын. Һәр ни исә ниятем гүзәл бит. Шунлыктан, уйлый алам ки, кариэләремез ул мәкалә өчен мөахәзәдә булынмаслар.

---

*Ихтар* — искәртү.
*Тәэсис итешү* — нигезләшү, оештырышу.
*Тәслим итү* — тапшыру.
*Мәзмун* — кертелгән материал, эчтәлек.
*Мөәссәсә* — учреждение.
*Кыйсьмән* — өлешчә.
*Мәкаләи гаҗизә* — «тыйнак мәкалә» мәгънәсендә.
*Хакыйкате хазирә* — хәзерге чынбарлык.
*Кариэ* — укучы.
*Мөахәзәдә булынмаслар* — гаепле итеп санамаслар.

# МАТБУГАТЫМЫЗНЫҢ «ФӘСАХӘТ НӘМҮНӘЛӘРЕ»

*«Мәктәп» журналыннан*[1]:

«Мәктәп исламиятнең иң мөкаддәс хәрәме иде. Шаригы кәбир нәбие көрим галәйһис-салате вәссәлам хәзрәтләри һиҗрәт сәнәсендә Мәдинәи мөнәүвәрәя васыйль улыр-улмас, үзләренә һәм әһле бәетләренә ханәи сәгадәт бина итүдән кабел иң әүвәл бер мәктәп, бер җамигъ бина итмеш иде.

Аллаһең фәрманилә, Җибрил әминнең һәндәсәсилә, хәрам нәбәви улмак сыйфатилә иң әүвәл бина кыйлынмыш у мөкаддәс мәктәп әсхабе кәрамен, нәбие кәримнең үз көчләрилә, үз әлләрилә бина кыйлынмыш иде.

У мөкаддәс мәктәби бина идар икән, нәбие мөхтәрәм сәййиделвөҗүд галәйһис-салате вәссәлам хәзрәтләри гади бер хезмәтче кеби хезмәт итте. У мөкаддәс мәктәбең, у бөек хәрәме нәбәвинең бинасы тәмам улдыгы дәкыйкасендә, шаригы мөхтәрәм галәйһис-салате вәссәлам хәзрәтләри, җәмәгатьлә фарыз намази әдадән кабел, иң әүвәл тәгълим вәзыйфәсилә иштигаль итте. Шаригы хәкимең, нәбие кәримең шу хәрәкәтилә...»

*«Ялт-йолт»:*

— Бакыңыз, кош теленнән кечкенә булган ушбу намәдә бердәнбер пәйгамбәремезнең никадәр вә ничә төрле ләкаб вә титуллары язылган. Әгәр пәйгамбәр белән генә эш бетмичә, мәкаләдә Аллаһы Тәгаләне зикер итү лябеддә булса, мәкалә сахибе, һичшиксез, мең дә бер әсмаи хөснаны санап чыгар иде.

И Ходаем, «гыйлем» кешенең эше! Сезгә «фәсахәт былбылы» дисә, тагы да «вә бәлягать сөнбеле» дип әйтәсе кала. «Алтын бармагым» ди, «көмеш тырнагым» ди, ни булса да килештереп яза. Без булсак: «Гөлҗамал! мин сине яратам», — белән эш бетерер идек.

*«Кояш»тан:*

«Сан-җан-ди — Мидваны «Хәмидия» крейсере утка тоткан- да, «Хәмидия» тупларыннан 119 кеше үлтерелгән һәм яраланган».

*«Ялт-йолт»:*

— Бичара «Хәмидия» туплары әле генә чуеннан итле, кан-

---

*Фәсахәт нәмүнәләре* — матурлык үрнәкләре.
*Намә* — язма.
*Ләкаб* — кушамат.
*Зикер итү* — телгә алу.
*Лябеддә* — кирәкле, ансыз мөмкин булмаган.
*Сахиб* — ия.
*Әсмаи хөсна* — Алла исемнәре.
*Бәлягать* — камиллек, төзеклек.

лы кешегә әйләнү белән, алардан «119 кеше үлтерелгән һәм яраланган». Бу инде — «әдәм булгач кына әрәм булу».

*«Идел»дән:*

### ШИГЫРЬ

***Тазиянә***

Әл чак, и, ... истибдад! Золмеңнән сакыйн,
Бунҗә нахак түкдигең кандай тәгафел өйләмә!
Бең сәмәр бәклә мәкяфәт гамәлдән ит якыйн,
Тәхте гяһ дәүләтең бер көн улыр ашәфтә хун.

*«Мирза ага Галиюф».*

*«Ялт-йолт»:*

«Бу персиян үзенең «сәнә, менә, сән үләсән, мән үләм, нә данишарсән?»ләренә, ягъни үз милли теленә бер кадак кишмиш кадәр генә ригайәсе булса, төрекләрнең шушы чиркәнеч сонгый телләре белән «шигырь» язмас һәм әүзане шигырьдән кишмиш үлчәве кадәр генә хәбәре булса, «якыйн вә ашәфтә хун» сүзләренең вәзендәш түгеллекләрен сизәр иде».

*«Акмелла»дан:*

Моның «фәсахәт»еннән «нәмүнә» алмыйбыз инде. Чөнки бөтен журналын күчерергә кирәк.

Бу исә, дәүләт эчендә дәүләт дигән кеби, хилафе сәясәт бер эш була.

Тик «Акмелла»ның «Чала татар» имзасы белән яза торган тәнкыйтьчесенең театр тугърысындагы мәгълүмат вә тәнкыйтен күрсәтеп китик әле.

*«Чала татар» тәнкыйте:*

«Ни исемле иде әле, оныттым, бер театр китабы бар. Уйнаучыларыннан беренчесе тешсез карт булырга кирәк. Хәзерлә мөселманнардан театрда участвовать итүче карт табу мөмкинме соң? Яшьләрдән, әлбәттә, аның өчен генә теш сындыручылар булмас».

*«Чала татар» үзен юата:*

«Хәер, андый карт мөселманнан табылмаса, сәхнәгә руслардан бер картны алып керәсең. Сүзен үзең сөйлисең дә, теш тугърысына килгәндә, шул картның гына тешен күрсәтәсең. Менә аннан була да куя, бернәрсәсе юк».

---

*Тазиянә* — камчы, чыбыркы.
*Ригайә* — ихтирам.
*Сонгый* — ясалма.
*Әүзане* — шигырь үлчәмнәре.
*Хилафе сәясәт* — политикага каршы.

*«Чала татар» тагы үз-үзенә бәхәс итә:*

«Менә сиңа кирәк булса тагы бер сүз. Синеңчә, бер рольне ике кеше уйнарга кирәк. Бик гаҗәп».

*«Ялт-йолт»:*

«Вакыйган, «Чала татар»ның[2] башына авыр мәсьәлә төшкән. Драматургның герое тешсез карт. Яшьләр бер кичә өчен генә тешен сындырмый. Мөселман тешсез картлары сәхнәгә керми. Рус картын кертсәң, ул татарча белми.

Нәкъ шушындый авыр мәсьәлә бервакыт бөтен бер авыл рус халкына да килгән иде: мунча башына чирәм үскән. Бу хәл гади ызбаларга яраса да, мунчага ничектер килештермәгәннәр. Чирәм вә үләнне һәр ничек бетерергә кирәк. Менә берзаман мужиклар, чирәмне ашатыр өчен, муенына җеп бәйләп, сыерны мунча түбәсенә өстериләр. Бу авыл халкы этрафка җүләрлеге белән мәшһүр икән. Сыерны вә үз-үзләрен ах-ух килеп газаплаган бу халыкны читтән карап торучы чит авыл кешесе: «Сыерны да, үзеңезне дә йөнчетмәңез, үләнне йолкыңыз яки урак белән урыңыз да эш бетте», — дигән. Мужиклар, бу кешенең гакыллылыгына хәйран каларак, үләнне йолкалар. Эш тәмам.

Монда, Казанда да, атна саен спектакльләр куйганлыктан, төрле уңайсызлыклар чыгып кына тора.

Мәсәлән, «Яшь хатын» пьесасында «яшь хатын»ның күзе агып чыккан булырга кирәк. Билгеле инде, артисткалар бер кичә өчен генә күзләрен агыздырып чыгарырга риза булмыйлар. Шәһәр кызлары, бер-бер гайбәтләрдән куркып, театр уйнауга катышмыйлар.

Менә артистлар күзе агып чыккан бер кыз эзләргә Казан тирәсендәге авылларга чабышырга тотыналар. Монда халык көтә. Ачулана. «Ах, сызгыралар», — дигәндә генә, бер артист күзе агып чыккан кыз өстерәп кайтып керә.

Былтыр, мәсәлән, «Алдым-бирдем» Галиясе[3] белән шулай йөдәп беттеләр. Галия, аксак хатыннар кулыннан ычкынганда, канга бата. Битләре тырналган була. Инде бер кичә өчен генә артисткалар битләрен тырнамаслар бит!

Менә артистлар тагы урам буе чабалар. Ниһаять, Ходайның рәхмәте белән, ире белән сугышып, палисәгә жалобага баручы бер яшь хатын очрап кына артистлар авылга йөгерү зәхмәтеннән котылалар!

Иншалла, «Акмелла» милләт хадимнәре мөхәррирләргә вә драмачыларга һәрвакыт шулай кимчелекләрен күрсәтеп торырлар, вә акрын-акрын кеше мәшәкатьли торган пьесалар да мәйданнан югалырлар».

*«Аң»нан:*

«Ләкин бит анда мохтәсарлар укылмый. Искеләрнең шәригатенә сыймый торган әллә нинди гыйлемлекләр укыла. Укытучылары да Хуҗа Әхмәт мулла хатыннары түгел».

*«Ялт-йолт»:*

«Хуҗа Әхмәт мулла хатыны» димәк, бөтен Казанга мәгълүм Маһруй Мозаффария димәктер. Моны кулына гәзитә алгалаган чит шәһәр халкы да беләдер. Биби-фәләнә остазбикә ире Атласов та яхшы белсен ки, Казандагы Мозаффариярләр, Ләбибәләр[4] үзләреннән яхшыларның юлларын бикләп тормыйлар. «Бишенче» елда үз кимчелекләрен аңлаганнан бирле һаман үз-үзләрен тәкмил вә мәгърифәт белән шөгыльләнеп килделәр, тәрәкъкый иттеләр, үзләре белгәнне шәкертләре белән бүлешә тордылар. Әле җитмәсә, «Брокгауз-Ефрон» алып, синең борының нос куймакчы булалар.

Симергән булгач та, тилергән булгач та, Таврида сараенда йөргәч тә, зур словарь күргәч тә, бу әле һич гаепсез бер ханымның шәхесенә тияргә хак биреп бетермидер. «Гимназия» — ул киләчәк эше әле. Әйе, аның укытучылары да Хуҗа Әхмәт мулла хатыннары булмас. Киләчәктә өмид зур. Менә тиздән гали мәгълүматлы кешеләремез өлгерәчәк. Ул вакыт, иншалла, Дума депутатларымыз да әллә нинди Әлмәт муллалары вә Биби-фәләнә остазбикә ирләре булмас. Гимназия ачылгач, татар хатыннары чапан бөркәнмәсләр. Киләчәк заман депутатларымыз да «сукыр трудовик» булып йөрмәсләр. Ай, киләчәк! Ул кайчан киләчәк?

Рәфикымез «Аң»га татар матбугатындагы бу кеби «фәсахәт» нәмүнәләрен күп күрсәтмәскә киңәш бирәмез.

## УЯНГАЧ БЕРЕНЧЕ ЭШЕМ

Ярты төш мисалендә үтеп киткән 7 сәнәлек бер мөддәт эчендә минем тарафтан шактый гына мәнзумат язылып ташланган. Ул мәнзумат, вак-вак диваннарга тәдвин ителеп, төрек-татар галәменең һәр ягына таралган. Гәрчә һичбер диванның басылу саны икедән артмаган булса да, алар шактый вә хәтта күп таралган, һәр тарафта: «Бер казакъга гына түгел, бездә дә бер оста такмакчы булды», — дип, минем такмаклар мисал итеп күрсәтелгән. Шулай булган. Заман кичкән. Сулар аккан.

---

*Тәкмил* — камилләштерү, үстерү.
*Рәфикъ* — юлдаш, иптәш.
*Мөддәт* — вакыт арасы.
*Мәнзумат* — шигъри, көйле әсәрләр.
*Тәдвин ителү* — тезелү.

Югарыда шәхси тормышымны «ярты төш»кә охшатуымны Казанда минем ничек вә ни рәвештә көннәр уткәруемә шаһит булган кешеләр, әлбәттә, аңлыйлар. Бутәннәр бик аңлап җиткермәсәләр дә, монда үкенерлек хәл юк. Фәкать сабыр кирәк. Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле.

Әнә шул «ярты төш» мөддәтендә мин бәгъзан уянып, тәмам сафланып та китә идем. Андый чакларда мин әллә ничек, итегемә чия төше кергән кеби, штиблит бавым чишелгән кеби, тормышымның өскерәк кат уңайсызлыкларын сизеп тә ала идем. Ләкин нә файда: бәхетсез милләтнең бәхетсез угылы, бәхетсез почмакның әсир былбылы булган мин бичара тагы әллә кемнәрдән агу алам, тагы кәефләнәм, тагы төш күрә идем. Әйе, кардәшләр, минем уянуларым тормышымны төзәтер вә алдагы идеалыма тугърырак атлар өчен, җитди вә әсаслы бер эш кыйла алмыйлар иде.

Тугъры әйтергә яраганда, кинаяләргә сыгыну нәрсәгә? Минем кайсы чаклар уянганда тыгызланган вә газапланган маддәләрем төрле диваннарымда һаман әле үзем, җаным, вөҗданым, оятым, хәятым разый булмаган шигырьләремнең шушы көнгәчә халык тарафыннан укылып (нахально) йөрүләре иде. Вә ул шигырьләрнең, бүген бу сәгатьтә үзләрен тотып яндыра вә җәһәннәмгә юнәлтә алмавым сәбәпле, гүя минем өстән кычкырып көлүләре иде. Ләкин, тәәссефләр улсын, тагы уйкуга тала идем.

Көн киттек, төн киттек, тәртә буе җир киттек. 1913 ел, менә мин уяндым. Инде мәңге йокламаска дип уяндым.

Фәсәуфә тара иза инҗәләл-гобар
Әфәрәсен тәхтәкә әм химар!*

Күрдем. Атланганым ишәк икән. Үзем бер җүләр вә фитъръәтем җиһанга килмешәк икән. Чыннарым ялган, суларым төтен икән, «мәгъсум»нәрем бер җәһәннәмгә дип өйгән утын икән.

Теге «төш» күргәндә, шыр ялангач калдырылып талансам да, тормышта бик каты алдансам да, тукта әле, егъламыйм, Аллам юл ачар әле, дидем. Күз ачылуының беренче дәкыйкаләреннән билистифадә иң элек 7 ел, тәмам 7 ел мөддәтендә себерү вә пакьләү күрмәгән «такмак бүлмә»сен себерергә тотындым.

---

* Атланганың атмы яки ишәкме икәнен тузан басылу белән тиздән күрерсең.

*Тәәссеф* — үкенеч.

*Фитъръәт* — яратылыш.

*«Мәгъсум»нәрем* — «ак, саф» дип караганнарым.

*Дәкыйка* — минут.

*Билистифадә* — файдаланып.

Һу, монда чүп-чар! Монда әллә нинди «американизировать» ителгән «Кичке азан»нар, бозаудан ахмак төрек шыгырдаучыларына ишәктән тиле тәкълидләр. «Шәкерт, яхуд бер тәсадеф» кеби, инсан авызыннан чыкмаган диярлек тәркибләр, тагы шундый кабахәтләр...

Менә шундыйлар минем рухани бүлмәдә 7 ел торганнар. Меңнәр мәртәбә халык күз алдын мәсхәрә итеп, кайсылары бишәр меңнән икешәр кат басылганнар вә, Хода гына белә, күпме укылганнар. Соң, боларның 7 шәр ел буе бүлмәдә ятуларына ни сәбәп булган? Менә шул чүпләрнең язылуына нинди кабахәт вә кара көч сәбәп булса, шул сәбәп булган.

Башында гакылың сафайгач, «төш» күрмәгән чакта бүлмәңдә үзең сөймәгән бер генә кешене дә тотасы килми. Кая ул минем «теге шигырьләрем» кеби бөтен бер артельне! Юк, котылдым. Инде мин аларны себердем. Алар «һәбаән мәнсүра» инде. Бүлмәмдә «үз сөйгәнем», «үз сөйгән шигырьләрем» генә калдылар.

Тормыш юлымда очрап, минем белән бәлешләнгән вә дусланган кешеләр бәгъзан аларга бөтен диваннарымны һәдия итүемне сорыйлар иде. Чит шәһәрдә налож белән җибәрүемне үтенәләр вә, күпме хак куйсам да, түләп алачакларын вәгъдә итәләр иде.

Ул китапларның кибетләрдә сатылуын да төрле сәбәпләрдән наши туктата алмаганыма ләгънәт укып йөргән мин һичбер вакыт үз кулым белән, «борыны сизми» дип, чын дустыма үлгән мәче һәдия итәмме соң? Юк! Әлхәмделиллаһи, юк. Лән тәналлу әлбиррә хәтта төнфику мима мөхиббух*.

Яхшы беләмен ки, ушбу, хәзер ташлаячагым вә игъдам итәчәгем шигырьләрем белән минем хәяма тукынырга күп тәшәббесләр иттеләр. «Вакыт», «Шура», «Идел» вә башка да бик күп идарәләргә мәкаләләр бирделәр. Дәреҗ итәргә үтенделәр. Әгәр алар мине үз-үземә дә, кешегә дә шул шигырьләр белән тәкъдим итсәләр вә миннән мәлгунанә бер сурәттә

---

* Үзегез яраткан әйберегезне биреп торып, изгелеккә ирешмәссез.

*Тәкълид* — ияру.

*Тәркиб* — сүз тезмәсе.

*«Һәбаән мәнсүра»* — «тузан кебек таралдылар».

*Сәбәпләрдән наши* — сәбәпләр аркасында.

*Һәдия* — бүләк.

*Игъдам итү* — юк итү.

*Хәя* — намус.

*Тәшәббес итү* — тырышып карау.

*Дәреҗ итү* — урнаштыру, басып чыгару.

*Мәлгунанә* — ләгънәтле.

шаркылдап көлсәләр, вакыйган, максудларына җитәләр иде. Ләкин миңа эш башында рух биргән идарә мөхәррирләре эш уртасында мине мәсхәрә иттермәделәр. «Теге»ләрнең мәкаләләре дә басылмадылар. (Мүтү бигайзыйкем!)

Китапчыларның да хакымдагы төрле рисаләләрне басмыйча калдыруларына вә хәямны химая итүләренә тәшәккер итәм.

Мөхәррирләр дә, китапчылар да мине хәзерге «аң»ым вә самокритикам ул шигырьләрдән гали икәнен беләләр иде.

Мин үзем дә:

— Ләкми чир, аурып та булмый, ичмасам![1] — сүзләренә бара-бара, рухани бүлмәмне бертөрле тазартырга вакыт эзли идем вә һаман Алла юл ачар әле дип өмидләнә идем.

Менә Алла юл ачты, «бүлмә» себерергә бушадым. Себереп тә чыгардым. Әй, җир йөзендәге төрек баласы, галимме син, хәкимме син, падишаһмы син, теләнчеме син, инде мин сине өемә кертергә оялмыйм, инде син кем булсаң да, мин сиңа такмак китабымны мәгаль ифтихар һәдия итә алам.

Әле күптәнме, берәү диваннарымның берсен кесәсеннән чыгарса, калтырый идем. Кешеләр алдында укып җибәрсәләр, бүркемне дә кимичә, урамга кача идем. Җаннан кадерле кешемне, шул такмакларымны сораса, мәхрүм итәргә мәҗбүр була идем.

Фәиннә мәгаль госри йөсра*.

Тиз арада үзем браковать итмәгән вә үзем яраткан шигырьләрдән җыеп, 400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга[2] чыгарырга карар бирдем.

Валлаһел муаффикъ.

---

* Авырлык соңында җиңеллек тә була.
*Мүтү бигайзыйкем!* — Ачуыгыздан үлегез!
*Химая* — саклау.
*Тәшәккер итү* — рәхмәт әйтү.
*Хәким* — философ.
*Мәгаль ифтихар* — мактана-мактана.
*Валлаһел муаффикъ* — Алла — теләккә ирештерүче.

## *Истәлекләр. Юлъязмалар.*
## *(1909–1912)*

# ИСЕМДӘ КАЛГАННАР

### МӨКАДДИМӘ

Бу «Исемдә калганнар»ны язуыма башлыча сәбәп берничә наширләрнең миннән тәрҗемәи халемне язып бирергә үтенүләре булды.

Мин аларга туганымнан алып хәзерге яшемә кадәрле тәрҗемәи халемне кыска гына рәвештә язып бирү нияте илә кулыма каләм алган идем, әллә ничек сүз озынга китте.

Минем гомерем (укучылар күрерләр) шактый ямьсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үткән булганга, яза башлагач, исемдә калганнарның һәммәсен язасым килде.

Шунлыктан Уральскигә килеп җиткәнемә кадәр кичердекем хәлләр илә аннан соң хәзер шушы сәтырларны язып утырган вакытыма кадәрге башыма килгәннәрне икесен ике рисалә итеп чыгарырга мәгъкуль күрелде.

*Г.Тукаев*
*29 сентябрь, 1909 сәнә*

### I

Минем атам Мөхәммәтгариф[1], Кушлавыч карьясендә[2] Мөхәммәтгалим исемле мулланың угылы булып, 14–15 яшьләрендә Кышкар мәдрәсәсенә[3] китеп, анда хәтме көтеб кыйлырга гадәттә ничә сәнә кирәк булган булса, шулкадәр торып, карт атасы тере вакыттук авылымыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр.

Мулла булгач та өйләндеке бер җәмәгате илә берничә генә еллар торгач, җәмәгате вафат булып, бер ир вә бер кыз баласы калмыштыр.

Моннан соңра атам, икенче мәртәбә өйләнүе уларак, Өчиле карьясе[4] Зиннәтулла хәзрәтнең[5] Мәмдүдә[6] исемле кызыны (минем анамны) алмыштыр.

Анам илә бер ел ярым кадәр торгач, беренче бала уларак, мин дөньяга килгәнмен.

---

*Мөкаддимә* — сүз башы.
*Сәтыр* — юл (язма юл).
*Рисалә* — китапчык.
*Хәтме көтеб кыйлырга* — укып тәмам итәргә.

Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам аз гына вакыт авырып тәрке дөнья итмештер.

Тол калган анам янында мин берничә вакыт торгач, анам мине авылымыздагы Шәрифә исемле бер фәкыйрә карчыкка вакытча асрарга биреп калдырып, үзе Сасна нам карьянең[7] имамына кияүгә чыкмыштыр.

Бу вакыт атамның ата-анасы (бабай вә әби) күптән вафат булып, авылда башка туганнарым булмаганлыктан, мин бу карчык ханәсендә кадерсез, артык бер бала булганлыктан, ул мине, әлбәттә, тәрбияләмәгән; тәрбияләү түгел, яшь балаларның иң мохтаҗ булдыклары ачык йөзне дә күрсәтмәгән.

Мин үзем ул карчыкта үткән заманның ничеклеген белмим. Ул вакыт мин ике-ике ярым яшемдә генә булганмын дип уйлыйм.

Хәзер авылда минем вакъты сабавәтемне күргән карчык вә хатыннар мөрәббия карчыгымның минем илә бик начар мөгамәләдә булганлыгын үземә хикәят итәләр.

Җөмләдән берсе.

Мин кыш көннәрендә төнлә яланаяк, күлмәкчән көенчә тышка чыгам икән дә, бераздан өйгә кермәкче булып, ишеккә киләм икән. Кыш көне авыл ызбаларының ишекләрен ачмак балага түгел, шактый үсмер кешеләргә дә мәшәкать вә көч булганлыктан, табигый, мин ишекне ача алмыйм вә ишек төбендә аякларым бозга ябышып катканча көтеп торам икән.

Карчык исә үзенең «Кадалмас әле килмешәк!» дигән «шәфкатьле» фикере илә мине үзе теләгән вакытта орыша-орыша кертә икән.

Ул карчык үлгән инде; Аллаһы аңар рәхмәт итсен.

Мин бу карчыкта торган мөддәттә анам да теге муллага үзләшеп йиткән булырга кирәк: ул бервакыт мине үзе янына Саснага алдырырга атлар йибәрткән.

Мине бу атлар, әлбәттә, Саснага алып киткәннәр.

Хәер, алып киткәннәр генә түгел, шул атка утырып киткән дәкыйкаларда миндә, бала булсам да, бер нәүгы шөгур хасил булганмы, нидәндер, мин хәзердә дә атта утырып Саснага барганымны, үземне бер киң вә рәхәт галәмдә хис иткәнемне, юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганыны онытмаган шикелле булам.

Саснага барып җиткәнмен. Ничек, ни рәвеш бардым, мине

---

*Тәрке дөнья итмештер* — дөнья куйган, үлгән.
*Вакъты сабавәтемне* — сабый вакытымны.
*Мөрәббия* — тәрбияче (хатын-кыз).
*Мөддәттә* — вакыт эчендә.
*Бер нәүгы шөгур хасил булганмы* — бертөрле сизенү, аң ачылып китү барлыкка килгәнме.

кемнәр каршылады — анысын белмим, ләкин үги этиемнең[8] мине сөюе, миңа чәй янында кәрәзле балны ак күмәчкә ягып бирүе, минем шунда куанганнарым, биш минутлык төш шикелле генә, әле дә булса хәтеремдә.

Ләкин бу рәхәт бик озакка бармаган. Минем анам, бу муллада бер ел кадәрме — күпмедер торгач, белмим, нинди авырудандыр вафат булган.

«Булган», «булганмын», «мине шулай иткәннәр» дип язуымны, билгеле, ул яшьтәге сабыйларның хәтерләрендә бик мөәссир булмаса, сирәк дәкыйкалар гына калганлыгыннан гынадыр дип уйлыйм.

Шуның өчен мин монда, әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә капка астыннан үкереп җылый-җылый җөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» — дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне язамын.

Әни дә үлгәч, мин бөтенләй ятим булып җиткәнгә, мин бу Сасна мулласы өенә дә сыймаганга, ул мулла мине Өчиле карьясендәге анамның атасы булган бабайга кайтарып биргән.

Минем анамның анасы булган үз әбием әни кыз чактук үлгән булганга, бабай кайсы мулладандыр тол калган бер хатынны аңар ияреп килгән алты баласы илә алган булган.

Өчиле карьясе (исеменнән дә мәгълүм) бик кечкенә вә ярлы бер карья булганга, шуның өстенә мин ятим калган елларда ул тарафларда каты ачлык булганга, бабайның көн күрмеше гаять начар булган.

Менә шул фәкыйрь вә шуның өстенә әллә ничә авызлы булган семья эченә мин ятим бала булып килеп кергәнмен.

Үги әбинең алты күгәрченнәре эчендә мин бер чәүкә булганга, мине җыласам — юатучы, иркәләнем дисәм — сөюче, ашыйсым-эчәсем килсә, кызганучы бер дә булмаган, мине эткәннәр дә төрткәннәр.

Бу семья эчендә фәкыйрьлек шул дәрәҗәгә җиткән булырга кирәк ки, мин хәзер дә булса бабайның күрше баерак авыллардан икмәк сыныклары теләнеп алып кайтканын исемдә тотамын.

Шул рәвешчә көннәр үткән, мин монда торганда чәчәк белән дә авырганмын, башка әллә нинди хәстәлекләр дә күргәнмен, тәмам зәгыйфьләнгәнмен.

Бу гаиләдә һәммәсе (бер җитеп килә торган Сәҗидә исемле кыздан[9] башкасы) минем авыруыма: «Ичмасам, чәнчелсә, бер тамак кимер иде», — дип кенә караганнар.

*Мөәссир* — тәэсирле, эз калдырган.
*Тәхаттыр иткәнемне* — хәтерләвемне.

Мин әле хәзер истисна итдекем Сәҗидә апайның үги әбидән яшереп кенә мине җуатканын вә сөйгәнен, әби килә башлагач та, минем белән эше юк кеше шикелле, үзенә икенче кыяфәт биргәнен һаман хәтеремдә саклыйм.

Менә шул вакыттан бирле ул апа минем күңелемә фәрештә булып утырган да калган. Күңелем аны уйлый башладисә, хәзер күземә аппак саф бер фәрештә күренә.

Ни күрсәм дә күргәнмен, ни булса да булган — һәр ничек мин бу семьяга сыймаганмын. Беркөнне бабай, үги әбинең киңәше илә булырга кирәк, авылымыздан Казанга бара торган бер ямщиккә мине утыртып, Казанга озаткан.

Ямщик, Казанга килеп җиткәч (безнең авыл Казаннан 60 кына чакрым), Печән базарында: «Асрарга бала бирәм, кем ала?!» — дип кычкырып йөргәндә, халык арасыннан бер кеше чыгып, мине ямщиктән алган. Ул мине мөддәтсез бер асрау бала итеп өенә алып кайткан.

Мин монда торганымны ярты йомык күз белән генә күргән шикелле булам.

Мәсәлән, бервакыт, әллә нинди авырудан күзем авырган вакытта, мине бер карчыкка алып барганнарын, ул минем күзгә шикәр салганын, үземнең салдыртмаска азапланганымны, тартышканымны беләм.

Бу яңа ата-анамның хәленнән бераз язып китим әле.

Миңа эти булганы Мөхәммәтвәли исемле булып, әни булганы Газизә исемле иде. Торулары Яңа бистәдә иде.

Эти талчокта сату итә идеме, әллә тирече идеме шунда — анысын яхшы белмим. Әни, бер дә армый-талмый, байларга кәләпүш эшләп чыгара иде.

Әни, Печән базарына кәләпүш чыгарганда яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә ияртеп баргалый иде.

Мин, байлар йорт эченең матурлыгыны, идәннән түшәмгә кадәр торган зур көзгеләрен, чиркәү кеби суга торган сәгатьләрен вә сандык кадәр зур органнарын күреп, боларны оҗмахта торалар кеби уйлый идем.

Бервакыт шулай байларга барганда, ишегалдында әллә нинди зиннәтле вә алтынлы койрыгын кояшка каршы ялтыратып йөргән тависне күреп, бигрәк тә сокландым.

Бу ата-анам икесе дә эш кешеләре булдыкларыннан, монда миңа ач торырга тугъры килми иде.

Кайчакта әни белән Ташаяк базарына[10] барып, андагы уенчык базарларына кызыгып вә самокатларда шатланып-шатла-

---

*Истисна итдекем* — аерып алып сөйләгән (кешем).
*Мөддәтсез* — вакыты чикләнмәгән.

нып агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.

Мин дә атланыр идем — акчам юк. Әнидән сорарга куркам, ул үзе белеп бирми иде.

Шулай итеп, мин кеше рәхәтенә генә кызыгып кайта идем.

Аннан соң, җәй көне ике бистә арасындагы яшел үлән өстендә малайлар илә каз җоннары куып йөргәнемне, арыгач, Хан мәсҗеденә юнәлеп ятып, чирәмдә ял иткәнемне бер дә онытмыйм.

Мин бу ата-анамда ике елмы, — күпмедер торгач, әти дә, әни дә — икесе берьюлы авырый башлаганнар.

Алар, үзләренең үләчәкләреннән куркып: «Без үлсәк, бу бала кем кулына кала, ичмасам, авылына кайтарыйк...» — дип, теге мине Казанга китергән ямщикне табып, мине янәдән аңар утыртып, Өчиле карьясенә йибәргәннәр.

Инде миннән мәңгелеккә котылдык дип уйлаган бу семьяның мине ничек каршы алганлыкларын уйлап белергә мөмкин.

Мин кайтып бераз торгач та, әби белән бабай, инде мине шәһәргә җибәрүдән өмид кисеп, кайда булса да бер чит авылга асрарга бирергә уйлашканнар.

Болар Өчилегә килгән һәрбер чит авыл кешесенә үзләрендә асрарга бирергә бер ятим бала барлыгын сөйләгәннәр.

Шулай мәшәкатьләнә торгач, Кырлай[11] исемле бездән җиде генә чакрым авылдан Сәгъди[12] исемле бер ир баласыз кеше, килеп, мине үзенә алып киткән.

Бу урыннан игътибарән тәрҗемәи халемне үземнән хикәя итүне күңелем хаклы тапканга, «булган»ны — «булды»га, «йөргәнмен»не — «йөрдем»гә илх алмаштырам.

## II

Бабайлар өеннән чыгып, Сәгъди абзыйның арбасына утырдым. Бабай белән әби (Сәгъди абзыйдан яхшысынмый гына булырга кирәк) мине озатырга чыктылар. Тагы да минем китүемне кызык күргән яланаяклы малайлар да арба тирәсендә җөгергәләп йөриләр иде.

Арба кузгалды. Сәгъди абзый белән без янәшә утырып киттек. Ул юлда миңа: «Менә хәзер Кырлайга кайтып җитәбез, анда әниең[13] каршы чыгып көтеп тора торгандыр. Аллаһы боерса, бездә катык, сөт, ипи күп, теләгәнчә ашарсың», — дип, миңа барып йитәргә ике-өч кенә чакрым калган бәхетләр илә мине җуатып бара иде.

---

*Игътибарән* — башлап.
*Илх* — (ила ахириһи — ахырына кадәр) һ.б. (һәм башкалар).

Мин дә, ачык йөзләрне бик күптән күрмәгәнгә күрә, эчемнән бик шатлана идем.

Бу вакыт җәйнең матур чаклары булганга, әтрафтагы яшел чирәмнәр вә урманнар, артык эссе булмыйча, үзенең нурлары белән сөеп кенә торган кояш икенче яктан тагы рәхәтләндерәләр иде.

Ниһаять, Кырлайга барып кердек. Сәгъди абзыйның йорты басу капкасыннан кергәч күп ерак түгел икән; аз гына баргач, коймасы читәннән булган тәбәнәк кенә, салам түбәле бер өйгә туктадык.

Юлда Сәгъди абзый әйткәнчә, вакыйган, минем әни каршы чыккан икән, ул капканы ачты; мине ачык йөз илә каршы алып, арбадан күтәреп төшереп, өйгә дә алып керде.

Тыштагы эшләрен караштыргалагач, атын туаргач, эти дә өйгә керде. Кергәч тә, әнигә хитабән: «Хатын! Бар, балага катык белән ипи китереп бир», — дип әмер итте.

Әни дә, дәрхаль баздан катык алып менеп, миңа зур гына икмәк телеменең яртысын тоттырды.

Мин исә, Казаннан кайтканнан бирле җүнләп аш йөзен күрмәгәнгә күрә, бик шәп бер иштиһа илә икмәк белән катыкны ялт иттердем.

Тамак туйгач, әнинең рөхсәте илә урамга чыктым. Мин, анда чыгып, адашудан куркып, артыма карый-карый гына барадыр идем, менә берзаман тирә-ягымны әллә кайдан килеп чыккан авыл малайлары сарып алдылар.

Алар һәр көн авылның бер башыннан бер башына җөгереп йөреп тә, бу көнгә кадәр мине күрмәгәнгә, аннан соң минем өстемдә Казаннан киеп кайткан каюлы ситса күлмәк, башымда да мине Өчилегә кире йибәрер алдыннан әнинең, миңа сагынмалык булсын дип, төрле төсле хәтфәләрдән корамалап ясаган кәләпүше булганга, бу Кырлай малайлары миңа бик гаҗәпләнеп карыйлар иде.

Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар; мин бүген аларга катыша алмадым, өйгә кереп киттем.

Өйгә кайтып керсәм, анда (бая катык ашаганда күрмәдекем) ике җиткән кызлар күрдем.

Боларның берсе — таза гына гәүдәле, кызыл йөзле, күк күзле, икенчесе — арык кына, сары йөзле генә, култыгында агач таяклары бар аксак бер кыз иде.

---

*Вакыйган* — чыннан да.
*Хитабән* — эндәшеп.
*Дәрхаль* — шунда ук.
*Иштиһа илә* — теләк (аппетит) белән.

Әни миңа: «Менә болар апайларың: берсе Сәҗидә[14] апаең, берсе Сабира[15] апаең, күреш», — дигәч, мин әкрен генә барып кулымны суздым.

Болар Сәгъди абзыйның кызлары булып, аксагы Сәҗидә атлы икән. Шулай итеп, мин монда яхшы гына тора башладым. Авыл малайлары белән дә таныштым.

Сәгъди абзыйның юлда әйткәненчә, вакыйган, монда катык, сөт күп, шулай ук бәрәңгегә дә ихтыяҗ юк иде.

Мин барып бер аймы, күпмедер торгач, урак вакыты җитте. Әти, әни вә ике апай уракка китә башладылар.

Мин исә уракка бармый идем. Иптәш малайлар илә авыл буенда җөгерә вә болынлыкларда көн буе ауный идем. Әгәр көндез кайвакыт уен арасында карыным ачса, тиз генә өйгә кайтып, җан тәрәзәдән генә өйгә кереп, әнинең минем өлешкә калдырган бер җамаяк бәрәңгесе илә бер телем икмәген ашый идем.

Алар әбәттән (көндезге аш) соң ишекне бикләсәләр дә, минем ашарга кайтасымны белеп, җан тәрәзәне эчтән бикләми китәләр иде.

Урак вакытында бөтен халык һәммәсе эшкә китеп, авылда эшкә ярамаган карчыклардан башка һич кеше дә калмаганлыктан, без бакчалардагы яшел суганнар башына бер дә кәҗәдән ким бәла булмыйдыр идек. Әгәр өй саклаучы карчыклар күрсә, без дәрхаль киртәдән сикереп качадыр идек. Карчык мискинәнең орышып, тешен кысып калудан башка кулыннан бер эш тә килмидер иде.

Әгәр уйный торгач тирләсәк, хәзер үзебезнең ындыр артындагы кечкенә генә инешкә төшеп, шуннан әллә ничәшәр сәгать чыкмыйча коенып, күлмәк-ыштаннар илә вак балыклар сөзеп ята идек. Күңелле чаклар!

Бервакыт шулай уйнап йөргәннән соңра, кич белән өйгә кайтсам, өй эчендә һәммә кешене күңелсез вә кәефсез күрдем. «Бу нидән икән?» дип уйлап торгач, Сабира апайның идәннән сәкегә котырган шикелле җөгерүен вә кая барып бәрелгәнен дә белмәвен һәм күзләре әллә нинди коточкыч булып акайганын күргәч, аның уракtan «җенләнеп» авырып кайтканын белдем.

Ул көнне өйдәгеләр берсе дә йокламый үткәрделәр. Мин генә, бик йокым килгәч, тыштагы арбага чыгып йокладым.

Иртә белән, таң сызылып килгәндә, колагыма:

«Сабира апаң вафат булды; син йоклап ятасың, тор, тор!» дигән бер тавыш килгәч, күземне ачып карасам — каршымда әни тора иде.

Бу, билгеле, миңа да гади хәбәр түгел — йокы тәмле булса да, сикереп тордым.

Шул көнне Сабира апаны җирләделәр. Аны җирләп берничә көн үткәч, энинең этигә:

— Менә «үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр; үксез бозау асрасаң, авызың-борының май итәр» шул инде ул; мөгаен, шуның шомлыгыннан булды инде бу! — дип сөйләгәнен ишеткәли башладым.

Андин соң кайчакларда энинең җә кушкан җомышын тыңламасам, җә җиренә җиткерми эшләсәм, шул сүзне әйткәли торган иде.

Эти белән без бик-бик тату идек. Ул бер дә миңа каты сүз әйтми иде. Мәсәлән, бервакыт минем Казаннан киеп кайткан күлмәк-ыштаннарым, читек-кәвешләрем, казакиләрем тузгач, эти үзенең мин килмәстән бер ел элек үлгән угылының күк киндер күлмәге белән бишмәтен миңа бирмәкче булды.

Шунда эни:

— Мин үз угылымның төсе итеп саклаган киемнәрне кешегә бирер хәлем юк, — дип, бик озак тарткалашты.

Ахырда эти:

— Җә, хатынланма әле юкка, үзеңнән тумаган бала дип, әллә аны шыр ялангач йөртерсеңме? — дип, киемнәрне көчләп диярлек миңа алып киертте.

## III

Шулай итеп, урак бетте, көз җитте. Ашлыклар эшен бетергәч, бакчага чыгып, бәрәңге казырга вакыт җитте.

Бу бәрәңге казу вакытында миңа урак вакытындагы кеби уйнап йөрергә тугъры килмәде: мине казып чыгарылган бәрәңгеләрне капчыкка тутырырга куштылар. Мин дә үз хезмәтемне яхшы гына эшләдем.

Бу вакыт, көз көненең салкын вакытлары булса да, мин яланаяк идем. Аякларым туңганга, мин аларны балчыкка күмеп утыра идем.

Бервакыт шулай, аякны балчыкка күмеп, бәрәңге чүпләгән чагымда, теге бәрәңге казучы аксак Сажидә апай яңлыш минем аякка тимер көрәк белән чапты.

Аяк шактый тирән җәрәхәтләнде, мин урынымнан сикереп торып, бераз читкә барып утырып егъладым да, соңра, җәрәхәткә балчык сибеп, янә хезмәтемә дәвам иттем; ләкин бу юлы аяклар никадәр туңсалар да, балчыкка күмәргә курыктым.

«Моны ни өчен яздың?» — диерләр.

Ни өчен языйм? Шул вакытта аягым бик авыртканга вә хәзер дә аякта шул җәрәхәтнең эзе булганга тоттым да яздым.

Бара торгач бакча эшләре дә бетте.

Беркөнне кич белән әти белән әни иртәгә иртүк мине абыстайга укырга илтәчәкләрен миңа мәгълүм иттеләр.

Таң атты; кояш чыкмас борын ук торып чәй эчтек. Чәйне җыештыргач, әни мине кулымнан җитәкләде дә үземездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып барды.

Анда барып кердек. Мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында, минем яшемдәге кечкенә кыз балалар күп булганы кеби, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында, богъдай арасындагы берничә борчаклар кеби, берничә минем шикелле ир балалар да бар иде.

Әни иң элек ике бөтен икмәк илә бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кыйлдык.

Әни мине тапшырып, үзе киткәч, мин кызлар белән бергә «әлеп, пи, ти, си, җымыкый»ны, бер дә тарланмыйча, кычкырып укый башладым.

Шул рәвешчә «әлеп, пи, ти, си»не берничә көн такмаклагач, миңа «Иман шарт» та тоттырдылар.

Бу «Иман шарт»ының иҗеге белән сүрәсе миңа кыш буена җитте бугай. Мин бу кышта һаман шул кыска гына «Иман шарт» тирәсендә әйләнүдән уза алмадым.

Фәкать, «Иман шарт» бетерүгә гыйлавә уларак, бервакыт абыстай өйдә юк вакытта, бәгъзе шаян кызларның. «Кәлимәтен таййибәтен, безнең әни бай катын, изүе тулы тәңкә, борыны тулы...» дигән сүзләрен ишеттем.

Ишетелмәгән сүз вә күрелмәгән нәрсә һәрберсе гыйлем булганлыктан, табигый, мин дә бу сүзне яратып отып алдым, һәм шуны үземнән надан малайлар каршында тәкрарлап, аларны көлдереп йөрер булдым.

## IV

Бу Кырлайдагы беренче кышым үтте. Яз җитеп, карлар эри башлады. Озакламый кырлар, игенлекләр тәмам кардан ялангач калып карала башладылар.

Менә бераздан сабан туе җитте. Мине сабан туе көнне иртүк уятып, кулыма янчык дәрәҗәсеннән аз гына үткән кечкенә бер капчык тоттырдылар.

Мин, шул капчыкны тотып, авыл буенча киттем.

Авыл халкы тегеләй дә иртә торучан булса да, бүген сабан

---

*Иҗеге белән сүрәсе* — хәрефләрне иҗекләп һәм аңлатмалары белән өйрәнү.
*Гыйлавә* — өстәмә.

туе бәйрәме көне булганга, бигрәк тә иртә торганнар, вә һәр өйдә, һәркемдә көләч йөз, тәмле сүз иде.

Мин кайсы гына өйгә керсәм дә, минем ятим калган мулла баласы икәнемә игътибарән, миңа, башка малайларга биргән кеби, конфет, бер-ике перәннек кенә бирмичә, һәр йорт иясе дә буяган күкәй бирәләр иде.

Шунлыктан минем капчыгым буяган күкәйләр илә бик тиз тулып, өйгә дә кайтып кердем. Башка малайлар һаман йөреп калдылар шикелле.

Әти белән әни дә минем капчыкның болай тиз тулуына гаҗәпләнделәр дә, шатландылар да.

Ул көнне чәй эчтемме, юкмы — анысын белмим; капчыкны әнигә бирдем дә үзем, кулыма берничә күкәй тотып, урамга чыгып чаптым.

Мин урамга чыкканда, кояш күтәрелгән, бөтен авыл нурланган, авыл җегетләре, авыл кызлары ак оекларын мөмкин кадәр шомартып киеп, чабата киндерәләрен дә бик тырышып, матурлап бәйләп, урамга чыкканнар иде.

Бер яктан сабан туе башлыгы да, кулына бер таяк башына чүпрәк таккан әләм тотып, өй саен яулык, ситса кеби нәрсә җыеп йөри иде. Без, яланаяклы малайлар исә, аның артыннан бер дә калмыйча җөгерә идек.

Чүпрәкләр, яулыклар җыелып тәмам булгач, бөтен авыл халкы: хатыны-кызы, баласы-чагасы болынлыкка төштеләр. Көрәшләр, узышулар башланды. Болынлыкта җөк-җөк белән торган чикләвек, көнбагыш вә кызыл билле ак перәннекләр хисапсыз иде.

Болар арасында егетләр тарафыннан кызларга бирелергә иң муафигы, әлбәттә, кызыл билле ак перәннек инде. Чөнки ул перәннек хакында бер авыл җыруы да бар. Болай:

Болынлыкка бөркет килгән,
    Куркытадыр казларны;
Кызыл билле ак прәннек
    Кызыктыра кызларны.

Атлар да чабышты, малайлар да җөгереште, яулыклар да алынды; шулай итеп сабан туе да бетте.

Исемдә юк инде: бу сабан туе ничә көн булгандыр, мин бер көнне генә яздым. Бәлки ул 3–4 көн булса да, миңа бер генә көн кеби тоелгандыр.

Шуны да әйтергә кирәк: мин бу җәйне үткән җәй кеби җөгереп, уйнап үткәрә алмадым. Чөнки шушы язга чыгар алдыннан гына Сәгъди абзыйның бер ир баласы дөньяга килгәнгә, мин, әни эштә чагында, һәрвакыт шул баланы җуатып, тирбәтеп утыра идем.

Менә тагы урак вакыты да җитте; үткән җәй, бөтен авыл халкы эштә булганда, урам буе чабып йөргән мин бер малайны

бу ел Садрины (ул бала Садретдин исемле иде) тартып йөрергә уракка да алып чыктылар. Шунлыктан бу җәем уйныйсы килгән балалар өчен зур газап булган нәрсә — эш белән үтте.

Бу бала тугач, этинең мине сөюе әүвәлгечә бөтен калса да, әни миңа, эш кушарга кирәк булмаса, сүз дә дәшмәс булды, шөйлә ки, мин үз өлешемә төшкән аз гына мәхәббәттән дә коры калдым.

Җитмәсә тагы теге аксак кыз да: «Үз энем! Җан энем!» — дип, Садрины җүри мине кәефсезләндерер өчен сөйгән була иде.

## V

Көз җитте. Гадәттәге бәрәңге хезмәтемне иткәч, мине бу юлы (кызлар белән бергә абыстайга түгел) мәдрәсәгә бирделәр.

Мин мәдрәсәдә, «Һәфтияк» иҗеген вә сүрәсен бик тиз белгәч, «Бәдәвам», «Кисекбаш»ларга кердем. Үземнең сабагымны тиз белеп, миңа күп вакыт тик торырга тугъры килгәнгә, миңа өйрәтергә үземнән наданрак балаларны да бирә башладылар.

Шул балалар арасында авылымызның бер бай баласы да булып, ул мине хәлфәсе кебек итеп, чәйгә вә эченә борай ярмасы салган бәлеш ашарга чакыргалый иде.

Бер яктан, мин сабагымны яхшы белсәм, икенче яктан, аз булса да йорт хезмәтләренә дә ярый башладым.

Мәсәлән, иртә белән менеп морҗа ачу, аннан соң морҗа ябу, мичкә ягар өчен салам көлтәләр бәйләү, сыерны көтүгә чыгару, кич каршы алу кеби эшләр һәммәсе минем кулымнан киләләр иде.

Кайвакыт җәй көне эти белән Әтнә базарына бара идек. Ул үзенең хезмәтләре илә базар арасында йөргәндә, мин атны тотып тора идем.

Авылымызның мулласы Фәтхерахман хәзрәт, белмим, берзаман этинең шәриге йә дусты булганмы, нидәндер миңа атна саен 5 тин акча бирә иде. Мин бу акчага Әтнә базарында ак күмәч сатып алып, өйгә кайтканда, юл буе ашап кайта идем.

Эти мәрхүм, арбаның артында күмәч ашап утырганда, миңа кисәктән әйләнеп карап: «Күмәчеңне энисеңә дә калдыр!» — дип куя иде. Мин дә, әлбәттә, «ярар» дия торган идем. Ләкин ул күмәч авылга кайтып җиткәнчә, вак-вак кына капкаласам да, энигә кала идеме, юкмы — анысын хәтерләмим.

Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным булганга, андагы хатирәләрдә озаграк туктарга тугъры килде.

---

*Шөйлә ки* — менә шулай.
*Шәрик* — мәдрәсәдәге сабакташ.

Шуның өчен хәзер андагы үзгәреш вә тәхаттырларны берничә җөмлә белән генә язам да Кырлайдан чыгып китәм.

Саҗидә апай чахотка белән бик озак авырып, хәтта мунчага-фәләнгә барганда аны әти үзенең аркасына күтәреп йөри торгач, ниһаять, үлде. Әтине дә, кич белән әллә кайсы авылдан кайтып ат туарган чакта, кисәктән килгән бер авыру эләктерде. Аның шундук аңсыздан бер аягы аксады. Бу авыру хакында «ат җене сукты», «йолдыз атты»-фәлән кеби төрле хөкемнәр йөрттеләр.

Әти бу авыру сәбәпле эштән калмады, тик бер аягы гына чатанлап йөрүчән булып калды.

Бервакыт көз көне, өйләдән соң, әти белән әни ындырда иде, мин җан тәрәзә төбендә «Рисаләи Газизә» укып утыра идем, безнең капкага бер арбалы кеше килеп туктады.

Бу кеше, атын куеп, өйгә керде дә миңа хитабән: «Әтиәниең кайда?» — диде.

Мин: «Ындырда», — дидем. Бу кеше: «Бар, чакырып кайт», — дигәч, мин, тиз генә ындырга җөгереп барып: «Өйгә әллә нинди бер кеше килгән, сезне чакыра»,— дигәч, алар хәзер кайтырга булдылар.

Бераздан ишектән әти белән әни килеп керделәр; мөсафир белән күрештеләр.

Чәй куелды. Бу юлы, кунак булса да, чәй янына нидәндер мине дә утырттылар вә, гадәткә хилаф уларак, минем алдыма бер шакмак шикәр дә куйдылар.

Әтинең: «Ни хезмәт илә килдеңез?» — дигән сөаленә каршы мөсафир: «Менә бу баланы алырга килдем», — диде.

Бу сүздән әти, бик гаҗәпкә калып: «Ничек ул? Ник син алырга килдең?» — дип сөальләр бирә башлагач, мөсафир бу рәвешчә сүзгә башлады: «Мин — Кушлавыч кешесе. Бу бала авылымызның имамының баласы. Без аны ничә еллардан бирле югалтып, кайда икәнлегеннән бихәбәр идек; менә хәзер таптык. Ул сездә икән. Җаек каласында аның атасы белән бертуган апасын алган җизнәсе бар. Менә шул җизнәсе, каенесенең болай кара кешеләр кулында йөрүен ишетеп, аны Җаекка үз катына чакырмакчы була. Менә мин быел, Җаекта аның кушуы буенча, бу баланы эзләргә чыктым, менә хәзер алып китәм».

Мөсафирнең бу сүзләренә әтинең дә, әнинең дә бик кәефләре китте: «Ярар менә, без икмәкнең поты фәләнчә кадәр кыйммәт вакытта аны 3–4 ел ашатып торыйк та, хәзер, эшкә ярар вакыты җиткәч, сиңа биреп йибәрик, имеш. Юк, булмас. Әгәр ул кардәше булса, ник аны әүвәлдә күрмәгән?» — кеби сүзләр илә бик нык тартыштылар.

---

*Бихәбәр* — хәбәрсез.

Ара-тирә әни дә: «Юк, бездә кешегә бирә торган бала юк!» — дип куйгалый иде.

Мөсафир Бәдретдин абзый[16]: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга, мин хәзер урядниккә әйтәм, әле без аны таба алмый йөрсәк, ул сездә икән. Мин сезне падсуд җибәрермен», — дип, авыл халкын куркытырга җитәрлек иттереп сөйләгәч, бичара әти-әни йомшардылар.

Бераздан минем тату тормаган әнием: «Җә, атасы, бирик инде; ахры, кеше баласы безгә булмас, Аллаһы сакласын, әллә ниләр күрербез», — дип, үкереп җылап та йибәрде.

Озакламый, җил басылганнан соң да бераз дулкынланып торган диңгез кеби, актык вә йомшак тартышу белән генә тартышкач, әти дә разый булды.

Иске-москы бишмәтләремне, тишек киез каталарымны кидереп, күп тә үтми мине арбага чыгарып утырттылар.

Әти-әни, бичаралар, һәр икесе егълаганнары хәлдә, мине басу капкасына кадәр озата бардылар.

Ахырда әни: «Онытма безне, онытма! Безне онытсаң, тәмуг кисәве булырсың», — дип, ахыр сүзен кычкырды да, без авылдан чыгып киттек.

Минем китү мәсьәләм бөтенләе ярты сәгать диярлек аз вакытта хәл ителгәнгә, авылдагы иптәшләр вә таныш-белешләр илә күрешә алмадым. Алар гафил калдылар.

Без юлга чыккач, күп тә үтми кич булып, караңгы төшә башлады.

Юлда Өчиле карьясенә бабайларга төштек. Анда чәй эчтек.

Бу гаиләнең һәммәсе мин күргәндәгечә бергә торалар, фәкать Саҗидә апай гына кияүгә киткән иде.

Чәй эчкәч, әллә нинди Югары Аты, Түбән Аты, Урта Аты авылларыны үтеп, төн урталарында үземнең туган авылым Кушлавычка барып кердек.

Юлда килә-килә, мин арбада шактый ватылган булырга кирәк, Бәдри абзыйның өенә кергәч тә, эреп йокладым.

Иртә белән торгач, үземне бер кара өй эчендә күрдем. Бу өйнең эчендә табак-савыт, кашык-чүмеч, камыт-эшлия кеби нәрсәләр генә булып, җиһаз-фәлән кеби нәрсәләр бер дә юк иде.

Чәй эчтек, Бәдри абзыйның Гайшә исемле зур гәүдәле, күк күзле, ачык кына йөзле бер хатыны, Камалетдин исемле 14–15 яшьлек бер угълы, вә Кәшифә исемле 12 яшьләрендә бер кызы, вә Нәгыймә исемле бер имчәк баласы бар иде.

Чәйдән соң бу өйдән чыгып, аңар каршырак салынган ак өйгә кердек.

---

*Гафил калу* — белмичә калу.

Бу инде мин кунган кара өйгә охшамый, стеналары сапсары нараттан, җиһазлары вә язу өстәлләре авыл кешесе өчен мөкәммәл диярлек иде.

Бәдри абзыйның амбарлары тулы ит, ярма, богъдай, арышларны күргәч, мин аны бу авылның иң бай кешеләреннән берсе икәненә хөкем иттем.

Тагы Камалетдин миңа, көз җиту сәбәпле яме киткән булса да, умарта оялары белән тулган шактый зур бакчаларын да күрсәтеп йөрде.

Мин инде, бер кергәч, бу ак өйдән чыкмас булдым вә шунда куна да башладым.

Кич белә китаплар актарганда, кулыма «Фәвакиһел җөләса» китабы төшеп, шуны укырга тотындым. Актыктагы шигырьләрен бик яратып укыйм вә аңларга тырышам, фәкать мин Кырлайда чакта тик «Газизә» вә «Сөбател гаҗизин»нәр генә укыганга, бу китаптагы оят сүзләргә гаҗәпләнәм вә, китапта шундый сүзләр дә була микәнни дип, үземә сөаль бирә идем.

Кайчакта мин, шул «Фәвакиһел җөләса» тәэсире илә, Гайшә абыстайның кер юган җиренә — кара өйгә барып, аның белән кычкырыша торган идем. Ул ирләрне мыскыллый иде, мин дә үз нәүбәтемдә хатыннардан көлә идем.

Кая барсам да, мине, мулла баласы дип, халык башка малайлардан аерганга, хәтта җыеннарда яшьтәш кызларым илә «так-каравыл» уйнау да миңа гаеп булганга, мин үзем дә үземне һәрвакыт мулла баласыча тотарга вә укыган китапларым илә гамәл итәргә тырыша идем.

Мәсәлән, берзаман, Бәдри абзыйларга килгәч, минем илә күрешергә Ситдикъ исемле, авылымызның шактый мөгътәбәр кешесе килде, үзе исерек иде.

Миңа килеп сәлам бирде — сәламен кайтармадым, кулын сузды — кулын алмадым.

Сәбәбен сорадылар. Мин шул вакыт «Бәдәвам»ның:

> Исереккә сәлам бирмә,
> Ул бирсә һәм син алма... —

дигән бәетен ярдым да салдым. Моңар бөтен Бәдри абзый гаиләсе гаҗәпләнүдән башка, минем бу диндарлыгым авылга да җәелде.

Бәдри абзый, мине өенә алып кайткач та, үзе бер эш белән Казанга китте.

Ул анда бер ай кадәр торган мөддәттә мин дә буш ятмадым. Камалетдин илә бергә авылымызның мәдрәсә шикелле бернәрсәсенә барып сабак укыдым. Күп вакыт кунып укырга да тугъры килә иде.

Хәзрәтләре, ахры, бик «кысып» укыта торган вә кешене

«гыйлем» итә торган кеше булган булырга кирәк ки, шул аз мөддәт эчендә дә мин аның көн саен әллә ничәшәр баланы эт урынына кыйнаганын күреп, калтырап торганым бар.

Качан да булса бервакыт бу хәзрәт таягының миңа да эләгү ихтималы мине куркытканга вә таң белән, шәкертләр белән бергә куылып, иртә намазына бару бик авыр булганга, эчемнән: «Ай, Бәдри абзый кайтса, тизрәк Җаекка китәр идем»,— дип көтә идем.

Берзаман Бәдри абзый кайтты. Миңа яңа бүрек, яңа киез ката, яңа бишмәт алып кайткан.

Мин бу яңаларны бик зур куанычлар илә кидем дә үземнең иске киемнәремнән бүркемне, бервакыт кайтып карармын дип, очырмага яшереп саклап куйдым. Бу да гаҗәп эшләремнән берсе булды.

Шуннан соң Кушлавычта берничә көн генә тордык та Бәдри абзый белән Җаекка таба юнәлеп чыгып киттек.

Бер тәүлек кадәрле баргач, Казанга килеп кереп (Печән базары тирәсе булырга кирәк), бер урынга туктадык.

Шул вакыт күрдек ки, безгә таба күзләре яшәргән, куллары җәелгән, сакалы агарып бетә язган бер кеше җөгереп килә.

Бу минем яныма килгәч тә: «Әле син теремени?! Анаң әле кичә генә сине төшендә күргән иде. Әйдә, өйгә алып барыйм; чәй эчәрсең, бездә кунарсың»,— дип, мине алып китте.

Өйгә барып кердем. Анда әни каршы алды. Бичара, сагынган икән, ул да елады.

Минем өчен хәзер чәй куелды. Әти хәрчәүнәдән пилмән алып чыкты; сыйландык. Миннән моңар кадәр ниләр күргәнемне сораштылар. Мин дә онытмаган кадәрене сөйләдем.

Бу ата-анамның мин аерылып торган мөддәттә, әтинең сакалы агаруы вә әүвәл Яңа бистәдә булып, хәзер Иске бистәгә күчүләреннән бүтән үзгәреш күренми иде.

Ул кичне шунда кундым. Иртәге чәйне эчкәч, әни мине ләгәнгә утыртып җуындырды. Яхшы кәләпүш һәм кыш көне барачак минем озын сәфәрем өчен кирәкле булган бер тире чалбар кидерде.

Ул мине нумиргә Бәдри абзый янына озатканда, тагы сагынмалык итеп, тәсбихләр вә «Мәрьям ана»лар бирмәкче булса да, мин: «Кирәкми, берсе дә кирәкми, мин бай җиргә барам», — дип, нидәндер кабул итмәдем.

Без торган нумир бик начар да, бик яхшы да түгел, уртача гына бер нумир иде.

Җаектан мине алырга килүче Алты-биш Сапый[17] дигән кеше әле Казанга килеп җитмәгән икән. Шул сәбәпле Бәдри абзый белән без бер-ике атна кадәр шул кешене көтеп яттык.

---

*Нумир (номер)* — кунак йортындагы бүлмә.

Ниһаять, безнең көткән Алты-биш Сапыемыз килеп, без торган нумир күршесенә төште.

Ул килеп берничә көн торгач, Бәдри абзый мине аның нумиренә күчерде дә үзе, миңа алты данә икешәр тиенлек 12 тиен акча биреп, авылга кайтып китте.

Мин Бәдри абзыйдан тагын бер генә көн торуын үтенсәм дә, аннан бер дә аерыласым килмәсә дә, ул мине төрле сүзләр илә җуатты-җуатты да китеп барды.

Ул киткәч, мин Алты-биш Сапый вә хатыны янында калдым.

Бу шәһәрдән килгән кешенең киемнәре вә сөйләшүе миңа ят тоела иде.

Мәсәлән, ул сүз арасында: «Мин — өлкән кеше», — дип ычкындырса, мин бу «өлкән» дигән сүзне һич аңлый алмый идем.

Алты-биш Сапыйның өстендә якасы вә җиңе камалы төлке тун булганга, «өлкән» кеше дип әллә шундый тун кигән кешегә әйтәләрме? дип тә уйлый идем. Соңыннан, Җаекка килгәч белдем ки, «өлкән» — «олугъ» дигән сүз икән.

Бәдри абзыйдан калган унике тиенгә тозлы балык — вобла һәм симәнкә алып ашадым.

Берничә көн торгач, Җаекка юнәлдек.

Мине, чыпталы чананың өстен каплап, Алты-биш Сапыйның хатыны алдына утырттылар да һичбер яктан сулыш алырга бирмәделәр.

Тик бер-бер авылга чәй эчәргә төшкәч кенә, иркенгә чыгаралар иде.

Мин никадәрле: «Җәяү барсам да, тышта, иркендә барам», — дип гозерләнсәм дә: «Туңарсың, җизнәң туңдырмаска кушты», — дип, мине чыгармыйлар иде.

Җизни бу Алты-биш Сапыйга Казаннан әллә нинди бер яхшы чана алып кайтырга кушкан икән, шул чана безнең артка тагылган һәм безнең алдан бара торган тагы төрле-төрле йөкләр төягән Җаек кешеләре булганга, без «абуз» йөрүе илә бардык. Шул сәбәпле ябык чана зинданында, мең төрле газаплар эчендә, тәмам унсигез көн булды дигәндә, кичкә таба Җаекка барып кердек.

Җаекта иң элек Сапый абзыйның өенә төштек. «Монда чәй эчик тә, җизнәңнәргә кичкә илтербез», — диделәр.

Кичкә таба, икенде-ахшам арасында, Сапый абзыйның җитәгендә җизниләргә киттем.

Юлда яшел чапан бөркәнгән бер яшь кенә хатын очрады, Алты-биш Сапый: «Бу — апаең, күреш», — дигәч, моның илә күрештем.

Җизниләрнең өе бер ун сажин гына булыр ераклыкта икән; капкадан кереп, биек-биек баскычлардан менеп, өйнең икенче катына кердем.

# КЕЧКЕНӘ СӘЯХӘТ

Бу ел апрель ахырында Казанның «Самолет» ширкәтенең «Тургенев» нам парахудына утырып, Әстерханга сәфәр иттем. Урыным 3 нче класста иде.

Парахуд эчендә кеше күп булса да, миңа яраргы, сөйләшеп утырырлык берәү дә күренми иде.

Эчем пошкач, «приличия»-фәлән рамкасына кысылмаган, прастуй 4 нче класс халкы арасына чыга идем. Вакыйган, анда чыгу бушка китмичә, бер хили заман карап торырлык күренешләр булгалый иде.

Әнә анда ике марҗа, бер шешә артыннан икенчене бушатып, аракы эчеп утыралар. Камыр кеби изелгәннәр, аракыдан тамаклары карылган, «Самокат»тагы Петрушка тавышы белән җырлыйлар. Арадан бер урыс, чыгып, гармун уйный башлый, теге марҗалар, торып, ава-түнә бииләр. Тавышка бөтен 4 нче вә 3 нче класс халкы җыела.

Кәефле мәҗлес иясе марҗаларның бу кадәр халык җыелуына эчләре поша башлый. Чөнки, кыяфәтләре вә тавышлары көленеч булганга, халык алардан көлә. Арадан бәгъзеләре төрле сүзләр белән мыскыл итә. Шул арада мәҗлескә яланаяклы бер хулиган килеп утыра. Сорап та тормый, салып куйган аракыны алып каплый. Башына киткәч:

Милая Маруся,
Будешь ли моя?
Куплю пуд картошки,
Лопай как свинья, —

дип, вәли нигъмәтләре исерек марҗага мәдхия җырлый. Халык шаркылдап көлә. Мин дә эчемнән бу кешенең хиссияте минем «Ялт-йолт»та язган «Нечкә хиссият»емнән[1] дә дәкыйкърәк икән дип уйлыйм.

Мин урыныма керәм. Манзара һаман төрләләнеп кала. Минем урыннан җырак түгел бер эскәмиядә җуан-җуан урыс мещаннары белән мещанкалары бар. Кайсы чәй эчә, кайсы сузылып ята; шунда бер борынын сөртеп утырган калын марҗа, үзе белмичә, яңлыш яулыгын төшереп җибәрә. Җуан урыслардан берсе аңар хитабән:

— Мадам, платок уронили, — ди.

Марҗа аңышып яулыгын ала.

---

*Вакыйган* — чыннан да.
*Бер хили заман* — байтак вакыт.
*Вәли нигъмәт* — сыйлаучы.
*Дәкыйкърәк* — нечкәрәк.
*Хитабән* — эндәшеп.

Марҗаны тәнбиһ итүче урыска икенче берсе игътираз итә:

— Ник аңар «мадам» дисең, ул бит дама түгел — баба, — ди.

Тегесе:

— Соң, дама белән баба арасында ни аерма бар?

Әүвәлгесе:

— Дама бывает узкая, а баба — широкая, — дип тәфсил итә. Халык көлешәләр. Минем дә күз алдыма «Державин»да йөргән нәзек дамалар белән Балык базарында куас сатучы юан бабалар килә.

Мин дә көләм.

Бераз ятып торган булам; йокы килми, күңелсез.

Тагы 4 нче класска таба аяк атлыйм. Мин чыгып барганда, бер зур корсаклы урыс, бармагы белән төртеп, әллә кемнәргә мине күрсәтә:

— Смотрите: барышня! — ди.

Минем хатыннар чәче кеби йомшак, озын чәчем җилкәмә салынып төшкән. Кулларым гадәттән тыш нечкә. Гәүдәм дә нәхиф булганга, чынлап та «барышня»га охшаганмындыр шул.

4 нче класста ары-бире әйләнеп җөрим, үзгәргән хәл юк. Баягылар баягыча.

Әйләнеп 3 нче класска кермәкче булсам, класс ишегендә теге зур корсаклы урыс тора. Ишектән мине кертми.

Һаман баягыча миңа төртеп:

— Смотрите: барышня! — ди.

Минем ачуым килә башлый да, зур корсаклыга карап:

— Дело не в том, — уберите-ка сперва ваше громадное брюхо! — дим дә, аны читкә төртеп, көчкә урыныма кереп утырам; бераз ятып йоклыйм.

Самарга җиттек. Мин Самарга кадәр чәй-шикәрне, тәмәкене, булканы — һәммә кирәк-яракны буфеттан алып килгән идем. Ул, бик кыйбат булганга, минем кесәмне шактый бушаткан иде.

Әле берничә сәгать кенә элек танышкан бер татарым белән Самарга чыктым. Анда тау башында утырган бер татар хәрчәүнәсенә кердек.

— Хәзер пешкән пилмән бармы?

— Юк, көтеңез, бик тиз хәзерләп бирәбез.

Минем бар курыккан нәрсәм парахудтан калу булганга, көтәргә разый булмадым. Аннан чыгып, пристаньдагы вак ки-

---

*Тәнбиһ итүче* — искәртүче.
*Игътираз итү* — каршы килү (бәхәс итү).
*Тәфсил итү* — аңлатып бирү.
*Нәхиф* — арык.

бетләрдән чәй-шикәр, тәмәке, кумәч (үзем Әстерханга кадәр җитәр дип уйлаганча) бик күп итеп алдым.

Пристань төбендә:

— Горячие пельмени! Горячие, хорошие!* — дип, бер марҗа кычкырып утыра.

Якыннан уздым: чынлап та, чиләгеннән җылы пар чыга. Ач кешенең борыны гашыйк булырлык дәрәҗәдә тәмле ис тә килә. Марҗаның янына барып:

— Сколько стоят пельмени, бабушка?** — дидем.

Егермесе биш тиен икән. Мәзкүр микъдар пилмәнне бер кечкенә касәгә салып бирде. Ашадым. Бик тәмле булды. Әбине чорнап алган рабочийлар вә әллә нинди хулиган кыяфәтле кешеләр:

— Мин баядан бирле көтәм. Миннән соң килгәннәр ашап киттеләр. Миңа төбен генә калдырасың,— кеби сүзләр белән кычкырышалар иде.

## МИЧ БАШЫ КЫЙССАСЫ

### *(Баштан уткән бер эш)*

Мин быел 29 сентябрьдән үк салкынлыктан зарлана башладым. Шуннан бирле икәнлеге язып ташлаган бер бәетемнең төбендәге тарихтан беленде. Бәет шушы иде:

Номер салкын, якмыйлар бит, арка туңа,
Иртә берлән, киям дисәң, яка туңа;
Авыр да соң иртә берлән тышка чыгу,
Чыкмый хәл юк, чыгасың шул ката-туңа.
Җәйләр үтте, җиттек инде октябрьгә,
Җылылык юк җирдә һәм дә күктә бер дә,
Сентябрьдә син дә бер, ди, мин дә бер, ди,
Миһманнарның якмаучыга үпкә бергә.
Хөкем итмим, Ходай кыйлыр үзе судын,
Кайгырмый бай, күтәргән дә ята ботын;
Акчам янга калыр, ди ул, якмый торсам,
Барыбер бит җәһәннәмгә үзе утын!

*Туңучы*
*1911 сәнә, 29 октябрь*[1]

Бу бәетләр актык тамчы күз яшьләре булган, ахры: озакламый номерны яга башладылар. Ләкин күзләр беткәч, кояш

---

* Кайнар пилмән, кайнар, әйбәтләр.
** Әби, пилмән кыйбат торамы?
*Мәзкүр микъдар* — шулкадәрле.
*Миһман* — кунак (номерда торучы).

булудан сиңа ни файда? Миңа шул якмый торган арада, бизгәкнең шәбе эләккән. Бинаән галәйһи мин, җылылык-фәлән сизмичә, көне-төне туңуда идем. Бизгәк, мин иртәге чәйне эчеп бетерер алдыннан (сәгать беренче яртыда), көтелгән кадерле кунак шикелле, миңа рәхим итеп, тәнемдә күпме тамыр бар исә, һәммәсен селкетеп, мине хәрәкәттәге поезд шикелле итә иде. Бу дерелдәү никадәр кәеф җибәргеч нәрсә булса да, мин аңар әһәмият бирмичә, чәемне дерелдәгән кул белән ясап эчә бирә идем. Тик бу дерелдәү вакытында күрше марҗаларфәлән килеп керсә, һәм алар минем кул дерелдәүдән купкан «стакан диңгезе»ндәге дулкынны күрсә генә, бүлмәмдә тавыш куба иде.

— Батюшки! Что с тобой?

— Лихорадка, разве не видите?

— А у доктора был?

— Пусть сам придет!

Мин, бигрәк каты тәгассыбтанмы, нидәндер дөнья күрә башлаганнан бирле медицинага ышанмый идем вә һәр халәткә «нервы расстроены» дигән докторларны һәр авыруны кизүдән диюче әбиләр белән тиңләштерә идем. Шунлыктан, тетрәү көн саен дәвам итсә дә, доктор дип әйткән кешене хәтеремә дә кертмидер идем. Минем хәлне белгән иптәшләр дә миңа күп даруның исемен әйтеп карадылар. Әмма мин лям-ялтәфит. Авырсам, бүлмәмдә бишмәтме, юрганмы, казакиме — һәммәсен бөркәнеп ятам да бер сәгать кадәр заманнан соң тирләп торам. Тир белән авыру чыккан була, чыкса да мине тәмам алҗыткан була иде.

Көннәрдә бер көн хәстәм килеп, баягы чүпрәкләр астында хәзан япрагы кеби дерелдәп ятканда, берсекөнгә рамазан гаеде икәнлеге исемә төште. Абау, Ходаем! Мин гаед көнне дә шушылай дерелдәп ятармынмы? Юк, бу һич тә ярамый.

Бар күңеллелек бөтен дөньяда[2], бар бер ямь бүген!
Нәрсәдән бу? — Билгеле: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!
Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген! —

дип, берзаманнарда җырлаучы үзем түгел идемме? Юк, бәйрәм хөрмәтенә мин докторга да ышанам дип уйлап ятканда, ишек ачылып, бер иптәшем килеп керде.

---

*Бинаән галәйһи* — шуңа күрә.
*Тәгассыб* — кирелек.
*Лям-ялтәфит* — әйләнеп тә карамыйм.
*Хәзан япрагы* — көзге яфрак.

— Иптәш, кара әле. Син нәрсәне бизгәктән файдалы дигән идең?

— Аспиринны.

— Зинһар, иптәш, шуны алып кайтсана!

Иптәшем даруны алып кайтты. Менә сиңа берсекөн! Гаед җитте. Гаед көн мин, йокыдан торып киенгәч тә, бер стакан җылы су белән аспиринны эчтем. Бөтен Казан буе өстерәлеп йөргәнем визитнең берсендә мин тирләдем, шапырма тиргә баттым. Менә аспирин нишләтә! Ул көнне, иртәгесен, аның иртәгесен мин һаман аспирин эчәм. Бизгәк килми иде. Гаед бетте. Корбан бәйрәме җитеп, ул да үтте. Мин һаман бизгәкне, ул килде исә, аспирин таягы белән кыйныйм. Димәк, бизгәк тә аспирин, бизгәк тә аспирин!

Беркөнне бер якын иптәшем килеп керде дә:

— Иптәш, әйдә фәлән мөсафирханәгә күчәсеңме? — диде.

— Күчәм, — дидем.

Ул мөсафирханәдәге миңа булачак номерны барып карадык. Бу номер әүвәлге номерым кадәр өч бар. Түшәме биек, умывальнигы бар. Әлхасыйль, элек торган номерыма караганда җәннәт!

Тора башладым. Элек өстәлем иң түрдәге тәрәзә төбендә иде. Андагы сыростька сабырым бетеп, өстәлне ишек төбенә күчердем.

Бу әүвәлгедән дә начар. Монда бөтенләй зәмһәрир. Бу көналаш бөтенләй үк ягылмый. Мич ягучы урысны чакырып:

— Почему вчера не топили?— дидем.

Ул колагыма гына:

— Дров не было, — диде.

«Ярабби! Монда да мине кыш көне очырмага элгән каз кеби катыралар!» — фикерләренә киттем. Монда утын булмауга мин тәгаҗҗеб итми идем, чөнки бу номерның нәрсәсенә генә карасаң да, аның фәкыйрьлеген күрсәтә иде. Айлап торучылар булса да, күбесе болайрак. Залына кеше керми. Анда музыка куйганнар. Бөтенләй мужик урыслары күпер суккан төсле уйный.

— Наплевать на все, — дидем дә, беркөнне ямщик ялладым да авылга киттем[3]. Монда миңа кечкенә генә, нараттан салган сандык шикелле җыйнак, матур бер өй бирделәр. Көненә ике мәртәбә ягалар. Һавасы яхшы, җылы, күңелле. Монда бер 15 көн эчендә 29 сентябрьдән бирле күргән салкын михнәтләре һәм юлда килгәндәге адашулар, туңулар — барысы да онытылды. Михнәт үтсен генә, адәм баласы тиз оныта

---

*Әлхасыйль* — кыскасы.
*Тәгаҗҗеб иту* — гаҗәпләну.

аны. Беркөнне мин үземнең борадәр муллам белән, тәмам терелгән кеше шикелле, күтәренке бер рух белән авылымыздан ун чакрым җыраклыктагы базарлы авылга киттем. Көннең җылысын сайлаган идек. Бер дә туңмыйча гына барып җиттем. Фатирчы бер карт урыска төштек. Монда бүтән авыл муллалары да бар икән, алар белән сөйләшеп чәй эчтек. Ни сөйләшкәнемезне язмыйм әле. Муллалар һәм минем борадәр әйберләр алырга базарга чыгып киттеләр. Без карт урыс белән икәү генә аулак өйдә калдык.

Бабай белән без элек минем авыруым тугърысында, аннан күчеп бүтән мәсьәләләр тугърысында сөйләштек.

Бабай миңа Александр Второйның крәстияннәргә манифест укып торганын буяп ясаган бер рәсем күрсәтте. Мин карадым да:

— Добрый царь! — дидем.

Бабай терелде. Хөрриятькә кадәр солдатларның илле биш яшендәге карт булып, үзләрендә жизнь калмагач кына өйгә кайтканнарын, хөрриятькә кадәр мужиклар җәйдә иң элек алпавыт игенен урып, тәмам урнаштырып бетергәч кенә, үз җирләренә тотынуларын, вакыт аз калганлыктан, нинди начар һаваларда да кырда эшләргә мәҗбүр булуларын вә алпавытның, ачуы килгән саен, крәстиянне розгалавын вә солдатка тотып бирүен, вә башка золымнарын да бер-бер бәян итте.

— Ә хәзер без кырда үз игенемез бар вакытта, алпавыт көненә алтмыш тиен бирсә дә, аның кырын эшләмибез; алпавыт ялына, бичара, — дип, кәефе килеп, кычкырып көлеп җибәрде.

Ул көлгәнгә, мин дә көлдем. Бабай тагы да кызып сүзгә кереште:

— Менә хәзерге көндә студентлар һәм жидләр падишаһымызны безгә хөррият биргән өчен яратмыйлар. Менә әле, ничек исеме, Киевтә бер жид министрны үтерде[4].

Бабай министр һәм үтерүченең фамилияләрен белми икән, мин әйтеп бирдем. Шул вакыт, белмим нәрсәдән, минем бабайның кәефенә тагы да кәеф кушасым килде дә болай дидем:

— Ие, ул жидләр — начар кешеләр. Аларны Русиядән куасы иде.

— Да, да!

— Без — руслар белән татарлар — һәрвакыттагы кеби, тату гына, честный гына алыш-биреш итеп тора алабыз. Әмма жидләр үзләренең биниһая хәйлә вә ялганнары белән безне алдый-

---

[1] *Розгалау* — суктыру.

[2] *Биниһая* — чиксез күп.

лар вә бөтен сәүдәне диярлек кулдан алып баралар. Бозык халык. Безнең Коръән аларны «мәгъзубе галәйһи» дип атый.

— Дөрест, дөрест.

Шул вакыт минем аркамда суык чымырдап тора, вә мин ихтыярсыз, хәзер генә сүнеп, капкачы ябылган мич янында торып кына бабай белән сөйләшә ала идем. Бераздан, тышка да чыгып кергәч, суык, бөтенләй минем тешләрне шакылдатып, Казандагы рәвешчә бөтен тамырларны дерелдәтә башлады.

Бабайдан:

— Ятып торырга бер урын булмасмы? — дип кенә йокларга сорап, авыру килгәнне әйтмәдем.

Ул:

— Хәзер генә морҗа ябылды, мич башы бик җылы,— дип, миңа анда менәргә киңәш бирде.

Менеп яттым. Минем тәндәге суык үзеннән көчлерәк эссе белән очрашканлыктан, миңа шундый рәхәт хасил булды ки, тәгъриф мөмкин түгел. Әгәр бай булсам, бабайга аның мич башында яткан вакытымның минутына бер тәңкә бирер идем!

Мич башы рәхәт. Тән пешәргә җитә, аның саен шәп. Шулай рәхәтләнеп ятканда, өченче ел ук бик шәбәеп язган бер шигыремнең бәгъзе сәтырлары исемә төштеләр дә үз-үземнән кычкырып көлә башладым. Шигырь ушбу иде:

Булмамын, юк, картайсам да, чын карт кеби,
Утырмам тик юк-бар теләк тели-тели;
Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына,
Шигырьләрдән килер миңа кирәк җылы.

Мич башына менмәм, дим, имеш; менмәссең, аркаң туңса! «Менмәмен мин, Ходай кушса» дип, «Ходай кушса»сын да язганмын ләбаса. «Бу нигә көферлегем җитте икән!» дим дә кычкырып көләм. Көлдем-көлдем дә:

— Әйе, шигырь башка да, дөньяны әйләндерүче чыгыр башка,— дип, җитди кыяфәт алып, ишегалдындагы чанага чыгып утырдым. Кайтып киттек.

---

*«Мәгъзубе галәйһи»* — «каргалган зат» (Алла тарафыннан).
*Тәгъриф мөмкин түгел* — сөйләп аңлатырлык түгел.
*Бәгъзе сәтырлары* — кайбер юллары.

# КАЗАНГА КАЙТЫШ

## I

Авылны күпме мактасаң да, аның калада торып өйрәнгән кешене разый итмәслек урыннары табыла икән. Бигрәк кыш көне һәм быелгы кеби ачлык елда. Һәр көн димәсәм дә, бик җыш буран. Урамга да чыга алмыйсың. Муеннан кар. Каты буранның икенче көнен безнең авыл башында остабикәсе белән кунактан кайтучы бер мулла аты белән карга баткан иде. Атны чыгарганчы өшемәсен дип, безнең авыл мужиклары мулланың остабикәсен, үз чаналарына утырган көе, безнең өйгә тартып кайтардылар. (Үзен Япония извозчигында кеби хис иткәндер!)

Быел авылда батканнар да, өшегән-катканнар да хисапсыз булды (ачлык, салкын, ялангачлык — өчесе берьюлы һөҗүм иткәч, адәм түгел, дию дә чыдамас).

### БӘЕТ

Бу сәнә ачлык җыланы чын халык бәгърен ашый!
Кит, китап! Сабрит, дип әйтмә, — ул халык көчен ашый!

Бу сәнә ачлык сәбәбеннән урманнарда, аулакларда караклар күбәйгән, дип тә күп сөйлиләр. Безнең якта, мәгълүм Чыпчык, Балавыз урманнарында фәлән кешене үтергәннәр, фәлән байны талаганнар, дигән хәбәрләр атна саен ишетелә. Ләкин мондый хәбәрне сөйләүчеләр һич тә чынга охшатып сөйли алмыйлар.

Мәсәлән, берәвенең нәкыле: «Әлләкеметдин бай Чыпчык урманы аркылы калага кайтып бара икән, каршыларына өч карак чыгып, ат башыннан тотканнар. «Малыңмы, җаныңмы?» — дигәннәр. Ләкин байның кучеры таза җегет булган». Равинең нәкыленчә, әллә кайсы авылда шактый «җибәргән» дә булган, ди. Менә шул кучер, повозкадагы нуктаны алып, каракларны уңлы-суллы яңакка кыйный башлаган. Караклар качканнар. Ләкин повозка кузгалып киткәч, байның артыннан әллә ничә мәртәбә «либарбир»дан атканнар. Ни булса булган, бай сау-сәламәт калага кайтып җиткән. Бу хикәяне ишеткәч, кучер минем күңелемдә бер Сәет Баттал[1] кеби булып калды. Кавказ тауларындагы «тотылмас» Залим ханны[2] тотарга да шундый бер кучерны нукта күтәртеп җибәрү тиеш кеби күренде.

Нәкыле болай булса да, факты алай түгелдер дип, мин иртәгә иртүк шәһәргә чыгачак сәфәрем өчен күрше агаемыздан бер алтатар сорарга кичтән ният итеп яттым.

---

*Нәкыле* — сөйләве.
*Равинең нәкыленчә* — сөйләүченең сөйләвенчә.

Бу мин — алтатар алачак агай, табган үткен, бәдәнән көчле, үз сүзеннән күчми. Бер алачыгы бар; тимер-чуенны үзе эшли, авылдагы вә әтрафтагы сәгатьләрне ул төзәтә. Авылның хөкүмәт эшләренә дә катыша, укый-яза белә. Үз исеменә алдырмаса да, Казаннан «Вакыт»-фәлән кеби гәзитәләр алып кайткалый. Бер тарафтан кибет тә тота. (Бер-ике ел гына элек бу авылда кибет булмаган. Нинди һавага да карамыйча, күрше 3 чакрым җиргә җөгерергә мәҗбүр булганнар.) Менә бу кеше инде сугыш коралларын да карый, мылтык, алтатарны да карый, тубыннан да качмый. Ул элек гармун, скрипка кеби уен кораллары төзәтсә дә, хәзер аны ташлаган. Чөнки мәзкүр кораллар аркылы аның йортын яшьләр, никрутлар басып, картаеп бармакта булган һөнәрчене тынычсыз иткәннәр.

Минем алачак алтатарым да, минемчә, шунда иде. Ул бирер идеме, юкмы — анысын белмәдем.

Әгәр авылда бу адәм кеби биш-алты гына кеше булса да, авыл күптән инде тәрәкъкый иткән булыр иде. Яңа укулар мәйдан алыр иде.

**БӘЕТ**

Мәдрәсә дип нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе,
Нәкъ эче азган мөрид, мәҗнүн ишаннар хилкасы.
Чәйниләр монда җирәнгеч әллә нинди мөһмәлят,
Яшь гомерләр мөһмәлят чәйнәп була монда һәлак.
Кайсысы «каптырку» ди, һәм кайсысы «кәбтерку» ди;
Чорт ява знат, нәрсә ди, «сентерсу» ди, «саттырсу» ди!
Кыш буе шул мөһмәлятне ач төя төсле күшәп,
Яз көне туктый укудан һәр күсәк угълы күсәк.
Алларында шунда да Коръән була һәм Әфтияк,
Буш түгел букча — китергәннәр аны көчләп төяп.
Кул керенә былчыраткач Һәфтиякнең һәр битен,
Уртасыннан капкалап, тәмләп кимергәннәр читен...

Читтәге бик күп өяздә, күр, авыллар яктыра,
Пар, тату йолдыз кеби, школ белән мәктәп тора.
Бу ике дуст, берсенә чөнки аларның берсе тиң,
Бертигез тәгълимнәре дә: берсе — дөнья, берсе — дин.
Ва әсәф! Ачлык вә коллыктан бүтән һич бездә юк.
Шул гаҗәп: ник бу егерменче гасырда (йөз дә) юк!

---

*Табган* — табигате белән.
*Бәдәнән* — гәүдәсе белән.
*Мәзкүр* — әлеге.
*Мәҗнүн* — юләр, акылдан язган.
*Хилка* — түгәрәкләнеп утыру.
*Мөһмәлят* — буш, файдасыз нәрсәләр.
*Тәгълим* — укыту, өйрәтү.
*Ва әсәф*! — Ни үкенеч!

Әлкыйсса, инде шигырь язудан туктыйм. Чөнки мине күптән инде, башына сөртергә эзләпме, май таба алмаган бер «критик» сүнгән шәмгә охшатты. Мәхмүт бай мәрхүм кантурында ташландык майлар беткәндер шул!

Шулай да, ягъни әлегә шигырь язмый торсам да, җырлаудан тартынмыйм:

Җырласаң да, җегет, ачы җырла,
Уяу җаткан кызлар җокласын;
Тәрәзәләр ачтым, гөлләр сачтым,
Асыл кошлар килеп чүпләсен.

Әле каләмне куеп торып, кулыма карадым. Тырнаклар Шүрәленеке шикелле булган. Болай ярамый, мин аларны кисәм, һәм һәрвакыт, һәр җирдә «Сөю — сәгадәт» язган кулны, Аллаһыдан оялмый, бәндәдән кызармый: «Кул кисеп бәхәсләшәм», — дип фаш иткән бер критик[3] белән мин «тырнак кисеп бәхәсләшәм». Чөнки Шүрәле тырнагы бары «Ялт-йолт»та гына булып, теге критик кулы кеби, теләсә кайда сузылмаганга, кулдан кыйбатлырак инде. Минем белән бәхәсләшүчеләр дә тизрәк табылыр. Пәке дә үткен икән.

«Бәшири мырауламый башлады» — тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Укмасый порнографияләрен сирәкләндерде» — тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Сәгыйть белән Тукай сүнгән шәмгә охшый» — тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Фатихның «Хәят»ы милли роман түгел» — тырнак кисеп бәхәсләшәм.

«Гаязны шагыйрь дисәләр, третейский судка бирәм» — тырнак кисеп бәхәсләшәм.

Ун тырнакны кисеп тә бетердем — бәхәс тә тәмам булды.

«Әгузе биллаһи минәшшәйтан иррәҗим; бисмиллаһ иррәхманир рәхим»*. Тырнакларны, кәгазьгә төреп, стена җарыгына куйдым.

## II

Иртәнге сәгать алтынчы. Без мулла белән Казанга сәфәр өчен чана түренә чыгып утырдык. Кучер — кучерда. Җул тып-тын. Алдымыз ачык, бер дә җил исми. Әкрен генә исә калса да, каты кар кузгалмаслык. Тик ат борыныннан чыккан сулыш кына минем күземә кырауча кеби күренә иде. Шактый җир киттек. Иптәш безнең алтатар алмаганны искә төшерде

---

* Таш атып куылган шәйтаннан, и рәхимле, шәфкатьле Аллам, үзеңә сыенам.

*Әлкыйсса* — озын сүзнең кыскасы.

*Кырауча (карамчык)* — томанлы кара нокта.

дә: «Хәер, чана төбенә бәйләгән күсәк бар әле!» — дип гыйлавә итте.

Минем күз алдыма Чыпчык урманы һәм безнең күсәк чишеп алганны сабырлык белән көтүче пычаклы караклар килделәр. Көтсәләр дә гаҗәп түгел, чөнки кыш гаҗәеп мәүсим ул, «волшебница-зима» ул. Кышның суыгы белән кайчакта кеп-кечкенә колагыңны чабата кадәр ясый алган* Аллага безне каракларның куллары каткан чакка тугъры китерүе дә мөшкил түгелдер.

Юлда әллә нинди гаҗиб, тыштан караганда мөһмәл кеби күренгән исемдәге авыллар очрый. Мәгънәсе мәгълүм Тимерче атлы авылны да чыктык. Бу авылның мулласы «Әннәсолул хәдидә»че һәм әллә нинди исемнәр белән осуле җәдидәгә каршы китаплар чыгарган каһәрмане дин икәнлеген сөйләделәр. Авылны дикъкать беләнрәк карадым. Күрдем ки, моңарча килгән авылларның һәммәсеннән ярлы, һәммәсеннән чокырчакырлы. Өйләренең һәммәсе карчык кеби бөкрәйгән, кайсы ачык, кайсы тишек. Авылның тыш ягында дикъкать итәрлек хәл: бер данә диярлек арыш, богъдай кибәне булмаса да, печән кибәне бик күп дәрәҗәсендә. Моны күргәч: «Мулласы «Дин вә мәгыйшәт»че булган бу авылның халкы да печән ашый мәллә? Һәм «Дин вә мәгыйшәт» айгырларына печән шушы авылдан доставить ителәә микән әллә?» — дигән фикерләр килде.

Көн суык. Аяклар туңа. Безнең чәй эчә торган Чыпчык — һич шунда җитеп булмый. Әллә без барган саен, Чыпчык еракка-рак оча бара?!

«Көлле атин карибен» мәаленчә, ахырда Чыпчыкка җиттек. Чишендек, чәй эчтек. Бүтән язарлык нәрсә күренмәде. Тик бер ямщик кына, «шәйтанны коткарырга барам» дип, әллә кая барып, эчеп, кәефләнеп кайтты. Аның эчүе түгел, шуны «шәйтан коткару» дип тәгъбире көлке тоелды. Бу сүз минем башта бәгъзе хыяллар кузгатканга, аны үткән номер «Ялт-йолт»ка рәсем итеп ясарга бирдем.

Чыпчыктан сәгать көндезге бердә чыгып киттек. Теге куркынычлы урман алдыбызда мәһабәтләнеп тора иде. Барып кердек. Ләкин бердән — көндез, икенчедән — олугъ юл атлар белән тулы булганга, күсәк түгел, таяк та кузгатырга тугъры

---

* Өшү сәбәпле зурайган колак белән Алланың кодрәтен исбат иткән бер шигырь идарәбезгә килгән иде; шуннан икътибас. *(Г.Тукай искәрмәсе.)*

** «Һәр киләчәк якын» сүзе буенча.

*Гыйлавә иту* — өстәү.

*Гаҗәеп мәүсим* — елның искиткеч вакыты.

*Гаҗиб* — искиткеч.

*Мөһмәл* — мәгънәсез, мәгънәсе билгесез.

*Каһәрмане дин* — дин каһарманы.

килмәде. Менә Киндерле авылы. Казан күренә. Менә без кич белән гаять биек «Швейцария» тавын[4] менәбез. Корт күк урмәлибез. Мендек. Өйләргә ут алынган. Күк — йолдызлар белән, шәһәр фонарьлар белән бизәлгән. Әле сәгать 7 генә. Кибетләр ачык. Урамда хәят бөтен; «тең-тең» дип шалтырап, эче тулы кешеләрен якты тәрәзәсеннән күрсәтеп, Бельгия ширкәтенең «барабызы»[5] — трамвай һәм безнең татар ширкәте «барабызы» — Гайфулла агай урам уртасында чабышалар иде.

## III

Авылдагы тәфәрред, андагы тынлык миңа тәмам сөекле күренгәнгә, мин, Казанга кайткач та, шулай япа-ялгыз тору планын корган идем. Фәкать бердәнбер карчыгы булган тыныч фатирда торырга, бер җиргә дә чыкмаска, берәүне дә кабул итмәскә, фатирны да Подлужный тирәсендәрәк эзләргә, ашарга да йокларга, укырга да язарга, сукранмый гына авырырга карар биргән идем. Подлужныйгук китмәсәм дә, «Йолдыз» әйтмешли, «Икенче чокырский» урамда бер бүлмәгә күчтем. Апалы-сеңелле ике марҗа-хозяйкаларым. Мещанкалар, кабахәтләр, мещанкалар.

Максим Горький укыганда — шуларга нәфрәтем,
Кнут Гамсунны укыганда — шуларга ләгънәтем.

Моннан ике ел элек бер мещанкага фатир өчен ай ярымга акча түләп, шуларны сөймәгәннән өйдә өч кенә кич кунганымны оныткан кеби, тагы шуларга барып эләктем.

Айга 8 тәңкә, эчендә аш пешерү дә бар. Итне җумыйлар. Чи иттереп китерәләр. Ашның тозы юк, тозы күп. Чәйнең чүбе тәүлекләп тора. Чынаяк сарыга каткан. Өстәлең чүплек төсле. Кергән көнне: «Иртәгә караватт кертәбез», — диделәр. Бер атна, буш бутылка төсле, идәндә аунадым, һаман караватт юк. Ана мәчеләр кеби, көне-төне югалалар. Самавырны да бүтән квартирантлар куя. Беркөн сөйләшкәндә, маймыл кеби кыйланып, сүз саен рожа алыштыра торган, авызында алгы бер теше юк хозяйкамны күреп: «Когда у вас кровать будет?» — дигән идем. Ул, әүвәлге вәгъдәсен инкяр итеп, үзенең караватт сатып ала алмаячагын, ярлылыгын мыгырдарга тотынды. Шундук, ялганын тыңлап бетермичә, яныннан качып, иптәшем белән номер эзләргә киттек.

Номер таптык. Әмма яхшы, әмма матур! Исеме дә «Яктылык», эчендә нур. Ул җиһаз! Караватның дүрт читендә — дүрт ялтыраган гөмбәз. Көзгесе дисәң, кыргыз сахраларында ком арасында ярсыз гына җәелгән саф күл шикелле. Ишек ак

*Тәфәррред* — ялгызлык.

сәдәфтән ясалган кеби. Җуынгыч — мәрмәрнең нәгызе. Язу өстәле бордовый төсле сукнолы, әллә ничә тартмалы. Паркет идәннәре адәм угылы аяк белән басарга оялып, күкрәге белән генә шуарлык. Стеналар әллә нинди шиколад төсле перәннектән коелган кеби. Әлхасыйль, «тәгърифе мөхаль». Әмма «ля нөсәллиме» дию — кариэмнең иркендә.

## IV

Бу реклам төсле мактау, дисәңез, минем «шүрәлийский девизем»:

Теләрсәң кемне сүк син яки макта,
Берәү берлән дә булма иттифакъта, —

дыр. Кич белән тугъры өйгә кайтып, дәшми-тынмый, әйберләрне «барабыз»га чыгарып төйи башладым. Задатка акчамны сорый башлагач, теге ике марҗа, задатканы кайтармау юлында булырга кирәк, шулкадәр колак төбемдә чәрелдәп кычкырырга тотындылар ки, тиз генә колакларны тыгып, актык әйберемне күтәреп, көчкә качып өлгердем. 3 тәңкә янды.

Номер. Алдан бер айга түләп, үземнең шушы матур урында тыныч кына тора алачагымны хис итү кадәр татлы минутларны оныткынмындыр инде. Бер кич кундым. Иртә белән номер үземә бертөсле матур. Кич белән электрик яктысында тагы бүтәнчә гүзәл. Икенче кич кундым, рәхәт йокладым.

Өченче кичне, мин сиңа әйтим, язу эшләрем белән төнлә утырадыр идем, үземне хикәят китапларындагы «кергән кеше сәламәт чыкмый» торган пәриле җортта кеби тойдым. Әллә ниләр кытырдый. Дикъкать итсәм: күселәр! Ах, Алла дошманнары! Ах, бәндә дошманнары! Ах, генерал Толмачев[6] дошманнары! Алар минем комод эчендәге азыкларымны кимерәләр. Язудан туктадым. Күселәр болай да гасаби булган минем тәмам канымны бозалар. Юк, язып булмый. Аптырагач, утны сүндереп йокларга яттым. Яныма, күселәр тавышланса, комод өстенә сугып аларны куркытырга дип, юл каешы алдым.

Күзне генә йомасың, караватка каршындагы комод тартмасында күсе кытырдый. Шикәрне көл итә. Булкины кимерә.

---

*Сәдәф* — энҗе кабырчыгы, перламутр.

*Нәгызе* — яхшысы, әйбәте, гүзәле.

*Әлхасыйль, «тәгърифе мөхаль»* — кыскасы, «сөйләп аңлату мөмкин түгел».

*Ля нөсәллиме* — ышанмыйбыз.

*Кариэ* — укучы.

*Иттифакъ* — союз.

*Гасаби* — нервлы.

Аптырагач, каешны алып, бар көчем белән комодка сугам. Аз гына тына. Күзне генә йомасың, тагын шытырдый. Тагын сугам, тагын сүгенәм. Аптырагач әйтәм: «Әй, карак! Беләм инде, син, бичара, ач үлмәс өчен мондый кыюлыклар илтизам итәсең; соң, әкренрәк ашасаң булмыймы инде? Мин синнән аш кызганмыйм, чөнки мин ашны син җитә алмаслык урынга яшерсәм, ачлык сине минем колагымны вә борынымны кимерү кыюлыгына да мәҗбүр итәчәк», — дим. Ләкин: белә этәч синең хәрфе җәреңне![7] Ул һаман үз эшендә. Менә сиңа матур номер! Иртә белән ак майда да күсе тәпиләре эзен күрдем. Юк, моңар чыдар хәл юк, китәм, бүгеннән үк песи эзләргә китәм!

## V

Иртә белән «барабыз» белән барам. Ат очрый — песи очрамый, эт очрый — песи очрамый, кәҗә очрый — песи очрамый. Мөхәммәтҗан хафиз очрый — песи очрамый. Зур корсаклы татар байлары очрый — песи очрамый. Ул көнне кичкә кадәр йөрсәм дә, песи табалмагач, номерыма песисез кайтмаска булып, кунарга Әрмәнскидәге иптәшләремә киттем. Йокыга яттым. Менә кандала! Менә кандала! Һәр чәнчүендә бер кашык кан ала. Торып ут белән карасам: ак мендәрнең тышы, гайре мөтәнаһи вак үрнәк белән чигелгән кеби, бихисап кандала белән тулган! Йокыдан өмид өздем. Иртәнге сәгать сигезгә кадәр ут белән утырып, өстәлдәге һич бүтән чакта кулга да алмаслык чепуха китапларның һәммәсен укып чыктым.

Минем йөрү оборотым болай булды: күседән качып, песи эзләргә чыгып, табалмыйча, кандала ияртеп кайттым...

Башыма шәп фараз килде. Мин үзем мәче булырга уйладым. Беркөн кич аякка киез итек һәм өсткә, эчен тышка әйләндереп, тун кидем. Башта да эче тышка чыгарылган бүрек иде. Тунның арт итәгенә мунчаладан койрык төсле бернәрсә тактым. Бервакыт, мәчечә кычкырып, номерымда репетиция ясарга тотындым. «Мияу», «мырау», «мә-аа-ауу», «мор-рр-а-ууу»! Үземә бик яхшы, бөтенләй мәчечә тоелганга, мин түн уртасында, һәйбәтләп аяк бөкләп, күсе чыга торган тишек янына утырдым. Менә мияулыйм, менә мыраулыйм!

— Мияу, мырау, мә-аау, мор-ррау!

Бервакыт мыраулаудан туктап карасам, күселәр тишек эченә бөтен гаиләләре белән җыелганнар. Аларның үткен тешләре

---

*Илтизам итү* — өстеңә алу.

*Хәрфе җәр* — предлог (ярдәмлек сүз яки кисәкчә).

*Гайре мөтәнаһи* — чиксез күп.

аркылы минем мыраулавым хакында түбәндәге рәвешчә мөхакәмә сүзләре ишетелә:

— Менә Камил Мотыйгый! *(Шырык-шырык көләләр.)*

— Җә, әле без акча биреп тыңламыйбыз, әле Камилнең моннан начар концертына адәмнәр акча да түләделәр.

— Плохой артист!

— Шунда да чалбарчылардан[8] артык.

— Мәче, имеш!

— Безне куркыта, имеш!

Мин, боларның үземне мөхакәмәләрен вакытча кисеп:

— «Йа әйеһәл-каумел-күсиюн! Ля тәнзыру иля мән мыраулый вәнзыру иля ма мыраулый!»*.

— Ничек синең үзеңә карамаска, адәмчә тырнакларыңны да баягы бәхәстә кисеп ыргыттың... битең дә шоп-шома; мыегың да юк, үзең дә зур.

Байбәтчәләр шикелле мактанып әйтмим, мин дә усал бит, менә аларга нәрсә дидем:

— Әй, күселәр! Сез нигә минем локмәмне ашыйсыз? Ник интендант булмыйсыз? Ашасаңыз, корсакларыңыз яхшы күперә бит; килешле булыр иде.

— Син безне, идән астында яткач та, бернәрсә белми дип уйлыйсың икән. *(Гомуми хахылдап көлү.)* Бу җылларда интендантларны тимер капчыкка утырталар аларны. Менә Казанда, Киевтә, Петербургта...

— Хәбәрдар халык икәнсез. Ихтилалчыларның рухы төшкәч, әллә «идән асты матбугаты» бөтенләй сездәме?

Бер күсе, күкрәген киереп:

— Бездә шул, бездә! Нишләтмәкче буласың?

Икенчеләре, мине кызганышып:

— Әмма үз ролендә булмаган кеше кәмит соң!

— Миңа нишләсәм мәгъкуль булыр, критик әфәнделәр?

— Язуыңны яз. Карт чиновник шикелле борчылма.

Бу сүзләрдин соң мин, аларның сүзен җыкмас өчен, ушбу озын кыйссага хатимә итеп, түбәндәге бәетләрне борчак кеби тездем:

---

* Әй, күсе халыклары. Кем мыраулаганга карамагыз, ничек мыраулавына карагыз!

*Мөхакәмә* — тикшерү, хөкем йөртү.

*Локмә* — бер кабым (ашамлык).

*Ихтилалчы* — революционер.

*Хатимә* — йомгак.

**ГЫЙБРӘТ ВӘ НӘСЫЙХӘТ**

Номерың матур булса, күсе булгай,
Һәр матурда начар якның берсе булгай;
Ансы булып җитмәсә дә, монсы булгай, —
Андин җыртык, мондин җыртык туннарым бар.
Бер адәмнең чын дошманы күсе булгай,
Икенчесен җөдәтүче кеше булгай;
Һәркемнең үзенчә бер эше булгай, —
Андин сүтек, мондин җыртык туннарым бар.

## МӘКАЛӘИ МАХСУСА

### *Мөхәррир әфәнде[1] мине орышып яза:*

«Казаннан киткәнеңә икенче ай инде, бернәрсә дә язмыйсың, идарәгә бер мәкалә дә җибәрмисең...» — ди.

Соң инде, әфәндем, үзең озата төшкәндә, «Фультон» парахудының эсселеген вә «сәйяр мунча» дияргә яраклык булганын, минем шуңар никадәр куанганымны күрдең бит. Парахуд кузгалды. Син чыгып киттең. Мин каютның ләүкәсенә мендем дә яттым. Шуннан бүтән нәрсә языйм? Мин яныма каләм, кара да алмаган идем. Һәркем үз кайгысын язарга рөхсәт инде. Арка туңу мәсьәләсен кыш көне бер кәррә язган да идем.

Әле Гаяз әфәнде рисаләсендәге Сөннәтче бабай[2], аркасы туңганлыктан гына, арка җылытырга бер хатын алган, ди. Мин ул китапны үзем укымадым, укыган кеше генә сөйләде.

Укырга, мин Гаяз әсәрләреннән куркам да. Беркөн, соңгы китапларыннан берсен укыган тәэсир бетмәс борын, мәхәббәт хакында бернәрсә язган идем, гөнаһ шомлыгына каршы, язганым ушбу рәвешчә булды: «Берзаман үгез, сыеры бар бер агайның капка төбенә барып, авызын күтәрде дә, мәхәббәт һәм нәзек хиссият белән, ишегалдындагы бозауга хитабән:

— Әниең өйдәмүүүһһһ! Әниең өйдәмүүүһһһ! — дип кычкырды.

Бозау җавабында әкрен генә:

— Өйдәәәәммм, — диде. Шуннан соң гашыйк садыйк маңлай сөңгеләре белән капканы төртте дә эчкә тәшрифе кадәм боерды.

Димәк, мин язалмыйм; әгәр материалыңыз булмаса, мәсә-

---

*Сәйяр* — күчмә.
*Кәррә* — тапкыр.
*Хитабән* — эндәшеп.
*Гашыйк садыйк* — чын турылыклы гашыйк.
*Тәшрифе кадәм боерды* — атлап керде.

лән, Һинди Минһаҗ дарелфөнүн акчасына «Дөньяда җәннәт вә аның хурлары» ясап ята, ди[3]. Шуны языңыз.

Беренче апрель көнне Җиңги Садыйк кибетенә әллә кем алдап автомобиль китерткән, ди. Шуны языңыз. Кяфер арбалар дин мәсхәрә итә, диеңез. Шуны языңыз.

Теге, яз көне Иделнең күперен ватып, миллионнарча зарар иткән зур бозны Каф тавы артыннан Дәҗҗал мәлгунь безнең шәһәргә җибәргән, имеш. Дәҗҗалның болай каты күңеллеләнүенә Казаннан чыккан «Дәҗҗал» атлы пьеса[4] сәбәп, имеш, ди. Дәҗҗал мәлгунь мәзкүр пьесада үз усаллыгының бер кешегә ике бутылка кара сыра эчерү белән генә беткәнлегенә гаять тә кәефе киткән, ди. Маңлаендагы чынаяк чаклы күзе, акаеп, табак чаклы булган, ди. «Нигә Мефистофель вә демоннарны үз дәрәҗәләреннән төшермичә, көчле итеп, чын усал итеп язалар да, мине кара сыра эчертүче дип кенә сыйфатлыйлар», — дип әйтә, ди. Боз әждәһа сурәтендә, ди. Казан городской галавасына хат язган, ди. «Күперне ваттырасың килмәсә, кызыңны бир!» — дигән, ди. Городской галава, дуст-ишләре белән киңәшкәч, әждәһага (бозга) каршы мөселман итчеләреннән иң тазаларын сайлап, балта күтәртеп җибәрмәкче булган, ди. Үзеңез ялгаңыз да, ялганлаштырыңыз да шуны языңыз.

Казанда бер зыялы мәрхүм Әхмәтҗан абзыйны милләт хамие, дин атасы, хәдис көтүчесеме[5], нәрсәләр дип мактаган, ди. Шуны языңыз.

Лөгатьче Хәсән Гали Казан дигән сүзнең ата казлар җәмгысе икәнен кәшеф иткән, ди. Ягъни фарсы җәмгысе дип әйтә, ди. Казан татарча дип әйтә, ди; Казан фарсыча дип әйтә, ди. Чорт ява знат, нәрсә дип әйтә, ди; шуны языңыз.

Казанда бер хәрчәүнәче үзенең пәрәмәч сата торган номерларына «Амуръ»[6] дип исем кушкан. Вәхәлбуки «Камыр» дип атау тиеш иде (аның да тараканлысы). Шуны языңыз.

«Ялт-йолт» дигән сүз безнең журналга исем булырга ярамый икән. Шуны языңыз. Көлке журналларга үлгән шагыйрь вә мөхәррирләр исемен куярга кирәк икән. Мәсәлән, русларның «Будильник», «Оса», «Сатирикон», «Стрела», «Осколки», «Весельчак», «Попрыгунья-Стрекоза» исемнәрендә олугъ шагыйрь вә мөхәррирләре булган икән дә, алар, шул бөекләр ру-

---

*Дарелфөнүн* — югары уку йорты.
*Мәзкүр* — әлеге.
*Хамие* — сакчысы.
*Лөгатьче* — сүзлекләр төзүче.
*Җәмгысе* — күплек.
*Кәшеф итү* — уйлап табу.

хына дога булсын дип, мәзкүр исемнәр белән көлке журналлары чыгаралар икән. Баштук мәдәни кавемнәргә бер нәүгы мәмдух тәкълид* белән ияргән «Акмелла» мискиннең ахыры нишләп сүә хатимәгә терәлсен?

Мөхәррир әфәнде! Әле минем авырудан башка эшем юк. Бер зур эш эшләгән шикелле, әллә кайларга барып авырып йөрим. Авылда авырдым, Казанда авырдым. Самарда авырдым. Уфада авырдым, ахиреләмер, патша тора торган шәһәргә — Петербургка барып авырдым. Троицки халкы да күрми калмасын дип, монда да авырыйм. Ләкин монда эш шәп. Терелермен кебек. Терелсәм, әллә нәрсәләр язармын әле.

Әлегә хушыгыз.

## I

Ләүкәгә менү бәхтиярлыгының икенче көнендә бугай, төнгә табарак, Самарга җиттем. Ярдагы извозчикка: «Мине бигүк начар булмаган бер номерга илт», — дидем. Извозчик, әллә минем тышкы кабыгым чибәр булганга, әллә үзенә якынлыктан, Самарның безнең Воскрәсәнемез кеби яхшы урамындагы «Бристоль» номерына туктатты. Бинасы гаять мәһабәт, ишеге койма кадәрле зур, кыйбатлы пыяладан булганга, уңымнан, сулымнан шәһәрнең хисаплаулы публикасы үткәнгә, бу номерга керүдә тәрәддед иттем. Тик җүләр балык шикелле торам. Читтән караган кеше Саламторханның патша сарае янында торуын исенә төшергәндер.

Акылым тиз үк йитеште:

— Син Самарда начаррак номерга төшсәң, бер атна тормакчы идең, «Бристоль»дә исә бер генә кич кунарсың; син бит Казаннан, аның юеш һавасыннан качып кына чыктың, Самарны яратып түгел, ягъни «ля лихөбби Галиин биллибогзый Могавия»**. Төрекләр: «Бер көн шаһлык — шаһлыктыр», — диерләр...

Шуннан соң тәүлеге 1 сум 25 тиенлек иң арзанлы номерына кереп урнаштым.

Караңгы булды. Ут янды. Ләкин кыр зурлыгы номерда япаялгыз утырырга күңелсез. Извозчик белән Фатих әфәнде Мортазинга[7] киттем.

* Бертөрле мактаулы ияру.

** Галине яратудан түгел, бәлки Могавиягә дошманлыктан (әйтем).

*Мәдәни кавем* — мәдәниятле халык.

*Сүә хатимә* — күңелсез бету (нәтиҗә).

*Ахиреләмер* — ахырында.

*Бәхтиярлык* — бәхет.

*Тәрәддед иту* — икеләну.

Извозчиктан:

— Мулла ерак торамы?

— Вот, за углом.

Чынлап та, бер чатны борылсак, Фатих әфәнде капка төбендүк тора икән. Дәгъвәт иттем. Бер сәгатьтән килмәкче булды.

Кайтып самавыр сорадым. Фатих әфәндене көтәм. Әмма эчемне бернәрсә тырный... Ходай орган извозчик шул бер чатлык җиргә бер тәңкә алды бит! Әле номерга кереп җитмәгән, 2 сум 25 тиен — выжжжт! Менә ничек булды:

— Самарның мулласын беләсеңме?

— Беләм.

— Шунда күпмегә алып барасың?

— Илле тиен.

— Таксача күпме тиеш?

— Кырык тиен. Ну, бер ун тиен арттырырсыз инде.

Риза булдым. Бер чаттан барып, икенчесеннән алып кайтты да, мин, ди, ике конец йөрттем, ди. Бер тәңкә кирәк, ди. Нишлим? — бирдем. (Бу вакыт муллаларның дәвере исемә төште.) Чәй янында кайгырып утырам. Ник полицийский чакырмадым? Ник 50 тиен генә биреп кереп китмәдем? Вә әсәф! «Икътисад» мөхәрриренә барганда шундый икътисадсызлык эшләдем бит! Соңыннан таксаның 25 тиен генә икәнен белдем.

## II

Вәгъдәсендә Фатих әфәнде килде. Бик озаклап һәм төрле мәсьәләләр тугърысында сөйләп, тәмам төнге уникене җиткердек. Фатих әфәнде тыныч кич теләп китте. Иртәгә миңа вокзалга барырга вә озатышырга бер шәкертен җибәрәчәген вәгъдә итте.

Фатих әфәнде тыныч кич теләсә дә, минем күңел тыныч түгел, йокы килми иде. Чәй урынын җыярга звонок бастым. Марҗа килде. Аңар йокы килмәгәнлектән, эч пошудан зарландым.

Ул номерда тоташ первоклассный ресторан барлыгын, анда номер коридорыннан эчке кием белән керергә мөмкинлеген сөйләде... Ресторанның первоклассный булуы миңа ошамады. Мин андый рестораннарны яратмый торган идем. Чөнки Казанда шуларның швейцарлары, кием начарлыктан, бер-

---

*Дәгъвәт иту* — чакыру.

*Вә әсәф!* — Ни үкенеч!

ике мәртәбә кертми җибәргәннәр иде. Шул заман ук ресторан ишекләренә тыштан йозрык селкеп киткән идем. Көннәрдә бер көн шундый рестораннарның берсенә бер иптәшем берлән бардык. Ишеген ачкач та, швейцар, безгә күзен акайтып:

— Вас не пустим!

— Почему?

— Одеты неприлично.

— Чорт с вами*.

Без мәэюс-мәэюс, мәхзүн-мәхзүн чыгып киттек. Юлда иптәшем бер хәйлә корды:

— Әйдә, — ди, — мин синең фуражканы киим, син минем бүрекне ки, — ди.

Мәгъкуль, шулай иттек, тагы ресторан ишегенә бардык. Безне инде икенче кешеләр дип белерләр дип уйлыйбыз. Швейцар, ишектән башын гына чыгарып:

— Вам сказано, господа! — диде.

Иртә белән торгач, иптәшем белән кичә кичке хәйләбездән шундый көлештек ки, хәтта «Болгар» стенасындагы тараканнар, көлкедән эчләре катып, идәнгә шап-шап егылып төшәләр иде.

Хикәят бетте. Әлхасыйль, Самар киченең иртәсендә кесәмдә акчам сәламәт, башым сау көенчә уяндым.

Шәкерт үз вакытында килде. Әйберләрне төреште.

Без икәү, резиналы фәйтунга утырып, Самарның ат аягы ләп! ләп! итеп кәефне китереп бара торган асфальт урамы белән вокзалга юнәлдек. Юлымызда атлы вагон — конка очрый иде. Зур шәһәрләрдә трамвай күреп өйрәнгән күзгә бу конка бик хәкыйрь һәм көлке тоела иде.

Конка янымнан үтсә, мин андагы пассажирларның сакалмыексыз кешеләренә карамыйча, бигрәк сакаллы сабыйларга күзем төшә иде. «Оялмыйча, сакалларын салпайтып, шунда утырып баралар бит!» диясе килә иде. Кыскасы гына, көлкегә калган бу нәрсәне тотасы да балаларга бирәсе! дигән фикер хәтергә килә иде. Конкага җигелгән атлар җан авырттырырлык кызганыч вә теге сакаллы сабыйлар тарафыннан мәзлум тоелалар иде. Бу бөтенләй чебенгә сука җигү булып күренә иде. Вокзалга барып җиттек. Вагонда бер урысның слойка белән тозлы кыяр ашавыннан башка бернәрсә дә кызык тоелмады. Уфага барам.

---

*Мәэюс-мәэюс, мәхзүн-мәхзүн* — өметсез-өметсез, кайгылы-кайгылы.
*Хәкыйрь* — кимсетелүле, хурлыклы.

## III

Уфага җиттем. Тау башында тәртипсез таралып утырган. Извозчикка утырдым. Ләкин бу инде Самарныкы түгел иде. Арбасы шундый иске, шундый каты иде ки, эчәкләрем, такта арбага буш салган дилбегә кеби, үрле-кырлы сикерә иде. Таудан акрынлап менәсең. Җулның әтрафында җәһәннәм кеби тирән чокырлар хисабы юк. Җәһәннәмнәрнең тирәсенә саклык өчен тезгән баганаларның арасы бик сирәк булып, арба янтайса, мөкиббән галә вәҗһиһи җәһәннәмгә төшү бик мөмкин иде.

Уфага кергәндә бер дә шәһәргә кергән кебек булмый. Әллә нинди ачык-тишек вә рәтсез һәм пустынный урамнар белән барасың. Эч поша. «Кая соң моның шәһәрлеге?» — дип сукранганда, көчкә беркадәр яхшырак урамнарга кердек. Шулай барганда, «Сабах» көтепханәсенең ак вывескасы күренде. Тугъры анда туктадым.

«Сабах»ка килүдән максудым, Самардагы кеби, бер «Бристоль»гә барып эләкмәскә, ягъни нинди номерлар ничек булачагын сорашу иде. Ләкин, күрдем ки, магазинга тоташ шундый киң вә яхшы бер квартир бар, монда мин түгел, миңа тагы 19 кеше кушсаң да сыярлык иде. Җитмәсә, аның асты кухня булып, һәрвакыт астан җылы бәргәнлеге беленде. Менә рәхәт! Менә икенче ләүкә! Монда китап төялеп килгән гайре мөтәнаһи ящиклардан караваt ясау вафли пешерү шикелле тиз. Аста ящик булса да, өстенә йомшак вә матур нәрсәләр каплагач, ярый ул: өстендә әйбәт кием булгач, синең бәрәңге генә ашаганыңны кем белә? Урамга чыксаң, мыекны кашыктагы май белән майлап була. Дөнья яратылганнан бирле ялганнар күбесенчә тотылмый калган. Бичара Рәшит казый гына, микадо мөселман була дигән булып[8], һәммә татар галәмен алдый язган иде. Ләкин «Тәрҗеман» мөхәррире[9], чыгып, Рәшиткә: «Баба, кашыктагы мыек майлый торган маеңны песи ашады», — дип оятлы итте. Мин фәкыйрь дә, татар вә исламга гаид эшләрдә «чебен тимәс чер итәр» бер кеше булганымнан, «Японияне мөселман идүче голяма нәрдә?» сәрләүхәле бер шигырь язган идем.

Квартир, гомумән, күңелле. Кеше күп килә. Эч пошарлык түгел. Монда һәр көн мөхәддисе кәбир Әхмәтфаиз Даудов[10] белән күрешәбез. Ул скрипкәдә маташтыра, әлегә яхшы уйный алмый. Ләкин җырласа, мин андый җыруны бөтен гоме-

---

*Мөкиббән галә вәҗһиһи* — йөзтүбән.
*Гайре мөтәнаһи* — чиксез күп.
*Гаид* — бәйләнешле.
*Сәрләүхәле* — исемле.
*Мөхәддисе кәбир* — хәдисләрне күп белүче.

ремә тыңлар идем. Аның гади сөйләшүдә дә металлический вә музыкальный тавышы җырлау заманында бөтен көчен вә голүвиятен изһар итә. Мин Латыйповны[11] ишеткәнем юк, ләкин Камил бушбугаз кебиләрне бу җирдә телгә алырга да хурланам. Петербург профессорлары хәзер башкорт халкының бик тиздән монкариз булачагына иман иткәннәр. Башкортларның гадәт вә әхлакларын язып һәм кием вә зиннәтләрен музей өчен тикшереп ятмакталар икән. Әгәр Фаиз әфәнде кеби чын башкорт рухы вә башкорт моңы белән җырланган җырлар да граммофоннарга алынып калса, моның башкорт инкыйразыннан соң азмы әһәмияте булыр иде?! Ләкин милләтемез диңгезенең энҗеләре төптә ятып, «ул-бу»лары гына өсткә кала шул.

Дикъкать итәсезме? Хәзер граммофонга җырлау фахишәләр вә әнвагъ эшсез, ашсызлар кәсебе булды. Казанның «Кәҗә Маһи», «Подвал Фатима», «Этле Хөсни», «Җиңгәчи кызлары»на кадәр төрле шәһәрләрдә граммофонга җырлап, милләтнең сәмгын мәсхәрә итеп бетерделәр. Фахиш тавыш, фахиш рух, фахиш көй! Фахиш мәгънә! Менә шулар безнең фәхшиятсез, пакь мөселман түрләренә кереп утыралар. Түрдә утырып, граммофоннар сүгенәләр. Мин Казанда, Әстерханда әллә ничә граммофоннан шуны уйнатучы гаилә әфрады өчен кызарып утырдым. Алар минем кәефемне ачарга граммофон боралар иде. Мин исә чыраемны сытып утыра идем. Чөнки алар, миңа шикәр дип, үзләре белмичә, ачуташ каптыралар иде.

## IV

Уфаның мәгъмурият ягы Казаннан күп начар булса да, табигать ягы күп шәһәрләрдән өстен. Әүвәл үк ул тау башында. Димәк, җәй көне дә, кыш көне дә һава яхшы. Җырларымызда шулкадәр күп җырланган Ак Идел буенда. Шәһәр эчендә йортларга караганда агачлар күп диярлек. Моның җәй көнеге әһәмияте! Өстән караштa, Уфаның халкы да айнык вә саф күренә. Чөнки бу шәһәрдә чат саен халык саулыгын химая итә торган сөт кибетләре, һәммәсендә халык. Пивнойлар сирәк. Бу шәһәр — «ай-һай, Казанның каласы, аза ишан баласы» тү-

---

*Голүвиятен изһар итә* — бөеклеген ачып бирә.
*Монкариз булу* — бетү.
*Инкыйраз* — бетү, юкка чыгу.
*Әнвагъ* — төрле-төрле.
*Сәмгъ* — тыңлау тойгысы.
*Гаилә әфрады* — гаилә әгъзалары.
*Мәгъмурият* — төзеклек.
*Химая итү* — саклау.

гел. Сөт сатучылар, мендәргә утырган мулла кеби, үзләре хезмәт итмиләр. Сөт эчүчеләр үзләре буфеттан сөт алып килә. Чөнки мулла сиңа Коръән укыта, дин өйрәтә, сөтче дә сәламәтлек бирә, алар нишләп хезмәт итсеннәр! Мөселман буласың килсә — дин өйрән, сау буласың килсә — әнә сөтне үзең барып ал! Монда трахтир официантлары кеби рия, нифакъ вә посетительгә ярарга тырышып кыйлану күренми.

Фәлсәфәгә кердем... язам, язам — кая көлкесе; урман, урман — кая төлкесе?!

## V

Әйе, урманның да бөтен җирендә төлке булмый, мәкаләнең дә һәр сәтырында көлке булмый. Актар агач араларын — бардыр төлкесе; укып чык бөтен караларым — бардыр көлкесе.

Мәҗит әфәнде Гафури белән күрештек. Ул миңа караганда да җуашланган вә дөнья тарафыннан басылган кеби күренде. Аның белән безнең мосахәбәмез күп вакыт күзләр аркылы гына кыйлына иде. Читтән безне караган кеше, икемезне әле генә хисапсыз каты шаярып, соңра аналары кыйнап, бер минут элек кенә җылаудан туктаган балаларга охшатыр иде.

Нишлик соң? Шаярыр идек — әле генә язмыш ханым кыйнаган; җылар идек — әле күздән яшемез дә кипкән*.

Русиядә хәзер уйнаган җилләр вә Русия һавасы безнең бөтен коллегаларымызны шул халәте рухиягә китергән...

Әйе, әле күздән яшемез дә кипкән. Киләчәктәге шатлык яки ерак, яки юк.

Уфада шактый заман торсам да, аның эчен вә әтрафын карап җөри алмадым. Мәҗит белән йөрергә чыксам да, ярты юлда, хәл беткәч, өйгә борыла идек. Монда трамвай җук. Извозчикта эч кенә авырта, эч авырттырмый торганына утырсаң, кесә авырта иде.

Шәһәр бакчасында борадәран Кәримевләрнең «Йолдыз» исемендә кинематографлары бар. Көннәрдә бер көн Кәримевләр, әлбәттә, үзләре сизмичә булырга кирәк, кинематографларында «Мөхәммәт оҗмахы» дигән нәрсәне күрсәтмәкче булып игълан таратканнар. Бу хәлне сизгәч, Уфага яңарак килгән бер «зыялы» мәсҗедтәге картларга Кәримевләрнең шундый начар эш эшләячәгене сөйләгән. Картлардан хәбәр халыкка да таралган. Халык кызып, витринадагы афишаларны җыртып, Кә-

---

* «Елый-елый яшебез дә калмаган, кипкән» мәгънәсендә.

*Рия, нифакъ* — ялагайлык, икейөзлелек.

*Мосахәбә* — әңгәмә.

*Халәте рухия* — рухи хәл.

римев кешеләрен кыйнарга да уйлаганнар. Ләкин Кәримевләр ни дип җавап биргәннәр?

Наданлык сәбәпле көфергә төшү җиңел инде:

Алар, без белмәдек дип, зари кыйлды,
Гөһәрләр күзләреннән җари кыйлды...

Әлкыйсса, мәзкүр нәрсәне күрсәтмәгәннәр.

Хәзергә җитәр әле.

## VI

Өстән генә ләктереп китү тарызын алган мондый сәяхәтнамә өчен Уфада артык нәрсә күрмәдем бугай.

Хәер, шәһәр бакчасында, өстенә җөббә, башка зәңгәр фәс, күзгә күзлек, аякка бәтинкә, авызына кош канаты төшәрлек дәрәҗәдә борынын күтәреп барган бер мәгъруур шәкертне туктатып, җүри, «вәкарь вә мәһабәтен» бозар өчен: «Син курай уйный беләсеңме?» — дип сорыйсым килде. Мин үзем, гомумән, шундый кәмитле мәһабәтлекне бозудан ләззәт табам. Аннан соң без беләбез ки, татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек аның «вәкар»ен бозарга кирәк.

Бу өй салганда иң элек нигездән башлау, сүткәндә түбәдән тотыну кеби кагыйдә инде.

Андый «вәкарь» яшьлектә җимерелмәсә, бәгъзан, мөхәррир булып гомер итеп, неграмотный үләчәк «зате галиләрдә» дә кала. Мисал эзләсәңез, күктән йолдыз эзләгән кеби генә булып, аны табуда зәхмәт чикмәссез.

Әле апрельнең әүвәлге яртысы гына җитә. Минем өчен көннәр әкрен кичәләр. Апрельнең әүвәл ягыннан, әүвәле Коръәннән чыгалмый җөдәгән малай кеби, мин дә үтә алмыйм. Малай, хәлфәсе сизмәгәндә, сабагын «сикерткән» кеби, мин дә күп йоклап карыйм. Ләкин максады аслый булган кымыз сезоны җитми. Уфада кымыз юк.

Дөрест, мин кымызны Уфада да, әтрафында да эчәчәк түгел. Мин аның өчен Троицкигә барырга Казаннан ук карар биреп чыккан вә йөзләп баш бия саудыра торган бер Троицки кешесенә барасы, кымызны савылган урынында чатыр тегеп торып эчә-

---

*Зари кыйлу* — кычкырып елау.

*Гөһәр (гәүһәр, җәүһәр)* — алмаз, асылташ; монда «алмаздай күз яшьләре» мәгънәсендә.

*Җари кыйлу* — агызу.

*Тарыз* — рәвеш.

*Җөббә* — җиләннең бер төре.

*Зате гали* — бөек зат.

*Әүвәле Коръән* — Коръәннең беренче кисәге.

*Максады аслый* — төп максат.

се кеше. Чөнки Уфа әтрафын европалылар басып, биттабгы, андагы кымыз искусственный* (җәгъли)ланганыннан хәбәрем бар иде. Ләкин Уфада кымыз да булмаганлыгыннан, Троицки «кусагасылары»ның да «бия байламаганлыгын» истидлял итә идем.

Шулай ни ары, ни бире булып торганда, кесәмдәге Петербурга мине чакырып язган бер хат исемә төште. Бу хат инде беренче түгел, берничәнче иде.

Буш та түгел, җитди иде. Ләкин җитди булса да, мин Петербурга баруны көзгә, кымыз эчеп хәлләнгән чакка кичектермәкче идем. Юк инде, Петербурга хәзер барам. Кымыз да булмагач, Уфада нәрсәгә ятыйм. Җитмәсә, аның «авыллыгы», тынлыгы, җайсызлыгы минем әле хасил булмактагы яурупалылыгымны, культурный шәһәр кешеселегемне, шау-шу яратучылыгымны, галәбәлек, көрәш сөючелегемне үчекләгән кеби булды. Китәм Петербурга! Кымызга кадәр торам. Телеграм — ответ. Киттем.

## VII

Иртә белән, сәгать сигез. Менә сиңа Петербург. Николайский вокзал. Кечкенә чакта Бәдигыльҗамалны эзләп барган Сәйфелмөлекне укыганда, Сәйфелмөлек барган пәри шәһәре әллә нинди тып-тындыр, җеннәр үз шәһәрләрендә күренеп йөрсәләр дә, безгә күренмәгәндәге кеби, тавышсыз йөри торганнардыр, һәм әллә нигә ул шәһәр томанлыдыр, караңгыдыр кеби тоела торган иде.

Күккә баскыч куеп, фәрештәләрнең серләрен урларга менә торган җеннәрнең өйләре дә күз җитмәслек биек була торгандыр кеби сизелә иде. Вокзалдан чыгып извозчикка утыргач, миндә дә шул хатирә яңарды. Шәһәрдә бер тавыш, шатырдау, дөбердәү юк; үзе караңгы, томанлы; агач түшәгән урамда, резиновый шинле йомшак фәйтунга утырып барганда, бөтенләй калын киез итек киеп барган кеби буласың.

Ул өйләрнең биеклеге! Чорт белә: күгең кайда да, кояшың кайда! Болытмә, аязмә? Бернәрсә күренми. Бу шәһәргә керүне Уфага керүемне язган кеби язалмыйм инде. Гакылым хәйран.

Мине шәһәрнең мәһабәте баскан. Барысы бертөсле агач түшәүле урамнар. Конкалар уза. Алардан Самардагы кеби көләсе килми.

---

* «Искусственный» сүзе рус хәрефләре белән басылган.

*Биттабгы* — табигый.

*Кусагасы* — кымызчы.

*Байламаган (казакъча)* — бәйләмәгән. «Бия савып кымыз ясый башламаган» мәгънәсендә.

*Истидлял иту* — нәтиҗә ясау, уйлап белү.

*Галәбәлек* — җиңү, өстенлек.

Чөнки трамвай да шундук, артындук автомобиль дә! Өйләрнең номерларын санап барам. Менә Сергеевская, 81.

Шып... туктадык.

Звонок бастым. Әле һаман иртә булганга, Муса әфәнде[12] йокысыннан хәзер генә торган иде. Чыгып кабул итте.

Ишегалды эчендә, бөтен дөньяны вә Петербургны күрсәтми торган сәдде Искәндәрләр кеби стеналар арасында бер квартир. Үзе кешегә зәхмәт биру дәрәҗәсендә артык югары түгел. Дүрт-биш бүлмәле, шәһәренә күрә якты да. Муса әфәнде рәфыйкасе вә бала-чагалары белән шунда торалар икән. Мин түр бүлмәгә кереп урнаштым. Чөнки минем хәбәрем тизлектә вә телеграм белән генә килгәнгә, табигый, минем өчен номер-фәлән кеби махсус бер урын хәзерләнмәгән.

Мин Муса әфәнденең эш бүлмәсендә (рабочий кабинетъ*). Бүлмә әнвагъ гарәби китаплар белән тулы. Язу өстәле бер көн, өченче көн, кичә, аннан элек, әле генә язып ташланган материалларга күмелгән. Муса әфәнденең иртәге чәе дә, көндезге ашы да, кичкесе дә язу өстәлендә эш арасында, между прочим** гына, ашалып эчелә.

Петербург — мәгариф урыны. Анда гакыл биналары да шул пәри йортлары кебек биек. Анда гыйлем урамнары да шулай пакизә вә тәрбияле. Көндезнең әллә кай сәгатьләрендә, кич белән төн буе, әллә кайда, әллә нинди лекцияләр, укулар...

Муса әфәнде шулар артыннан да җисмани вә рухани көче җиткәнчә йөгерә. Аңар көн җитми, төн җитми. Ул таң атарда мәзкүр урыннардан кайта. Между прочим гына йоклый. Тагы иртүк тора, тагы укый, тагы яза, тагы җөгерә. Между прочим гына идәндә җөргән берсе-берсеннән бер илле генә биек кечкенә балаларны сөеп, җуатып ала.

Менә шул фәгалият, шул эш арасында, җитмәсә, Муса әфәнденең үзе ята торган караватында мин авырып, җөткереп, гадәт буенча папирос тартып ятам. Муса әфәнде минем белән ләкъләка сатарга аз бушагач, бу кабинетта үземә-үзем уңайсызлык та сизгәч, минем көннәр, табигый, тагы авырая төштеләр.

Ихтыярсыз минем исемә Петербургта үземә бер номер алып

---

* «Рабочий кабинетъ» сүзләре рус хәрефләре белән басылган.

** «Между прочим» сүзе рус хәрефләре белән басылган.

*Зәхмәт* — кысынкылык, тыгызлык.

*Рәфыйка* — хатын.

*Гарәби* — гарәпчә.

*Пакизә* — пакь, нәфис.

*Мәзкүр* — телгә алынган (кешеләр).

*Фәгалият* — эшчәнлек.

*Ләкъләка* — гәп-әңгәмә.

тору төшә. Бу мәсьәләдә мин Муса әфәндене борчырга уйламыйм. Петербургта минем бишәр еллык иптәшләр: Кәбир Бәкер, Габделкәрим Сәгыйтевләр бар. Номер табышыр өчен дә, сагынганга да шуларны хәтерлим. Ләкин алар Муса әфәнде ханәсенә килмиләр икән. Билгеле, килгәнемне ишетмәгәннәрдер, ә мин инде бишенче көн Петербургта! Муса әфәндедән мәзкүрләрнең адресын вә «Нур» идарәсен[13] сорыйм — ул белми.

Шулай аптыраганымда, бишенче көнне кич, бер студент килеп, Сафа әфәнде Баязидовтан[14] миңа дәгъвәтнамә тапшыра. Дәгъвәтнамәдә адресы бар. Иртәгесен иртүк Сафа әфәндегә барып, «Нур» идарәсендә кичә уйлаган иптәшләрне күрәм. Хәлне сөйлим. «Казанская»дан* әгъля бер номер алабыз. Номер тәүлеге самавырдан башка ике ярым. Чынлап та, әгъля коридор, очыннан урамга кадәр хәтфә палас. Мин аның коридор вә баскычына «Муромцев юлы» куштым. Невский проспектка якын. Гүзәл урамда.

Менә монда аулак, теләгәнчә авырып ят. Мин барганда «Нур» чыгачак көннәр тугъры килеп, Кәбир Бәкергә эш муеннан булса да, Сафа әфәнде аның урынына вакытча бүтән бер кешене язарга бәйләп, аны минем белән булышырга вә гәпләшергә «сәрбәст быракты». Менә Шакир әфәнде Мөхәммәдъяров килеп чыкты. Менә укучы яшьләр, мөгаллимнәр, менә Габделкәрим Сәгыйтев. Инде монда күңелсезләнергә урын калмады. Чөнки минем бүлмә чирек сәгать тә кешесез тормый. «Нур» идарәсенә барабыз. Сафа әфәнде анда гәзитә мәкаләләре тәртипли. Шул арада наборщиклар килә. Мәкалә сорыйлар. Хәзерләнгән бернәрсә юк.

Чөнки без берничә кеше, аны онытып, аш ашап, фәлсәфәләр сатып утырабыз. Чөнки яңа килгән кеше булганга, мин үзем гәзитә, үзем мәкалә булып киткәнмен.

Шулай да мин кайчыны искә төшерәм. Кайчы китерәләр. Яңа килгән татар гәзитәләрен сорыйм. Күз төшерәләр. Гәзитәләрдән әллә никадәр кисеп алырлык нәрсәләр чыга.

Шытырдатып кисеп алалар. Кая наборщик? Менә материал! Идарә кешеләрен мин кайчы тугърысында мөсаһәләдә гаеплим. Чөнки рус гәзитә идарәләрендә кайчының әһәмияте бик зур була. Анда каләм белән кайчы янәшә торалар. Кайчы белән эш итүчегә каләм кешесенә биргән вазифәне үк бирәләр. Шулай иттереп, кайчы безнең бүленгән татлы гәпне ялгап җибәрде.

---

* «Казанская» сүзе рус хәрефләре белән басылган.

*Дәгъвәтнамә* — чакыру кәгазе.

*Әгъля* — бик шәп.

*«Сәрбәст быракты»* — «эшеннән бушатты».

*Мөсаһәлә* — игътибарсызлык.

*Вазифә* — хезмәт хакы.

Петербургның сыросте мине вокзалдан, төшкәч тә, хаҗига ябышкан мөселман кеби кочаклап алганга, табигый, минем авыру Петербургта гаять тә көчәйде. Апрель ахырлары җитсә дә, Петербургның суыгы — гыйнвар суыгы, сыросте сырость иде. Шунлыктан фәйтүнгә утырып булса да урамга чыгу миңа газап иде.

Кайвакыт үзеңне җәберләп, каһәрләп чыкканда, юлда гади шәһәр бакчалары очрый. Агач төпләрендә яшь кыз белән җегет бер-беренә могашәка серләре сөйлиләр, «в любви объясняться»* итеп утыралар. Болар төбенә утырган агачлар миңа урам себеркеләре булып күренәләр. Менә старший дворник җегет белән кызның торып киткәнен көтә, менә алар киткәч, дворник гашыйкларның агач дип уйлаган урам себеркеләрен алып китә шикелле тоела. Монда яз булганына галәмәт булса, ул да ит кибетләре тәрәзәсендә күренгән яшел суган иде.

Иттифакый уларак, Невский проспектка чыгыла иде. Бу урам мине гаҗәпләндерә дә, куркыта да иде. Бервакыт Муса әфәнде белән шуның бер ягыннан барганда, аркылы чыгарга тугъры килгән иде. Мин уртага таба бер-ике атладым да артык барырга куркып чигендем. «Муса әфәнде, дим, зинһар, дим, аргы якка 10 тиенгә извозчик яллап чыгыйк», — дим. Муса әфәнде көлә дә, ачулана да. Ул алай итү көлкелеген, курыкмаска кирәклеген, ахырда, үзе семьяле кеше булып та, рисковайт иткәнлеген сөйли. Мин тагын, извозчик, дим. Ул күнми, гакыйбәт, Аллага тапшырып, күзне йомам да, Муса әфәнденең култыгына тотынам да, күзне ачканда ары якта булабыз. Күкрәгем куркудан шулкадәр суга ки, площадьтагы чиркәү төбендә 15 минут җал итмичә ары китә алмыйм.

Курыкмаска, ул урам — дию кеби. Һәр көн үзенә бер-ике корбан алмый калмый, һәр көн тапталучыларны тикшерсәң, күбесе рабочий була. Чөнки алар да, минем кеби, андый «пәриле» урамнардан йөрергә өйрәнмәгәннәр.

Байлар урамы ул! Шомалар урамы ул!

## VIII

Мин дә Петербурга бардым, дегет чиләге дә! Никадәр мөмкин була торып, Думага керә алмадым[15]. Финляндиягә чакырдылар, анда бара алмадым. Бер театрга, бер музейга вә, гомумән,

---

* «В любви объясняться» сүзләре рус хәрефләре белән басылган.

*Могашәка* — яратышу, сөешү.

*Иттифакый* — очраклы.

*Гакыйбәт* — ахырда.

бер достопримечательный җиргә булсын, җөреп булмады: әлеге хәстәлек! Алла бүрегә бәхет бирсә, тешен сындырып бирә, имеш!

Но иной находит счастье,
Чувство счастья потеряв*, —

дигән бер шигырь дә исемдә.

Тик Сафа әфәндегә барганда гына бер җан рәхәте була иде. Анда граммофон, идәннән түшәмгә кадәр өелгән кыйммәтле пластинкалар. Әнвагъ арияләр. Бөтен мәшһүр моганни вә моганнияләр. Тәмам колак арыганчы граммофон борыла иде. Сафа әфәнде, граммофонны борганчы, нинди нәрсә вә нинди көй куелачагын бәян итә иде. Ул үзе дә музыканың илаһи ләззәтләрен аңлый торган кеше икән. Мин иң элек, ул граммофон уйнатмакчы булгач та, «татарча булмаса иде» дип үтенгән идем. Ул үзендә татарча пластинка юклыгын сөйләде. Мин, мәкаләмнең әүвәл башларында зарланган пычрак татар җырчыларын тагы бер ишетермен дип курыкканлыктан, Сафа әфәндегә эчемнән чын күңелемнән тәхсин әйттем. Менә Онегин ариясе. Татьяна бакчада утыра. Онегин, агач араларыннан килеп чыгып, җуан, ир кеше дә сискәнеп китәрлек тавыш белән җырлый. Татьяна әле генә өйдән, Онегиннан, гыйшыклык куркуы дигән курку белән качып чыгып утырган. Җөрәк леп-леп тибә. Шундый мәгънәле, нечкә курку һәм аптырау заманында Онегинның, Татьяна янына килеп, үгез тавышы белән кычкыруы, әгәр сценада күрсәм, миңа бик җәгъли кебек тоелыр иде дип уйладым. Чөнки минем (надо признаться**) әлегә кадәр опера дип әйткән нәрсәдән җүнләп хәбәрем юк. Быел, разочароваться*** итәчәгемне алдан сизеп, гомеремдә беренче мәртәбә операга йөрү эшен башламакчы булам. Шул тугърыда ничек тә гыйлем тәхсил итмәкче вә аңламакчы булам. Әгәр мин уйлаган җәгълият шулай ук чыкса вә ул фикерем хаталыгын аңласам да, бернәрсә оттырмаячагым билгеле. Ни булсам да, Сафа әфәнденең бай вә мөхтәлиф пьесалы граммофоны миңа яңа бер галәм ачарга сәбәп булыр төсле әле.

Кирәк номерымда, кирәк Сафа әфәндедә шулай күңелле вә ямьле тормыш белән Петербургта тагы бер атналар үткәргәч,

---

* Кайберәүләр бәхетне сиземләү тойгысын югалткач кына бәхет табалар.
** «Надо признаться» сүзләре рус хәрефләре белән басылган.
*** «Разочароваться» сүзе рус хәрефләре белән басылган.
*Моганни вә моганния* — җырчы ир һәм хатын-кыз.
*Тәхсин* — рәхмәт.
*Җәгъли* — ясалма.
*Гыйлем тәхсил итү* — мәгълүмат, белем алу.
*Җ0Ыәгълият* — ясалмалылык.
*Мөхтәлиф* — төрле-төрле.

иптәшләр мәслихәте белән, Петербургның дарелфөнүн табибен, зогъфем сәбәпле, минем номерыма китерттек. Ул, мине карап, кымыз эчәргә кирәклеген вә бик тиз Петербургтан китәргә тиешлеген сөйләде. 13 көн Петербург «ризыгын» ашагач, тагы Уфага таба сәфәр иттем. Инде Ряжскине үткәч тә, яшәргән агачлар (Петербург бакчасындагы урам себеркеләре түгел) күренеп, күкрәккә саф һава керә башлады. Уфага кайтсам, Уфа мине кияү көткән кыз кеби көтеп торган. Әтраф киенгән. Ямь-яшел. Кояш көлә. Яз җиткән, яз!

## IX

Инде Уфада да кымыз күренгәли. Димәк, Троицкидә күптән бар. Г.Баттал әфәнденең[16] үткен вә искренний интикадларын укыганым булса да, биззат күргәнем юк иде. Бу юлы Уфада аны күрдем. Уфада берничә генә көн хәл җыйгач, Баттал әфәнде белән вокзалга киттек. Троицкигә сәфәр. Поезд кузгалыр алдыннан билетнең бераз хатарак алынганы вә кире кайтарырга мөмкин түгеллеге аңлашылды. Чөнки без Чиләбегә туп-туры, туктамый бара торган поезд билете алганбыз. Дөрестән дә, безгә Чиләбедән бер станса бире — Полетаевкага туктый торганга алырга кирәк булган. Баттал әфәнде минем баруым тугърысында Чиләбедә Галиевләргә телеграм белән игълам итәргә уйлады. Мин рәд иттем. Чиләбедә вокзал тирәсендә бер номерда ял итеп, аннан соң ат яллап, кире Полетаевкага кайтырга карар бирдем.

Шулай итеп, видагълашып, Чиләбегә киттем. Чиләбе вокзалына төшсәм, өст-башы яхшы бер мөселман миңа тугъры карый вә һаман янымнан бара. Мин, сизенеп:

— Абзый, сез мине таныйсыз мәллә?

— Сез фәлән түгелме?

— Әйе.

— Мин Галиев булам. Сезне алырга килдем.

Вокзалда берәр стакан кофе эчкәч, әйберләрне сакларга биреп, Чиләбенең каласына юнәлеп, Галиевләрнең йортына килдем. Чәй янында хата билет алганнарны сөйләп, Троицкигә барырга берәр иптәш юкмылыгын сораштым. Бу мөхтәрәм әфәнделәр, мин аштан соң ятып хәл җыеп торганчы, иптәш тә тапканнар. Ат та киләчәк булган.

---

*Зогъфем* — авыруым, зәгыйфьлегем.
*Интикад* — тәнкыйть.
*Биззат* — үзен.
*Рәд иту* — каршы төшү.
*Видагълашу* — саубуллашу.

Бераздан атлар килеп, Троицкигә бара торган бер приказчик юлдаш булып, Полетаевкага юнәлдек. Юлымыз күңелле. Ике тарафы урман. Көн матур. Җилсез. Кояшлы. Җылы. Иптәш белән Троицкидә вәгъдә куешкан тройкалы ике нимес вояжеры безне урманда туктап көтәләр икән. Аларга юлыктык. Свежесть вә здоровье дигән нәрсәнең мөҗәссәме* булган бер вояжерымыз, яшел чирәмгә утырып, авыз гармуны уйный. Ул шул гармунында такмаклардан, тансылардан алып озын арияләргә кадәр — һәммәсен уйный. Ул тәмәке урынына кесәсендә калай тартма белән ландрин манпасие йөртә икән. Тартмасын ачып, безгә дә тәкъдим итте. Гармунны уйнагач, манпасине суыргач, без тарантасларга менеп киттек. Тройка алдан, без арттан. Тузан куба. Безнең пар ат кына булса да, аларның тройкасыннан һич калышмый, этраф мужикларның ихтыярсыз дикъкатен җәлеп итәбез. Шулай күңелле рәвеш барганга, Полетаевкага җиткәнебезне тоймый да калдык.

Төнлә поездга утырдык. Берзаман таң аткан, кояш күтәрелгән. Мине вагонда берәү уята. Поездда бер кеше дә калмаган. Буп-буш.

— Габдулла әфәнде сезме?

— Мин.

— Мин Габдерахман мулладан[17], алырга килдем.

Чыгып атка утырдым. Шәһәргә киттем. Габдерахман хәзрәткә барып кердем. Нәкъ аш вакыты. Аштан соң беренче стакан кымыз эчеп, ахры, наконец, гакыйбәт, авызга кымыз тиде. Мине кымыз өчен Уфага бару фикереннән кайтаручы вә андагы кымызның җәгълилеген сөйләүче вә яз көне кымыз эчәргә үзенә чакырып вәгъдә алып китүче ушбу Габдерахман хәзрәт иде. Троицкидә берничә көн генә торгач, сахрага, шәһәрдән егерме биш чакрым җиргә киттем. Анда хәзрәт тарафыннан ялланган казакълар аның йөзләп баш биясен савып, бүтән малларын көтеп торалар. Ике киез өйдән гыйбарәт шул казакъ авылына өченчегә миңа махсус чатыр тегелде.

Шәһәр смрадыннан, завод агуыннан, бозык һавадан качып чыгып, арбадан парахудка, парахудтан поездга күчә-күчә, эштән чыккан мин бичара ахры бер рәхәткә, тынычлыкка барып егылдым. Бу — сахра. Бу — казакъ җире. Әүвәл, «бисмиллаһи» дип, бер чишенеп ташладым. Коры степь һавасы. Сөт,

*Тазалык һәм сәламәтлек... гәүдәләнеше.

*Вояжер* — сәүдә агенты.

*Гакыйбәт* — ахырда.

каймак, теләсәң коен, әле генә сауган саф кымыз. Бүген генә суйган ит. Бөтен нәрсә табигый, бөтен нәрсә алдаусыз.

**ВАЛЛАҺИ**

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!
Ак күмәч берлән ашарлык саф һава,
Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!
Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!
Аз гына бер җил исү берлән үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Иштә бу сахрада беренче көнемдә язылып ташланган бер кәгазьдән алынган җырулар!

*Иштә* — менә.

## *Хатлар*

## *1902–1913*

### 1. АПАСЫ САҖИДӘГӘ

*[1902 ел]**
***Уральскидән Өчилегә***

*Әлхатты ныйсфел-мөлякат.*
*Һүвә Аллаһел бари.*
*Бисмиллаһ иррәхман иррәхим.*
*Әсгадәкә Аллаһе фид-дарәйни.*

Сезки, әгаззен-наси вә әкрәмех-хавас улан җизнәмезнең җәнабе галиләренә сәламе мәснүнләремезне ирсаль вә иблягъ әйләдекемез бәгъдендә, фатихаи хәйрияләреңезне өмид идә калдым. Вә кянә мөхтәрәмә вә мөгаззәзә тутамыз Бибисаҗидәгә бихәдде вә биля ниһая сәламләремезне ирсаль вә тәблигъ әйдәдем. Кәзалик энемез Габделвәһһаб идән сеңлемез Бибимәсрүрәгә һәм сеңлемез Өммеһанигә бихәдде вә биниһая сәламе мәснүнләремезне ирсаль әйләдем. Вә кянә мөгаззәзә вә мөкәррәмә тутамыз Гөлчәһрә[1] илин гыйззәтлү вә һиммәтлү җизнәмезгә, барча әһле бәйтенә бихәдде вә биниһая сәламләремезне ирсаль вә тәблигъ әйләдем. Вә кянә әфзале вә әкрәмешшәйүх улан бабамыз Зиннәтуллага бихәдде вә биля ниһая сәламләремезне ирсаль вә иблягъ әйләдем. Вә һәм мөкәррәмә вә мөгаззәзә әбигә бик күп сәлам күндердем. Сәлам бәгъдендә үз әтрафымыздан сөале шәрифеңез улына калса, әлхәмделиллаһи, сагъ вә сәламәтләрмез бу көнгәчә; мин бәгъдә фәрман Ходаныңдыр. Үземез хәзердә мәдрәсәдә укыб торамыз. Дәресемез — «Тәркиб»не[2] чыгыб барамыз. Быел укырга акчамыз юк иде. Шулай булса да Аллаһе Тәгалә бер юл ачдыгы: Гурьевда бай туганларым[3] унбиш тәңкә акча бирде һәм үземезнең ахун җизни[4] биш кадак чәй бирде...тигән** егерме биш тәңкә бар иде. Шул акчалар берлә, Ходага тапшырыб, мәдрәсәгә кереб укыб торамыз. Апай[5] янына бер атнада бер кайтыб киләмен. Аллаһе Тәгалә гыйльме нәфигъ виргәй иде дию, һәрдаим хәер-фатихада булмакыңызны риҗа вә нияз идәмез. Вә кянә анамыз бәрабәрендә улан тутамыз Бибигази-

---

* Билгеле булмаган, әмма редакция тарафыннан куелган дата квадрат җәяләр эченә алынды.

** Хатта бу урын танылмый.

зәдән[6] бик күбдин-күб сәламе мәснүнләремезне ирсаль вә тәблигъ әйләдем.

Вә кянә үзеңезнең йибәргән әманәтеңез сәламәт тапшырылды. Рәхмәт, Алла разый булсын, гомереңез озын улыб, дәүләтеңез вә бәхетеңез көндин-көнгә зиядә улсын. Вә һәм хат язганда, андагы әхвальләрнең барчасын бәян кыйлыб языңыз. Вә янә үзеңезгә ярты кадак чәй илән бер яулык йибәрдем һәм бер исле сабын. Аз булса да, күб күреб алыңыз. Икенче йибәргәндә, иншаАллаһе Тәгалә, күбрәк йибәрермез. Гайре нә язаек? Сүз күб иде, әмма без мохтәсар кыйлдык.

*Вәссәлам*

### *Хатның хәзерге әдәби телгә тәрҗемәсе:*

*Хат — күрешүнең яртысы инде.*
*Юктан бар итүче — Алла.*
*Рәхим-шәфкатьле Алла хакына.*
*Алла сезне һәр ике йортта (дөньяда да, ахирәттә дә) бәхетле итсен.*

Сезки, кешеләрнең иң кадерлесе, югары дәрәҗәлеләрнең иң ихтирамлысы булган хөрмәтле җизнәбезгә гадәттәге сәламнәребезне җибәреп ирештергәннән соң, хәер-догаларыгызны өмет итеп калдым. Һәм дә хөрмәтле һәм кадерле тутабыз Бибисаҗидәгә чиксез күп һәм бетмәс-төкәнмәс сәламнәребезне җибәреп ирештердем. Шулай ук энебез Габделвәһһаб белән сеңлебез Бибимәсрүрәгә һәм сеңлебез Өммеһанигә гадәттәгечә чиксез һәм бетмәс-төкәнмәс сәламнәребезне юлладым. Һәм дә кадерле һәм хөрмәтле тутабыз Гөлчәһрә белән хөрмәтле һәм кайгыртучан җизнәбезгә, барлык гаиләсенә чиксез күп һәм бетмәс-төкәнмәс сәламнәребезне җибәреп ирештердем, һәм дә картларның иң яхшы күңеллесе булган бабабыз Зиннәтуллага чиксез күп һәм бетмәс-төкәнмәс сәламнәребезне җибәреп ирештердем. Һәм дә хөрмәтле һәм кадерле әбигә бик күп сәлам күндердем. Сәлам соңында үз тарафыбыздан безнең хакта сорый калсагыз, Аллага шөкер, сау-сәламәтләрбез бу көнгәчә; моннан соңгысы Хода кулында. Үзебез хәзерге көндә мәдрәсәдә укып торабыз. Дәресебез — «Тәркиб»не чыгып барабыз. Быел укырга акчабыз юк иде. Шулай булса да Аллаһе Тәгалә бер юл ачты: Гурьевтагы бай туганнарым унбиш тәңкә акча бирде һәм үзебезнең ахун җизни биш кадак чәй бирде... (тигән) егерме биш тәңкә бар иде. Шул акчалар берлә, Ходага тапшырып, мәдрәсәгә кереп укып торабыз. Апай янына бер атнада бер кайтып киләмен. Аллаһе Тәгалә файдалы гый-

лем бирсен иде, дип, һәрвакыт хәер-фатихада булуыгызны өмет итәбез һәм үтенәбез. Анабыздай булган тутабыз Бибигазизәдән гадәттәгечә бик күптин-күп сәламнәребезне җибәреп ирештердем.

Һәм дә үзегезнең җибәргән әманәтегез сәламәт тапшырылды. Рәхмәт, Алла риза булсын, гомерегез озын булып, байлыгыгыз һәм бәхетегез көннән-көн артып торсын. Һәм дә хат язганда андагы хәлләрнең барысын әйтеп языгыз, һәм дә үзегезгә ярты кадак чәй белән бер яулык җибәрдем һәм бер исле сабын. Аз булса да, күп күреп алыгыз. Икенче җибәргәндә, Алла теләсә, күбрәк җибәрербез. Тагы ни языйк? Сүз күп иде, әмма без кыскарттык. Тәмам булды.

## 2. АПАСЫ САҖИДӘГӘ

***1903 ел, 30 июнь***
***Уральскидән Өчилегә***

Биисми Габдулла бине Мөхәммәдгариф Тукаев.*

Фөтүвәтле вә сәгадәтле җизнәмез илән миһербанә вә мөшфика Саҗидә апайга биниһая догаи-сәламләремне васил вә мөтәвасил әйләдем. Кәзалик мөгаззәзә вә мөхтәрәмә сеңлемез Бибимәсрүрә илән энемез Габделвәһһабка бездән күп-күп дога вә сәлам диеңез. Вә дәхи хөрмәтле атамыз бәрабәрендә улан бабамызга, әһлияи мөхтәрәмәләрене шамилән, биниһая дога вә сәлам, дидем.* Сез туганымның йибәргән әманәт вә хатларыңызи ушбу үткән кышта алдым. Үзем йоклаган вакытта, баш очыма куеп киткән. Торып карасам, бер савыт манпаси һәм какъ тора. Соңра какыңыздан һәр апаларыма өлеш чыгардым. Бик рәхмәт укыдылар. Бу әманәтләрне биреп киткән кешене таба алмадым. Зинһар, гаеп итмәңез. Инша Алла, мондин ары һаман хәбәрләшеп торырмыз. Үзем әлхаль мәдрә-

---

* Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев исеме белән.

Киң күңелле һәм изгелекле җизнәбез белән йомшак күңелле һәм шәфкатьле Саҗидә апайга чиксез күп теләк һәм сәламнәремне ирештердем. Шулай ук кадерле һәм хөрмәтле сеңлебез Бибимәсрүрә белән энебез Габделвәһһабка бездән күп-күп теләк һәм сәлам, диегез. Һәм тагын хөрмәтле атабыз урынында булган бабабызга, хөрмәтле гаиләләрен дә кертеп, чиксез күп теләк һәм сәлам, дидем.

*Әлхаль* — хәзерге көндә.

сәдә таләбе голүмдәмен. Дәресем «Шәрхе мелла»дыр[1]. Кадәри халь сарфы иҗтиһад идәмез.* Һәрничек хәер-фатихада булышаек. Сездән янә бер илтимасым бар: Сез, җизнәңнән күп сәлам, дип язасыз. Ләкин җизнәм нә исемдә вә кайда тәхсиле голүм иткән — шулары бәңа бик мәҗһүлдер. Мөмкин булса, хат язганда мәгълүм итеңез. Бервакыт, Кырлайдан Өчилегә җыенга килгән вакытымда, бабайларда җизнәмнең яңа кияү вакыты иде. Исеңездәме, мин икеңезнең хәлвәт бүлмәсенә кереп чәй эчтем, әмма яшьлегемнән бернәрсә фәһемләмәдем. Мөшфика апаем! Синең сабый вакытта һәм хәзер дә иткән изгелекләреңне кабердә ятсам да онытмам. Анам дарелбәкайә рихләт иткәч, бабайлар өендә бәңа мәрхәмәт күзе илән караучы юк иде, мәгәр син бар идең.** [...] дия золым-җәберләренең җәрәхәте җәннәте гаденгә керсәм дә, йөрәгемнән китмәс. [...] ...ләр дә шуның тәвабигыннан иде... дөрестен әйтеңез. [...] хәзер ничек тора, һәм ул да Саҗидә апай илән бер атадан, бер анадан туганмы? Йә булмаса ул мыеклы әбидән[2] туганмы?

Хәзер дә атам-анама һаман Коръән укып торам, мәүлам кабул итсен. Бу үткән кышта Кырлайдагы анам да кура җиләге кагы җибәргән иде. Атам бер елдан бирле авыртып ята икән. Сезнең җибәргән чиккән аяк чолгавыңызны, апай төсе дип, кадерләп кенә тотамын. Үзем дә хәзер тәмам мөстәкыйль булдым. Бүләкләр йибәргәләрмен. Хәзер бу җулы йибәрә алмадым, зинһар, рәнҗи күрмәңез. Язачак сүзләрем күп иде, икътисар иттем. Мондагы апаларым барчасы сәламәтләр. Сезнең догаларыңызны үтенеп, сәлам, диделәр. Бик ашыгыч яздым.

*Хәерле гомерләреңезне теләп язгучы талибел-гыйлем Габдулла...*

---

* Хәлдән килгәнчә тырышабыз.
** Күп нокта куелган урыннар кулъязмада бозылган, танылмый.
*Таләбе голүмдәмен* — гыйлем алам, укыйм.
*Илтимас* — үтенеч.
*Тәхсыйле голүм итү* — уку, белем алу.
*Мәҗһүл* — билгесез, мәгълүм түгел.
*Хәлвәт бүлмәсе* — кияү белән кыз ялгыз кала торган бүлмә.
*Фәһемләмәү* — аңышмау.
*Мөшфика* — шәфкатьле.
*Дарелбәкайә (бәкага) рихләт итү* — үлү.
*Җәннәте гаден* — оҗмах.
*Тәвабигъ* — иярчен.
*Икътисар итү* — кыскарту.
*Талибел-гыйлем* — гыйлем эстәүче, укучы.

## 3. ТУГАННАРЫ АБДУЛОВЛАРГА

***[1904] ел, 26 апрель***
***Уральскидән Гурьевкә***

Сезки ике дөньяда сәгадәтемә сәбәп улан шәфкатьле агаларым Әхмәди әфәндем илә Әүхәди әфәндемә ля ниһаятьлә сәлам вә хәер-фатихаларыми иһда итдекем бәгъдендә, сездән дә хәер-дога өмид итдем. Ушандак мөкәррәмә Газизә апаем сезләргә күп-күп догаи сәлам күндерде, һәр икемез сәламәтләрмез. Ул бари Тәгалә сезләрне дә һәр ике йортта сәламәт кыйлсын дию догадамыз.

Хәзрәтеңезә мәгълүм булсын, Садыйк Әмирев исеменә җибәргән ун сум акчаңызны 22 апрельдә ахшамнан соң юлыгып алдым. Безнең кеби ятим шәкерт нәкадәр шатланганы һәм нәкадәр сезгә рәхмәт укыганы сезләргә билгеледер. Инша Алла, бу изгелекеңезгә каршы изгелек кыйла алырмын дип Алладин өмидем бардыр. Мин кыйла алмасам, ятимнәр вә талибләр атасы улган Аллаһе Тәгалә хәзрәтләре сезгә изгелек кыйлыр. Аяте кәримә: Валлаһе ля йозыйгы әҗрәл-мохсинин (аяте кәримә)*. Шәһәремездәге дамелла ахун Мотыйгулла хәзрәт илән үземнең хәлфәм һәм Сибгатулла хәзрәт мәхдүмнәренең остазы Сираҗетдин хәлфәгә[1] сезләрнең хәзер җибәргән ун рубляне күрсәткән идем, бу рәвешчә кычкырып сезләргә хәер-дога кыйлдылар: «Ярабби илаһи, ушбу ятим шәкертнең хәленә мәрхәмәт кыйлып, акча җибәргән Гурьев байларының күңелләрен һәрвакыт шат кыйл вә ул җумартларның дошманнарын мәкъһур әйләп, йөзләрен түбән капла, вә һәм ул байлар солтаны улан Абдуловларны бөтен җир йөзенә мәшһүр вә данлыклы кыйл, вә янә һәртөрле бәла вә казалардан үзең сакла вә җирләрен җәннәт кыйл. Ярабби, яүме кыяматтә[1] кояш сөңге озынлык якын килеп, халыкның миләрен кайнатып, бәгырьләрен көйдердектә, бу җумартларны гарше күләгәсендә күләгәләндер!»

---

* Ярдәм итүчеләрне Алла савапсыз калдырмый (кадерле аять — Коръәннән).

*Ля ниһаятьлә* — чиксез күп.

*Иһда итдекем бәгъдендә* — җибәргәннән (ирештергәннән) соң.

*Ушандак мөкәррәмә* — шулай ук хөрмәтле.

*Бари Тәгалә* — юктан бар иткән (бөек) Алла.

*Талиб* — укучы, шәкерт.

*Мәхдүм* — мулла улы.

*Мәкъһур әйләү* — тар-мар итү, җиңү.

*Яүме кыямәт* — кыямәт көне, дөнья беткән көн.

*Гарше* — Алла тәхете.

Ушбу мәзкүр ике оҗмах юлбашчыларының догасын мин фәкыйреңез күңелемә бикләп алып, бу рәвешчә сезләргә бәет илә дога кыйлдым:

И әфәндем, Хак сәни даимән мәсрүр әйләсен:
Кем сәңа дошман улырса, аны мәкъһүр әйләсен;
Һәм шәҗагать, һәм сәхавәт сәндә мәҗмугъ әйләсен;
Җөмлә галәм халкы үзрә сәни мәшһүр әйләсен.

Имди сездән үтенечем: бән бичараны үзеңездән гайре адәмнең күзенә тилмертеп карата күрмәңез. Һәрвакыт Аллаһе Тәгалә хәзрәте күңелеңезгә тәүфикъ нуры кертеп, изгелек кыйлмак, сәдака вирмәк ниятеңез булса, мине дә исеңезгә төшереңез... Мәкәрҗәгә барышлый безне зыярәт итәрсез дип, апай берлә икемез дә Гурьев тарафына дүрт күз берлә карамактамыз. Һәрвакыт хат язып торырмын. Сез дә җавап языңыз. Башка сүзләрем дә күп иде, икенче хатымда язармын.

Даимән хәерле гомерләреңезне теләп язгучы мелла Габдулла бине мелла Мөхәммәтгариф.

*Интиһа*

## 4. ПИРМӨХӘММӘТ НИЯЗОВКА

***1904 ел, 11 декабрь***
***Уральскидән Әстерханга***

Мөхтәрәм әфәндем!

«Тәмәдден, яхуд Мәгарифе исламия» ичүн йибәрелмеш парәңез вакытында кәлмеш иде. Адрәсеңез дәфтәрә каид улынмыш иде. Фәкать «Тәмәдден» китабының вәгъдәсендә чыйкмасына беркач гозер вә сәбәбләр улды. Шимди у китаб синзур өченче дәфга уларак тәслим улынды. Без у китаби, иншаллаһе Тәгалә, шөбһәсез, бастырачагыз. Сезә һәм басылдыгы кеби эстәдегеңез кадәр йибәрәчәңез.

Уральск шәһәрендә Мөхәммәд Камил әл-Мотыйгый-Төхфәтуллин ичүн кантурщик

*Габдулла Тукаев*

---

* Бөтен дөнья халкына.
*Хак* — Аллаһы.
*Даимән мәсрүр әйләсен* — һәрвакыт шат кылсын.
*Шәҗагать* — батырлык, гайрәт.
*Сәхавәт* — юмартлык.
*Мәҗмугъ әйләсен* — туплансын (Ходай тарафыннан).
*Интиһа* — бетте.

### *Хатның хәзерге әдәби телгә тәрҗемәсе:*

Хөрмәтле әфәндем!

«Мәдәниләшү яки Ислам мәгарифе» өчен җибәргән акчагыз вакытында килгән иде. Адресыгыз дәфтәргә теркәлгән иде. Тик «Мәдәниләшү» китабының вәгъдә ителгән вакытта чыкмавына бераз сәбәпләр булды. Хәзер ул китап цензурага өченче тапкыр бирелде. Без ул китапны, Аллаһе Тәгалә боерса, һичшиксез бастырачакбыз. Басылуы белән Сезгә дә теләгәнегез кадәр җибәрәчәкбез.

Уральск шәһәрендә Мөхәммәт Камил әл-Мотыйгый-Төхфәтуллин өчен конторщик

*Габдулла Тукаев*

## 5. ГЫЙЛЬМЕТДИН ШӘРӘФКӘ

***1907 ел, 9 июнь***
***Уральскидән Казанга***

Хөрмәтле Гыйльметдин Шәрәф әфәнде!

Тарафыңызга заказной бандероль уларак «Әшгар мәҗмуга»мне йибәрдем. Шигырьләрнең мөкаддәм-моаххир басылуын рәкымнәр илә яздым. Үзеңез аерырсыз. Зинһар, яхшылап тәсхих итеп басыңыз. Азсынсаңыз, ушбу арада тагы бәгъзе тәхрират йибәрермен. Үзеңез дикъкатьләп карап чыгыңыз да, нәшер итәргә разый булсаңыз, миңа тизлек берлә 50 тәңкә акча йибәреңез. Ихтимал, андин соң Казанга үзем барып, китабымны лично тәсхих итеп бастырырмын. Әгәр разый булмасаңыз, китапны кире үземә кайтарыңыз. Инде мин Сезгә бөтенләй тапшырдым. Ничә мәртәбә бастырсаңыз да рөхсәт.

Җавап көтәм. 7 июньдә мәктүбеңезне алдым. Шартыңызны кабул итәмен, димешсез.

*Бәндәңез Г.Тукаев*
*Адресым: г. Уральск, гост. «Казань», А.Тукаеву*

---

*Әшгар мәҗмугам* — шигырьләр җыентыгым.
*Мөкаддәм-моаххир* — бер-бер артлы.
*Рәкым* — сан (цифр).
*Тәсхих иту* — карау-дөресләү.
*Бәгъзе тәхрират* — «кайбер шигырьләр, язмалар» мәгънәсендә.

## 6. ГЫЙЛЬМЕТДИН ШӘРӘФКӘ

***1907 ел, 5 июль***
***Уральскидән Казанга***

«Тарафыгызга тагы да «Шүрәле» вә «Тәрбиятел әтфальгә» сәрләүхәле шигырьләремне күндердем. Шуларны «Китмибез!» вә «Бездә истигъдад бар» шигырьләре белән бергә рисаләнең башына куярсыз. «Кечкенә генә бер көйле хикәя» (бу әсәр тиздән матбугатыбызда чыкса кирәк) сәрләүхәле шигырь басылмый калса да зарар итмәс зан итәм».

## 7. АПАСЫ ГАЗИЗӘ ГОСМАНОВАГА

***1907 ел, 30 декабрь***
***Казаннан Уральскигә***

Мөхтәрәмә Газизә апай!

Вакыты бераз үтә төшкән булса да, Сезне гайде сәгыйд Корбан берлә тәбрик итәм: гайде Корбан котлы вә мөбарәк булсын! Мәстүрә абыстай аркылы йибәргән хатыңыз, әманәтеңез һәм әманәт сүзеңез сәламәт тапшырылды. Илтифатыңызга бик мәмнүн вә мөтәшәккермен. Әманәт сүзеңезне тәмам Сез теләгәнчә җиренә тиздән китерәчәкмен. Әле бу арада бик яхшы гына авырып алдым. Хат яза алмадым. Кәефем вә тормышым яхшы. Дуст-ишләр күп. Казанда тору күңелле, Уральски бик сирәк искә төшә. «Шүрәле» китабы[1] җибәрдем. Монда кечкенә вакытымда тәрбия иткән әнкәмне дә таптым.[2] Иртәгә күрешмәкче булдым.

Хәзергә хуш.

*Г.Тукаев*

## 8. ГАБДУЛЛА КАРИЕВКӘ

***1907 ел, 30 декабрь***
***Казаннан Уральскигә***

Хөрмәтле аркадаш Габдулла Хәйруллин[1] җәнабләре!

Сезне иң элек гайде сәгыйд илә тәбрик итәм (ахыры көннәре булса да). 30 декабрь тарихлы мәктүбеңезне алмаклә

---

*Гайде сәгыйд Корбан* — изге Корбан бәйрәме.
*Мәмнүн вә мөтәшәккермен* — шат һәм рәхмәтлемен.

мәмнүн булдым*. Бичара караңгыда калган Уральск мөселманнарына шактый зыян сачмакчы икәнсез. Эшләреңездә парлак сурәттә муаффәкъ булуыңызны** телим.

Бу сәнә гаҗәп булды: Сез дә, һаман бертөсле караңгы вә ямьсез булган эт оясыннан чыгып, кояш күрдеңез; дөнья гиздеңез; мин дә менә, Казанны вә туган җирем булган Казан арты авылларын күреп, күп гыйбрәтләр вә хиссиятләр алдым. Мин хәзер Казанда инде. Уральскидә вакыт шуны сөйли-сөйли авыз суларым кибеп бетдеге вә шунда бару хакында шигырьләр яздыкым Казанда инде.

Әлхәмделиллаһ. Монда күңелле. Дуст-иш, зыялылар күп, сөйләшәбез, көлешәбез, укыйбыз, тәгаттый әләфкярдә булынабыз***. Кызык соң. Шулай да, Казанга килгәч, каты-каты гына хәстәләнеп алдым. Ахры, һавасы килешмәде. Үзем теләп кенә «Әл ислах»ка хезмәт итәм. Жалуние башка җирдән алам. Әйе, Уральскидә берничә сабый балалар тарафыннан надан вә җаһиланә чыгарылган «Яңа тормыш»[2] монда килеп тора. Мәрхүмнәр! дим дә куям.

*Г.Тукаев*

## 9. АПАСЫ ГАЗИЗӘ ГОСМАНОВАГА

***1908 ел, 27 март***
***Казаннан Уральскигә***

Сөекле гаммәм Газизә апай!

Каз вә кортлы майларыгызны алгач, Сезгә бер хат язган идем, алгансыздыр. Шул вакыттан бирле Сездән бер дә хатхәбәр алганым юк. Әллә адресымны белмисезме? Белмәсәгез, менә язам:

В гор. Казань, книгоиздательство «Китаб»,

Абдулла Тукаеву

Вәссәлам. Мин Казаннан, әүвәл язганча, бик разый. Тагын әйтәм, дус-иш күп. Күңелле, укыган кызлар берлә дә танышырга туры килде. Гәзитәләр күп. Китаплар һәр көн яңадан-яңа чыгып тора. Укыймыз, үземез дә язамыз. Әле бу арада тагы бер зур гына шигырь китабы яздым. Монысы, һәртөрле матур буяулы сурәтләр илә зиннәтләнеп, балаларга бүләк өчен язылды. Тиздән басылып чыгачак. Чыккач та, Сезгә җибәрермен.

---

* Хатыгызны алып шат булдым.
** Якты, зур уңышка ирешүегезне.
*** Фикер алышабыз.
*Гаммәм* — эти белән бертуган апам.

Моннан элек басылган ике төрле китабымның бер төрлесен Сезгә җибәргән идем. Бер төрлесен тагы бу хат белән җибәрәм.

Миннән 10 тәңкә акча сорагансыз икән. Аны мин Сезгә яки бүләк итеп, яки акчалата җибәрсәм кирәк.

Казанга килгәч, ике китап язып, 50 шәр тәңкәдән 100 тәңкә акча алган идем. Ләкин расход күп. Укырга кирәк, һәртөрле китаплар алырга, номерга, керләргә, ашарга, киемгә — һәммәсенә акча кирәк.

Бәлки, Сез Казаннан тапкан әнкәем хакында сорашырсыз. Яңа бистәдә җимерек кенә, җир астындагы бер өйдә бер карчык бар икән. Көннәрдә бер көн мин ничектер шул өйгә чакырылдым. Анда мине әнкәем көтеп торачак иде. Вакыт төн иде. Мин, әллә нинди баскычлардан төшеп, караңгыда шул өйгә барып кердем. Кергәч тә, түрдә яше 40лардан узмаган диярлек, кара кашлы, кара күзле, тулы гәүдәле бер хатын күренде. Моның әни икәнлеген танып: «Исәнме, әни», — дип күрештем. Ул кулын бирде дә: «Син дә сәламәтмени соң әле?» — дип егълап җибәрде. Минем дә күңелем йомшарды да ничек тә үземне тота алдым. Соңыннан сорашып белдем ки, бу карчык минем әнинең анасы икән. Әнинең мин барындагы ире үлгәч, әни Баһави ишәк[1] мөритләреннән берсенә барган икән. Ул мөрит, мине намәхрәм дип былчылдап, мине әни берлә күрештермәскә карар биргән икән.

Шул сәбәпле әни, төнлә берлә генә, үзенең мөритеннән яшеренеп, аналарына килеп, мине чакырткан икән. Әбинең, мин барганда, самавыры кайнаган иде. Без әни белән кара-каршы утырып чәй эчә идек. Шул заманда әни мине: «Угылым, саклан, тәүфикъле бул, Казан бик бозык, сиңа мин әйтмичә кем әйтер», — дип үгетли иде. Мин дә: «Ярар, ярар», — дип баш ия идем.

Әби бер яктан, калтыравыклы тавыш белән: «Кызым, җитәр инде. Зинһар, тизрәк кайт. Кияү бик тар холыклы кеше, монда килеп, әллә ниләр куптарыр», — дип, минем илә сөйләшеп торган әнине ашыктыра иде.

Әни һаман, аның сүзенә илтифат итмичә, миңа: «Әмма әүвәлге этиең исән булса иде!» — дип, бу иреннән риза түгеллеген сөйли иде. Мин дә шундый уңмаган мөриткә эчемнән дошманлык саклый идем. Ахыры әни китәргә җыенды. Миңа: «Мин хәзер кайтып чәй әзерлим, син барырсың», — диде. Мин: «Соң синең белән бергә утырырбызмы?» — дидем. Ул: «Юк, ирем белән бергә утырырсыз, мин күренмәм», — дигәч, мин, ул мөритне күрәсем килмәгәнлектән, бармыйм, дидем. Бу эш Корбан бәйрәменең 3 нче көннәрендә иде. Мин гарәфә көнне әнигә кеше аркылы бүләкләр җибәргән идем, шунда этигә дә күлмәклек, ыштанлык җибәргән идем. Шуның өчен ул мөрит минем аның

өенә баруыма риза булган. Менә шуннан бирле без беребезне беребез күргәнебез юк. Бу тугърыда язу җитәр.

Без хәзер Әхмәт байның угылы[2] илә бергә «Китап» нәшрияты исемле бер ширкәт ясадык. Һәртөрле яңа китаплар сатып алып, үземез бастырып сатабыз. Һәр көн һәр тарафларга җибәрәбез. Мин китапларның хаталарын төзәтәм. Хак куям. Сораган кешеләргә җибәрәм. Контора минем номерымдадыр. Бу эштән дә яхшы гына акча алам. Әлхасыйль, хәлем яхшы, әлхәмделиллаһ. Әле Оренбургтан да мине чакырып хат килде; «Вакыт» гәзитәсендә, «Шура» журналларында эшләргә; 40 тәңкә айга жалуние бирәләр. Ләкин мин хәзергә анда бара алмыйм. Оренбург язучылары илә гәзитә аркылы бераз чәкәләшеп алган идек. Шуңа күрә алар, хатны минем үземә язмыйча, бер иптәшемә язып, мине чакырганнар.

Иртәгә Казанда әдәбият кичәсе була. Анда Казанның барча мөселманнары, хатын-кызлары — һәммәсе җыела. Мин шунда үземнең «Утырышу» атлы шигыремне җырларга өстемә алдым.

Сораганнарга сәлам диярсез.

*Энегез Г.Тукаев*

## 10. ГАБДЕРАХМАН ДӘҮЛӘТШИНГӘ

***1908 ел, 9 июнь***
***Казаннан***

Хөрмәтле Габдерахман әфәнде!

Менә Сезгә актык мәртәбә мөрәҗәгать итәм: әгәр Сездә миңа тиешле акча, үзеңез әйткәнчә, беткән булса да, пожалуста, Сез хәзер 25 сум акча биреп йибәреңез әле. Мин Сезгә, вәгъдәм буенча, тиздән бер китап бирермен[1].

Ушбу көннәрдә Оренбургка хат яздым. Анда барсам[2], баргач та акчаңызны йибәрермен. Китап та минем өсттә калыр.

Китап басылып беткәч, «Сабах»тан үзеңез күпме барын алырсыз. Әле Гыйльметдиндә[3] дә алачак бөтен. Пожалуста, [сүземне] кире кайтармаңыз, бер җәйге пальто алмакчы идем бу көннәрдә.

*Г.Тукаев*

## 11. ФАТИХ ӘМИРХАНГА

***1908 ел, 23 июнь***
***Казаннан Серноводскига***

Фатих әфәнде! Сәлам, конечно.

Хатыңызны алдым. «Әл-ислах»та «Кызык гыйшык» шигырен яраттыңызмы? Керпе үзенең кабыгына кереп яшеренгән

төсле, мин дә, сөю хакында бернәрсә язсам, ялган имзалар астына сыгынам. Язам шунда. Үзем хәзер бернәрсәне дә, беркемне дә сөймим. Күңел эчү белән тәмам бозылган.

Уянды хандра* күңелемдә инде,
Караңгылык күңелдә нурны җинде!

Торам-торам да: «Ярабби! Ятимлекләр, фәкыйрьлекләр, ачлыклар, авылдан авылга сатылып йөрүләр, рәхимсез татар байларында хезмәт итүләр, татар мәдрәсәсендә черүләр арасында да саклап килдекем истигъдад очкыны шушы исереклекләр, исерек иптәшләр арасында бер дә кабынмаслык булып сүнәрмени инде?» — дим.

Тәмам бер сәнә җон агызып йөрим бит!

Бу хәл туйдырды инде тәмам. Оренбургка Фатих Кәримев чакырган иде. Анда барсам, бәлки, үземә мөгайян эш булуы һәм серьезный кешеләр тирәсе файдалы булыр иде, дим. Нишлим? Барыйм микән?

Монда «Әл-ислах» ходка китсә, көлке журналы да чыкса, үземнең кальбән сөйгән гәзитә вә идеямә хезмәт итәр идем. Ләкин бу да бәгыйд. Шушы минем кайгым тугърысында бер-ике юл языңыз әле. Һаман үземне генә сөйлим икән. Сезнең кәефләр нәсыл, әфәндем? Анда баргач, тәәссереңез ничек булды? «В.-К.»да «Татарин» имзалы бер зат теге Касыйм Уралецка җавап язды[1]. Сезгә кирәк булса, шул номер газетаны җибәрермен.

Монда хосусый минем хәл искечә. Көндез «Ислах» идарәсенә барып утырам. Кич «Швейцария», «Аркадия», «Панаевский»ларга[2] барам. Мин әле кая барам.

Соңгы номерга бернәрсә дә яза алмадым. Бик озын бер хат языңыз әле, зинһар.

*Г.Тукаев*

## 12. ГАЙНЕТДИН ТУПРИЕВКӘ

***1909 ел, 13 март***
***Казаннан Уральскигә***

Мөхтәрәм Гайнетдин әфәнде!

Хатыңызны алдым. Рәхмәт. Бу көнгә кадәр җавап яза алмаганымны кичерәсез. Казан бит, ахры, һаман кайныйбыз. Төрле яктан төрле кешеләр, җавап язмыйсың, дип үпкәләп язалар. Эш тә ул кадәрле күп-күп түгел дә, әллә нигә бушап булмый.

---

* «Хандра» сүзе җәяләр эчендә рус хәрефләре белән басылган.
*Истигъдад* — булдыклылык, талант.
*Кальбән* — чын күңелдән, йөрәктән.
*Бәгыйд* — ерак.
*Нәсыл* — ничек.

Минем хәлләрне сорыйсыз. Минем хәлем Ходайга каршы мыгырданырлык түгел.

Казан күңелле. Мөхәррирләрдән, укучы яшьләрдән гыйбарәт дустларым күп.

Монда бай байбәтчәләр дә гомумән диярлек русча укыган вә һәр җәһәттән аз-күп мәгълүматлылар. Шул сәбәпле аларга да катышам. Бәгъзан Казанның иң бай вә иң мөгътәбәр гаиләләре эченә дә кереп утырырга тугъры килгәли.

Җитди вә көлмичә язган нәрсәләремне «Әл-ислах»ка бирәм.

Һөҗүви вә көлке нәрсәләремне «Яшен»гә тапшырам.

Ара-тирә рисалә вә мәҗмугаләрем дә мәйданга килә.

Мадди җәһәтне шулар илә тәэмин итәм.

«Яшен»нең секретаре мин булганга, анда бик күп язарга тугъры килә. Шул сәбәпле төрле-төрле мөстәгар имзалар артына яшеренәм.

«Чүкеч» безгә каршы язган була. Ләкин без шундый икътидарсыз, каләмсез, бәхетсез вә зәгыйфь дошманнарымыз барлыгына тик куанабыз гына.

«Яшен» журналын, мәгаттәәссеф, Сезгә йибәрә алмыйм. Чөнки һәр номерының бер нөсхәсе булсын калмыйча бетте. Озак чыкмый торганга, халык бик сагынып каршы ала.

Уральскинең үзенә вә җаһил татарларына һәммәсенә киткән вакытымда ләгънәт укып киткән идем.

Шуңар күрә Рәкыйбе[1] булсын, аның бозавы вә Ишәк Хәсәнҗаны[2] булсын — һичбере тугърысында хәзер сиңа язасым вә шуларны исемә төшерәсем килми.

Муеннары астына килсен шунда ул сыерларның!

Кирәк-яракларыңызны һәммәсен менә шушы адрес илә соратыңыз:

Казань. Книгоиздательство «Сабах».

Бу көтепханә Сезгә һәр теләгәнеңезне йибәрер. Әгәр наложный платеж илә алдырырга теләмәсәңез, ул Сезгә простой посылкада йибәрер. «Мине Тукаев белә» дип, аларга язган хатыңызда язсаңыз, мин Сезне белгәнемне аларга, әлбәттә, сөйләрмен. Простой посылкада йибәрергә яраганлыгын әйтермен.

---

*Бәгъзан* — кайвакыт.
*Һөҗүви* — сатирик, юмористик.
*Мөстәгар* — уйлап чыгарылган; псевдоним.
*Икътидарсыз* — сәләтсез.
*Мәгаттәәссеф* — кызганычка каршы.
*Җаһил* — надан.

Үзем андый эшләр артыннан, чынын әйтим, йөри алмыйм.

Ике Бәдри абзыйга да вә барча җәмәгатьләренә дә миннән сәлам укырсыз.

Камил вә хәзрәтләрнең[3] кәйфият хәлләрен вә ни дәрәҗәдә мәгыйшәт иткәннәрен язсаңыз, яхшы булыр.

Беркөннәрдә нә имзасы вә нә тарихы бар бер хат алган идем. Кемнеке икәнен белмәдем; белмәсәм дә, Фәссах Фәттахевнекедер[4], дидем.

Шуңар күрә аңар да сәлам.

Мәдрәсәдәге караңгы вә ямьсез торышлар күз алдыма килеп, кайвакытларда кәефне йибәргәли.

Безнең яшь гомеремезне бушка тәләф иткәне өчен мәдрәсәсенә, бөтен шундагы схоластикасына ләгънәт укыйм.

Уйлап торам да:

— Ну укытканнар икән безне! — дип куям.

Имеш, без дә курс бетереп, студент булып чыкканбыз. Имеш, безне дә мәгыйшәт берлән көрәшергә коралландырып чыгарганнар!

Габдулла Кари берлә 5–6 ай бергә дип әйтерлек тордык. Яхшы вә кабилиятле артист булып килә. Аның истикъбале парлакъ.

Гайнетдин кари[5] чүплегеннән котылганына куана.

Мин дә аның әрәм булып, теләнче булып калмавына шатланам.

Әйдә теләнсен Гайнетдин кари, әйдә теләнсен Фәссах кари!

Габдулла Кари хәзер труппада үзе баш. Әле Оренбургта. Хатлары килеп тора.

Язга Уральскигә кайтып, андагы хәлләрне карап килергә дә исәбем юк түгел.

Хәзергә хуш әле, иптәш.

Хат яз, ярыймә?

*Габдулла Тукаев*

Адресыңызны белдермәгәнсез, белдереп языңыз.

---

*Тәләф итү* — әрәм итү.
*Кабилиятле* — сәләтле.
*Истикъбале парлакъ* — киләчәге якты, нурлы.

## 13. КӘМАЛЕТДИН ХИСАМЕТДИНЕВКӘ

***1910 ел, 25 сентябрь***
***Казаннан Уральскигә***

Борадәр Кәмалетдин әфәнде!

Һәр өч хатыңны да алдым. Җавап язмаганым өчен гафу итәсез. Чөнки һичкемнең хатына да каршы җавап язмыйм. Әллә нигә ялкауландым. Хәзер бер җирдән дә хат килми. Барысы да миннән җавап булмаганга тукталдылар.

Хатыңны «Юл» көтепханәсенә күрсәттем. «Дөруссеш шифаһия[1]»нең ничәнче җөзьэләрен һәм нәхүнең нинди нәхү вә кем тәэлифе икәнлеген аерым язуыңызны үтенәләр. Дәфтәрдә, чынлап та, җибәргән акча вә маркаларыңыз күренми.

Шулай да, хат язып, нәрсә вә ни сумага китап сораганыңызны язсаңыз, Сезгә ышанып китаплар җибәрелер.

*Бакый ихтирам Г.Тукаев*

## 14. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1910 ел, 9 ноябрь***
***Казаннан Сарашка***

Хөрмәтле Сәгыйть Сүнчәләй әфәнде!

Миңа дустанә озаткан кулыгызны мәгальмәмнүният кысып кабул иттем. Кулыма төшкәндә, шигырьләрегезне укыйм. Шөбһә юк. Сездә милләткә яки шөһрәткә бик кызу мәхәббәт бар. Әмма һәр язганыгызны нәфис вә изящный дип әйтсәм, мин, Сезгә дуст булудан бигрәк, монафикъ булудан куркам. Шунда да әллә кайчан чыккан «Бәянел хак»ның бер номерында Сезнең манарага менгән һәм балалар: «Чыпчык икән, диделәр дә көлештеләр», — дип туктаган шигырегезне чынлап та ярattым. Әгәр таба алсам, ул шигырьне тиздән чыгачак бер мәктәп китабына нәмүнә рәвешендә дә алырга ниятем юк түгел. Борадәр! Мөмкин кадәр, шигырьне аз язсагыз да, матур вә хуш

---

*Борадәр* — туган.
*Җөзьэ* — том, китап.
*Нәху* — синтаксис.
*Кем тәэлифе* — кем төзегән яки язган.
*Бакый* — мәңге.
*Мәгальмәмнүният* — шатлык белән.
*Монафикъ* — икейөзле, хыянәтчел.
*Нәмүнә* — үрнәк.

иттереп язгыгыз. Сәнаигы нәфисә аз гына бер хата сәбәпле тупас һөнәрләрдән булып китүе бар.

Аннан соң Сезнең шигырьләрегездә мин провинциальный һәм төп халык телендә булмаган сүзләр табам. Аларны катыштырмасагыз икән... Мин Казанны тәхте пай һәм Казан арты татарларын шушы көнгә кадәр милләтен югалтмаган вә киләчәктә дә югалтмаячак төп халык дип саныйм. Милли әдәбиятыбыз фәкать шулар телендә, шулар рухында гына булуын телим. Мин... Мәҗит Гафуриның «булмый» урынына «булмай»ларын терпеть не могу. Мин үзем лично тормыштан, аны тасвирдан, аның хакында уйлаудан тәмам биздем. Менә шул бизү сәбәбеннән менә шушылай дип бер шигырьчек яза башладым:

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшъялар төсе;
Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.
Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал урнында — анда тулган айның яктысы.
Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы[1].

Мин моңарча жизнерадостный кеше булганга, бөтен гомерен җылап үткәргән Надсонны сөймәдем[2]. Белмим, хәзер укысам — ни булыр.

Әфәндем! Хәзергә Сезгә һәр эшегездә муаффәкыять теләп вә озын-озын мөзакәрәләрне киләчәктәге мәктүбләргә кичектереп, каләмне ташладым.

*Габдулла Тукаев*

## 15. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1910 ел, 4 декабрь***
***Казаннан Сарашка***

Мөхтәрәм Сәгыйть әфәнде!

Бүлмәмдә ары-бире карандым да, каләм заты таба алмагач, карандаш белән генә язарга керештем. Дөнья искедән бирле шулай инде: итекченең аягы ялангач, язучының каләме юк. «Шильон мәхбүсе[1]»нә, минемчә, иртәрәк, көчегезнең микъдарын үлчәмичәрәк тотынганга охшыйсыз. Әүвәлдә 4–5 сәтыр-

---

[1] *Сәнаигы нәфисә* — матур сәнгать, әдәбият.
[2] *Провинциальный* — монда «диалекталь яки урынчылык» мәгънәсендә.
[3] *Тәхте пай* — башкала.
[4] *Әшъя* — әйбер, нәрсәләр.
[5] *Яшь һилал* — яшь ай (яңа туган ай).
[6] *Муаффәкыять* — уңыш.
[7] *Мөзакәрә* — сөйләшү, киңәшләшү.
[8] *Мәхбүс* — тоткын.

лык шигырьләрне асыл шагыйреннән калышмаслык дәрәҗәдә гүзәл вә нәфис чыгарырга тырышырга кирәк иде. Менә Сәгыйть Рәмиев Пушкин «Пәйгамбәр»ен, мин фәкыйрь дә Лермонтов «Пәйгамбәр»ен тәрҗемә иттек. Безнең икебезнеке дә шактый шома чыктылар. Шулай да без әле олугъ поэмаларга тотынырга батырчылык итә алмыйбыз.

«Мөселман» журналы[2] татарча чыга башласа, монда басылмаслык резкий нәрсәләремне шунда җибәрмәкче булам. Ул вакыт М. К.[3] белән хат язышa башларга кирәк булыр. Байрон рәсемнәрен кую кебиләр икенче дәрәҗәдә эшләр әле. Аларын киңәш итешербез.

Гаилә хакында минем фикерем коры гына: әгәр кече яшьтән фәләнне... сүә истигъмаль итеп, рәфыйкаңнең синдәге хакын бөтенләй үк тәләф итмәгән булсаң, син аны, ул сине якыннан белеп яратышсаң, шуның өстенә шәрмәндәи гыял булмасын өчен, иң азында ел тәүлегенә биш йөз тәңкә килерең булса, һәркемгә өйләнү тиеш.

Югыйсә, эчеңә сәнәк белән төрткәндә, бер тамчы кан чыкмаслык булса, ике күңелдә чын мәгънәсе белән булган мәхәббәт уты янмаса, гаилә өчен әллә нинди түбән кешеләргә мөрәҗәгать йә тәлинкә тотарга булса, — Алла сакласын!

Минем синең хатың эченә язып җибәргән күңелсез шигыремнең ахырлары да «Вакыт»ның бәйрәм номерында басылып чыкты. Укып карарсыз, бәлки. Бу хатыңа кичегеп җавап бирдем... Гафу итәсез.

Хәзергә хуш, сәламәт буласыз.

*Г.Тукаев*

## 16. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1911 ел, 1 гыйнвар***
***Казаннан Сарашка***

Сәгыйть әфәнде!

С.Р.нең[1] вәзеннәр тугърысында артык лаф сугуына исегез китмәсен. Әле без татарларда «Теория словесности[2]» вә шигырьләр өчен хорей, дактиль-фәләннәр ясалмаган чакта, вәзен

---

[1] *Сәтыр* — юл (китапта, кулъязмада).
[2] *Сүә истигъмаль итү* — бу урында «җенси азгынлык» мәгънәсендә.
[3] *Рәфыйка* — хатын.
[4] *Тәләф итү* — юкка чыгару; монда «ир кешенең җенси куәтсезлеге» мәгънәсендә.
[5] *Шәрмәндәи гыял* — гаиләне оятка калдыру.
[6] *Вәзен* — ритм, үлчәм (шигырьдә).
[7] *Теория словесности* — әдәбият теориясе.

вә гармонияләр төрлечә булса да зарар юк, фәкать мәгънә кирәк, гүзәл ифадә кирәк. Минем бу көннәрдә генә басылып чыккан «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабымны күргәндерсез, бәлки. Мин анда Нәҗип Думавиның «Сугыш», Бәширинең «Балалар теләге» исемендәге шигырьләрен, үзенә һич тә әһәмият бирмичә, фәкать мәгънәви яклары яхшы булганга күрә генә алдым. Чөнки Тургеневнең көйсез язылган «Отцы и дети» әсәре прозамыни? Анда вәзен рамкалары бер дә юк. Ә между прочим — поэзия!

«Мусульманин»да, Ходай илһам бирсә, бик каты участвовать итмәкче булам. Тормышымны сорагансыз. Казанның «Болгар» атлы номерында торам. 33 нче номер. Көндез Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов вә бәгъзан Фатих Әмирхан вә башка да интеллигентлар белән катышам. Кич белән, күрше мәйханәгә кереп, тиречеләр, итчеләр, извозчиклар, жуликлар белән катышам.

*Бакый ихтирам: Г.Тукаев*

## 17. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1911 ел, 22 гыйнвар***
***Казаннан Сарашка***

Сәгыйть әфәнде!

«Шильон мәхбүсе»н «Гасыр»[1] дөньяга чыгарса, Сезне беренче муаффәкыятегез белән тәбрик итәчәкмен.

Минем мәктәп китапларына керешкәнемне «җәл» дисең. Алай түгел. Мин мәктәпләребезнең хәл теле илә миннән ярдәм көткәнен күрдем. Мин моңа салкын кан белән карый алмадым. Мәктәп китаплары язарга башладым. Мин язган китапларымда (әлбәттә, хрестоматия) русларның Пушкине, Лермонтовы, Аксаковы, Майковы, Плещееве вә башка да бик күбе булып являться итәм. Мин иттифакый гына тәрҗемә иткән вә икътибас ителгән шигырьләрем татар мәктәбендә беренче урынны алачак булды. Шулай булгач, мин, үз шигырьләремнән чүпләтеп башкалардан мәктәп китабы яздырганчы, әллә нинди шәкертләрне күрә торып баетканчы, бу эшкә үзем тотындым. Бу мәгънән вә маддәтән минем законный хакым иде. Татар балаларының рухына файдалы тәэсирем булачак, иншалла. Шагыйрьгә матур шигырь язу читен. Әмма бер дә язмый тору аннан да читен, диләр.

---

*Ифадә* — аңлата белү.
*Бәгъзан* — кайвакыт.
*Иттифакый* — очраклы рәвештә генә.
*Икътибас иту* — файдалану, ияру.
*Мәгънән вә маддәтән* — мәгънәви (мораль) һәм материаль яктан.

Шуның кеби син дә, тик торырга авырсынсаң, Пушкин поэмасын да, башканыкын да тәрҗемә ит. Ләкин матур була күрсен, мин догада. Минем соңгы «Шура»да «...га» сәрләүхәле бер шигырем бар[2]. Укырга туры килсә, фикереңне язсаң да ярый.

Бу көннәрдә «Сабах» көтепханәсе тарафыннан минем «Күңел җимешләре» исемендә бер шигырь мәҗмугам басылып чыга. Иренмәсәм, табгы җәһәтеннән тәрбияле чыгармакчы булам әле. Шаять, сиңа бер данәсен һәдиятән җибәрермен.

Чорт белә, мин, ахрысы, сөюдә дә милләтче... Мин татар кызының телен, сөйләшү рәвешен яратам. Бер төрек шагыйре Истамбул гүзәлләре хакында шулай яза:

Куркарым җәннәттә дә гошшака рәхә булмыйя,
Үгрәнерсә шивәи хубан Истамбули хур*.

Мәгънәсен аңларсың инде, гариб тоелса, киләсе хатта тәүзыйх итәрмен. «Мусульманин»ның мөселманчасы чыгуы, әлбәттә, күңеллерәк булган булыр иде. Хәерле булсын.

*Ихтирам илә Тукаев*

## 18. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1911 ел, 11 февраль***
***Казаннан Сарашка***

Сәгыйть!

Мин кечкенә чагымда малайлар белән алма бакчасы тирәсенә бара идем. Миннән бүтән малайлар алманы коялар һәм урлыйлар иде. Әмма мин һичбер данәсенә тимидер идем. Бакчачы, минем яхшылыгымны белгәнгә, ул алманы миңа үзе бирәдер иде. Мин шул «үзе биргән» алманы, урлаган алманы ашап торган малайлар алдында: «Менә үзе бирде!» — дип, мәгърурланып ашыйдыр идем.

Мин әле кызлар тугърысында да шул ук мөгамәләдә. Бер кыз, үзе танышырга теләп, миңа яучы җибәрмәсә, мин һичва-

*« Әгәр гүзәл хурлар Истамбул шивәсендә (диалектында) сөйләшсәләр, җәннәттә дә гашыйкларга рәхәт булмас дип куркам» дигән мәгънәдә.

*Сәрләүхәле* — исемле.

*Табгы җәһәтеннән тәрбияле* — «басылышы, бизәлеше ягыннан матур итеп» мәгънәсендә.

*Һәдиятән* — бүләк итеп.

*Гариб тоелса* — ятрак тоелса.

*Тәүзыйх иту* — «ачык аңлату» мәгънәсендә.

*Мәгърурлану* — горурлану, мактану.

кыт танышырга эзләп, ваксынып йөрмим. Әмма үзе кул бирсә, тагы да «үзе бирде» дип горурланам, кадерлим ул кулны!

Мин шундый малай инде, әфәнде, алма бакчасында да, мәхәббәт бакчасында да би-и-ик акыллы. Ярар, бу калсын.

«Күңел җимешләре»[1] — вакыйган матур исем. Аны тапканга үзем дә кәефләндем. Камыт аякларны, әлбәттә, яратмассың. Андый табигый яратмауны нигә сүз итеп язасың!*

Рәмиевнең «Толстой» шигыре, минемчә дә, бөтенләй тозсыз, вәзенсез, ямьсез, бигрәк холостой выстрел.

«Саташкан», дөрес, Сәгыйть хакында[2].

Поэзия эзләргә булганда, Иделнең югары ягыннан бигрәк, түбән тарафы муафикъ. Мәкәрҗә бик коры. Халкы да, к...ә нишатыр кыстырган кеби, анда-монда йөгерешәләр, һәркем үз эшендә. Кыямәт!

«Күңел җимешләре» чыккач та, сиңа җибәрермен.

Бакый ихтирам вә сәлам.

*Габдулла Тукаев*

## 19. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1911 ел, 4 март***
***Казаннан Сарашка***

Сәгыйть!

Габди-Галимҗанның[1] вакытлы матбугатта чыккан язулары шома, ихласлы вә шактый гына төпле чыгалар. Ләкин мин аның аерым рисаләләрендә күңелдә бер-бер төрле эз калдырырлык нәфасәт вә мәһарәт күрмим. 10 сәхифәдә язылырлык бер мәүзугъка һәрвакыт әллә ничәшәр өлеш артык кәгазь исраф итә...

Бер поэма хакында башымда әнвагъ төрле хыяллар йөри. Фәкать зиһен варить итеп чыгарганы юк әле. Гаяи хыялым — татарча, татар рухында, татар геройлары белән дөньяга бер «Евгений Онегин» чыгарудыр. Алла ни бирер. Син, кулыңнан килсә, тырышып кара. Мин догада.

---

* «Татар кызын яратам» диюенә мин камыт аяклар сурәте ясап җибәргән идем бугай... (*С.Сүнчәләй искәрмәсе.*)

*Вакыйган* — чынлап та.

*Холостой выстрел* — бушка ату.

*Рисалә* — әсәр, мәкалә.

*Нәфасәт вә мәһарәт* — матурлык, нәфислек вә осталык.

*Мәүзугъ* — тема.

*Әнвагъ төрле* — «күптөрле, төрле-төрле» мәгънәсендә.

*Гаяи хыялым* — хыялымның нәтиҗәсе.

Никитиннең[2] фитрый таланты, минемчә, Пушкиннән ким түгел. Фәкать ул, тәртипле образование алып, гакылын вә рухын кирәгенчә тәрбия итә алмаган. Бу, шактый кирәкле фактор. Җитәрлек акча табып булса, җәен түгел, язын беренче парахуд илә Әстерханга Сәгыйть Рәмиевкә кунакка китмәкче булам, вә аннан икәүләшеп кыргыз арасына кымызга бармакчы булабыз. Ният җәй буе Идел өстендә йөрү һәм, мөмкин булса, Истамбулга да бер-ике атнага заглянуть. Алла ни бирә инде.

С.Р. — тумыштан ук голүвият аралаш үзсүзле булып туган кеше. Ф.Ә.[3] күптән бирле «Теория словесности» язып маташа. Мин дә аңар шул эштә азрак файдалы булмакчы булам. Шулай итеп, икәүләп, бәлки, шигырь вәзеннәре хакында бер кагыйдә вә тәртип чыгармабызмы дип торабыз.

Мин бу арада балалар өчен «Песи Г. Җамал» яки «Песибикә» исемле бер рәсемле рисалә[4] язып бетердем. Шактый муаффәкыятьле чыкты; басылып чыккач, сиңа җибәрермен. «Күңел җимешләре» ике-өч көннән чыкса кирәк. Басыла башлады.

«Халык моңнары»ның[5] икенче җөзьэнә дә бик изящный материаллар таптым. Аны стряпать итеп алырга торам. Хуш әлегә. Догада булышыйк.

*Г.Тукаев*

## 20. СӘГЫЙТЬ РӘМИЕВКӘ

***1911 ел, 4 март***
***Казаннан Әстерханга***

Эчем, тышым Ишми вә игъванына злоба белән тулды. Бөтен көтепханәләрне, матбагаларны вә газеталарны ябып бетерсәләр, бу көннән яңа киемнәремне җыртып ташлап, яланаяк чыгып йөгерәчәкмен. Күз алдым караңгыланды, милли тормыш, милли хәяттан вә үземнең хыялларымнан тәмам өмид кистем. Мин бит синең шикелле саф, коеп куйган поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә...

---

*Фитрый* — табигый.
*Кыргыз* — «казакъ» мәгънәсендә.
*Голүвият* — галилек, бөеклек.
*Вә игъванына злоба* — һәм иярченнәренә ачу.

## 21. ӘХМӘТ УРМАНЧИЕВКА

***[1911] ел, 5 май***
***Әстерханнан Казанга***

Мелла Әхмәт әкә!

Мин, малай, Әстерханда. Бу хат сиңа барганчыга кадәр булган вакытны исәпләмичә, тагын бер ай кадәре торырга карар бирдем. Киләсе хатымда рәсемнәр өчен темалар вә, булдырып булса, мәкалә вә шигырьләр дә җибәрсәм кирәк. Әле хәзер кунакка йөрүдән бушаганым юк.

Бу мәкаләләрне дөрест басарга иҗтиһад итеңез[1]. Әлбәттә, бик шәп чыкмадылар. Моны «Шүрәле» имзаи шәрифен куймавымнан да аңларга мөмкин. Кымыз эчәм. Ит ашыйм, һава яхшы. Хәзердән үк үземдә җисмән вә рухан бер көч хис итә башладым.

Квартирым да ничава. Сәгыйть белән бергә торабыз. Баерак вакытыңыз булса, миңа бер 5 тәңкә акча җибәрсәңез, яхшы булыр иде. Ят җирдә кирәк бит...

Һәрхәлдә, адресым:

Астрахань, ред. газ. «Идель», Сагиду Рамееву.

Үз исемемә (хосусән акча булса) җибәрергә ярамый.

*Г.Т.*
*5 май, [1911] сәнә, Әстерхан*

## 22. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1911 ел, 20 октябрь***
***Казаннан Сарашка***

Мелла Сәгыйть! Бу хат белән теге, вәгъдә иткәнем Садриның[1], ачык хатын җибәрәм. «Шура»да һәм «Идел»дәге «Мусульманство»ны яклаган мәкаләләреңне укыдым[2]. Балаларга ярдәмгә килүем тугърысындагы дөрест фикереңә тәхсин. Бүген сигезенче көн инде авыруым килми. Авыруына кайгырмаганым шикелле, сәламәтләнүенә дә куанмыйм. Барыбер. М-гә[3] мин, әлбәттә, яхшы тәэсир калдырганмындыр. Чөнки аның алдында мин һаман көлдергечлек ролен уйнадым, һәм аның безнең Казанның бәгъзе интеллигентләреннән аерым булуына вә укып та чукынмаганлыгына, һаман татар булып калуына таянып, аннан бер дә тартынмыйча, алдына рухымны ачып салдым.

«Мусульманство» һәм «Мусульманин» кешеләре[4] хакында монда төрле сүзләр сөйләнгәнгә генә тәвәкъкыф итәм. Югыйсә

---

*Имзаи шәрифе* — кадерле имза.
*Тәхсин* — рәхмәт.
*Тәвәкъкыф итү* — тукталып тору.

миндә «Мусульманство»ның татарчасына бастырырга шигырьләр бар.

Син аларны кемнәр дип танийсың? М. ул кавказлыларга алданып йөрми микән?

Мин хәзергә шулкадәр генә язам. Вакытым аз.

*Бакый сәлам вә ихтирам. Г.Тукаев.*

## 23. СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙГӘ

***1911 ел, 15 ноябрь***
***Казаннан Сарашка***

Сәгыйть!

Бер кешенең гәзитәдә: «Хөррият! Инсаният! Исламият!»— дип кычкыруы гына аның рухын аңларга җитмәгәнлеге сиңа билгеле инде. Моңар Мөхәммәт ага Карабиков, Сабир әл-Хәсәни кеби зате галиләр үз әфгале илә шәһадәт итәләр. Бу замандагы яурупалылар нәрсә тарихында изге ат калдырса, шуңар түгел, нәрсә әле бүген дә тамак туйдырса, шуңар тотыналар, түгел аерым личностьлар, хәтта бөтен милләтләр шул эш илә генә мәшгульләр. Бу күз алдында.

Сине мин һәр тугърыда садәдил кеше таптым. Мин үзем дә, Казанга килмәс борын: «Гаяз Исхаков ашый-эчәме икән?» — дигән кызык бер шөбһәле фикердә идем. Ләкин Казанга килгәч, бөтен милләтчеләрне күреп, хәлләрен аңладым. Мәгаттәәссеф, алар минем колагыма: «Синең шигырьләр халыкка үтә, фәлән хакка гына саткансың икән, без фәләнне биргән булыр идек»,— кеби ачкүзле сүзләре илә мине мыскыллый башладылар. «Киләчәкне тәэмин итәргә кирәк-фәлән», — дип лыгырдадылар. Миңа, һәрвакыт милләт вә миллият фикере белән рухланып, илһамланып торган шагыйрьгә, табигый, ул сүзләр тәхкыйрь иде. Мин нишлим аларның киләчәкләре белән? Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора. Миңа хәзерге вакыт кадерле. Хәзерем шулай мәгънәле булганда, миңа киләчәкне-миләчәкне уйлау хәрам иде. Аларның киләчәкләре минем шул матур дәкыйкаләремдә дә мөтәрәттәб булса булыр иде.

Ләкин алар миңа тынычлый бирмәделәр: «Син бу язганыңны безгә бир, фәлән нәшир сиңа аз биргән, ул — вөҗдансыз!»

---

*Зате гали* — бөек кеше; монда ирония белән әйталгән.
*Әфгале* — эшләре.
*Садәдил* — гади, эчкерсез.
*Мәгаттәәссеф* — кызганычка каршы.
*Тәхкыйрь* — хурлау.
*Дәкыйкаләремдә мөтәрәттәб* — минутларда тәртипкә китерелгән.

Менә шулар мине тәмам ваксыттылар, изделәр... Алар миңа дүрт ел буе «киләчәкне тәэмин!», «кеше»чә тору, киенүне, тагы әллә нәрсәләрне лыгырдадылар. Шул тавышлардан миндә бер колак шаулавы пәйда булды. Башым эшләми, хиссиятем тупасланды; беттем, һавада очкан кошлар шаһы-шаһинәне атып төшерделәр. Җитәр әле.

Язмыйсың, дисең. Ләкин менә шушы хаттан күрәсең бит: мин никадәр үзем белән мәшгуль! Шуңар күрә күп яза алмыйм. Соңгы хатыңда күңелсезлектән зарланасың:

> Яшь җаныңны синең яшь хатының
> Бер дә генә җуатмыймыни?[1]

*Сәлам вә ихтирам. Г.Тукаев*

## 24. ГЫЙЛЬМЕТДИН ШӘРӘФКӘ

***1912 ел, 1 гыйнвар***
***Өчиледән Казанга***

Ниһаять, авылга кайтып җиттем. Сандык шикелле кечкенә генә, нараттан салган ак өй — үземнеке. Көненә ике ягылганга, бик җылы, тәмам чишенеп йоклыйм. Иртә белән яңа сауган җылы сөт эчәм. Гомумән, тегенди сөтне дә күбрәк эчәргә тырышам. Фәкать әле авылларда сыерлар бозауламаган икән. Хәзер үк үземдә бераз яхшыру вә хәлләнү сизә башладым. Казаннан алып кайткан даруларны да истигъмаль итәм. Эшләр болай барса, бер-ике айдан сихәтләнермен кебек...

## 25. ӘХМӘТ УРМАНЧИЕВКА

***1912 ел, 1 гыйнвар***
***Өчиледән Казанга***

Әхмәт!

Мин монда. Хәзергә кайтуымнан бик мәмнүнмен. Киләчәктә дә хәзән булмас кеби. Казанның арты бигрәк кара. Берничә авылга кереп күрдем. Минем хәзерге торган мулла братыма ир вә кыз балаларга иҗек укытырга мәҗбүр. Бу якта һәркайда мәхәллә халкы мулланы авызлыклаган.

---

*Шаһ-шаһин* — патшалар патшасы.
*Истигъмаль итү* — куллану.
*Мәмнүнмен* — шатмын.
*Хәзән* — кайгы.

«Ялт-йолт» чыккач, миңа җибәрерсез әле. Русча көлке журналлары җибәрегез. Иншалла, рәсем мәүзугъlары вә мәкаләләр җибәрсәм кирәк. Түбәндә адресым булыр. Фатихтан[1], бер дә ялыкмыйча, «Ялт-йолт»ка язгалаштыруын просить ит. Колагын тондырганнан соң, гаҗиз калып, бер-ике нәрсә язса да файда. Габди[2] тавышы ахыры ни булып калды? Ул беркөн, бик шәбәеп, «Ялт-йолт»ның соңгы номерын эзләп йөридер иде. Ник эзләгән? Нәтиҗәсе юкмы әле? Берәр җирдә журналга бәйләнеп язарга йөрми микән?.. Журналдагы сез ычкындырган ... сүзенә бәйләнүе ихтимал.

Хат вә матбугат көтеп

*Габдулла Тукаев*

Адресым:

Дер. Малый Верезей

Казанской губ. и уезда

Ново-Кишитской волости

Указному мулле К. Кабиру Амирову.

Астына, татарча язып, миңа тапшырылуын үтенәсез.

Бу адресны, кем сораса да, бирмәгез. Гыйльметдингә[3] дә шулай яздым.

Әхмәт! Син калушны кәрзинкәгә салган кебек идең. Ул ничектер монда килмәгән. «Шәрекъ»тә калмаганмы? Аннан соң минем паспорт «Шәрекъ»кә килергә тиеш. Килгән булса, зинһар, тизлек белән миңа җибәр. Әллә, мин булмагач, кире авылга кайтарганнармы? Белеш әле.

*Г.Т.*

## 26. ӘХМӘТ УРМАНЧИЕВКА

***1912 ел, гыйнвар***
***Өчиледән Казанга***

...Февраль урталарысыз монда сыерлар бозауламас. Минем максады аслыем булган сөт вә катыкны шуңарча туйганча эчеп булмас, ахры. Шунда да көннән-көн яхшырам кебек. Казанга апрель башларысыз кайтмаска дип торам. Чөнки «Болгар» белән «Шәрекъ»тән өмид өздем[1]. Барыбер, Щетинкин вә Колесниковка күчсәм[2] дә, салкын булыр кебек. Теге рәкымнәр астында языла торган нәрсә 20 рәкымнән артты. (Син күргәндә 7 рәкым иде.) Әгәр хөсне хатимә белән тәмам булса, исе-

---

[1] *Максады аслый* — төп максат.
[2] *Рәкым* — цифр.
[3] *Хөсне хатимә* — яхшы нәтиҗә.

мен дә «Рәкымнәр астында» куярмыз. «Рәкымнәр астында» пессимистический рух белән башланган иде, монда бөтенләй оптимистландым, ахры. Ул да үзгәрде... Миңа «Горе от ума» белән Лермонтов «Полное собрание»сен җибәрә күр әле, кирәк... Әле, авыл хатирәсе булыр дип, бер юрган, ике мендәр эшләтеп алдым. Моннан соңра мин фатирда гына торачак булганга, бунлар тормышта да әһәмиятле нәрсәләр...

## 27. ӘХМӘТ УРМАНЧИЕВКА

***1912 ел, 11 май***
***Уфадан Казанга***

Әхмәт! Менә бүген 11 май, ягъни Казаннан чыкканыма тәмам бер ай тулганда, сиңа хат яза алам. Уфада гына торган булсам, хат түгел, мәкаләләр дә язган булыр идем. Ләкин әллә нинди бер мәшьум җил ташлап, Питерга барып чыктым. Анда Казанда көчкә качып котылдыгым гыйнвар суыгына барып эләктем. Барган көннүк үкчә күтәреп китәсе иде. Ләкин мин, сәфәрем бернәрсәгә охшасын инде дип, үземчә аны мәшругъ ясарга тырышып, шул кабахәт шәһәрдә 12–13 көн гомер үткәрдем. Бер-ике мәҗлестән бүтән бер җиргә дә чыга алмадым. [Бизгәк] һәр көнне дә килә — аспиринне эчеп, җөрәкне әллә никадәр зәгыйфьләндердем. Кайсы көнне икешәр мәртәбә эчә идем, чөнки суыкка чыдап булмый иде. Петербургта университет докторына күрендем, кыяфәте белән пәйгамбәр төсле кеше икән. Ул Петербургтан китәргә, кымыз белән даруланырга кушты. Аны Шакир Мөхәммәдьяров[1] минем номерыма алып килгән иде.

Уфага кайткач, Петербург суыгының вә аспириннең гаять тә сүэ тәэсире чыга башлады. Ләкин бу шәһәрнең һавасы ләтыйф, саулык багышлар булганга, хәвефсезрәк күрәм. Ак Идел буендагы бакчага барып, берничә сәгать агач төпләрендә кырын ятам. Шунда ук кымыз да бар. Шушы көннәрдә инде Троицкигә китәсе булып торам. Керләрне, хатларны анда җибәрерсең. 38 нче «Ялт-йолт» гомумән яхшы чыккан. Мәскәү мулласының лекциясен әүвәлге биткә басарга кирәк иде. Бу номерда да әдәпсез сүзләр бар. Шундый сүзләргә юл киселсен иде. Тагы ун номердан журналның ике еллык җүбәләе

---

*Мәшьум* — шомлы.
*Мәшругъ* — кеше төсле, рәтле.
*Сүэ тәэсире* — зарарлы йогынтысы.
*Ләтыйф* — йомшак.

була бит. Тырышмалы. Фатих Сәйфигә сәлам. Һәм һәрнәрсәгә бәйләнергә өлгерүенә вә шактый...* дип сораучылар булгалады.

Әлегә мин Троицкигә барып урнашмыйча яза алмам, кәефем шәп түгел. Үземне мөтәкаррир белмим. Тән урнашмагач, җан урнашмый. Җан урнашмагач, фикер урнашмый. Шунлыктан бернәрсә дә язып булмый. Иншалла, язармын әле. 37 нче номерның беренче сәхифә рәсемен Галиәсгар[2] тагын бозып чыгарган. Аңар да рәхмәт! Остроумныйрак бер темабыз шул иде, ул да чыкмады. Гыйсмәтине[3] күрсәң, сәлам. Аңар минем хәлне сөйлә. Үзенә дә язмакчы булам. Муса Коръәнен (тәрҗемәсен) бик ул кадәр яклап язмаска вә айныграк, равнодушныйрак карарга кирәк иде, чөнки аның теле юк. Бу — бер. Укып, Коръәннең гадилеген белеп, халык аннан йөз дүндерсен яки яхшылыгын белеп, иһтида итсен, дигән максудларның һәр икәвенә дә хезмәт итә алмый, чөнки чуаш теле**.

Әгәр Русиядә Коръән тәрҗемә ителергә кирәк булса, мөтәрҗимлеккә иң муафикъ кеше — Риза казый[4]. Чөнки ул «Әсма», «Сәлимә» кеби китаплары[5] белән куәи тәхририя вә хәтта шигъриясен күрсәткән вә гомумән ифадәсе ачык, язу тарызы садә вә гүзәл бер язучыдыр.

Әллә аның гарәбияте Мусадан кимме?! «Яңа» дип һәрнәрсәгә мөкиббән кителмәскә вә бигрәк тә Казан матбугатына айнык караштан аерылмаска кирәк иде.

Керләрне җибәргәндә, почтада җугалмаслык итеп, эченә минем корзинкада онытылып калган кара тышлы дәфтәрне дә җибәрсәңез иде, зинһар. Ул дәфтәрдә минем «Җан азыклары»[6] дигән почти шул мәҗмугалек шигырьләрем бар.

Хәзер Уфада булсам да, сезнең өчен адрес:

Троицк (Оренб. губ.). Абдуррахману Рахманкулову.

Передать А.Тукаеву.

*Бакый сәлам вә ихтирам. Г.Тукаев*

---

* Биредә бер юл, кәгазь бөкләнгән урынга туры килеп, юылган, танымаслык хәлгә килгән.

** «Әдәби татар телендә яңгырамый» дигән мәгънәдә.

*Мөтәкаррир* — карарланган, урнашкан дип.

*Иһтида иту* — яхшы юлга төшү.

*Мөтәрҗимлек* — тәрҗемәчелек.

*Куәи тәхририя* — язу көче.

*Ифадә* — сөйләп, аңлатып бирү.

*Язу тарызы садә* — стиле җиңел.

*Гарәбияте* — гарәп телен һәм әдәбиятын белүе.

## 28. КӘБИР БӘКЕРГӘ

***1912 ел, 12 май***
***Уфадан Казанга***

Мелла Кәбир!

...Мин кайтып җиттем. Эшләр көткәнчә. Уфа докторына кан тәхлиле тугърысында бардым. Ул әүвәл тазарырга, сәламәтләнергә кирәклеген вә бу кадәр беткән тәнне тәхлилгә вә, анда микроб булган тәкъдирдә дә, аңар агулы дару җибәрү мөмкин түгеллеген сөйләде. Җүтәлдән бер-ике төрле дару бирде. Кымыз эчәргә кушты. Уфада кымыз бер генә җирдә. Публика дәрхаль эчеп бетерә. Шулай да күп көнне бер-ике бутылка ләктерәм...

Монда чәчәк тә агач исе. Теге аспирин җоттыра торган авыру (бизгәк) күптән бетте...

Сез нишләп йөрисез? Иблис галәйһи... кайларга барырга киңәш бирә? Шакиргә[1] шундый пәйгамбәр төсле кешесе өчен рәхмәтме — ни генә әйтим. Кәрим Сәгыйдевкә күп сәлам. Сафа әфәндегә[2] хосусый хат яздым...

Тиздән китмәк булам (ягъни Троицкигә). Хатны шушы адрес белән язарсың: «Троицк, Оренбургская губерния. Габдрахман Рахманкуловка (Тукаевка)». Шәрифел Әхмәдигә[3] сәлам. Мәскәүдән соң, Ходай тугъры китереп, урыным яхшы булды. Вагонда буфет та бар иде. Бернәрсәгә дә аптырамадым. Әлегә җитәр.

*Тукай*

## 29. ГЫЙЛЬМЕТДИН ШӘРӘФКӘ

***1912 ел, 11 июнь***
***Троицкидән Казанга***

Монда бер тарафтан хәлем яхшы, казакъ бае шикелле, иткә тук, кымызга гарык булып торам. Урыным Троицкидән 25 чакрым җирдә, һәр тараф сахра. Ике казакъ өеннән башка бернәрсә дә күренми. Күңелсез, эч поша. Шунысы изә. «Авыруым, тагы яңалары башланмаса, бетә инде. Ләкин терелеп нәрсә бар? — дип карыйм каравын. Ач кеше вакытның соң икәнен белсә дә ята: «Торып нәрсә бар?» — ди. Мин дә шулай, өмидем юк.

---

*Тәхлил* — анализ.
*Дәрхаль* — шунда ук.

## 30. ӘХМӘТ УРМАНЧИЕВКА

*1913 ел, 10–25 гыйнвар*
*Казаннан*

Әхмәт!

«Яңа ел» рәсеме ярар да, пожалуй; фәкать аның астына «Әзалияттән очып килгән Яңа ел үзенә дөньямызда урын да таба алмый», — дип язарга кирәк. Шулай тәфсилләмәсәң, татар аңламый. Менә уртада дигәнең татар фәһеме өчен авыр. Иң элек — татар «Марс»ны белми. Бу рәсемне аңлар өчен белергә тиешле хикәячекне белми.

«А воз и ныне там» сүзен «Ә җөк һаман да шунда» дип язып, ни аңлатабыз? Бүтән җиңел рәсем табылганчы, сабыр итмисеңме? Минем фикерем шул.

## 31. ФАТИХ ӘМИРХАНГА

*1913 ел, февраль (?)*
*Казан, Клячкин шифаханәсеннән*

Больница хадимнәре миңа: «Ник алданрак больницага кермәдеңез?» — диләр. Мин аларга: «Без больницаны үлемнең әүвәлге стансасы дип беләмез. Аз булса да дөньяда торып калыйм дип әйттем», — дидем.

## 32. ФАТИХ ӘМИРХАНГА

*1913 ел, 18 март*
*Казан, Клячкин шифаханәсеннән*

Фатих!

Мәкаләне бик сирәк нәрсәне баскан кеби зурлап баскансыз[1]. Рәхмәт. Тагы да язмый булмас, ахры, дип торам әле.

Хәтереңдә булса, Шиһаб хәзрәтнең[2] әллә кайсы гарәп шагыйреннән алып Болгар манарасына язган бәетен язып җибәр әле. Хәзер үк.

«Кояш» тәртипсез килә. Соң килә. 72 нче номер бер көндә өчәү килде. Бу көнге номер икәү килде. 73 не исә бөтенләй

---

*Әзалият* — мәңгелек дөньясы; монда « Ә очсыз-кырыйсыз, галәм — космос» мәгънәсендә.

*Фәһеме* — аңы, зиһене.

күргәнем юк. Зинһар, хәзер бер номерын җибәрсәгез лә! Зәкәрия абзыйга[3] сәлам.

*Бәндәгез Тукай*

## 33. ӘХМӘТГӘРӘЙ ХӘСӘНИГӘ

***1913 ел, 20 март***
***Казан, Клячкин шифаханәсеннән***

Мөхтәрәм Гәрәй әфәнде!

«Бер мөхәрриргә» шигыремдә[1] «Аң»га лаек дәрәҗәдә үк нәфасәт күрмәгәнемә күрә, «Мәктәп» журналына бирдем. Анда да ул шигырьне баш сәхифәгә керттермәдем. Ахырда вә незаметныйрак җирдә китәчәк. 7 нче санда минем шигырь бик аз вә кешегә сизелерлек аз кергән. Өстәп йибәрергә бер нәрсәм бар иде. Инде, әлбәттә, соңдыр. Иншалла, 8 нчедән дә гафил калмам. Бер шәй язармын. Шулай да 7 нчегә өстәргә материал алып китсәң ярыйдыр иде. Көн дә сине көттем. Хәер ула.

*Г.Тукай*

## 34. ЗӘЙНӘП ХӘСӘНИЯГӘ

***1913 ел, 28 март***
***Казан, Клячкин шифаханәсеннән***

Мөхтәрәмә Зәйнәп ханым!

8 нче санга бар кадәремне җибәрдем. Беренче корректурын үземә күрсәтсәңез икән. Аннан соң шушы язылган микъдар шигырьнең һәммәсе бер номерга кереп бетсә иде. Шулай булганда, ул шактый көч булырлык. Хәер, «Толстой сүзләре»нең бер-икесен синзур бозар кеби сизәм. Ул вакыт һәммәсенең басылуы мәҗбүри үк булыр.

*Г.Тукаев*

---

*Нәфасәт* — матурлык, гүзәллек.

# ИСКӘРМӘЛӘР ҺӘМ АҢЛАТМАЛАР

## 1906

7 бит.

**Кыямәт көне.** «Әлгасрел җәдит» журналының 1906 елгы 4 нче (15 апрель) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнгән Г.Тукайның дүрт томлы «Әсәрләр»ендә[1] (Казан: Таткнигоиздат, 1955–1956; төзүчеләре — Хәй Хисмәтуллин һәм Якуб Агишев) басылган. Текст журналдан алынды.

*«Әлгасрел җәдит» («Яңа гасыр»)* — 1906 елның 15 гыйнварыннан 1907 елның 15 маена кадәр (барлыгы 17 сан) Уральскида Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин (1883–1940) редакторлыгында чыккан әдәби, фәнни һәм иҗтимагый журнал.

Әсәр, Коръәннең аерым сүрә һәм аятьләрендә сурәтләнгән күренешләрен истә тотып, назыйрә рәвешендә язылган.

[1] *Сур мөгезе* — бу сурдан (быргыдан) кычкыртып, Исрафил фәрештә бөтен үлгәннәрне терелтәчәк.

[2] *Гарәсат мәйданы* — кыямәт көнендә Аллаһы каршына хөкемгә җыела торган урын.

9 бит.

**Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?** «Фикер» газетасының 1906 елгы 17 апрель (14 нче) санында баш мәкалә урынында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өч томлы Г.Тукай «Әсәрләре»нә[2] (Казан: Яңалиф, 1930–1931; төзүчесе — Фатих Сәйфи-Казанлы) кертелгән. Текст газетадан алынды.

«*Фикер*» — 1905 елның 27 ноябреннән 1907 елның 13 маена кадәр (барлыгы 73 сан) Уральскида Камил Мотыйгый редакторлыгында һәм наширлегендә чыккан газета.

[1] *Гозәер пәйгамбәр йокысы* — Аллаһы тарафыннан йөз еллык йокыга талдырылган пәйгамбәр.

[2] *Мәксәлмина, Мәслина, Дөбернуш, Шаднуш, Кәфәштатыюш* — Коръәннең берничә сүрәсендә тау тишегенә кереп (дошманнардан качып), Аллаһының ирке белән анда 309 ел йоклаган җиде егет турында сүз бара. Болар — бишесенең исеме.

[3] *Сөләйман мөлке* — Коръәндә искә алынган Сөләйман пәйгамбәр Аллаһының ирке белән эш йөртеп бик баеган була.

[4] *«Сагълук» китабы* — гарәп телендә язылган китап.

[5] *Әндәлес* — Испаниянең урта гасырларда гарәпләр кулында булган тарихи өлкәсе (Андалузия). Ул заманнарда гарәп мәдәниятенең эре үзәкләреннән булган.

[6] *Бохара козгыннары* — Бохара ягында иске ысул белән (кадимчә) укып кайткан муллалар һәм ишаннар истә тотыла.

11 бит.

**Граф Лев Толстой җәнабләре язадыр.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 25 май (19 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. I томы Татарстан Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшерену институтында, II томы СССР Фәннәр академиясе Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнгән Г.Тукайның академик басмасында[3] (Казан: Татарстан дәүләт издательствосы, 1943, 1948; төзүчелә-

---

[1] Бу басма моннан соң беренче дүрттомлык дип кенә исемләнәчәк.

[2] Бу басма моннан соң өчтомлык дип кенә исемләнәчәк.

[3] Чынлыкта ул академик басмаларга куела торган бөтен таләпләргә җавап бирми. Тукайның күп кенә әсәрләре аңа кертелмәгән, ул тулы түгел. Шулай да моннан соң без аны кыскалык өчен академик басма дип кенә исемләрбез.

ре — Хәй Хисмәтуллин һәм Якуб Агишев) беренче мәртәбә басылган. Текст газетадан алынды.

Әсәр рус язучысы Л.Н.Толстойның «Ильяс» (1885) исемле хикәясеннән иҗади тәрҗемә.

15 бит.

**Сүз башы.** «Уклар» журналының 1906 елгы 1 нче (июнь) санында журналның программа мәкаләсе рәвешендә «Дугъры» имзасы белән басылган. СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнгән Г.Тукайның биш томлы «Әсәрләр»енә[1] (Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1985–1986; төзүчесе — Рашат Гайнанов) беренче мәртәбә кертелгән. Текст шуннан алынды.

*«Уклар»* — Уральскида 1906 елның июненнән алып ноябренә кадәр (барлыгы 6 сан) Камил Мотыйгый редакторлыгында чыккан рәсемле айлык сатирик журнал.

17 бит.

**Ялкаулык, яхуд Җиңел кәсеп.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 25 июнь (23 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр академик басмага кертелгән. Текст «Фикер» газетасыннан алынды.

Фельетонда автор Казанда аталы-уллы Сәйдәшевләр чыгарган «Бәянел хак» газетасында (фельетонда: «Лап-лап-лап») мәкаләләр бастырган мулла Гарифулла Салиховтан көлә (вакыйганы исә Уральскиның «Казанская площадь»ындагы кибеттә барган итеп сурәтли).

19 бит.

**Тугъры җавап.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 25 июнь (23 нче) санында имзасыз басылган (бу санда ачык имзасы белән чыккан бер язмасы алда кителде). Беренче мәртәбә биш томлыгына кертелгән. Текст «Фикер» газетасыннан алынды.

[1] *«Габдел хак» исемле гәзит* — «Бәянел хак» газетасы истә тотыла.

20 бит.

**Алай-болай.** Баш өлеше «Фикер» газетасының 3 июль (24 нче) санында «Биик усал» имзасы белән, ахыры 21 июль (27 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст «Фикер» газетасыннан алынды.

[1] *Сабир муллалар вә Садыйк муллалар* — сүз Уфа шәһәре мулласы Сабир Хәсәнов (1866–1917дән соң) һәм Казан шәһәре мулласы Садыйк Иманколыйлар (1870–1932) турында бара.

[2] *«Тәрҗеман» бабай* — бу елларда Кырымда (Бакчасарайда) Исмәгыйль бәк Гаспралы (Гаспринский; 1851–1914) тарафыннан «Тәрҗеман» газетасы чыгып килә.

[3] *Әхмәт бай* — Әхмәт Хөсәенов (1837–1906), Оренбург сәүдәгәре, миллионер, җәмәгать эшлеклесе.

[4] *23 нче номер «Фикер»дә... язылган иде бугай.* — «Ялкаулык, яхуд Җиңел кәсеп» фельетоны истә тотыла.

[5] *«Бәянел батыйль»* — «Бәянел хак» газетасы.

[6] *Кязиб мулла әл-Имансызый* — Садыйк Иманколый.

[7] *З. әл-Кәмали* — Зыя Кәмали (1873–1942) — мулла, дин галиме, җәмәгать эшлеклесе.

[8] *«Таң йолдызы»* — 1906 елда Казанда башта Гали Путиляков, 10 нчы саннан Сәгыйть Рәмиев (1880–1926) редакторлыгында чыккан газета; фактик редакторы — Гаяз Исхакый (1878–1954).

---

[1] Моннан соң биштомлык дип кенә исемләнәчәк.

[9] *«Тәрәкъкый» гәзитәсе* — 1906 елда Ташкентта Исмәгыйль Габиди редакторлыгында чыга.

27 бит.

**Погром.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 10 июль (25 нче) санында «Уральск кешесе» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст «Фикер» газетасыннан алынды.

Фельетон Уральскидагы бер төркем затларның «Фикер» газетасы тоткан позициягә каршы эш алып барулары уңае белән язылган.

[1] *кәвеш тегүче Шәрәфетдин абзый* — Шәрәфетдин Галиуллин, Уральск һөнәрчесе.

[2] *Хәйрулла Гаделшин* — Уральск сәүдәгәре, миллионер.

[3] *бер мулла* — Уральск мулласы Гайнетдин Җәлалетдинов.

[4] *Фәссах карый* — Фәссахетдин Нәзиров.

[5] *Габдерәкыйп хәзрәт* — Уральск мулласы, Габдерәкыйп Тулбаев.

[6] *Гайниҗамал хәзрәт* — Гайнетдин Җәлалетдинов.

[7] *Камил әфәнде* — Камил Мотыйгый.

[8] *Мәннафов* — Уральскида ресторан тотучы.

29 бит.

**Уральск имамнарына ачык хат.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 10 июль (25 нче) санында «Идарә» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә Г.Тукайның дүрт томлы «Әсәрләр»енә[1] (Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1976; төзүчесе — Рашат Гайнанов) кертелгән. Текст газетадан алынды.

«...ачык хат»ның эчтәлеге «Алай-болай» һәм «Погром» фельетоннарында сурәтләнгәннәр белән бәйле.

[1] *Шәрәфетдин Каниев* — Уральск сәүдәгәре.

[2] *Тау Гайни* — Уральск сәүдәгәре Гайнулла Гаделшин, Хәйрулла Гаделшинның агасы.

[3] *мөәззин Ярулла әфәнде* — Ярулла Гафиятуллин.

32 бит.

**Гайниҗамал хәзрәтнең дәхи бер ялганы.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 14 июль (26 нчы) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Фельетонның эчтәлеге алдагы мәкаләләр белән бәйләнештә ачыла төшә.

[1] *Шәрулла бай* — Хәйрулла Гаделшин.

33 бит.

**Урамда.** «Уклар» журналының 1906 елгы 2 нче (июль) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Сатирик парчада Фатих Кәрими (1870–1937, язучы, нашир, җәмәгать эшлеклесе) белән Гаяз Исхакый (1878–1954, язучы, җәмәгать эшлеклесе) арасында («Вакыт» һәм «Таң йолдызы» газеталары битләрендә) 1906 елның май-июнь айларында булып алган «бәрелешү» турында сүз бара.

34 бит.

**Хакны белеп инкяр кылу.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 21 июль (27 нче) санында «Уральск кешесе» имзасы белән басылган («Ахыры бар» дип куелса да, ахыры күренми). Беренче тапкыр беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Бәянел батыйль»* — «Бәянел хак» газетасы.

[2] *«Фикер» сахибе* — Камил Мотыйгый.

---

[1] Моннан соң икенче дүрттомлык дип кенә исемләнәчәк.

35 бит.

**Шәһәремездәге зур тәмгылы муллаларә бер-ике сүз.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 21 июль (27 нче) санында «Берничә кешеләрнең үтенүе буенча, вәкил — «Уральск кешесе» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Мәкалә газета редакторы Камил Мотыйгый һәм аның атасы Мотыйгулла Төхфәтуллинга каршы алып барылган кампания уңае белән язылган.

37 бит.

**Идарәдән.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 28 июль (28 нче) санында баш мәкалә булып имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Мәкаләдә бу көннәрдә «Фикер» газетасы яклы булган «Борһане тәрәккый» (Әстерхан, 1906–1911) һәм «Әлгаләмел исламия» (Уфа, 1906–1907) газеталарына да рәхмәт белдерелә. Аларның теле шактый дәрәҗәдә чуар булганлыктан, Тукай да мәкаләсен бу вакытларда искерә төшкән тел элементларын кулланып язган.

39 бит.

**Идарәдән җаваплар**. «Фикер» газетасының 1906 елгы 4 август (29 нчы) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка «Ф.Әмирханга җавап» исеме белән кертелгән. Текст газетадан алынды.

Фатих Әмирхан, поляк инкыйлабчысы Марек Конкольнең «Коммуна 71 года. Краткая история восстания парижских рабочих в 1871 году» исемле брошюрасын рус теленнән татарчага тәрҗемә итеп, кульязмасын «Әлгасрел җәдит» журналы редакциясенә җибәрә, һәм ул Тукай кулына килеп керә. Ләкин кульязма Тукайга каралама булып кына күренгән. Хәер, Ф.Әмирханнан акка күчерелгәнен көтеп тормаганнар булса кирәк: тәрҗемә тиздән журналның 1906 елгы 6 нчы (10 июнь) һәм 8 нче (10 август) саннарында ук «Фатих әл-Әмирхани» имзасы белән басылып та чыга.

39 бит.

**«Тәрҗеман»ның кязибе.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 11 август (30 нчы) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] «*Ха-ха-ха*» — 1906 елда Кырымда И.Гаспралы чыгарган сатирик журнал (биш саны гына дөнья күрә).

[2] *Сөләйман ака илә Иван аканың мөкяләмәсе* — «Ха-ха-ха» журналында бирелеп барган диалог рәвешендәге язмалар.

41 бит.

**Гүзәл бер хакыйкать.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 11 август (30 нчы) санында «Һәйьәте идарә» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

42 бит.

**Тугъры сүз.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 11 август (30 нчы) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

43 бит.

**Алырга ашыгыңыз!** «Уклар» журналының 1906 елгы 3 нче (август) санында «Һөд-һөд» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст шуннан алынды.

43 бит.

**Ахун хәзрәтләрнең сатылулары.** «Уклар» журналының 1906 елгы 3 нче (август) санында «Шәкерт угы» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

44 бит.

**Яңа дәгъва.** «Уклар» журналының 1906 елгы 3 нче (август) санында «Адвокат» имзасы белән (текстның соңгы абзацына «Идарә» имзасы куелып) басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Азат» гәзитәсе вафат булган иде.* — Казанда 1906 елның 1 февраленнән 28 маена кадәр нәшер ителгән газета; редактор һәм наширләре — Габдулла Апанаев һәм Галиәсгар Камал. 56 номеры гына чыгып кала. 9, 10, 44 нче саннары конфискацияләнә, редакторы хөкемгә дә тартыла. Аның дәвамы рәвешендәге «Азат халык» газетасы озак яшәми, 1906 елның 12 сентябренә кадәр нәшер ителә.

44 бит.

**Тимерчыбыксыз телеграм хәбәрләре.** «Уклар» журналының 1906 елгы 3 нче (август) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

45 бит.

**«Өлфәт»кә җавап.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 18 август (31 нче) санында «Идарә» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

*«Өлфәт»* — 1905–1907 елларда С.-Петербургта чыккан газета, нашир һәм редакторы — Габдерәшит Ибраһимов. Аның 2 һәм 9 август (33 нче һәм 34 нче) саннарында Петропавловск мулласы, публицист Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдевнең «Заманымызның әдиб вә мөхәррирләренә гаид» исемле мәкаләсе басылган була.

[1] *«Миръат»* — журнал рәвешендәге китап һәм брошюралар, 1900–1903, 1907–1909 елларда шул ук Г.Ибраһимов нашир һәм редакторлыгында чыккан, 16сы С.-Петербургта, 6сы Казанда дөнья күргән.

45 бит.

**«Заманымызның әдиб вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсенә гаид.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 18 август (31 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

48 бит.

**Уральскидә хөррият бәйрәме.** «Таң йолдызы» газетасының 1906 елгы 2 сентябрь (37 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Сәет Баттал» китабы* — «Сәет Баттал газый хикәясе», XIII гасыр төрек әдәбияты үрнәге. Сәет Баттал — әсәрнең баш каһарманы.

49 бит.

**«Җаваб»ә җаваб.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 17 сентябрь (34 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

Тукайның «Заманымызның әдиб вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсенә гаид» исемле мәкаләсе чыккач, Хөҗҗәтелхәким Мәхмүдев «Фикер» газетасының 1906 елгы 11 сентябрь (33 нче) санында шуңа «Җавап» язып бастыра. Тукайның әлеге мәкаләсе шушы уңай белән урнаштырылган.

51 бит.

**Уральскидә Дума членын вә тәвабигын нагайкалау.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 3 сентябрь (32 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

«Уральскидә хөррият бәйрәме» мәкаләсен Тукай: «27 августта тагы бер митинг булачак. (...) Ни булыр? Тагы язармын», — дип тәмамлаган иде. Бу мәкалә-репортаж шушы вәгъдәне үтәү йөзеннән язылган кебек.

54 бит.

**Алданмаңыз!** «Фикер» газетасының 1906 елгы 11 сентябрь (33 нче) санында «Һәйьәт идарә» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *карт бабай* — Әхмәтҗан Сәйдәшев.

55 бит.

**Габдерәкыйп хәзрәтнең вәгазе.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 11 сентябрь (33 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Габдерәкыйп хәзрәт* — Габдерәкыйп Тулбаев, Уральск мулласы.

[2] *Нәмруд* — Аллаһы барлыгы һәм берлеге турында Ибраһим пәйгамбәр белән бәхәскә кергән борынгы Бабил (Вавилония) хөкемдары.

56 бит.

**Татар диненчә мөселман булу.** «Уклар» журналының 1906 елгы 4 нче (сентябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Тишекбаш»иһи* — «Кисекбаш» китабы истә тотыла.

56 бит.

**Яңа камустан берничә лөгать.** «Уклар» журналының 1906 елгы 3 нче (август) санында «Шәкерт угы» имзасы белән һәм 4 нче (сентябрь) санында («Башы 3 номерда» диелеп) «Җен» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *мөфти* — бу урында Диния Нәзарәте башлыгы мөфти Мөхәммәдъяр Солтанов (1836–1915) турында сүз бара. Аның эшчәнлеген Тукай берничә мәртәбә тәнкыйть итә.

57 бит.

**Хиссияте миллия.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 17 сентябрь (34 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *иҗтиһад мөнкариз* — «иҗат заманы үткән, борынгылар сүзе изге, яңалык өчен тырышырга кирәкми» дигән мәгънәдә.

[2] *Мәкәрҗә базарында да җыелышлар...* — «Иттифакы мөслимин» партиясенең Мәкәрҗәдә 1905 елның 15 августында, 1906 елның 13–23 гыйнварында һәм шул ук елның 15–21 августында уздырылган съездлары турында сүз бара.

61 бит.

**Муллалар.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 24 сентябрь (35 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

64 бит.

**«Казан» чәйханәсендә голяма җәмгыяте.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 24 сентябрь (35 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Ахунд М.Төхфәтуллин* — Уральскида «Мотыйгия» мәдрәсәсе мөдәррисе, Г.Тукайның мәдрәсәдәге остазы Мотыйгулла Төхфәтуллин (1846–1920).

[2] *«Уклар» журналындагы бәет* — журналның 1906 елгы 4 нче (сентябрь) санындагы «Пыяла баш» исемле шигырьдән алынган өзек. Соңгы юл журналда «Ялангач кыз, бәлеш, тәңкә, тиен дә» дип басылган була.

64 бит.

**Уральскидә Думага сайлаулар.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 1 ок-

тябрь (36 нчы) санында баш мәкалә сыйфатында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Язмада II Дәүләт Думасына сайлаулар турында сүз бара.

[1] *Торгыл, күтәрел, эшче кешеләр...* — сүзләрен дә, музыкасын да Руже де-Лиль язган «Марсельеза» җырыннан тәрҗемә ителгән строфа. «Марсельеза» — хәзерге вакытта Франция республикасы гимны.

65 бит.

**Уральскидә дарелмөгаллимин.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 1 октябрь (36 нчы) санында баш мәкалә сыйфатында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Газетада тексттан соң «Мухамеданский духовный собраниягә Уральскидә 3 нче мәсҗед җәмәгатеннән гарзы халь» китерелә. Аңа 40 кеше кул куйган, 6 нчысы — Г.Тукайныкы.

Газетаның бу санындагы «Төрле хәбәрләр» бүлегендә чыккан «Идарә» имзалы бер хәбәр «Уральскидә дарелмөгаллимин» мәкаләсенә соңгы абзац сыйфатында кушылып бирелде.

[1] *опекун* — Хәйрулла Гадельшин.

[2] *Гомәр Хөсәенев* — «Мотыйгия» мәдрәсәсе хәлфәсе, Тукай якыннарыннан.

67 бит.

**Дәхи бер фетнә.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 6 октябрь (37 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *гарзыхальләргә кул куйгучылар* — алар арасында Г.Тукай да булуы югарыда искәртелде.

68 бит.

**Уральск хәбәрләре (Уральскидә мәшһүр Мортаза...).** «Фикер» газетасының 6 октябрь (37 нче) санында имзасыз («ахыры бар» диелеп) басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Мәкаләнең шигырь өлешендәге соңгы ике юл кулъязма «Әлгасрел җәдит» журналының 1904 елгы 15 нче (4 ноябрь) санындагы Тукай шигырендә үк бар.

[1] *«Сырой егет» фельетоны* — газетаның 37 нче санында басылган.

68 бит.

**Уральск хәбәрләре (Бу сәнә «Фикер»...).** «Фикер» газетасының 1906 елгы 15 октябрь (38 нче) санында басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка «Төрле хәбәрләр» исеме белән кертелгән. Текст газетадан алынды.

Беренче хәбәрдә әйтелгән «Фикер» газетасын көндәлек, «Уклар» журналын атналык, «Әлгасрел җәдит» журналын ике атналык итеп бастыру нияте тормышка ашмый, чөнки Уральскидагы татарлар арасындагы каршылыклар нәтиҗәсендә Камил Мотыйгыйдан нaширлек һәм мөхәррирлек хокукы алына.

[1] *Гайнетдин карый* — Гайнетдин Җәлалетдинов.

[2] *Габдулла карый* — Габдулла Кариев (1886–1920), соңыннан атаклы артист, режиссер, «Сәйяр» труппасының җитәкчесе.

[3] *ихтираз партиясенә гыйбрәт* — «Фикер» газетасының «Уральск хәбәрләре» исемле язма басылган санында Нуриәхмәт хәлфә Һидиятуллинның бер аксак һәм бер таз хәлфә белән берләшеп «бер партия» (ихтираз партиясе) ясап йөрүләре тәнкыйтьләнгән була. Аларның мондый кыңгыр эшләре барып чыкмаган.

69 бит.

**Игълан.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 15 октябрь (38 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

«Уклар» журналы, 1907 елда да аны яздырып алучылар дәфтәре ачылса да, властьларның һәм кайбер Уральск кешеләренең каршылыгы аркасында 1906 елның ноябрендә (6 нчы саны дөнья күргәч) чыгудан туктала.

69 бит.

**Чит мәмләкәт хәбәрләре.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 15 октябрь (38 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Габделхәмит* (1842–1918) — 1876–1909 елларда Төркия солтаны.

[2] *Мидхәт вә Мәхмут пашаларны үтерткән* — Әхмәт Мидхәт паша (1822–1884) 1872, 1876–1877 елларда вәзир булып тора, Габделхәмит кушуы буенча үтерелә.

70 бит.

**Уральскидә җәмгыяте хәйрия башлануы.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 15 октябрь (38 нче) санында «Уральск җәмгыяте хәйриясенең бик усал бер члены» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

71 бит.

**Дәхи ниләр күрермез икән?** «Фикер» газетасының 1906 елгы 15 октябрь (38 нче) санында «Мөсафир» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Әлгаләмел ислами»* — 1906–1907 елларда Уфада чыккан газета; нашир һәм редакторы — Шәехгаттар Абызгилдин, 29 нчы саныннан редактор — Баһаветдин Максудов.

[2] *«Хәят» үлде, «Иршад» уләргә якын* — «Хәят» газетасы 1904–1910 елларда, «Иршад» газетасы 1905–1908 елларда Бакуда чыкканнар (димәк, 1906 елда әле алар «үлмәгәннәр»).

[3] *Һади абзый да үзенең «Йолдыз»ында* — нашире һәм редакторы Һади Максуди булган «Йолдыз» газетасы турында сүз бара . Ул Казанда 1906–1918 елларда нәшер ителгән.

[4] *«Азат халык»ның җарылуы* — 1906 елның июнендә Казанда Галиәсгар Камал наширлегендә һәм редакторлыгында чыга башлаган бу газета сентябрь аенда «Йолдыз» газетасына кушыла. Бу кушылуны («җарылуны») Тукай хупламаган.

72 бит.

**Төрле хәбәрләр. Яңа гәзитә вә журналлар һәм мәкаләләр.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 15 октябрь (38 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Милләт» исемле бер гәзитә* — 1906 елда Бакчасарайда чыккан.

[2] *«Карчыга» исемле бер журнал* — 1906 елның 29 сентябреннән 1907 елның 15 июленә кадәр Оренбургта чыккан (барысы 9 сан) рәсемле, көлке журнал.

[3] *«Таң йолдызы»нда бу арада Рәшит әфәнде хосусында* — бу газетада Рәшит Ибраһимовны тәнкыйтьләгән берничә мәкалә басылган була.

73 бит.

**Телсез телеграф хәбәрләре. Гәзитәләр.** «Уклар» журналының 1906 елгы 5 нче (октябрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Тылмач» исемле гарәпчә бер гәзитә* — 1906–1907 елларда Петербургта гарәп телендә чыккан «Әт-тилмиз» газетасы. Нашир һәм редакторы — Габдерәшит Ибраһимов.

[2] *«Чүкеч» журналы* — 1906–1910 елларда Оренбургта чыккан көлке журналы. Нашир һәм редакторы Тимерша Соловьев һәм Зариф Бәшири.

[3] *«Тәрҗеман» бабай* — Исмәгыйль бәк Гаспралы (Гаспринский).

74 бит.

**Куркынычлы хәбәр. Кыямәт.** «Уклар» журналының 1906 елгы 5 нче (октябрь) санында «Хәсрәт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Язмада «Йолдыз» һәм «Азат халык» газеталары кушылулары тәнкыйтьләнә.

[1] *Күлтәси* — Шәмсетдин Күлтәси (1856–1930), мәгърифәтче, дин галиме, 1906–1920 елларда Күлтәс авылы мулласы.

74 бит.

**Тимерче.** «Уклар» журналының 1906 елгы 5 нче (октябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Тимерче Сандугач* — Тимерша (Тимершаһ) Соловьев.

[2] *«тәкый гаҗәб»* — «Тәкый гаҗәп, яки Ахырзаман китабы» исемле динидидактик эчтәлекле шигъри китапның һәр бәете «Андин артык тәкый гаҗәп дыңлари вар» дип тәмамлана. Тукай монда шул сүзләрне истә тотып яза.

[3] *«Таң»чыларның социализмын* — «Таң йолдызы» газетасы битләрендә социализм турында да мәкаләләр басылган.

[4] *«Әлгасрел җәдит»нең әдәбиятын* — бу журналда матур әдәбият әсәрләренә зур урын бирелгән.

75 бит.

**Гаҗаиб!** «Уклар» журналының 1906 елгы 5 нче (октябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

75 бит.

**Әдәбият ахшамы, яки Литературный-музыкальный вечер.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 22 октябрь (39 нчы) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Фәзаилеш-шөһүр»* — дини эчтәлекле вак-вак хикәяләрдән торган, иске мәктәп-мәдрәсәләрдә дәреслек итеп йөртелгән китап, авторы — Җамалетдин Бикташи (Казан артыннан).

[2] *«Тишекбаш»* — «Кисекбаш» китабы, борынгы дастан, Октябрьгә кадәр күп укылган әсәр. Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы аңа назыйрә рәвешендә иҗат ителгән.

[3] *«Мөһиммәтел-мөслимин»* — Октябрьгә кадәр вәгазь һәм уку китабы булып йөргән дини эчтәлекле әсәр («Мөселманнар өчен мөһим эшләр» мәгънәсендә).

[4] *«Бәдәвам»* — мәдрәсәләрдә кулланма рәвешендә йөргән кечкенә күләмле, көйле дини китап.

[5] *Зәркум* — әкият (кыйсса) батыры.

78 бит.

**Ләтыйфә.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 19 ноябрь (43 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Бәдигъ мөәззин ата күркәсе* — Казанда Яңа бистә мөәззине күркәсе югалуы һәм аны табып китерүчегә бер сум акча бүләк ителәчәге турындагы игълан «Казан мөхбире» газетасының 1906 елгы 3 февраль санында басылган («үткән сәнә» дип үткән кышта чыгуын истә тотып әйткән булса кирәк). Бу мәзәкле хәлне Тукай берничә мәртәбә юмор-сатира максатларында телгә ала.

79 бит.

**Кызыкка очрау.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 19 ноябрь (43 нче) санында «Тиктормас» имзасы белән басылган (ахыры булуы әйтелсә дә, ул кү-

ренми). Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

81 бит.

**«Тәрҗеман»ның татарларга галякасе.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 26 ноябрь (44 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Әбүҗәһел* — гарәп кабиләләрендә иске тормыш тәртипләрен, дини ышануларны саклау өчен Мөхәммәд пәйгамбәргә каршы көрәшүчеләрнең берсе.

[2] *Истанбулдагы истибдад корбаны булган «Сабах», «Икъдам», «Тәрҗемане хакыйкать» гәзитәләре* — Төркиядә «Яшь төрекләр» (партиясе) тарафыннан чыгарылган бу газеталарны ул вакыттагы Габделхәмит солтан режимы эзәрлекләве турында сүз бара.

[3] *«могътәзилә ля әдрияләр»не рәд кыйлучы* — Урта гасыр Көнчыгыш галимнәре арасында барлыкка килгән философик агым. Алар фикеренчә, кеше акылы һичбер нәрсәнең асылына төшенә алмый.

[4] *«Новое время»* — 1868–1917 елларда Петербургта чыккан газета.

[5] *«Милләт»* — бу газетаны 1906 елда Кырымда И.Гаспралы (Гаспринский) нәшер итә.

[6] *«Камусы гыйльми»* — «Камусы гыйльмия һәм фәнния», И.Гаспралы әсәре.

82 бит.

**Янә «Тәрҗеман»га.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 3 декабрь (45 нче) санында «Ш.» («Шүрәле» сүзенең баш хәрефе) имзасы белән басылган (ахыры булу әйтелсә дә, ул чыкмаган). Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Тәрҗеман» иясе... бер гәзитә чыгарып торды* — бу газета 1883 елның 10 апрелендә чыга башлый.

[2] *«Мәшһүр хатыннар»* — Риза Фәхретдинев әсәре (Оренбург, 1903).

[3] *«Галәме нисван»* — 1906 елда Бакчасарайда чыккан журнал.

83 бит.

**Уральск хәбәрләре (Бу арада гына...).** «Фикер» газетасының 1906 елгы 26 ноябрь (44 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка «Лично-почетный потомственный...» исеме белән кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *лично-почетный потомственный...* — Уральск миллионеры Мортаза Гобәйдуллин.

84 бит.

**«Чүкеч»тән.** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган (ахыры күренмәде). Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *дөрест сүз әйткәнмен икән!* — журналның 5 нче санында басылган «Тимерче» исемле язмага ишарә (авторы — «Шүрәле», ягъни Тукай үзе).

84 бит.

**Җен берлә Убыр.** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Җамусы бәхри* — И.Гаспралының «Камусы гыйльмия вә фәнния» әсәренең исеме сатирик максатта үзгәртелгән (җам — бокал; әсәр сай эчтәлекле булып чыга).

[2] *«Зилләт» гәзитәсе* — «Милләт» газетасы.

[3] *Бакчасарайдагы акча сарае, акча малае түгел!* — Исмәгыйль Гаспралыга ишарә ителә.

85 бит.

**Гаҗәп түгелме?** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Габделхәмит* — Төркия солтаны.

[2] *Әхмәтҗан* — Әхмәтҗан Сәйдәшев.

[3] *Рәшид вә Мөршид* — Габдерәшит Ибраһимов истә тотыла булса кирәк.

[4] *Дурново* — Дурново П.Н., бу чорда патша Россиясенең эчке эшләр министры.

[5] *Каульбарс* — Каульбарс А.Н., патша генералы.

[6] *Тимершаһ* — Тимерша Соловьев, «Чүкеч» журналы редакторы.

[7] *«Карчыга»* — 1906–1907 елларда Оренбургта чыккан юмор журналы, нашир һәм редакторы — язучы Шакир Мөхәммәдев (1865–1923).

86 бит.

**Мосаләхә.** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Шатыр-потыр-апчыхи» гәзитәсе* — «Бәянел хак» газетасы.

[2] *Гайса каршындагы Дәҗҗал шикелле* — хәдисләрдә Дәҗҗал (алдакчы) дөнья бетәр алдыннан үзен Гайса пәйгамбәр итеп танытучы сыйфатында күрсәтелә. Әмма Гайса пәйгамбәр догалары кешеләрне аңардан коткарачак.

[3] *Куропаткин* — Куропаткин А.Н. (1848–1925), патша генералы, хәрби эшләр министры; рус-япон сугышында уңышсыз һөҗүм оештыруы аркасында рус гаскәрләре җиңелүгә дучар була.

86 бит.

**Телеграмнар.** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Әхтәри»* — «Әхтәри кәбир» исемле гарәпчә-төркичә аңлатмалы сүзлек.

[2] *«Әт-тилмиз»* — 1906–1907 елларда Петербургта гарәп телендә чыккан газета. Нашир һәм редакторы — Габдерәшит Ибраһимов. «Телеграмма»да Г.Ибраһимовның «Өлфәт» газетасы теле шул вакыттагы татар теленнән аерылып торуы, чуарлыгы тәнкыйтьләнә.

[3] *Тимерче Соловьев җәнабләре* — бу урында Тимерша Соловьевның Мәкәрҗәдә «Двусветный» исемле («Кушъяктылы») кунакханә идарәчесе булып торуына да ишарә ителә.

[4] *Бухгалтерия гыйльменә маһир Алмаев хәзрәтләре* — язучы, журналист Мәхмүт Алмаев (1874–1907). Оренбургта «Хөсәения» мәдрәсәсендә бухгалтерия дәресләрен укыткан, берара (1906, октябрь — 1907, июль) «Чүкеч» журналы редакторы булып эшләгән.

87 бит.

**Шартлар.** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Фельетон Тукайның беренче рус инкыйлабы елларында (1905–1907) социалистик идеяләр йогынтысында фикерләвен чагылдыра.

88 бит.

**Казанда никях мәҗлесе.** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Парчада Һади Максудиның «Йолдыз» газетасы белән Галиәсгар Камалның «Азат халык» газетасы белән кушылуына (аннан соң чыккан газета «Йолдыз» исемендә була) Тукайның тискәре мөнәсәбәте чагыла.

[1] *Календаретдин кызы* — бу урында Һ.Максудиның календарьлар да чыгаруына ишарә ясала.

89 бит.

***** («Уклар» гали фикерле...»).** «Уклар» журналының 6 нчы (ноябрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Уклар»... татарның корсагына карады.* — Журналда рәсем белән бирелгән. Янәшәдәге русча текстта болай диелә: «Стрелы», продолжая исследовать благомыслящего татарина, на этот раз заглянули в его чрево, где и нашли все изображенное на рисунке. Всячески радуемся такому благополучию благоутробного правоверного, но только, к несчастью, известно, что... сытое брюхо к учению глухо...»

Тукайның бу язмасы «Пыяла баш» исемле парчасы («Уклар», 4 нче сан) тибында иҗат ителгән һәм басмада урнаштырылган.

89 бит.

**Сәдәхә.** «Уклар» журналының 1906 елгы 6 нчы (ноябрь) санында «Уклар»ның лөгать мөтәфтише» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Фатих абзый* — Уральск сәүдәгәре Фатих Шәрипов.

[2] *Капчыклы Шашы* — Татарстан Республикасының Әтнә районындагы Түбән Шашы авылы. Ярлылыгы сәбәпле халкы теләнчелек белән дә шөгыльләнгәнлектән, ул заманда бу авыл Капчыклы Шашы исеме белән дә телгә кергән.

90 бит.

**Уральск хәбәрләре (Шәһәремезнең яшьләре...).** «Фикер» газетасының 1906 елгы 3 декабрь (45 нче) санында бер өлеше «Ш.» («Шүрәле»дән кыскартылма) имзасы, ахыргы ике хәбәре «Партия» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текстлар газетадан алынды.

[1] *«Казан» миһманханәсенең яңа хуҗасы* — Садыйк Гобәйдуллин.

[2] *Мәхлукулла бай* — Мортаза Гобәйдуллин.

91 бит.

**Мөселманнарны ни өчен особый группага бүләләр?** «Фикер» газетасының 1906 елгы 10 декабрь (46 нчы) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Тартышуда гына табарсыз сез үз хакыңызны!* — Бу өндәмә «Таң йолдызы» газетасының («Таң»чыларның) төп лозунгысы булып торды. Тукайның «Таң»чылар позициясенә якынлыгына бу тагын бер дәлил.

92 бит.

**Мөһим эш — имамнар җәмгыяте.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 10 декабрь (46 нчы) санында баш мәкалә рәвешендә имзасыз (чынлыкта газета редакциясе фикере итеп) басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Язма ахырындагы русча шигъри дүртьюллык революцион гимн — «Интернационал»дан алынган.

94 бит.

**Уральскидә сайлаулар.** «Фикер» газетасының 13 декабрь (47 нче) санында баш мәкалә итеп имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *гәзитәмезнең мөхәррире* — Камил Мотыйгый.

[2] *...үзеңезнең кулларыңыз илә...* — бу дүртьюллык «Интернационал»дан (икенче строфасы) тәрҗемә итеп бирелгән.

97 бит.

**Җәмгыяте хәйрия.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 17 декабрь (48 нче) санында, «Төрек» газетасыннан татарлар хәленә борыбрак, «Мөтәрҗим Г.Тукаев» имзасы белән, ахыры газетаның 31 декабрь (50 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

100 бит.

**Театруның файдасын халыкка ничек төшендерәмез һәм хәзрәтләрдән ничек дөрестләтәмез?** «Фикер» газетасының 1906 елгы 17 декабрь (48 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *кызыл кәгазь* — ул вакыттагы Россия акчасы (ун сумлык).

102 бит.

**Һәркимиң кәндинчә вардыр ля мөхаль әндишәси.** «Фикер» газетасының 1906 елгы 31 декабрь (50 нче) санында «Бер «Фикер»че» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Борһане тәрәкъкый» гәзитәсе* — 1906–1911 елларда Әстерханда татар һәм төрек телләрендә нәшер ителгән газета. Наширләре — Мостафа Лотфый Исмәгыйлев (Ширванский), Закир Хуҗаев; редакторлары — Мостафа Лотфый Исмәгыйлев (Ширванский), Нәҗип Гасрый, Заһидулла Шәрифуллин.

## 1907

105 бит.

**Төш күрдем.** «Фикер» газетасының 1907 елгы 6 гыйнвар (1 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

Фельетон Уральскида татарларның «Казан» кунакханәсендә булып торган җыелышларына пародия рәвешендә язылган.

Газетаның бу санында түбәндәге игълан да басылган:

«Ушбу бу көннәрдә генә мәдрәсәи «Мотыйгия»дән чыктым.

Бинаән галәйһи[1] дустларым вә якыннарыма игълан итәмен ки, бу көннән ары миңа язачак мәктүбләренең адресын болай язсыннар:

Уральск.
Гостиница «Казань».
А.Тукаеву.
Бакый ихтирам: Г.Тукаев».

[1] *Бик зур бер ишәк* — Хәсәнҗан Хөсәенев, Мортаза Гобәйдуллин.

[2] *«Төлке теле»* — рус башлангыч мәктәбендә Тукай остазы Әхмәтша Сираҗетдиновның «Төрки теле» исемле китабы истә тотыла.

108 бит.

**Тәшәккер.** «Фикер» газетасының 1907 елгы 28 гыйнвар (4 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

Мәкалә Уральск шәһәрендә II Дәүләт Думасына сайлаулар һәм сайлауларда прогрессистларның җиңүе уңае белән язылган.

[1] 17 *октябрь партиясе* — төгәл исеме: «17 октябрь союзы», монархистик партия.

[2] *Тирече* — Хәйрулла Гадельшин.

[3] *Аю, маймыл, кәҗә, ишәкләрнең музыка уйнарга утырганнары* — И.А.Крыловның атаклы «Квартет» мәсәле истә тотыла.

---

[1] *Бинаән галәйһи* – шунлыктан.

109 бит.

**Уральск хәбәрләре (Хәсәнҗан Хөсәенев җәнабләре...).** «Фикер» газетасының 1907 елгы 4 февраль (5 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

110 бит.

**Кабергә киткән «Фикер» яңадан терелеп кайтты.** «Фикер» газетасының 1907 елгы 8 март (9 нчы) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

1907 елның 22 февралендә хакимият Камил Мотыйгыйдан нашир һәм редакторлык хокукларын ала, һәм газета берара чыкмый тора. Әмма ун көннән соң ул яңа нашир Мортаза Гобәйдуллин һәм редактор Вәлиулла Хәмидуллин тарафыннан кабат нәшер ителә башлый (әмма тиздән туктала да). Реплика шул уңай белән басылган.

110 бит.

**Идарәдән.** «Әлгасрел җәдит» журналының 1907 елгы 3 нче (15 март) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

«Идарә» (чынлыкта, Тукай) «Әлгасрел җәдит» журналы чыгудан тукталмаячагын әйтсә дә, ике саны чыккач (1907 елның 20 маенда), ул нәшер ителми башлый.

Текст ахырындагы шигъри ике юл Тукайның «И каләм!» исемле үз шигыреннән китерелгән (8 нче строфа).

111 бит.

**Тәкрар әйтәмез.** «Әлгасрел җәдит» 1907 елгы 4 нче (15 апрель) санында «Идарә» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Бу — «Мәгариф — хәяттыр» исемле тәрҗемә мәкаләгә редакция искәрмәсе.

[1] *11 нче номер «Фикер»дәге Тартар кошы...* — моннан соң китерелгән дүрт юл шигырь Тукайның «Тартар кошы сайрый» исемле шигыреннән («Фикер» газетасы, 1907 ел, 11 март, 10 нчы сан) алынган.

112 бит.

**Шигырьләремез.** «Фикер» газетасының 1907 елгы 22 апрель (15 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Касыйдәи бөридә»* — гарәп телендәге тезмә әсәр.

[2] *«Фәвакиһелҗәләса» китабы* — «Фәвакиһелҗөләса фил-әдәбият» исемле китапны (хрестоматия-дәреслек) Каюм Насыйри төзеп чыгарган (Казан, 1884).

[3] *«Эсма, яки Гамәл вә җәза» китабындагы Сәлим бабайның шигырьләре* — Риза Фәхретдиневнең бу исемдәге повестенда (Оренбург, 1903) Сәлим бабай җыры (бу шигырьнең авторы исә Дәрдемәнд була).

[4] *Акмелла хәзрәтләре* — татар шагыйре, мәгърифәтче Мифтахетдин Акмулла (1831–1895), иҗаты башкорт һәм казакъ әдәбиятлары казанышы итеп тә карала.

[5] *Ике бөек шагыйрьләремез* — Мәҗит Гафури һәм Нәҗип Думави.

115 бит.

**Ана мәктүбләре.** «Фикер» газетасының 1907 елгы 4, 6 һәм 13 май (16, 17 һәм 18 нче) саннарында «Г.Тукаев» имзасы белән, ахыры булуы әйтелеп басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

123 бит.

**Партияләр.** «Фикер» газетасының 1907 елгы 6 май (17 нче) санында баш

мәкалә сыйфатында, имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Т» гәзитәсе* — «Тәрҗеман» газетасы.

[2] *С.Р., С.Д.* — социал-революционерлар, социал-демократлар партияләре.

[3] *«карт мөхәррир»* — Исмәгыйль Гаспринский.

125 бит.

**Думаның хәле.** «Фикер»нең 1907 елгы 13 май (18 нче) санында баш мәкалә сыйфатында, имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Головин* — II һәм III Дәүләт Думалары рәисе Ф.А.Головин (1867–?).

[2] *Зурабов* — II Дәүләт Думасы депутаты А.Г.Зурабов (Кавказдан) (1873–1920).

126 бит.

**4 май — җомга.** «Фикер» газетасының 1907 елгы 13 май (18 нче) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Владимир Гисин* — бу елларда Россиянең мәгариф министры.

[2] *Әфләтун* — борынгы грек философы Платон (б.э.к. якынча 427–347).

[3] *Мәхмүдев* — Уфа губернасыннан III Дәүләт Думасы депутаты Шәрәфетдин Мәхмүдев (1859–1914 елдан соң).

[4] *Хәсәнев* — Уфа губернасыннан II Дәүләт Думасы депутаты Кәлимулла Хәсәнев (1876–1949). Дума утырышында аның чыгышыннан соң уңнарның «Төркиягә барыгыз!» дип тавыш чыгарулары Тукайны «Китмибез!» шигырен язуга этәргән.

130 бит.

**Тәнкыйть — кирәкле шәйдер.** «Әл-ислах» газетасының 1907 елгы 17 октябрь (3 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

«Әл-ислах» 1907 елның октябреннән 1909 елның июленә кадәр Казанда чыккан. Аның битләрендә Тукайның шигъри әсәрләре һәм мәкалә-фельетоннары дөнья күргән.

## 1908

133 бит.

**Бәйрәм, без вә руслар.** «Әл-ислах» газетасының 1908 елгы 1 гыйнвар (13 нче) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

Газетаның бу саны Корбан гаетенә багышланып чыгарылган. Анда Тукайның «Фөрьяд» һәм «Бәйрәм вә бәйрәм!» исемле шигырьләре дә урын алган.

135 бит.

**Август башы.** «Яшен» журналының 1908 елгы 1 нче (3 август) санында баш мәкалә рәвешендә «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

Тукайга, Казанда 1909 елның 24 июненә кадәр чыккан бу журналның секретаре булып эшләгәнгә, «анда бик күп язарга тугъры килә». Шунлыктан язмаларын төрле-төрле яшерен (мөстәгар) имзалар (псевдонимнар) белән бастырган.

135 бит.

**Яңа гәзитәләр.** «Яшен» журналының 1908 елгы 1 нче (3 август) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

136 бит.

**Төрлечә дөнья тану.** «Яшен» журналының 1908 елгы 2 нче (10 сентябрь) санында имзасыз басылган, «Яшен ташлары» җыентыгында (беренче җөзьә; авторы — «Шүрәле», нашире — «Су анасы»; Казан, 1911). Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

[1] *«Дингә мишәйт»челәр* — «Дин вә мәгыйшәт» журналын чыгаручылар һәм аның мәсләген яклаучылар күз алдында тотыла. Вәли мулла (Мөхәммәтвәли) Хөсәенев (1871–1933) — журналның нашире, Ф.Сәймани — язмалары журналда еш басылган автор.

[2] *Ашмарин* — Н.И.Ашмарин (1870–1930), төрки телләр белгече, педагог, цензор.

[3] *Мөхәммәтгали шаһ* (1872–1925) — Иран шаһы, 1908 елда тәхеттән төшерелә.

[4] *Ляхов* — В.П.Ляхов (1869–1919), Иранда Россия гаскәрләре башлыгы.

137 бит.

**Хикәя.** «Яшен» журналының 1908 елгы 2 нче (10 сентябрь) санында имзасыз (ахыры булуы әйтелеп) басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Чүкеч» мөхәррире* — Тимерша Соловьев; «Чүкеч» журналында бу елларда Г.Тукайга карата тупас тәнкыйтьләр басыла.

[2] *«Бәянел хак» нашир вә мөхәррире* — аталы-уллы Әхмәтҗан һәм Мөхәммәтҗан Сәйдәшевләр. Бу газета Тукай тәнкыйтенә бик еш эләкте.

[3] *Буага мөдәррис вә дамелла* — Нургали Хәсәнев, патша хөкүмәте медальләр белән бүләкләгән шәхес.

[4] *Кәҗә Якуб* — Якуб Хәлили; бу урында әлеге кешенең, Яңа бистәдәге 11 нче мәхәллә мәдрәсәсенә кереп, аның эшенә тыкшынуына ишарә ителә.

138 бит.

**Лөгатьләр.** «Яшен» журналының 1908 елгы 3 нче (30 сентябрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Хиҗаз мәчеләре* — кеше өчен ялланып хаҗга баручылар (бәдәлчеләр). Мәккә шәһәре исә Согуд Гарәбстанының Хиҗаз исемле өлкәсенә керә.

140 бит.

**Кемнәрнең ни дисәң котлары чыга?** «Яшен» журналының 1908 елгы 3 нче (30 сентябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Морат вә башка бәдәлчеләр* — Морад Мәкки (Рәмзи, 1855–1934) турында сүз бара. Аның тарих китаплары да бар.

[2] *Тимершаһ* — Тимерша Соловьев.

[3] *Һади Максудиның «Мөгаллиме әүвәл»е* — Һ.Максуди төзеп бастырган әлифба китабы.

[4] *Йосыф Акчуринның — «Рисаләңә яңлыш бер татарча сүз кергән» дисәң* — бу сәясәтче һәм публицистның мәкаләләрен төрекчә язуына ишарә ителә.

141 бит.

**Төрле хайваннар тугърысында бераз мәгълүмат.** «Яшен» журналының 1908 елгы 4 нче (5 ноябрь) санында «Хәятел хайванаттан күчерүче» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Хайваннар тормышы турындагы «Хәятел хайван» китабы 1900 елда Казанда басылган.

[1] *Мулла Ш.К.* — чын исем-фамилиясе әлегәчә ачыкланмаган Оренбург мулласы, мәкаләләр авторы; «Таң»чылар, яки Кызыл паразитлар» исемле китабы да бар (Оренбург, 1908).

[2] *Гыйбраһим* — Габдерәшит Ибраһимов, «Өлфәт» исемле газета да чыгарган.

[3] *Минһаҗел Һинди* — Һиндстанда укып кайткан зыялы Минһаҗетдин Кадермәтев (1871–1925), Хвалыйн шәһәрендә, мәдрәсә салам дип, акча җыйнаган һәм аны салмаган кеше.

[4] *Кәҗә Аякыф* — Якуб Хәлили.

142 бит.

**Мин шушылар илә милләтче.** «Яшен» журналының 1908 елгы 4 нче (5 ноябрь) санында «Милләтче» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Шакир Хәмитев* — шырпы фабрикасы хуҗасы.

142 бит.

**Төшемдә күргәннәрем.** «Яшен» журналының 1908 елгы 4 нче (5 ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән (ахыры булуы әйтелеп) басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Вилдан вә гыйльманнар* — оҗмахтагы хезмәтче егетләр.

[2] *Кәүсәр елгасы* — оҗмахтагы татлы сулы елга.

[3] *Әхмәт бай* — Әхмәт Хөсәенев. Фельетонда вафат булыр алдыннан килере «Хөсәения» мәдрәсәсе файдасына калдырган вакыфы тирәсендә булган хәлләргә ишарә ителә. Ак башлы күселәр — муллалар.

[4] *Мәмдүх бай* — Мәхмүт бай Хөсәенев (Әхмәт байның энесе) әлеге вакыф акчасын тиешенчә тотмавы турында сүз бара.

[5] *«Вакыт» мөхәррире* — Фатыйх Кәрими.

[6] *Мөхәммәтзаһир Бигиев* — фельетонда телгә алынган романнар һәм сәяхәтнамәсеннән тыш Заһир Бигиевнең «Мөртәд» һәм «Катилә» исемле романнары да булган. Аларның басылмый ятуларына энесе Муса Бигиев гаепле итеп күрсәтелә.

145 бит.

**Мәкальләр.** «Яшен» журналының 1908 елгы 4 нче (5 ноябрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *гласный* — шәһәр думасы әгъзасы. Журналның бу санында гласныйлыкка (татарлардан да) яңа сайлаулар булу темасына ике карикатура да бирелгән.

146 бит.

**Словарьдан фал ачу.** «Яшен» журналының 1908 елгы 5 нче (17 декабрь) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Мөхәммәдия»* — төрек шагыйре Мөхәммәт Чәләби Язычы углының көйле әсәре, татарлар арасында киң таралган, 1845 елдан башлап Казанда күп мәртәбә нәшер ителгән.

[2] *«Йосыф китабы»* — Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы.

[3] *Шаһтәхтинский* — кавказлы җәмәгать эшлеклесе, Тифлистә 1903–1904 елларда азәрбайҗан телендә чыккан «Шәркы рус» газетасы редакторы.

[4] *Мотыйгый* — Камил Мотыйгый.

[5] *Риза казый* — Ризаэтдин Фәхретдинов.

[6] *Рәшит казый* — Габдерәшит Ибраһимов.

[7] *мөфти* — Мөхәммәдъяр Солтанов.

147 бит.

**Гәзитәләрдән («Бәянел хак» гәзитәсенең...).** «Яшен» газетасының 1908 елгы 5 нче (17 декабрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Әхмәтҗан абзый* — Әхмәтҗан Сәйдәшев.

149 бит.

**Хәзерге заманча сөйләшүләр.** «Яшен» журналының 1908 елгы 5 нче (17 декабрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Нур»* — бу газета шактый тәртипсез чыккан.

[2] *«Фикер» шикелле алдан мактанып куйма!* — Газета редакциясе яңа нашир кулына күчкәннән соң чыгуын дәвам итәсен игълан итсә дә, ике ай үтүгә туктап кала (бу турыда Тукайның «Кабергә киткән «Фикер» яңадан терелеп кайтты» исемле язмасын һәм аңа искәрмәне карагыз).

[3] *«Чүкеч» белә «Ислах» түгелсездер әле.* — «Чүкеч» газетасы «Әл-ислах» газетасын тәнкыйтьләргә маташты, моңа каршы «Әл-ислах» та җавапсыз калмады, билгеле.

[4] *«Тәрәккъкый» теле* — 1906–1907 елларда Ташкентта чыккан газета, теле ярым үзбәкчә, ярым татарча.

## 1909

151 бит.

**Ахыр күрешүләр.** «Яшен» журналының 1909 елгы 6 нчы (31 гыйнвар) санында баш мәкалә урынында имзасыз басылган, бераз үзгәртелеп «Яшен ташлары» (1 нче җөзьә) җыентыгына урнаштырылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

[1] *бер яшь төрек* — сүз «Яшь төрекләр» партиясенең, 1908 елның июлендә Төркиядә хакимияткә килгәч, демократик карашларыннан ваз кичүе турында бара.

152 бит.

**Актык сүзләр.** «Яшен» журналының 1909 елгы 6 нчы (31 гыйнвар) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган, «Яшен ташлары» җыентыгында (1 нче җөзьә) редакцияләп бирелә. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

Сатирик парчада төрле сәбәпләр аркасында 1909 елның башына инде чыгудан туктаган татар газета һәм журналлары турында сүз бара. Хәер, «Әддин вәләдәб» журналы (Казан; нашир һәм редакторы — Галимҗан Баруди) 1908 елда тукталса да, 1913–1917 елларда кабат нәшер ителгән әле.

153 бит.

**Матбугат каһарманнары.** «Яшен» журналының 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында «Мин язмадым» имзасы белән, аннары, бераз кыскартылып, «Яшен ташлары» җыентыгында (1 нче җөзьә) басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

153 бит.

**«Безнең заман».** «Яшен» журналының 1909 елгы 8 нче (29 апрель) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Сатирик рецензиядә язучы Фатих Сәйфи-Казанлы («бер школьник») язган «Безнең заман» исемле пьесага (Казан, 1909; нашире Харис Фәхретдинов) бәя бирелә.

154 бит.

**Татарча театр.** «Йолдыз» газетасының 1909 елгы 21 июнь (413 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

Рецензиядә «Сәйяр» труппасы тарафыннан куелган «Хуҗа һәм приказчик» (Гариф Богданов комедиясе, китап булып 1907 елда дөнья күрә) спектакленә бәя бирелә.

[1] *Кариев* — Габдулла Кариев (Миңлебай Хәйруллин, 1886–1920), артист, режиссер, татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе.

[2] *Сакаев* — Нури Сакаев (1885–1927), артист.

[3] *Мортазин* — Вәлиулла Мортазин-Иманский (1885–1938), артист, режиссер.

[4] *Сәмитова* — Фәхерниса Сәмитова (1890–1939), актриса.

[5] *Гыйззәтуллина* — Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская (1885–1974), беренче татар актрисасы, режиссер.

155 бит.

**Милләтче.** «Яшен» журналының 1909 елгы 10 нчы (24 июнь) санында «Шүрәле» имзасы белән, аннары «Яшен ташлары» җыентыгында (1 нче җөзьә) үзгәртелеп басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

Фельетонда кайбер авторларда милләтне сөю хисенең гаять примитив тезмәләрдә чагылыш табуы тәнкыйть ителә.

156 бит.

**«Безнең заман» вә Сәгъди абзый.** «Яшен» журналының 1909 елгы 10 нчы (24 июнь) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче тапкыр академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

Сәгъдинең (җәмәгать һәм дин эшлеклесе, журналист Борһан Шәрәф, 1883–1942) «Безнең заман» исемле рецензиясе «Вакыт» газетасының 1909 елгы 13 июнь санында басылган була.

## 1910

158 бит.

**Сабын ашаганнар.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 1 нче (15 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

158 бит.

**Ике хәзрәт вә извозчик.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 1 нче (15 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

159 бит.

**Гаҗәп талантлар.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 1 нче (15 март) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Һади Максуди* — «Йолдыз» газетасы нашире һәм редакторы.

[2] *Рәшит казый* — Габдерәшит (Рәшит) Ибраһимов.

[3] *Шәһидуллин* — Шәрәфетдин Шәһидуллин (1870–1925тән соң), нашир, китап сәүдәгәре, календарьчы.

[4] *Хәмзә ахун* — Хәмзә Хәмиди, Томск мулласы, ахун; татар вакытлы матбугатында аның провокаторлыгы турында да язылган (мәс., Ф.Әмирхан).

[2] *Вәли мулла* — Мөхәммәтвәли Хөсәенев.

[3] *Чәйдәшевләр* — Сәйдәшевләр.

159 бит.

**«Яшен» мәрхүм.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 2 нче (1 апрель) санында «Догачы: Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

161 бит.

**Кеше — хайваннар.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 5 нче (15 май) санында «Гөмберррт» имзасы белән (ахыры булуы әйтелеп) басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Кәримев-Хөсәенев» ширкәте* — Оренбургта һәм Уфада эшләгән бу компания үз китапларын башка көтепханәләр аша саттыра торган булган.

[2] *Чыгътай хәзрәтләре* — язучы, мулла Галиәсгар Гафуров-Чыгътай (1867–1942) «Исабәт» исемле китабы өчен Диния Нәзарәтендә тәүбә итәргә мәҗбүр була. Бу турыда Тукай «Мәҗрух указ» исемле шигырь дә язган иде.

[3] *«Дингә мишәйт»* — «Дин вә мәгыйшәт» журналы турында сүз бара.

[4] *С.Р.* — Сәгыйть Рәмиев, берара «Бәянел хак» газетасында эшли һәм Тукай тарафыннан тәнкыйть ителә.

[5] *«Шура» әдипләре* — бу журналда басылган мәкаләләрнең теле төрек теленә якын булган, гомумән, аның битләрендә төрек матбугатыннан алынган язмалар да басылган.

162 бит.

**Керешү хотбәсе.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 5 нче (15 май) санында «Яңа хотбә» дип исемләнеп, «Имам хатыйб» имзасы белән (ахыры булуы әйтелгән), «Яшен ташлары» җыентыгында (1 нче җөзьә) текст бераз үзгәртелеп, «Керешү хотбәсе» дип аталып басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст «Яшен ташлары» җыентыгыннан алынды.

Памфлет мәчетләрдә муллалар укый торган хотбәләр (вәгазьләр) стиленнән файдаланып язылган.

[1] *«Билпьяныл хап»* — «Бәянел хак» газетасында сыра заводлары игъланнарын бик еш бастыруына ишарә ителә.

[2] *Әхмәд әл-Исхак* — Орск шәһәрендә «Шәрекъ көтепханәсе» исемле кибет ачып, китап бастыру һәм аны сату эше белән шөгыльләнгән кеше. Күбесенчә төрек һәм гарәп телендәге китаплар белән сату иткән.

[3] *Мөхәммәтҗанәл-хафизә вә Низамиял-аксак* — Мөхәммәтҗан хафиз — Печән базары сәүдәгәре, һәртөрле яңалыкка каршы булуы сәбәпле, демократик матбугатта көлке объекты булып торган. Аксак Низами исә Мөхәммәтҗан хафизның фикердәше.

[4] *мәбгусәйниш-Шәрмәхутефә вәл-Байбулыймә кәбирәл-колак* — III Дәүләт Думасы депутатлары Шәрәфетдин Мәхмүтев белән Җиһангир Байбуриннар турында сүз бара.

[5] *мәймүнәл-гавамәз-Зөттатария* — Казанда Коръәнне төрле көйләргә салып укыган кари Кыйвам Зөлфөкари.

[6] *бәррәкәл-Мәмдүх байә* — Мәхмүт бай Хөсәенев.

[7] *әл-Ишмиил мөбарәки вә Такырҗанил-Хәсән* — Түнтәр авылы мулласы Ишмөхәммәд Динмөхәммәдев (Ишми ишан) һәм Уфа мулласы Сабир Хәсәни, ул чор матбугатында тәнкыйть угына эләккән кешеләр.

[8] *Зәйнуллаһи вә Хәйбуллаһил-ишан* — Троицк шәһәрендә яшәгән Зәйнулла Рәсүлев (Зәйнулла ишан) һәм Зимничә авылы ишаны Хәбибулла Хансүәров.

163 бит.

**Акыллы башлар.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 6 нчы (1 июнь) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Исабәт» язды* — Г.Гафуров-Чыгътай истә тотыла.

[2] *«Табаныл хак»* — «Бәянел хак» газетасы.

[3] *«Сөбател гаҗизин»гә тәкълид итте, ди* — Мәҗит Гафури 1909 елда Уфада «Замана шигырьләре» исемле китап бастыра. Ул Суфи Аллаһиярның «Сөбател гаҗизин» дигән шигъри китабына ияреп язылган.

[4] *Һинди Минһаҗ* — Минһаҗетдин Кадермәти (Кадермәтев).

165 бит.

**Фәлсәфи сүзләр.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 8 нче (1 июль) санында «Имза: Фәйләсүфләр» имзасы, дәвамы 9 нчы (15 июль) санында «Фәйләсүф» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Әхмәтҗан Биктимерев подвалдан вә Вагыйз Нәүрузи сухтәлектән* — әдәби әсәрләр язган Ә.Биктимеров һәм журналист, редактор В.Нәүрузи (Нәүрузов) истә тотыла.

[2] *бер зур кешемезгә памятник* — Әхмәтҗан Сәйдәшев. Журналның 8 нче санында карикатурада ул Болак күпере астында һәйкәл булып күрсәтелгән.

[3] *сахибе «Кәҗә бәете»* — Тукай үзе.

[4] *«Фикер» мөхәррире* — Камил Мотыйгый.

[5] *М.ә.Б. мәрхүм Заһир әфәнде рисаләләренә... бер тамчы да тиермидер* — Муса Бигиевнең абыйсы Заһир Бигиев язган «Катилә» һәм «Мөртәд» романнарын бастырмавына ишарә ителә.

[6] *«Пьяный шап»* — «Бәянел хак» газетасы.

168 бит.

**«Гыйшык» уты.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 8 нче (1 июль) санында «Шүрәле дию белгәйсез» имзасы белән басылган, исеме — «Нечкә хиссият». «Яшен ташлары» җыентыгында (1) текст, бераз үзгәртелеп, «Гыйшык уты» дип аталып урнаштырылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

[1] *Шам шәриф* — Сириянең башкаласы Димәшкъ шәһәре.

[2] *Сәет Баттал гази* — «Сәет Баттал гази хикәясе» исемле төрек әдәбияты әсәре каһарманы.

170 бит.

**Бозау кадәрле зур фәлсәфә.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 11 нче (15 август) санында «Гөмберррт» имзасы белән, аннары «Яшен ташлары» (2 нче җөзьә) җыентыгында басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

Тукай бу фельетонда үзе яшәгән чорда Россиянең төрле төбәкләрендә һәм төрле вакытларда чыккан, эшләгән газета һәм журнал, китап бастыру оешмалары, типографияләр, әдәби әсәрләр исемен алып, шуларның сүзлек мәгънәсен файдаланып яза.

172 бит.

**Толстой хакында мәшһүр татарларның фикерләре.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 12 нче (1 сентябрь) санында «Имзасыз да Яраретдинов» имзасы белән баш мәкалә булып басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Мөхәммәтхан Чәйдәшев* — Мөхәммәтҗан Сәйдәшев.

[2] *Шәмретдин хаҗи* — «Чәйче Шәмси» дип йөртелгән Казан сәүдәгәре.

173 бит.

**Милләткә файда урынына зарар.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 13 нче (15 сентябрь) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Фельетонда Мәҗит Гафури (текстта «Җамид Фигури») бастырган «Кызларга махсус милли шигырьләр» (Уфа, 1910) тәнкыйть ителә. Шуңа да карамастан М.Гафури бу китапны 1912 һәм 1914 елларда кабат бастырган.

[1] *«Төхфәтел мөлүк»* — гарәп телендә язылган дини китап.

[2] *Б.Ш.* — Борһан Шәрәф.

175 бит.

**Фәлсәфә.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 14 нче (1 октябрь) санында «Олугъ Фәйләсуф» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Риза казыйның дәрес китаплары илә «Рәунәкыль ислам» вә «Дөррәтен насихин» арасында аерма* — бу урында Ризаэтдин Фәхретдинев язган дәрес китаплары башлыча дини һәм әхлакый эчтәлекле булуларына Тукайның ированияле карашы чагылыш таба. «Рәунәкыль ислам» — төрекмән суфи шагыйре Вафаи әсәре. «Дөррәтен насихин» — дини-әдәби әсәр.

176 бит.

**Мөфти җүбәләе.** «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 15 нче (15 октябрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *мөфти* — Мөхәммәдъяр Солтанов, Диния Нәзарәтендә 1886 елдан 1915 елгача мөфти булып торган. Фельетон язылган вакытка аның мөфти хезмәтен башкара башлавына 24 ел булган була.

[2] *«Эннәсолул хәдидә»* — җәдитчеләргә каршы язылган бу китапның тулы исеме — «Эннәсолул хәдидә ли ибтатыйль осулел җәдидә»; авторы — Казан өязе Тимерче авылы мулласы Гыйлаҗетдин Мөхетдинов.

178 бит.

**Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсе.** «Йолдыз» газетасының 1910 елгы 22 ноябрь (613 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән, «17 ноябрь, 1910 сәнә» дип язылу вакыты күрсәтелеп басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

181 бит.

**Мөкаддимә («Үземезнең яңа үсеп килмәктә...»).** Тукай төзегән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле китап-хрестоматиядә (Казан, 1910; тышлыкта: 1911) сүз башы рәвешендә басылган (текстның ахырында: «1910 сәнә, 13 ноябрь, Г.Тукаев»). Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст китап-хрестоматиядән алынды.

185 бит.

**Халык әдәбияты.** Казанда 1910 елда аерым китап булып (1912 елда кабатлап) басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст китапның 1910 елгы басмасыннан алынды.

## 1911

205 бит.

**Әстерхан мөзакәрәләре.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 20 нче (1 гыйнвар) санында «Телсез телеграф» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Идел» мөхәррире* — Сәгыйть Рәмиев.

[2] *Урманчиевләр, Әсгарләр* — Әхмәт Урманчиев, Галиәсгар Камаллар истә тотыла.

[3] *«Мин, су, димен, ул — җон ага...»* — С.Рәмиевнең «Алданган» шигыреннән. Тукай аңа пародия дә язды («Саташкан»).

[4] *«Арыслан» исеме белән* — С.Рәмиев бер мәкаләсендә «Лев» исемен татарчалаштырып «Арыслан» дип бирә.

[5] *«Таң»чы* — С.Рәмиевнең «Таң йолдызы» газетасында эшләгән чагы искә төшерелә.

[6] *Яичницасын «Тәбә» дип татарчага кәлҗемә иткән иде* — Гогольнең

«Өйләнү» комедиясен тәрҗемә итеп бастырганда (Казан, 1905), Яичница исемле персонажны татарчалаштырып «Тәбә» дип исемләгән булалар.

206 бит.

**Яңа әсәрләр («Хәмитнең хәяты»).** «Идел» газетасының 1911 елгы 10 май (351 нче) санында «Г.Тукаев» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст газетадан алынды.

Рецензиядә Мәҗит Гафуриның «Хәмитнең хәяты, яхуд Ләйлә вә хәятым» исемле повестена (Уфа, 1911) уңай бәя бирелә. Тукай элегрәк М.Гафуриның «Кызларга махсус милли шигырьләрем» китабын кискен тәнкыйтьләгән иде.

[1] *«Яшь гомерем»ендәге «Электрик фонарена»* — «Электрик фонарена хитап» исемле шигыре чынында М.Гафуриның «Милләт мәхәббәте» нам әшгаре» исемле китабында (Казан, 1907; Уфа, 1911) басылган.

208 бит.

**Исемнәремез хакында.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 23 нче (4 июль) санында «Имза «Шәп кеше» дип әйтелеп, аннары «Яшен ташлары» (2 нче җөзьә) җыентыгында басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст җыентыктан алынды.

[1] *Һади хәлфә* — Һади Максуди.

212 бит.

**Хикәя язарга теләүче яңа әдипләргә үрнәк.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 23 нче (4 июнь) санында «Мөхәррир мин түгел» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Бәянел хак» мөгайян мөхәррирләреннән* — Мөхәммәтҗан Сәйдәшев.

[2] *«Хак»* — 1911 елда Әстерханда чыккан (20 сан) төрекчә ислами газета. Нашир һәм редакторы — Мостафа Лотфи Исмәгыйлев-Ширванский.

[3] *мөфти* — 1911 елда Диния Нәзарәте мөфтие Мөхәммәдъяр Солтановның бу вазифаны үти башлавына 25 ел тула, һәм бу нәрсә татар-мөселман җәмәгатьчелеге тарафыннан билгеләп үтелә.

213 бит.

**Идарәдән җаваплар.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 23 нче (1 июль) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Җон вә бишмәт»* — «Дин вә мәгыйшәт» журналы турында сүз бара.

[2] *«Игълан фәкать»* — «Бәянел хак» газетасы.

215 бит.

**Мөкаддимә (Арамызда әдәбият вә шигырь...).** Текстның ахырында «Г.Тукаев, 23 апрель, 1911сәнә. Казан» диелеп, Байронның «Шильон мәхбүсе» исемле китапта (Казан, 1911) сүз башы рәвешендә басылган (поэманың үзен исә Сәгыйть Сүнчәләй тәрҗемә иткән була). Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст «Шильон мәхбүсе» исемле китаптан алынды.

С.Сүнчәләй «Тукай турында истәлеге»ндә: «Мәхбүс»ем язылып беткәч, мин аңа җибәрдем, һәм ул яраткан. Көтепханәдә (ягъни нәшриятта. — *Төзүче.*) бастыруны да үз өстенә алды. Хәтта төзәткәләп күчереп тә чыккан һәм «Мәгариф»кә басарга биргән».

216 бит.

**Аз гына төзәтү.** «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 30 июнь (703 нче) санында ахырына «Габдулла Тукаев, 1911 сәнә, 25 июнь» дип әйтелеп басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

Габдинең (Галимҗан Ибраһимов) рецензиясе әлеге газетаның 1911 елгы 21

июнь (699 нчы) санында «Яңа әсәрләр. «Мияубикә». Назымы Тукаев» исеме белән чыккан (18 июньдә язылуы әйтелә).

[1] *аерырга* — Габдидә: аера белергә.

217 бит.

**Русчадан дөрест тәрҗемәләр.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 26 нчы (15 август) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

218 бит.

**Өч баш.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 26 нчы (15 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Бу текст журналның 1912 елгы 36 нчы (31 март) санында «Гөмберррт» имзасы белән чыккан «Америкадан Вәли муллага телеграм», «Вәли мулладан Америкага», «Ялт-йолт», «Көлеп язмыйбыз, көлеп әйтмибез» исемле язмалар белән тыгыз бәйләнешле, шунлыктан аларны бер тирәгә туплап бирү мәгъкуль күрелде. Бу мәкаләләр беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгәннәр. Басмага текстлар «Ялт-йолт» журналыннан алынды.

[1] *хикәядә укыгансыз бит* — «Бакырган китабы»ндагы бер риваятьтә Гали батырны (дүртенче хәлифә) үтерү өчен җибәрелгән кешеләрнең Гали урынына Әхтәм сәхабәнең башын кисүләре турында сөйләнә. Әхтәм сәхабә, Галине исән калдыру өчен, үзен Гали итеп күрсәткән була.

[2] *Мөхәммәтгали батыр* — Иран шаһы.

[3] *Кышири* — Зариф Бәшири.

[4] *«Дин вә чүплек»* — «Дин вә мәгыйшәт» журналы.

[5] *Вәли мулла* — Вәли Хөсәенев.

225 бит.

**«Ялт-йолт» идарәсеннән сөальләр.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 28 нче (12 октябрь) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Фельетонда губерна, өяз, авыл һәм аерым кеше исемнәре еш кына сатирик максатларда үзгәртелеп кулланыла, чынбарлыктагы хәлләргә туры килми.

[1] *Казанда Җиңгәчи, Уфада Кәмали* — фәхешханә тотучылар.

[2] *Прахуд Мәхүб* — фахишә (академик басмада соңыннан бу эшне ташлап, гаилә тормышы белән яшәгәнлеге әйтелә).

[3] *Дәҗҗал белән Мәһди дигән затлар* — Дәҗҗал — ялганчы зат (хәдисләрдә телгә алына, ахырзаманда үзенә ияргәннәрне, оҗмахка алып барам, дип алдап, тәмугка кертә; христианнарда: Антихрист). Мәһди хәдисләрдә телгә алына, ахырзаманда халыкларны туры юлга күндерүче. Фельетонда бу образларны кулланып, Тукай Төркиядәге хәлләргә үз мөнәсәбәтен белдерә, «Яшь төрекләр»нең хакимияткә килгәч алып барган сәясәтләрен тәнкыйтьли.

[4] *«Осуле кадимче»* — Тукайның үз әсәре (1908 елда басылган).

[5] *«Әминтәзәк»* — дини эчтәлекле, фарсы телендәге тезмә әсәр (китап).

[6] *«Икътисад» журналы* — 1908–1913 елларда Самарада чыккан журнал.

229 бит.

**Сәгъде Вәкъкас әфәндегә.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 29 нчы (18 ноябрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Сәгъде Вәкъкас имзалы бер автор (бу кеше Сәгыйть Сүнчәләй дигән фикер бар) «Шура» журналының 1911 елгы 18 нче (15 сентябрь) санында Тукайның «Мияубикә» исемле шигыренә уңай рецензия бастыра һәм кимчелеге итеп рифмаларының «ямьле оеша алмаулары»н, «өстән-өстәнлек»леген күрсәтә. Тукайның бу язмасы шушы рецензиягә җавап булып тора.

[1] *Мин, димен мин!* — С.Рәмиевнең «Мин» дигән шигыреннән («Әнә алар» урынында С.Рәмиевтә «Аллалар» сүзе).

231 бит.

**Гарәпчә яңа масдарлар.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 29 нчы (18 ноябрь) санында басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

231 бит.

**Татарчага сарыф, нәхү язучыларга ихтар.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 29 нчы (18 ноябрь) санында имзасыз басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

1 *«Ярты алма»* — дини хикәяләр китабы.

2 *Хәсән Гали* (1870–1940) — тел белгече, фольклорчы, «Мөгаллим» журналы (Оренбург, 1913–1914) нашир һәм редакторы.

3 *Габдулла Гыйсмәти әфәнде* (1883–1938) — Тукайның дусты, 1912 елда аны кымызга озатып җибәрә; журналист, сәясәт эшлеклесе.

## 1912

234 бит.

**Былтырның хисабы.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 31 нче (1 гыйнвар) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган (билгеле, бу хисап 1911 елның декабре азагында ук язылган). Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

1 *утыз яшенә җитеп* — 30 саны чыкты мәгънәсендә.

2 *Һади әфәнде* — Һади Максудиның «Йолдыз» газетасындагы мәкаләләренә ишарә.

3 *«Новое время»дә Мишников* — Петербургта чыккан «Новое время» газетасының редакторы М.О.Меньшиков истә тотыла.

4 *Троицкий Мирфәйзә* — җырчы Мирфәйзә Бабаҗанова, Казанда «Буф» исемле кинотеатрда да чыгышлар ясаган.

5 *Габди* — Галимҗан Ибраһимов.

6 *Камчылы ишан* — Яңа бистә ишаны Габдесаттар, өшкергәндә камчы кулланган.

7 *Түнтәр тарафыннан Дәҗҗал мәлгунь* — Түнтәр авылы ишаны Ишмөхәммәд Динмөхәммәдев.

8 *Троицкидә «Акмулла»* — бу сатирик журнал Троицкида 1911–1916 елларда чыккан, редакторы Хәбибрахман Ганиев.

9 *Маймыл Хафиз... театр сәхнәсендә дә күренә* — Мөхәммәтҗан Әхмәрев турында сүз бара, ул Г.Камалның «Безнең шәһәрнең серләре» пьесасындагы Шкафчы образының прототибы.

10 *Аксак Низами* — җәдитчеләргә каршы язылган «Китабел-җәдит ли-ибталил-җәдит, яхуд Мисыр каргасы» исемле көйле китапчык авторы.

11 *Һирман вә Франс атлы ике «зур маэмай»* — Германия белән Франциянең Марокко өчен сугышулары турында сүз бара.

12 *Магулстан исемендә олугъ вилайәт* — Монголия аерым дәүләт булып яши башлый.

13 *әфәнде хәзрәтләре белән Шаляпин лакееның дуэле булды* — әфәнде — Камил Мотыйгый.

14 *«Идел» фельетонында «Живой труп» тәрҗемә ителә* — бу газетада Л.Толстой әсәрен тәрҗемә итеп бастыручы — Сәгыйть Рәмиев.

15 *Һади Атласов «тик тора алды»* — биредә бу тарихчының «Тик тора алмыйм» исемле мәкалә бастыруына («Шура» журналы, 1909, 24 нче сан) ишарә ителә.

16 *«В мире мусульманства»* — 1911–1912 елларда Петербургта чыккан газета.

17 *Ахмакшәрик Сапсатасатаров* — драматург, педагог Шәриф Саттаров (1887–1972), шактый примитив эчтәлекле әсәрләр авторы.

18 *«Вакыт» Дорошевиче Шәриф Камал әфәнде эш ташладылар* — Ш.Ка-

мал каләменнән чыккан язмаларның бу газетада бик еш басылуы күз алдында тотыла.

[19] *Мөхәммәтгали шаһ* — Иран шаһы.

239 бит.

**Мәкальле киңәшләр.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 36 нчы (31 март) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

240 бит.

**Яңлыш уйланмасын.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 39 нчы (1 июнь) санында «Г.Тукаев. 26 апрель, 1912 сәнә. Петербург» имзасы белән басылган (кулъязмасы бар). Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

Тукайның «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» исемле шигыре башта «Йолдыз» газетасының 1912 елгы 15 апрель (317 нче) санында, аннары (шагыйрь үзе үк соңрак чыгуын әйтә) «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 37 нче (15 апрель) санында («1912 сәнә, 7 апрель» диелеп) басылган була.

240 бит.

**Хәзер җиләк-җимеш вакыты.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 42 нче (5 август) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Пуришкевич* — Россиянең сәяси эшлеклесе, монархия тарафдары, «Рус халкы союзы» лидерларыннан, эре помещик.

[2] *«Ислах»* — «Әл-ислах» газетасы.

242 бит.

**Динчеләр куаныштылар.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 43 нче (20 сентябрь) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Форштадт* — Оренбург шәһәрендәге урам исеме.

[2] *«Дингә мишәйт»* — «Дин вә мәгыйшәт» журналы.

[3] *«Дүнә вә мишәйт»* — шул ук журнал.

[4] *Вәли мулла* — журналның нашире Вәли Хөсәенев.

243 бит.

**Хаксызлыктан котылдык.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 45 нче (5 ноябрь) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

1912 елның көзендә IV Дәүләт Думасына сайлаулар уздырылганда, «Бәянел хак» газетасының редакторы һәм наширләреннән Мөхәммәтҗан Сәйдәшев сәүдәгәрләр, кайбер муллалар, байлар булышлыгы белән Думага депутат итеп кияве адвокат Шәехгаттар Иманаевны уздырырга тырышып карый (Ш.Иманаев, выборщиклыкка үтсә дә, депутат булып сайланмый. Бу хәлдән көлеп, журналның алдагы санында Ф.Әмирхан да «Кияүне сайладык» исемле фельетон бастырган була. Әлеге вакыйга турында Тукайның «Казан мулласы һәм булачак депутат» дигән шигыре дә бар, журналның шушы 45 нче санында ук басылган).

[1] *Кәмал бәк* — Нәмекъ Кәмал (1840–1888), төрек шагыйре, драматург.

246 бит.

**Тегеннән-шуннан.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 48 нче (22 декабрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Гаяз әфәнденең соңгы «Мулла бабай» романында...* — бу Гаяз Исхакый әсәре.

[2] *бездә бер җырчы* — Камил Мотыйгый.

[3] *«Катын-кыз» имзасы белән* — сүз Маһруй Мозаффариянең «Әл-ислах» газетасында (1907 ел, 1 декабрь) басылган «Мәшһүр хатыннар» исемле шигыре турында бара.

[4] *янында утырган шагыйрь* — Габдулла Тукай үзе.

## 1913

253 бит.

**1912 елның онытылганнан калган гына хисабы.** «Ялт-йолт» журналының 1913 елгы 49 нчы (10 гыйнвар) санында «Счет төймәсе» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Вакыт» белән «Йолдыз» мөхарәбәләре* — бу ике газета битләрендә бер-берсенә каршы чыгулы язмалар басылуга ишарә.

[2] *Ишми ишан* — Ишмөхәммәд Динмөхәммәдев, ишан; бериште гамәлләре белән алдынгы зыялылар тарафыннан тәнкыйтьләнеп торган.

[3] *«Кояш» чыгу* — 1912 елның 10 декабрендә Казанда «Кояш» газетасы чыга башлый (1918 елга кадәр дәвам итә).

[4] *«Аң» чыкты* — 1912 елның 15 декабрендә Казанда «Аң» журналы чыга башлый (1918 елгача дәвам итә).

[5] *Гаяз әфәнде... язып күрсәтте* — Г.Исхакыйның «Теләнче кыз» исемле романында фахишәлек күренешләре дә тасвирланган.

[6] *Садри Максудов профессиясеннән аерылды* — ул елда Дәүләт Думасына сайлаулар уздырылып, С.Максуди депутатлыкка үтми.

[7] *Тимер кендекләр белән сыйпый башладылар* — 1912 елда хулиганнар Г.Камалга кендек белән сугалар.

[8] *кеше плагиатта тотылды* — Тукай Г.Ибраһимовны плагиатта гаепләү вакыйгасын истә тота. Ләкин бераздан бу гаепләүнең нигезсез булуы ачылган.

[9] *Габди* — Галимҗан Ибраһимов.

[10] *Шәһидуллин... тәрҗемәи халь вә монакыйбен бастырды* — календарьчы Шәрәфетдин Шәһидуллинның «Заман календаре»нда аерым кешеләрнең рәсемнәрен бастыруына ишарә ителә.

[11] *Зариф* — Зариф Бәшири.

[12] *«Яман вә тозсыз» календаре* — «Заман календаре».

[13] *Ватан бәйрәме* — 1912 елда 1812 елгы Ватан сугышының йөз еллыгы билгеләп үтелә.

255 бит.

**Юбилей мөнәсәбәте белән.** «Ялт-йолт» журналының 1913 елгы 52 нче (1 март) санында баш мәкалә сыйфатында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Мәкалә Романовлар династиясенең Россиядә патшалык итүенә 300 ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә язылган.

[1] *Әнвәр бәк* — Төркиянең сәяси эшлеклесе Әнвәр паша (1881–1922), «Яшь төрекләр» партиясе эшлеклеләреннән.

258 бит.

**Ике ихтар.** «Ялт-йолт» журналының 1913 елгы 53 нче (15 март) санында «Шүрәле» имзасы, «5 март, 1913 сәнә» датасы белән басылган (Клячкин шифаханәсендә язылган). Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *52 нче номердагы баш мәкалә* — «Юбилей мөнәсәбәте белән» мәкаләсе. «Ике ихтар»да исә Тукай үзенең гимназия һәм приют мәсьәләсенә караган фикерләренә төзәтмә кертергә тиешлеген сиздерә.

259 бит.

**Матбугатымызның «фәсахәт нәмүнәләре».** «Ялт-йолт» журналының

1913 елгы 53 нче (15 март) санында «Гөмберррт» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Мәктәп»* — 1913–1914 елларда Казанда чыккан журнал, нашире Шиһап Әхмәрев.

[2] *Чала татар* — шагыйрь һәм журналист Әкрам Галимов (1892–1913) псевдонимы. Аның белән «Акмулла» журналында чыгыш ясаган.

[3] *«Алдым-бирдем» Галиясе* — Гаяз Исхакыйның «Алдым-бирдем» пьесасындагы Галия исемле кыз.

[4] *Ләбибә* — Ләбибә Хөсәенова (1880–1920), педагог, 1903 елда үз мәктәбен ача (Ләбибә Хөсәения мәктәбе).

262 бит.

**Уянгач беренче эшем.** «Кояш» газетасының 1913 елгы 18 март (74 нче) санында «Габдулла Тукаев» имзасы белән, «Клячкин шифаханәсе, 14 март, 1913 сәнә» дип басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *Ләкми чир, аурып та булмый ичмасам!* — Тукайның «Читен хәл» (1911) исемле шигыренең соңгы юлы.

[2] *400 сәхифәле зурлыгында рәсемле бер мәҗмуга* — 464 битле бу китап — «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре» — Җамал Вәлидинең сүз башы белән 1914 елда басылып чыга.

## ИСТӘЛЕКЛӘР. ЮЛЪЯЗМАЛАР (1909–1912)

266 бит.

**Исемдә калганнар.** Китап булып 1909 елда Казанда («Үрнәк» матбагасы) «Исемдә» сүзе эре хәрефләр белән, шагыйрьнең рәсеме дә урнаштырылып басылган (авторы — «Габдулла Тукаев»)[1]. Әсәрнең «Мөкаддимә»сендә (кереш сүзендә) «Ахыры икенче җөзьәдә» диелгән булса да, әлеге икенче кисәк күренмәде. Күптомлыкларына беренче мәртәбә 1931 елда (өчтомлыкка) кертелгән. Текст 1909 елгы беренче басмадан алынды.

[1] *Мөхәммәтгариф... Мөхәммәтгалим исемле мулланың угылы* — 1842/1843–1886 елларда яшәгән.

[2] *Кушлавыч карьясе* — хәзер Татарстан Республикасының Арча районындагы авыл.

[3] *Кышкар мәдрәсәсе* — хәзерге Арча районындагы Кышкар авылында борынгыдан мәдрәсә эшләп килгән.

[4] *Өчиле карьясе* — Арча районында.

[5] *Зиннәтулла хәзрәт* — Тукай әнисенең әтисе Зиннәтулла Зәйнелбәшир улы, 1829–1909 елларда яшәгән.

[6] *Мәмдүдә* — Тукайның әнисе Бибимәмдүдә Зиннәтулла кызы, 1865–1890 елларда яшәгән.

[7] *Сасна нам карья* — Балтач районындагы Сасна пучинкәсе (авыл).

[8] *үги әтием* — Сасна пучинкәсенең указсыз мулласы Мөхәммәтшакир Фәйзуллин (1819–1916).

[9] *Сәҗидә исемле кыз* — Бибисаҗидә Зиннәтулла кызы (1877–1956).

[10] *Ташаяк базары* — Казанда май аенда була торган ярминкә (урыны — Кремль астында, хәзерге Үзәк стадион һәм цирк каршында).

[11] *Кырлай* — Әтнә районындагы Иске Кырлай авылы.

[12] *Сәгъди* — Сәгъдетдин Шәмсетдин улы Салихов (1837–1904).

[13] *Эни* — Сәгъдетдин хатыны Зөһрә Габделгани кызы.

[14] *Саҗидә* — Сәгъдетдин кызы Бибисаҗидә (1879–1894).

[15] *Сабира* — Сәгъдетдин кызы Бибисабира (?–1892).

---

[1] Китапның 33 нче битендә (аста) «Г.Тукаев. Тәрҗемәи хале» диелгән.

[16] *Мөсафир Бәдретдин абзый* — Бәдретдин (Бәдри) Хисаметдин улы, Тукайның ерак туганы, аны Кырлайдан табып алып Җаекка озатучы.

[17] *Алты-биш Сапый* — Тукайны Казаннан Уральскига алып китүче.

282 бит.

**Кечкенә сәяхәт.** «Ялт-йолт» журналының 1911 елгы 24 нче (15 июнь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган (ахыры күренми). Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *«Нечкә хиссият»ем* — «Ялт-йолт» журналының 1910 елгы 8 нче (1 июль) санында «Шүрәле дию белгәйсез» имзасы белән басылган «Гыйшык уты» исемле юмористик парча.

284 бит.

**Мич башы кыйссасы.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 32 нче (21 гыйнвар) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *1911 сәнә, 29 октябрь* — 29 сентябрь булырга тиеш. Кыйссаның башында «29 сентябрьдә үк зарлана башладым»лыгы әйтелә. 29 октябрь, яңа стиль белән күрсәтсәң, 11 ноябрьгә туры килә, ә салкыннар Казан тирәсендә нәкъ менә сентябрь ахырында була башлый.

[2] *«Бар күңеллелек бөтен дөньяда...»* — Тукайның «Бәйрәм бүген» исемле шигыреннән.

[3] *авылга киттем...* — Тукай Өчиле авылына 1911 елның декабрендә китә.

[4] *Киевтә бер жид министрны үтерде.* — 1911 елда эсер Богров Россиянең эчке эшләр министры Столыпинны үтерә.

289 бит.

**Казанга кайтыш.** «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 35 нче (11 март) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Сәет Баттал* — «Кыйссаи Сәет Баттал» әсәре каһарманы.

[2] *Залим хан* — патша властьларына каршы Кавказда 13 ел буе көрәш алып барган Залимхан Гушмазукаев (1913 елда үтерелә).

[3] *«Сөю — сәгадәт» язган... бер критик* — шул исемдәге хикәя дә язган Галимҗан Ибраһимовның «Йолдыз» газетасында басылган «Әдәбият» дигән мәкаләсенә ишарә ителә.

[4] *«Швейцария» тавы* — хәзер бу җирдә Казанның М.Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркы урнашкан.

[5] *«барабыз»* — ул чорда кешеләрне гади йөк чаналарына утыртып йөртүчеләр (ташучылар).

[6] *генерал Толмачев* — патша генералы, «Рус халкы берлеге» эшлеклесе, халык хәрәкәтләрен бастыруда аяусыз эш иткән карагруһ.

[7] *белә әтәч синең хәрфе җәреңне!* — Үз наданлыгыңны оста җавап белән башка нәрсәгә япсарып кала белүгә мисал йөзеннән әйтелә (Н.Исәнбәт) торган афоризм.

[8] *чалбарчылар* — Казанда оешкан театр труппасы.

297 бит.

**Мәкаләи махсуса.** Беренче кисәге «Ялт-йолт» журналының 1912 елгы 40 нчы (1 июль) санында «Хәкыйрь Шүрәле» имзасы белән, ахырына «Троицк, 20 май, 1912 сәнә» дип куелып, икенче кисәгенең I–V өлешләре журналның 41 нче (15 июль) санында «Сәяхәте көбралар ясаучы Шүрәле» имзасы белән, калган өлешләре 45 нче (5 ноябрь) санында «Шүрәле» имзасы белән басылган. Беренче мәртәбә өчтомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Мөхәррир әфәнде* — журналның редакторы Әхмәт Урманчиев (1880–1922).

[2] *Гаяз әфәнде рисаләсендәге Сөннәтче бабай* — Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» хикәясендәге төп образ (Корбанколый).

[3] *Һинди Минһаҗ дарелфөнүн акчасына «Дөньяда җәннәт вә аның хурлары» ясап ята, ди* — дарелфөнүн салдырам дип җыйган акчаны үз кирәгенә генә тоткан Һинди Минһаҗ Кадермәтевнең китабы Казанда 1912 елда чыккан (әсәре: «Минһаҗетдин Йосыф Кадермәти»; беренче җөзьә).

[4] *«Дәҗҗал» атлы пьеса* — Галиәсгар Камалның 1912 елда язылган һәм басылган драмасы.

[5] *Әхмәтҗан абзыйны... хәдис көтүчесе* — «Бәянел хак» газетасындагы язмаларында Әхмәтҗан Сәйдәшев хәдисләрне күп куллана торган булган.

[6] *«Амуръ»* — ул чакта Казанның Мәскәү (Киров) урамында урнашкан кунакханә. Шифаханәгә керер алдыннан Тукай анда яшәгән.

[7] *Фатих әфәнде Мортазин* — Самара шәһәре мулласы, «Икътисад» журналының нашир һәм редакторы.

[8] *Бичара Рәшит казый гына, микадо мөселман була дигән булып* — Габдерәшит Ибраһимов Япония мөселманлыкка чыга дигән хәбәрләргә ышанып, Япониягә баруы истә тотыла.

[9] *«Тәрҗеман» мөхәррире* — Исмәгыйль Гаспринский.

[10] *Әхмәтфаиз Даудов* — һәвәскәр җырчы. Буби мәдрәсәсе мөгаллиме булган. 1917 елда провокатор диеп кулга алына.

[11] *Латыйпов* — Фәттах Латыйпов (1884–1966), җырчы, артист.

[12] *Муса әфәнде* — Муса Бигиев.

[13] *«Нур» идарәсе* — «Нур» газетасы редакциясе.

[14] *Сафа әфәнде Баязидов* — Петербург мулласы, «Нур» газетасының нашир һәм редакторы.

[15] *Думага керә алмадым* — ул чакларда Дума депутаты булмаган кешеләргә дә бу бинага — Таврида сараена керергә мөмкин булган.

[16] *Г.Баттал әфәнде* — Габделбари Баттал (1880–1969), тарихчы, журналист, җәмәгать эшлеклесе.

[17] *Габдерахман мулла* — Габдерахман Рахманкулов, Тукайны Троицкига чакыручы кеше.

## ХАТЛАР (1902–1913)

314 бит.

**1. Апасы Саҗидәгә.** Күчермәсе Г.Ибраһимов исем. институт Мирасханәсендә саклана (9 ф., 2 тасв., 13 с.б.). Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст күчермәдән алынды (автографы сакланмаган).

Хат Тукай әнисе Бибимәмдүдәнең сеңлесе (башка анадан туган) Бибисаҗидә Зиннәтулла кызына язылган. Бу вакытта ул инде Әхмәтсафа Зариф улы Хәбибуллинда кияүдә булып, аларның хатта телгә алынган Габделваһһаб, Бибимәсрүрә һәм Өммеһани исемле балалары булган.

[1] *Гөлчәһрә* — Саҗидәнең бертуган сеңлесе.

[2] *«Тәркиб»* — мәдрәсә дәреслеге.

[3] *бай туганнарым* — Гурьев шәһәрендәге Әхмәди һәм Әүхәди Абдуловлар.

[4] *ахун җизни* — Мотыйгулла Төхфәтуллин.

[5] *апай* — Газизә Зәбирова, Тукайның апасы (ана башка, Мөхәммәтгарифның әүвәлге хатыны Гафифәдән туган).

[6] *тутамыз Бибигазизә* — Мөхәммәтгариф сеңлесе (ире — Галиәсгар Госманов).

316 бит.

**2. Апасы Саҗидәгә.** Хат Г.Ибраһимов исем. институт Мирасханәсендә саклана (9 ф., 2 тасв., 10 с.б.). Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст Мирасханәдәге кульязмадан алынды.

Хатта исемнәре очраган шәхесләр алдагы хатта да телгә алынды.

[1] *«Шәрхе мелла»* — мәдрәсә дәреслеге (гарәп теле синтаксисы буенча).
[2] *мыеклы әби* — Зиннәтулланың беренче хатыны Камилә.

318 бит.

**3. Туганнары Абдуловларга.** Күчермәсе Мирасханәдә саклана (9 ф., 2 тасв., 19 с.б.). Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст Мирасханәдәге күчермәдән алынды.

[1] *Сираҗетдин хәлфә* — мәдрәсәдә Тукайны укыткан хәлфә.

319 бит.

**4. Пирмөхәммәт Ниязовка.** «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 7 нче (июль) санында басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

320 бит.

**5. Гыйльметдин Шәрәфкә.** «Казан утлары» журналының 1970 елгы 1 нче (гыйнвар) санында (факсимилесы Энҗе Кәримованың «Тукайның ике җыентыгы» исемле мәкаләсе эчендә; ачык хат) басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Хат «Мәтбагаи Шәрәф» (соңрак «Үрнәк», «Мәгариф» дип исемләнгән) хуҗасы Гыйльметдин Шәрәфкә (1885–1943) җибәрелгән. Бу матбагада Тукайның күп кенә китаплары нәшер ителгән.

Хатта сүз барган «Әшгар мәҗмуга»сы (шигырьләр җыентыгы) аерым китап булып 1907 елның ноябрендә, Тукай Казанга кайткач дөнья күрә: «Г.Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр. Беренче кыйсем. — Казан: Шәрәф матбагасы, 1907. — 48 б.).

321 бит.

**6. Гыйльметдин Шәрәфкә.** Хат (өзек) «Аң» журналының 1914 елгы 7 нче санында басылган Гыйльметдин Шәрәф истәлегендә («Тукай тугърысында истә калганнар») китерелгән. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

Хатта телгә алынган «Шүрәле» һәм «Тәрбиятел этфаль»гә» шигырьләре «Г.Тукаев шигырьләре»ндә (3 нче дәфтәр), «Китмибез!» исә «Габдулла Тукаев шигырьләре»ндә («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 4 нче дәфтәр. Икенче кыйсем. — Казан: Шәрәф матбагасы, 1908. — 56 б.) басылган.

321 бит.

**7. Апасы Газизә Госмановага.** «Ил» газетасының 1914 елгы 2 апрель (23 нче) санында басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *«Шүрәле» китабы* — «Г.Тукаев шигырьләре» (3 нче дәфтәр) истә тотыла.
[2] *әнкәмне дә таптым* — Казанда Тукайны кечкенә чагында тәрбиягә алган Мөхәммәтвәли хатыны Газизә турында сүз бара.

321 бит.

**8. Габдулла Кариевкә.** «Мәктәп» журналының 1913 елгы 4 нче (20 апрель) санында басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Габдулла Хәйруллин* — Габдулла Кариевнең чын исем-фамилиясе Миңлебай Хәйруллин булган.
[2] *«Яңа тормыш»* — 1907–1908 елларда Уральскида чыккан газета, редакторы һәм нашире — Мөхәммәтгали Мусин.

322 бит.

**9. Апасы Газизә Госмановага.** «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 5 нче (май) санында басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Бәһави ишәк* — вәисиләрнең дини һәм иҗтимагый-сәяси хәрәкәтен башлап җибәргән Бәһаветдин Вәисев (1804–1893), XX йөз башында бу хәрәкәтне аның улы Гайнан (Гайнанетдин) Вәисев (1878–1918) җитәкләгән. Татар демократик эшлеклеләрендә (аерым алганда Тукайда) вәисиләрнең гамәлләре теләктәшлек тапмаган.

[2] *Әхмәт байның угылы* — Габдерахман Дәүләтшин (элек аны Әхмәт бай Хөсәенев тәрбиягә алган була).

324 бит.

**10. Габдерахман Дәүләтшингә.** Шагыйрьнең шәхси бланк кәгазенә язылган бу хат (үтенеч-мөрәҗәгать; автограф) Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсендә саклана. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст автографтан алынды.

[1] *бер китап бирермен* — биредә сүз 1908 ел ахырында «Сабах» көтепханәсендә чыккан «Җуаныч» яисә «Алтын әтәч» (Пушкиннан тәрҗемә) исемле китаплар турында бара.

[2] *Оренбургка хат яздым. Анда барсам* — Тукай Оренбургка бармый кала.

[3] *Гыйльметдин* — нашир Гыйльметдин Шәрәф.

324 бит.

**11. Фатих Әмирханга.** Мирасханәдә саклана (9 ф., 2 тасв., 9 с.б.). Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст Мирасханәдәге кулъязмасыннан алынды.

[1] *«В.-К.»да «Татарин» имзалы бер зат теге Касыйм Уралецка җавап язды* — Казанда чыга торган «Волжско-Камская речь» газетасында берәү С.Рәмиевне генә үгет-нәсихәтчелектән азат шагыйрь итеп язгач, Касыйм Уралец «Волжский листок» газетасында (Казанда чыккан) М.Гафурины өстен куеп, Тукайны тәрҗемәче итеп күрсәткән була. Бер атнадан «Волжско-Камская речь» газетасында әлеге «Татарин» сүз ала һәм Касыйм Уралецның дөрес фикерләмәвен әйтә.

[2] *«Швейцария», «Аркадия» «Панаевский»ләр* — Казандагы бакчалар, шәһәр халкы ял итә торган урыннар.

325 бит.

**12. Гайнетдин Туприевкә.** Факсимилесы «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 7 нче (июль) санында (Тукайның апасы Газизәнең улы Вәли Зәбирев искәрмәләре белән) басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст факсимиледан алынды.

Хатның автографын исә Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының С.-Петербург филиалына 1935 елда Гайнетдин Туприев үзе тапшырган.

[1] *Рәкыйбе* — Габдерәкыйп Тулбаев, Уральск рухание.

[2] *Ишәк Хәсәнҗаны* — Хәсәнҗан Хөсәенев, сәүдәгәр.

[3] *Камил вә хәзрәтләр* — Камил Мотыйгый һәм Мотыйгулла Төхфәтуллин.

[4] *Фәссах Фәттахев* — «Мотыйгия» мәдрәсәсе мулласы, аннары сәүдәгәр.

[5] *Гайнетдин кари* — Гайнетдин Җәлалетдинов, мулла.

328 бит.

**13. Камалетдин Хисаметдиневкә.** Кулъязмасы (ачык хат) Мирасханәдә саклана (9 ф., 2 тасв., 15 с.б.). Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текст кулъязмадан алынды.

Хат Тукайны Кырлайдан алып кайтып Уральскига озаткан Бәдретдин абзыйның улы Камалетдингә язылган.

[1] *«Дөруссеш шифаһия»* — гарәп телендәге китап («Тел дәресләре»).

328, 329, 330, 331, 332, 333 битләр.

**14, 15, 16, 17, 18, 19. Сәгыйть Сүнчәләйгә.** Бу алты хат «Совет әдәбияты» журналының 1960 елгы 4 нче (апрель) санында басылган. Беренче мәртәбә икенче дүрттомлыкка кертелгән. Текстлар журналдан алынды.

Шагыйрь, тәрҗемәче, драматург Сәгыйть Сүнчәләйгә (1888–1937) язылган бу хатларның күчермәләре генә аның архивында сакланган. Аларны журналга С.Сүнчәләйнең бертуган абыйсы Шәриф Сүнчәләй (1885–1959) тапшырган була.

(14). [1] *саф, яшь мәхәббәт чаткысы* — Тукайның «Өзелгән өмид» шигыреннән.

[2] *Надсонны сөймәдем* — рус шагыйре С.Я.Надсон (1862–1887), күп шигырьләрендә моңсу-сагышлы (кайгылы) кичерешләр чагылыш тапкан.

(15). [1] *«Шильон мәхбүсе»* — инглиз шагыйре Д.Г.Байрон поэмасының Сәгыйть Сүнчәләй эшләгән тәрҗемәсен Тукай төзәтеп чыга һәм матбагага бирә (китап 1911 елда басыла).

[2] *«Мөселман» журналы* — 1908 елда С.-Петербургта чыга башлаган «Мусульманин» журналы.

[3] *М.К.* — Мирсәяф Кырымбаев, Оренбург укытучысы.

(16). [1] *С.Р.* — шагыйрь Сәгыйть Рәмиев.

(17). [1] *«Гасыр»* — 1907 елда Казанда ачылган нәшер һәм сәүдә итү ширкәте.

[2] *«Шура»да «...га» сәрләүхәле бер шигырем бар* — бу шигырь әлеге журналның 1911 елгы 2 нче (15 гыйнвар) санында басылган була.

(18). [1] *«Күңел җимешләре»* — Тукайның 1911 елда басылган шигырьләр җыентыгы.

[2] *«Саташкан», дөрес, Сәгыйть хакында* — Тукайның бу шигыре С.Рәмиевнең «Алданган» шигыренә пародия рәвешендә язылган.

(19). [1] *Габди-Галимҗан* — Галимҗан Ибраһимов.

[2] *Никитин* — рус шагыйре И.С.Никитин (1824–1861).

[3] *Ф.Ә.* — Фатих Әмирхан.

[4] *рәсемле рисалә* — бу әсәр (китап) 1911 елда «Мияубикә» исеме белән басылды.

[5] *«Халык моңнары»* — аның икенче кисәге дөньяга чыкмады.

334 бит.

**20. Сәгыйть Рәмиевкә.** «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә (Казан, 1914) Җамал Вәлиди язган сүз башында басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст «...мәҗмугаи асаре»ннән алынды.

Хат татар дөньясын гаять тә борчыган вакыйгалар тәэсирендә язылган. 1911 елның 30 гыйнварында жандармнар Иж-Бубый мәдрәсәсендә тентү оештыралар. Нәтиҗәдә бер төркем укытучы кулга алына, мәдрәсә ябыла. Бу тентүне оештыруда Ишми ишанның да (Ишмөхәммәд Динмөхәммәдевнең) роле булганлыгы мәгълүм.

335 бит.

**21. Әхмәт Урманчиевка.** «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 5 нче (май) санында (Фәтхи Бурнашның «Талант юлы» мәкаләсе эчендә, факсимилесы белән) басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст факсимилесыннан алынды.

Хат Әстерханнан «Ялт-йолт» журналы нашире һәм редакторы Әхмәт Урманчиевка җибәрелгән.

[1] *Бу мәкаләләрне дөрест басарга иҗтиһад итеңез* — «Ялт-йолт» журналының бу хат язылганнан соң Тукай Казанга әйләнеп кайтканчыга кадәр чыккан 23 нче (4 июль) санында шагыйрьнең «Исемнәремез хакында» исемле фельетоны («Имза: Шәп кеше» имзасы белән), ике рәсем асты язмасы (имзасызлар) урнаштырылган. Сүз шулар турында бара кебек.

335 бит.

**22. Сәгыйть Сүнчәләйгә.** Автографы (кулъязмасы) Мирасханәдә саклана (9 ф., 2 тасв., 8 с.б.). Беренче мәртәбә академик басмага (Сәгыйть Рәмиевкә язылган дип) кертелгән. Текст автографтан алынды.

[1] *Садри* — Садри Максуди.

[2] *мәкаләләреңне укыдым* — «Идел» газетасының 19 октябрь санында С.Сүнчәләйнең «Мусульманин» журналы» исемле мәкаләсе басылган. «Шура» журналында С.Сүнчәләйнең шигырьләре генә күренә.

[3] *М-гә* — Мирсәяф Кырымбаев (автографта башта Мирсәяф дип тутырып язылган була, ләкин сызыла).

[4] *«Мусульманство» һәм «Мусульманин» кешеләре* — «В мире мусульманства» газетасы һәм «Мусульманин» журналы истә тотыла.

336 бит.

**23. Сәгыйть Сүнчәләйгә.** «Тормыш» газетасының 1916 елгы 3 апрель (442 нче) санында басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка (С.Рәмиевкә язылган дип) кертелгән. Текст газетадан алынды.

[1] *яшь хатының / Бер дә генә җуатмыймыни?* — С.Сүнчәләйнең Фәридәгә яңарак кына өйләнгән чагы (беренче хатыны Сәлимә баладан үлгән була).

337 бит.

**24. Гыйльметдин Шәрәфкә.** «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст «...мәҗмугаи асаре»ннән алынды.

Тукай 1911 елның декабрендә Өчилегә китә һәм кышны анда уздыра (әмма Казанга әле чана юлы белән кайткан).

337 бит.

**25. Әхмәт Урманчиевка.** «Совет әдәбияты» журналының 1961 елгы 4 нче (апрель) санында басылган. Беренче мәртәбә биштомлыкка кертелгән. Текст журналдан алынды.

[1] *Фатих* — Фатих Әмирхан.

[2] *Габди* — Галимҗан Ибраһимов.

[3] *Гыйльметдин* — Гыйльметдин Шәрәф.

338 бит.

**26. Әхмәт Урманчиевка.** «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә (1914) Җ.Вәлидинең сүз башында (өзек) басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст «...мәҗмугаи асаре»ннән алынды.

[1] *«Болгар» белән «Шәрекъ»тән өмид өздем* — Тукай яшәгән Казан кунакханәләре.

[2] *Щетинкин вә Колесниковка күчсәм* — Казан кунакханәләре.

339 бит.

**27. Әхмәт Урманчиевка.** Факсимилесы өчтомлыкта (2 нче томда) басылган. Текст шуннан алынды.

[1] *Шакир Мөхәммәдъяров (1883–1964)* — журналист, педагог, юрист.

[2] *Галиәсгар* — Галиәсгар Камал.

[3] *Гыйсмәти* — Габдулла Гыйсмәти (1883–1938), журналист, Тукайны кымызга озатып җибәргән кеше.

[4] *Риза казый* — Ризаэтдин Фәхретдинев.

[5] *«Әсма», «Сәлимә» кеби китаплары* — Р.Фәхретдинев романнары.

[6] *«Җан азыклары»* — Тукайның бу исемдәге җыентыгы 1912 ел ахырында чыккан.

341 бит.

**28. Кәбир Бәкергә.** Кәбир Бәкернең «Тукай Петербургта» исемле кита-

бында (Оренбург, 1914) басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст китаптан алынды.

Хат дусты Кәбир Бәкергә (1885–1944; язучы, публицист) язылган.

[1] *Шакир* — Шакир Мөхәммәдъяров.

[2] *Сафа әфәнде* — Сафа Баязитов.

[3] *Шәрифел Әхмәди* — Шәриф Әхмәтҗанов (1892–1939), бу вакытта студент, соңыннан җәмәгать эшлеклесе.

341 бит.

**29. Гыйльметдин Шәрәфкә.** «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ндә (1914) Җ.Вәлидинең кереш сүзе эчендә басылган. Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст «...мәҗмугаи асаре»ннән алынды.

342 бит.

**30. Әхмәт Урманчиевка.** «Ялт-йолт» журналының 1913 елгы 55 нче (10 июнь) санында басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст журналдан алынды.

Журналның бу саны Тукайга багышлап чыгарылган. Хат исә анда Әхмәднең (Ә.Урманчиевның) «Ялт-йолт» һәм Тукай» исемле язмасы эчендә бирелә.

342 бит.

**31. Фатих Әмирханга.** «Кояш» газетасының 1914 елгы 2 апрель (377 нче) санындагы «Тукай үлем алдыннан» исемле Фатих Әмирхан мәкаләсе эчендә басылган. Томнарына «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре»ннән (1914) башлап кертелеп килә. Текст газетадан алынды.

Табибларның кушуы буенча Тукай Клячкин шифаханәсенә 1913 елның 26 февралендә керә.

342 бит.

**32. Фатих Әмирханга.** Факсимилесы «Татар әдәбияты. XX гасыр» исемле дәреслек-хрестоматиядә (Казан, 1947; төзүчеләре М.Гайнуллин һәм Җамал Вәзиева) басылган. Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст факсимиледан алынды.

[1] *Мәкаләне... баскансыз* — сүз «Уянгач беренче эшем» исемле мәкалә турында бара.

[2] *Шиһаб хәзрәт* — Шиһаб Мәрҗани.

[3] *Зәкәрия абзый* — Зәкәрия Садретдинов, «Кояш» газетасының нашир һәм редакторы.

343 бит.

**33. Әхмәтгәрәй Хәсәнигә.** Кулъязмасы (автограф) Мирасханәдә саклана (9 ф., 2 тасв., 17 с.б.). Беренче мәртәбә беренче дүрттомлыкка кертелгән. Текст Мирасханәдән алынды.

Хат «Аң» журналының нашир һәм редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәнигә (1883—1934) язылган.

[1] *«Бер мөхәрриргә» шигыре* — «Мәктәп» журналының 1913 елгы 3 нче (24 март) санында басылган.

343 бит.

**34. Зәйнәп Хәсәниягә.** Кулъязмасы (автограф) Мирасханәдә саклана (9 ф., 2 тасв., 18 с.б.). Беренче мәртәбә академик басмага кертелгән. Текст Мирасханәдән алынды.

Хат Әхмәтгәрәй Хәсәни хатыны, «Аң» журналы секретаре Зәйнәп Хәсәниягә язылган.

# ЭЧТӘЛЕК

## 1906


Кыямәт көне . . . . . 7
Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? . . . . . 9
Граф Лев Толстой җәнабләре язадыр . . . . . 11
Сүз башы . . . . . 15
Ялкаулык, яхуд Җиңел кәсеп . . . . . 17
Тугъры җавап . . . . . 19
Алай-болай . . . . . 20
Калмичә сөйләү кыйсеме . . . . . 23
Погром . . . . . 27
Уральск имамнарына ачык хат . . . . . 29
Гайниҗамал хәзрәтнең дәхи бер ялганы . . . . . 32
Урамда . . . . . 33
Хакны белеп инкяр кылу . . . . . 34
Шәһәремездәге зур тәмгылы муллаларә бер-ике сүз . . . . . 35
Качыр илә Үрмәкүч . . . . . 35
Идарәдән (Мөхтәрәм рәфикъларымезә гарыз тәшәккер...) . . . . . 37
Идарәдән җаваплар . . . . . 39
«Тәрҗеман»ның кязибе . . . . . 39
Гүзәл бер хакыйкать . . . . . 41
Тугъры сүз . . . . . 42
Алырга ашыгыңыз! . . . . . 43
Ахун хәзрәтләрнең сатылулары . . . . . 43
Яңа дәгъва . . . . . 44
Тимерчыбыксыз телеграм хәбәрләре . . . . . 44
«Өлфәт»кә җавап . . . . . 45
«Заманымызның әдиб вә мөхәррирләренә гаид» мәкаләсенә гаид . . . . . 45
Уральскидә хөррият бәйрәме . . . . . 48
«Җаваб»ә җаваб . . . . . 49
Уральскидә Дума членын вә тәвабигын нагайкалау . . . . . 51
Алданмаңыз! . . . . . 54
Габдерәкыйп хәзрәтнең вәгазе . . . . . 55
Татар диненчә мөселман булу . . . . . 56
Яңа камустан берничә лөгать . . . . . 56
Хиссияте миллия . . . . . 57
Муллалар . . . . . 61
«Казан» чәйханәсендә голяма җәмгыяте . . . . . 64
Уральскидә Думага сайлаулар . . . . . 64
Уральскидә дарелмөгаллимин . . . . . 65
Дәхи бер фетнә . . . . . 67
Уральск хәбәрләре (Уральскидә мәшһүр Мортаза...) . . . . . 68
Уральск хәбәрләре (Бу сәнә «Фикер»...) . . . . . 68
Игълан . . . . . 69
Чит мәмләкәт хәбәрләре . . . . . 69

Уральскидә җәмгыяте хәйрия башлануы . . . 70
Дәхи ниләр күрермез икән? . . . 71
Төрле хәбәрләр. . . . 72
Телсез телеграф хәбәрләре . . . 73
Куркынычлы хәбәр . . . 74
Тимерче . . . 74
Гаҗаиб! . . . 75
Әдәбият ахшамы, яки Литературный-музыкальный вечер . . . 75
Ләтыйфә . . . 78
Кызыкка очрау . . . 79
«Тәрҗеман»ның татарларга галякасе . . . 81
Янә «Тәрҗеман»га . . . 82
Уральск хәбәрләре ( Бу арада гына...) . . . 83
«Чүкеч»тән . . . 84
Җен берлә Убыр . . . 84
Гаҗәп түгелме? . . . 85
Мосаләхә . . . 86
Телеграмнар . . . 86
Шартлар . . . 87
Казанда никях мәҗлесе . . . 88
*** («Уклар» гали фикерле...) . . . 89
Сәдәхә . . . 89
Уральск хәбәрләре (Шәһәремезнең яшьләре...) . . . 90
Мөселманнарны ни өчен особый группага бүләләр? . . . 91
Мөһим эш — имамнар җәмгыяте . . . 92
Уральскидә сайлаулар . . . 94
Җәмгыяте хәйрия . . . 97
Театрының файдасын халыкка ничек төшендерәмез һәм хәзрәтләрдән ничек дөрестләтәмез? . . . 100
Һәркимиң кәндинчә вардыр ля мөхаль әндишәси . . . 102

## 1907

Төш күрдем . . . 105
Тәшәккер . . . 108
Уральск хәбәрләре . . . 109
Кабергә киткән «Фикер» яңадан терелеп кайтты . . . 110
Идарәдән (Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин...) . . . 110
Тәкрар әйтәмез . . . 111
Шигырьләремез . . . 112
Ана мәктүбләре . . . 115
Партияләр . . . 123
Думаның хәле . . . 125
4 май — җомга . . . 126
Тәнкыйть — кирәкле шәйдер . . . 130

## 1908

Бәйрәм, без вә руслар . . . 133
Август башы . . . 135

Яңа гәзитәләр (Казанда иске-москылар...) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Казанда базар бәһаләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Төрлечә дөнья тану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 136
Хикәя . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Лөгатьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
Чыбыксыз телеграм хәбәрләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Кемнәрнең ни дисәң котлары чыга? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Төрле хайваннар тугърысында бераз мәгълүмат . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Мин шушылар илә милләтче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Төшемдә күргәннәрем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Мәкальләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 145
Словарьдан фал ачу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Гәзитәләрдән («Бәянел хак» гәзитәсенең...) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Хәзерге заманча сөйләшүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 149

**1909**

Ахыр көрәшүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Актык сүзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Матбугат каһарманнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
«Безнең заман» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Татарча театр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Милләтче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
«Безнең заман» вә Сәгъди абзый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

**1910**

Сабын ашаганнар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Ике хәзрәт вә извозчик . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 158
Гаҗәп талантлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
«Яшен» мәрхүм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Кеше — хайваннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Керешү хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Акыллы башлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Фәлсәфи сүзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
«Гыйшык» уты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Бозау кадәрле зур фәлсәфә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Толстой хакында мәшһүр татарларның фикерләре . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Милләткә файда урынына зарар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 173
Фәлсәфә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Мөфти җүбәләе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
Галиәсгар әфәнде Камалның 10 еллык юбилейсе . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Мөкаддимә («Үземезнең яңа үсеп килмәктә...») . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Халык әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 185

**1911**

Әстерхан мөзакәрәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
Яңа әсәрләр («Хәмитнең хәяты») . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Исемнәремез хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Хикәя язарга теләүче яңа әдипләргә үрнәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212

Идарәдән җаваплар . . . 213
Мөкаддимә (Арамызда әдәбият вә шигырь...) . . . 215
Аз гына төзәтү . . . 216
Русчадан дөрест тәрҗемәләр . . . 217
Өч баш . . . 218
«Ялт-йолт» идарәсеннән сөальләр . . . 225
Сәгъде Вәкъкас әфәндегә . . . 229
Гарәпчә яңа масдарлар . . . 231
Татарчага сарыф, нәху язучыларга ихтар . . . 231

**1912**

Былтырның хисабы . . . 234
Мәкальле киңәшләр . . . 239
Яңлыш уйланмасын . . . 240
Хәзер җиләк-җимеш вакыты . . . 240
Динчеләр куаныштылар . . . 242
Хаксызлыктан котылдык . . . 243
Тегеннән-шуннан . . . 246

**1913**

1912 елның онытылганнан калган гына хисабы . . . 253
Юбилей мөнәсәбәте белән . . . 255
Ике ихтар . . . 258
Матбугатымызның «фәсахәт нәмунәләре» . . . 259
Уянгач беренче эшем . . . 262

**Истәлекләр. Юлъязмалар (1909–1912)**

Исемдә калганнар . . . 266
Кечкенә сәяхәт . . . 282
Мич башы кыйссасы . . . 284
Казанга кайтыш . . . 289
Мәкаләи махсуса . . . 297

**Хатлар (1902–1913)**

1. Апасы Саҗидәгә. *Уральск, 1902 ел* . . . 314
2. Апасы Саҗидәгә. *Уральск, 1903 ел, 30 июнь* . . . 316
3. Туганнары Абдуловларга. *Уральск, 1904 ел, 26 апрель* . . . 318
4. Пирмөхәммәт Ниязовка. *Уральск, 1904 ел, 11 декабрь* . . . 319
5. Гыйльметдин Шәрәфкә. *Уральск, 1907 ел, 9 июнь* . . . 320
6. Гыйльметдин Шәрәфкә. *Уральск, 1907 ел, 5 июль* . . . 321
7. Апасы Газизә Госмановага. *Казан, 1907 ел, 30 декабрь* . . . 321
8. Габдулла Кариевкә. *Казан, 1907 ел, 30 декабрь* . . . 321
9. Апасы Газизә Госмановага. *Казан, 1908 ел, 27 март* . . . 322
10. Габдерахман Дәүләтшингә. *1908 ел, 9 июнь* . . . 324
11. Фатих Әмирханга. *Казан, 1908 ел, 23 июнь* . . . 324
12. Гайнетдин Туприевкә. *Казан, 1909 ел, 13 март* . . . 325
13. Камалетдин Хисаметдиневкә. *Казан, 1910 ел, 25 сентябрь* . . . 328
14. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1910 ел, 9 ноябрь* . . . 328

15. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1910 ел, 4 декабрь* . . . . . . . . . . . . . . 329
16. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1911 ел, 1 гыйнвар* . . . . . . . . . . . . . 330
17. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1911 ел, 22 гыйнвар* . . . . . . . . . . . . . 331
18. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1911 ел, 11 февраль* . . . . . . . . . . . . . 332
19. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1911 ел, 4 март* . . . . . . . . . . . . . . . . 333
20. Сәгыйть Рәмиевкә. *Казан, 1911 ел, 4 март* . . . . . . . . . . . . . . . . . 334
21. Әхмәт Урманчиевка. *Әстерхан, 1911 ел, 5 май* . . . . . . . . . . . . . . 335
22. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1911 ел, 20 октябрь* . . . . . . . . . . . . . 335
23. Сәгыйть Сүнчәләйгә. *Казан, 1911 ел, 15 ноябрь* . . . . . . . . . . . . . . 336
24. Гыйльметдин Шәрәфкә. *Өчиле, 1912 ел, 1 гыйнвар* . . . . . . . . . . . . 337
25. Әхмәт Урманчиевка. *Өчиле, 1912 ел, 1 гыйнвар* . . . . . . . . . . . . . 337
26. Әхмәт Урманчиевка. *Өчиле, 1912 ел, гыйнвар* . . . . . . . . . . . . . . . 338
27. Әхмәт Урманчиевка. *Уфа, 1912 ел, 2 май* . . . . . . . . . . . . . . . . . 339
28. Кәбир Бәкергә. *Уфа, 1912 ел, 12 май* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 341
29. Гыйльметдин Шәрәфкә. *Троицк, 1912 ел, 2 июнь* . . . . . . . . . . . . 341
30. Әхмәт Урманчиевка. *Казан, 1913 ел, 10–25 гыйнвар* . . . . . . . . . . . 342
31. Фатих Әмирханга. *Казан, Клячкин шифаханәсе, 1913 ел, февраль (?)* . . 342
32. Фатих Әмирханга. *Казан, Клячкин шифаханәсе, 1913 ел, 18 март* 342
33. Әхмәтгәрәй Хәсәнигә. *Казан, Клячкин шифаханәсе, 1913 ел, 20 март* 343
34. Зәйнәп Хәсәниягә. *Казан, Клячкин шифаханәсе, 1913 ел, 28 март* 343

**Искәрмәләр һәм аңлатмалар** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344

Литературно-художественное издание

**Тукай Габдулла**
(**Тукаев** Габдулла Мухамметгарифович)

ИЗБРАННЫЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ
В двух томах
**Том 2**

Составители: **Э.Галимзянова, З.Шайхелисламов, З.Рамиев**

Казань. Татарское книжное издательство. 2006

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Тукай Габдулла**
(**Тукаев** Габдулла Мөхәммәтгариф улы)

САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР
Ике томда
**2 том**

Төзүчеләре: **Э.Галимҗанова, З.Шәйхелисламов, З.Рәмиев**

Мөхәррирләре *Р.Х.Корбанов, Ф.М.Хафизов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректорлары *С.Н.Галимуллина, Г.М.Хәбибуллина, Л.З.Шиһапова, Г.Г.Гарифуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.03.2006. Форматы 84×108 $^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 20,16+форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 21,42.
Нәшер-хисап табагы 21,44+форз.0,36. Тиражы 3000. Заказ З-171

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.